Фәкыйһ Әбү Ләйс Сәмәрканди

# تَنْبِيهُ الْغَافِلِينَ

# Тәнбиһүл гафилин

*(Гафилләрне уяту)*

# II

Казан 2004
«МАТБУГАТ ЙОРТЫ» НӘШРИЯТЫ

ББК 86.38
Т12

*Татарстан Республикасы Казан иҗтимагый Хәйрия фонды*
*«Ду'а Мәдәни – рухи мирас»*

Т12 Тәнбиһүл гафилин.– Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты. 2004.– 442 б.

Сәмәрканд шәһәренең галиме Фәкыйһ Әбү Ләйс Сәмәрканди разыяллаһү ганһүнең ике өлештән торган "Тәнбиһүл гафилин" (Ваемсызларны уяту) китабының икенче бүлеге тәкъдим ителә. Бу китап кешеләрне дингә чакыру һәм диндә булып та, Аллаһы Тәгаләне зекер итүне, Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең сөннәтен һәм олуг кешеләрнең хикмәтле сүзләрен фикерләүне калдырып, гафләттә булучылар өчен үгет-нәсыйхәттер. Бөек галим Әбү Ләйс рахмәтуллаһи галәйһи китапны укучыга бирелгән хәдисләр һәм хикмәтләр белән гамәл кылуны, нәфес белән көрәшүне һәм моны башкаларга да ирештерүне безгә васыять итте.

ISBN 5-94259-123-7 © «Матбугат йорты» нәшрияты, 2004

## Садака хуҗасын нәрсәдән саклый?

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Фәрәҗдән риваять итә. Ул әйтте: «Гайсә галәйһиссәләм бер авылдан үтте. Ул авылда кер юучы бар иде. Авыл халкы: «Әй Гайсә, бу кер юучы өсләребездәге киемнәребезне ерта да, ул киемнәрне кайтармый тора. Син Аллаһы Тәгаләдән ул кер юучыны кер салган савыты белән өенә кайтармауны сора», – диделәр. Гайсә галәйһиссәләм әйтте: «Әй Аллаһым, ул кер юучыны савыты белән өенә кайтарма». Риваять итүче әйтте: «Кер юучы киемнәрне юарга дип китте. Аның янында өч күмәч бар иде. Бер гыйбадәт кылучы кер юучы янына килде. Гыйбадәт кылучы шул тауларда гыйбадәт кыла иде. Ул кер юучыга сәлам биреп әйтте: «Мине ашатырга синең икмәгең бармы яисә миңа күрсәтер идең, мин ул икмәккә карар идем һәм шул икмәкнең исен иснәр идем. Чөнки мин фәлән вакыттан бирле икмәк ашаганым юк». Кер юучы гыйбадәт кылучыга бер күмәчне ашатты. Гыйбадәт кылучы әйтте: «Әй кер юучы, синең гөнаһларыңны Аллаһы ярлыкасын һәм синең күңелеңне пакьләсен». Кер юучы гыйбадәт кылучыга икенче күмәчен бирде. Гыйбадәт кылучы әйтте: «Әй кер юучы, Аллаһы Тәгалә синең башта кылган һәм соңыннан кылган гөнаһларыңны ярлыкасын». Кер юучы аңа өченче күмәчен дә ашатты. Гыйбадәт кылучы әйтте: «Әй кер юучы, Аллаһы Тәгалә сиңа җәннәттә бер бина әзерләп куйсын». Кер юучы кич белән өенә сәламәт хәлдә кайтты. Ул авылның әһелләре Гайсә галәйһиссәләмгә әйттеләр: «Әй Гайсә, дөреслектә бу кер юучы кайтты». Гайсә галәйһиссәләм: «Аны чакырыгыз», – диде. Кер юучы Гайсә галәйһиссәләмгә килгәч, Гайсә галәйһиссәләм

әйтте: «Әй кер юучы, бүген нинди гамәл кылганыңны миңа сөйләп бир. Кер юучы әйтте: «Минем яныма бер гыйбадәт кылучы килде. Миннән ашарга сорады. Мин аңа өч күмәч ашаттым. Ашаткан һәрбер күмәчем өчен дога кылды». Гайсә галәйһиссәләм әйтте: «Кер савытыңны китер, мин ул савытка карыйм әле». Кер юучы савытын ачып караса, ул савытта кара елан ята һәм ул тимердән ясалган йөгән белән йөгәнләнгән. Гайсә галәйһиссәләм әйтте: «Әй кара елан». Кара елан: «Әй Аллаһының пәйгамбәре, нәрсә боерасың? Бу кешегә зарар өчен җибәрелгән идең түгелме?» – дип сорады. Елан әйтте: «Әйе. Ләкин ул кер юучыга таулардан бер гыйбадәт кылучы килде һәм ашарга сорады. Кер юучыга һәр ашаткан күмәче өчен ул төрле дога кылды, аның янындагы фәрештә, кабул ит, дип тора иде. Аллаһы Тәгалә бер фәрештәне минем өчен җибәрде һәм ул фәрештә мине тимер йөгән белән йөгәнләде». Гайсә галәйһиссәләм әйтте: «Гамәлеңне баштан кыл, таулардагы гизүчегә биргән садакаң бәрәкәтендә Аллаһы Тәгалә сине ярлыкады».

Әбү Җәгедтән риваять ителә. Ул әйтте: «Бер хатын юлга чыкты, янында баласы бар иде. Бүре килеп хатынның баласын урлады. Хатын баласын эзләп чыкты, кулында күмәче бар иде. Аның каршысына бер сорanучы каршы очрады. Хатын күмәчен сорanучыга ашатты. Бүре аның баласы белән кире килеп, баласын кайтарды. Гаибтән бер тавыш ишетелде: «Бер кисәк бәрабәренә бер кисәк».

Мөгътәб бине Сәмйидән риваять ителә. Мугътәб әйтте: «Бәни Исраилдән бер рухани үзләренең гыйбадәтханәләрендә алтмыш ел гыйбадәт итте. Бер көнне кырларга карады, ул җир руханины гаҗәпләндерде. «Ул җиргә төшсәм, анда йөрсәм, аңа

карасам», – диде. Үзе белән күмәч алды. Бу руханига бер хатын очрады, ул хатын аңа йөзен ачты. Шул хатын сәбәпле рухани фетнәләнде. Үз-үзен тота алмады һәм бу халәттә аңа үлем ирешге. Рухани янына соранучы килде. Соранучыга күмәчен бирде, үзе үлде. Алтмыш ел гыйбадәтенең савабы кайтарылып, үлчәүнең бер табагына хата кылган эше китерелеп икенче табакка куелды. Руханиның бер гөнаһысы басты. Күмәч биргәннең әҗере алтмыш ел гыйбадәт янына куелган иде, гөнаһысын басты. Бер риваятьтә: садака явызлыкның җитмеш ишегенә, дип әйтелде.

Әбү Зәрр разыяллаһү ганһүдән һәм Катәдәдән риваять ителә. Алар әйттеләр: «Безгә зекер ителде: су утны сүндергән кебек садака хатаны сүндерә».

Гайшә разыяллаһү ганһәдән риваять ителә. Беркөнне ул утырып торганда, аңа бер хатын килде, кулын җиң эченә яшергән иде. Гайшә разыяллаһү ганһә әйтте: «Сиңа ни булды, кулыңны җиңеңнән чыгармыйсың». Хатын әйтте: «Әй мөэминнәр анасы, миннән сорама». Гайшә разыяллаһү ганһә әйтте: «Миңа хәбәр бирүеңнән һич чара юк». Хатын әйтте: «Әй мөэминнәр анасы, минем атам-анам бар иде. Атам садака бирүне сөя, әмма анам исә садакага ачулана иде. Ул анамның бер генә нәрсәне дә садака итеп биргәнен күрмәдем, мәгәр хайванның эч мае кисәген һәм бер иске киемне садака итеп биргәнен күрдем. Атам белән анам үлгәч төш күрдем. Кыямәт көне булган имеш, анамны халык арасында күрдем, аның кулында май кисәге иде. Хәлбуки, анам ул майны ялый, әй сусызлык, дип кычкыра иде. Атамны күл янында күрдем, ул аннан су эчә. Атам каршында су эчертүдән дә сөеклерәк садака юк иде. Бер савыт белән су алып анамны эчерттем. Югарыдан тавыш

килде: «Аң булсын, әгәр берәү ул хатынга су эчертсә, шул бәндәнең кулы корыр». Уянганда, тәхкыйк, кулым корыган иде».

Бер вакыт Мәлик рахимәһуллаһ утырып торганда соранучы килде һәм аңардан бер әйбер сорады. Мәликнең бер савыт хөрмәсе бар иде. Мәлик үзенең хатынына әйтте: «Хөрмә савытын миңа китер». Мәлик савытны алып соранучыга хөрмәнең яртысын бүлеп бирде, яртысын хатынына кайтарды. Хатыны аңа әйтте: «Синең кебек кешегә заһид дип әйтәләр. Кемнең дә булса падишаһка сынык бүләк җибәргәнен күргәнең бармы?» Мәлик соранучыны чакыртып калган хөрмәне дә бирде. Аннан соң хатынына карап әйтте: «Әй хатын, тырыш, моның соңында тырыш, чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ خُذُوهُ فَغُلُّوهُ . ثُمَّ الْجَحِيمَ صَلُّوهُ . ثُمَّ فِي سِلْسِلَةٍ ذَرْعُهَا سَبْعُونَ ذِرَاعًا فَاسْلُكُوهُ ﴾

«Аллаһ газаб фәрештәләренә әйтер: "Ул кешене алыгыз, аны богаулагыз! Соңра аны җәһәннәм утында яндырыгыз! Соңра аны җитмеш аршын озынлыктагы чылбыр белән урагыз!» («Хаккат» сүрәсе, 30-32)

Бу кадәр катылык кайдан дип әйтелә. Мәлик әйтте:

﴿ إِنَّهُ كَانَ لَا يُؤْمِنُ بِاللَّهِ الْعَظِيمِ . وَلَا يَحُضُّ عَلَى طَعَامِ الْمِسْكِينِ ﴾

«Чөнки ул, әлбәттә, олуг булган Аллаһыга ышанмый иде. Дәхи ул үзен һәм әһелен мескеннәрне ашатырга кызыктырмый иде». («Хаккат» сүрәсе, 33, 34)

Әй хатын, бел, дәреслектә, без муеныбыздан ул чылбырның яртысын иман белән ташладык. Икенче яртысын садака белән ташлавыбыз тиешле булды».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән риваять итә. Ул әйтте: «Бер кыр гарәбе йөремсәк булды һәм садаканы аз бирә иде. Арык куй бәрәнен садака итте. Төш күрде, гүя аның уйлары моңа каршы караганнар. Куйларының һәркайсы хуҗаны таптыйлар, әмма арык бәрәнне таптаудан саклый иде. Уянгач гарәп әйтте: «Аллаһ белән ант итәм, әгәр көчем җитсә, синең юлдашларыңны, әлбәттә, күп кылырмын». Риваять итүче әйтте: «Моннан соң бирә торган һәм бүлә торган булды».

Гади бине Хатимнән риваять ителә: ул әйтте: «Рәсүлуллаһ әйтте:

عن عدي بن حاتم ﷺ قال : قال رسول الله ﷺ :"ما منكم من أحد إلا سيكلمه ربه ، فينظر أيمن منه فلا يرى إلا شيئا قدمه ، ثم ينظر أشأم منه فلا يرى إلا شيئا قدمه ، ثم ينظر أمامه فلا يرى شيئا إلا النار فاتقوا النار ولو بشق تمرة"

«Сезнең һәркайсыгыз Раббысы белән сөйләшер, уң тарафына карар, үзенең элек кылганыннан башка һичнәрсә күрмәс. Моннан соң сул ягына карар, үзенең элек кылганыннан башка һичнәрсә күрмәс. Моннан соң алдына карар, тәмугтан башканы күрмәс. Хөрмә кисәге белән булса да тәмугтан сакланыгыз».

Фәкыйһ әйтте: «Ун төрле хасият бәндәне изгеләр мәртәбәсенә ирештерә. Ул хасиятләр белән дәрәҗәләргә ирешә:

1. садака күп бирү;

2. Коръәнне күп уку;

3. ахирәтне искә төшерә торган һәм аны дөньяда заһид кыла торган кеше белән бергә утыру;

4. кардәшләр хәлен белү;

5. авыру кешенең хәлен белү;

6. байлыклары ахирәт кайгысын бетерә торган байлар белән аз аралашу;

7. иртәгәсе көн башына киләчәк нәрсә хакында күп уйлау;

8. өметнең кыска булуы һәм үлемне күп искә төшерү;

9. тик торуның тиешлеге һәм сүзнең азлыгы;

10. кече күңеллелек, түбәнчелек киеме, фәкыйрьләрне сөю, ярлылар белән аралашу, ятимнәргә һәм мескеннәргә якын булу һәм аларның башларын сыйпау;

Җиде хасият садаканы зурайта һәм тәрбия итә:

1. садаканы хәләл малдан чыгару. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте: ﴿ فقوا من طيبات ما كسبتم ﴾ «Тапкан малыгыздан яхшысын бирегез». («Бәкара» сүрәсе, 267)

2. Аз малдан садака бирү;

3. Садака бирелми калудан куркып, аны ашыктыру;

4. Саранлыктан курыкканлыктан садаканы ихлас кылыр, ягъни садаканы малының иң күркәменнән бирер, начарыннан бирмәс. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ ولا تيمموا الخبيث منه تنفقون ولستم بآخذيه
إلا أن تغمضوا فيه واعلموا أن الله غني حميد ﴾

«Садакага начарын аралаштырып бирмәгез. Ул начар малны алмассыз, мәгәр онытып, ялгышып кына алырсыз. Белегез, Аллаһы Тәгалә бай һәм мактаулы». («Бәкара», сүрәсе, 267) Әгәр сезнең икенче берәүдә бурычыгыз булса, белмәгәндә генә начар малны алырсыз.

5. Риядан куркып садаканы яшерен бирү.

6. Савапны бушка җибәрүдән куркып, садакадан миннәтне ерак кылыр.

7. Гөнаһтан куркып садака алучыны рәнҗетүдән тыяр, чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ لَا تُبْطِلُوا صَدَقَاتِكُمْ بِالْمَنِّ وَالْأَذَى ﴾

«Садакаларыгызны миннәт һәм рәнҗетү белән биреп әҗерен бушка җибәрмәгез». («Бәкара» сүрәсе, 264)

## Рамазан аеның фазыйләтләре

عن ابن عباس ﷺ أنه سمع النبي ﷺ يقول : "إن الجنة لتنجد وتزبن من الحول إلى الحول ، لدخول شهر رمضان ، فإذا كان أول ليلة من رمضان هبت ريح من تحت العرش يقال لخا المثيرة ، فتصفق ورق أشجار الجنة وحلق المصاريع ، فيسمع لذلك طنين لم سيمع السامعون أحسن منه ، فتبرز الحور العينحتى يقمن على شرف الجنة فينادين : هل من خاطب إلى الله تعالى فيزوجه الله سبحانه وتعالى منا ؟ ثم يقلن : يا رضوان ، ما هذه الليلة؟ فيجيبهن بالتلبية ، فيقول : يا خيرات حسان ، هذه أول ليلة من شهر رمضان ، ويقول الله: سا رضوان ، افتح أبواب الجنان للضائمين من أمة محمد ﷺ ، ويقول: يا جبريل اهبط إلى الأرض فصفد مردة الشياطين ، وغلهم بالأغلال ، ثم اقذفهم في لحج البحار ، حتى لا يفسدوا على أمة حبيبي محمد صيامهم ، فيقول الله تعالى في كل ليلة من شهر رمضان ثلاث مرات : هل من شائل فأعطيه سؤله؟ هل من تائب فأتوب عليه؟ هل من مستغفر فأغفر لهظ ثم ينادي مناد : من يقرض الملئ غير المعدم ، الوفي غير الظلوم.

وإن لله تعالى في كل يوم من شهر رمضان عند الإفطار ألف عتيق من النار كلهم قد استوجبوا العذاب ، فإذا كان يوم الجمعة وليلة الجمعة أعتق في كل ساعة منها ألف ألف عتيق من النار كلهم من أول الشهر إلى آخره ، فإذا كانت ليلة القدر يأمر الله تعالى جبريل فيهبط في كبكبة من الملائكة إلى الأرض ، ومعه لواء أحضر فيركزه على ظهر الكعبة ، له ستمائة جناح منها جناحان لا يتشرهما إلا في ليلة القدر ، فينشرهما تلك الليلة فيجاوزان المشرق والمغرب ، فيعث جبريل الملائكة في هذه الأمة ، فيسلمون على كل قائم وقاعد ومصل وذاكر ، ويصافحوهم ويؤمنون على دعائهم حتى يطلع الفجر.

فإذا طلع الفجر نادى جبريل عليه السلام يا معشر الملائكة ؛ الرحيل ؛ فيقولون : يا جبريل ما صنع الله في حوائج المؤمنين من أمة محمد ﷺ؟ فيوقل : إن الله تعالى نظر إليهم وعفا عنهم وغفر لهم ، إلا أربعة ن فقالوا : ومن هؤلاء الأربعة؟ قال : مدمن خمر ، وعاق لوالديه ، وقاطع الرحم ، ومشاحن ، قسل : يا رسول الله ، ومن مشاحن؟ قال : هو المصارم ، يعني الذي لا يكلم أخاه فوق ثلاثة أيام.

فإذا كانت ليلة الفطر سميت تلك الليلة ليلة الجائزة ، فإذا كانت غداة الفطر بعث الله الملائكة في كل البلاد فيهبطون إلى الأرض ، فيقومون على أفواه السكك فينادون بصوت يسمعه جميع ما خلق الله تعالى إلا الجن والإنس ، فيقولون : ياأمة محمد ، اخرجوا إلى رب كريم ، يعطي الجزيل ويغفر الذنب العظيم.

فإذا برزوا إلى مصلاهم ، يقول الله جل جلاله لملائكته : ياملائكتي ما جزاء الأجير إذا إذا عمل عمله؟ فتقول الملائكة : إلهنا وسيدنا ، جزاؤه أن

توفيه أجره ، فيقول الله تعالى : فإني أشهدكم يا ملائكتي أني قد جعلت ثوابهم من صيامهم شهر رمضان وقيامهم رضائي ومغفرتي ، فيقول الله تعالى : يا عبادي سلوني ، فوعزتي وجلالي لا تسألونني اليوم شيأ لدينكم ودنياكم إلا أعطيتكم إياه".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Ибен Габбастан риваять итә. Ул Пәйгамбәр галәйһиссәләмнең әйткәнен ишетте: «Дөреслектә, Рамазан ае кергәндә, җәннәт елдан-ел зиннәтләнә һәм хәзерләнә. Әгәр Рамазан киченең башы булса, Гареш астында җил исәр. Ул җилне «Мәсира» дип атыйлар. Оҗмах агачларының яфраклары, ишек капкачларының бозҗ-ралары селкенер, бу хәлдә сөенеч авазы ишетелер. Ишетүчеләр ул аваздан күркәмрәк аваз ишетмәделәр. Хур кызлары, хәтта җәннәтнең югары урыннарына басканга кадәр чыгарлар. «Безне Аллаһы Тәгаләдән яучылап сораучы бармы? Аллаһы Тәгалә ул яучыны безгә өйләндерсен иде», – диярләр. Соңыннан әйтелер: «Әй җәннәт башлыгы, бу нинди кич?» Ризван ул хур кызларына: «Ни кушсагыз шуны әзерләрмен», – дип җавап бирер. Әй күркәм изге кызлар, бу кич Рамазан аеның беренче киче, дип әйтелер. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй Ризван, Мөхәммәд галәйһиссәләм өммәтенең ураза тотучылары өчен җәннәтләрнең ишекләрен ач. Әй Мәлик, Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәтеннән булган ураза тотучылардан тәмуг ишекләрен бикдә. Әй Җәбраил, җиргә төш, шайтаннарның көчлеләрен чылбырлар белән бәйлә һәм аларны диңгез төбенә ташла. Ул шайтаннар Минем дустым булган Мөхәммәд өммәтенең уразаларын бозмасыннар».

Рамазан аенның һәр кичендә Аллаһы Тәгалә өч мәртәбә әйтер: «Миннән сораучы бармы? Мин аның сораганын бирермен. Әй, тәүбә итүче бармы? Мин аның тәүбәсен кабул итәрмен. Ярлыкау сораучы бармы? Мин аны ярлыкармын».

Соңыннан бер кычкыручы кычкырыр: «Юклыктан башка тулы савыт белән һич киметмичә кем бирер? Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә Рамазан аенның һәр кичәсендә авыз ачкан вакытта тәмугтан мең-мең колны коткарыр, аларның һәрберсе үзләрен газапка ваҗиб итүчеләр. Һәркайчан җомга киче һәм җомга көне булса, ул җоманың һәрбер сәгатендә тәмугтан мең-мең кол азат ителер аларның һәркайсы газапны үзләренә ваҗиб иттеләр. Рамазан аенның соңгы көнендә булса, бу көндә айның башыннан ахырына кадәр азат кылынган кадәр кол азат ителер. Әгәр кадер киче булса, Аллаһы Тәгалә Җәбраилгә боерыр, фәрештәләр җәмәгате белән җиргә иңәр. Җәбраилнең яшел әләме булыр, аны Кәгъбәгә кадап куяр. Җәбраилнең алты йөз канаты булыр, ике канатын ачмас, мәгәр кадер кичәсендә генә ача. Бу өммәткә Җәбраил фәрештәләрне күндерер. Алар һәрбер утыручыга, һәрбер намаз укучыга һәм һәрбер зекер әйтүчегә сәлам бирерләр. Фәрештәләр өммәт белән күрешерләр, таң атканга кадәр өммәтнең догаларына, әмин, дип әйтерләр. Әгәр таң атса, Җәбраил галәйһиссәләм кычкырыр: «Әй фәрештәләр җәмәгате, китәргә китәргә». Фәрештәләр әйтерләр: «Мөхәммәд галәйһиссәләм өммәтләренең хаҗәтләре хакында Аллаһы Тәгалә ни кылды»? Җәбраил әйтер: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә мөэминнәргә карады, ягъни алардан явызлыкларны кичте һәм аларны ярлыкады, мәгәр дүрт төрле халыкны гына ярлыкамады». Әйтерләр: «Кемнәр алар»? Җәб-

раил галәйһиссәләм әйтер: «Беренчесе, даими хәмер эчүче; икенчесе, ата-анасын ачуландыручы; өченчесе, кардәшләренең хәлләрен белмәүче; дүртенчесе, көнчелек итеп дошманлык саклаучы».

Әй Аллаһының илчесе, дип әйтелде. Рәсүлуллаһ әйтте: «Ул кеше кардәшлекне өзгән булыр, ягъни мөэмин кардәшенә өч көннән артык сүз кушмый йөрер. Әгәр фитыр гаетенең кичәсе булса, бу «рөхсәт киче» дип аталыр. Фитыр гаете көненең иртәсе булса, һәр шәһәргә фәрештәләр җибәрелер. Алар җиргә иңәрләр, йорт башларында торырлар, бер тавыштан кычкырырлар. Аллаһы Тәгалә яраткан мәхлукларның барчасы ул тавышны ишетерләр, мәгәр адәмнәр һәм җеннәр генә ишетмәсләр. Алар әйтерләр: «Әй Мөхәммәд өммәтләре, юмарт булучы Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә чыгыгыз. Ул Аллаһы Тәгалә бүләк бирер һәм олуг гөнаһысын ярлыкар. Гает намазын укый торган урыннарына чыксалар, Аллаһы Тәгалә үзенең фәрештәләренә әйтер: «Әй Минем фәрештәләрем, әгәр гамәлен кылса, хак алучының әҗере ни булыр?» Фәрештәләр әйтерләр: «Әй безнең Хуҗабыз, аның әҗерен Син Үзең бирүче». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй фәрештәләр, Мин сезне шаһит итәм, дөреслектә, Мин аларны Рамазан аендагы көндез ураза тотулары, кич уяу торулары белән савабын кылдым, Үземнең ризалыгым белән гөнаһларын ярлыкадым». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй Минем бәндәләрем, Миннән сорагыз, Үземнең хөрмәтем һәм олуглыгым белән ант итәм, дөнья һәм ахирәт өчен бу көнне сорасагыз да бирәм».

عن أبي هريرة ﷺ قال : قال رسول الله ﷺ "أعطيت أمتي في شهر رمضان

خمس خصال لم تعط أمة قبلها : لخلوف فم الصائم أطيب عند الله من ريح

المسك ، وتستغفر لهم الملائكة حتى يفطروا ، وتصفد فيه مردة الشياطين ، فلا يخلصون فيه إلى ما كانوا يخلصون في غيره ، ويزين الله كل يوم جنته ويقول لها : يوشك عبادي الصالحون أن تكفي عنهم المؤونة والأذى ويصيروا إليك ، ويغفر لهم في آخر ليلة ، قيل : يارسول الله أهي ليلة القدر؟ قال : لا ولكن العامل إنما يوفى أجره إذا قضى عمله".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителә. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Рамазан аенда өммәтемә биш төрле хасият бирелде. Аннан элек булган өммәткә бирелмәгән иде. Авыз исенең хушлыгы, ураза кешенең авызы Аллаһы Тәгалә каршында яфәрдән дә хуш ислерәк, ул өммәт авыз ачканга кадәр фәрештәләр алар өчен ярлыкауны сорарлар. Рамазан аенда шайтаннарның көчлеләре бәйләнер. Бу айда Рамазаннан башка котыла торган вакытка кадәр шайтаннар котылмаслар. Аллаһы Тәгалә Үзенең оҗмахын һәркөн бизәр һәм җәннәткә әйтер: «Минем изге бәндәләремә якынай. Алардан мәшәкать һәм рәнҗеш ташланды. Алар сиңа омтылырлар, актык кичтә аларның гөнаһлары ярлыканыр». Әйтелде: «Әй Рәсүлуллаһ, ул кич, кадер киче түгелме?» «Юк, мәгәр үз эшен үтәсә, гамәл кылучыларга әҗер хакы бирелер», – дип әйтте.

عن أبي هريرة ﷺ قال : كان رسول الله ﷺ يبشر أصحابه ويقول : "قد جاءكم شهر رمضان ، شهر مبارك قد افترض الله عنكم صيامه ، فتح فيه أبواب الجنة ، وتغلق فيه أبواب الجحيم ، وتغلل فيه ردة الشياطين : وفيه ليلة خير من ألف شهر".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителә. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм үзенең сәхабәләрен сөендереп әйтте:

«Тәхкыйк, сезгә мөбарәк Рамазан ае килде. Тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә сезнең өчен Рамазанның уразаларын фарыз итте. Рамазанда җәннәт ишекләре ачылыр һәм җәһәннәм ишекләре бикләнер. Рамазанда шайтаннарның куәтлеләре бәйләп куелыр һәм Рамазанда кадер кичәсе бар. Ул кичә мең айдан да артыграк».

Хайсәмәдән риваять ителә. Ул әйтте: «Әгәр зур гөнаһлардан сакланса, Рамазаннан Рамазанга, хаҗдан хаҗга, җомгадан җомгага һәм намаздан намазга кадәр арада булган гөнаһларга кәффәрат, дип әйтә торганнар иде».

Гомәр разыяллаһү ганһүдән риваять ителә, ул: «Рамазан ае керсә, хуш килдең безне пакьләүче, дип әйтә иде. Рамазанның һәркайсы изге. Көндез ураза тотулар һәм кич уяу торулар һәм бу Рамазанда малны сарыф итү – ул малны Аллаһы юлында тотуга тиң».

وروى عن أبي هريرة ﷺعن النبي ﷺ أنه قال : "قال الله تعالى : كل حسنة يعملها ابن آدم تضاعف له من عشرة إلى سبعمائة ضعف إلا الصوم فإنه لي وأنا أجزي به ، يدع شهوته وطعامه وشرابه من أجلي ، ولاصوم جنة ، وللصائم فرحتان : فرحة الإفطار ، وفرحة عند يوم القيامة".

Әбү Һөрәйрә Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә. Ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйтте: «Адәм баласы уразадан башка кыла торган һәр изгелек уннан җиде йөз өлешкә кадәр. Чөнки ул ураза тик Минем ризалыгым өчен генә һәм ул бәндәгә уразасы бәрабәренә әҗерен Мин генә бирүчемен. Чөнки ул бәндә Минем өчен ашау-эчүне һәм күңел теләкләрен ташлый». Ураза – ул уттан пәрдә. Ураза тотучының

ике шатлыгы бар: берсе – авыз ачканда, икенчесе – Кыямәт көнендә Аллаһыга юлыккан вакытта.

عن سلمان الفارسي ﷺ قال : خطبنا رسول الله ﷺ آخر يوم من شعبان فقال : "أيها الناس إنه قد أظلكم شهر عظيم مبارك ، شهر فيه ليلة القدر وهي خير من ألف شهر ، شهر فرض الله صيامه ، وجعل قيام ليلة تطوعا ، فمن تطوع فيه بخصلة من الخير كان كمن أدى فريضة فيما سواه ، ومن أدى فريضة فيه كان كمن أدى سبعين فريضة فيما سواه ، وهو شهر الصبر ، والصبر ثوابه الجنة ، وهو شهر المواساة وشهر يزاد فيه رزق المؤمن ، من فطر فيه صائما كان له كعتق رقبة ومغفرة لذنوبه" ، قلنا : يا رسول الله ليس كلنا يجد ما يفطر به الصائم؟ قال : "يعطي الله هذا الثواب لمن يفطر صائما على مذقة لبن أو تمرة أو شربة ماء ، ومن أشبع صائما كان له مغفرة لذنوبة ، وسقاه ربه من حوضي شربة لا يظمأ بعدها حتى يدخل الجنة ، وكان له مثل أجره من غير أن ينقص من أجره شيء وهو شهر أوله رحمة ، وأوسطه مغفرة ، وآخره عتق من النار ، ومن خفف عن مملوكه فيه أعتقه الله من النار".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Салман Фарсидән риваять итә. Ул әйтте: «Шәгъбанның соңгы көнендә Рәсүлуллаһ безгә хөтбә сөйләде. Әйтте: «Әй адәмнәр, тәхкыйк, сезне күләгәләп мөбарәк һәм олуг ай килде. Ул айда кадер кичәсе бар һәм ул кичә мең айдан артыграк. Янә Аллаһы Тәгалә бу айда көндез ураза тотуны фарыз, кич уяу торуны нәфел кылды. Гүя Рамазаннан башка айда фарызны үтәгән кебектер. Бер кеше ул Рамазанда фарызны үтәсә, гүя Рамазаннан башка вакытта җитмеш фарызны үтәгән кебек булыр. Рамазан ае – ул сабырлык ае.

Сабырлыкның савабы җәннәт. Ул ай тигезлек ае, бу айда мөэминнең ризыгы арттырылыр. Берәү ураза тотучыга авыз ачтырса, аңа кол азат итү әҗере булыр һәм гөнаһлары ярлыканыр». Без әйттек: «Әй Рәсүлуллаһ, безнең һәркайсыбыз ураза кешене авыз ачтыра торган нәрсә тапмый». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә бу савапны сөт, хөрмә, яки бер йотым су белән авыз ачтыручыга бирә. Бер кеше ураза тотучыны туйдырса, аның гөнаһларына ярлыкау булыр һәм ул кешене Раббысы минем махсус күлемнән бер мәртәбә эчерер. Бер мәртәбә эчкәннән соң, хәтта оҗмахка кергәнчегә кадәр һич сусамас». Ул авыз ачтыручыга ураза тоткан кешенең әҗере кебек, һич ким булмаган әҗер булыр. Ул шундый ай, аның башы рәхмәт, уртасы гөнаһларны ярлыкау, ахыры җәһәннәмнән азат итү булыр. Бер кеше ураза вакытында хезмәтчесенең хезмәтен җиңеләйтсә, Аллаһы Тәгалә ул кешене җәһәннәмнән азат итәр».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Ибен Мәсгудтән риваять итә: Рамазанда ураза тоткан бәндәгә сөйләшмичә тик торуда бернәрсә юк. Аллаһыны зекер итсә, Аллаһы Тәгалә хәләл иткән нәрсәне хәләл, хәрамын хәрам дип белсә, ул Рамазанда начар һәм кабәхәт эшкә дучар булмаса, тиешле көнендә Рамазаннан чыкса, мәгәр шундый бәндәнең бөтен гөнаһлары ярлыканыр, һәр тәсбих һәм тәһлил бәрабәренә оҗмахта яшел изумруд таштан бер өй төзелер, ул изумруд ташның эчендә кызыл якут, якутның эчендә куыш эчле энҗедән чатыр булыр. Шул энҗе эчендә хур кызларыннан бер хатын булыр. Ул хатын кулында алтыннан, кызыл якут белән бизәлгән ике беләзек булыр. Аның яктылыгыннан җир яктырыр.

عن أبي مسعود ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال وقد دنا شهر رمضان : "لو يعلم العباد ما في رمضان لتمنت أمتي أن يكون رمضان سنة" فقال رجل من خزاعة : حدثنا رسول الله بما فيه ، قال : "إن الجنة لتزين لرمضان من الحول إلى الحول فإذا كان أول ليلة من رمضان هبت ريح من تحت العرش ، فصفقت ورق أشجار الجنة فتنظر الحور إلى ذلك ، ويقلن : يارب اجعل لنا في هذا الشهر من عبادك أزواجا نقر أعيننا بهم ، وتقر أعينهم بنا ، فما من عبد صام رمضان إلا زوج زوجتين من الحور العين في خيمة من درة مجوفة مما نعت الله تعالى في كتابه : ﴿حور مقصرات في الخيام﴾ و على كل امرأة منهن سبعون حلة ليس فيها خلة على لون الأخرى ، وبعطى سبعين لونا من الطيب ، وكل امرأة منهن على سرير من ياقوتة حمراء ، منسوجة بالدر ، على كل سرير سبعون فراشا بطائنها من استبرق ، لكل امرأة سبعون وصيفة ، هذا لكل يوم صامه من رمضان سوى ما عمل من الحسنات".

Әбү Мәсгуд Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә, ул әйтте: «Тәхкыйк, Рамазан ае якынлашты. Рамазан аеның нинди әҗерле икәнен белсәләр, минем өммәтем ул айның ел буе булуын теләрләр иде. Хузәга кабиләсеннән бер кеше әйтте: «Безгә Рамазандагы әҗер турында сөйлә әле». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Рамазан вакытында, елдан елга җәннәт бизәлер. Рамазанның беренче кичә булса, Гареш астыннан җил исәр оҗмах агачларының яфракларына бәрелүдән шалтырап китәр. Бу хәлгә хур кызлары карарлар һәм әйтерләр: «Бу айда безнең өчен бәндәләреңнән ирләр кыл, безнең күзләребез аларга карап, аларның

күзләре безгә карап нурлансын. Бәндәләрдән Рамазанда ураза тотучы булса, эче куышлы энҗедән ясалган чатыр эчендә хур кызларыннан ике хатынга никахланыр. Аллаһы Тәгалә Үзенең китабы Коръәндә ачык бәян иткән аятькә нигезләнеп: «Ул җәннәттә чатырларда гына тора торган хур кызлары булыр». («Рахмән», сүрәсе, 72) Хур кызларыннан булган һәрбер хатында җитмеш кием булыр, ул киемнәр бер-берсенә охшамаслар. Җитмеш төрле хуш ис бирелер. Кызыл якуттан ясалган урындык хозурында алардан һәрбер хатын булыр. Ул урындыклар энҗе белән тукылган, һәрбер урындыкта җитмеш түшәк, ул түшәкләр яхшы атластан булыр. Һәрбер хатынга җитмеш хезмәтче кыз бирелер. Бу әҗер Рамазан аенда ураза тотучының һәрбер көне .өчендер. Уразада булган башка гамәлләр бу хисапка керми».

وعن النبي ﷺ : "رجب شهر أمتي ، وفضله على سائر الشهور كفضل أمتي على سائر الأمم ،وشعبان شهري وفضله على سائر الشهور كفضلي على سائر الأنبياء ، ورمضان شهر الله وفضله على سائر الشهور كفضل الله على خلقه".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителә: ул әйтте: «Рәҗәп ае минем өммәтемнең ае. Ул рәҗәпнең башка айларга караганда артыклыгы – минем өммәтемнең башка өммәтләргә караганда булган артыклыгы кебек. Шәгъбән ае – ул минем ай. Рамазанның башка айларга караганда булган артыклыгы – Аллаһы Тәгаләнең мәхлуклары каршында булган артыклыгы кебек».

عن الحسن أن النبي ﷺ خرج وإذا الناس يتلاحون ، فقال النبي ﷺ : جئت وأنا أريد أن أخبركم بليلة القدر ، غير أني خشيت أن تتكلموا عليها ، وعسى أن يكون خيرا ، فاطلبوها في العشر الأواخر ، في تسع بقين ، وفي سبع بين ،

وفي خمس بقين ، وفي ثلاث بقين ، وفي آخر ليلة تبقى ، ومن أماراتها : أنها ليلة بلجة سمحة لا حارة ولا باردة ، حتى تطلع الشمس في صبيحتها ليس لها شعاع ، ومن قامها إيمانا واحتسابا غفر الله له ما كان قبل ذلك من ذنب".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Хәсәннән риваять итә: «Дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм чыкканда, кешеләр бер-берсе белән низагълашалар иде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Сезгә кадер кичәсе хакында хәбәр бирү өчен килдем һәм шул кадер кичәсендәге әҗерләргә генә ышануыгыздан куркам. Шаять, кадер кичәсенә ышануыгызда изгелек булыр. Соңгы ун көне эчендә тугызы калганда, ул кадер кичәсен эзләгез. Җиде көн калганда, калган бишендә һәм өч көн калганда соңгы кичәсендә эзләгез. Ул кадер кичәсенең галәмәтләре: ул ачык һәм җиңел кич, эсселеге дә һәм салкыны да булмас. Ул кичнең иртәсендә кояш чыгар, кояшның күләгәсе булмас, ягъни томанланмас. Бер кеше ул кичтә әҗер-савапка ышанып уяу торса, Аллаһы Тәгалә аның шул кичтән әүвәл булган гөнаһларын ярлыкар».

Фәкыйһ әйтте: «Тәхкыйк, Пәйгамбәр галәйһиссәләм кич уяу торуда һәм көндез ураза тотуда ышануны һәм разыйлыкны шарт кылды. Аллаһы Тәгалә вәгъдә иткән савапка күңел белән ышану иман була. Аллаһы Тәгаләнең вәгъдә иткән савабына юнәлгән һәм Аллаһы Тәгаләгә кечелек кылган хәлдә булу разыйлык була. Әгәр бәндә Пәйгамбәр галәйһиссәләм бәян иткән савапларга һәм фазыйләтләргә ирешергә теләсә, Рамазан аеның хөрмәтен тану, телне ялганнан, гайбәттән һәм артык сүздән, әгъзаларны хаталардан һәм аяк таюдан, күңелне көнләшүдән, мөселманнарга дошман булудан саклану тиешле.

Әгәр моны эшләсә, Аллаһы Тәгалә ул бәндәдән кабул итәрме, юкмы дип куркырга кирәк».

Хәкимнәрнең кайберләреннән риваять ителә. Бер хәким: «Әй минем Раббым! Дөньяда кайгы иясенә әҗер бирүне өстеңә алдың, ахирәттә савап бирүне вәгъдә иттең. Әй Раббым! Әгәр син безгә бу уразаны кайтарсаң, безне кайгы бәрабәренә бирә торган әҗердән мәхрүм итмә, әй күркәм сыйфатлар белән танылган күркәм Зат!» – дип әйтә торган булган.

وروى أبو ذر الغفاري ﷺ قال : صمنا مع رسول الله ﷺ فلما كان ليل الثالث والعشرين قام وصلى بنا حتى مضى ثلث الليل ، ثم لما كانت ليلة الرابع والعشرين لم يخرج إلينا ، فلما كانت ليلة الخامس والعشرين خرج إلينا ، وصلى بنا حتى مضى شطر الليل فقلنا لو نفلتنا ليلتنا هذه ، فقال : "إنه من خرج وقام مع الإمام حتى ينصرف ، كتب له قيام ليلة" ثم لم يصل بنا في الليلة السادسة والعشرين فلما كانت ليلة السابع والعشرين قام وجمع أهله ، وصلى بنا حتى خشينا أن يفوتنا الفلاح ، قلنا: وما الفلاح؟ قال : السحور.

Әбү Зәррдән риваять ителә. Ул әйтте: «Пәйгамбәр белән ураза тоттык, Рамазанның егерме өченче кичәсе булгач, кич белән торып, төннең өчтән бер өлеше үткәнгә кадәр намаз укыды. Моннан соң егерме дүртенче кичәсе булгач безгә чыкмады. Егерме бишенче кичәсе булгач, янә безнең янга чыгып, кичнең бер өлеше үткәнгә кадәр безнең белән намаз укыды. Без: «Бу кичәбез артыграк булсачы!» – дидек. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Берәү чыгып имам белән, хәтта имам кайтып киткәнгә кадәр кич торса, аңа бөтен кич уяу торган савабы язылыр». Моннан соң егерме алтынчы кичәдә Пәйгамбәр

галәйһиссәләм безнең белән намаз укымады. Егерме җиденче кичә булгач, торып бөтен гаиләсен җыйды һәм безнең белән намаз укыды, хәтта фәләх вакыты үтүдән курыктык. Нәрсә ул «фәләх», дип сорадык. Әбү Зәрр: «Сәхәр ашау», – диде.

Гайшә разыяллаһү ганһәдән риваять ителә. Рамазан киченең башында Пәйгамбәр галәйһиссәләм чыгып, мәчеттә намаз укыды. Аның белән бергә кешеләр дә намаз укыдылар. Таң аткач, кешеләр бу хәлне сөйләшә торган булдылар. Икенче кичтә кешеләр күбәйде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм намаз укыды, аның белән бергә башкалар да укыдылар. Өченче кичә булгач халык күбәйде, хәтта мәчет әһеленнән гаҗиз калды, мәчеткә сыймас булдылар. Пәйгамбәр галәйһиссәләм кешеләр янына чыкмады, бары тик иртә намазына гына чыкты. Иртә намазын укыгач, кешеләргә карап әйтте:

أنه لم يخف علي شأنكم الليلة ، ولكني خشيت

أن يفرض عليكم صلاة الليل فتعجزوا عن ذلك

«Пәйгамбәр бу кичәдәге эшегездән курыкмады. Ләкин мин сезнең хозурга кичке намазның фарыз ителүеннән курыктым. Әгәр фарыз ителгән булса, үтәүдән гаҗиз булыр идегез».

Гайшә разыяллаһү ганһә әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм Рамазан кичләрендә уяу торуны фарыз итеп боермыйча гына кешеләрне өнди иде. Рәсүлуллаһ вафат булгач, Әбү Бәкер разыяллаһү ганһүнең хәлифәлек заманында бу эш шулай дәвам итте. Гомәр бине Хаттаб хәлифәлегенең әүвәлендә бу эш шул рәвештә калды. Гомәр кешеләрне Үбәй бине Кәгъб разыяллаһү ганһүнең өенә җыйды».

عن علي بن أبي طالب ﷺ أنه قال : إنما أخذ عمر بن الخطاب هذه التراويح من حديث سمعه مني ، قالوا : ما هو يا أمير المؤمنين ؟ قال : سمعت رسول الله ﷺ يقول : "إن الله تعالى حول العرش موضعا يسمى حظيرة القدس ، وهو من النور ، فيها ملائكة لا يحصي عددهم إلا الله تعالى ، يعبدون الله عز وجل عبادة لا يفترون ساعة ، فإذا كان ليالي شهر رمضان استاذنوا ربهم ان ينزلوا إلى الارض فيصلون مع بني آدم ، فينزلون كل ليلة الارض ، فكل من مسهم أو مسوه سعد سعادة لا يشقى بعدها أبدا".

Гали бине Әбү Талиб разыяллаһү ганһүдән риваять ителә. Ул әйтте: «Гомәр бине Хаттаб бу тәравихне миннән ишеткән хәдистән алды». Әйттеләр: «Әй мөэминнәрнең әмире, ул нинди хәдис?» Әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән ишеттем, ул: «Гареш тирәсендә Аллаһы Тәгаләнең яраткан урыны бар, ул урынны «Хәзыйратүль-кудс», диләр. Ул урын нурдан, андагы фәрештәләрнең һич саны юк. Мәгәр аларның санын Аллаһы Тәгалә генә белә. Аллаһы Тәгаләгә шулкадәр гыйбадәт кылалар ки, вакытларын һич гыйбадәтсез үткәрмиләр. Рамазан аеның кичәләре булса, Раббыларыннан җиргә иңәргә рөхсәт сорарлар. Адәм балалары белән намаз укырлар. Һәр кичәне җиргә төшәрләр. Аларны тоткан һәр кеше, яки алар тоткан һәрбер кеше шундый бәхет белән бәхетле булыр ки, ул бәхеттән соң мәңге кайгы күрмәс», – диде. Гомәр әйтте: «Бу сүзне сөйләгәч, әлеге гамәлне кылу безгә бигрәк тә тиешле». Хәзрәти Гомәр кешеләрне тәравих намазына җыйды. Һәм шул тәравих намазын шәргый итеп куйды».

Гали бине Әбү Талиб разыяллаһү ганһүдән риваять ителә. Рамазан аеның бер кичәсендә чыккач,

мәчетләрдә кыйраәтне ишетте, андагы ялтыраган кандилләрне күреп әйтте: «Гомәр безнең мәчетләребезне Коръән белән нурландырган кебек Аллаһы Тәгалә Гомәрнең каберен яктыртса иде». Госман бине Гаффән разыяллаһү ганһүдән дә шулай ук риваять ителде.

## Ун көннең фазыйләте

عن ابن عباس ﷺ أن النبي ﷺ قال : "ما من أيام العمل الصالح فيها أحب إلى الله من هذه الأيام" يعني ايام العشر ، قالوا : ولا الجهاد في سبيل الله تعالى؟ قال : "ولا الجهاد في سبيل الله إلا رجل خرج بنفسه وماله ، فلم يرجع من ذلك بشيء".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Ибен Габбас разыяллаһү ганһүмәдән риваять итә. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә каршында изге гамәл кыла торган көннәр арасында бу ун көннән сөеклерәге юк». «Аллаһы юлында сугышта булу бу көннәрдән сөеклерәк түгелме?» – дип сорадылар. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы юлында җиһад кылу да сөекле түгел, мәгәр малы белән сугышка чыгып, шул сугыштан кайтмыйча калучы гына әлеге көннәрдән ким түгел».

عن جابر بن عبد الله ﷺ قال : قال رسول الله ﷺ : "ما من أيام أحب إلى الله وأفضل من أيام العشر" ، قيل : ولا مثلهن في سبيل الله؟ قال : "ولا مثلهن في سبيل الله ، إلا رجل عقر جواده ، وعفر وجهه" ، وفي رواية أخرى "عقر جواده وأهريق دمه"

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Җәбир бине Габдулладан риваять итә. Ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә өчен зөлхиҗҗәнең беренче ун көненнән дә сөеклерәк

көн юк». Әйтелде: «Аллаһы юлында сугышкан көннәр дә ул зөлхиҗҗәнең ун көннәре кебек түгелме?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһ юлында сугышкан көннәр дә ул көннәр кебек булмас, мәгәр бер кеше Аллаһы юлына яхшы хайваны һәм малы белән чыгып, үзе шәһид булса гына Аллаһы каршында ул ун көннән артык булыр».

عن عائشة اضي الله عنها أن شابا كان صاحب سماع ، وكان إذا أهل هلال ذي الحجة أصبح صائما، فارتفع الحديث إلى النبي ﷺ فأرسل إليه فدعاه ، فقال : "ما يحملك على صيام هذه الأيام؟" قال : بأبي أنت وامي يا رسول الله ، إنها أيام المساعر ، وأيام الحج عسى الله أن يشر كني في دعائهم ، قال : "فإن بكل ضوم تصومه عدل مئة رقبة ، ومئة بدنة ، ومئة فرس ، تحمل عليها في الله ، فإذا كان يوم التروية فلك فيها عدل ألف رقبة وألف بدنة وألف فرس ، تحمل عليها في سبيل الله ، فإذا كان يوم عرفة فلك بها عدل ألفي رقبة وألفي بدنة وألفي فرس تحمل عليها في نسبيل الله ، وهو صيام سنتين سنة قبلها وسنة بعدها".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Гайшә разыяллаһү ганһәдән риваять итә. Бер егет бик тыңлаучан иде. Зөлхиҗҗә аеның башы керсә, таңнан уразага керә иде. Бу хәбәр Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә иреште, Пәйгамбәр галәйһиссәләм ул егетне үзенә чакырды. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Бу көннәрдә ураза тотуга сине ни көчли?» Егет әйтте: «Әй Аллаһының илчесе, ата-анам сиңа фида булсын. Ул көннәр хаҗ һәм Ислам әркәннәре үтәлә торган көннәр. Шаять, Аллаһы Тәгалә мине ул көннәрнең догасына тиңдәш итәр». Рәсүлуллаһ әйтте: «Син ураза тоткан һәр көн бәрабәренә синең өчен йөз кол

азат иткәннең һәм Аллаһы юлында йөк күтәрүче йөз дөя белән йөз атның әҗере булыр. Әгәр тәрвия көне булса, синең өчен мең кол азат иткәннең әҗере булыр. Аллаһы юлында йөк күтәрүче мең дөя һәм мең ат әҗере булыр. Гарәфә көне булса, синең өчен ике мең кол азат иткән һәм ике мең дөя белән ике мең ат өстенә йөк йөкләткән әҗере булыр. Ул Гарәфә көнендә ураза тоту ике ел ураза тотуга тиң: бер ел Гарәфә көненнән әүвәл һәм бер ел Гарәфәдән соң тоткан хөкемендә булыр».

وروى في رواية أخرى أنه قال ﷺ : "يعدل صوم يوم عرفة بصوم سنتين ويعدل صوم عاشراء بصوم سنة".

Икенче бер риваятьтә китерелә. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Гарәфә көненең уразасы ике ел уразага, Гашура көненең уразасы бер ел уразага бәрабәр».

Аллаһы Тәгаләнең аяте турында тәфсир әһелләре әйттеләр:

وَوَاعَدْنَا مُوسَى ثَلَاثِينَ لَيْلَةً وَأَتْمَمْنَاهَا بِعَشْرٍ فَتَمَّ مِيقَاتُ رَبِّهِ أَرْبَعِينَ لَيْلَةً

«Мусаны Тур тавында утыз кич һәм утыз көн тоту белән вәгъдә иттек, ул утыз көнне янә ун көн кушып тәмам иттек. Раббысының вәгъдәсе кырык кичтә тәмам булды». («Әгъраф» сүрәсе, 142) Аятьтә әйтелгән ун көн – ул зөлхиҗҗәнең беренче ун көне.

Аллаһы Тәгалә Муса белән камил сөйләшү белән сөйләште. Муса галәйһиссәләм Аллаһы Тәгаләгә сердәш һәм зөлхиҗҗәнең беренче ун көнендә якын булды һәм аңа шул ун көндә такталар язылды.

Әбү Дәрдәдән риваять ителә. Ул әйтте: «Сезнең өчен ун көннең уразасы, дога күп кылу һәм ул ун көндә садаканы күп бирү һәм ярлыкау лязем булсын. Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән ишеттем, ул әйт-

те: «Зөлхиҗҗәнең беренче ун көненең хәереннән мәхрүм булган кешегә ни үкенеч. Сезнең өчен тугызынчы көннең уразасы гына лязем булсын. Чөнки ул тугызынчы көннең уразасында санаучылар санап бетергесез әҗерләр бар».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Габдулла бине Гобәйддән риваять итә. Ул әйтте: «Безгә иреште, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә Муса бине Гомәргә биш доганы бүләк итте. Җәбраил галәйһиссәләм ул догаларны зөлхиҗҗәнең унынчы көнендә китерде. Ул догаларның беренчесе:

لا إله إلا الله وحده لا شريك له ، له الملك وله الحمد ت يحيى ويميت ، وهو حي لا يموت ، بيده الخير وهو على كل شيء قدير

Икенчесе:

أشهد أن لا إله إلا الله وحده لا شريك له ، إلها واحدا أحد صمدا لم يتخذ له صاحبة ولا ولدا

Зекер ителә: бу сүзләр Инҗилдә иңдерелде. Хәвариләр Гайсә галәйһиссәләмнән бу догаларның әҗерләре турында сорадылар. Ул аларга савабын һәм әҗерен сөйләде. Ул догаларны зөлхиҗҗәнең ун көнендә укыган кешегә әҗерләрен һичкем сөйләп бетермәслек итеп бәян итте. Әбү Нәдыр әйтә: «Миңа бер кеше сөйләде. Ул бу догаларны зөлхиҗҗәнең ун көнендә укыган икән. Төшендә күргән, гүя аның йортында нурдан биш катлам имеш. Ул нур катламнары берсе икенчесеннән югарырак».

وروى مجاهد عن ابن عمر ﷺ أن النبي ﷺ قال : "ما من ايام اعظم عند الله ولا أحب إليه فيهن العمل من هذه الأيام العشر ، فأكثروا فيها التكبير والتحميد والتهليل".

Мөҗәһид Ибен Гомәрдән риваять итә. Дөреслектә Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Зөлхиҗҗәнең ун көнендәге гамәлләр башка көннәрдә кылынган гамәлләрдән Аллаһы Тәгалә каршында олуграк һәм сөеклерәк. Ул көннәрдә тәкбир, хәмед һәм тәһлилне күп кылыгыз».

Нәфигъ Ибен Гомәрдән риваять итә: «Ибен Гомәр зөлхиҗҗәнең ун көнендә дә түшәктә булганда, яисә утырып торганда, һәрвакыт тәкбир әйтә торган иде. Гата бине Әбү Рабәх зөлхиҗҗәнең ун көнендә юлда да, базарларда да тәкбир әйтә иде».

Җәбир бине Язид Әбү Зиядәдән риваять итә. Ул әйтте: «Сәгыйд бине Җөбәер белән Габдрахман бине Әбү Ләйлә һәм мөселман галимнәреннән без күргән кешеләр гает һәм тәшрикъ көннәрендә: «Аллаһү әкбәр аллаһү әкбәр лә иләһә иллә-ллаһү валлаһү әкбәр аллаһү әкбәр вә лилләһил-хәмдү», – дип әйтәләр иде».

Җәгъфәр бине Сөләймән әйтте: «Сәбит әл-Бәннәнине күрдем. Зөлхиҗҗәнең ун көнендә сүзен бетерә иде, ягъни зекер мәҗлесендә». Моннан соң: «Аллаһү әкбәр, аллаһү әкбәр аллаһү әкбәр», – дип әйтә иде. Янә: «Ул көннәр – зекер көннәре», – дип әйтә иде. Кешеләр дә шулай эшлиләр иде. Җәгъфәр: «Мәлик бине Динарның шулай эшләгәнен күрдем», – диде».

Могыйра, Әбү Мәгъшәрдән риваять итә. Ул әйтте: «Зөлхиҗҗәнең беренче ун көннәрендә юлда тәкбир әйтүдән Нәхәгыйдән фәтвә сорадым. Ул: «Моны бәс тукучылар гына эшлиләр», – диде.

Ләйс бине Әбү Сәлим әйтте: «Мөҗәһиттән зөлхиҗҗәнең ун көнендә юлда тәкбир әйтү хакында сорадым. Ул: «Моны бәс тукучы халык кына шулай эшли, – дип җавап бирде».

Фәкыйһ әйтте: «Берәү бу көннәрдә үзе алдында гына, ягъни үзеннән башкага ишеттермичә тәкбир әйтсә, хәерлерәк булыр. Әгәр берәү тавышын күтәреп, ягъни кычкырып тәкбир әйтсә һәм шуның белән шәригатен белдерергә, башкаларның исенә төшерергә теләсә, ул вакытта кычкырып әйтүдән зарар юк. Бу хакта олуглардан да хәбәр килде».

وروى عبد الله بن مسعود ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "إن الله تعالى قد اختار من الأيام أربعة ، ومن الشهور أربعة ، ومن النساء أربعة ، وأربعة يسبقون إلى الجنة ، وأربعة اشتاقت إليهم الجنة ، أما الايام : فأولها : يوم الجمعة ، والصاني يوم العرفة ، والثالث يومالنحر ، والرابع يوم الفطر . و أما الشهور : فشهر الله الأصم رجب ، وثلاثة متواليات ذو القعدة وذوالحجة والمحرم . وأما النساء : غمريم بنت عمران ، وخديجة بنت خويلد سابقة نساء العالمين إلى الإيمان بالله ورسوله ، وآسية بنت مزاحم امرأة فرعون ، وفاطمة بنت محمد سيدة نساء أهل الجنة .

وأما السابقون فلكل قوم سابق إلى الجنة ، فمحمد ﷺ سابق العرب ، وسلمان سابق الفرس ن وصهيب سابق الروم ، وبلال سابق الحبشة .

وأما الأربعة التي اشتاقت إليهم الجنة : فأمير المؤمنين علي بن أبي طالب ﷺ وسلمان ، وعمار بن ياسر ، والمقدار بن الأسود ﷺ ".

Габдулла бине Мәсгуд Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә: ул әйтте: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә дүрт көнне ихтыяр итте, ягъни кадерле итеп бар кылды. Айлардан да дүрт айны ихтыяр итте һәм хатыннардан дүрт затны ихтыяр итте, ягъни кадерле итеп яратты. Дүрт кеше җәннәткә алдан керерләр. Дүрт затны җәннәт көтеп алыр. Аллаһы Тәгалә

каршында ихтыяр ителгән көннәрнең беренчесе җомга көне. Ул җомгада шундый вакыт бар, мөселман бәндә ул вакытка туры килмәс. Дөнья һәм ахирәт эшендә Аллаһы Тәгаләдән сорый торган бәндә шул вакытка туры килсә, Аллаһы Тәгалә ул бәндәгә сораганын бирер. Икенчесе Гарәфә көне. Әгәр Гарәфә көне булса, Аллаһы Тәгалә фәрештәләренә мактанып әйтер: «Әй Минем фәрештәләрем, бәндәләремә карагыз, тузанга батып төрле тарафтан килделәр, малларын сарыф иттеләр, тәннәрен мәшәкатьләндерделәр. Тәхкыйк, Мин аларны ярлыкадым. Өченчесе, корбан чала торган көн. Бәндә корбан чалса, корбаннан беренче тамган кан бәндә эшләгән һәр гөнаһка кәффарәт булыр. Дүртенчесе, ураза бәйрәме көне. Рамазан аенда ураза тотсалар, үзләренең бәйрәмнәренә чыксалар, Аллаһы Тәгалә фәрештәләренә әйтер: «Һәр гамәл кылучы үзенең гамәленә күрә әҗерен таләп итә. Минем бәндәләрем Рамазан аеның уразасын тоттылар, бәйрәмнәренә чыктылар, үзләренең әҗерләрен теләделәр. Мин сезне шаһид итәрмен. Тәхкыйк, Мин аларны ярлыкадым. Бер кычкыручы кычкырыр: «Әй Мөхәммәд өммәте, кайтыгыз, тәхкыйк, явызлыкларыгыз изгелеккә алмаштырылды».

Аллаһы Тәгалә ихтыяр кылган дүрт айларның беренчесе – рәҗәб ае. Калганнары бер-бере артлы килүче өч ай: зөлкагъдә, зөлхиҗҗә һәм мөхәррәм айлары.

Дүрт фазыйләтле хатыннарның беренчесе, хәзрәти Мәрьям. Икенчесе, Хәдичә Көбра, ул Аллаһы Тәгаләнең берлегенә, Аның илчесенә иман китерүче бөтен дөнья хатыннарының иң әүвәлгесе. Өченчесе, Фиргавен хатыны Асия. Дүртенчесе, Мөхәммәд га-

ләйһиссәләмнең кызы Фатыйма, ул җәннәт халкы хатыннарының олугы.

Җәннәткә әүвәл керүчеләр: һәрбер кавемнең җәннәткә алдан керүчесе бар. Гарәп халкының иң беренче керүчесе – Мөхәммәд галәйһиссәләм; фарсы халкының әүвәл керүчесе – Салман Фарси; Сөһәеб – Рум халкының һәм Билал – Хәбәш халкының әүвәл керүчеләреннән булырлар.

Җәннәтнең көтеп торган дүрт затлары: мөэминнәрнең әмире Гали бине Әбү Талиб, Гаммәр бине Йәсир, Микдәд бине әл-Әсвәд һәм Салман разыяллаһү ганһүм.

وروى عن سالم بن أبي الجعد أن النبي ﷺ قال لفاطمة رضي الله عنها : "قومي إلى أضحيتك ، فاشهديها ، فإن الله تعالى يرفع عنك ذنوبك عند أول دفعة من دمها".

Сәлим бине Әбү Җәгедтән риваять ителә: дөреслектә Пәйгамбәр галәйһиссәләм Фатыймага әйтте: «Корбаның янында тор, чөнки ул корбанның каны иң элек тамган вакытта Аллаһы Тәгалә синнән гөнаһларыңны күтәрер». Гыймран бине әл-Хәсыйн әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, бу фазыйләт сиңа һәм синең өй җәмәгатеңә генәме яисә барча мөселманнарга дамы?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Юк, миңа гына түгел, бәлки бөтен мөселманнарга да».

وعن عائشة رضي الله عنها أنها قالت : قال رسول الله ﷺ : "ضحوا وطيبوا بها نفسا ، فإنه من أخذ أضحيته يوم محلها ، فاستقبل بها القبلة ، كان قرنها وفرثها ودمها وشعرها وصوفها ووبرها محضورات له وم القيامة ، إن الدم إذا وقع في التراب فإنما يقع في حرز الله ، أنفقوا يسيرا تؤجروا كثيرا".

Гайшәдән риваять ителә. Ул әйтте: Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Бугазлагыз һәм ул корбанлык белән нәфесне пакьләгез. Берәү корбанлыгын хәләл булган көндә алса һәм шул корбанлык белән кыйблага юнәлер. Ул корбанлыкның мөгезе, аның бер ягы, каны, йоны, әгәр дөя булса, аның йоны Кыямәт көнендә аңа хәзерләнгән әҗерләр булыр. Дөреслектә кан туфракка төшсә, Аллаһының саклавына төшәр. Җиңелчә бирегез, күп әҗерле булырсыз».

## Гашура көненең фазыйләте

عن عبد الله بن عباس ﷺ قال : قال رسول الله ﷺ : "من صام يوم عاشوراء من المحرم ، أعطاه الله تعالى ثواب عشرة آلاف ملك ومائة شهيد، و من صام يوم عاشوراء من المحرم أعطى ثواب عشرة آلاف حاج ومعتمر ، وعشرة آلاف شهيد ، ومن مسح بيده على رأس يتيم يوم عاشوراء رفع الله تعالى له بكل شعرة درجة ، ومن فطر مؤمنا ليلة عاشوراء ، فكأنما أفطر عنده جيع أمة محمد ﷺوأشبع بطونها" ، قالوا : "يا رسول الله لقد فضل الله يوم عاشوراء على سائر الأيام" ، قال : "نعم ، خلق الله تعالى السموات والأرضين يوم عاشوراء ، وخلق الجبال يوم عاشوراء ، وخلق النجوم يوم عاشوراء ، وخلق اللوح والقلم يوم عاشوراء ، وولد إبراهيم يوم عاشوراء ، ونجاه الله من النار يوم عاشوراء ، وقد أمر بالذبح يوم عاشوراء ، وفدى ولده من الذبح يوم عاوراء ، وأغرق فرعون يوم عاشوراء ، وكشف البلاء عن أيوب يوم العاشوراء ، وتاب الله على آدم يوم عاشوراء ، وغفر ذنب داود يوم عاشوراء ، ورد ملك سليمان يوم عاشوراء ، وولد عيسى في يوم عاشوراء ،

ورفع الله عيسى في يوم عاشوراء ، وولد النبي ﷺ في يوم عاشوراء ، ويوم القيامة في يوم عاشوراء".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Габдулла бине Габбастан риваять итә. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Бер кеше мөхәррәм аеның унынчы көнендә ураза тотса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә ун мең фәрештә савабын бирер. Берәү мөхәррәмнең унынчы көнендә ураза тотса, ун мең хаҗ һәм гомрә кылучының һәм ун мең шәһид савабы бирелер. Бер кеше Гашура көнендә ятимнең башын сыйпаса, Аллаһы Тәгалә ул кешене һәрбер төге саны бәрабәренә бер дәрәҗәгә күтәрер. Бер кеше Гашура кичәсендә бер мөэминне ифтар кылдырса, гүя Мөхәммәд галәйһиссәләмнең бөтен өммәте аның янында ифтар кылып карыннарын туйдырган кебек булыр. Әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, Аллаһы Тәгалә башка көннәргә караганда Гашура көнен шулай артык иттеме». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә җирләрне һәм күкләрне, диңгезне, ләүех белән каләмне Гашура көнендә яратты. Адәмне Гашура көнендә җәннәткә кертте. Ибраһим Гашура көнендә тудырылды һәм бу көндә Ибраһим галәйһиссәләмне уттан коткарды. Гашура көнендә Ибраһим галәйһиссәләм корбан чалу белән боерылды. Улы Исмәгыйль галәйһиссәләм бугазлаудан коткарылды. Әюб галәйһиссәләмнең бәласе Гашура көнендә җибәрелде. Аллаһы Тәгалә Адәмнең тәүбәсен Гашура көн кабул итте. Давыд галәйһиссәләмнең гөнаһысы Гашура көнендә ярлыканды. Сөләйман галәйһиссәләмнең патшалыгы Гашура көнендә кайтарылды. Гайсә галәйһиссәләм Гашура көнендә тудырылды. Идрис галәйһиссәләм белән Гайсә галәйһиссәләм мәртәбәгә Гашура көнендә күтәрелде».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Гакрәмәдән риваять итә: ул әйтте: «Гашура көнне Адәм галәйһиссәләмнең тәүбәсе кабул ителде, Нух галәйһиссәләм көймәдән чыккан көне. Ул көндә Нух галәйһиссәләм шөкранә йөзеннән ураза тотты. Бу көндә Фиргавен батырылды һәм бу көнне Бәни Исраил ураза тотты. Әгәр аның уразасын үткәрмәскә көчең җитсә, син шуны эшлә».

عن محمد بن ميسرة قال : بلغنا عن أبي هريرة ، عن النبي ﷺ أنه قال :"من سع على عياله يوم عاشوراء وسع الله عليه سائر السنة"

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Мөхәммәд бинѐ Мәйсәрәдән риваять итә: «Безгә Әбү Һөрәйрәдән иреште. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Бер кеше Гашура көнендә гаиләсенә киңлек кылса, Аллаһы Тәгалә аның өчен айның башка көннәрендә дә киңлек кылыр». Суфьян әйтте: «Сынап карадык һәм шулай таптык».

سعيد بن جبير عن ابن عباس ﷺ قال : قدم النبي ﷺ المدينة ، فوجد اليهود يصومون يوم عاشوراء فسألهم عن ذلك ، فقالوا : إن هذا اليوم أظهر الله فيه موسى وبني إسرائيل علىقوم فرعو ، فنحن نصومه تعظيما له ، فقال النبي ﷺ : "نحن أولى بموسى منكم".

Сәгыйд бине Җәбир, Ибен Габбастан риваять итә. Ул әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм Мәдинәгә килде. Яһүдләр Гашура көнендә ураза тоталар иде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм яһүдләрдән моның хикмәте турында сорады. Яһүдләр әйттеләр: «Ул көндә Аллаһы Тәгалә Муса белән Бәни Исраилне Фиргавен кавеменә өстен кылды. Без Гашура көнен олылау йөзеннән ул көнне ураза тотабыз». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Без сезгә караганда Муса

галәйһиссәләмгә лаеклырак». Гашура көнендә ураза тотарга боерды».

Фәкыйһ әйтте: «Бу Гашура көненең тәфсирен төрлечә әйттеләр. Тәфсир әһелләренең кайберләре әйттеләр: «Мөхәррәмнең унынчы көне булганга «гашура» дип аталды». Кайберәүләр әйтүенчә, бу көндә Аллаһы Тәгалә ун пәйгамбәрне ун төрле кәрамәт белән хөрмәтләде. Адәмнең тәүбәсен кабул итте; Идрис галәйһиссәләмне югары урынга күтәрде; Нух галәйһиссәләмнең көймәсе Гашура көнендә Җүди тавында туктады; Ибраһим галәйһиссәләм Гашура көнендә туды һәм Аллаһы Тәгалә аны Хәлил итте, аны Нәмруд утыннан котарды; Давыд галәйһиссәләмнең тәүбәсен кабул итте; Гайсә галәйһиссәләмне югары дәрәҗәгә күтәрде; Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәләмне диңгездән коткарды, Фиргавенне диңгезгә батырды; Юныс галәйһиссәләмне балык карыныннан чыгарды; Сөләйман галәйһиссәләмнең падишаһлыгы кайтарылды; Пәйгамбәр галәйһиссәләм тудырылды». Ул тәфсир әһелләренең кайберләре әйттеләр: «Гашура дип аталуының сәбәбе – ул көн ун кәрамәтнең унынчысы, Аллаһы Тәгалә бу өммәтне ун кәрамәт белән хөрмәтләде. Ун кәрамәтнең беренчесе, рәҗәб ае. Рәҗәбнең башка айларга караганда артыклыгы бу өммәтнең башка өммәтләргә караганда булган артыклыгы кебек. Икенчесе, шәгъбан ае, аның башка айларга караганда артыклыгы Пәйгамбәр галәйһиссәләмнең башка пәйгамбәрләргә караганда артыклыгы кебек. Өченчесе, рамазан ае. Рамазанның башка айларга караганда артыклыгы Аллаһы Тәгаләнең мәхлуклары каршындагы артыклыгы кебек. Дүртенчесе, Кадер кичәсе. Кадер кичәсе мең айдан изгерәк. Бишенчесе, Фитыр гаете көне.

Алтынчысы, зөлхиҗҗәнең ун көне. Ул көннәр Аллаһы Тәгаләне зекер итү көннәре. Җиденчесе, Гарәфә көне. Гарәфә көненең уразасы ике еллык гөнаһларның кәффарәте. Сигезенчесе, корбан бугазлау көне. Тугызынчысы, җомга көне. Җомга – ул көннәрнең башы. Унынчысы, Гашура көне. Гашура көнендә ураза тоту бер еллык гөнаһларның кәффарәте. Бу вакытлардан булган һәрбер вакыт өчен кәраматләр бар. Аллаһы Тәгалә ул вакытларны бу өммәт файдасына гөнаһларын ярлыкау һәм хаталарын пакьләү өчен яратты».

Гайшәдән риваять ителә: ул әйтте: «Гашура көне шундый көн булды, җаһилият заманында корәеш кабиләсе Гашура көнендә ураза тота иде. Мәккәдә булганда Пәйгамбәр галәйһиссәләм дә бу көнне ураза тотты. Мәдинәгә килгәч Рамазан аеның уразалары фарыз ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Гашура көненең уразасын тоту белән әмер итә идем. Теләгән кеше тотсын, теләгәне калдырсын».

Гайшәдән риваять ителә: ул әйтте: «Гашура – ул мөхәррәмнең тугызынчы көне». Кайберәүләр, унберенче көн, диделәр. Аларның күбрәге, ул көннең унынчысы булуына таяндылар. Аллаһы Тәгалә – белүчерәк.

## Ирекле рәвештә һәм ак көннәрдә ураза тоту

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Зәйд бине Әсләмнән риваять итә. Ул әйтте: «Кем аркылы икәнен белмим, шулай булса да ул хәдис Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән китерелә. Дөреслектә ул әйтте: «Гамәлләр биш төрле: беренчесе, бер гамәл бәрабәренә савап та үзе кебек бер генә өлеш;

икенчесе, әҗере важиб ителгән гамәл; өченчесе, гамәл бәрабәренә ун савап; дүртенчесе, гамәл бәрабәренә җиде йөз савап; бишенчесе, гамәл, кылучының савабын Аллаһыдан башка зат белми.

Җәзасы үзе охшаш булган гамәл – ул кеше бер явызлыкны кылса, бер явызлык кына языла. Бер кеше изгелекне кылырга ниятләп, аны кылмый калдырса, аның файдасына бер изгелек языла. Әҗере важиб ителгән гамәл – ул берәү Аллаһыга юлыгып, Аллаһыдан башкага гыйбадәт кылмас, аңа оҗмах важиб булыр. Әҗере ун өлеш булган гамәл – ул берәү изгелекне кылыр һәм аңа ун өлеш әҗер языла. Әҗере җиде йөз булган гамәл – ул Аллаһы юлында, ягъни җиһадта, яисә гыйлем юлында гамәл кылучы, аңа җиде йөз әҗер языла. Гамәлнең савабын Аллаһыдан башка зат белми торган гамәл – ул ураза тоту».

حدثنا أبو صدقة اليماني قال : دخل بلال ﷺ على رسول الله ﷺ وهو ياكل الطعام ، فقال : "يا بلال الطعام الطعام" فقال : يا رسول الله إني صائم ، فقال رسول الله ﷺ : "ناكل أرزاقنا ، ورزق بلال في الجنة ، إن الصائم إذا كان عند قوم ياكلون تسبح أعضاؤه وتصلي عليه الملائكة ، وتقول : اللهم اغفر له ، اللهم ارحمه مادام في مجلسه".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Садака әл-Йәмәнидән риваять итә: ул әйтте: «Билал Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә керде, Пәйгамбәр аш ашап утыра иде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Билал, ашка, ашка». Билал: «Әй Рәсүлуллаһ, мин уразамын», – диде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Без ризыгыбызны ашыйбыз, Билалның ризыгы җәннәттә. Дөреслектә, ураза тотучы бер халыкның янында булса, ул ураза кешенең әгъзасы тәсбих

әйтер, аның хозурына фәрештәләр рәхмәт әйтерләр. Фәрештәләр әйтерләр: «Әй Раббыбыз, ул ураза тотучыны ярлыка. Әй Раббыбыз, ул ураза тотучы үзенең урынында даими утырганда, аңа рәхмәт ит»,

Фәкыйһ үзенең иснәде белән риваять итә: Мәүлә Әбү Гойәйнә булган ирештерүче әйтте: Миңа Ләкыйт Әбү Бәрдәдән, ул Әбү Муса әл-Әшгаридән хәбәр бирде. Әбү Муса әйтте: «Диңгезгә чыктык, диңгезнең тирән җирләрендә йөргән вакытта парусны күтәрдек. Һичбер атау һәм һичбер нәрсә дә күрмибез. Шул вакытта без бер кычкыручыга очрадык. Ул: «Әй көймә халкы, туктагыз, мин сезгә хәбәр бирәм», – дип кычкыра иде. Әбү Муса әйтте: «Туктап тормастан киттек, һичнәрсә күрмәдек. Кычкыручы җиде мәртәбә кычкырды». Әбү Муса әйтте: «Җиденче мәртәбә кычкыргач, туктап әйттем: «Әй син, безнең ни хәлдә икәнебезне күрәсең, сиңа тукталырга көчебез җитми. Ни телисең, безгә хәбәр бир». Кычкыручы әйтте: «Аллаһы Тәгалә Үзе хөкем иткән хөкем турында сезгә хәбәр биримме?» Без: «Безгә сөйлә», – дидек. Ул әйтте: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә Үзенә хөкем итте, эссе көндә үзен сусаткан кеше булмас, мәгәр булса, Аллаһы Тәгалә аны Кыямәт көнендә суга күндерер».

Ибен Мөбарәк үзенең иснәде белән Әбү Муса әл-Әшгаридән шуңа охшашны риваять итә: «Әбү Муса әл-Әшгари ураза тоту өчен бик нык эссе көнне эзли иде».

عن رسول الله ﷺ قال : "ست خصال من الخير : مجاهدة عدو الله بالسيف ،

والصوم في الصيف ، وحسن الصبر عند المصيبة ، وترك المراء وإن كان محقا ،

والتكبير بالصلاة في يوم الغيم — أو قال : في يوم الصيف — وحسن الوضوء في أيام الشتاء".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә. Ул әйтте: «Алты төрле нәрсә изгелекләрдән. Аллаһы дошманына каршы кылыч белән сугышу; җәй көнендә ураза тоту; кайгы вакытында күркәм сабырлык; дөрес булса да рияны ташлау; болытлы көндә намазда тәкбир әйтү; кыш көннәрендә күркәм тәһарәт».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Дәрдәдән риваять итә: ул әйтте: «Әгәр өч нәрсә булмаса, үлемнән курыкмас иде: чын күңелдән Аллаһыга сәҗдә кылган хәлдә йөземнең туфракка буялуы; ике тараф ерак булган көндә, ягъни таң беленү белән кояш бату арасы ерак булган көндә ачлык һәм сусау белән чолганган хәлдә ураза тоту; сүзнең яхшысын ихтыяр кылучы халык белән утыру, хөрмәнең матурын сайлау шикелле».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Ибен Әбү Сөләйманнан риваять итә: ул Әбү Һөрәйрәдән ишеткән. Әбү Һөрәйрә разыяллаһү ганһү әйтте: «Рәсүлуллаһ миңа өч төрле хасиятне өйрәтте, үлгәнчегә кадәр аларны ташламам. Шуларның берсе, витыр намазын укыганнан соң гына йоклау; икенчесе, һәр айда өч көн ураза тоту; өченчесе, иртәнге намазын калдырмау».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Хавсадан риваять итә: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм дүрт нәрсәне һич ташламады: берсе, Гашура көненең уразасы; икенчесе, зөлхиҗҗәнең ун көн уразасы; өченчесе, һәр айның өч көн уразасы; дүртенчесе, иртәнге намазның фарызыннан әүвәл ике рәкәгать намаз уку».

عن حارث عن علي ﷺ ان النبي ﷺ قال : "صوموا شهر الصبر ، يعني شهر رمضان ، وثلاثة أيام من كل شهر ، فهو بمنزلة صوم الدهر ن ويذهب وحر الصدر".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Хәрис бине Галидән риваять итә: «Дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Рамазан аенда һәм һәр айдан өч көн ураза тотыгыз, шул өч көн ураза тоту бөтен гомер буенча ураза тоту урынында. Күкрәкнең күгәргәннәре югалыр».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Габдулла бине Шәкыйкътан риваять итә: ул әйтте: «Мәдинәгә килгәндә Әбү Зәрргә очрадым. Мин, бу көн нинди хәл, мин аны күрәмен, – дидем. Аңардан: «Син уразадамы?» – дип сорадым. Ул: «Әйе», – диде. Ул кешеләр хәзрәти Гомәр бине әл-Хаттабка керергә рөхсәт көтәләр иде. Кергәч алдыбызга хөрмә белән бер табак китерелде. Әбү Зәрр ашады, мин кулым белән аны тоттым, исенә төшерергә теләдем. Әбү Зәрр әйтте: «Мин сиңа әйткәнемне онытмадым. Мин уразадамын, дип әйттем. Чөнки мин һәр айда өч көн ураза тотам, шул мәгънә белән мин гомер буе ураза тотучымын (димәк һәр айда ураза тоту ул гомер буе ураза тотуга бәрабәр)».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Гамру бине Гастан риваять итә: ул әйтте: «Мин – тырышучы кеше идем, атам миңа хатын алып бирде. Беркөнне атам минем йортыма керде, мине күрмәде. Хатынымнан: «Иреңне ничек табасың?» – дип сорады. Хатын әйтте: «Ул гаҗәеп хуш ир, кичен йокламый, көндезен ашамый». Атам минем хакта начар уйга төште һәм әйтте: «Хатының синең мөселман хатыннар җөмләсеннән. Син аны ташладың». Көч һәм тырышу тапканымнан

атам әйткән сүздән кайгырмадым. Бу хәбәр Рәсүлуллаһка иреште. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм мине чакырып әйтте:

"لكني أنام وأصلي وأصوم وأفطر ، فصل
ونم وصم من كل شهر ثلاثة أيام"

«Мин йоклыйм да, уянып намаз да укыйм, ураза да тотам, ифтар да ашыйм. Син дә намаз укы да һәм йокла да, ураза да тот һәм авыз да ач. Һәрбер айда өч көн ураза тот». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, мин моннан куәтлерәкмен, ягъни моннан артыграк ураза тотарга да көчем җитә». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте:

"صم يوما وأفطر يوما وهو صوم داود عليه السلام"

«Көн аралаш тот, ул көн аралаш ураза тоту Давыд галәйһиссәләмнең уразасы». Янә Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте:

"في كم تقرأ القرىن؟"

«Коръәнне күпме вакытта укыйсың?» «Ике тәүлектә», – дидем. Ул әйтте:

"اقرأه في خمسة عشر يوما"

«Коръәнне унбиш көндә укы». «Әй Рәсүлуллаһ, минем көчем артыгракка җитә», – дидем. Ул әйтте:

"فاقرأه في سبع"

«Алай булса җиде көндә укы». Моннан соң Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте:

"إن لكل عمل شرة ولكل شرة حرص فترة ، فمن كانت فترته
إلى سنتي فقد اهتدى ، ومن كانت فترته إلى غير ذلك فقد هلك"

«Һәрбер гамәл кылучының эшләргә теләге була. Һәрбер теләкнең ихтиләфе була, ягъни бер вакытта

күбрәк эшлисе, икенче вакытта аннан азрак эшлисе килә. Әгәр берәүнең теләге минем сөннәтем тарафына булса, тәхкыйк, ул кеше туры юлга күнелде. Әмма берәүнең теләге сөннәтемнән башкага булса, тәхкыйк, ул кеше һәлак булды».

Габдулла бине Гамру әйтте: «Минем өчен Рәсүлллаһның рөхсәтен кабул итү малым һәм гаиләм чаклы нәрсә булудан сөеклерәк. Бу көн мин инде зәгыйфьләнгән һәм картайган картмын. Мин Рәсүлуллаһ боерган нәрсәне куярга яратмыйм».

Ибен Габбастан риваять ителә. Аның янына бер кеше килде. Ибен Габбастан ураза тоту хакында сорады. Ибен Габбас әйтте: «Сиңа бер хәдисне сөйлимме? Ул хәдис миндә сакланган бүләкләр җөмләсеннән булды. Әгәр син Давыд галәйһиссәләмнең уразасын теләсәң, дөреслектә, ул Давыд галәйһиссәләм бер көн ураза тота, бер көн тотмый иде. Әгәр син аның улы Сөләйман галәйһиссәләмнең уразасын теләсәң, дөреслектә, Сөләйман галәйһиссәләм һәр айның башында, уртасында һәм ахырында өч көн ураза тота торган иде. Әгәр син Гайсә галәйһиссәләмнең уразасын теләсәң, дөреслектә, Гайсә галәйһиссәләм бөтен гомерен ураза тотып үткәрә иде. Ризыгы – арпа, кигән киеме – каты йоннан иде. Кайсы урында кич җитсә, шул урында тукталып, таң галәмәте күренгәнче намаз укый иде. Нинди урында гына туктаса да, ике рәкагәть намаз укый иде. Әгәр син аның анасы уразасын теләсәң, дөреслектә, ул Мәрьям ике көн ураза тота, ике көн тотмый иде. Әгәр син адәмнәрнең изгесе булган Мөхәммәд галәйһиссәләмнең уразасын теләсәң, дөреслектә, Пәйгамбәребез һәр айда өч көн ураза тота торган иде. Ягъни ул унөченче, ундүртенче, унбишенче көннәр булган ак көннәрдә ураза тота һәм: «Ул өч көндә

ураза тоту бөтен гомер буена ураза тоту кебек», – дип әйтә иде.

وروى عن أبو هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "من صام شهر رمضان ثم أتبعه بست من شوال ، فكأنما صام الدهر كله"

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителә. Дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Бер кеше Рамазан аенда ураза тотса, ул шул Рамазан уразасына шәүвәл аеның алты көнен ияртеп тотса, ул кеше гомер буе ураза тоткан кебек булыр». Әбү Һөрәйрә әйтте: «Килегез, хисаплап күрсәтәм. Рамазан уразасы өч йөз көн, шәүвәлнең алты көне алтмыш көн булыр. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

مَنْ جَاءَ بِالْحَسَنَةِ فَلَهُ عَشْرُ أَمْثَالِهَا

«Берәү бер изгелек кылса, ул бер изгелеге ун тапкыр арттырылыр» («Әнгам» сүрәсе, 160). Бер көн ураза ун көн урынына торыр».

Фәкыйһ әйтте: «Шәүвәл аенда алты көн ураза тотуны кайберәүләр мәкруһ күрделәр. Кайберәүләрнең әйтүенчә: «Шәүвәлдә алты көн ураза тотуда насара динендә булучыларга охшашлык бар».

Ибраһимән-Нәхәгыйдән риваять ителә: аңардан алты көн ураза хакында сорадылар. Ул әйтте: «Алты көн ураза – ул Рамазан аенда хәез күрүчеләрнең уразасы».

Кайберләре әйттеләр: «Насара халкына охшашлык булмасын өчен шәүвәл аеның уразасын аерып тотарга кирәк. Минем фикеремчә ул уразаның тоташ, яисә аерым-аерым булуында да зарар юк. Чөнки фитыр гаете көне ул ике араны аерган».

## Гаиләне тәэмин итү турында

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әюбтән риваять итә: «Дөреслектә, Пәйгамбәрнең сәхабәләре үз урыннарында булганда, аларга бер кеше килде. Ул кешенең яшьлеге һәм көчлелеге сәхабәләрне гаҗәпкә калдырды. Алар әйттеләр: «Бу кеше үзенең егетлеге белән куәтен Аллаһы юлында кылса иде!» Моны Пәйгамбәр галәйһиссәләм ишетеп әйтте:

"أو ما في سبيل الله إلا كل من قاتل أو غزا ، من سعى على نفسه ليعفها فهو في سبيل الله ، ومن سعى على والديه ليعفخما فهو في سبيل الله ، ومن سعى على عياله ليعفهم فهو في سبيل الله ، ومن سعى مكاثرا فهو في سبيل الله الشيطان".

«Сугышкан кешеләр генә Аллаһы юлындамы? Берәү үзен хәрамга төшүдән, яки кешедән соранудан сакланып, яисә ата-анасын кеше йөзеннән саклау өчен кәсеп итсә, ул да Аллаһы юлында булыр. Берәү мал күбәйтү өчен кәсеп итсә, ул кеше шайтан юлында булучыдыр».

عن ثوبان ﷺ أن النبي ﷺ قال : "أفضل الدينار : دينار ينفقه الرجل على عياله ، ودينار ينفقه الرجل على دابته في سبيل الله ، ودينار ينفقه على أصحابه في سبيل الله".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Сәүбәннән риваять итә. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Алтын акчаның артыгррагы кешенең гаиләсенә тоткан акчасы, янә Аллаһы юлында хезмәт итүче хайванына һәм Аллаһы юлындагы иптәшләренә ашаткан малы».

Әбү Каләбә әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм гаилә белән башлаган (димәк, иң әҗерле мал – ул гаиләгә сарыф ителгәне). Кечкенә өй җәмәгать-

ләренә кәсеп иткән кешедән әҗер йөзеннән кайсы кеше олуграк».

وروى عن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "إنما الصدقة عن ظهر غني، واليد العليا خير من اليد السفلى ، أبدا بمن تعول".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителә. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Дөреслектә, аның өчен садака тиешле бай кешедән: югары кул түбән кулдан изгерәк, ягъни бирә торган кул ала торган кулдан изгерәк. Садаканы биргәндә гаиләңдәге кеше белән башла».

سمعت أبي قال : كان ثابت البناني عند أنس بن مالك ﷺ فذكر أنه سمع رسول الله ﷺ يقول : "إن الله عز وجل قد ضمن دين العبد إذا استدان في ثلاثة : أحدهما من قبل النكاح مخافة الفجور ، ثم لم يقدر على قضائها حتى مات ، فقد ضمن الله دينه أن يقضي عنه يوم القيامة ، والثاني دينه لإعانة المسلمين ليخرج إلى الغزو ، والثالث : إذا استدان لكفن الميت ، فإن الله تعالى يرضى خصماءه يوم القيامة".

Фәкыйһ: «Атамнан ишеттем», – диде. Атам әйтте: «Әнәс бине Мәлик каршында Сәбит Бәннәни була иде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән ишеткәнен искә төшерә иде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә бәндәнең бурычын Үз өстенә алды. Әгәр бәндә өч төрле эш өчен бурыч алса, гөнаһтан куркып никах өчен алса, моннан соң ул бурычны кайтарырга көче җитмәсә, тәхкыйк, Кыямәт көнендә аның бурычын түләүне Үз өстенә алды. Икенчесе, ул бәндәнең башка мөселманнарга Аллаһы юлына чыгарга ярдәм итү өчен алган бурычы. Өченчесе, мәет кәфенене өчен бурыч алса, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә бурыч

ияләрен разый кылыр», – дип әйтә иде. Шуннан соң Сәбит Бәннәни Хәсән Басрига кереп Әнәстән ишеткәнен сөйләде. Хәсән әйтте: «Әнәс картайды һәм зәгыйфьләнде, моннан артыграк әҗерен онытты. Бу зекер ителгән кешеләр белән гаиләсен ашату өчен бурыч алып бурычын үтәргә тырышып, үлгәнче максатына, ягъни бурычын түләү морадына ирешмәүчене дә Аллаһы Тәгалә Үз өстенә алды. Кыямәт көнендә ул кеше белән бурыч ияләре арасында хөкем ителү, хак сорашу булмас».

وروى أبو هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "إن في السماء ملكين ماهما عمل إلا يقول أحدهما : اللهم أعط لمنفق خلفا ، ويقول الآخر : اللهم عجل لمسك تلفا".

Әбү Һөрәйрә Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте. Дөреслектә ул әйтте: «Күктә ике фәрештә бар. Берсенең малын сарыф итүче урынына: «Әй Аллаһым, бир», – дип, икенчесенең малын тиешле урынга бирми торучыга: «Һәлакәтне ашыктыр», – дип дога кылудан башка гамәлләре юк».

وروى مكحول عن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "من طلب الدنيا حلالا استعفافا عن المسألة ، وسعيا على عياله ، وتعطفا على جاره ، جاء يوم القيامة ووجهه كالقمر ليلة البدر ، ومن طلب الدنيا حلالا ، مكاثرا مفاخرا مرائيا ، لقى الله يوم القيامة وهو عليه غضبان".

Мәкхул Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә. Дөреслектә ул әйтте: «Бер кеше кешедән соранууны калдыру өчен, бала-чагасына ризык һәм кәсеп булсын өчен, күршесенә ярдәм итү өчен хәләл малны теләсә, Кыямәт көнендә бу кеше йөзе айның ундүртенче кичәсендәге кебек булган хәлдә килер.

Бер кеше күбәйтү һәм мактану өчен, рия гамәл кылу өчен хәләл дөньяны кәсеп итсә, Кыямәт көнендә ул кеше Аллаһы Тәгалә аңа ачулы булган хәлдә юлыгыр».

عن أنس بن مالك ﷺ قال : قلت : يا رسول الله ، رغيف اتصدق به أحب إليك أم مائتا ركعة تطوعا؟ قال : "رغيف تتصدق به احب إلي من مائتي ركعة تطوعا" ، قلت : يا رسول الله ، قضاء حاجة مسلم أحب إليك أم مائتا ركعة تطوعا؟ قال : "قضاء حاجة المسلم أحب إلي من ألف ركعة تطوعا" ، قال : قلت : ترك لقمة من الحرام أحب إليك أم ألف ركعة تطوعا؟ ، قال : "ترك لقمة من حرام أحب إلي من ألفي ركعة تطوعا".

قال : قلت : يا رسول الله الجلوس مع العيال أفضل أم الجلوس في المسجد؟ قال : "الجلوس ساعة عند العيال أحب إلي منالإعتكاف في مسجدي هذا" . قال : قلت : يا رسول الله النفقة على العيال أحب إليك أم النفقة في سبيل الله؟ ، قال : "درهم ينفقه الرجل على العيال أحب إلي من ألف دينار ينفقه في سبيل الله".

قال : قلت : يا رسول الله ، بر الوالدين أحب إليك أم عبادة ألف سنة؟ قال : "يا أنس، "جَاءَ الْحَقُّ وَزَهَقَ الْبَاطِلُ إِنَّ الْبَاطِلَ كَانَ زَهُوقًا" قبر الوالدين أحب إلي من عبادة ألف سنة".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителә. Ул әйтте: «Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, синең каршыңда минем бер күмәч садака бирүем сөеклеме, яки йөз рәкәгать нәфел намаз укуыммы?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Синең бер күмәчне садака кылуың ике йөз нәфел намаздан сөеклерәк». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, синең өчен бер мөселманның йомышын үтәү, яки йөз рәкәгать нәфел

намаз уку сөеклерәкме?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Минем өчен мең рәкәгать нәфел намазы укудан бер мөселман йомышын үтәү сөеклерәк». Әнәс әйтте: «Синең каршыңда бер кисәк хәрамны калдыру сөеклерәкме, яки йөз рәкагәть нәфел намазымы?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Минем каршымда ике мең рәкагәть намаздан бер кисәк хәрамны ташлау сөеклерәк». Әнәс әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, синең каршыңда гайбәтне ташлау, яки ике мең нәфел намаз уку сөеклерәкме?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Гайбәтне калдыру ун мең рәкәгать нәфел намаздан сөеклерәк». Әнәс әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, синең каршыңда тол хатын йомышын үтәү сөеклерәкме, яки ун мең рәкагәть нәфел намаз укумы?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Тол хатынның йомышын үтәү утыз мең рәкагәть намаздан сөеклерәк». Әнәс әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, синең каршыңда бала-чага белән бергә утыру, яки мәчеттә утыру сөеклерәкме?» Рәсүлуллаһ әйтте: «Бала-чага янында бер сәгать утыру минем мәчетемдә игътикяфтә утырудан сөеклерәк». Әнәс әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, синең өчен бала-чага өчен тоткан мал, яки Аллаһы юлында сарыф кылынган мал сөеклерәкме?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Кешенең гаиләсенә сарыф итә торган бер дирһәм көмеш акчасы, Аллаһы юлында сарыф ителә торган мең алтынына караганда сөеклерәк». Әнәс әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, синең каршында ата-анага изгелек итү, яки мең ел гыйбадәт кылу сөеклерәкме?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әй Әнәс, хак һәм туры юл килде, батыйл һәм ярамас эшләр юкка чыкты. Минем каршымда ата-анага изгелек кылу ике мең ел гыйбадәт кылудан сөеклерәк».

عن أبي كبشة، قال : ضرب لنا رسول الله : "ثل الدنيا أربعة رجال ، رجل آتاه الله علما وآتاه مالا فهو يعمل بعلمه في ماله ، ورجل آتاه الله علما ولم يؤته مالا ، فيقول : لو أن الله تعالى آتاني مثل ما آتي فلانا لفعلت فيه مثل ما يفعل ، فهما في الأجر سواء ، ورجل آتاه الله مالا ، فلم يؤته علما ، فهو يمنعه من حقه ، وينفقه في الباطل ، ورجل لم يؤته مالا ولم يؤته علما فيقول : لو ان الله تعالى آتاني مثل ما آتى فلانا لفعلت به مثل ما يفعل فهما في الوزر سواء".

Әбү Кәбәшәдән риваять ителә: Рәсүлуллаһ дөньяның охшашын дүрт кеше охшашы итеп күрсәтте. Берсе шул, аңа Аллаһы Тәгалә гыйлем һәм мал бирде. Ул кеше үзенең гыйлеме белән малын тиешле урында тиешлечә сарыф итә. Бер төрле кеше шул, Аллаһы Тәгалә аңа гыйлемне бирә, мал бирми. Ул кеше әйтә, әгәр Аллаһы Тәгалә ул кешегә биргән кебек миңа да малны бирсә, ул фәлән кылган кебек мин дә кылыр идем. Бу ике кеше әҗер савапта бертигез булырлар. Янә шундый кеше бар, Аллаһы Тәгалә аңа мал бирә, гыйлем бирми. Ул кеше надан булганлыктан, малын тиешле урынга сарыф итми, кирәкмәгән урынга малын сарыф итә. Бер төрле кеше бар Аллаһы Тәгалә ул кешегә мал да, гыйлем дә бирми. Ул кеше әйтә: «Әгәр Аллаһы Тәгалә миңа фәләнгә биргән кебек бирсә, ул фәлән кылган кебек мин дә кылыр идем». Алар гөнаһта бәрабәр булырлар».

عن أنس بن مالك ﷺ عن رسول الله ﷺ أنه قال : "إن في الجنة لغرفا يرى ظاهرها من باطنها وباطنها" ، قسل : فمن سكانها يا رسول الله؟ قال : "الذين

يطعمون الطعام ، ويطيبون الكلام ، ويديمون الصيام ، ويفشون السلام ، وسصلون بالليل والناس نيام".

قالوا : يا رسول الله ، غن هؤلاء أهل لدلك ، ومن يطيق ذلك؟ قال : "فمن قال : سبحان الله والحمد لله ولا إله إلا الله والله أكبر ، فقد أطاب الكلام ، ومن أطعم أهله فقد أطعم الطعام ، ومن صام رمضان فقد أدام الصيام ، ومن لقى أخاه فسلم عليه فقد افشى السلام ، ومن صلى العشاء الآخرة والفجر فقد صلى باليل والناس نيام".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителә: Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Дөреслектә, оҗмахта бер чарлак бар, эченнән – тышы, тышыннан – эче күренә. Ул чарлакта торучылар кемнәр булыр, дип соралды. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Анда торучылар кешеләрне ашатучылар, матур сүз сөйләүчеләр, һәрвакыт ураза тотучылар, ачык сәлам әйтерләр, башка кешеләр йокыда вакытта кич белән намаз укырлар». Әйттеләр: «Әй Аллаһының рәсүле дөреслектә, син әйткән кешеләр шул бәян ителгән чарлакка лаек булучылар. Бу гамәлгә кемнең көче җитәр?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Бер кеше «сүбханә-ллаһи вәл-хәмдү лилләһи вә лә иләһә иллә-ллаһү валлаһү әкбәр», дип әйтсә тәхкыйк, ул кеше күркәм сүз әйтүче булды. Бер кеше бала-чагасын ашатса, тәхкыйк ашату әҗерен тапты. Бер кеше Рамазан аенда ураза тотса, тәхкыйк, даими ураза тотучы булды. Бер кеше үзенең кардәшенә юлыгып сәлам бирсә, тәхкыйк, сәламне ачык кылды. Бер кеше кешеләр йокыда вакытта ястү намазы белән иртә намазын укыса, тәхкыйк, кичен намаз укучы булды». Ягъни кешеләр йокыда вакытта

дигәннән морадны Рәсүлуллаһның үзенең өммәтеннән булучылар түгел, бәлки ястү һәм иртә намазлары вакытында йоклаучылар Мөхәммәд өммәтеннән түгел, дип әйтүдер. Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгалә – белүчерәк.

## Кул астында булучыларның хәтерләрен саклау

عن عطاء بن ياسر أن أبا ذر ﷺ ضرب وجه غلام به ، فاستعدي عليه النبي ﷺ فقال النبي ﷺ : "لا تضربوا وجوه المصلين من مماليككم ، واطعموهم مما تأكلون ، وألبسوهم مما تلبسون ، فإن رابوكم فبيعوهم".

Гата бине Ясирдән риваять ителә: Дөреслектә, Әбү Зәрр үзенең хезмәтче колының йөзенә сукты. Пәйгамбәр галәйһиссәләм аңа кычкырды һәм әйтте: «Намаз укучыларның йөзләренә сукмагыз, колларга үзегез ашаганны ашатыгыз һәм аларны үзегез киенгәннән киендерегез. Әгәр ул коллар сезгә мәкруһны эшләсәләр, ул вакытта аларны сатыгыз (әмма сугу, җәза кылу дөрес түгел)».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Гаширдән риваять итә: ул әйтте: «Сәхабәләрдән берәү эчәргә сорады, Рәсүлуллаһның өй җәмәгатеннән бер хатын үзенең асравын чакырды. Ул асрау кыз, хатынның хезмәтен акрын кылды. Хатын асрауны начар сүз белән сүкте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Сак бул, Кыямәт көнендә син шул хатынга әйткән сүзең өчен җәзаланырсың. Яки дүрт кеше хәзерләрсеңме. Ул дүрт кеше син хатынга әйткәнгә шаһидлык кылырлар». Ул хатын асрауны азат итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм хатынга әйтте: «Шаять, бу синең азат итү гамәлең гөнаһыңа кәффарәт булуга якын».

وروى أبو ذر ﷺ عن النبي ﷺ قال : "إخوانكم خولكم جعلهم الله تحت أديكم ، فمن كان أخوه تحت يده فليطعمه مما يأكل ، ويلبسه مما يلبس ، ولا تكلفوهم فوق طاقتهم ما يغلبهم ، فإن كلفتوهم فأعينوهم".

Әбү Зәрр Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә. Ул әйтте: «Сезнең кардәшләрегез – милкегездәге колларыгыз. Аллаһы Тәгалә аларны кул астыгызда кылды. Берәүнең кул астында кардәше булса, аны үзе ашаганнан ашатсын һәм үзе кигән киемнән киендерсен. Аларны эшләтә торган эшләрегездә хәлләреннән килгәннән артыгын йөкләмәгез. Әгәр йөкләсәгез, аларга ярдәм итегез».

وروى أبو بكر الصديق ﷺ عن النبي ﷺ قال : "لا يدخل الجنة سيئ الملكة ، أكرموهم إكرامكم أولادكم ، وأطعموهم مما تاكلون" ، قلت : يا رسول الله ما ينفعنا من الدنيا؟ قال : "فرس تربطه تقاتل عليه في سبيل الله ، ومملوك يكفيك ، وإذا صلى فهو اخوك".

Әбү Бәкер Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә. Ул әйтте: «Мөлкәтендәге халыкка начар мөгамәлә итүче җәннәткә кермәс. Балаларыгызны хөрмәтләгән кебек аларны да хөрмәтләгез. Үзегез ашаганнан аларны да ашатыгыз. Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, дөнья нәрсәсеннән ни-нәрсә безгә файда бирер?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы юлында сугышуың өчен бәйләп куйган атың файда бирер. Сиңа бер кол җитәр. Әгәр ул колың намаз укыса, ул кардәшең булыр».

وروى عن النبي ﷺ أن رجلا سأله فقال : كم نفعو عن الحادم ؟ قال : "كل يوم سبعين مرة".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителә: бер кеше пәйгамбәрдән сорады: «Хезмәтчене ничә мәртәбә гафу итик?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Һәр көн җитмеш мәртәбә».

وعن قتادة ﷺ قال : كان من لآخر كلام النبي ﷺ عند موته : "الصلاة ، وما ملكت أيمانكم"

Катәдәдән риваять ителә: ул әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләмнең үлем алдыннан әйткән соңгы сүзе бу булды: «Намазны һәм кул астындагы кешеләрне карагыз. Сезгә намазларны үтәү, хезмәтчеләрегезне тәрбияләү (саклау) лязем булсын».

وعن أبي هريرة ﷺ ان النبي ﷺ قال : "دخلت امرأة النار في هرة لها ربطتها في البيت لم تطعمها ولم تسقها ، ولم ترسلها فتاكل من خشاش الأرض حتى ماتت".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителә: дөреслектә Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Бер хатын үзенең мәчесе сәбәпле җәһәннәмгә керде. Ул хатын мәчене йортына бәйләп куйды, ягъни бикләгән иде. Мәчесен ашатмады, эчертмәде һәм беркая җибәрмәде. Шул мәче үлгәнче үлән ашады».

وعن الحسن البصري قال : مر النبي ﷺ ببعير معقول صدر النهار ، فقضى حاجته ثم رجع والبعير على حاله ، فقال لصاحبه : "أما علفت البعير هذا اليوم ؟" قال : لا قال : "أما إنه ليحاجك يوم القيامة".

Хәсән Басридән риваять ителә: ул әйтте: «Көн уртасында Пәйгамбәр галәйһиссәләм бәйләп куелган дөя янынннан үтте. Хаҗәтен үтәп кире кайтканда, дөя шул хәлдә, ягъни бәйләнгән килеш басып тора иде.

Пәйгамбәр галәйһиссәләм дөянең хуҗасын эзләп китте. Хуҗасына килеп: «Бүген дөяңне ашаттыңмы?» – дип сорады. Хуҗасы әйтте: «Юк, ашатмадым». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аң бул, Кыямәт көнендә Аллаһы каршында дөя синнән хакын сорар».

عن علي بن أبي طالب ﷺ عن النبي ﷺ انه قال في خطبته : "أيها الناس ، الله الله ، فيما ملكت أيمانكم أطعموهم مما تأكلون ، وألبسوهم مما تلبسون ، ولا تكلفوهم ما لا يطيقون ، فإنهم لحم ودم ، وخلق أمثالكم — ألا من ظلمهم فأنا خصمهم يوم القيامة ، والله حاكمهم".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителә: ул үзенең вәгазендә әйтте: «Әй кешеләр, кул астында булган затларыгыз хакында Аллаһыдан куркыгыз. Үзегез ашаганнан аларны ашатыгыз, үзегез кигәннән киендерегез. Көчләре җитмәгән нәрсәләрне аларга кушмагыз, чөнки алар да сезнең кебек мәхлуклар. Әгәр берәү аларны җәберләсә, Кыямәт көнендә мин алар тарафыннан хак дога кылучымын».

وروى عن النبي ﷺ : "أرقاءكم أرقاءكم ، اطعموهم مما تأكلون ، وألبسوهم مما تلبسون ، فإذا جاءوا بذنب ولم تريدوا أن تغفروا لهم ، فبيعوهم ، ولا تعذبوا خلق الله تعالى".

Әбү Бәрдә Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә. Дөреслектә Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Өч төрле нәрсә бар, аларның һәркайсы өчен ике өлеш әҗер булыр. Берәүнең кәнизәге булыр. Ул кәнизәккә әдәп өйрәтте, әдәбен яхшыртты да, аны азат итте, соңыннан аны никахлап алды. Берәү китап әһелләреннән булып, үзенең пәйгамбәренә инана торган булса, соңыннан ул Пәйгамбәр галәйһиссә-

ләмгә ирешеп аңа инанса, ул кешегә ике савап булыр. Берәүнең колы, яки кәнизәге булыр. Ул кол, яки кәнизәк Аллаһының һәм хуҗаларының хакын үтәр. Бу колга ике савап булыр».

Хәсән Басридән риваять ителә: колның хәле турында, хуҗасы колын йомышка җибәрә һәм шул вакытта җәмәгать намазы да җиткән булыр. Бу очракта беренче кайсы гамәлен кыла башлар, дип соралды. Хәсән Басри: «Хуҗасының хаҗәтен эшләр», – диде. Ягъни ул колның намаз вакыты үтми торган булса, вакыт үтүдән курыкмаса хуҗаның йомышын йомышлар. Әгәр намаз вакыты чыгудан курыкса, колга намазны вакытыннан кичектерү дөрес булмас. Чөнки Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте:

لا طاعة لمخلوق في معصية الخالق

«Аллаһы Тәгалә хәрам кылган эштә мәхлукның сүзен, боерыгын тыңлау юк». Адәмгә кул астындагы мәхлукларны тәрбияләү, көче җитмәгән эш белән аны көчләмәү тиешле була. Чөнки Аллаһы Тәгалә көче җитмәгән нәрсәләр белән бәндәләренә боермады. Гаилә әһеле белән күркәм мөгамәләгә килү тиешле.

Пәйгамбәр галәйһиссәлмнән риваять ителә. Ул әйтте: «Кул астындагы мәхлукларга начар мөгамәлә итүче җәннәткә кермәс. Ул мәхлукларны балаларыгызны хөрмәтләгән кебек хөрмәтләгез, үзегез ашаган нәрсә белән аларны да ризыкландырыгыз».

عن عبد الله بن عمر ﷺ انه رأى كسرة خبز فقال لغلامه : ارفع وأمط عنها الاذى ، فلما أمسى وأراد أن يفطر قال لغلامه : ما فعلت بالكسرة ؟ قال :

أكلتها قال : اذهب فانت حر ، سمعت النبي ﷺ يقول : "من وجد كسرة فرفعها وأكلها لم تصل إلى جوفه حتى يغفر الله له" ، فإني أكره أن أستعبد من قد غفر له .

Габдулла бине Гомәрдән риваять ителә. Габдулла бине Гомәр ташландык икмәкне күрде. Ул үзенең колына әйтте: «Ул икмәкне һәм аңарда булган җәфаны ал, ягъни ул икмәк рәнҗеп ята». Кич җиткәч Габдулла бине Гомәр уразасын ачарга теләде. Колына әйтте: «Ипи сыныгы белән ни эшләдең?» Кол әйтте: «Мин аны ашадым». Габдулла бине Гомәр әйтте: «Кит! Син азат. Мин Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән ишеттем, ул әйтте: «Берәү ипи сыныгын табып, аны алып ашаса, эченә, ягъни карынына төшеп җиткәнче Аллаһы Тәгалә аны ярлыкар». Шуңа күрә мин гөнаһысы ярлыканган кешене кол итүчеләрне мәкруһ күрәм».

### Ятимнәргә изгелек кылу

عن عبد الله بن أبي أوفى يقول : قال رسول الله ﷺ : "كم مسح على رأس يتيم رحمة كتب الله له بكل شعرة ملات عليها يده حسنة ، زمحت عنه بكل شعرة سيئة ، زرفع له بكل شعرة درجة".

Габдулла бине Вәфәдән риваять ителә. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Берәү шәфкать йөзеннән ятимнең башыннан сыйпаса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә кулы үткән һәр төк саен бер изгелек язар һәм ул кешедән һәрбер төк саен явызлыкны алыр һәм ул кешене һәрбер төк саен бер дәрәҗәгә ирештерер».

عن ابن عباس ﷺ قال : قال رسول الله ﷺ : "ضم يتيما من بين يتامي المسلمين إلى طعامه وشرابه حتى يغنيه الله تعالى ، أوجب الله تعالى له الجنة البتة ، إلا أن يعمل عملا لا يغفره الله له ، ومن أذهب الله كريمته فصبر واحتسب أوجب الله له الجنة البتة إلا أن يعمل عملا لا يغفره الله له" قيل : وما كريمته؟ قال : "عينه ومن كان له صلاص بنات أو مثلهن من الاخوات فأدبهن وأنفق عليهن حتى يمتن ، أو يبني بهن اوجب الله له الجنة البتة غلا أن يعمل عملا لا يغفره لله له" ، قال : فناداه رجل من الأعراب فقال : يا رسول الله أو اثنتين؟ قال : "أواثنتين".

Ибен Габбастан риваять ителә: Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Бер кеше мөселман ятимнәр арасындагы ятимне бәлагатькә ирешкәнче үзенең ашына һәм эчемлегенә кушса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә һичшиксез җәннәтне вәҗиб итәр. Мәгәр Аллаһы Тәгалә ярлыкамаслык гамәл кылса гына җәннәткә кермәс. Аллаһы Тәгалә берәүнең кәримәсен бетерсә һәм шуңа сабыр итеп әҗеренә ышанса, Аллаһы Тәгалә – ул кешегә һичшиксез җәннәтне вәҗиб итәр. Мәгәр Аллаһы ярлыкамастай эш эшләгән вакытта җәннәт вәҗиб булмас». «Кәримә» нәрсә ул, дип сорадылар. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм: «Күзе», – дип җавап бирде. Берәүнең өч кызы булып, аларны әдәпкә өйрәтсә һәм ул кызлары үлгәнче яки аларны кияүгә биргәнче аларга мал сарыф итсә, һичшиксез Аллаһы Тәгалә ул кешегә җәннәтне вәҗиб итәр. Мәгәр ярлыкамастай эшне эшләгән вакытта гына җәннәтне вәҗиб итмәс». Ибен Габбас әйтте: «Шул арада кыр гарәпләреннән бер кеше кычкырып әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, ике кызы булсадамы?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Ике кызы булса да шул ук әҗер булыр». Риваять итүче

әйтте: «Ошбу хәдисне сөйләгәндә Ибен Габбас: «Аллаһы белән ант итәм, бу хәдис хәдисләрнең иң кызыкларыннан», – дип әйтә иде».

وعن أبي درداء ﷺ أن رجلا جاء إلى النبي ﷺ فشكا إليه قسوة القلب ، فقال له النبي ﷺ : "إن سرك أن يلين قلبك فامسح برأس اليتيم وأطعمه".

Әбү Дәрдәдән риваять ителә: «Дөреслектә, бер кеше Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә килеп күңеленең каралыгыннан зарланды. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Күңелеңнең йомшаклануы уеңа килсә, ятимнең башын сыйпа һәм аны ашат».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Ибен Гомәрдән риваять итте. Дөреслектә, Ибен Гомәр зур гөнаһлар турында соралды. Ул әйтте: «Зур гөнаһлар тугыз: 1) Аллаһыга ширек китерү; 2) мөэмин кешене үтерү; 3) сугыш сафыннан качу; 4) ятим малын ашау; 5) риба ашау; 6) ата-ананы рәнҗетү; 7) сихерчелек; 8) хәрамны хәләлгә санау; 9) яла ягу».

Мөҗәһит Ибен Габбастан риваять итә: ул әйтте: «Һәлакәткә китерүче алты төрле гамәлгә тәүбә юк: 1) хаксызга ятим малын ашау; 2) пакь, зина кылмаучы хатынга, зина кылган дип яла ягу; 3) сугыш сафыннан качу; 4) сихерчелек; 5) Аллаһы Тәгаләгә ширек кылу; 6) пәйгамбәрләрдән бер пәйгамбәрне үтерү».

Аллаһы Тәгаләнең аятенең тәфсире турында Ибен Габбастан риваять ителә:

إِنَّ الَّذِينَ يَأْكُلُونَ أَمْوَالَ الْيَتَامَى ظُلْمًا إِنَّمَا يَأْكُلُونَ فِي بُطُونِهِمْ نَارًا وَسَيَصْلَوْنَ سَعِيرًا

«Бидгать гамәлләрне сәбәп итеп, яки башка золым юлы белән ятимнәр малын ашаган кешеләр ахирәттә, әлбәттә, карыннарына утны ашарлар һәм

бик тиз җәһәннәм утына керерләр, ягъни ахирәттә тәмугка керерләр». («Ниса» сүрәсе, 10)

Әйтелде: «Ятим булган йортка ни сөенеч һәм ятим булган йортка ни үкенеч, ягъни ятим хакын белгән йорт халкына ни сөенеч, ятим хакын белмәгән йорт халкына ни үкенеч».

وروى أن رجلا جاء إلى النبي ﷺ فقال : عندي يتيم فمم أضربه ؟ قال : "مما تضرب به ولدك".

Дөреслектә, бер кеше Пәйгамбәр галәйһиссәләм янына килеп әйтте: «Минем янымда бер ятим бар, аңа сугарга ярардай сәбәпләр бармы?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Балаңны нәрсә белән сугасың, ягъни ата баласына суккан кебек авырттырмыйча гына әдәп өчен ятимгә сугуда зарар юк».

Фөдайлдән риваять ителә. Ул әйтте: «Ятимгә сугуга караганда яхшы аш ашату күпкә файдалырак».

Фәкыйһ әйтте: «Әгәр ул ятимне башкача тәрбияләргә көче җитмәсә, аны сугу тиешле. Чөнки ятимгә сугу зур һәм каты эш». Фәкыйһ риваять иткән хәдиснең дәлиле булганга күрә ятимгә сугу бик каты эш санала.

عن عمر بن الخطاب ﷺ قال : قال رسول الله ﷺ : "إن اليتيم إذا ضرب اهتز عرش الرحمن لبكائه ، فيقول الله تعالى : يا ملائكتي من أبكى الذي غيبت أباه في التراب ؟ وهو أعلم به ، قال : تقول للملائكة : ربنا لاعلم لن ، قال : فإني أشهدكم أن من أرضاه في فأرضيه من عندي يوم القيامة".

Гомәр бине Хаттабтан риваять ителә. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әгәр ятим сугылса, аның елавыннан Аллаһы Тәгаләнең Гареше селкенер. Аллаһы Тәгалә Үзе белүчерәк булса да әйтер: «Әй фәрештәләрем, Мин атасын туфракка яшергән ке-

шене кем елатты?» Фәрештәләр әйтерләр: «Әй Раббыбыз, безнең гыйлемебез юк». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Дөреслектә, Мин сезне шаһид итәм, берәү Минем ризалыгым хакына ул ятимне разый кылса, Мин аны Кыямәт көнендә Үз каршымдагы нәрсәдән разый итәрмен».

Риваять итүче әйтте: «Рәсүлуллаһ ятимнәрнең башын сыйпады, һәм аларга шәфкать итә торган иде. Гомәр разыяллаһү ганһү дә шулай итә иде».

Габдрахманнан риваять ителә: ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә Давыд галәйһиссәләмгә әйтте: «Ятимгә шәфкатьле ата кебек бул. Шуны бел, син нәрсә чәчсәң шуны урырсың. Шуны бел, иренә игелекле булучы хатын алтын белән таҗланган падишаһ кебек. Ул хатынны күргәннән аның күзе нурланыр. Иренә явыз хатын карт кешегә авыр йөк кебек».

وعن زيد بن أسلم ﷺ أن النبي ﷺ قال : "أنا وكافل اليتيم المسلم كهاتين في الجنة".

Зәйд бине Әсләмнән риваять ителә. Дөреслектә Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Минем белән мөселман ятимнең тәрбиячесе җәннәттә бергә булуда бу ике бармак кебек», – диде. Һәм үзенең бармакларын күрсәтте.

Әбү Гыймраннан риваять ителә. Ул әйтте: «Давыд галәйһиссәләм мәсьәләсендә укыдым. Давыд галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһым, Синең ризалыгың өчен ятим һәм тол хатын тәрбиягә бирелгән кешенең әҗере ни булачак?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Минем күләгәмнән башка күләгә булмаган көндә ул кешене Үземнең күләгәм белән күләгәләрмен, ягъни Кыямәт көнендә Гареш күләгәсеннән башка күләгә булмас».

وعن عوف بن مالك الأشجعي أن النبي ﷺ قال : "ما من مسلم يكون له ثلاث بنات فينفق عليهن حتى بين أو يمتن ، إلا كن له حجابا من النار" فقالت امراة : يا رسول الله أو ثنتان ؟ قال : "أو ثنتان".

Гауф бине Мәликтән риваять ителә. Дөреслектә Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Бер мөселманның өч кызы булып, ул кызларны кияүгә биргәнче, яки кызлары үлгәнче ризыкландырса, Кыямәт көнендә алар шул атага тәмугтан пәрдә булырлар». Бер хатын: «Әй Рәсүлуллаһ, ике кызы булсадамы?» – дип сорады. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Икәү булса да».

وقال النبي ﷺ : "أنا وامراة سفعاء الخدين في الجنة كهاتين وأشار بأصبعيه امرأة مات زوجها فحبست نفسها على بناهّا حتى يبن أويمتن".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Мин һәм мәшәкать сәбәпле ике яңагы үзгәргән хатын җәннәттә ошбу ике бармак кебек янәшә булырбыз». Пәйгамбәр галәйһиссәләм бармагы белән ишарә итте. «Ике яңагы үзгәргән хатын» – ул ире үлеп, кызлары өчен иргә бармыйча, кызлары кияүгә бирелгәнче, яисә алар үлгәнче тол калучы.

عن أنس بن مالك ﷺ عن النبي ﷺ انه قال : "من حمل من السوق طرفة إلى ولده ، كان كمن يحمل صدقة حتى يضعها في فيهم ، وليبدأ بالإناث ، فإن الله تعالى يرق للإناث ، ومن رق للأنثى كان كمن بكى من خشية الله ، ومن بكى من خشية الله غفر له ، ومن فرح أنثى فرحه الله يوم الدين".

Язид Рәкаши Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә: ул әйтте: «Берәү балалар өчен базардан ашамлык күтәрсә, хәтта ашамлыкны авызларына салганга чаклы садака бирәчәк нәрсәне күтәргән

кебек булыр. Ул кеше ашамлык биргәндә кызлардан бирә башласын. Чөнки Аллаһы Тәгалә хатын-кыз өчен мәрхәмәтле. Бер кеше хатын-кызларга йомшарса, Аллаһыдан куркып елаган кеше кебек булыр. Бер кеше Аллаһыдан куркудан еласа, аның гөнаһысы ярлыканыр. Бер кеше кыз балага шатланса, Аллаһы Тәгалә ул кешене көенеч көнендә шатландырыр».

## Зина турында

عن أبي هريرة ويزيد بن خالد ﷺ أنهما أخبر : أن رجلين احتصما إلى رسول ﷺفقال أحدهما : يا رسول الله ، اقض بيننا بكتاب الله تعالى ، وقال الآخر وهو افقههما : أجل يا رسول الله ، أقض بيننا بكتاب الله ، وأذن لي أن أتكلم ، قال : "تكلم" قال : إن أبني كان عسيقا لهذا الرجل فزنى بامراته ، فأخبروني أن على أبني الرجم ، فافتديت منه بمائة شاة وجارية لي ، ثم سألت أهل العلم فأخبروني أن على بي مئة جلدة وتغريب عام ، وإنما الرجم على لمرأة ، فقال رسول الله ﷺ : "اما ولذي نفسي بيده ، لأقضين بينكما بكتاب الله تعالى ، أما غنمك وجاريتك فرد عليك ، وأما الذي على ابنك فجلد مائة ، وتغريب عام" فجلد بنه مائة ، وغربه عاما ، وامر أنيسا الاسلمي أن ياتي المرأة ، و قال : "أغد يا انيس إلى امراة هذا ، فإن اعترفت فارجمها" فاعترفت فرجمها.

Әбү Һөрәйрә белән Зәйд бине Халидтән риваять ителә. Дөреслектә алар хәбәр бирделәр. Рәсүлуллаһ янына ике кеше низагълашып килде. Аларның берсе: «Әй Рәсүлуллаһ, Аллаһының китабы белән безнең арабызда хөкем ит». Икенчесе галимрәге: «Әй Рәсүлуллаһ, Коръән белән безнең арабызда хөкем ит. Миңа сөйләргә рөхсәт бир». Пәйгамбәр галәйһиссә-

ләм: «Сөйлә», – диде. Хөкемгә килүченең икенчесе әйтте: «Дөреслектә, минем улым бу кешедә хезмәттә иде. Улым аның хатыны белән зина кылды. Минем улымны таш белән атып үтерү тиеш булуын әйттеләр. Мин ул кешедән улымны йөз куй һәм кәнизәгем бәрабәренә йолып алдым. Моннан соң гыйлем ияләреннән сорадым. Минем улымны йөз камчы бер ел читкә китеп тору важиб икәнен сөйләделәр. Зина кылучы хатынны исә таш белән атып үтерү тиеш, диделәр». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Минем җаным Аның кулында булган Зат белән ант итәм, мин һичшиксез Аллаһының Китабы белән икегезнең арада хөкем итәрмен. Әмма куең белән кәнизәгең сиңа кире кайтарылыр. Синең улың өчен булган хөкем – йөз камчы сугу белән ватаныннан чит җиргә китеп тору тиеш». Пәйгамбәр галәйһиссәләм Әнәс разыяллаһү ганһүгә хатын янына барырга кушты. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әй Әнәс! Бу кешенең хатыны янына бар. Әгәр хатын зина кылганын икърар итсә, ул хатынга таш белән ат». Хатын икърар итте, Әнәс ул хатынга таш белән атты. Тәхкыйк, Пәйгамбәр галәйһиссәләм зина хөкемен сөйләде. Дөреслектә, зина кылучының хатыны булмаса, аңа йөз камчы сугу важиб булыр. Аллаһы Тәгалә әйтте:

الزَّانِيَةُ وَالزَّانِي فَاجْلِدُوا كُلَّ وَاحِدٍ مِنْهُمَا مِائَةَ جَلْدَةٍ وَلَا تَأْخُذْكُمْ بِهِمَا رَأْفَةٌ فِي دِينِ اللَّهِ إِنْ كُنْتُمْ تُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ وَلْيَشْهَدْ عَذَابَهُمَا طَائِفَةٌ مِنَ الْمُؤْمِنِينَ

«Зиначы хатын белән зиначы ирнең һәрберсенә йөзәр камчы сугыгыз. Аллаһы Тәгалә билгеләгән хәддтә сезне шәфкать тотмасын, ягъни Аллаһы Тәгалә шулай кушканда кызганмагыз. Чөнки Аллаһы Тәгалә сездән булган бәндәләргә бигрәк тә мәрхәмәтлерәк. Зиначыларны дөньяда сугу белән боер-

ды. Берәү дөньяда Аллаһының җәзасын йөртмәсә, Кыямәт көнендә халык хозурында уттан булган камчылар белән сугылыр. Моннан соң Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әгәр сез Аллаһыга һәм Ахирәт көненә ышансагыз, хәддне туктатмагыз».

Янә Аллаһы Тәгалә әйтте: «Зиначыларның газабы вакытында мөэминнәрдән бер җәмәгать, ягъни зиначылар җәзага тартылганда мөэминнәр хәзер булсыннар. Халыкның хәзер булуы газап каты артык булсын өчен, чөнки зиначылар халык каршында булсалар, оялырлар. Бу эш зиначыларны зинадан тыю булыр һәм бу хәдд өйләнмәгән һәм кияүгә бармаган кешенең җәзасы. «Мухсин» булса дигән сүз – ир була. Әгәр ирнең хатыны булып, хатыны белән аулакта калган булса, яки зина кылучы хатынның ире булса һәм ул икенче ир белән бергә кавышкан булса, бу очракта ир һәм хатынның хәдде – таш белән атып үтерү.

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителә: дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм Мәгыйз бине Мәликне таш белән атты.

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителә: «Дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә бер хатын килеп, зина кылганын икърар итте. Ул хатын йөкле иде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм хатын баласын тудырганга кадәр кайтып торырга әмер итте. Ул хатын баласын тудыргач Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә килде һәм ул хатын таш белән атылды. Дөньяда зинаның җәзасы шушыдыр. Зиначылар өчен дөньяда хәдд ителү бик яхшы. Әгәр дөньяда хәдд ителмәсәләр, алар ахирәттә җәзаланырлар. Ахирәт газабы катырак һәм озаграк. Зинадан сакланыгыз, чөнки ул зина зур гөнаһ. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Зинага якын килмәгез, чөнки зина – начар эш». Ягъни зина кылмагыз, зина-

дан сакланыгыз, чөнки зина кылучыга гөнаһ һәм Аллаһының ачуы ирешер.

Ул зина нинди начар юл! Зина халык өчен нинди начар эш, ягъни зина кылучы үзен тәмугка алып бара торган юлны ихтыяр итеп алды. Янә Аллаһы Тәгалә икенче аятендә әйтте:

﴿قُلْ إِنِّي أَخَافُ إِنْ عَصَيْتُ رَبِّي عَذَابَ يَوْمٍ عَظِيمٍ﴾

«Әйт, әгәр мин бидгатьче мөшрикләргә ияреп, тәрбиячем булган Аллаһы Тәгаләнең хөкемнәренә хилафлык кылсам, әлбәттә, олуг Кыямәт көненең газабыннан куркамын». («Әнгам» сүрәсе, 151)

Ягъни олуг булганы – зина, кечкенәсе – үбү белән кагылу, һәрберсе – зинадан санала. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән ишетелде: «Әгәр нәмәхрәмгә кагылса, ике кул зина кыла һәм нәмәхрәмгә караса, ике күз зина кыла». Аллаһы Тәгалә әйтте:

قُلْ لِلْمُؤْمِنِينَ يَغُضُّوا مِنْ أَبْصَارِهِمْ وَيَحْفَظُوا فُرُوجَهُمْ ذَلِكَ أَزْكَى لَهُمْ إِنَّ اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا يَصْنَعُونَ(٣٠)وَقُلْ لِلْمُؤْمِنَاتِ يَغْضُضْنَ مِنْ أَبْصَارِهِنَّ وَيَحْفَظْنَ فُرُوجَهُنَّ

«Мөэминнәргә әйт, карарга ярамый торган нәрсәләрдән күзләрен йомсыннар, күрсәтергә ярамый торган әгъзаларын күрсәтмәсеннәр, ике бот арасын зинадан сакласыннар. Бу әйткәнне эшләү аларга пакьлек. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә аларның кылган эшләреннән хәбәрдар. Мөэминә хатыннарга әйт, карарга ярамаган нәрсәдән күзләрен йомсыннар, фәрежләрен зинадан сакласыннар». («Нур» сүрәсе, 30,31)

Тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә хәрамнан күзләрне йому белән ирләргә дә, хатыннарга да әмер итте. Фәрежләрен хәрамнан саклауны боерды. Тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә Коръәндә, Зәбурда, Инҗилдә һәм Тәүратта күп аятьләр белән зинаны хәрам итте. Ул

зина – олуг гөнаһ. Мөселманнарның хөрмәт пәрдәсен ертудан, нәсәбләрне капма-каршы кылудан да зуррак нинди гөнаһ булыр?!

Җәгъфәр бине Әбү Талибтән риваять ителә: дөреслектә, ул җаһилият заманында зина кылмый торган иде. «Әгәр берәү минем хөрмәтемне төшерсә, мине гаҗәпләндерми. Мин һичберәүнең хөрмәт пәрдәсен ертмам», – дип әйтә торган иде.

Сәхабәләрнең кайберләреннән риваять ителә: дөреслектә ул әйтте: «Сез зинадан сакланыгыз, чөнки ул зинада алты төрле җәза бар: өчесе – дөньяда, өчесе – ахирәттә булыр. Дөньяда булганнары: ризыкның кимлеге, ягъни зиначының ризыгының бәрәкәте китәр; изгелекләрдән мәхрүм булыр; кешеләрнең күңелендә ачулы булып калыр. Ахирәттә булганнары: Аллаһы Тәгаләнең ачулануы; хисапның катылыгы һәм тәмугка керү. Ул тәмугны Аллаһы Тәгалә зур ут дип атады».

وروى عن النبي ﷺ أنه قال : "إن ناركم هذه جزء من سبعين جزءا من نار جهنم".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителә: ул әйтте: «Дөреслектә, сезнең бу утыгыз, тәмуг утының җитмеш өлешеннән бер өлеш кенә».

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителә: Ул Җәбраилгә әйтте: «Миңа тәмугның сыйфатларын сөйлә». Җәбраил әйтте: «Әй Мөхәммәд, каралыкта бик нык кара, башкаларны караңгылаучы. Әгәр тәмуг утыннан энә тишеге кадәре генә дә дөньяга чыкса, җир йөзендәге нәрсәләрне яндырыр иде. Әгәр тәмуг киемнәреннән булган бер кием җир белән күк арасына элеп куелса, ул киемнең сасы исеннән бөтен җирдәге халык үләр иде. Әгәр тәмуг ашамлыгыннан бер тамчысы җиргә ташланса, җир халкының көн-

күреш рәвешен бозар иде. Әгәр Аллаһы Тәгалә Үзенең китабында бәян иткән унтугыз фәрештәдән берсе җир халкына күренсә, ул фәрештәнең ямьсезлегеннән җир халкы үләр иде. Аллаһы Тәгалә Үзенең китабында бәян иткән чылбырлардан бер боҗра җиргә ташланса, ул җирне аскы катлавына кадәр ватар иде. Шуннан соң тукталмастан, тәмам җәһәннәмгә кадәр төшерер иде». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әй Җәбраил, җитәр». Аннан соң Рәсүлуллаһ белән Җәбраил галәйһимәссәләм еладылар. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Җәбраил, син дә елыйсың, хәлбуки үзең Аллаһы Тәгаләнең шундый зур мәртәбәле урынында торасың». Җәбраил галәйһиссәләм әйтте: «Әй Мөхәммәд, Аллаһы Тәгалә каршында хәзерге дәрәҗәмнән башкача урында булмавымнан мине ни-нәрсә тынычландырсын? Һарут белән Марут һәм Иблис мәлгунь бәлаләнгән нәрсә белән бәлаләнмиячегемә мине нәрсә ышандыра». Җәбраил галәйһиссәләм үзенең Раббысына хөрмәтле булуы белән елый торган иде. Шулай булгач, гөнаһ кылучы кешегә ничек еламаска кирәк. Син тереклегең һәм сәламәтлегең белән алданма. Чөнки дөнья үтә, газап исә озын. Зинадан саклан, чөнки ул зина ачуны калдыра һәм каты газапны ваҗиб иттерә. Зинаның иң катысы даими кылына торганы. Даими зина кылучы ул хатынын талак итәр, ул кешенең хатыны белән торуы хәрам булыр. Хәрам кылуын кешеләр каршында хурланудан куркып икърар да итми. Серләр беленә торган көндә ахирәт хурлыгыннан ничек курыкмый?! Шулай булса ул көннең хурлыгыннан саклан. Зинадан саклан һәм зинага даимчылык кылма. Чөнки син Аллаһы Тәгаләнең газабына чыдый алмассың. Аллаһы Тәгаләгә тәүбә кыл, чөнки

Аллаһы Тәгалә бәндәләрен ярлыкый. Вафат булгач үкенү һәм тәүбә сиңа файда бирмәс. Тәүбә һәм үкенү терек булганда гына файда бирә. Аллаһы Тәгалә мөэминнәрне фәрежләрне саклау белән мактады. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَالَّذِينَ هُمْ لِفُرُوجِهِمْ حَافِظُونَ . إِلَّا عَلَى أَزْوَاجِهِمْ أَوْ مَا مَلَكَتْ أَيْمَانُهُمْ فَإِنَّهُمْ غَيْرُ مَلُومِينَ . فَمَنْ ابْتَغَى وَرَاءَ ذَلِكَ فَأُوْلَئِكَ هُمُ الْعَادُونَ ﴾

«Һәрбер мөселман кешегә зинадан тәүбә кылу һәм кешеләрне зинадан тыю важиб. Чөнки Аллаһы Тәгалә һәрбер зина чыккан урындагы кешеләрне тагун авыруы белән бәлаләндерер».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Гакрәмәдән риваять итә: «Кәгебтән ишеттем, Кәгеб Ибен Габбаска әйтә иде: «Кылыч ялангачланганын, ягъни каннан чыгарылганын һәм каннарның агызылганын күрсәгез, белегез, алар арасында Аллаһының боерыгы тар кылынды, ягъни Аллаһы хөкеме буенча эш кылынмады. Аллаһы аларның кайберсеннән үч алды. Әгәр яңгыр яумаганын күрсәгез, белегез, дөреслектә, кешеләр, зәкәтне тыйдылар, бирми башладылар. Аллаһы Тәгалә дә Үз каршындагы нәрсәне тыйды. Әгәр тагунның таралганын күрсәгез, белегез, дөреслектә, зина таралды».

## Риба

عن أبي هريرة ﷺ أن النبي ﷺ قال : "ليلة أشرى بي سمعت في السماءالسابعة فوق رأسي رعدا وصواعق ورأيت برقا ، ورأيت رجالا بطونهم بين أيديهم كالبيوت ، فيها حيات ترى نت ظاهر بطونهم ، فقلت يا جبريل : من هؤلاء ؟ قال : هؤلاء أكلة الربا".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителә: Дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Мигъраҗ кичәсендә, җиденче кат күктә баш өстемдә күк күкрәү һәм яшен тавышын ишеттем һәм яшенне һәм шунда кешеләрне күрдем. Алларындагы корсаклары йортлар кебек, корсаклары эчендә еланнар, эчләре тышкы якларыннан күренәләр. Мин: «Әй Җәбраил, болар кемнәр?» – дип сорадым. Җәбраил галәйһиссәләм әйтте: «Риба ашаучылар».

Гата Хорасәнидән риваять ителә: Габдулла бине Сәләм әйтте: «Риба җитмеш ике гөнаһ кадәр, ягъни җитмеш өлеш. Ул рибаның гөнаһ йөзеннән иң кечкенәсе – мөселманның анасы белән зина кылганы кебек. Рибадан булган бер дирһәм акча, утыз зинадан да явызрак». Габдулла бине Сәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә һәр явыз һәм изге кешегә торырга рөхсәт итә, мәгәр риба ашаучыга гына тору белән кушмый. Чөнки риба әһеле тормас, мәгәр торса, дивана кеше кебек торган саен егылыр».

الَّذِينَ يَأْكُلُونَ الرِّبَا لَا يَقُومُونَ إِلَّا كَمَا يَقُومُ الَّذِي يَتَخَبَّطُهُ الشَّيْطَانُ مِنْ الْمَسِّ

«Риба ашаучылар, ягъни бурычка биреп торган өчен арттырып алучылар, каберләреннән, шайтан буып ташлаган кеше кебек, бик яман сурәттә кубарлар». («Бәкара» сүрәсе, 275)

Гомәр бине Хаттабтан риваять ителә: ул әйтте: «Коръәннең иң соңыннан иңгән аяте – рибаның хәрам булуы турындагы аять. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм риба аятен безгә тәфсир кылмыйча вафат булды. Рибаның кечкенәсен дә, зурысын да куегыз (ташлагыз)».

عن الحارث ، عن علي ﷺ أنه قال : لعن رسول الله ﷺ آكل الربا ، وموكله وشاهديه ، وماتبه ، والواشمة والمستوشمة ، والمحلل ونحلل له ، ومانع الصدقة .

Хәрис Гали разыяллаһү ганһүдән риваять итә: ул әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм риба ашаучыны, риба катнашкан сәүдәнең вәкилен, ике шаһидны, риба кергән сәүдәне язучыны, сүз йөртүчене, сүз йөрттерүчене, өч талак әйткәннән соң хәйлә белән хәләл кылучыны, хәләл иттерелгән кешене, зәкәт бирмәүчене ләгънәт кылды».

Габдулла бине Мәсгуд Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә: ул әйтте: «Берәү хәрамны кәсеп итеп, шул малны садака итеп бирсә, аның садакасы хозурына савап булмас һәм аннан сарыф та итмәс. Аның өчен малда бәрәкәт булмас, малын үзеннән соң калдырмас, мәгәр калдырды исә, бәндәнең азыгы җәһәннәм өчен генә булыр».

Әбү Рафигътән риваять ителә: ул әйтте: «Әбү Бәкер разыяллаһү ганһүгә хатыннарның иң башларыннан һәм култык астыннан кия торган зиннәтле нәрсәсен саттым. Мизанның бер табагына шул нәрсәне, икенче табакка көмеш акчаларны салдым. Сатыла торган әйбер көмеш акчаларга караганда аз гына авыр булды. Әбү Бәкер кайчы алды. Мин: «Әй Рәсүлуллаһның хәлифәсе, артыгы сиңа булсын», – дидем. Ул әйтте: «Юк, булмасын. Рәсүлуллаһтан ишеттем, ул әйтте:

الزائد والمستزيد في النار

«Арттыручы да һәм арттырып алучы да тәмугта булыр».

أبو هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "الفضة بالفضة مثلا بمثل والفضل ربا ، والحنطة بالحنطة مثلا بمثل والفضل ربا وذكر الشعير والتمر والملح ، ثم قال : فمن زاد أو استزاد فقد أربي"

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителә: Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Көмешне көмеш бәрабәренә үлчәгәндә бертигез сату тиеш, артыгы риба була. Онны он бәрабәренә бертигез үлчәргә кирәк, артыгы риба. Арпаны, хөрмәне һәм тозны да бәян итте». Аннан соң Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Берәү арттырып алса яки арттырып бирсә, тәхкыйк, ул кеше риба ашады».

Ибен Мәсгудтән риваять ителә: ул әйтте: «Рибадан куркып, хәләл нәрсәләрнең уннан тугыз өлешен кылмый торган булдык».

Гомәр бине Хаттабтан шулай ук риваять ителә. Әйтелде: «Бер шәһәрдә зина кылынса яки риба ашалса, ул шәһәр харап ителмичә калмас».

Гали разыяллаһү ганһүдән риваять ителә: ул әйтте: «Диндә галим булмастан элек бер кеше сату итсә, тәхкыйк, ул кеше рибага чумганнан чумды».

Галә үзенең бабасыннан риваять итеп әйтте: «Гомәр разыяллаһү ганһү әйтте: «Диндә галим булмаган кешеләр безнең базарларыбызда сату итмәсеннәр».

Ләестән риваять ителә: ул әйтте: «Дүрт нәрсәне хәләл санасалар, авылларның һәлак ителүенә рөхсәт бирелер. Шуларның берсе, үлчәүне киметү; икенчесе, сәүдә иткәндә үлчәүне тутырмау; өченчесе, зинаны ачык кылу; дүртенчесе, рибаны ашау. Әгәр ачык зина кылсалар, аларга ваба (чума) авыруы ирешер. Әгәр үлчәүне тутырмасалар, яңгыр яумас булыр. Әгәр риба ашасалар, алар хозурына кылычны

чыгарырлар. Мин Гали бине Әбү Талиб артыннан базарда йөри торган идем. Хәлбуки, Галинең кулында камчысы булыр иде. Үлчәүне тутырмый торган кешене күрсә, камчысы белән сугып: «Үлчәвеңне тутыр», – дип әйтә иде.

Ибен Габбастан риваять ителә: ул әйтте: «Әй гарәп булмаган халыклар! Сездән элек булган кешеләр һәлак ителгән ике эшне үзегезгә бәла һәм зәхмәт иттегез. Ул гер үлчәве белән савыт үлчәве, ягъни шул үлчәүләрдә хыянәт иттегез».

وروى عن رسول الله ﷺ أنه قال : "ياتي على الناس زمان لا يبقى أحد إلا أكل الربا" قسل : يا رسول الله ، أو كلهم ياكلون الربا ؟ قال : "من لم ياكل منه يصبه من غباره".

Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Адәмнәргә шундый заман килер, һичкем риба ашамыйча калмас». Әйтелде: «Әй Рәсүлуллаһ, һәр бәндә риба ашармы?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Ашамаса да, аңа тузаны, ягъни гөнаһысы ирешер. Чөнки ул моңа ярдәм итә. Ул риба ашамаса да рибалы сәүдәгә шаһид яки риба ашаучының эшенә разый була. Мондый кешегә шул рибачының өлеше булыр».

Әбү Бәкер разыяллаһү ганһүдән риваять ителә: «Артык бирүче һәм артык алучы җәһәннәмдә булыр».

Шулай булгач, сәүдәгәргә сәүдәсе өчен никадәр гыйлем кирәк, шул чаклы гыйлем өйрәнү, риба ашамасын өчен үлчәүдә тырышу тиешле була. Чөнки Аллаһы Тәгалә үлчәү хакында каты һәм куркынычлы вәгъдәләр әйтте. Аллаһы Тәгалә үлчәүне киметүчеләргә ни үкенеч, ягъни каты газап вәгъдә итте.

Коръән Кәримдә Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَيْلٌ لِلْمُطَفِّفِينَ(١)الَّذِينَ إِذَا اكْتَالُوا عَلَى النَّاسِ يَسْتَوْفُونَ(٢)وَإِذَا كَالُوهُمْ
أَوْ وَزَنُوهُمْ يُخْسِرُونَ(٣)أَلَا يَظُنُّ أُولَئِكَ أَنَّهُمْ مَبْعُوثُونَ(٤)لِيَوْمٍ عَظِيمٍ ﴾

«Киметеп үлчәүчеләргә үкенеч каты газап. Алар башка кешеләрдән берәр нәрсә үлчәп алсалар, үлчәүне тутырып, мул үлчәп алалар. Башка кешеләргә савыт яки бизмән белән үлчәп биргәндә киметеп үлчиләр. Әллә ул кешеләр терелеп кубарылачакларын уйламыйлармы. Олуг Кыямәт көнендә». («Мутаффифин» сүрәсе, 1–5 аятьләр). «Вәйл» – ул үлчәүдә хыянәт итүчеләргә махсус булган җәһәннәм уртасындагы чокыр. Үлчәп алганда тәмам тутырып алалар, биргәндә киметеп бирәләр. Моннан соң Аллаһы Тәгалә әйтте: әллә алар куркыныч зур булган Кыямәт көнендә кубарылачакларын белмиләрме? Әй Адәм баласы, уйла, Аллаһы Тәгалә зур дип атаган көн ничек булыр? Кайсы көн ул көннән куркынычлы һәм олуг булыр? Ул көндә бәндәләр Аллаһы Тәгалә каршында торырлар. Аллаһы Тәгалә аларның азыннан һәм күбеннән сорар. Бәндә үзенең китабыннан, ягъни дәфтәреннән укыр. Үзләренең явызлык һәм яхшылыкларын табарлар. Синең Раббың һичкемне җәберләми. Шулай булгач, дөньяда вакытта адәмнәрнең хакларында гаделлек иткән кешегә ни сөенеч. Адәмнәрнең хакларында гадел булмаучыга ни үкенеч.

Гомәр разыяллаһү ганһүдән риваять ителә: Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Дөреслектә, гаделлек Аллаһы Тәгаләнең җирдәге үлчәве. Бер кеше ул гаделлекне алса, гаделлеге аны оҗмахка җитәкләр. Бер кеше гаделлекне ташласа, ул аны тәмугка өстерәр. Дөреслектә, гадел кеше халык арасындагы солтаннан үзләре арасындагы халыклар

җөмләсеннән дә булыр. Каты газаптан котылуыгыз өчен сезгә тигезлек лязем булсын, тигез булыгыз».

## Гөнаһлар турында

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Җәбир бине Габдулладан риваять итә: ул әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән ишеттем. Ул әйтте: «Муса галәйһиссәләмгә Аллаһының биргән нәрсәләре арасында ун баб булды. Беренчесе, әй Муса, Миңа һичнәрсәне шәрик итмә. Тәхкыйк, Миннән сүз әйтелде. Аллаһыга ширек китерүчеләрнең йөзләрен ут ялкыны ялап көйдерер. Миңа һәм ата-анаңа шөкер ит. Сине һәлакәттән саклармын һәм шул һәлакәтләрне сиңа оныттырырмын. Сине күркәм тормыш белән яшәтермен. Хәзерге тереклегеңнән изгерәккә күчерермен. Үтерү хәрам иткән кешене үтермә. Әгәр Мин хәрам иткән кешене үтерсәң, синең хозурыңа җир йөзенең бөтен киңлеге һәм күк йөзе үзенең тарафлары белән тараер. Ачуым сәбәпле җәһәннәмгә керерсең. Минем исемем белән ялганлаучы, яки гөнаһлы булган хәлдә ант итмә. Чөнки Мине пакьләмәгән, исемнәремне олугламаган кешене Мин дә пакьләмәм. Үземнең фазыйләтемнән адәмнәргә биргәнемне көнләмә. Чөнки көнче кеше Минем нигъмәтемә дошман, хөкемемне кайтаручы. Бәндәләремә өлешләп биргән ризыгыма ачулы. Әгәр бирәү Мин кушканча булмаса, Мин аннан, ул Миннән түгел. Үзең ишетмәгәнгә шаһидлык бирмә, акылың күңелеңә алмаганга һәм күңелең теләмәгәнгә шаһидлык бирмә. Чөнки Кыямәт көнендә шаһидлык бирүчеләрнең шаһидлыкларына төшенүчемен. Син күрше хатыны белән зина кылма, әгәр күрше хатыны белән зина кылсаң, Мин йөземне синнән борырмын.

һәм синнән күк ишекләрен бикләрмен, үзең сөйгән әйберне кешеләр өчен дә ярат. Минем исемемнән башка хайван бугазлама. Чөнки Мин исемем зекер ителмәгән якынлыкны сөймим, тик Минем ризалыгым өчен генә кылынганны сөям. Минем ризалыгым өчен генә гыйбадәт кылу белән шимбә көн эштән буша. Бөтен өй җәмәгатеңне шимбә көнне бушандыр».

Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәләм өчен шимбә көнне, безнең өчен җомганы сайлап гает кылды».

عن محمد مب كعب القرظي ، قال : قام النبي ﷺ على لمنبر فقبض كفه اليمني ، ثم قال : "كتابا كتب الله تعالى فيه اهل الجنة ياسمائهم وانسبهم ، ولا يزاد فيهم ولا ينقص" ،. ثم قبض كفه اليسري فقال : "كتابا كتب الله فيه اهل النار باسمائهم وانسبهم لا يزاد فيه ولا ينقص ، وليعملن أهل السعادة بعمل أهل الشقاء حتى يقال باهم منهم بل.هم ، ثم يستنقذهم الله تعالى بقضائهم من الشقاء إلى السعادة قبل الموت ولو بفواق ناقة ، وليعملن أهل الشقاء بعمل أهل السعادة حتى الموت ولو بفواق ناقة السعيد من سعد بقضاء الله تعالى ، والشقي بقضاء الله ، والاعمال بالخواتيم".

Мөхәммәд бине Кәгеб Карзыйдән риваять итә: Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм минбәргә менде, уң учын йомарлап әйтте: «Шундый дәфтәр бар, Аллаһы Тәгалә ул дәфтәрдә җәннәт халкының исемнәрен, нәселләрен язды. Шул язылганнан арттырылмый да, киметелми дә. Бәхетле, ягъни җәннәт кешеләре җәһәннәм кешеләре кыла торган гамәлләрне кылырлар, хәтта ул җәннәт әһелләре – гүя шул җәһәннәм әһелләредер, бәлки үзләре үк, – дип әйтелә. Моннан соң шул бәхетле булучыларны Аллаһы Тәгалә Үзенең хөкеме белән үлемнән элек явызлык-

тан, ягъни бәхетсезлектән, хәтта терек вакытта дөя-
нең бер төчкерегә хәтле генә булса да җәннәткә китерә. Бәхетсез халык, ягъни җәһәннәм халкының кайберсе җәннәт кешеләренең гамәлләрен кылалар, гүя алар җәннәт әһелләреннән, бәлки үзләре үк, дип әйтелер. Аллаһы Тәгалә ул бәхетсезләрне җәннәт әһеле янәшәсеннән, әлбәттә, чыгарыр. Моннан соң Аллаһы Тәгалә аларны һичшиксез үлемнән элек дөянең бер төкерегә кадәр вакыт булса да җәһәннәмнән чыгарыр. Бәхетле булучы – ул Аллаһы Тәгаләнең хөкеме белән җәннәтле булучы кеше. Гамәлләр исә соңгы яхшы яки начар сулыш белән булыр».

وروى عن فضلة بن عبيد ، عن رسول الله ﷺ انه قال في حجة الوداع ك

"ألا اخبركم بالمؤمن ولمسل والمجاهد والمهاجر ، والمؤمن من امنه الناس على أموالهم وأنفسهم ، والمسلم من سلم الناس من سانه ويده ، والمجاهد من جاهد نفسه في طاعة الله تعالى ، والمهاجر من هجر الذنوب والخطايا".

Фудаләтә бине Гобәйд Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә: дөреслектә ул соңгы хаҗында сәхабәләренә әйтте: «Мөэминнең кем икәнен әйтимме? Адәмнәр үзләренең малларына да, җаннарына да ул кешедән зарар килмәү турында тыныч булырлар. Мөселман шул ки, адәмнәр аның теленнән һәм кулыннан зарарсыз булырлар. Сугышчы – ул Аллаһы Тәгаләгә буйсынуда нәфесе белән көрәшүче. Һиҗрәт кылучы – ул гөнаһларны һәм хата эшләрне ташлаучы».

Әбү Дәрдә әйтте: «Гүя Аллаһыны күргән кебек Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылыгыз. Белегез, дөреслектә, сезнең ихтыяҗыгыз кадәрле аз нәрсә Аллаһыны онытдыра торган күп малдан изгерәк.

Белегез, дөреслектә, изгелек – һич югалмас, гөнаһ эш – һич онытылмас».

وروى ابن عمر ﷺ عن النبي ﷺ انه قال : "البر لا يبلى ، والإثم لا ينسى ، والديان لا يفنى — كن كما شئت — يعني كما تدين تدان".

Ибен Гомәр Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә. Дөреслектә ул әйтте: «Дөреслектә яхшылык югалмас һәм явызлык һич онытылмас. Җәза кылучы, ягъни Аллаһы Тәгалә һич фани булмас. Ничек теләсәң шулай бул, ничек эш кылсаң, шулай каршылык ителерсең».

Фәкыйһ рахмәтуллаһи галәйһи әйтте: «Кәмә тәдинү түдән» сүзенең мәгънәсе, әгәр син изгелекне эшләсәң, изгелек әҗерен табарсың. Әгәр син явызлыкны эшләсәң, шул явызлык бәрабәрендә Кыямәт көнендә явыз җәза белән җәзаланырсың. Аллаһы Тәгаләнең, яхшылык итсәгез дә, явызлык кылсагыз да үзегез өчен, дип әйткән сүзе кебек, ягъни, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә бераүне җәбер итми һәм бәндәнең изгелекләренең әҗерен һич киметми. Гөнаһысыз ул кешене газапламый. Тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә туры юлны күрсәтте, өммәтенә яхшылыкка өндәүче һәм күркәм холыклы илче җибәрде. Оҗмах юлы белән тәмуг юлын белдерде.

وروى أبو هريرة ﷺ عن رسول الله ﷺ انه قال : "مثلي ومثلكم كمثل رجل أوقد نارا فجاء الفراش يتهافتن فيها ، فانا امنعكم من أن تقعوا في النار".

Әбү Һөрәйрә Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә. Дөреслектә ул әйтте: «Сезнең белән минем охшашыбыз ут кабызып яндырган кеше кебек. Ул ут янына күбәләкләр килеп, шул утка төшәләр. Мин сезне утка төшүдән тыям, ягъни сезне гөнаһ-

лардан тыям. Чөнки гөнаһлар гөнаһ кылучыны тәмугка ташлый».

Адәм галәйһиссәләмнең тәүбәсе биш төрле хасият өчен кабул ителде. Берсе, Адәм галәйһиссәләм үзенең гөнаһысын икърар итте һәм шул гөнаһ өчен үкенде, үз-үзен шелтәләде, тәүбәне ашыктырды. Аллаһының рәхмәтеннән өметен өзмәде, биш төрле нәрсә өчен Иблис мәлгуньнең тәүбәсе кабул ителмәде, чөнки ул Иблис үзенең гөнаһлы икәнен икърар итмәде, гөнаһлы булуына үкенмәде, үз-үзен шелтәләмәде, тәүбәне ашыктырмады, Аллаһының рәхмәтеннән өмет кисте. Берәүнең хәле Адәм галәйһиссәләм хәле кебек булса, аның тәүбәсе кабул ителер. Иблис халәтендә булучының тәүбәсе кабул ителмәс.

Ибраһим бине Әдһәмнән риваять ителә: ул әйтте: «Минем өчен Аллаһы Тәгаләгә буйсына торып та, тәмугка керүем, Аллаһы Тәгаләгә гөнаһ кылып та җәннәткә керүемнән сөеклерәк». Бу сүзнең мәгънәсе, Аллаһы Тәгаләгә гөнаһлы булып җәннәткә керсә, гөнаһ кылганы өчен Аллаһыдан оялуы кала. Әгәр ул тәмугка керсә, хәлбуки Аллаһы Тәгаләгә буйсынган булса, Ибраһим бине Әдһәмгә кызару һәм оялу булмас һәм тәмугтан чыгуы өмет ителә.

Мәлик бине Динардан риваять ителә: «Мәлик бине Динар каты салкында Готбә исемле кеше яныннан үтте. Готбәнең өстендә начар иске күлмәк иде. Готбә уйга чумды һәм тирләп чыкты. Мәлик аңа әйтте: «Нинди сәбәп сине туктатты?». Ул әйтте: «Әй остазым, бу минем Аллаһы Тәгаләгә гөнаһ кылган урыным», ягъни Готбә үзенең гөнаһысы хакында уйлый иде. Аллаһы Тәгаләдән оялудан ул тиргә батты.

Мәкхул әйтте: «Берәү түшәгенә ятып та, шул көндә кылган эшләре турында уйламаса, кеше түгел. Әгәр изгелек эшләгән булса, Аллаһы Тәгаләгә хәмед кылыр. Әгәр гөнаһ кылган булса, Аллаһыдан ярлыкауны сорар. Әгәр түшәгенә яткач көндезге эшләрне уйлап, хисаплап карамаса, сизмәстән мөфлис (банкрот) булганчы, ягъни бөтен эшне туктатканга кадәр малын сарыф иткән сәүдәгәр кебек булыр».

Әйтелде: «Аллаһы Тәгаләнең китапларында әйтелә: «Әй бәндәм, Мин һәрвакыт булучы Патша. Мин боерган эштә Миңа буйсын, Мин тыйганнан тыел. Хәтта Мин сине терек итәрмен, һич үлмәссең. Әй Минем бәндәм, Мин шундый Зат, әгәр бер нәрсәгә «бул», дип әйтсәм, ул нәрсә була».

Әбү Мөхәммәд бине Язидтән риваять ителә: ул әйтте: «Әгәр үзең сөйгән кешегә явызлык итмәскә көчең җитсә, явызлык кылма». Аңа: «Кем дә булса үзе сөйгән кешегә явызлык итәрме?» – дип әйтелде. Ул әйтте: «Әйе, синең нәфесең үзең өчен барча нәфесләрнең иң сөеклесе һәм газизе. Әгәр син гөнаһ кылсаң, тәхкыйк, шул яраткан нәфесеңә явызлык кылдың».

Кайбер хәкимнәргә: «Берәр нәрсәне миңа васыять ит», – дип әйтелде. Ул әйтте: «Раббыңны, кешеләрне һәм нәфесеңне җәфалама. Раббыңны җәфалау – ул Аллаһы Тәгаләдән башка затларның хезмәте белән мәшгуль булу. Кешеләрне җәфалау – ул аларны кешеләр янында явызлык белән искә алу. Әмма нәфесне җәфалау – ул Аллаһы Тәгалә фарыз иткән эшләрне нәфестән хурлату».

Кәһмәс бине Хәсәннән риваять ителә: ул әйтте: «Бер гөнаһ кылдым, шул гөнаһ өчен кырык елдан бирле елыйм». «Әй Габдулла, ул нинди гөнаһ соң?» – дип соралды. Ул әйтте: «Кардәшем мине

күрергә килде, ул кардәшем өчен бер балык сатып алып ашаттым. Моннан соң күршемнең дивары янында торганда, шуннан бер кисәк балчык алып кулымны юдым».

وعن رسول الله ﷺ انه قال : "أعظم الذنوب عند الله تعالى أصغرها عند الناس ، واصغر الذنوب عند الله تعالى أعظمها عند الناس".

Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять ителә: ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә каршында гөнаһларның иң зурысы – адәмнәр каршында кечкенә булганы. Аллаһы Тәгалә каршында гөнаһларның иң кечкенәсе – кешеләр алдында иң зур булганы».

Фәкыйһ әйтте: «Әгәр гөнаһ кылучы үзенең гөнаһысын зурга санаса һәм аннан курыкса, гөнаһ кылучы каршында бу иң зур гөнаһ булыр. Дөреслектә, шул гөнаһ Аллаһы Тәгалә каршында иң кечкенәседер. Әмма гөнаһ кылучының гөнаһысы күзенә кечкенә күренсә, бу гөнаһ Аллаһы Тәгалә каршында олуграк. Чөнки гөнаһларның иң олысы даими кылынганы». Бу кайбер сәхабәләрдән риваять ителгәнгә охшый. Дөреслектә ул әйтте: «Даими кылу белән кечкенә гөнаһ, тәүбә итү белән зур гөнаһ юк булыр».

Гәввәм бине Хәүшәбтән риваять ителә: дөреслектә ул әйтте: «Гөнаһтан соң кылынган дүрт төрле гамәл гөнаһтан да яманрак. Гөнаһны кечкенәгә санау, кызыктыру, мактаучыга каршы сөенү, даими кылу».

Фәкыйһ әйтте: «Бу аять сине алдамасын:

﴿ مَنْ جَاءَ بِالْحَسَنَةِ فَلَهُ عَشْرُ أَمْثَالِهَا وَمَنْ جَاءَ بِالسَّيِّئَةِ فَلَا يُجْزَى إِلَّا مِثْلَهَا وَهُمْ لَا يُظْلَمُونَ ﴾

«Бер мөэмин Аллаһы хозурына изге гамәлләр белән килсә, ул мөэмингә изгелекләре ун тапкыр арттырылыр, бер кеше явыз эшләр белән килсә, кылган гөнаһысы бәрабәрендә генә җәза кылыныр һәм алар гөнаһларын арттыру белән золым ителмәсләр». («Әнгам» сүрәсе, 160). Аллаһы Тәгалә изгелекне Кыямәт көненә алып баруны шарт итте. Эшләүчегә эшне эшләү җиңел, мәгәр Кыямәт көнендә алып баруы кыен булыр. Дөреслектә, явызлык бер генә, шулай булса да явызлыкның ун төрле гаепләре бар: беренчесе – дөреслектә, бәндә явызлыкны эшләсә, тәхкыйк, Аллаһы Тәгаләне үзенә ачулы ясады. Аллаһы Тәгалә ачулануга кодрәтле. Икенчесе – ул кеше Аллаһы Тәгаләгә иң ачулы мәхлукны шатландырды. Ул исә Аллаһының һәм аның дошманы булган иблис мәлгунь. Өченчесе – ул кешенең иң күркәм урыннан, ягъни җәннәттән еракләшуы. Дүртенчесе – ул кешенең иң начар урынга җәһәннәмгә якынлашуы. Бишенчесе – дөреслектә, ул кеше үзенә иң сөекле булган нәфесне җәфалады. Алтынчысы – Аллаһы Тәгалә пакь итеп яраткан нәфесен пычратты. Җиденчесе – үзенә тими торган иптәшләрен рәнҗетте, алар сакчы фәрештәләр. Сигезенче – Пәйгамбәр галәйһиссәләмне каберендә кайгылы ясады. Тугызынчы – үз-үзенә кич һәм көндезне шаһид итте, моның бәрабәрендә аларны рәнҗетте һәм кайгылы ясады. Унынчы – кешеләрдән һәм башкалардан булган барча мәхлукларга хыянәт итте. Берәү кеше файдасына шаһидлык бирергә тиеш икән һәм аның шаһидлыгы гөнаһ кылган өчен кабул ителми. Гөнаһысы өчен иптәшенең хакы чыгар. Әмма бөтен мәхлукларга хыянәт итү – ул гөнаһ эш эшләп яңгырны киметү. Бу эш бөтен халыкка хыянәт була. Гөнаһтан сак бул, чөнки гөнаһта шушы гаепләр бар.

Боларның һәркайсы үз-үзенә гөнаһ сәбәпле золым кыла».

Әйтелде: «Кешеләрнең иң сараны – үзендә бәхет булган өчен үз нәфесенә саранлык кылучы. Кешеләрнең иң залиме – Аллаһының гөнаһ кылган нәрсәсе белән үз нәфесен җәберләүче. Чөнки гөнаһ кылучы үз нәфесен һәлак итте».

Хәкимнәрнең кайберләре әйттеләр: «Гөнаһтан сак бул. Чөнки гөнаһ – ул вәбәл. Вәбәл исә мылтык ядрәсе булыр. Тәгать диварына эләгеп диварны егар. Нәфес хозурына керер, мәгъфирәт шәменең яктылыгын сүндерер».

Хәкимнәрнең кайбрәүләренә әйтелде: «Ни булды безгә гыйлемне ишетәбез, ләкин гыйлем белән файдалана алмыйбыз?» «Биш төрле нәрсә сәбәпле сез гыйлемнән файдалана алмыйсыз: беренчесе – Аллаһы Тәгалә сезгә нигъмәт бирде, мәгәр сез шөкер кылмадыгыз; икенчесе – гөнаһ эшләдегез, Аллаһы Тәгаләгә тәүбә итмәдегез; өченчесе – белгәнегез белән гамәл кылмадыгыз; дүртенчесе – изгеләргә мәҗлестәш булдыгыз, мәгәр аларга иярмәдегез; бишенчесе – үлекләрне күмдегез, ләкин алар белән гыйбрәтләнмәдегез».

روى عن رسول الله ﷺ انه قال : "ما من يوم إلا ويترل من الشماء خمسة من الملائكة : أحدهم بمكة ، والصاني بالمدينة ن والثالث ببيت المقدس ، زالرابع بمقابر المسلمين ، والخامس باسواق المسلمين . فاما الذي يترل بمكة فينادي : الا من ترك فرائض الله تعالى فقد خرج من رحمة الله تاعلى ن وأما الذي يترل بالمدينة فينادي : ألا من ترك سنن النبي ﷺ فقد خرج من شفاعته . وأما الذي يترل يمقابر لمسلمين فينادي : يا اهب المقابر ، بماذا تغتبطون وعلى ماذا

تندمون ؟ فيقولون : نداتنا على مافات من اعمارنا ونغتبط باهل الجماعات لقراءهم كلام الله تعالى ، وتذاكرهم بالعلم وصلواهم على النبي ﷺ وستغفارهم لذنوبهم ونحن لا نقدر على شيء من ذلك . وأما الذي ينزل في الاسواق فينادي ويقول : يا معشر الناس مهلا مهلا ن فإن لله تعالى سطوات ونقمات ، فمن خشى سطواته ونقماته فليداوي جراحته ، حتى توب من ذنوبه ، وشوقناكم فلم تشتاقوا ن خوفناكم فلم تخافوا ، ولو لا رجال خشع ن وصبيان رضع ، وبهائم رتع ، وشيوخ ركع ، لصب عليكم العذاب صبا".

Фәкыйһ әйтте: «Атамнан ишеттем. Ул әйтә иде: «Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителә: ул әйтте: «Күктән биш фәрештә иңмәгән һичбер көн юк, ягъни һәркөнне биш фәрештә иңә. Ул фәрештәләрнең берсе – Мәккәгә, икенчесе – Мәдинәгә, өченчесе – Кудс Шәрифкә, дүртенчесе – мөселманнар каберлегенә, бишенчесе – мөселманнарның базарларына иңә. Мәккәгә иңүче фәрештә кычкырыр: «Аллаһы Тәгаләнең фарызларын ташлаучылар сак булыгыз. Тәхкыйк, ул кеше Аллаһының рәхмәтеннән чыкты». Мәдинәгә иңүче фәрештә кычкырыр: «Пәйгамбәр галәйһиссәләмнең сөннәтләрен ташлаучы сак булсын, тәхкыйк, ул кеше Пәйгамбәр галәйһиссәләмнең шәфәгатеннән чыкты». Кудс Шәрифкә иңүче фәрештә кычкырыр: «Хәрам малны кәсеп итүче сак булсын, аның башка гамәлләрен Аллаһы Тәгалә кабул итмәс». Мөселманнарның каберләренә иңүче фәрештә кычкырыр: «Әй каберләрнең кешеләре, ни-нәрсәгә кызыгасыз һәм ни-нәрсәгә үкенәсез?» Әйтерләр: «Гомеребез үткәнгә үкенәбез, Аллаһы Тәгаләнең Китабын укучы, гыйлем хакында сөйләшүче, пәйгамбәр галәйһиссәләмгә салават әйтүче,

гөнаһлары өчен ярлыкау сораучы җәмәгать әһеленә кызыгабыз. Безнең бу эшләрнең һичберсенә көчебез җитми». Базарларга иңүче фәрештә кычкырыр: «Әй җәмәгать, туктагыз, дөреслектә, Аллаһы Тәгаләнең каһәре һәм үч алуы бар. Берәү Аллаһының каһәреннән һәм үч алуыннан курыкса, үзенең кутырлы урынын даруласын, хәтта ул кеше гөнаһларыннан тәүбә итсен. Без сезне кызыктырдык, сез кызыкмадыгыз. Сезне куркыттык, ләкин сез курыкмадыгыз. Әгәр Аллаһыдан куркучы кешеләр, имчәк имүче сабыйлар, ризыклана торган тереклекләр һәм гыйбадәт кыла торган картлар булмаса, сезнең өчен газап тәмам кубар һәм иңәр иде».

وروى ع عائشى ﷺ أن رسول الله ﷺ قال لها : "ي عائشة إياك ومحقرات الذنوب فإن لها من الله تعالى طالبا".

Гайшә разыяллаһү ганһәдән риваять ителә: Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Гайшә, гөнаһларның кечкенәләреннән дә сак бул. Чөнки Аллаһы Тәгалә тарафыннан шул гөнаһларны да җентекләп торучы бар».

Әйтелде: «Кечкенә гөнаһларның охшашы, вак утыннар җыйган кеше кебек. Ул кеше утыннарга ут төртте».

Тәуратта язылган: «Берәү изгелекне чәчсә, сәламәтлекне урыр». Инҗилдә язылган: «Берәү явызлыкны чәчсә, үкенечне урыр». Бу сүз шулай ук Коръәндә да бар:

﴿ مَنْ يَعْمَلْ سُوءًا يُجْزَ بِهِ ﴾

«Берәү явыз эшләр кылса, ягъни Аллаһыга итагать итмәсә, шул явызлыгы белән җәза кылыныр...». («Ниса» сүрәсе, 123)

Әбү Касим Ибен Габбастан риваять итә: «Ибен Габбастан: «Синеңчә изгелеге һәм гөнаһысы күп кеше яисә гөнаһысы да изгелеге дә аз кеше гаҗәбрәкме?», – дип соралды. Ул әйтте: «Минем өчен гөнаһысы аз кеше гаҗәбрәк».

Кайбер хәкимнәр әйттеләр: «Һәр түбән катлаудагы кешеләр изгелекне кылалар, мәгәр олуг кеше гөнаһ кылмас».

Фәкыйһ әйтте: «Гөнаһны кылмау изге гамәлләрдән артыграк булуга Аллаһы Тәгаләнең китабында дәлил бар. Чөнки Аллаһы Тәгалә изгелек кылуны һәм ул изгелекне ахирәткә алып баруны шарт итте. Гөнаһта исә, гөнаһны кылмаудан башка һичнәрсәне шарт кылмады». Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿مَنْ جَاءَ بِالْحَسَنَةِ فَلَهُ عَشْرُ أَمْثَالِهَا﴾

«Бер мөэмин Аллаһы хозурына изге гамәлләр белән килсә, ул мөэмингә изгелекләре ун тапкыр арттырылыр». («Әнгам» сүрәсе, 160)

﴿وَنَهَى النَّفْسَ عَنِ الْهَوَى . فَإِنَّ الْجَنَّةَ هِيَ الْمَأْوَى﴾

«...вә нәфесе теләгән гөнаһлы эшләрдән үзен тыйса, әлбәттә, аның урыны җәннәт булыр». («Нәзигат» сүрәсе, 40, 41)

## Мәзлумнар (рәнҗетелүчеләр) турында

عن أبي موسى الأشعاي ﷺ قال : قال رسول الله ﷺ : "إن الله تعالى يملي للظالم فإذا أخذه لم يفلته" ، ثم قرأ : "وَكَذَلِكَ أَخْذُ رَبِّكَ إِذَا أَخَذَ الْقُرَى وَهِيَ ظَالِمَةٌ إِنَّ أَخْذَهُ أَلِيمٌ شَدِيدٌ"

Әбү Муса Әшгаридән риваять ителә: Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә золым итүчегә иркенлек кыла. Әгәр аны тотса,

җибәрми, ул залим котылмый». Моннан соң укыды: «Әнә шулай Раббыңның кешеләре азган шәһәрне газап белән тотуы бик тиз һәм бик каты». («Һуд» сүрәсе, 102)

عن أبي هريرة ﷺ ع رسول الله ﷺ أنه قال : "من كانت لأخيه عده مظلمة م عرض أو مال ، فليتحلله اليوم قبل أن يؤخذ منه يوم لا ديار ولا دلاهم ، فإن كا له عمل صالح أخذ منه بقدر عمل مظلمته ، وإن لم يكن به عمل أخذ من سيئاته فحملت عليه ، ثم يلقى في النار".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителә: Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Берәүнең өстендә дин кардәшенең йөз куй яки малдан хакы булса, ул кеше хәзер үк, алтын һәм көмеш алынмый торган көнгә кадәр, ягъни Кыяматкә кадәр бәхилләтсен. Әгәр ул кешенең изге гамәле булса, шул изгелектән золым кылган гамәленең зурлыгы кадәр алыныр. Әгәр аның изге гамәле булмаса, мәзлумның (золым ителүченең) явызлыкларыннан алынып, залимга йөкләтелер».

عن أبي هريرة ﷺ أن رسول الله ﷺ قال : "أتدرون من المفلس في أمتي؟" قالوا له : المفلس من لا درهم له ولا دينار ولا متاع ، قال : "فإن المفلس من أمتي : الذي ياتي يوم القيامة بصلاته وزكاته وصيامه ، ويأتي وقد شتم هذا ، وقذف هذا ، وأكل مال هذا ، وسفك دم هذا ، وضرب هذا ، فيعطى هذا من حساته ، وهذا من حسناته ، فإن فيت حساته قبل أن قضى ما عليه أخذ م خطاياهم وطرحت عليه ن ثم طرح في النار".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителә: Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Бөлгән кешенең кем икәнен беләсезме?» Аңа әйттеләр: «Бөлгән кешенең алтыны, көмеше һәм башка малы булмас». Рәсүлуллаһ

галәйһиссәләм әйтте: «Минем өммәтемнән бөлгән кеше – ул Кыямәт көнендә уразасын, зәкәтен һәм намазын алып килүче. Шуның өстенә берәүне начар сүз белән хурлаган, түбәнсеткән, малын ашаган һәм канын агызган кеше килер, бишенче берәүне суккан булыр. Аңа да, моңа да изгелекләре бирелер. Ул залимнең өстендәге хак үтәлгән кадәр изгелекләр бетеп китсә, хак ияләренең гөнаһлары алынып, залимгә ташланыр. Моннан соң шул залим үзе тәмугка ыргытылыр».

Әбү Мәйсәрәдән зекер ителә: ул әйтте: «Күмелгәннән соң кабердә кешегә камчы китерелер, ул кешегә Мөнкир һәм Нәкир килеп, аңа: «Без сине йөз камчы сугабыз», – дип әйтерләр. Мәет әйтер: «Мин шундый-шундый кеше идем». Алар ул мәеткә шәфәгать итәрләр, хәтта ул ике фәрештә аннан ун камчы киметерләр. Моннан соң ул кеше һаман үзенең соравында булыр. Алар киметә-киметә, хәтта бер мәртәбә сугу калганга кадәр киметерләр. Алар әйтерләр: «Без сиңа бер генә мәртәбә сугарбыз». Алар аңа бер мәртәбә сугарлар. Кабер эченә бөтенләй ут кабар. Ул кеше әйтер: «Ни өчен мине суктыгыз?» Алар әйтерләр: «Син золым ителгән кеше яныннан үттең, ул кеше синнән ярдәм сорады, син аңа ярдәм итмәдең». Бу золым ителгән кешегә ярдәм итмәгән кешенең хәле. Шулай булгач залим кешенең хәле ничек булыр?»

Мәймүн бине Мәһран әйтте: «Дөреслектә, кеше Коръән укый һәм үз-үзенә ләгънәт кыла». Мәймүн әйтте: «Коръән әйтә:

﴿ أَلَا لَعْنَةُ اللَّهِ عَلَى الظَّالِمِينَ ﴾

«Аң бул, Аллаһының ләгънәте золым кылучылар хозурына». («Һуд» сүрәсе, 18) Хәлбуки, ул укучы үзе золым итүчедер.

Фәкыйһ әйтте: «Золымнан зуррак гөнаһ юк. Чөнки гөнаһ ул Аллаһы белән синең араңда булучы. Аллаһы Тәгалә юмарт һәм рәхимле, сине гафу итәр. Әгәр халык белән синең арада гөнаһ булса, золым ителүченең ризалыгыннан башка сиңа һич хәйлә юк. Залимгә кылган золымы өчен тәүбә кылу, дөньяда вакытта золым ителгәннән бәхиллек сорау тиеш. Әгәр бәхилләтүгә көче җитмәсә, шул вакытта золым ителүче өчен дога кылу һәм мәгъфирәт сорау тиешле. Чөнки ул золым ителүчене залимне бу дога бәрабәренә бәхилләве өмет ителә».

Мәймүн бине Мәһран әйтте: «Әгәр берәү икенче бер кешене җәберләсә һәм аңардан бәхиллек алырга теләсә, золым ителгән кеше вафат булса, бәхилләтергә көче җитмәсә, ул залим үзенең намазы артыннан золым ителүче өчен мәгъфирәт сорасын. Шулай итеп золым итүчелегеннән чыгар».

Ибен Мәсгудтән риваять ителә: ул әйтте: «Берәү залимнең золымы өчен ярдәм итсә, яки ул залимгә котылу өчен дәлил өйрәтсә, шул дәлил өйрәтүче мөселман кеше хакына кергән булыр. Тәхкыйк, ул кеше Аллаһының ачуына юлыкты. Бу өйрәтүчегә шул залимнең авырлыгы булыр».

Гомәр разыяллаһү ганһүдән риваять ителә: ул Ибен Мәсгуд Әхнәф бине Кайскә әйтте: «Кешеләрнең иң наданы кем?» Әхнәф әйтте: «Дөнья бәрабәренә ахирәтне сатучы». Гомәр бине әл-Хаттаб: «Сиңа моннан да наданракны әйтимме?» – дип сорады. «Әй мөэминнәрнең әмире, сөйлә», – диде. Гомәр әйтте: «Ахирәтне башка кешенең дөньясы бәрабәренә саткан кеше».

Гали бине Әбү Талиб разыяллаһү ганһүдән риваять итеЛә: «Һичберәүгә изгелек итмәдем һәм явызлык та кылмадым. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ مَنْ عَمِلَ صَالِحًا فَلِنَفْسِهِ وَمَنْ أَسَاءَ فَعَلَيْهَا ﴾

«Берәү Коръән юлыннан барып, Аллаһы ризалыгы өчен генә изге гамәлләр кылса, файдасы, әлбәттә, үзенә булыр. Берәү Коръән юлын ташлап шайтан юлыннан барып, бозык эшләр кылса, зарары, әлбәттә, үзенәдер». («Фуссиләт» сүрәсе, 46)

Ягъни, әгәр мин бер кешегә изгелек итсәм, тәхкыйк, мин үз-үземә изгелек кылган булдым. Әгәр бер кешегә явызлык кылсам, тәхкыйк, мин үземә явызлык иттем».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Сәгыйд Хөдридән риваять итә: ул әйтте: «Мөһаҗирләрдән бер кеше булды, ул кешенең Рәсүлуллаһка йомышы бар иде. Ул Рәсүлуллаһ аулакта булганда аның йомышын үтәр дип уйлап, аулакта юлыгуны теләде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм ул вакытта Мәккә янында гаскәр эчендә иде. Кичен Мәккәгә килеп Кәгъбәне таваф кылыр, иртән кайтыр иде. Кайткач иртә намазын укый иде. Риваять итүче әйтте: «Бер кичтә Рәсүлуллаһны тавафта озак, тәмам таң атканчы торды. Дөягә атлангач, аңа әлеге кеше очрады. Рәсүлуллаһның утырган дөясен тезгененнән тотып әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, минем сиңа йомышым бар». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Син мине җибәр һәм синең йомышың тиздән ирешер». Теге кеше тыңламады, ул кешенең озак тотуыннан куркып, Рәсүлулла галәйһиссәләм камчысы белән бер селтәде һәм китте. Иртә намазын укып бетергәч, йөзе белән халыкка юнәлде. Халык Рәсүлуллаһ тирәсенә җыелды. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте:

«Хәзер генә мин камчылаган кеше кайда?» Рәсүлуллаһ бу сүзне янә кабатлап әйтте: «Әгәр ул кеше халык арасында булса торсын». Ул кеше: «Аллаһыга аннан соң Аның рәсүленә сыгынам», – дия башлады. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм: «Миңа якынрак кил», – диде. Ул кеше Рәсүлуллаһка якынлашты. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм аның алдына утырды, кулына камчыны тоттырды. «Камчыны алып касас кыл», – диде. Ул кеше әйтте: «Аллаһының Пәйгамбәрен камчы белән сугарга Аллаһыга сыгынам». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Камчыңны ал һәм касас кыл, һич зарар юк». Ул кеше янә кабатлап: «Аллаһының Пәйгамбәрен камчы белән сугарга Аллаһыга сыгынам», – диде. Рәсүлуллаһ әйтте: «Алай түгел, мәгәр гафу кылсаң гына сукмассың». Ул кеше камчыны ташлап әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, мин гафу иттем». Моннан соң Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әй адәмнәр, Раббыгыздан куркыгыз, сездән арадан һичкем, мөэмин кешене золым кылмасын, мәгәр золым кылды исә, Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә ул кешедән үч алыр».

Янә Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять ителә: «Дөреслектә, золым ителүчеләр Кыямәт көнендә котылучылардан булырлар».

Суфьян Сәүридән риваять ителә: ул әйтте: «Аллаһы белән үз араңда булган гөнаһлар белән бергә Аллаһы Тәгаләгә юлыгуың, синең белән бәндәләр арасында булган бер гөнаһ белән юлыгуга караганда җиңелрәк».

Ибраһим бине Әдһәмнән риваять ителә. Ул әйтте: «Кеше бурычлы булып, шул бурычын үтәгәнгә кадәр агач мае майлану тиеш түгел».

Фәдаел бине Гыядтән риваять ителә. Ул әйтте: «Минем өчен Аллаһы Тәгаләнең китабыннан бер аятьне уку һәм шул аять белән гамәл кылу Коръәнне мең мәртәбә хәтем кылудан сөеклерәк. Мөэмин кальбенә шатлык кертү һәм мөэминнең йомышын үтәү бөтен гомер буена гыйбадәт кылудан сөеклерәк. Дөньяны ташлау җир һәм күкләрнең халкы кыла торган гыйбадәттән дә сөеклерәк. Бер орлык кадәр хәрам мал кылмавым хәләл мал белән йөз хаҗ кылудан сөеклерәк».

Әбү Бәкер әл-Вәракадан риваять ителә: ул әйтте: «Күңелдән иманны чыгара торган нәрсәләрнең күбрәге – халыкка золым кылу».

Әбү Касимнан: «Бәндәдән иманны чыгара торган гөнаһ бармы?» – дип сорадылар. Ул әйтте: «Әйе, өч төрле нәрсә кешедән иманны чыгара: беренчесе, Ислам дине өчен шөкер итүне ташлау; икенчесе, Ислам дине китүгә курыкмау; өченчесе, мөселман кешеләргә золым кылу».

وروى حميد بن أنس ﷺ أوصي النبي ﷺ رجلا بصلاص فقال له : "أكثر ذكر الموت يشغلك عما سواه ، وعليك بالشكر فإنه زيادة في العمة ، وعليك بالدعاء ، فإنك لا تدري متى يستجاب لك ، وأنهاك عن ثلاث : لا تنقض عهدا ، ولا تعن على قضه ، وإياك والبغي ، فإن بغى عليه لينصرنه الله وإياك والمكر ، فإنه لا يحيق المكر السيء إلا بأهله".

Хәмид Әнәс разыяллаһү ганһүдән риваять итә: ул әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм бер кешегә өч төрле нәрсә белән васыять итә. Ул аңа әйтте: «Үлемне күп искә төшер. Әгәр син күбрәк үлемне искә алсаң, ул күңелеңне башкадан алыр. Шөкер ит, чөнки шөкер итү нигъмәткә артыклык китерә. Дога кыл, чөнки син ул

дога кайчан кабул ителәчәген белмәссең. Мин сине өч төрле нәрсәдән тыям: вәгъдәне бозма, бозарга дип ниятләмә дә. Золымнан сак бул, чөнки золым ителгән кешегә Аллаһы Тәгалә шиксез ярдәм итәр. Мәкер кылудан саклаң, чөнки явыз мәкер төшмәс, мәгәр ул явыз мәкер үз ке-шесенә генә иңәр, ягъни берәү мәкер кылса, үзенә генә булыр».

Мансур Мөҗәһидтән, ул Язид бине Сәмрадән риваять итә. Язид әйтте: «Җәһәннәмнең диңгез кебек урыннары бар. Ул урыннарда дөя зурлыгындагы еланнар бар. Качарлар кебек көтү-көтү чаяннар булыр. Әгәр тәмуг халкы газапны җиңeләйтүне сораса, ул еланнарга һәм чаяннарга әйтерләр: «Яр кырыеннан чыгыгыз». Еланнар чыгарлар. Тәмугта бу еланнар халыкның иреннәреннән һәм йөзләреннән, Аллаһы Тәгалә теләгән урыннардан чагарлар, аларның тәннәре ялангач калыр. Тәмуг халкы ул еланнардан качкан хәлдә ярдәм сорарлар. Аларга корт җибәрерләр, ул тәмуг әһеленең, хәтта сөяге күренгәнгә кадәр тиресен кырыр. «Әй фәлән кеше, бу нәрсә сине җәфалыймы, рәнҗетәме?» – дип соралыр. Ул әйтер: «Әйе, бик җәфалый». Аңа каршы әйтелер: «Бу эш синең дөньяда вакытта мөэминне рәнҗеткәнең өчен булыр». Моңа Аллаһының сүзе дәлил:

﴿ زِدْنَاهُمْ عَذَابًا فَوْقَ الْعَذَابِ بِمَا كَانُوا يُفْسِدُونَ ﴾

«...кешеләрне Аллаһы юлыннан тыйганнары өчен газап өстенә газап арттырып газапларбыз». («Нәхел» сүрәсе, 88)

Гомәр разыяллаһү ганһүдән риваять ителә: ул әйтте: «Мөэмингә золым итүгә өч нәрсә җитә: үзе кыла торган нәрсәне кешедә гаеп итеп санау; үз гаебен күрмичә кешеләрнең гаепләрен күрү; фай-

дасыз нәрсә хакында сүз алып мәҗлестәш кешене рәнҗетү».

وع رسول الله ﷺ أنه قال : "يادي مناد من تحت العرش يوم القيامة : يا أمة محمد ، وما كان لي قبلكم م التبعات فقد وهبته لكم ، وبقيت التبعات التي فيما بينكم فتواهبوها ، وادخلوا الجنة برحمتي".

Рәсүлуллаһтан риваять ителә, ул әйтте: «Кыямәт көнендә Гареш астыннан бер кычкыручы кычкырыр: «Әй Мөхәммәд өммәте, сезнең тарафтан минем өчен булган нәрсәләрне сезгә бүләк иттем, арагызда булган хаклар калды. Сез бер-берегезгә бүләк итешегез. Минем рәхмәтем белән җәннәткә керерсез».

## Мәрхәмәт һәм шәфкать

عن أبي هريرة ﷺ أن رسول الله ﷺ قال : "بيما رجل يمشي في الطريق اشتد عليه العطش فوجد بئرا فترل بها فشرب ، ثم خرج ، فإذا كلب يلهث ، وهو يأكل الثرى من العطش ، فقال الرجل : لقد بلغ هذا الكلب م العطش مثل الذي بلغ مني ، فزل البئر ، فملا خفه ماء ، ثم أمسكه بفيه حتى رقى ، فسقى الكلب وواه ، فشكر الله تعالى له فغفر له" قالوا : يا رسول الله ، إن لنا في البهائم لأجرا ؟ قال : "في كل ذات كبد طبة أجر".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Һөрәйрә разыяллаһү ганһүдән риваять итә: Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Бер кеше юлда барган вакытта бик нык сусады. Кое тапты һәм шул коега төшеп су эчте. Коедан чыкканда, янәшәдә сусаган бер этне күрде. Ул эт сусавыннан туфрак ашый иде. Бу кеше: «Бу эткә дә миңа ирешкән кебек сусау ирешкән икән», – дип уйлады. Коега төшеп читегенә су

тутырды, читекне авызы белән тешләп алып менеп эткә суны эчертте. Аллаһы Тәгалә ул кешегә шөкер итте, аның гөнаһысын ярлыкады. Әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, дөреслектә безгә дә хайваннар хакында савап булырмы?» Пәйгамбәр әйтте: «Һәрбер канлы, йөрәк иясе хайван хакында әҗер бар».

عن الحسن أن رسول الله ﷺ قال : "لا يدخل الجنة إلا رحيم" قالوا : يا رسول الله ، كلنا رحيم ، قال : "ليس رحمة أحدكم خويصية ولكن حتى يرحم الناس عامة ، ولا يرحمهم إلا الله تعالى".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Хәсәннән риваять итә. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Оҗмахка шәфкатьле кешедән башка кеше кермәс». Әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, безнең һәркайсыбыз шәфкатьле». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Үз-үзенә генә шәфкатьле булуы түгел, мәгәр бөтен халыкка шәфкатьле булса гына җәннәткә керер. Аллаһы Тәгаләдән башка бөтен халыкка рәхмәт итүче юк».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Габдулладан риваять итә: ул әйтте: «Әгәр кардәшегезгә җәза ирешкәнен күрсәгез, сез аны ләгънәт итмәгез, шайтанны аңа ярдәмгә кушмагыз. Әй Аллаһым, ул бәндәгә рәхмәт ит һәм аның тәүбәсен кабул ит, дип әйтегез».

وعن الشعبي قال : صعد العمان بن بشير المنبر ، فحمد الله وأثني عليه ثم قال : "وتراحمهم فيما بينهم كمثل العضو م الجسد إذا اشتكى بعضه تداعي الجسد كله بالسهر حتى يذهب الألم من ذلك العضو".

Шәгъбидән риваять ителә: ул әйтте: «Ногман бине Бәшир минбәргә менде, Аллаһыга хәмед-сәнә әйткәннән соң әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән ишеттем, ул әйткән иде: «Мөселманнарга бер тән-

дәге әгъзалар кебек бер-берсен изгелеккә димләү һәм үзара шәфкать итешү тиешле. Тәндәге әгъзаларның берсе авыртса, шул әгъзасы сәламәтләнгәнче бөтен тән йокысызлык белән сызлана».

Әнәс бине Мәликтән риваять ителә: ул әйтте: «Гомәр разыяллаһү ганһү бер кичтә урам әйләнеп йөргәндә юлчылар төркеме янынннан үтте. Алар бу урынга төнне үткәрергә тукталганнар һәм йокларга ятканнар иде. Хәзрәти Гомәр разыяллаһү ганһү аларның әйберләре урланудан курыкты. Шунда Габдрахман бине Гауф килеп: «Әй мөэминнәрнең әмире, бу сәгатьтә ни эшләп йөрисең?» – дип сорады. Гомәр әйтте: «Кич кунарга тукталган юлчылар янынннан үттем. Күңелем сөйләде, дөреслектә, ул юлчылар монда кичләсәләр, йокларлар, дип. Мин аларның әйберләре урланудан курыктым». Әйдә безнең белән бар, аларны сакларбыз». Әнәс бине Мәлик әйтте: «Икәү киттеләр һәм юлчыларга якын җиргә утырып, хәтта таң атканчы әйберләрен сакладылар. Гомәр разыяллаһү ганһү: «Әй юлчы иптәшләр, намазга, намазга», – дип кат-кат кычкырды. Юлчыларның урыннарыннан кузгалганын күргәч, хәзрәти Гомәр белән Габдрахман бине Гауф урыннарыннан торып кайтып киттеләр».

Фәкыйһ әйтте: «Сиңа үзеңнән элек булган халыкка иярү лязем булсын. Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәр галәйһиссәләмнең сәхабәләрен үзара шәфкатьле булулары белән мактады. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿رُحَمَاءُ بَيْنَهُمْ﴾

«...үз араларында бер-берсенә шәфкатьлеләр». («Фәтех» сүрәсе, 29)

Мөселманнар бөтен халыкка да шәфкатьле булдылар. Алар зимми халыкка да шәфкатьлелек

күрсәттеләр, мөселманнарга ничек рәхмәт итмәсеннәр».

Гомәр разыяллаһү ганһүдән риваять итела: Ул зимми халыктан булган бер кешене күрде, үзе бик карт кеше, өй саен сораныып йөри иде. Гомәр разыяллаһү ганһү аңа әйтте: «Без сиңа оятлы эш эшләмәдек, егет вакытыңда синнән җизьяне алдык, соңыннан бу көн сине тар кылдык». Мөселманнарның казнасыннан ризык бирүне әмер итте.

Гали бине Әбү Талиб разыяллаһү ганһүдән риваять итела: ул әйтте: «Гомәр разыяллаһү ганһүнең дөя өстендә утырганын күрдем, ул Гомәр сазлыкта йөри иде. Аңа әйттем: «Әй мөэминнәрнең әмире, кая киттең?» Ул әйтте: «Зәкәттән килгән дөя югалды, мин шуны эзлим». Мин аңа әйттем: «Син үзеңнән соң килүче хәлифәләрне хур кылдың» (син болай булгач, үзеңнән соң килүчеләр дә шундый вак эш артыннан йөрерләр, дип әйтү). Гомәр әйтте: «Әй Әбү Хәсән, мине шелтәләмә, Мөхәммәд галәйһиссәләмне пәйгамбәр итеп җибәргән Зат белән ант итәм; Фәрат елгасы ярына куй бәрәне китә икән, Кыямәт көнендә моның өчен Гомәр җәза кылыныр, чөнки мөселманнарны тар кылучы түрәгә һич кадер һәм мөэминнәрне куркуга төшергән бозыкка хөрмәт юк».

وعن الحسن ، عن رسول الله ﷺ أنه قال : "بدلاء أمتي لا يدخلون الجنة بكثرة صلاة ولا صيام ، ولكن بحمة القلوب ، وسلامة الصدور ، سخاوة النفس ، والرحمة لجميع المسلمين".

Хәсәннән риваять итела: Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Минем өммәтемнең изгеләре намаз һәм уразаның күп булуы белән җәннәткә кермәсләр, мәгәр Аллаһы Тәгалә аларга күкрәкнең сәламәтлеге, ягъни ихлас күңелләре, нәфесләренең юмартлыгы

һәм бөтен мөселманнарга рәхмәтле булганнары өчен рәхмәт кылыр».

عن أس بن مالك ﷺ قال : قال رسول الله ﷺ : "أربع من حق المسلمي عليك : أ تعين محسنهم ، وأن تستغفر لمذهم ، وأن تدعو لمدبرهم وأن تحت تائبهم".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителә: Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Синең хозурыңда мөселманнарның хакы дүрт төрле: изгелек кылучыга ярдәм итү; гөнаһ кылучыларга ярлыкау теләү; дөньядан үткәннәргә дога кылу; тәүбә кылучыларны сөю».

عن أبي أيوب ﷺ قال : سمعت رسول الله ﷺ يقول : "للمسلم على اخيه ست خصال واجبة ، إن ترك منها واحدة فقد ترك حقا واجبا : إذا دعاء أن يجيبه ، وإذا مرض أن يعوده ، وإذا مات أن يحضره ، وإذا لقيه أن يسلم عليه ، وإذا استنصحه أن يصحه ، وإذا عطس أن يشمته".

Әбү Әюб Әнсаридән риваять ителә: Ул Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнең әйткәнен ишетте: «Мөселман кешенең кардәше өстендә алты важиб хакы бар. Әгәр шул алтыдан бер хакны ташласа, тәхкыйк, ул кеше бер важиб хакны калдырды. Берсе, әгәр мөселман кардәше чакырса, аңа бару важиб. Икенчесе, чирләсә аның хәлен белергә бару. Өченчесе, мөселман кеше үлсә, аны озату. Дүртенчесе, юлда очраса, аңа сәлам бирү. Бишенчесе, нәсыйхәт сораса, аңа нәсыйхәт бирү. Алтынчысы, төчкерсә, аңа «йәрхәмүкәллаһ» дип әйтү».

وروى عن رسول الله ﷺ انه قال : "ما من بي إلا وقد رعى" قالوا : يا رسول الله وأنت قد رعيت ؟ قال : "نعم رعيت".

Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять ителә, ул әйтте: «Һич пәйгамбәр юк, мәгәр булса ул саклады».

Сорадылар: «Әй Рәсүлуллаһ, син дә сакладыңмы?» Ул әйтте: «Әйе, сакладым».

Фәкыйһ әйтте: «Пәйгамбәрләрнең саклавының хикмәте, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә аларны иң элек хайваннарга бәлаләндерде, ягъни пәйгамбәрләрнең мәхлукларга шәфкатьләре беленсен өчен аларны хайваннар белән сынады. Хәлбуки, Аллаһы Тәгалә аларны сынамаса да белә. Әгәр ул пәйгамбәрләрне хайваннарга шәфкатьле итеп тапса, аларны пәйгамбәр кылды һәм адәм балаларының дин эшләренә түрә итеп җибәрде».

Риваять ителә: дөреслектә Муса галәйһиссәләм әйтте: «Әй Раббым, ни өчен мине сайладың?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Минем мәхлукларыма шәфкатьле булганың өчен. Чөнки син Шөгаеб галәйһиссәләмнең хайваннарын саклап ашаттың. Синең куйларың арасыннан берсе югалды син аны эзләдең. Ул куйны эзләп тапканчы сиңа мәшәкать һәм зәхмәт иреште. Син ул куйны тоткач, аны үз каравыңа куштың. Мине дә, үзеңне дә мәшәкатькә салдың, аңа, әй мескен, дип әйттең. Минем мәхлукларыма шәфкатең өчен сине пәйгамбәр итеп сайладым һәм пәйгамбәрлек белән хөрмәтләдем».

وروى عن أبي هريرة ﷺ عن رسول الله ﷺ أنه قال : "من شت أخاه المسلم في الديا سته الله في الدنيا والآخرة ، ومن فس عن أخيه كربة من كرب الديا فس الله عه كربة كم كرب يوم القيامة والله تعالى في عون العبد ما دام العبد في عون أخيه المسلم".

Әбү Һөрәйрә разыяллаһү ганһүдән риваять ителә: Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Берәү дөньяда мөселман кардәшенең хатасын яшерсә, Аллаһы Тәгалә ул кешенең хатасын дөньяда һәм

ахирәттә яшерер. Берәү кардәшенең дөнья кайгыларыннан бер кайгысын ачса, Аллаһы Тәгалә аның кайгысын Кыямәт көнендә ачар. Бәндә мөселман кардәшенең ярдәмендә булганда, Аллаһы Тәгалә шул бәндәнең ярдәмендә булыр».

وروى عن أنس ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "والذي فس محمد بيده ، لا يؤمن أحدكم حتى يحب لأخيه ما يحب لنفسه من الخير".

Әнәс разыяллаһү ганһүдән риваять ителә: Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Мөхәммәд үзе Аның кодрәтендә булган Зат белән ант итәм, изгелектә, хәтта үзе өчен сөйгән нәрсәне мөселман кардәшенә сөйгәнгә кадәр һичберегез мөэмин булмас».

Шәгъби Гомәр разыяллаһү ганһүдән риваять итә: ул әйтте: «Шәфкать итмәгән кешегә Аллаһы Тәгалә рәхмәт кылмас, кичермәгән кешенең гөнаһысын да ярлыкамас, бәхиллек сораганда бәхиллек бирмәгән кешенең Аллаһы Тәгалә тәүбәсен кабул итмәс».

Сәхабәләрнең кайберләреннән риваять ителә: дөреслектә ул әйтте: «Рәхмәт кылучыларга рәхимле Зат рәхмәт кылыр. Җирдәге халыкка шәфкать кылыгыз, күктәгеләр сезгә рәхмәт итәрләр».

وروى عن رسول الله ﷺ أنه قال : "من لا يرحم الاس لا يرحمه الله تعالى".

Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять ителә. Ул әйтте: «Берәү адәмнәргә рәхмәт итмәсә, Аллаһы Тәгалә ул кешегә рәхмәт итмәс».

Катәдәдән риваять ителә. Ул әйтте: «Безгә зекер ителде: «Дөреслектә, Инҗилдә язылган: «Әй адәм улы, ничек шәфкать итсәң, син дә шулай ук рәхмәт ителерсең. Аллаһының бәндәләренә рәхмәт итмәстән, Аллаһының рәхмәт кылуын ничек өмет итәрсең?!»

Әбү Дәрдәдән риваять ителә: ул балаларга иярә, алардан чыпчыклар сатып ала һәм ул чыпчыкларны

җибәрә иде. Үзе: «Барыгыз, көн күрегез», – дип әйтә иде. Шәкыйк әйтте: «Әгәр сиңа бер кеше явызлык белән сөйләнсә һәм син шул кешегә шәфкать итәргә теләмәсәң, син аннан да яманрак булырсың. Әгәр син яхшы кешедән хәбәр бирсәң, ягъни сиңа, фәлән кеше яхшы, дип сөйләсәләр, күңелеңдә Аллаһыга гыйбадәт кылуда тәм тапмасаң, син үзең дә явыз кеше».

Мәлик бине Әнәс әйтте: «Гайсә галәйһиссәләмнең әйткәне миңа иреште. Аллаһы Тәгаләне зекер итүдән башка сүзне күп кылмагыз. Әгәр күп сөйләсәгез, күңелләрегез каралыр. Кара күңел Аллаһының рәхмәтеннән ерак, мәгәр сез генә белмисез. Хуҗалар кебек кешеләрнең гаепләрен күрмәгез, гүя коллар кебек ул гаепләргә карагыз, ягъни кол хуҗасының гаепләрен күрсә дә, үз эшен үзе белә, минем эшем юк дияр. Шулай ук ят кешеләрнең эшендә кайгың булмасын, үз эшеңне бел, дип әйтү була. Кешеләр ике төрле: бәлале һәм бәладән сәламәт булучы». Аллаһы Тәгалә – белүчерәк. Бәла иясенә шәфкать кылыгыз, сәламәтлек өчен Аллаһыга хәмед әйтегез.

Әбү Габдулла Шамидән риваять ителә: ул әйтте: «Тавус дигән кешегә керергә сорадым, бик олы карт чыкты һәм: «Мин шул үзе», – диде. Мин аңа әйттем: «Әгәр син шул булсаң, дөреслектә, син алдыйсың». Тавус әйтте: «Галим кеше һич алдамас». Мин аңа кердем һәм ул миңа әйтте: «Сора һәм сүзеңне кыска тот». Мин аңа әйттем: «Әгәр син кыскача җавап бирсәң, мин дә кыскача сорармын». Ул әйтте: «Әгәр син Тәүрат, Инҗил һәм Коръәннең өч сүздән җыелганын теләсәң, мин шуны эшләрмен». Мин: «Шуны сөямен», – дидем. Ул әйтте: «Аллаһыдан шундый курку белән курык, синең каршыңда

Аллаһыдан башка һичберәү куркыныччлы булмасын. Аллаһының рәхмәтенә шул чаклы таян, ул өмет итүең Аллаһыдан куркуыңнан да катырак булсын. Үзең өчен сөйгәнне кеше өчен дә сөй».

Гомәр бине Габделгазиздән риваять ителә: ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә сөйгән нәрсәләр өч: үч алырга көч җиткәндә дә гафу итү; олуг эшләрдә дә ният итү; Аллаһының бәндәләренә йомшак булу. Берәү Аллаһының бәндәләренә йомшаклык кылса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә йомшаклык кылыр».

Һәшим Хәсәннән риваять итә. Ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә Адәмгә вәхи кылып әйтте: «Әй Адәм, дүрт төрле нәрсә сиңа да һәм балаларыңа да бөтен изгелекне чыгучы. Берсе – Минем өчен; икенчесе – синең өчен; өченчесе – Минем белән синең арада уртак; дүртенчесе – синең белән адәмнәр арасында уртак. Минем өчен булганы – ул Миңа гыйбадәт кылу һәм гыйбадәттә һичнәрсәне Миңа ширек кылмау. Синең өчен булганы – ул синең гамәлең. Аның бәрабәренә мохтаҗ булган вакытыңда сине әҗерле итәрмен. Синең белән минем арада уртак булганы – ул синең дога кылуың, Минем кабул итүем. Синең белән кешеләр арасында булганы – ул кешеләрнең сиңа карата ничек булуларын яратсаң, синдә аларга шундый ук мөгамәләдә бул».

## Аллаһы Тәгаләдән курку хакында

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Сәгыйд бине Мөсәйибтән риваять итә: Гамру, Өбәй бине Кәгеб һәм Әбү Һөрәйрә разыяллаһү ганһүм Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмгә килеп әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, кешеләрнең галимрәге кем?» «Акыллы кеше», – диде. Алар: «Әй Рәсүлуллаһ, адәмнәрнең гыйбадәт

кылучырагы кем?» – диделәр. «Акыллы кеше», – диде. «Әй Рәсүлуллаһ, юмартлыгы камил булучы, тәмле телле, кулы юмарт булучы һәм дәрәҗәсе югары кеше акыллы түгелме?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Дөреслектә, бу сез бәян иткән нәрсәләрнең һәрберсе Раббың каршында тәкъвалыларга, дөнья һәм ахирәт өчен кирәк. Әмма акыллы кеше – ул сакланган кеше. Гәрчә ул кеше дөньяда түбән, хур кеше булса да. Тәкъва кешедән морад – Аллаһыдан һәм аның хәрамыннан сакланучы».

Мәлик бине Динардан риваять ителә: ул әйтте: «Әгәр кеше үзеннән-үзе курку һәм Аллаһының рәхмәтен, фазыйләтен өмет итү галәмәтен белсә, тәхкыйк, ул кеше ышанычлы нәрсәгә таянды. Аллаһыдан курку галәмәте – ул Аллаһының тыйганыннан саклану. Рәхмәтен өмет итү галәмәте – ул Аллаһы Тәгалә боерган нәрсәне кылу. Әйтелде: «Өмет һәм курку белән ике галәмәт бар. Өмет галәмәте – ул Аллаһының ризалыгын таләп итү. Курку галәмәте – ул Аллаһы Тәгаләнең тыйганыннан саклану».

Фәкыйһ иснәде белән Ибен Габбастан риваять итә: ул Гомәргә әйтте: «Әй мөэминнәрнең әмире, кешеләр кәфер булганда – син мөселман булдың, кешеләр аны хурлаганда – Рәсүлуллаһ белән бергә сугыштың. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм синнән разый булган хәлдә вафат булды. Һәм синең хозурыңа ике кеше низагъ белән кермәде. Шәһид булып үләчәксең». Гомәр разыяллаһү ганһү әйтте: «Алданган шул ки, сез аны алдадыгыз, Аллаһ белән ант итәм, минем өстемә кояш чыга торган нәрсә булса, кояшның чыгу куркынычыннан шул нәрсәне фидә кылыр идем».

عن الحس البصري ﷺ عن رسول الله ﷺ أه قال : "المؤمن بين مخافتين ، بين أجل قد مضى لا يدي ما الله صانع به ، وبين أجل قد بقى لا يدري ما الله قاضفبه ، فليتزود العبد من فسه لفسه ، ومن دياه لآخرته ، فوالذي نفس محمد بيده ما بعد الموت من مستعتب ، وما بعد الديا دار إلا الجنة أو النار".

Хәсән Басридән риваять ителә. Ул Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять итә: дөреслектә, ул әйтте: «Мөэмин кеше ике куркыныч арасында. Беренчесе – үткән вакыт арасында, бәндә ул вакыт өчен Аллаһы Тәгалә нишләгәнен белми. Икенчесе – киләчәк вакыт арасында, бәндә ул вакытта Аллаһы Тәгаләнең нәрсә хөкем итәчәген белми. Бәндә үз-үзе өчен азык хәзерләсен. Дөньясында ахирәт өчен, терек булганда үлеме өчен әзерләнсен. Мөхәммәд Аның кодрәт кулында булган Зат белән ант итәм, үлемнән соң һич ризалык теләүче юк, дөньядан соң җәннәт яисә җәһәннәм йорты гына булыр».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "قال الله عز وجل : وعزتي وجلالي إني لا أجمع على عبدي خوفي ، ولا أمين ، من خافني في الديا أمته في الآخرة ، ومن أمنني في الديا أخفته يوم القيامة".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителә. Ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйтте: «Үземнең гыйззәтем һәм олуглыгым белән ант итәм, дөреслектә, бәндәмдә ике куркынычны һәм ике өметне җыймам. Берәү дөньяда Миннән курыкса, ахирәттә аны тыныч итәрмен. Берәү дөньяда вакытта Миннән курыкмаса, тыныч торса, Кыямәт көнендә аны куркытырмын».

وروى عن عمار بن منصور ﷺ قال : كنت تحت مبر عدي بن أرطأة فقال : ألا أحدثكم حديثا ما بيني وبين رسول الله ﷺ إلا جل واحد ؟ قالوا : نعم ،

قال : قال رسول الله ﷺ : "إن لله ملائكة في السماء سجودا منذ خلقهم الله إلى يوم القيامة ،تعد فرائضهم م مخافة الله ، فإذا كان يوم القيامة فعوا رؤوسهم وقالوا : سبحانك ما عبداك حق عبادتك".

Гаммәрдән риваять ителә: ул әйтте: «Гади бине Әртәнең минбәре астында булдым. Ул әйтте: «Рәсүлуллаһтан бер генә кеше аркылы ишеткән хәдисне сөйлимме?» Без: «Сөйлә», – дидек. Ул әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Җиденче кат күктә Аллаһы Тәгаләнең шундый фәрештәләре бар, алар Аллаһы Тәгалә яратканнан алып Кыямәт көненә кадәр сәҗдәдә булырлар. Аллаһы Тәгаләдән курку сәбәпле тамырлары авазлы. Кыямәт көне булса, башларын күтәрерләр». Әйтерләр: «Әй пакь Зат, без Сиңа һич тиешлечә гыйбадәт кылмадык».

Әбү Мәйсәрәдән риваять ителә: Ул түшәгенә яткач: «Аһ, мине анам тудырмаган булсачы», – дип әйтә торган иде. Хатыны аңа: «Әй Әбү Мәйсәрә, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә сиңа изгелек кылды һәм сине Ислам диненә күндерде», – дип әйтә иде. Ул әйтте: «Дөрес, ләкин Аллаһы Тәгалә безгә тәмугка баруыбызны сөйләде, әмма безнең ул тәмугтан кайтасыбызны сөйләмәде».

Фудайл бине Гыядтан риваять ителә: ул әйтте: «Аллаһының рәхмәтенә якын фәрештәгә дә, рәсүл булган пәйгамбәргә дә кызыкмыйм, алар да Кыямәт көнендә шелтәләнәләр. Бары мин бар кылынмаган кешегә генә кызыгам».

Бер хәким әйтте: «Кайгы аштан калдыра. Аллаһыдан курку гөнаһ кылудан саклый, Аллаһының рәхмәтен өмет итү итагать итүне куәтләндерә, үлемне искә төшерү артык кәсеп итүне калдыра».

وروى عن رسول الله ﷺ أنه قال : "إذا اقشعر قلب المؤمن من خشية الله تعالى تحاتت عه خطاياه كما يتحات من الشجر ورقها".

Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять ителә: ул әйтте: «Мөэминнең күңеле Аллаһыдан куркудан тетрәсә, ул мөэминнән гөнаһлары агачтан яфраклар коелган кебек коелыр».

وس‌ءل رسول الله ﷺ من آلك يا سول الله ؟ قال "آلي كل مؤمن تقي إلى يوم القيامة ألا إن أوليائي هم المتقون ، ولا فضل لأحد منكم على أحد إلا بتقوى الله عز وجل".

Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән: «Әй Рәсүлуллаһ, сиңа кем иярде?» – дип сорадылар. Ул әйтте: «Кыямәт көненә кадәр килә торган, хәрамнан сакланучы һәрбер мөэмин иярде. Аң булыгыз, дөреслектә, миңа иярүчеләр, хәрам һәм шөбһәдән сакланучылар гына. Аң булыгыз, сездән һичкемгә артыклык юк, мәгәр Аллаһының тәкъвасы белән генә артыклык булыр».

عن الحسن ع رسول الله ﷺ انه قال : "ثلاث منجيات وثلاث مهلكات فأماالمهلكات : فشح مطاع ، وهوى متبع ، وإعجاب المرء بنفسه ، وإما المنجيات : فالعدل في الضا والغضب والاقتصاد في الفاقة والغني ، وخشية الله عز وجل في السر والعلانية".

Рәсүлуллаһтан риваять ителә: ул әйтте: «Өч төрле нәрсә бәндәне Аллаһының каһәреннән котылдырыр һәм өч төрле нәрсә һәлак итәр. Һәлак итүчеләре: баш иелгән саранлык, иярелгән нәфес теләге, кешенең үз эшенә яхшылык кылуы. Котылучылар: дус вакытта да, ачулы вакытта да эшне уртага салу; юклык вакытында да, бай вакытта

чамалап тереклек итү; кеше алдында да, ялгыз булганда да Аллаһыдан курку».

Рабигъ бине Хәйсәмнән риваять ителә: дөреслектә ул һәрвакыт елый һәм һәрвакыт курка иде, төнне аягүрә үткәрә иде. Аның мәшәкатен анасы күреп әйтте: «Әй улым, әллә кемне булса да үтердеңме?» Әйтте: «Әйе, үтердем». Анасы әйтте: «Кем ул, хәтта без ул үтерелгән кешенең вәлиләреннән гафу телик. Аллаһы белән ант итәм, әгәр үтерелгән кешенең вәлиләре син юлыккан нәрсәне белсәләр, гафу итәрләр, сиңа шәфкать итәрләр иде. Рабигъ әйтте: «Әй анам, нәфесемне үтердем, ягъни гөнаһ кылу сәбәпле нәфесемне тәмугка салырга сәбәп булдым».

Фәкыйһ әйтте: «Аллаһыдан курку галәмәте, җиде нәрсә булыр:

Беренчесе: адәмнең теленнән беленер. Аның теле ялган сөйләүдән, гайбәттән һәм артык сүзне сөйләүдән тыелыр. Телне Аллаһының зикере һәм Коръән уку белән шөгыльләндерер.

Икенчесе: күзе хакында курку тиеш, ягъни хәрам әйберләргә һәм дөньяга кызыгып карамас. Дөньяга каравы бары тик гыйбрәт өчен генә булыр.

Өченчесе: эч хакында курку. Эченә хәләл һәм пакь ашамлыктан һәм эчемлектән башканы кертмәс.

Дүртенчесе: кулы хакында курку. Кулын хәрамга сузмасын, Аллаһының тәгате булган нәрсәгә генә сузсын.

Бишенчесе: ике аягы хакында курку. Аллаһының гөнаһысына йөрмәсен.

Алтынчысы: күңел хакында курку. Ул күңелдән дошманлыкны, ачуны һәм кардәшләрдән көнчелекне чыгарыр. Ул күңелгә мөселманнарга шәфкать кылуны һәм хәерлекне кертер.

Җиденчесе: тәгате хакында курку тиеш. Гыйбадәтне Аллаһы ризалыгы өчен генә кылыр. Рия һәм монафыйклыктан куркыр. Әгәр бәндә боларны эшләсә, ул Аллаһы Тәгаләнең мактап сөйләгән кешеләр җөмләсеннән булыр.

﴿ وَزُخْرُفًا وَإِنْ كُلُّ ذَلِكَ لَمَّا مَتَاعُ الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَالْآخِرَةُ عِنْدَ رَبِّكَ لِلْمُتَّقِينَ ﴾

«Дәхи алар өчен һәрнәрсәдән зиннәт кылыр идек, бу зекер ителгән нәрсәләр, дөнья тереклегенең аз вакытлы булган нәрсәсе һәм зиннәте, һич мәңге кала торган түгел. Әмма ахирәтнең байлыгы, зиннәте һәм рәхәте мәңгелек, ул бәхетле ахирәт, Аллаһы хөкемнәрен бозудан сакланучы тәкъва мөэминнәр өчен хәзерләнде». («Зөхруф» сүрәсе, 35)

Ахирәт көнендә Раббың каршындагы изгелек хәрамнан сакланган кешеләргәдер.

Аллаһы Тәгалә икенче бер аятендә әйтте:

﴿ إِنَّ الْمُتَّقِينَ فِي جَنَّاتٍ وَنَعِيمٍ ﴾

«Тәхкыйк, Аллаһыга һәм рәсүлгә итагать итүче тәкъва мөэминнәр җәннәтләрдә һәм нигъмәтләр эчендәдер». («Тур» сүрәсе, 17)

Аллаһы Тәгалә Китабында тәкъва әһелләрен күп урыннарда мактады. Дәхи Аллаһы Тәгалә хәбәр бирде, дөреслектә, ул тәкъвалык әһелләре тәмугтан котылырлар:

﴿ وَاتَّخَذُوا مِنْ دُونِ اللَّهِ آلِهَةً لِيَكُونُوا لَهُمْ عِزًّا . كَلَّا سَيَكْفُرُونَ بِعِبَادَتِهِمْ وَيَكُونُونَ عَلَيْهِمْ ضِدًّا ﴾

«Сездән һичкем ул тәмугка бармый калмас. Синең Раббыңа бу хөкем анык шиксез булды. Моннан соң тәкъвалык ияләрен котылдырдык һәм ул тәмугта залимнәрне тезләре хозурына егылган хәлдә калдырырбыз». («Мәрьям» сүрәсе, 81, 82)

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбүл-Гәвүәмнән риваять итә: ул әйтте: Кәгеб: «Вә ин минкүм иллә вәридүһә» сүзенең мәгънәсен беләсезме?» – дип сорады. Алар әйттеләр: «Ул, без тәмугка килүне күрә торган булмадык, мәгәр тәмугка керүне генә күрәбез, дигән сүз». Кәгеб әйтте: «Юк, мәгәр ул тәмугка килү – җәһәннәмне китерелүдер. Ул җәһәннәм сасыган ит мае кебек исле булыр, хәтта халыкларның изгесе һәм бозыкның аяклары шул җәһәннәмгә баскач, бер кычкыручы кычкырыр: «Үз кешеләреңне ал, минем кешеләремне калдыр». Тәмуг үзенә лаек булучыларның һәрберсен йотар. Ул тәмуг үзенең кешеләрен атасы баласын белгәннән артык белер. Мөэминнәр чабуларын кыстырып котылырлар, ягъни шул дәрәҗәдә якын булырлар. Дөреслектә, тәмуг хуҗаларыннан булган бер хуҗаның тимердән терәге булыр, аның ике бүлеге бар: берсе белән бер сугар, тәмугка җиде йөз мең түбән китәр».

عن عمان بن حصين قال : كنا مع رسول الله ﷺ في شيرة ، فنزلت هذه الآية : "يَاأَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمْ إِنَّ زَلْزَلَةَ السَّاعَةِ شَيْءٌ عَظِيمٌ" ثم قال رسول الله ﷺ : "أتدرون أي يوم ذلك ؟ " قالوا : الله ورسوله أعلم ، قال : "ذلك اليوم الذي يقول الله لآدم : قم فابعث بعث النار وبعث الجنة فيقول آدم : أي رب فما بعث الار وما بعث الجنة ؟ فيوقل الله تعالى : م كل ألف تسعمائة وتسعةوتسعون إلى الار وواحد في الجنة".

فانشأ القوم يبكون فقال رسول الله ﷺ : "لم يكنني إلا كانت قبله جاهلية ، فيؤخذ العدد م الجاهلية ، فإن لم يكمل العدد من الجاهلية فيؤخذ م المافقين وما مثلكم في الأمم إلا كمثل الرقمة في ذراع الدابة أو كالشامة في جنب

البعير" ثم قال : "إني لأرجو أن تكونوا ثلثي أهل الجنة فكبروا" ، قم قال : "! معكم لخلقتين ما كانتا في شيء إلا كثرتاه بأجوج ومأجوج ، ومن مات من كفرة الجن والإنس".

Гыймран бине Хәсәннән риваять ителә: «Без Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм белән сәфәрдә булдык. Шунда бу аять иңде:

«Әй кешеләр! Раббыгыздан сакланыгыз, дөреслектә, Кыямәт тетрәве олуг нәрсә». («Хаҗ» сүрәсе, 1)

Моннан соң Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Бу нинди көн, беләсезме?» Әйттек: «Аллаһы һәм Аның илчесе бездән яхшырак белүче». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Бу көн шундый көн ки, Аллаһы Тәгалә адәмгә, тор, дип әйтер. Тәмугка һәм җәннәткә кубучыны да кубар. Адәм әйтер: «Әй Раббым, тәмугка һәм җәннәткә кубу нәрсә?» Аллаһы Тәгалә әйтер: «Һәрбер меңнән тугыз йөз туксан тугызы тәмугта һәм берсе җәннәттә». Шул вакытта халык елый башлады. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Мин сезнең җәннәт халкы арасында булуыгызны өмет итәмен». Сәхабәләр тәкбир әйттеләр. Моннан соң Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Үзеннән элек җаһилиятсез пәйгамбәр һич булмады. Зекер ителгән сан җаһилият кешеләреннән алыныр, ягъни халкының меңнән тугыз йөз туксан тугызы җәһәннәмле димәктер. Әгәр сан җаһилияттән тәмам булмаса, ул вакытта монафыйклардан алыныр. Өммәтләр арасында сезнең охшашыгыз, атның терсәгендәге мең охшашыдыр яки дөянең кабыргасындагы үркәч кебек». Моннан соң Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Мин җәннәт халкының өчтән икесе булуыгызны өмет итәмен». Сәхабәләр тәкбир әйттеләр. Моннан соң Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте:

«Дөреслектә, сезнең белән ике төрле халык булыр. Ни-нәрсәдә булса, алар күплек белән өстен булырлар, Йәэҗүҗ вә Мәэҗүҗ белән адәм һәм җеннәрдән кәфер булып үлүчеләрдер».

Хәсән Бәсридән риваять ителде, ул әйтте: «Кеше үзе сөйгән зат белән була, дип әйткән кешенең сүзе сине алдамасын, чөнки син изгеләргә алар кыла торган гамәлләр белән генә юлдаш була алырсын. Чөнки яһүд, насара һәм бидгать халкы үзләренең пәйгамбәрләрен яраталар, ләкин алар ул пәйгамбәрләр белән түгелләр».

و عن سول الله ﷺ أنه قال : "من استوى يوماه فهو مغبون ، وم كان غده شا من يومه فهو ملعون ، وم لم يكن في زيادة فهو في النقصان ، ومن كا في النقصان فالموت خير له".

Рәсүлуллаһтан риваять ителде, ул әйтте: «Ике көне бертигез булган кеше, ягъни бүгенге көне кичәге көннән артык булмаган кеше алдангандыр. Иртәсе бу көнгедән начар булган кеше мәльгундер. Кем дә кемнең көннәре арттыруда булмаса, ул кеше киметүдә буладыр. Кем дә кем киметүдә булса, бәс аңа үлем изгерәктер».

Кәгъбтән риваять ителде, ул әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең зүмәрраттән яисә энҗедән ясаган йорты бардыр. Шул йорт эчендә җитмеш мең йорттыр. Һәрбер йортта җитмеш мең бүлмә бар. Ул йортка пәйгамбәр, яки иманда һич шиге булмаган кеше, ягъни иң әүвәлдә иман китергәндә һич бәхәссез бер булучы Аллаһы Тәгаләне кабул иткән кеше, яки шаһид булып үлгән кеше, яки гадел патша, яки үзе хакында нык булган кеше керер». «Үзе нык булу нәрсә ул?» – дип сорадылар. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Шундый кешедер ки, аңа хәрамны

кылырга алдына китерелер дә, Аллаһыдан курыкканнан ул хәрам эшне кылмас».

Фәкыйһ әйтте, атамнан ишеткән идем, ул әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм заманында бер кеше бар иде, аңа Ханзалә дип әйтеләә иде, ул әйтте: «Без Рәсүлуллаһ янында булганда ул безгә шундый вәгазь сөйләде ки, ул вәгазьдән күңелләребез нечкәрде, күзләребез яшьләнде, нәфесләребез үз-үзен таныды. Җәмәгатем янына кайткач, яныма хатыным утырды, арабызда дөнья сүзе булды, Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм янында ни булганын оныттым. Дөнья сүзен сөйләшә башладык, соңыннан Пәйгамбәребез галәйһиссәләм мәҗлесен искә төшердем һәм үз-үземә әйттем: «Минем курку һәм кайгылы булуым алмашынган вакытта мин нифаклык (икейөзлелек) кылдым», – дип. Чыгып, Ханзалә монафыйклык итте, дип кычкыра башладым. Миңа Әбү Бәкер очрады, ул: «Әй Ханзалә, монафыйклык кылмадың», – диде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм янына кердем һәм: «Ханзалә монафыйклык кылды, Ханзалә монафыйклык кылды», – дидем. Ул әйтте: «Әй, Ханзалә монафыйклык кылмады». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, без синең яныңда булдык, безне күңелләр курка һәм күзләр яшьләнә торган вәгазь белән вәгазьләдең, үзебезне үзебезгә таныттың. Соңыннан җәмәгатем янына кайттым, дөнья сүзләрен сөйли башладык, синең яныңда ни рәвештә булганыбызны оныттым». Рәсүлүллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әй, Ханзалә әгәр сез шул хәл хозурында булсагыз, фәрештәләр сезнең белән юлда күрешерләр иде, йортларыгызда һәм түшәкләрегездә дә сезне зиярат итәрләр иде».

وروى ع عائشة ﷺ أنها قالت : سألت سول الله ﷺ عن قوله تعالى : "وَالَّذِينَ يُؤْتُونَ مَا آتَوا وَقُلُوبُهُمْ وَجِلَةٌ" الآية ، أهم الذين يعملون بالمعاصي ويخافون ؟ قال : "لا ، ولكن هم الذين يعملون بالطاعة و يخافون أن لا تقبل منهم".

Гайшә разыяллаһү ганһәдән риваять ителде. Ул әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән «Мөэмин» сүрәсенең 60 аятьнең мәгънәсе турында сорадым. Алар гөнаһны кылып куркучылар түгелме, дидем. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Юк, алай түгел. Гамәлне кылырлар да һәм үзләреннән кабул булмавыннан куркырлар».

Фәкыйһ әйтте: «Кем дә кем изгелекне эшләсә, дүрт төрле нәрсәдән курку кирәк буладыр. Шулай булгач, явызлыкны эшләүче хакында ни уйлыйсың. Ул куркырга тиешле булган нәрсәләр шулардыр:

1. Кабул булмавыннан курку, чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ إِنَّمَا يَتَقَبَّلُ اللَّهُ مِنْ الْمُتَّقِينَ ﴾

«Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә тәкъва кешеләрнекен генә кабул итәдер». (Маидә: 27)

2. Риядан курку. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَمَا أُمِرُوا إِلَّا لِيَعْبُدُوا اللَّهَ مُخْلِصِينَ لَهُ الدِّينَ ﴾

«Ул кешеләр Аллаһы Тәгаләгә ихласлы булганнары хәлдә генә гыйбадәт кылу белән боерылдылар». (Бәййинә: 5)

3. Тапшырылу һәм Кыяматкә кадәр саклану куркынычы, ягъни ул кеше изгелекне Кыяматкә барырлык итеп саклый алырмы, юкмы? Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ مَنْ جَاءَ بِالْحَسَنَةِ فَلَهُ عَشْرُ أَمْثَالِهَا ﴾

«Бер мөэмин Аллаһы хозурына изге гамәлләр белән килсә, ул мөэмингә изгелекләре ун тапкыр арттырылыр». (Әнгам: 160)

Аллаһы Тәгалә шул изгелекне Ахирәт йортына алып баруны шарт итте.

4. Тәгатьтән мәхрүм булу куркынычы, чөнки кеше тәгатькә ирешә алуын яки алмавын белми. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَمَاتَوْ فِيقِي إِلَّا بِاللَّهِ عَلَيْهِ تَوَكَّلْتُ وَإِلَيْهِ أُنِيبُ ﴾

«... минем гамәл кылырга ирешүем тик Аллаһы Тәгалә белән генәдер. Ул Аллаһы Тәгаләгә тапшырдым һәм Аңа гына кайтачакмын». (Һуд: 88)

## Аллаһы Тәгаләне искә алу

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Дәрдәдән риваять итте. Ул әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Сезгә изге гамәлегез хакында хәбәр бирмимме? Хуҗагыз каршында ул гамәлләрнең иң сафыннан, дәрәҗәләрегезнең иң югарысы һәм сезнең өчен алтын, көмешне сарыф итүдән дә изгерәктер. Ул, мин әйтә торган нәрсә, дошманнарыгызны йолкып, аларның муеннарына сугуыгыздан һәм аларның сезнең муеныгызны сугуларыннан изгедер. Ул мин сезгә хәбәр бирә торган нәрсә – Аллаһының зикередер».

عن أبي جعفر ، أن رسول الله ﷺ قال : "أشد الأعمال ثلاثة : إنصاف الرجل من نفسه ، وماساة الأخ في المال ، وذكر اللهتعالى على كل حال".

Әбү Җәгъфәрдән риваять ителде. Рәсүллүлаһ галәйһиссәләм әйтте: «Гамәлләрнең иң катысы өчәүдер: кешенең үз нәфесеннән инсаф кылуыдыр;

малда кардәшен иптәш итүдер; Аллаһының зикередер».

Мугаз бине Җәбәлдән риваять ителде, ул әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең зикереннән башка Аллаһының газабыннан котылдыра торган гамәлне адәм баласы кыла алмады». «Аллаһының юлында сугышу ул дәрәҗәдә түгелме?» – дип сорадылар. Ул әйтте: «Юк, Аллаһы Тәгаләнең юлында сугышу, ул дәрәҗәдә түгел, чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте: ﴿وَلَذِكْرُ اللَّهِ أَكْبَرُ﴾ «Аллаһы Тәгаләнең зикере, әлбәттә, олуграктыр». (Ганкабут: 45)

وعن الحسن البصري قال : قيل : يا رسول الله أي العمل أفضل ؟ قال : "أن تموت ولسانك رطب بذكر الله".

Хәсән Бәсридән риваять ителде, ул әйтте: Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән: «Әй Рәсүлуллаһ, кайсы гамәл артыграк?» – дип сорадылар. Рәсүлуллаһ: «Аллаһыны зекер итү сәбәпле телең юаш булганда вафат булуың», – дип җавап бирде».

Мәлик бине Динар әйтте: «Кеше Аллаһы Тәгаләнең сүзе белән өлфәтләнмәсә, тәхкыйк, ул кешенең гамәле аз булды, күзе сукырайды, гомере буш үтте».

وروى أنس بن كالك ﷺ عن رسول الله ﷺ أنه قال : "ذكر الله علم الإيمان ، وبراءة من النفاق وحصن من الشيطان ، وحرز من النار".

Әнәс бине Мәлик Рәсүлуллаһтан риваять итте. Ул әйтте: «Аллаһының зикере иман галәмәте, монафыйклыктан бизү, шайтаннан кальгә һәм җәһәннәмнән сакланудыр».

Вәһәб бине Мөнбәһ Ибен Габбастан риваять итте, Ибен Габбас әйтте: «Аллаһы Тәгалә Яхъя

галәйһиссәләмне Бәни Исраил кавеменә пәйгамбәр итеп җибәргәндә, аңа Бәни Исраил кавеменә биш төрле нәрсәне кушырга боерды. Һәм һәрбер хасиләт өчен бер мисал күрсәтергә әмер итте. Яхъя галәйһиссәләм кавеменә Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылырга һәм ул гыйбадәттә Аллаһыга һичбер нәрсәне ширек итмәскә боерды. Һәм мисал күрсәтеп әйтте: «Ширек мисалы – саф үз малыннан гына кол сатып алган кеше кебектер. Моннан соң ул кеше колны йортка куйды һәм үзенең кәнизәген аңа өйләндерде һәм аңа мал бирде. Ул мал белән сату итеп, җитәрлек кадәр ашарга, табышның артыгын үзенә кайтарып бирергә кушты. Кол исә файданың артыгына максатланды, хуҗасына аз гына биреп, калганын хуҗасының дошманына бирә башлады. Инде мондый кол булса, аңа кайсыгыз разый булыр?» Шуннан соң намаз уку белән боерды. Һәм аңа да мисал китереп, әйтте: «Намазның мисалы патшаларның берсенә керергә рөхсәт сораган кеше кебектер. Ул патша аңа керергә рөхсәт итте һәм ул керде. Патша ул кешенең сүзен тыңлар һәм хаҗәтен үтәр өчен аңа йөзе белән әйләнде. Ләкин ул кеше уңга һәм сулга карана башлады, йомышының үтәлүе өчен кайгырмады, һәм патша аннан йөзен алды һәм йомышын үтәмәде». Бу мисалны китергәч, Яхъя галәйһиссәләм кавеменә ураза тоту белән боерды һәм аларга мисал күрсәтеп, әйтте: «Ураза тотучының мисалы сугыш өчен тимер күлмәк кигән һәм коралларны алган кеше кебектер. Аның дошманы аңа килеп очрый алмады. Һәм ул эштә дошманының коралларын эшләмәде». Аннан соң Яхъя галәйһиссәләм аларга садака бирү белән боерды. Һәм мисал китереп, әйтте: «Садаканың мисалы дошманы әсир итеп алган кеше охшашыдыр. Билгеле акча бә-

рабәренә ул үз-үзен сатып алды. Һәм ул кеше үз шәһәрендә эшли башлады. Аз яки күп булсын, ул үзенең кәсебеннән дошманнарына бирә торган булды, хәтта алардан үз-үзен сатып алды һәм азат булды». Бу мисалдан соң Яхъя галәйһиссәләм аларга Аллаһы Тәгаләне зекер итәргә боерды һәм шуңа мисал күрсәтте, ул әйтте: «Зикернең мисалы, нык кальгәләре булып, якыннарында дошман булган халык охшашыдыр. Аларга дошман килде һәм алар кальгәләренә керделәр, дошманнарыннан качып, кальгәнең ишеген бикләделәр һәм үз-үзләрен дошманнан сакладылар». Моннан соң Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте:

ثم قال رسول الله ﷺ : "وأنا آمركم بهذه الخصال الخمس التي أمر الله تعالى بهن يحيى عليه الصلاة والسلم وآمركم بخمس خصال أخرى أمرني الله تعالى بهن : عليكم بالجماعة ، والسمع والطاعة ، والهجرة ، والجهاد ، ومن دعا بدعاء الجاهلية فهو في جثا جهنم".

«Мин дә сезгә Аллаһы Тәгалә Яхъя пәйгамбәргә боерган ошбу биш төрле нәрсәләр белән боерам. Һәм моннан башка тагы биш төрле нәрсәне кылырга боерам, аларны миңа Аллаһы Тәгалә вәхи кылды. Сезгә җәмәгать, тыңлау, буйсыну, нәфес теләкләрен ташлау һәм шайтан белән сугышу лязем булсын. Кем дә кем җаһилият догасын кылса, ул кеше җәһәннәм уртасында утындыр».

Габдулла бине Гамирдән риваять ителде. Ул әйтте: «Кем дә кем әлхәмдүлилләһ дип әйтсә, аның өчен күк ишекләре ачылыр, тәкбир әйтсә, җир белән күк арасы тулыр, һәм Аллаһы өчен тәсбих әйтсә, савабының чиген Аллаһыдан башка кеше белмәс».

Габдулла бине Гамирдән риваять ителде, ул әйтте: «Кем дә кем «әлхәмдүлилләһ», дип әйтсә, аның өчен күк ишекләре ачылыр. Тәкбир әйтсә, җир белән күк арасы тулыр. Аллаһы өчен тәсбих әйтсә, савабының чиген Аллаһыдан башка бер кем дә белмәс». Аллаһы Тәгалә хәдис көдсидә әйтте:

"إذا ذكرني عبدي في نفسه ذكرته في نفسي ، وإذا ذكرني وحده ذكرته وحدي ، وإذا ذكرني في ملأ ذكرته في ملأ أحسن منه وأكرم"

«Минем бәндәм үз-үзенә Мине искә төшерсә, Мин дә аны үз-үземә зекер итәрмен. Әгәр ул ялгыз гына Мине зекер итсә, Мин дә аны ялгыз гына зекер итәрмен. Әгәр ул Мине җәмәгать арасында зекер итсә, Мин дә аны җәмәгать арасында күркәмрәк һәм хөрмәтлерәк итеп зекер итәрмен».

Әйтелде: «Аллаһы Тәгаләне зекер кылган хәлдә кабыргасын түшәгенә салып, аңа шул хәлдә йокы ирешсә, Аллаһы Тәгалә аны уянганга кадәр зекер итүчеләр җөмләсеннән язачак». Фәкыйһ әйтте: «Югарыда Аллаһы Тәгаләнең «Мин ул бәндәне зекер кылырмын» дигән сүзе бар иде. Шул зекердән морад – Аллаһының ярлыкавы белән гафу кылуыдыр. Әгәр бәндә Аллаһыны зекер итсә, Аллаһы Тәгалә ул бәндәне ярлыкау белән зекер кылыр».

Гали разыяллаһү ганһүдән риваять ителде, ул әйтте: «Аллаһыны зекер итү ике зекер арасында, Ислам ике кылыч арасында һәм гөнаһ кылу ике фарыз арасындадыр. Аллаһының зикере ике зикер арасында дигән сүздән морад – Аллаһы Тәгалә шул бәндәнең зекер кылуга муафыйк булуын теләмәсә, аның Аллаһыны зекер итәргә көче җитмидер. Әгәр бәндә Аллаһыны зекер кылса, Аллаһы Тәгалә аны мәгъфирәт белән зекер кылыр. Ислам дине ике кылыч арасында, дигән сүзнең мәгънәсе – кеше

тәмам мөселман булганга кадәр аның белән сугышырлар. Әгәр соңыннан Исламнан кайтса ул кеше үтерелер. Гөнаһ ике фарыз арасында дип әйткән сүзнең мәгънәсе – бәндә хозурына гөнаһ кылмаска фарыз ителде. Әгәр гөнаһ кылса, аңа тәүбә кылу фарыздыр».

Аллаһы Тәгаләнең ﴿من شر وسوس الخنس﴾, дип әйткән аятьнең тәфсирендә Ибен Габбастан риваять ителде. Ул әйтте: «Ул вәсвәсә шулдыр ки, күңел хозурында йоклаучы шайтандыр. Әгәр Аллаһы Тәгалә зекер ителсә, китеп тора. Әгәр Аллаһының зикереннән гафил булып торса, ул шайтан вәсвәсә кылыр».

وعن رسول الله ﷺ أنه قال : "لكل شيء صقال ، وصقال القلب ذكر الله تعالى".

Рәсүлуллаһтан риваять ителде. Ул әйтте: «Һәрнәрсәнең ялтыратучысы бар. Йөрәкнең ялтыратучысы Аллаһының зикередер».

Ибраһим Нәхәгый әйткән: «Әгәр кеше үзенең йортына кергәч, сәлам бирсә, шайтан: «Миңа монда урын калмады», – дияр. Әгәр аш китергәч «бисмилләһ» дип әйтсә, шайтан: «Эчәргә дә, ашарга да юк, урын да юк», – диеп, өметсез булып, өйдән чыгар».

وعن عائشة رضي الله عنها أن رسول الله ﷺ قال : "إذا أكل أحدكم طعاما فليقل : بسم الله، فإن نسي في أوله فليقل في آخره : بسم الله في أوله و لآخره".

Гайшә разыяллаһү ганһәдән риваять ителде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Сезнең берәрегез ризык ашаса, «бисмилләһ», дип әйтсен. Әгәр ашауның башында онытса, ахырында әйтсен».

Ибен Мәсгуд разыяллаһү ганһүдән риваять ителде, ул әйтте: «Әгәр кеше аш ашаганда «бисмилләһ» әйтмәсә, аның белән бергә шайтан ашар. Аллаһының исемен зекер итсә, ашның калганында шайтан тыелыр, ашаганын да косар. Яңа ризыкны ашый башлар».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Мөхәммәдтән риваять итте: «Иблис Раббысына әйткән: «Әй Раббым, адәм балалары өчен эчендә Сине зекер кыла торган өйләр кылдың, минем өем нәрсә булыр?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Синең өең мунча булыр». Иблис әйтте: «Ул адәмнәр өчен мәҗлесләр ясадың минем мәҗлесем ни булыр?» Аллаһы Тәгалә: «Мәҗлесең базар булыр», – дип җавап бирде. Иблис әйтте: «Адәм балаларына кыйраәт кылдың, минем кыйраәтем ни булыр?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Синең кыйраәтең шигыйрь булыр». Иблис әйтте: «Адәм балалары өчен сөйләшергә сүз ясадың, минем сүзем ни булыр?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Синең сүзең ялган булыр». Иблис әйтте: «Адәм балаларына азан ясадың, минем азаным ни булыр?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Уен тавышы синең азаның булыр». Иблис: «Адәм балаларына пәйгамбәрләр ясадың, минем пәйгамбәрләрем кем булыр?» – дип сорады. Аллаһы Тәгалә: «Күрәзә, багучылар синең пәйгамбәрләрең булыр», – дип җавап бирде. Иблис әйтте: «Адәм балаларына китап кылдың, минем китабым ни булыр?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Кан белән кул, аркага язылган нәрсә». Иблис әйтте: «Адәм балаларына ау кылдың, минем авым нәрсә булыр?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Синең авың хатыннар булыр». Иблис әйтте: «Адәм балаларына ашамлык ясадың, минем ашамлыгым ни булыр?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Минем исемем аның хозурына зекер

ителмәгән ашамлык синең ашамлыгың булыр». Иблис әйтте: «Адәм балаларына эчемлек кылдың, минем эчемлегем ни булыр?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Һәр исерткеч нәрсә синең эчемлегең булыр».

Фудайлдән риваять ителә. Аның янына бер кеше килде һәм: «Әй Фудайл, миңа берәр нәрсә белән васыять ит», – дип сорады. Фудайл әйтте: «Миннән биш нәрсәне күңелеңә ал:

Беренчесе: әгәр башыңа бер нәрсә төшсә, ягъни берәр бәла ирешсә, бу эш Аллаһының хөкеме белән дип бел, хәтта халыкны шелтәләмәссең. Ягъни берәр начарлык килсә, халыкны шелтәләмә.

Икенчесе: һәрбер халык синнән котылсын һәм син дә Аллаһының газабыннан котылыр өчен телеңне сакла.

Өченчесе: Аллаһы Тәгаләнең сиңа ризык вәгъдә кылган сүзенә ышан, хәтта мөэмин булырсын.

Дүртенчесе: үлем өчен хәзерлән, хәтта гафил булып үлмәссең.

Бишенчесе: нинди рәвештә һәм нинди генә хәлдә булсаң да, Аллаһыны күп зекер кыл, хәтта барча явызлыклардан пакь булырсың».

Ибраһим бине Әдһәмнән риваять ителеп сөйләнде. Ул дөнья сүзе сөйли торган бер кешене күрде. Аның янына килеп әйтте: «Савап өмет итә торган сүзең шулмы?» Теге кеше: «Юк», – диде. Ибраһим бине Әдһәм: «Ул сүзең хакында газап булмавында күңелең тынычмы?» – дип сорады. Ул кеше: «Юк», – диде. Ибраһим әйтте: «Савап өмет ителми торган һәм шуның өчен газап булмавыннан тыныч булмаган сүз белән нәрсә эшлисең? Сиңа Аллаһыны зекер итү лязем булсын».

Кәгъб әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәрләренә иңдергән китабында без Аллаһы Тәгаләнең шулай дип әйткәнен күрәбез:

من شغله ذكري عن مسألتي أعطيته فوق ما أعطى السائلين

«Кем дә кем сораудан башка Минем зикерем белән шөгыльләнсә, сораучыларга бирә торганымнан да артык бирермен».

Фудайл әйтте: «Дөреслектә, шәм утсыз йорт халкына ут биргән кебек, Аллаһының исеме зекер ителә торган йорт та күк халкына яктылык бирәдер. Һәм дөреслектә, Аллаһының исеме зекер кылынмый торган өй – ул өйнең халкына караңгылык итәр».

Хәбәрләрдә килә, дөреслектә, Муса галәйһиссәләм әйтте: «Әй Раббым, Син сөйгән кешене ачуланган кешеңнән ничек аерып белим?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй Муса, әгәр бәндәне сөйсәм, Мин анарда ике төрле галәмәт кыламын». Муса галәйһиссәләм әйтте: «Әй Раббым ул ике галәмәт нәрсә?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Күк һәм җир йөзендә аны зекер кылуым өчен аңа зикеремне илһам кылырмын. Аның хозурына Минем газабым һәм ачуым булмасын өчен аны хәрамымнан һәм ачуымнан саклармын. Әй Муса, әгәр мин бәндәгә ачулансам, анарда ике галәмәт кылырмын». Муса әйтте: «Әй Раббым, ул ике галәмәт нәрсәләр?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Минем хәрамнарыма һәм ачуыма төшсен өчен аңа зикеремне оныттырырмын һәм ул бәндә белән нәфес арасын ихтыярлы итәрмен. Һәм ул бәндәгә Минем газабым һәм ачуым иңәр».

وروى ع أبو المليح ع أبيه أن رجلا من أصحاب النبي ﷺ كان رديفه على دابة ، فعثرت بهما الدابة ، فقال الرجل : نعس الشيطان ، فقال النبي ﷺ :

"لا تقل السيطان فإنه عند ذلك يتعاظم حتى يكون ماء البيت ، ولكن قل : بسم الله ، فإنه يصغر عند ذلك حتى يكون مثل الذباب".

Әбүл-Мәлих атасыннан риваять итте. Сәхабәләрнең берсе хайван өстенә Рәсүлуллаһның артына атланды, хайван һәр икесен екты, теге кеше: «Шайтан һәлак итте», – диде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Шайтан һәлак итте, дип әйтмә. Чөнки ул шундый сүз әйткәндә өй кебек зураер. Мәгәр син «бисмилләһ» дип әйт. Чөнки «бисмилләһ» дип әйткәндә, кечерәер, хәтта чебен кадәр генә булып калыр».

وروى داود بن قيس ﷺ ع نافع م جبير عن أبيه أن النبي ﷺ قال : "كفارة المجلس إذا أراد أحدكم أن يقوم من مجلسه أن يقول : سبحانك اللهم وبحمدك ، أشهد أن لا إله إلا أنت ، أستغفرك وأتوب إليك فإن كان مجلس ذكر كان طالكابع عليه إلى يوم القيامة ، وإن كان مجلس لغو كان كفارة لما قبله".

Дәвыд бине Кайс, Нәфигъ бине Җәбирдән риваять итте, Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Һәркайчан сезнең берегез утырган урыныннан торырга теләсә, «Сүбханәкә аллаһүммә вә бихамдикә, әшһәдү әлләә иләәһә иллә әнтә, әстәгъфирукә вә әтүбү иләйк», дип әйтү мәҗлесенә кәффарәт булыр. Әгәр ул утырган мәҗлес зикер мәҗлесе булса, шул сүбхәнәкә сүзе Кыямәт көненә кадәр шул мәҗлеснең мөһере кебек булыр. Әгәр буш мәҗлес булса, шуннан әүвәл булган сүзләргә кәффарәт булыр».

عن محمد بن واسع قال : قدمت من مكة ، فلقيت أخا سالم بن عبد الله يحدث عن أبيه ، عن جده عمر ب الخطاب ﷺ أن رسول الله ﷺ قال : "من دخل السوق ، فقال : لا إله إلا الله وحده لا شريك له ، له الملك وله الحمد يحيي

ويميت ، وهو حي لا يموت ، بيده الخير وهو على كل شيء قدير ، كتب الله له ألف ألف حسنة ، ومحا عه ألف ألف شيئة ، ةرفع له ألف ألف درجة".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Мөхәммәд бине Васигъдән риваять итте, ул әйтте: «Мәккәгә килдем, Сәлим бине Габдулла исемле кардәшкә очрадым, ул үзенең бабасы Гомәр бине әл-Хаттаб разыяллаһү ганһүдән риваять кыла, Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Берәү базарга кереп:

لا إله إلا الله وحده لا شريك له له الملك و له الحمد يحي و يميت و هو حي لا يموت بيده الخير و هو على كل شيء قدير

«Ләә иләәһә илләл-лаһ, вәхдәһү ләә шәриикә ләһү, ләһүл-мүлкү вә ләһүл-хамдү, йүхйи вә йүмитү, вә һүвә хәййү ләә йәмүүтү, бийәдиһил-хайри вә һүвә галәә күлли шәй-иң кадиир», дип әйтсә, Аллаһы Тәгалә аңа мең-мең изгелекне язар, аңардан мең-мең явызлыкны юар һәм аны мең-мең дәрәҗәгә күтәрер».

Гомәр бине әл-Хаттаб әйтте: «Хорасанга бардым, Котәйбә разыяллаһү ганһүгә килдем һәм аңа: «Сиңа бүләк алып килдем», – диеп, югарыда бәян ителгән хәдисне сөйләдем. Котәйбә үзенең атлы гаскәре арасында иде, атка атланды һәм базарга җиткәнчегә кадәр барып, ошбу сүзләрне әйтте, моннан соң шулай итә торган булды».

Фәкыйһ әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең зикере гыйбадәтләрнең иң артыгы икәнен бел. Чөнки Аллаһы Тәгалә башка гыйбадәтләргә бер төрле үлчәү кылды һәм аларга билгеле вакытлар билгеләде. Аллаһының зикере өчен сан да, вакыт та кылмады. Чиксез күп әйтү белән боерды:

﴿ يَاأَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اذْكُرُوا اللَّهَ ذِكْرًا كَثِيرًا ﴾

«Әй иман китергән бәндәләр, күп зекер кылыгыз». (Әхзәб: 41) Ягъни Аллаһыны һәр хәлдә зекер кылыгыз. Моның мәгънәсе шулдыр: бәндә дүрт хәлләрнең берсендә булудан буш түгел. Я ул бәндә гыйбадәттә була, я гөнаһта була, я нигъмәттә, я кайгы һәм катылык эчендә була. Әгәр бәндә гыйбадәттә булса, аңа Аллаһы Тәгаләне искә төшерү ляземдер. Ул гыйбадәткә ирешүне, Аллаһы Тәгаләдән кабул итүне сорарга тиеш. Әгәр бәндә гөнаһта булса, Аллаһы Тәгаләдән дога кылып үзенең гөнаһтан тыелуын һәм Аллаһы Тәгаләнең ярлыкавын сорарга тиеш. Әгәр бәндә нигъмәттә булса, Аллаһы Тәгаләне шөкер белән зекер итәр. Әгәр бәндә катылык һәм кайгыда булса, Аллаһы Тәгаләне сабырлык һәм түземлек белән зекер итәр. Янә бел, Аллаһыны зекер кылуда мактаулы биш хасыять бар: беренчесе, зекер кылуда Аллаһыны риза кылу бардыр. Икенчесе, гыйбадәткә хирысны арттыра. Өченчесе, зикердә шайтаннан саклану бардыр. Дүртенчесе, зекер кылуда күңел йомшаруы бардыр. Бишенчесе, зекер кылучыны гөнаһлардан тыядыр.

## Дога бүлеге

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Һөрәйрәдән риваять итте, ул әйтте: «Берәү биш нәрсәне ризыкланса, биш төрле хасыятьтән мәхрүм булмас:

Кем дә кем шөкер кылса, нигъмәт артудан мәхрүм булмас. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ لَئِن شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ ﴾

«Әгәр шөкер кылсагыз, әлбәттә, арттырырмын». (Ибраһим:7)

Әгәр бер кеше сабыр итсә, саваптан мәхрүм калмас. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ إِنَّمَا يُوَفَّى الصَّابِرُونَ أَجْرَهُمْ بِغَيْرِ حِسَابٍ ﴾

«Түзүчеләр әҗерләре хисапсыз бирелер». (Зүмәр: 10)

Әгәр тәүбә итүчән булса, кабул булудан мәхрүм калмас. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَهُوَ الَّذِي يَقْبَلُ التَّوْبَةَ عَنْ عِبَادِهِ ﴾

«Бәндәләреннән тәүбәне кабул итә торган Зат-тыр». (Шура:25)

Әгәр истигъфар кылса, ярлыканудан мәхрүм калмас. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ اسْتَغْفِرُوا رَبَّكُمْ إِنَّهُ كَانَ غَفَّارًا ﴾

«Раббыгыздан ярлыкауны сорагыз, чөнки Аллаһы Тәгалә бик ярлыкаучыдыр». (Нух: 10)

Әгәр дога кылса, кабул булудан мәхрүм калмас. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ ادْعُونِي أَسْتَجِبْ لَكُمْ ﴾

«Дога кылыгыз, кабул итәрмен». (Гафир: 60)

Алтынчысы да риваять ителде, тиешле урынга сарыф итүне ризыкланса, артыннан килүгә мәхрүм булмас.

﴿ أَنفَقْتُمْ مِنْ شَيْءٍ فَهُوَ يُخْلِفُهُ ﴾

«Бер нәрсәне тиешле урынга сарыф итсәгез, Аллаһы Тәгалә аның урынына бирүчедер». (Сәбә: 39)

عن أبي هريرة ﷺ أن النبي ﷺ قال : "ما من مسلم يدعو بدعاء إلا استجيب له ، فإما أن يعجل له في الدنيا ، وإما أن يدخر له في الآخرة ، وإما أن يكفر عنه من ذوبه بقدر ما دعا ما لم يدع بإثم أو قكيعة رحم".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Һөрәйрәдән риваять итте. Дөреслектә, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйтте: «Дога кылган мөселманның догасы кабул ителми калмас. Я ул кешегә дөньяда бирелер, яки аңа Ахирәттә әзерләнер. Гөнаһка яки туганлыкны өзүгә дога кылмаса, дога кылган кадәр гөнаһысыннан кәффарәт булыр».

Язид әйтте: «Кыямәт көне булганда Аллаһы Тәгалә дөньяда вакытта бәндәнең дога кылып, кабул булмаган һәрбер догасын күрсәтер һәм ул бәндәгә әйтер: «Әй бәндәм, син Миңа шундый көндә дога кылган идең, Мин ул догаңны синең өчен тоттым. Ошбу догаң урынына ошбу савап тыр». Һәм бәндәгә ул савапның һәммәсе бирелер, хәтта бәндә барча догаларының кабул булмавын теләр».

وروى العمان ب بشير ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "الدعاء هو العبادة" ثم قرأ قوله تعالى : "وَقَالَ رَبُّكُمْ ادْعُونِي أَسْتَجِبْ لَكُمْ إِنَّ الَّذِينَ يَسْتَكْبِرُونَ عَنْ عِبَادَتِي سَيَدْخُلُونَ جَهَنَّمَ دَاخِرِينَ".

Ногман бине Бәшир Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Дога гыйбадәттер. Моннан соң бер аятьне укыды: «Раббыгыз әйтте: «Миңа дога кылыгыз, догагызны кабул итәрмен. Минем гыйбадәтемнән зурайган кешеләр тиздән җәһәннәмгә керерләр». (Гафир: 60)

Әбү Зәрр әйтте: «Ашның тәме өчен тоз җиткән кебек яхшылык йөзеннән дога җитәр».

وعن الحسن البصري عن النبي ﷺ أنه قال : "لا يزال العبد بخير ما لم يستعجل" قالوا : وكيف يستعجل يا رسول الله؟ قال : "يقول دعوت الله ودعوت فلم يستجب لي".

Хәсән Басридән риваять ителде, ул әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйткән: «Бәндә ашыкмаса, һәрвакыт изгелек белән булыр». «Әй Рәсүлуллаһ, бәндә ничек ашыга?» – дип сорадылар. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Ул бәндә: «Аллаһыга дога кылдым, ләкин Аллаһы минем сораганымны бирмәде», – дип әйтәдер».

Хәсәннән риваять ителде, ул Әбү Госман Нәһдигә хәлләрен белергә керде, чөнки Әбү Госман авыру иде. Хәсән әйтте: «Әй Әбү Госман, Аллаһы Тәгаләгә догаларыңны кыл. Чөнки авыру кешенең догасы хакындагы сөенечле хәдисләр сиңа ирешкәндер». Хәсән әйтте: «Әбү Госман Аллаһыга хәмед һәм сәна әйтте, Коръәннән аятьләр укыды, Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә салаватлар әйтте. Моннан кулын күтәрде һәм без дә кулларыбызны күтәрдек һәм дога кылды. Без кулларыбызны төшергәч, Әбү Госман әйтте: «Сөенегез, тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә сезнең догаларыгызны кабул итте». Хәсән аңардан: «Аллаһыга шулай ук ант кылып әйтәсеңме?» – дип сорады. Ул: «Әйе, ант итеп әйтәмен. Әгәр син миңа бер сүз сөйләсәң, сиңа ышаныр идем. Ничек инде мин Аллаһының сүзенә ышанмыйм. Хәлбуки, Аллаһы Тәгалә әйтәдер ки:

﴿ ادْعُونِي أَسْتَجِبْ لَكُمْ ﴾

«Догаларыгызны кылыгыз, аларны кабул итәрмен», – дип. (Гафир: 60)

Әбү Госманнан чыккач, Хәсән: «Ул Әбү Госман миннән галимрәк», – диде.

Муса галәйһиссәләм Аллаһы Тәгаләдән сорады: «Әй Раббым, кайсы вакытта дога кылсам, Син кабул итәр идең?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Син минем бәндәм һәм Мин синең Раббың, кайсы вакытта дога

кылсаң, мин аны кабул итәрмен». Муса галәйһиссәләм кат-кат кайтарып, Аллаһыдан сорады. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Миңа син кичнең уртасында дога кыл, дөреслектә, мин кабул итәрмен. Әгәр ул төннең уртасында салым җыючы Миңа дога кылса да, кабул итәрмен».

Хәбәр ителде, Рабига исемле хатын каберлеккә чыкты. Аңа бер кеше очрады һәм: «Минем өчен дога кыл», – дип үтенде. Рабига әйтте: «Аллаһы Тәгалә сиңа рәхмәт кылсын, Аллаһы Тәгаләгә буйсын һәм үзең аңа дога кыл. Чөнки Аллаһы Тәгаләгә дучар кеше дога кылса, кабул итәдер».

Әгъмәш Мәдиктән риваять итте, ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйтте:

من شغله ذكري عن مسألتي أعطيته أفضل ما أعطي السائلين

«Бер кеше Минем зикерем сәбәпле сорарга бушана алмаса, аңа сораучыларга бирә торганнан артыграк бирермен».

Җәгъфәр бине Бәрканнан риваять ителде. Ул Салихтән риваять итте. Ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйтте: «Үзегез Миннән сорыйсыз, әмма күңелегез Миннән алынган, ягъни күңелегез Миндә түгел. Сез бара торган нәрсә батыйльдыр».

Кайбер хәкимнәргә: «Без дога кылсак та, кабул булмый», – дип әйттеләр. Хәлбуки, Аллаһы Тәгалә:

﴿ ادْعُونِي أَسْتَجِبْ لَكُمْ ﴾

«Дога кылыгыз, мин кабул кылырмын», – дип әйткән. (Гафир: 60)

Ул хәким әйтте: «Догагыз кабул булмый, чөнки сездә догаларны күктән тыя торган җиде төрле сәбәп бардыр». Алар: «Ул сәбәпләр ни?» – дип сорадылар. Хәким әйтте: «Ул җиденең берсе, сез Раббыгызны ачуландырдыгыз да, Аның ризалыгын

теләмәдегез. Ягъни сез Аллаһы Тәгаләне ачуландырырлык эшләрне эшләдегез. Һәм шул эшегездән кайтмыйсыз, эшләгән эшегезгә үкенмисез. Икенчесе – без Аллаһының бәндәләре, дип әйтәсез, хәлбуки бәндәләр эшли торганны эшләмисез. Ягъни, бәндә хуҗасы кушканны эшли, кушканнан чыкмыйдыр. Өченчесе – сез Коръән укыйсыз, әмма хәрефләрне сакламыйсыз. Ягъни сез Коръәнне фикерләп һәм олуглап укымыйсыз, Аллаһы Тәгалә Коръәндә боерганны үтәмисез. Дүртенчесе – без Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәте, дип әйтәсез, хәлбуки, Мөхәммәд галәйһисәләмнең сөннәтен эшләмәдегез. Ягъни, сез хәрам һәм шөбһәле ризыкларны ашыйсыз һәм аларны ашаудан кайтмыйсыз. Бишенчесе – Аллаһы Тәгалә каршында дөнья чебен канатына да тормый дип әйтәсез, хәлбуки, тәхкыйк, сез күңелләрегезне дөньяга бөркеткәнсез. Алтынчысы – дөнья бетәчәк дип әйтәсез, ләкин эшләрегез ул дөньяда даим торучылар эше кебектер. Җиденчесе – ахирәт дөньядан яхшырак дип әйтәсез, хәлбуки ахирәтне теләүдә тырышлык кылмыйсыз, дөньяны ахирәттән артык күрәсез.

Фәкыйһ әйтте: «Аллаһыга дога кылучы кешенең эче хәрамнан пакь булырга тиешдер. Чөнки хәрам нәрсә доганы кабул булудан тыядыр».

عن سعد بن أبي وقاص ﷺ أنه قال : يا رسول الله أدعو الله فلا يستجيب لدعائي فقال النبي ﷺ : "يا سعد ، اجتنب الحرام ، فإن كل بطن فيه لقنة من حرام لا يستجاب دعاؤه أربعين يوما".

Сәгыйдтән риваять ителде, ул әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, Аллаһыга дога кылам, ләкин догам кабул ителми». Пәйгамбәр галәйһиссәләм: «Әй Сәгыйд, хәрамнан саклан. Чөнки эченә бер кисәк

хәрам керсә, аның догасы кырык көнгә кадәр кабул ителмәс».

Дога кылган кеше ашыкмаска тиеш. Чөнки кеше Аллаһыга дога кылса, шиксез, Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул итте. Доганың кабул булуы шул вакытта ук беленер, яки шул ук вакытта беленмичә, икенче бер вакытта беленер. Ә догаларның кайберләре ахирәттә генә беленер, дөньяда беленмәс.

Муса галәйһиссәләм Фиргавен белән аның кавеменә бәддога кылды, Һарун галәйһиссәләм «кабул ит» дип сорады. Аллаһы Тәгалә аларга:

﴿ قَدْ أُجِيبَتْ دَعْوَتُكُمَا فَاسْتَقِيمَا ﴾

«Сезнең догагыз кабул ителде, эшегездә булыгыз», – дип вәхи кылды. (Юнус: 89) Һәм Ибен Габбас әйтте: «Дога белән кабул булуы арасында кырык ел үтте».

وروى يزيد الرقاشي ﷺ أن رسول الله ﷺ قال : "إذا احب الله عبدا ضرب وجهه بالبلاء كما تضرب الغريبة من الإبل عن حياض الماء ، فيكون مرحوما في أهل السماء ـ وما من دعوة يدعو بها إلا أعطاه الله تعالى إحدى خصال ثلاث".

Язидтән риваять ителде, Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә бер бәндәне сөйсә, йөзенә бәла белән сугар. Дога кылгач Аллаһы Тәгалә без сөйләгән өч хасыятьнең берсен бирми калмас». Ягъни шул ук вакытта, яки бер микъдар вакыт үткәннән соң, яки ахирәттә бирер.

Кайбер хәкимнәр әйттеләр: «Дүрт кешедә бәхет булмас: беренчесе – Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә салават әйтергә саранланган кеше. Икенчесе – мөәззин азан әйткәндә, аның кебек укып бармаган кеше.

Өченчесе – берәү изгелеккә ярдәм сорап килгәндә, ярдәм итмәгән кеше. Дүртенчесе – намаздан соң үзенә һәм мөэминнәргә дога кылудан гаҗиз булган кешедер».

Габдулла Антакий әйтте: «Күңелнең дәвасы биш нәрсәдәдер: изгеләр белән утыру, Коръән уку, эчне хәрамнан бушату, төнлә уяу тору һәм таң вакытында Аллаһы Тәгаләгә ялвару».

وروى عن اب عباس ﷺ ، عن النبي ﷺ انه قال : "إذا سألتم الله فاسألوه ببطون أكفكم ، ولا تسألوه بظهورهت ، وامسحوا بها وجوهكم".

Ибен Габбас Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Аллаһыдан сораганда кулларыгызның эчләре белән сорагыз, кулларыгызның аркалары белән сорамагыз. Шул кулларыгызның эчләре белән йөзләрегезне сыйпагыз».

## Тәсбих әйтү турында

عن أبي هريرة ﷺ أن النبي ﷺ قال : "كلمتان خفيفتان على اللسان ، ثقلتان في الميزان ، حبيبتان إلى الحمن : سبحان الله وبحمده ، سبحان الله العظيم وبحمده".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Һөрәйрәдән риваять итә. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Ике сүз телгә җиңел һәм үлчәүдә авыр, Аллаһы Тәгаләгә сөеклеләрдер. Алар: «Сүбханәллаһи вә бихамдиһи» һәм «сүбханәллаһил-газыйм вә бихамдиһи».

عن خالد بن عمران أن الي ﷺ خرج على قومه فقال : "خذوا جنتكم" فقالوا : يا رسول الله ، أمن عدو حضر؟ قال : "لا ، بل من النار" ، قالوا : وما جنتنا من النار ؟ ، قال : "سبحان الله ، والحمد لله ، ولا إله إلا الله والله

أكبر ولا حول ولا قوة إلا بالله العلي العظيم فإنهم يأتين يوم القيامة مقدمات ومجبات ومعقبات ، ومن الباقيات الصالحات".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Халид бине Гыймраннан риваять итте, Пәйгамбәр галәйһиссәләм кавеме алдына чыгып: «Калканыгызны алыгыз», – диде. «Әй Рәсүлуллаһ, өстебезгә килгән дошманнанмы?» – дип сорадылар. Рәсүлуллаһ әйтте: «Юк, дошманнан түгел, бәлки тәмугтандыр». «Тәмугтан калканыбыз нәрсә?» – диделәр. Рәсүлуллаһ әйтте:

سبحان الله و الحمد لله و لا إه إلا الله والله

أكبر ولا حول ولا قوة إلا بالله العلي العظيم

«Сүбханәллаһи вәлхамдү лилләһи вә ләә иләәһә илләл-лаһ вәл-лаһү әкбәр, вә ләә хавлә вә ләә куввәтә илләә билләһил-галиййил-газыйм», дип әйтү. Чөнки ул сүзләр Кыямәт көнендә әйтүченең алдыннан, артыннан һәм яныннан килерләр». Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең «алдында килерләр», дип әйткән сүзенең мәгънәсе – ул сүзләр ияләрен җәннәткә илтерләр, «янында» дигән сүзнең мәгънәсе – тәмугтан сакларлар, «арттан да килерләр», дигән сүзнең мәгънәсе – саклаучы булып килерләр.

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Ибен Габбастан риваять итте, ул әйтте: «Исрафил галәйһиссәләм Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә килде һәм әйтте: «Әй Мөхәммәд,

سبحان الله و الحمد لله و لا إه إلا الله والله

أكبر ولا حول ولا قوة إلا بالله العلي العظيم

«Сүбханәллаһи вәл-хамдү лилләһи вә ләә иләәһә илләл-лаһ вәл-лаһү әкбәр, вә ләә хавлә вә ләә куввәтә илләә билләһил-галиййил-газыйм», дип

әйт. Хисабын, авырлыгын Аллаһыдан башка беркем дә белмәс. Аллаһы Үзе генә белә торган нәрсәнең тулысы. Берәү бер мәртәбә шул сүзләрне әйтсә, Аллаһы Тәгалә ул кешегә биш төрле әҗерне язар: Аллаһыны күп зекер кылучылар җөмләсеннән язар. Кичә һәм көндезен Аллаһыны зекер кылучылардан артыграк булыр. Аның өчен җәннәттә бакча булыр. Кипкән агачтан яфраклар коелган кебек аның гөнаһлары коелыр. Һәм Аллаһы Тәгалә аңа рәхмәт карашы белән карар. Аллаһы Тәгалә берәүгә рәхмәт карашы белән караса, аны газап кылмас».

Ибен Габбастан риваять ителде, ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә Гарешне яраткан вакытта күтәрүчеләргә ул Гарешне күтәрергә кушты. Ләкин Гареш аларга авыр булды. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Сүбханәллаһ», дип әйтегез». Фәрештәләр «сүбханнәллаһ», дип әйттеләр һәм аларга күтәрү җиңел булды. Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәләмне яратканга кадәр гомер буена «сүбханәллаһ» дип әйтә торган булдылар. Адәм галәйһиссәләм төчкергәч, Аллаһы Тәгалә аңа «әлхамдүлилләһ», дип әйтүне илһам кылды. Аллаһы Тәгалә: «Аллаһы сиңа рәхмәт кылсын, шуның өчен Мин сине яраттым», – дип җавап бирде. Фәрештәләр моны ишетеп: «Бу хөрмәтле һәм ачык булган икенче сүздер. Безгә ул сүздән гафил булу тиеш түгел», – дип «әлхамдүллиләһ» дигән сүзне «сүбханәллаһ»ка куштылар. Һәм Нух галәйһиссәләм пәйгамбәр булып җибәрелгәнгә кадәр, алар бөтен гомер буена «сүбханәллаһи вә бихамдиһи» дип әйтер булдылар. Потларны хөрмәтле итеп тотучыларның иң беренчеләре – Нух кавемедер. Аллаһы Тәгалә Нухка халыкка «лә иләһә илләллаһү» кәлимәсе белән боерырга вәхи кылды. Әгәр үтәсәләр, Аллаһы Тәгалә

алардан разый булыр. Фәрештәләр моны ишетеп: «Бу өченче яхшы сүздер. Безгә ул сүздән гафил булу тиеш түгел», – диделәр. Һәм бу кәлимәне әүвәлге ике сүзгә куштылар. Ибраһим галәйһиссәләм пәйгамбәр итеп җибәрелгәнчегә кадәр бу өч сүзне әйтәләр иде. Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәләмгә корбан чалу белән боерды, соңыннан корбанын тәкәгә алыштырды. Ибраһим галәйһиссәләм тәкәне күргәч, шатлыгыннан «аллаһү әкбәр», дип әйтте. Фәрештәләр әйттеләр: «Бу яхшы сүзләрнең дүртенчеседер». Аны да югарыда зекер ителгән сүзләргә куштылар һәм әйтә башладылар». Җәбраил галәйһиссәләм бу вакыйгаларны Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә сөйләгәч, ул гаҗәпләнеп: «Ләә хәвлә вә ләә куввәтә иллә билләһил-галиййил-газыйм», – диде. Җәбраил галәйһиссәләм әйтте: «Бу сүзне дә югарыда зекер ителгән сүзләргә куш».

Ибен Мәсгудтән риваять ителде, ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә ризыкларыгызны бүлгән сыман халыкларыгызны да бүлде. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә малны сөйгән кешесенә дә, сөймәгәнгә дә бирә. Ләкин иманны сөймәгән кешесенә бирми. Әгәр Аллаһы Тәгалә бер бәндәне сөйсә, аңа иман бирә. Берәү үзенә мал бирелүен уйласа, яки дошман белән сугышудан курыкса, яки төн уртасында уяу торудан курыкса,

لا إله إلا الله الله أكبر و سبحان الله والحمد لله

«ләә иләһә илләл-лаһ вә аллаһү әкбәр вә сүбханәллаһи вәл-хамдүлилләһи» дигән сүзләрне күбрәк кабатласын».

وروى أبو هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "لأن أقول : سبحان الله ، والحمد لله ، ولا إله إلا الله ، والله اكبر أحب إلي مما طلعت عليه الشمس".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителә, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйтте: «Минем «сүбханәллаһи вәлхамдү лилләһи вә ләә иләәһә илләл-лаһи вәл-лаһү әкбәр» дип әйтүем, минем өчен аның хозурына кояш чыккан нәрсәләрдән сөеклерәк».

وروى سمرة بن جندب عن النبي ﷺ أنه قال : "أفضل الكلام أربع : سبحان الله ، والحمد لله ، ولا إله إلا الله والله اكبر ، ولا يضرك بأيهن بدأت".

Сүмратә бине Җүндәб Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Сүзләрнең артыграгы дүрттер: сүбханаллаһ, вәл-хамдү лилләһ, вә лә иләһә илләллаһ, вәл-лаһү әкбәр. Кайсы белән башласаң да сиңа зарар кылмас».

Ибен Мәсгудтән риваять ителде, ул берәр нәрсә сорый торган кешене ишетсә әйтә иде:

﴿ مَنْ ذَا الَّذِي يُقْرِضُ اللَّهَ قَرْضًا حَسَنًا ﴾

«Берәү Аллаһыга бурычка биргән кебек яхшы эшләрне, изге гамәлләрне Аллаһы ризалыгы өчен генә кылса, Аллаһы ул мөэминнең әҗерен күп мәртәбә арттырыр». (Бәкара: 245) Габдулла бине Мәсгуд әйтте:

« سبحان الله والحمد لله ولا إله إلا الله والله أكبر », ягъни «Сүбханәллаһи вәл-хамдү лилләһи вә ләә иләәһә илләл-лаһ вәл-лаһү әкбәр — бу бурычларның күркәмрәгедер».

Фәкыйһ әйтте: «Әгәр кеше фәкыйрь булса, аның садака бирерлек нәрсәсе булмаса, ошбу сүзләрне әйтсен. Һәм ул кеше садака әҗеренә ирешер».

Риваять ителде, Пәйгамбәр галәйһиссәләм сәхабәләрен садака бирергә өндәде. Шуннан соң кешеләр садака бирергә булдылар. Әбү Әмәмә Рәсүлуллаһның алдында утыра иде, ул ике иренен

селкетә иде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм: «Син ике иреңеңне селкетәсең, ул вакытта ни әйтәсең?» – дип сорады. Әбү Әмәмә әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, кешеләрнең садака биргәннәрен күрәм, ләкин минем садака бирерлек бер нәрсәм юк, үз-үземә әйтәм: « سبحان الله والحمد لله ولا إله إلا الله والله أكبر». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Әбү Әмәмә, бу сүзләр мескеннәргә садака бирә торган бер савыт алтыныңнан изгерәктер».

## Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә салават әйтүнең әҗере

عن محمد بن عبد الرحمن أن النبي ﷺ قال : "ما منكم من احد سلم علي إذا مت إلا جاءني جبريل فقال جبريل : يا محمد هذا فلان ب لان يقرئك السلام ، فأقول : وعليه السلام ورحمة الله وبركاته".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Мөхәммәд бине Габдрахманнан риваять итте, дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Мин вафат булганнан соң миңа сәлам укыган кеше булса, Җәбраил галәйһиссәләм миңа килеп: «Фәлән кеше сиңа сәлам укый», – дип әйтер. Мин дә: «Аңа сәлам, Аллаһының рәхмәте һәм бәрәкәте булсын», – дип әйтермен».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Сәгыйд бине әл-Мүсәйибтән риваять итте, ул әйтте: «Гомәр әйтте: «Җир белән күк арасында дога тукталып торыр. Пәйгамбәргә салават әйткәнгә кадәр ул догадан һичберсе күтәрелмәс».

عن أنس ب مالك ﷺ أن رسول الله ﷺ صعد المنبر فقال : "آمين" ثم صعد فقال : "آمين" ثم صعد فقال : "آمين" ثم استوى فجلس ، فقال به معاذ بن جبل :

صعدت فأمنت ثلاثا ، قال : "أتاني جبريل فقال : يا محمد م أدرك مضا فلم يغفر له فمات فدخل الار فأبعده الله قلت : آمين ، وقال : من أدرك أبويه أو أحدهما فلم يبرهما فماتفدخل النار فأبعده الله ، قلت : آمين وقال : ومن ذكرت عنده فلم يصل عليك فمات فدخل النار فأبعده الله قلت : آمين".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әнәс бине Мәликтән риваять итте, Рәсүлуллаһ минбәргә менеп «әмин», диде. Янә менде дә, «әмин», диде. Соңыннан яңадан менде һәм «әмин», диде. Моннан соң минбәрдә утырды. Мөгәз бине Җәбәл: «Әй Рәсүлуллаһ, мендең дә өч мәртәбә «әмин» дидең?» – дип әйтте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Миңа Җәбраил килеп: «Әй Мөхәммәд, берәү Рамазанга җитсә һәм гөнаһлары ярлыканмыйча вафат булса, Аллаһы Тәгалә аны ерак кылсын», – диде. Мин: «Әмин», – дидем. «Берәү ата-анасына, яки берсенә генә ирешеп, аларга изгелек кылмыйча вафат булса һәм тәмугка керсә, аны да Аллаһы Тәгалә ерак кылсын», – дип әйтте. Мин: «Әмин», – дидем. Ул әйтте: «Берәүнең алдында сине искә төшерсәләр һәм ул сиңа салават әйтмичә үлсә һәм тәмугка керсә, аны да Аллаһы Тәгалә ерак кылсын». Мин: «Әмин», – дидем».

عن جابر بن عبد الله ﷺ ع النبي ﷺ قال : "من صلى علي في اليوم مائة مرة ، قضى الله له مائة حاجة ، سبعين منها في الآخة وثلاثين في الديا".

Җәбир бине Габдулладан риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Берәү һәр көн йөз мәртәбә салават әйтсә, Аллаһы Тәгалә аның йөз йомышын үтәр. Утызын дөньяда һәм җитмешен ахирәттә».

عن سعيد بن عمير الأنصاري وكا بديا ، أي قاتل يوم بدر ، قال : قال رسول الله ﷺ : "م صلى علي من أمتي مخلصا من قلبه صلاة واحدة صلى الله عليه عشر صلوات ورفع له عشر درجات ، ةمحا عنه عشر شيئات".

Сәгыйд бине Гамирдән риваять ителде (ул Бәдер сугышында үтерелде), ул әйтте: «Рәсүлуллаһ әйтте: «Берәү чын күңеленнән миңа бер мәртәбә салават әйтсә, Аллаһы Тәгалә аңа ун рәхмәт әйтер, аны ун дәрәҗәгә күтәрер һәм аннан ун явызлыкны юар».

Фәкыйһ атамнан ишеттем, дип әйтте, ул сөйли иде: «Суфьян әс-Сәүри таваф кылып йөргәндә бер кешене күрде аягын күтәрсә дә, төшерсә дә Пәйгамбәребез галәйһиссәләмгә салават укый иде. Суфьян әйтте: «Мин аңа әйттем: «Әй кеше, син тәсбих һәм тәһлилне ташладың, Пәйгамбәр галәйһисәләмгә салават белән юнәлдең. Ошбу хакта синдә дәлил填бармы?» Ул кеше әйтте: «Рәхмәт яугыры, син кем?» Мин әйттем: «Мин Суфьян әс-Сәүри». Ул әйтте: «Заманаң халкы арасында син ялгыз булмаса идең, үз хәлемне сиңа сөйләмәс идем, сине серемә төшендермәс идем». Моннан соң миңа әйтте: «Атам белән Аллаһының йортына хаҗ кылганыбыз хәлдә чыккан идек, хәтта тукталуларның берсендә атам сырхауланды. Шул тукталуда атамны дәваларга калдым. Бер кичтә башы очында торган вакытта атам вафат булды һәм аның йөзе каралды». Мин: «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун», – дип, йөзенә изарны капладым. Күземне йокы басты һәм мин йокыга киттем. Шул вакыт төшемдә бер кешене күрдем. Аның кебек күркәм йөзле һәм киемнәре пакь булган кешене күргәнем юк. Яныннан күркәм, хуш исләр таралып тора иде. Берен басып, икенчесен атлап килә, хәтта атам янына якын килде, йөзеннән

изарны ачты, кулын атамның йөзенә куйды. Атамның йөзе агарды, моннан соң кайтып китте. Мин ул кешенең киеменә ябыштым һәм: «Әй Аллаһының бәндәсе, чит җирдә атама мәрхәмәт кылучы, кем син?» – дип сорадым. Ул әйтте: «Мине танымыйсыңмы, мин Коръән иясе Мөхәммәд бине Габдулла. Сак бул, атаң үз нәфесенә зарарлы иде. Шулай булса да, миңа күп салаватлар әйтә иде. Башына син күргән нәрсә төшкәч, миннән ярдәм сорады. Мин, миңа күп салават әйтүче кеше өчен, ярдәмчемен». Уянып киттем, шул вакытта карасам, атамның йөзе агарган иде».

وروى عن عمرو بن دينار ، عن أبي جعفر ، إن النبي ﷺ قال : "من نسي الصلاة علي ، فقد أخطأ طريق الجنة".

Гомәр бине Динәрдән, ул Әбү Җәгъфәрдән риваять итте. Дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Берәү миңа салават әйтүне онытса, җәннәт юлыннан ялгышты».

وعن أبي بريدة ، عن أبيه ، عن النبي ﷺ أنه قال : "أربع من الجفاء : أن يبول الرجل وهو قائم وأن يمسح جبهته قبل أن يفرغ من الصلاة ، وأن يسمع الداء فلا يشهد مثل ما يشهد المؤذن ، وأن أذكرعنده فلا يصلي علي".

Әбү Бүридәдән, ул атасыннан риваять итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Дүрт төрле нәрсә золымнандыр: аяк хозурында булган хәлдә бәвел кылу; намаздан бушанмастан элек маңгаен сыйпау; азан ишетеп тә, мөэззин «әшһәдү» дип әйткәндә аның артыннан кабатламау; аның алдында мин искә төшерелсәм, миңа салават әйтмәве».

وروى أبو هريرة ﷺ ع النبي ﷺ أنه قال : "صلوا علي ، فإن الصلاة علي زكاة لكم ، زاسألوا الله لي الوسيلة" قالوا : وما الوسيلة ا رسول الله ؟ قال : "أعلى درجة في الجنة ، لا ياها إلا واحد ، وأنا أن أكون أنا هو".

Әбү Һөрәйрә Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Минем өчен салават әйтегез, чөнки минем өчен салават әйтү сезнең өчен арынудыр. Аллаһыдан минем өчен вәсиләне сорагыз». Әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, вәсилә нәрсә соң ул?» Ул әйтте: «Җәннәттә иң югары дәрәҗәдер. Ул дәрәҗәгә бер кешедән башка бер кем дә ирешмәс. Шул бер кеше мин үзем булырмын, дип өметләнәм».

Фәкыйһ әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләмнең «зәкәтүн ләкүм» (сезнең өчен арыну) дигән сүзнең мәгънәсе – сезнең өчен пакьлек һәм гөнаһларыгызның ярлыкануыдыр. Салават өчен шәфәгать өмет ителүдән башка савап булмаса да, акыллы кешегә салават әйтүдән гафил булмаска кирәк. Салават әйтүдә гөнаһларның ярлыкануы, Аллаһы Тәгалә тарафыннан рәхмәт бардыр».

وروى عن أنس بن مالك ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "من صلى علي صلاة واحدة صلى الله عليه عشر صلوات ، وحط عنه عشر خطيئات".

Әнәс бине Мәлик Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Берәү миңа бер генә салават әйтсә дә, аның өчен ун рәхмәт бирелер һәм аңардан ун гөнаһ төшерелер».

Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә салават әйтүнең башка гыйбадәтләрдән артык икәнен белергә теләсәң, Аллаһы Тәгаләнең сүзе хакында уйла:

﴿ إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَاأَيُّهَا

﴿الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا﴾

«Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә һәм Аның фәрештәләре Пәйгамбәргә салават әйтәләр. Әй иман китергән бәндәләр, Пәйгамбәргә салават әйтегез һәм сәлам укыгыз». (Әхзәб: 56)

Башка гыйбадәтләрдә дә Аллаһы Тәгалә бәндәләренә салават белән боерды. Әмма Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә Аллаһы Тәгалә үзе беренче салават әйтте һәм фәрештәләргә салават әйтү белән боерды. Моннан соң мөэминнәргә Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә салават әйтергә әмер итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә салават әйтү гыйбадәтләрнең иң артыгы икәнлеге ошбу дәлил белән исбатланадыр.

وروى عن عبد الرحمن ب أبي ليلي ، عن كعب ب عجرة قال : قلنا : يا رسول الله كيف نصلي عليك ؟ قال : "قولوا اللهم صلي على محمد وعلى آل محمد وبارك على محمد و على آل محمد كما صليت و باركت على إبراهيم و علي آل إبراهبم إنك حميد مجيد".

Габдрахман бине Әбү Ләйләдән, ул Кәгъб бине Гуҗрәдән риваять итте. Ул әйтте: «Без: «Әй Рәсүлуллаһ, сиңа ничек салават әйтик?» – дип сорадык. Ул әйтте:

اللهم صلي على محمد وعلى آل محمد وبارك على محمد و على آل محمد كما صليت و باركت على إبراهيم و على آل إبراهبم إنك حميد مجيد

«Аллаһүммә салли галә мүхаммәдин вә галә әли мүхаммәд вә бәрик галә мүхаммәдин вә галә әли мүхаммәд кәмә салләйтә вә бәрактә галә ибраһимә вә галә әли ибраһимә, иннәкә хамидүм мәҗид», дип әйтегез».

Кайберләре әйттеләр: Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә салават – اللهم صليت أنت وملائكتك على محمد.

«Аллаһүммә салләйтә әнтә вә мәләикәтүкә галә мүхаммәд»,– дип әйтүдер.

Ә кайберләре әйттеләр: «Аңа шулай итеп салават әйтү тиештер:

اللهم إني أشهدك و أشهد ملائكتك إني أصلى على محمد

«Аллаһүммә инни үшһидүкә вә үшһидү мәләикәтәкә әнни усалли галә мүхаммәд».

Галимнәрнең кайберләре болай әйтергә тиеш диделәр:

اللهم صل على محمد و على آل محمد النبي الأمي وعلى

آله وأصحابه كلما ذكرك الذاكرون وغفل عن ذكره الغافلين

«Аллаһүммә салли галә мүхаммәдин вә галә әли мүхаммәд, ән-нәбиййил-үммиййи вә галә әлиһи вә әсхабиһи күлләмә зәкәракәз-зәкирунә вә гафәлә ган зикриһил-гафилинә».

## «Лә иләһә илләллаһ» кәлимәсен әйтү

عن عبد الله بن عمرة بن العاص ﵁ قال : قال رسول الله ﷺ : "يؤتى بالرجل يوم القيامة إلى الميزان ، فيخرج له تسعة وتسعون سجلا ، كل سجل منها مد البصر ، فيها خطاياه وذنوبه ، فيوضع في كفة الميزان ، ثم يخرج قرطاس مثل أنملة فيها شهادة أن لا إله إلا الله وأن محمدا عبده ورسوله ، فيوضع في الكفة الأخرى فيرجح عن حطاياه".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Гамрү бине әл-Гастан риваять итте, ул әйтте, Рәсүлуллаһ әйтте: «Кыямәт көнендә кешене үлчәү янына китерерләр, аның

туксан тугыз дәфтәре чыгарылыр, һәрбер дәфтәре күз карашы кадәр озын булыр. Ул дәфтәрләрдә гөнаһлары һәм хаталары язылгандыр. Аны үлчәүнең бер табагына куярлар. Моннан соң бармак башы кадәр кәгазь чыгарылыр, ул кәгазьдә шәһадәт кәлимәсе булыр. Аны икенче табакка куярлар. Һәм ул кечкенә кәгазь гөнаһлар язылган олуг дәфтәрләрдән артык килер».

عن المطلب بن حنطب ، أن النبي ﷺ قال : "أفضل ما قلت أنا والنبيون من قبل لا إله إلا الله"

Муталиб бине Хәнтабтан риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Мин һәм миннән элек килгән пәйгамбәрләрнең әйтә торганының иң артыграгы лә иләһә илләллаһ кәлимәседер».

عن أنس بن مالك ﷺ قال : قال رسول الله ﷺ : "نزل جبريل عليه السلام وهو يتلو هذه الآية : ﴿ يَوْمَ تُبَدَّلُ الْأَرْضُ غَيْرَ الْأَرْضِ وَالسَّمَاوَاتُ وَبَرَزُوا لِلَّهِ الْوَاحِدِ الْقَهَّارِ ﴾ قال النبي ﷺ : "يا جبريل كيف يكون الناس يوم القيامة ؟" قال : يا محمد ، يكونون على أرض بيضاء ، لم يعمل عليها ذنب قط ، فإذا زفرت جهنم زفة تتعلق الملائكة بالعرش ، ويقول كل ملك : يا رب لا أسألك إلا نفسي ، وتكون الجبال كالعهن المفوش . قال : با جبريل وما العهن الكمفوش ؟ قال : يعني الصوف المندوف ، وتذوب الجبال من مخافة جهنم يا محمد ، فيجاء بجهم يوم القيامة ، وهي تزفر زفرة عليها سبعون ألف زمام على كل زمام سبعون ألف ملك ، حتى توقف بين يدي الله عز وجل ، فيقول لها : يا جهم ، تكلمي ، فتقول : لا إله إلا الله ، وعزتك وعصمتك لأتقمن لك اليوم ممن أكل رزقك ، وعبد غيرك ، لا يجاوزي إلا من عنده جواز .

قال النبي ﷺ : "يا جبريل ، وما الجواز يوم القيامة ؟" ، قال : أبشر يا محمد ، فإن أمتك يوم القيامة على الجواز ، ألا من شهد أنه لا إله غلا الله فقد جاز من جسر جهنم ، فقال النبي ﷺ : "الحمد لله الذي ألهم أمتي شهادة أن لا إله إلا الله".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде. Рәсүлуллаһ әйтте: «Миңа Җәбраил галәйһиссәләм иңде, ул: «Бу җир башка җиргә һәм башка күкләргә алмашынган көндә, каһәр кылучы бер Аллаһыга чыккан көндә», – дип аять укый иде. (Ибраһим: 48) Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Җәбраил, Кыямәт көнендә кешеләр ничек булачак?» Җәбраил галәйһиссәләм әйтте: «Әй Мөхәммәд, өстендә һич бер гөнаһ кылынмаган ак җир өстендә булырлар. Әгәр җәһәннәм бер сызгырса, фәрештәләр Гарешкә ябышыр, һәр фәрештә: «Үземнән башканы сорамыйм», – дип әйтер. Таулар тетелгән йон кебек булыр». Рәсүлуллаһ әйтте: «Әй Җәбраил, «гаһнил-мәнфүш» нәрсә ул?» Җәбраил: «Тетелгән йон. Җәһәннәмнән куркып тау эреп бетәр. Әй Мөхәммәд, Кыямәт көнендә җәһәннәм китерелер, ул җәһәннәм бер сызгыру белән сызгырыр. Йөгәннән тотучы җитмеш мең фәрештә булыр, ул җәһәннәмне Аллаһы Тәгалә каршында туктатырлар. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй җәһәннәм сөйлә». Җәһәннәм әйтер: «Аллаһыдан башка гыйбадәт кылынырга лаек зат һич юк, Синең олуглыгың белән ант итеп әйтәмен, Синең ризыгыңны ашап, Синнән башкага гыйбадәт кылган кешедән, шиксез, үч алырмын, үтәргә хакы булган кеше генә миннән үтәр». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Җәбраил, Кыямәт көнендә үтү нәрсә ул?» Җәбраил әйтте: «Сөен, әй Мөхәммәд! Чөнки синең өммәтең Кыямәт көнендә үтү хозурындадыр. «Лә иләһә илләллаһ» дип шәһадәт биргән кеше, тәхкыйк,

җәһәннәм күпереннән үтте». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Лә иләһә илләллаһ» дип шәһадәт бирүне минем өммәтемә илһам кылган зат Аллаһы Тәгаләгә хәмедләр булсын».

Гата бине Әбү Рубәхәдән риваять ителде, ул әйтте:

﴿ غَافِرِ الذَّنْبِ وَقَابِلِ التَّوْبِ شَدِيدِ الْعِقَابِ ﴾

«Гөнаһларны ярлыкаучы, тәүбәне кабул итүче һәм газабы каты булучы» (Гафир:3) дигән аятьнең тәфсире турында Ибен Габбастан сорадым». Ибен Габбас әйтте: «Лә иләһә илләллаһ» дип әйткән кешенең гөнаһысын ярлыкаучы. «Лә иләһә ил-ләллаһ» дип әйткән кешенең тәүбәсен кабул итүче. «Лә иләһә илләллаһ» дип әйтмәгән кешене каты газап кылучыдыр».

Фәкыйһ әйтте: «Һәр адәм өчен «лә иләһә илләллаһ» сүзен күп әйтү, төн уртасында һәм иртән Аллаһыдан дөньядан иманлы китүен сорау ваҗибтер. Бу сүзне, ягъни «лә иләһә илләллаһ» дип әйтүче кеше үзен гөнаһлардан сакларга тиеш. Чөнки бик күп кеше бу сүзне әйтә дә, начар гамәлләре сәбәпле гомеренең ахырында дөньядан имансыз китә (мондый хәлдән Аллаһы Тәгаләгә сыгынабыз). Кайсы кайгы моннан олуграк?» Адәмнең исеме бөтен гомеренә мөселманнардан булып, исеме кәферләрдән булган хәлдә Кыямәт көнендә кубарылыр. Бу инде бөтен хәсрәтләрнең хәсрәте! Чиркәүдән яки тәмуг йортыннан чыгып, җәһәннәмгә кергән кешегә кайгы түгел. Мәгәр хәсрәт мәчеттән чыгып тәмугка ыргытылгангадыр. Боларның барчасы начар гамәлләр кылу сәбәпле, яшерен урыннарда хәрам эшләргә катнаштыра. Кайберләренә башка кешеләрнең малы кулына төшеп, ул малны мин сарыф итим, соңыннан иясенә кайтарырмын, яки бәхил

булыр дип, кеше малын сарыф итә, ләкин мал иясен риза кылмастан әүвәл бу кеше вафат була. Шулай ук шундый кешеләр бардыр, хатыны белән ике арага хәрамлык төшә. Ничек мин ул хатынны ташлыйм, безнең балаларыбыз бар, дип ошбу хәрамлык хозурына даимчылык итә. Һәм ул шул хәлдә булганда аңа үлем килә. Күп вакытта шуның сәбәпле иман чыга. Әй кардәш, уйла. Үлем килмәстән элек эшеңне төзәтергә тырыш. Чөнки син үлемнең кайчан киләсен белмисең. Бел, гомер аздыр, кайгы озындыр. «Лә иләһә илләллаһ» дигән сүзне күп әйтү сиңа лязем булсын».

Хәсән Басри әйтте: «Лә иләһә илләллаһ» – җәннәтне сатып ала торган акчадыр».

وروى أنس ب مالك ﷺ ع النبي ﷺ أنه قسل به : يا رسول الله هل للجنة ثمن ؟ ، قال : "نعم لا إله إلا الله".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде, Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән: «Әй Рәсүлуллаһ, җәннәт өчен акча бармы?» – дип сорадылар. Пәйгамбәр әйтте: «Әйе, аның акчасы «лә иләһә илләллаһ» сүзедер».

عن أبي هريرة ﷺ قال : قلت يا رسول الله من أسبق الناس إلى شفاعتك ؟ ، اقل : "من قال لا إله إلا الله خالصا من نفسه".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде, ул әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, иң алдан адәмнәрдән синең шәфәгатеңә кем лаек?» Ул әйтте: «Чын күңелдән «лә иләһә илләллаһ» дип әйткән кеше минем шәфәгатемә лаек».

Аллаһы Тәгаләнең

﴿ رُبَمَا يَوَدُّ الَّذِينَ كَفَرُوا لَوْ كَانُوا مُسْلِمِينَ ﴾

«Кәферләрнең күбесе, эх, мөселманнар булсалар, дип теләрләр» (Хиҗер:2), дигән аятнең

тәфсирендә Мөҗәһиттән риваять ителде. Мөҗәһит әйтте: «Лә иләһә илләллаһ» дип әйткән кеше уттан чыгарылгач, мөшрикләр: «Эх, без дә мөселманнар булган булсабызчы», – дип әйтерләр».

Аллаһы Тәгаләнең ошбу сүзе турында Гатадан риваять ителде:

﴿ مَنْ جَاءَ بِالْحَسَنَةِ فَلَهُ خَيْرٌ مِنْهَا ﴾

«Берәү изгелек китерсә, аңа кылган изгелегеннән изгерәк әҗер булыр» (Нәмел: 89) ягъни, берәү «лә иләһә илләллаһ» дип әйтсә, аңа җәннәт булыр. Ләкин явызлыкны китерсә, ягъни ахирәткә ширек кылуны алып барса, йөзтүбән тәмугка ташланыр.

Хәсән Басри Аллаһы Тәгаләнең:

﴿ هَلْ جَزَاءُ الْإِحْسَانِ إِلَّا الْإِحْسَانُ ﴾

«Изгелекнең җәзасы изгелек кенәдер». (Рахмән: 60) дигән аятенең тәфсирендә әйтте: «Лә иләһә илләллаһ» дип әйткән кешенең җәзасы җәннәт кенәдер».

وعن ابن عباس ﷺ أن جبريل عليه السلام جاء إلى النبي ﷺ يوما فقال : "يا محمد ، إن الرب يقرئك السلام ، وهو يقول : مالي أراك مغموما حزيا ؟ وهو أعلم به فقال : "يا جبريل قد طال تفكيري في أمر أمتي يوم القيامة" قال : يا محمد في أمر أهل الكفر أم في أمر أهل الإسلام؟ ، قال : "يا جبريل لابل في أمر أهل لا إله إلا الله" ، قال : فأخذ بيده حتى أقامه على مقبره بني سلمه ، فضرب بجناحه الأيمن على قبر مت فقال : قم بإذن الله ، فقام الرجل مبيض الوجه وهو يقول : لا إله إلا الله ، محمد رسول الله ، الحمد لله رب العالمين ، فقال له جبريل : عد، فعاد كما كان ، ثم ضرب بجناحه الأيسر على قبر ميت

فقال : قم بلإذن الله ، فخرج رجل مسود الوجه ، أزرق العين ، وهو يقول : واحسرتاه واندامتاه واسوأتاه ، فقال له : عد فعاد كما كان ، ثم قال جبريل : هكذا يبعثون يوم القيامة على ما ماتوا عليه".

Ибен Габбастан риваять ителде: «Бер көнне Пәйгамбәр галәйһиссәләм янына Җәбраил галәйһиссәләм килде һәм әйтте: «Әй Мөхәммәд, дәреслектә, Аллаһы Тәгалә сиңа сәлам укый. Ул әйтә: «Ни булды, Мин сине кайгылы һәм хәсрәтле күрәмен? Хәлбуки, Аллаһы Тәгалә беләдер». Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: «Әй Җәбраил, Кыямәт көнендә өммәтемнең хәле ничек булыр, дип озак уйлыймын». Әйтте: «Әй Мөхәммәд, кәферләр хакында яки мөселманнар хакында уйлыйсыңмы?» Әйтте: «Әй Җәбраил, «лә иләһә илләллаһ» дип әйткән халык хакында уйлыйм, кәферләр турында түгел». Рәсүлуллаһ әйтте: «Җәбраил минем кулымнан тотып, Бәни Сәләмә кабиләсенең каберлегенә илтеп куйды. Бер мәетнең каберенә уң канаты белән сукты һәм әйтте: «Аллаһының рөхсәте белән тор». Йөзе агарган бер кеше торды һәм: «Лә иләһә илләллаһ, мүхәммәд рәсүлуллаһ әлхәмдүлилләһи раббил-галәмин», – диде. Җәбраил аңа әйтте: «Кайт». Ничек булды шул рәвештә кайтты. Моннан соң сул канаты белән янә мәетнең бер каберенә сукты һәм әйтте: «Аллаһының рөхсәте белән тор». Күзләре ямьсез, кара йөзле бер кеше чыкты. Ул кеше әйтте: «Әй ни хәсрәт, әй ни үкенеч, әй ни явызлык!» Җәбраил әйтте: «Кайт». Ул кеше әүвәлге хәленә кайтты. Җәбраил әйтте: «Менә күрдең, ничек вафат булган булса, Кыямәт көнендә дә шулай ук кубарылыр».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "لقنوا موتاكم لا إله إلا الله ، فإنها تهدم الذنوب هدما" . قالوا : يا رسول الله ، فإن قالها في حياته قال : "هي أهدم واهدم" .

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул әйтте: «Мәетләрегезгә «лә иләһә илләллаһ» дип әйттерегез. Чөнки «лә иләһә илләллаһ» гөнаһларны ватадыр». «Әй Рәсүлуллаһ, әгәр «лә иләһә илләллаһ» кәлимәсен тереклегендә әйтсә, ничек?» – дип сорадык. Әйтте: «Ул бигрәк тә ватучы».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "احضروا موتاكم فلقنوهم لا إله إلا الله ، وبشروهم بالجنة ، فإن الحكيم العليم من الرجال والنساء يحار عند ذلك المصرع ، وإن إبليس عدو الله أقرب ما يكون من العبد في ذلك الموطن ، عند فراق الدنيا الأحبة ولا تقنطوهم ، فإن الكرب شديد والأمر عظير ، والذي نفس محمد بيده لمعالجة ملك الموت أشد من ألف ضريع بالشيف" .

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул әйтте: «Мәет булачакларыгыз янында булыгыз. Аларга «лә иләһә илләллаһ» кәлимәсен әйтеп өйрәтеп торыгыз һәм аларны җәннәт белән сөендерегез. Чөнки ирләрдән һәм хатыннардан булган һәрбер белүче һәм изге булучы кеше, бу актык вакытта хайран була. Һәм дөреслектә, Аллаһының дошманы Иблис бәндәнең дөньядан аерылган һәм дусларын калдырган вакытта бигрәк тә якын була. Ул мәет булачакларның өметен өзмәгез. Чөнки кайгы каты һәм эш олугдыр. Мөхәммәднең үзе Аның кодрәт кулы астындагы Зат белән ант итәм, Газраилнең дәвалавы кылыч белән мең мәртәбә сугудан катырактыр».

Риваять ителде, Бәни Исраилдән бер кеше адәмнәрнең иң күп гыйбадәт кылучылардан булды,

икенче кеше шул ук заманда кешеләрнең иң гөнаһлыларыннан булды. Гыйбадәт кылучы үлде. Муса галәйһиссәләмгә: «Ул гыйбадәт кылучы тәмугтадыр», – диделәр. Гөнаһлы кеше дә вафат булды. Муса галәйһиссәләмгә: «Ул фәҗир җәннәт әһеленнән», – дип әйтелде. Муса галәйһиссәләм гыйбадәт кылучы кешенең хатынына килеп: «Аның гамәле нәрсә иде?» – дип сорады. Хатыны: «Кешеләрнең иң гыйбадәт кылучыларыннан иде, сезгә дә яшерен түгел», – диде. Муса галәйһиссәләм сорады: «Тагын гамәле ни иде?» Хатын әйтте: «Түшәгенә ятса: «Әгәр Муса шәригать, дип китергән нәрсә хак булса, безгә ни сөенеч!» – дип әйтә иде. Гөнаһлының хатынына килеп, әйтте: «Аның гамәле нәрсә булды?» Хатыны әйтте: «Сезгә дә яшерен түгел, кешеләрнең иң фасикъларыннан булды». Муса галәйһиссәләм: «Тагы гамәле ни иде?» – дип сорады. Хатыны әйтте: «Түшәгенә ятса: «Лә иләһә илләллаһ һәм Муса китергән шәригать бәрабәренә әлхәмдүлилләһ», – дип әйтә иде».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "من قال لا إله إلا الله خرج من فيه طير أخضر ، له جناحان أبيضان مكللان بالدر والياقوت ، فعرج إلى السماء ، فيسمع له دوي تحت العرش كدوي النحل ، فيقال به : اسكن ، فيقال : لا ، حتى يغفر لصاحبي ، فيغفر لقائله ، ثم يجعل بعدها لذلك الطائر سبعون لسانا يستغفر لصاحبه إلى يوم القيامة ، فإذا كان يوم القيامة جاء ذلك الطائر فإخذ بيد صاحبه حتى يكةن قائده ودليله إلى الجنة" .

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителә, ул әйтте: «Кем дә кем «лә иләһә илләллаһ» дип әйтсә, аның авызыннан яшел кош чыгар, аның энҗе һәм якут белән тукылган ике канаты булыр, ул кош күккә

ашар. Аның бал корты кебек тавышы Гареш астында ишетелер. Аңа тукта, дип әйтелер. Ул: «Минем хуҗам ярлыканганга кадәр туктамам», – дип җавап бирер. Бәс ул сүзне әйтүче кеше ярлыканыр. Моннан соң ул кошка җитмеш тел яратылыр. Ул кош Кыямәт көненә кадәр үзенең иясенә ярлыкау белән дога кылыр. Кыямәт көне булгач, бу кош килеп иясенең кулыннан тотар. Хәтта иясенә җәннәткә кадәр җитәкче булыр».

Риваять ителде: Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә Фиргавенне суга батырып, Муса галәйһиссәләмне коткаргач, Муса галәйһиссәләм әйтте: «Әй Раббым, миңа кылган ниґъмәтең өчен шөкер кылуым өчен миңа бер гамәлне өйрәт». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй Муса, «лә иләһә илләллаһ», дип әйт». Муса галәйһиссәләм артыкны тели торган булды. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй Муса, әгәр үлчәү табагының берсенә җиде күк белән җиде җирне куйсаң һәм икенче табагына «лә иләһә илләллаһ» кәлимәсен куйсаң, ул сүз, әлбәттә, басар».

Мөҗәһиттән риваять ителде, ул әйтте: «Өч төрле нәрсәне Аллаһы Тәгаләдән бернәрсә дә каплый алмас: «лә иләһә илләллаһ», дип шәһадәт бирү; кабул булуына чын күңелдән ышанган кешенең догасы; атаның балага кылган догасы һәм рәнҗетелгән кешенең рәнҗетүчесенә кылган догасы».

Сәхабәләрнең берсеннән риваять ителде, ул әйтте: «Кем дә кем чын күңелдән «лә иләһә илләллаһ», дип әйтсә һәм шул сүзне олуглап сузса, ул кешедән олуг гөнаһларыннан дүрт меңе ярлыканыр». «Аның дүрт мең гөнаһысы булмаса, ни булыр?» – дип сорадылар. «Җәмәгатенең һәм күршеләренең гөнаһлары ярлыканыр», – дип җавап бирде.

Фәкыйһ әйтте: «Берәү җиде сүзне ятласа, Аллаһы Тәгалә каршында һәм фәрештәләр янында хөрмәтле булыр, гөнаһлары диңгез күбеге чаклы күп булса да, Аллаһы Тәгалә аның гөнаһларын ярлыкар. Һәм ул гыйбадәтнең тәмен табар. Тереклеге дә, үлеме дә аның өчен изге булыр. Ул җиде сүз шулардыр: һәр нәрсәне башлаганда Аллаһы Тәгаләнең исеме белән, ягъни «бисмилләһ» әйтеп башлау. Икенчесе, һәр нәрсәдән бушаганнан соң «әлхәмдүлилләһ», ягъни Аллаһы Тәгаләгә мактаулар булсын, дип әйтү. Өченчесе, теләндә буш сүз, аз яки күп явыз гамәл кылса, шуннан соң «әстәгъфируллаһ», дип әйтү. Дүртенчесе, иртәгә шулай эшләрмен дип әйтергә теләсә, артыннан ук «ин шәә-ә аллаһ», ягъни Аллаһы Тәгалә теләсә, дип әйтү. Бишенчесе, ярамас нәрсә очратса, «лә хәүлә вә лә куввәтә илла билләһил-газыйм», ягъни олуг булучы Аллаһы Тәгаләдән башка бернинди дә көч-куәт юктыр, дип әйтү. Алтынчысы, малга яки җанга азмы, күпме берәр төрле кайгы килсә, «иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун», ягъни, дөреслектә, без Аллаһы Тәгаләнеке һәм Аңа гына кайтачакбыз, дип әйтү. Җиденчесе, төн урталарында, кичә һәм көндез «лә иләһә илләллаһ», ягъни Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк, дип әйтүне даим теләңдә кылу».

حدثنا من سمع معاذ بن جبل ﷺ أنه لما حضرته الوفاة يقول : أكشفوا عني ، فإني سمعت رسول الله ﷺ جدثنا يمنعني أن يحدثكم به إلا أن تتكلموا به سمعت النبي ﷺ يقول : "من قال لا إله إلا الله مخلصا موقنا دخل الجنة" .

Мугаз бине Җәбәлдән ишеткән кеше риваять итте. Мугаз бине Җәбәлгә үлеме якынлашкач әйтте: «Минем йөземне ачыгыз, чөнки мин Рәсүлуллаһтан шундый хәдис ишеттем, мине ул хәдисне сезгә

сөйләүдән сезнең үзгәртеп сөйләвегездән башка нәрсә тыймый. Рәсүлуллаһтан ишеттем, ул әйтте: «Берәү чын күңеленнән «лә иләһә илләллаһ» дип әйтсә, җәннәткә керер».

وروى عن النبي ﷺ "أنه قال :من لقن عند الموت لا إله إلا الله دخل الجنة"

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул әйтте: «Берәү үлем вакытында «лә иләһә илләллаһ» дип икрар итсә, җәннәткә керер».

وروى عن النبي ﷺ : أنه قال : "من كان أخر كلامه من الدنيا لا إله إلا الله دخل الجنة".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул әйтте: «Берәүнең дөньяда вакытта иң актык сүзе «лә иләһә илләллаһ» булса, җәннәткә керер».

عن جابر بن عبد الله ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "ألا أخبركم بشيء أمر به نوح عليه السلام ابنه ؟! قال : يا بني آمرك أمرين ، وأنهاك عن امرين ، آمرك أن تقول لا إله إلا الله ةحده لا شريك له ، فإن السماء والارض لو جعلتا في كفة ، ولا إله إلا الله في كفة لوزنتهما ، وآمرك أن تقول سبحان الله وبحمده ، فإنها صلاة الملائكة ودعاء الخلق وبها يرزق الخلق ، وانهاك أن تشرك بالله شيئا ، فإن من يشرك بالله شيئا فقد حرم الله عليه الجنة ، وانهاك عن الكبر ، فإنه لا احد يدخل الجنة وفي قلبه مثقال خبة من خردل من كبر".

Җәбир бине Габдулла Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән риваять итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Нух галәйһиссәләмнең улына боерган нәрсәдән сезгә хәбәр биримме? Нух галәйһиссәләм әйтте: «Әй улым, мин сине ике нәрсә белән боерам һәм ике нәрсәдән тыямын. Боерган әйберемнең беренчесе: һич ширеге булмаган, ялгыз Аллаһы

Тәгалә, Үзе генә коллык ителмеш зат, дип әйтергә боерам. Чөнки күк белән җир, икесе бергә, мизанның бер табагына куелсалар һәм «лә иләһә илләллаһ» икенче табагына салынса, җир белән күк салынган табакны, әлбәттә, басар иде. Икенчесе: «сүбхәнәллаһү вә бихәмдиһи» дип әйтергә боерам. Чөнки ул сүз фәрештәләр салаваты һәм бөтен мәхлукларның догасы. Ул сүз белән бөтен халык ризыкланадыр. Янә Аллаһы Тәгаләгә ширек кылудан тыям. Тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә ширек кылучыга җәннәтне хәрам кылды. Һәм сине тәкәбберлектән тыямын. Чөнки күңелендә тузан бөртеге кадәр тәкәбберлек булса, һичкем җәннәткә кермәс».

Риваять ителде: «Бер кеше чын күңелдән «лә иләһә илләллаһ» кәлимәсен әйтсә, җәннәткә керер. Бу сүздә ихлас шарт итеп куелды. Бу сүз аны гөнаһлардан тыйса гына, ихлас була. Әгәр ул сүз аны гөнаһлардан тыймаса, ул кеше ихлас түгел. Гөнаһ кылган кешенең бу сүзенең вакытлыча гына булуы куркынычы бардыр. Гария булган, ягъни бурычка алган нәрсә аннан кайтарылып алынадыр».

Фәкыйһ әйтте: «Кешеләр иман җәһәтеннән ике төрледер. Кешеләрдән бер төрлесенең иманы бүләк булыр. Ягъни Аллаһы Тәгалә тарафыннан кайтарылмас. Икенче төрлесенең иманы вакытлыча гына нәрсә булыр. Боларның галәмәтләре ошбудыр: иманы бүләк булган кешенең иманы аны гөнаһлардан тыяр, гыйбадәтләргә кызыктырыр. Иманы вакытлыча гына булган кешене иманы гөнаһлардан тыймас, ул кеше гыйбадәтләргә кызыкмас. Чөнки бу кешедә иманны саклау юктыр».

وروى في الخبر : "من قال لا إله إلا الله ، مخلصا دخل الجنة".

Әнәс бине Мәлик, Пәйгамбәр галәһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Лә иләһә илләллаһ» дигән сүз җәннәтнең ачкычыдыр».

Икенче бер риваятьтә: «Җәннәтнең ачкычыдыр», – дигәч, «Мәгәр ачкычның тешләре булырга тиеш. Шул вакытта гына ишек ачылыр. Ул җәннәт ачкычының тешләре җөмләсеннән шулардыр: гөнаһлардан һәм гайбаттән пакь, һәрвакыт Аллаһы Тәгаләне зекер итүче тел һәм көнчелек һәм хыянәттән пакь булган, курка торган күңелдер. Хәрам һәм шөбһәдән пакь эче – өченче тешедер. Гөнаһлардан пакь, хезмәт белән шөгыльләнүче әгъзалар – дүртенчеседер».

عن أبي ذر ﷺ قال : قلت يا رسول الله ، علمني عمل ا يقربني إلى الجنة ، ويبادعني من النار ، قال "إذا عملت شيئة فاعمل بجنبها حسنة ، فإنها بعشر أمثالها" ، فقلت : يا رسول الله لا إله إلا الله من الجسنات ؟ قال : «هي من أحسن الجسنات".

Әбү Зәрр разыяллаһү ганһүдән риваять ителде, ул әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, миңа җәннәткә якынайта һәм тәмугтан ерак итә торган гамәлне өйрәт», – дидем. Рәсүлуллаһ әйтте: «Әгәр явызлык эшләсәң, шул явызлык янына бер изгелек эшлә. Чөнки изгелек ун өлеш әҗерле буладыр». Әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, «лә иләһә илләллаһ» кәлимәсе изгелекләрдәнме?» Рәсүлуллаһ әйтте: «Ул «лә иләһә илләллаһ» изгелекләрнең иң күркәменнәндер».

Сәлмә бине Зәйд Хүзәйфә бине әл-Йәмәнидән риваять итте. Ул әйтте: «Ислам шулкадәр онытылыр, хәтта ураза белән намазны ни икәнен һичберәү белмәс. Хәтта кеше әйтер: «Бездән элек «лә иләһә илләллаһ» дип әйткән кешеләр булган икән. Без

дә «лә иләһә илләллаһ»,– дип әйтик». Аңа әйтерләр: «Лә иләһә илләллаһ» аларга һич нәрсә бирмәде. Ул кеше әйтер: «Лә иләһә иләллаһ» дигән сүз белән тәмугтан котылыр да, шуның сәбәпле җәннәткә керер».

## Коръәннең фазыйләте турында

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Габдулла бине Мәсгудтән риваять итте. Ул әйтте: «Коръән шәфәгатьче һәм аннан шәфәгать таләп итеңә. Коръән Аллаһы Тәгалә каршында үзенең иясе өстендә баручы һәм аның сүзе Аллаһы каршында һич башка бер шәһадәтсез, ышанычлыдыр. Ягъни Кыямәт көнендә Коръәннең: «Бу кеше мине укыды, ләкин таләбемчә гамәл итмәде», – дигән сүзенә шәһадәт соралмас. Берәү ул Коръәнне үзенең алдында кылса, ул кешене җәннәткә җитәклә барыр. Ләкин Коръәнне артына ташласа, ягъни Коръән таләпләре буенча булмаса, ул кешене җәһәннәмгә сөрер».

Фәкыйһ әйтте: «Ибен Мәсгуд разыяллаһү ганһүнең «шәфигъ һәм мүшәффигъ» дип әйткән сүзнең мәгънәсе – иясенә шәфәгать таләп ителер һәм иясенә шәфәгать бирелер. «Мәхил» дигән сүз өстеннән шикаять белән баручы димәктер. Ягъни: «Укымады һәм аның белән гамәл кылмады», – дип, иясенең өстенә барыр. Һәм аның сүзе раска алыныр. «Берәү Коръәнне үзенең имамы итсә» дигән сүзнең мәгънәсе – Коръәнне укып, аның белән гамәл кылса,– Коръән ул кешене җәннәткә җитәкләр. «Ләкин Коръәнне артында кылса» дигән сүзнең мәгънәсе – Коръәнгә золым кылса,– укымаса һәм аның белән

гамәл кылмаса, ул кешене Кыямәт көнендә тәмугка сөрер».

Шул ук иснәд белән Нәфигъ бине Габдулхәристән риваять ителде. Ул хәзрәти Гомәрнең Мәккәдә зәкәт һәм гошер җыючысы иде. Хәзрәти Гомәрнең бер хаҗендә Нәфигъ каршы чыкты. Гомәр аны күреп, әйтте: «Мәккә халкының садакасын җыярга кемне калдырдың?» Нәфигъ әйтте: «Габдрахман бине Әбү Әбзәне калдырдым». Гомәр әйтте: «Корәешнең электә коллары булган кешеләр җөмләсеннән булган кешене зәкәт җыярга калдырдыңмы?» Нәфигъ әйтте: «Әй мөэминнәрнең әмире, Габдрахман бине Әбү Әбзәдән артык Коръәнне укучы кешене үземнең артымда калдырмадым, ягъни Мәккәдә Габдрахманнан артык Коръән укучы юк иде, димәк. Шуның өчен аны калдырдым». Гомәр әйтте: «Дөрес, тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә күп кешеләрне Коръән сәбәпле күтәрде һәм күп кешеләрне төшерде. Габдрахман бине Әбү Әбзә – дәрәҗәсе Коръән сәбәпле күтәрелгән кешеләр җөмләсеннәндер».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Габдулла бине Мәсгудтән риваять итте, ул әйтте: «Дөреслектә, бу Коръән Аллаһы Тәгаләнең зыяфәт урыныдыр. Көчегез җиткән чаклы Аллаһы Тәгаләнең зыяфәте урынын өйрәнегез. Дөреслектә, Коръән Аллаһы Тәгаләнең нык җебе, ачык нур һәм файдалы шифадыр. Ул Коръәнгә таянган кешегә – саклanудыр һәм аңа ияргән кешегә котыла торган урын, авып тора торган түгелдер. Һәм ул Коръәндә шик тә юк, әгәр шик булса, шелтә таләп итәр, мәгәр ул юк. Аның гаҗәепләре һич бетә торган түгел. Коръәнне укыгыз. Чөнки Аллаһы Тәгалә укылган һәрбер хәрефе өчен ун изгелек, әҗер бирер. Белегез, мин

әлиф, ләм, мим дип әйтелгән сүзгә ун әҗер булыр дип әйтмим, ләкин әлифкә ун, мимгә ун һәм ләмгә ун әҗердер».

عن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "من نفس عن أخيه المؤمن كربة من كرب الدنيا ، نفس الله عنه كربة من كرب الآخرة ، ومن يسر على معسر يسر الله عليه في الدنيا والآخرة والله في عون العبد مادام في عون أخيه المسلم ، ومن سلك طريقا يلتمس فيه علما سهل الله له طريقا إلى الجنة ، وما اجتمع قوم في بيت من بيوت الله يتلون كتاب الله تعالى ، ويتدارسونه فيما بينهم ، إلا نزلت عليهم السكينة وغشيتهم الرحمة ، وحفتهم الملائكة وذكرهم الله تعالى فيمن عنده".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Мөэмин кардәшенең дөнья кайгыларыннан булган бер кайгысын ачса, Аллаһы Тәгалә ул кешенең ахирәт кайгыларыннан булган кайгысын ачар. Берәү фәкыйрьгә җиңеллек итсә, Аллаһы Тәгалә аңа дөнья һәм ахирәттә җиңеллек кылыр. Бәндә үзенең мөселман кардәшенә ярдәм иткән чагында Аллаһы Тәгалә дә шул бәндәнең ярдәмендәдер. Кем дә кем гыйлем тели торган юлга керсә, Аллаһы Тәгалә аңа оҗмах юлын җиңел кылыр. Әгәр Аллаһы Тәгаләнең өйләреннән булган бер өйдә халык Аллаһының китабын укып, бер-берсенә өйрәтсәләр, аларның хозурына тынычлык иңәр, аларны рәхмәт каплар һәм фәрештәләр чолгап алырлар. Һәм аларны Аллаһы Тәгалә Үзенең каршындагы кешеләр белән зекер итәр».

Язид бине Әбү Хәбибтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем Коръәнне зекер итсә, Аллаһы Тәгалә аның ата-

анасының газапларын җиңеләйтер, гәрчә алар кәфер булсалар да».

Габдулла бине Гамру бине әль-Гастан риваять ителде, ул әйтте: «Кем дә кем Коръәнне укыса, гүя аның ике кабыргасы арасына пәйгамбәрлек кертелде. Мәгәр Коръән аңа вәхи генә ителмәде. Кем дә кем Коръән укып, икенче берәүгә бирелгән нигъмәтне үзенә бирелгән нигъмәттән артык күрсә, тәхкыйк, ул кеше Аллаһы Тәгалә зур күргән нәрсәне кечкенә санады, Аллаһы Тәгалә кечкенәгә санаган нәрсәне олуг күрде. Коръән белүчегә ахмаклык кылган кеше хакында ахмаклык кылу ярамас. Мәгәр гафу кылыр һәм кичерер».

Габдулла бине Мәсгуд әйтте: «Коръәнне яттан белүче кешегә кешеләр йоклаган вакытта кичәсен белү; кешеләр ураза тотмаган вакытта ураза тота торган көндезен тану; кешеләр шат булган вакытта, кайгысын белү; кешеләр көлә торган вакытта елауны белү; кешеләр тәкәбберләнгән вакытта үзенең түбәнлеген аңлау тиештер. Шулай ук Коръән яттан белүче кешегә елаучы, кайгылы, гыйлемле, йомшак, тыныч булырга кирәк. Коръән белүчегә күзе кипкән булу, гафил булу, кычкыру, каты күңелле булу тиеш түгел».

وروى عن معاذ بن جابل ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "ثلاثة هم الغرباء في الدنيا : القرآن في جوف الظالم ، والرجل الصالح في قوم سوء ، والمصحف في بيت لا يقرأ فيه".

Мугаз бине Җәбәл Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Өч төрле нәрсә дөньяда адашкан, урынсызлардыр: залим кеше күкрәгендәге Коръән; явыз халык эчендәге изге кеше һәм укылмый торган өйдә Коръән китабыдыр».

Мөхәммәд бине Кәгъб әйтте: «Кем дә кем Коръәнне укыса, ул кеше Пәйгамбәр галәйһиссәләмне күргән шикелле булыр. Моннан соң ул Мөхәммәд бине Кәгъб аятьне укыды:

﴿ وَأُوحِيَ إِلَيَّ هَٰذَا الْقُرْآنُ لِأُنذِرَكُم بِهِ ﴾

«Минем пәйгамбәрлегемнең хәбәре ирешкән кешеләрне куркытуым өчен миңа бу Коръән вәхи ителде». (Әнгам: 19)

Риваять ителде: «Оҗмах дәрәҗәләренең саны Коръән аятьләре микъдарындадыр. Кыямәт көнендә Коръәнне укучы кешегә әйтелер: «Бер бит укы». Әгәр аның белән ярты Коръән булса, аңа: «Әгәр синдә артыгы булса иде, сиңа да арттырыр идек», – дип әйтерләр.

عن الحسين بن علي ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "من قرأ القرآن في الصلاة وهو قائم فله بكل حرف مائة حسنة ، ومن قرأ القرآن في الصلاة قاعدا كتب الله له بكل حرف خمسين حسنة ، ومن قرأ القرآن في غير الصلاة فله بكل حرف عشر حسنات ، ومن استمع إلى شيء من كتاب الله وهو يريد الأخرة كتب به بكل حرف حسنة ، ومن قرأ القرآن حتى يختمه كانت له عند الله دعوة مستجابة ـــ إما معجلة وإما مؤجلة".

Хәсән бине Галидән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем намазда Коръән укыса һәм ул басып торган хәлендә булса, ул кешегә һәрбер хәрефе бәрабәренә йөз изгелек әҗере булыр. Кем дә кем намазда утырган хәлдә Коръәнне укыса, Аллаһы Тәгалә һәрбер хәрефе бәрабәренә илле изгелек язар. Кем дә кем намаздан башка вакытта Коръән укыса, ул кешегә Коръәннең һәрбер хәрефе бәрабәренә ун изгелек булыр. Кем дә кем

Коръәннән берәр аять тыңласа һәм ул кеше әҗер теләсә, ул бәндәгә Коръәннең һәрбер хәрефе бәрабәренә бер изгелек языла. Кем дә кем Коръәнне тәмам кылса, ул кешенең догасы Аллаһы Тәгалә каршында бу дөньяда, яки ахирәттә кабул булыр».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "ثلاثة لا يستخف بحقهن إلا منافق : إمام مقسط ، وذو شيبة في الإسلام ، وحامل القرآن".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйткән: «Өч төрле кешенең хакын монафийктан башка кеше җиңелгә санамас. Гадел патшаның хакы, Ислам динендә картайган кешенең хакы һәм Коръән белүченең хакыдыр».

Әбү Өмәмә разыяллаһү ганһү әйтте: «Рәсүлуллаһ безне Коръән өйрәнүгә кызыктырды. Соңыннан Коръән өйрәнүнең әҗерен сөйләп әйтте: «Кыямәт көнендә Коръән иясенә килер. Коръәннән башка кешегә мохтаҗ нәрсә булмас. Ягъни Коръән Кыямәт көнендә иясен керәксенеп килер. Рәсүлуллаһ әйтте: «Иясенә иң күркәм кыяфәттә килер һәм: «Мине таныйсыңмы?», – дип сорар. Бәндә әйтер: «Син кем?» Коръән әйтер: «Син ярата һәм хөрмәтли торган кешемен. Минем сәбәпле кичеңне аяк өстендә үткәрдең, гадәтең буенча көндез дә мине укыдың». Бәндә әйтер: «Шаять, син Коръәндер?» Моннан соң Коръән иясе Аллаһы Тәгаләгә килер. Аллаһы Тәгалә мөлкәтне аның уң кулына, мәңгелекне сул кулына бирер, башына патшалык таҗы кидерелер. Коръән укучының ата-анасына ике кием кидерелер. Ул киемнәр дөнья бәясе тормас, әгәр микъдары артык булса да. Алар: «Кайдан безгә бу әҗер, безнең гамәлебез моңа ирешмәс», – дип әйтерләр. «Балаларыгызның Коръән укуы аркасында сезгә бу

дәрәҗәне бирдем», – дип әйтелер. Рәсүлуллаһ әйтте: ««Бәкара» белән «Әли Гыймран» сүрәләрен өйрәнегез. Чөнки бу сүрәләр Кыямәт көнендә ике болыт яки ике күләгә кебек килерләр. Ул сүрәләрне укучы кешеләргә шаһид булырлар». Моннан соң әйтте: «Бәкара» сүрәсен өйрәнегез. Чөнки ул сүрәне өйрәнү – бәракәт, аны ташлау – хәсрәттер. «Бәкара» сүрәсен өйрәнүчегә сихерчеләрнең көче җитмәс». Моннан соң әйтте: «Бу әйтелгән әҗерләр – өйрәнеп тә буш уздырмаган, аның белән гамәл кылган кешеләр өчендер, аны киптермәсә, аның белән мал ашауга гына сылтамаса гына булыр».

Сәгъд бине Әбү Вәккастан риваять ителде, ул әйтте: «Кем дә кем көндез Коръәнне тәмам кылса, фәрештәләр аңа кичкә кадәр салават әйтерләр. Кем дә кем кичтә Коръәнне тәмам кылса, фәрештәләр аңа таң атканга кадәр салават әйтерләр. Коръәнне көндез тәмам кылуны күркәм санадылар».

Габдулла бине Мөбәрак әйтте: «Җәй көннәрендә иртә белән тәмам кылуны күркәм санадылар. Үзләренә салават күбрәк булсын өчен кыш көннәрендә кичнең беренче яртысында тәмам кылуны күркәм күрделәр».

عن أبي مرسى الأشعري ﷺ أن رسول الله ﷺ قال : "مثل مؤمن الذي يقرأ القرآن كمثل الأترجة ، ريحها طيب وطعمها طيب ، ومثل المؤمن الذي يقرأ القرآن كمثل التمر طعمه طيب ولا ربح له ، زمثل الفاجر الذي يقرأ القرآن كمثل الريحانة ريحها طيب وطعمها مر ، زمثل الفاجر الذي لا يقرأ القرآن كمثل الحنظلة طعمها مر ولا ريخ لها".

Әбү Муса әл-Әшгаридән риваять ителде. Рәсүлуллаһ әйтте: «Коръән укый торган мөэминнең

охшашы, исе дә, тәме дә хуш булган кавын кебектер. Коръән укымый торган мөэминнең охшашы, тәме хуш, исе булмаган хөрмә кебектер. Коръән укый торган гөнаһлының охшашы, хушбуй кебек: исе тәмле, тәме ачыдыр. Коръән укымый торган *гөнаһлының охшашы: исе юк, тәме ачы булган* карбыз кебектер».

وروى عقبة بن عامر ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "المسر بالقرآن كالمسر بالصدقة ، والجاهر بالقرآن كالجاهر بالصدقة".

Гукбә бине Гамир риваять итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Коръәнне яшерен укучы садаканы яшерен бирүче кебек. Коръәнне кычкырып укучы садаканы күрсәтеп бирүче кебек. Ягъни Коръәнне кычкырып укыса ни хуш, ләкин яшерен укыса, ул артыграк булыр».

وعن الوليد بن حبيب أن النبي ﷺ قال : "عرضت على الذنوب ، فلم أر فيها شيئا اعظم من حامل القرآن وتاركه".

Вәлид бине Габдулладан риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Миңа гөнаһлар күрсәтелде. Һәм ул гөнаһлар арасында Коръән белүчеләрдә зур гөнаһлы кешеләрне һәм Коръәнне укымаучыдан да артык гөнаһлы кешене күрмәдем».

وعن طلق بم حبيب ان النبي ﷺ قال : "من تعلم القرآن ثم نسيه من غير عذر حط له بكل آية درجة ، وجاء يوم القيامة مخصوما"

Талка бине Хәбибтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем Коръән өйрәнеп, гозерсез онытса, һәрбер аяте бәрабәренә аның дәрәҗәсе төшерелер. Кыямәт көнендә кулы кисәк һәм дәгъва таләп ителгән хәлдә килер».

عن رسول الله ﷺ انه قال : "من تعلم القرآن ثم نسيه من غير عذر جاء يوم القيامة أجذم".

Рәсүлуллаһтан риваять ителде, ул әйтте: «Коръәнне ятлап, аны гозерсез онытса, Кыямәт көнендә кулы кисек булып килер».

Даххактан риваять ителде, ул әйтте: «Берәү Коръән өйрәнеп, соңыннан онытса, аңа ирешкән гөнаһ сәбәбеннән генә булыр. Моннан соң Даххак укыды:

﴿ وَمَا أَصَابَكُمْ مِنْ مُصِيبَةٍ فَبِمَا كَسَبَتْ أَيْدِيكُمْ وَيَعْفُو عَنْ كَثِيرٍ ﴾

«Сезгә нинди генә кайгы ирешсә, үзегездәндер. Шулай булса да Аллаһы Тәгалә гөнаһларыгызның күбрәген гафу итәдер». (Шура: 30) Инде Коръән онытудан кайсы кайгы олуграк?»

Фәкыйһ әйтте: «Әбү Хәнифәдән риваять ителде: «Кем дә кем елга ике мәртәбә Коръәнне укыса, тәхкыйк, ул кеше Коръәннең хакын үтәде. Чөнки Пәйгамбәр галәйһиссәләм ул Коръәнне Җәбраил галәйһиссәләмгә ел саен бер мәртәбә укып карый иде. Вафат булган елда исә ике мәртәбә укыды».

## Гыйлем алу фазыйләте

Кәсир бине Каййистән риваять ителде. Ул әйтте: «Мин Әбү Дәрдә белән Дамаск шәһәренең мәчетендә утыра идем. Аның янына бер кеше килде һәм әйтте: «Әй Әбү Дәрдә, миңа Рәсүлуллаһтан риваять кылып сөйләгәнсең икән, дигән хәбәр иреште, шул хәдисне белер өчен Рәсүлуллаһның шәһәреннән килдем». Әбү Дәрдә әйтте: «Син сәүдә яки башка йомыш өчен килмәдеңме, фәкать шул хәдисне белү өчен генә килдеңме?» Теге кеше:

«Бары тик шуның өчен генә килдем», – дип җавап бирде. Әбү Дәрдә әйтте: «Дөреслектә, мин Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән ишеттем, ул әйтте:

"من سلك طريقا يطلب به علما سهل الله له طريقا من طرق الجنة ، وإن الملائكة لتضع أجنحتها لطالب العلم رضا بما يصنع وإن العالم يستغفر له كل من في السماوات ومن في الارضوالحيتان في جوف الماء وإن فضل العالم على العابد كفضل القمر ليلة البدر على سائر الكواب وإن العلماء ورثة الانبياء وإن الأنبياء لم يورثوا درهما ولا دينارا وإنما ورثوا العلم ، فمن أخذه فقد أخذ بحظ وافر".

«Кем дә кем гыйлем алыр өчен юлга чыкса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә җәннәт юлларыннан булган бер юлны җиңел кылыр. Дөреслектә, гыйлем теләүчедән риза булганлыкларыннан фәрештәләр аларның аяк асларына канатларын җәярләр. Күкләрдә һәм җирдәге кешеләрнең һәрберсе һәм су эчендәге җанварлар галим өчен ярлыкау теләрләр. Дөреслектә, галимнең гыйбадәт кылучыга карагандагы артыклыгы ундүртенче кичәдәге айның башка йолдызларга карагандагы артыклыгы кебектер. Дөреслектә, галимнәр пәйгамбәрләрнең варислары. Пәйгамбәрләр көмеш акча, алтын тәңкә калдырмадылар, тик алар гыйлемне калдырдылар. Кем дә кем ул гыйлемне алса, тәхкыйк, күп өлеш алды».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Габдулла бине Мәсгудтән риваять итте. Ике төрле күп ашаучы бардыр, һичбер вакытта туймаслар. Гыйлем белән мал теләүчедер. Әмма болар бертигез түгелләр. Гыйлем теләүче Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын арттыра, әмма дөнья теләүче исә гөнаһ кылуны арттыра. Моннан соң укыды:

﴿ إِنَّمَا يَخْشَى اللَّهَ مِنْ عِبَادِهِ الْعُلَمَاءُ ﴾

«Аллаһыдан галимнәр генә куркыр». (Фатыр: 28) һәм:

﴿ كَلَّا إِنَّ الْإِنْسَانَ لَيَطْغَى . أَنْ رَآهُ اسْتَغْنَى ﴾

«Адәм баласы үзенең малы сәбәпле йомышы һәм ихтыяжы калмаганын күрүдән тугъян, ягъни гөнаһ кылуда чиктән узучыдыр». (Галәкъ: 6, 7)»

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Мөхәммәд бине Сириннән риваять итте. Ул әйтте: «Басра мәчетенә кердем. Әсвәд бине Сәригъ кешеләргә хикәя сөйли иде. Аның каршына мәчет халкы җыелды. Аның артында икенче якта фикыһ галимнәре утырып, фикыһ турында сөйләшәләр иде. Гыйлем мәҗлесе белән зекер мәҗлесе арасында ике рәкәгать намаз кылдым бушанганнан соң, әгәр Әсвәд бине Сәригъ янына утырсам, шаять, аларга рәхмәт ирешеп, миңа да шул рәхмәт ирешер. Әгәр гыйлем мәҗлесенә килсәм, шаять, ишетмәгән сүзне ишетермен һәм аның белән гамәл кылырмын, ошбу гамәл белән ахыргы сулышта да даим булырмын. Хәтта мин алардан үттем, һич берсе белән утырмадым. Шул көнне кич булгач, төштә берәү килеп, миңа: «Әгәр син фикыһ сөйләнә торган халык янына килсәң иде, алар белән бергә утырган хәлдә Җәбраил галәйһиссәләмне табар идең», – диде.

عن أنس بن مالك ﷺ قال : قال رسول الله ﷺ : "من أحب أن ينظر إلى عتقاء الله من النار فلينظر إلى المتعلمين ، عوالذي نفس محمد بيده ما من متعلم يختلف إلى باب العالم إلا كتب الله له بكل حرف وبكل قدر عبادة سنة ، وبنى

له بكل قدم مدينة في الجنة ، ويمشي على الأرض تستغفر له ، ويمسى ويصبح مغفورا له ، وشهدت له الملائكة ويقولون هؤلاء عتقاء الله من النار".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем Аллаһының тәмугыннан азат булган колларына карарга теләсә, гыйлем өйрәнүчеләргә карасын. Аллаһы Тәгалә белән ант итәмен, Аллаһы Тәгалә галим ишегенә гыйлем өйрәнү өчен барган шәкерткә һәрбер хәреф бәрабәренә һәм һәрбер аяк адымы бәрабәренә берьеллык гыйбадәт әҗерен язар. Һәрбер аяк адымы саен оҗмахта аның өчен бер шәһәр төзер. Җир йөзендә йөргәндә, җир аның өчен истигъфар кылыр. Йөреп, таңга ярлыканган хәлдә керер. Фәрештәләр аның файдасына шаһидлык бирерләр: «Болар Аллаһы Тәгаләнең тәмугтан азат ителгән коллары», – дип әйтерләр».

سمعت الفقيه أبا جعفر ﷺ يذكر بلإسناده أن النبي ﷺ دخل المسجد ، فرأى مجلسين : أحدهما يذكرون الله ، والآخر يتعلمون الفقه ويدعون الله ويرغبون إليه فقال ﷺ : "كلا الجلسين على خير ، وأحدهما أفضل من الآخر ، أما خؤلاء فيدعون الله فإن شاء أعطاهم وإن شاء منعهم ، وأما هؤلاء قيتعلمون ويعلمون الجاهل ، وإنما بعثت معلما ، فهؤلاء أفضل" ثم جلس معهم.

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Җәгъфәрдән риваять итте. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм мәчеткә кергәч, ике мәҗлесне күрде. Ул ике мәҗлеснең берсендә Аллаһы Тәгаләне зекер кылалар иде. Икенчесендә гыйлем өйрәнәләр. Аллаһыга дога кылалар һәм шуңа кызыктыралар иде. Рәсүлуллаһ әйтте: «Һәр ике мәҗлес яхшылыкта, әмма берсе икенчесеннән артыграк. Болар Аллаһы Тәгаләгә дога

кылалар. Әгәр Аллаһы Тәгалә теләсә, сораганнарын бирер, әгәр теләмәсә бирмәс. Икенче төркем исә өйрәнәләр һәм наданнарны өйрәтәләр. Мин үзем Аллаһы Тәгалә тарафыннан өйрәтүче булып җибәрелдем. Бәс болар артыграк», – дип, Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм гыйлем өйрәнүчеләр белән утырды».

Әбү Дәрдәдән риваять ителде. Ул әйтте: «Минем өчен бер мәсьәләне өйрәнүем төне буе уяу булып, гыйбадәт кылуымнан сөеклерәктер».

Ибен Мәсгудтән риваять ителде. Ул әйтте: «Сез әле гамәл гыйлемнән артык һәм изгерәк заманда. Әмма гыйлем гамәлдән артык һәм изгерәк булган заман тиз килер».

وروى عن رسول الله ﷺ انه قال : "أفضل الاعمال على ظهر الارض ثلاثة : طلب العلم ، والجهاد، والكسب ، لأن طالب العلم حبيب الل ، والغازي ولي الله ، والكاسب صديق الله".

Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять ителде. Ул әйтте: «Җир йөзендә гамәлләрнең артыграгы өчтер: гыйлем эзләү, сугыш кылу, хәләл ризык теләүдер. Чөнки гыйлем теләүче Аллаһының сөеклесе, сугышучы Аллаһының хөрмәтле колы, кәсеп итүче исә Аллаһының дустыдыр».

عن رسول الله ﷺ أنه قال : "من طلب العلم لغير الله لم يخرج من الدنيا حتى يأتي عليه العلم فيكون لله . ومن طلب العلم لله فهو كالصائم نهاره والقائم ليله ، وإن بابا من العلم يتعلمه الرجل خير من أن يكون له أبو قبيس ذهبا ، وأنفقه في سبيل الله تعالى".

Рәсүлуллаһтан риваять ителде: «Кем дә кем гыйлемне Аллаһы Тәгаләнең ризасыннан башка нәрсә өчен теләсә, аңа Аллаһы Тәгалә ризалыгы

өчен булган гыйлем килгәнгә кадәр дөньядан чыкмас. Кем дә кем Аллаһы ризалыгы өчен гыйлем теләсә, ул кеше көндезен ураза тотып, кичен гыйбадәт белән үткәргән кеше кебектер. Дөреслектә, кеше өйрәнә торган гыйлемнән бер ишек Мәккәдәге Әбү Кабис тавы кадәр алтынны Аллаһы Тәгаләнең юлында сарыф кылудан артыграктыр».

Габдулла бине Мөбарәктән: «Кешенең гыйлем өйрәнүе кайчанга кадәр күркәм күренер?» – дип сорадылар. Ул әйтте: «Аның хозурына наданлык начар булып күренгән вакыт дәвамында, аңа өйрәнү күркәм күренер».

Ибен Мөбарәктән риваять ителде. Ул, Ибен Мөбарәк, үлем хәлендә иде. Каршындагы бер кеше аның өчен гыйлем яза иде. Моны күреп: «Ни гаҗәп, сиңа гыйлем языла?» – дип әйттеләр. Ибен Мөбарәк әйтте: «Бәлки миңа файда бирә торган гыйлем әле дә миңа ирешмәгәндер».

Мөгаз бине Җәбәлдән риваять ителде, ул әйтте: «Гыйлемне өйрәнегез. Чөнки гыйлем өйрәнү изгелек, гыйлемне теләү гыйбадәт, гыйлем хакында сөйләшү тәсбих, гыйлемнән сорашу җиһад, аны белмәгән кешегә өйрәтү садака, кешегә гыйлем бирү якынлыктыр. Аң булыгыз, дөреслектә, гыйлем җәннәт халкының урыннарының юлы, ялгызлыкта иптәш, бай вакытта юл күрсәтүче, фәкыйрь вакытта ярдәм итүчедер. Дуслар янында бизәк, дошманнарга корал булыр. Аллаһы Тәгалә ул гыйлем сәбәпле күп халыкны күтәрә. Гыйлем ул халыкны изгелеккә җитәкче имамнар ясый. Андый халыкның калдырган әсәрләренә, аларның фигыльләренә башкалар иярерләр. Фәрештәләр аларның дуслыгын теләрләр, аларны канатлары белән сыйпарлар һәм алар өчен һәр корыган һәм һәр юешләнгән нәрсә, диңгездәге

җанварлар, җир йөзендәге хашәрәт, коры һәм диңгезнең ерткычлары, ягъни барча хайваннар рәхмәт әйтерләр. Чөнки гыйлем калебләрнең наданлыктан тереклеге, күзләрнең караңгылыктан яктыртучы, тәннәрнең загыйфьлектән куәтләредер. Бәндә шул гыйлем сәбәпле изгеләр һәм яхшылар дәрәҗәләренә, дөнья һәм ахирәттә югары мәртәбәләргә ирешер. Гыйлем хакында бер уйлау нәфел уразага бәрабәр килә. Гыйлем хакында сөйләшү гыйбадәт белән кичә торуга бәрабәрдер. Шуның белән якынларның күңеле табыла һәм шуның белән хәләл нәрсә хәрамнан аерыла. Ул гыйлем имамдыр, гамәл исә аның иярүчеседер. Ул гыйлемне бәхетлеләр белә, бәхетсезләр исә аңардан мәхрүм буладыр».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Хәсән Бәсридән риваять итте, ул әйтте: «Аллаһы юлында сугыштан артык нәрсәне белмим. Мәгәр гыйлем алу гына Аллаһы Тәгаләнең юлында җиһад кылудан артык була. Кем дә кем өеннән гыйлем алу нияте белән чыкса, ул кешене фәрештәләр канатлары белән чорнап алырлар, һава уртасындагы кошлар, кырдагы ерткычлар һәм диңгездәге җанварлар аның өчен рәхмәт әйтерләр. Аллаһы Тәгалә аңа җитмеш ике садикның (тугрылыклының) әҗерен бирер. Аң булыгыз, гыйлемне алыгыз. Гыйлем өчен күңел тынычлыгын, йомшаклыкны һәм акрынлыкны теләгез. Гыйлем ала торган кешеләрегезгә һәм үзегез өйрәтә торган кешеләргә түбәнчелекле булыгыз. Гыйлемегез сәбәпле галимнәргә мактанмагыз һәм ул гыйлем белән ахмакларга сүз ачмагыз, аның белән түрәләргә катнашмагыз һәм Аллаһының бәндәләренә зурлык кылмагыз. Зурайсагыз, Аллаһы Тәгаләнең ачуы ирешкән галимнәрнең залимнәреннән

булырсыз. Аллаһы Тәгалә шундый залим галимнәрне тәмуг утына йөзтүбән ябар. Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылырга зарар итми торган гыйлемне өйрәнегез. Һәм Аллаһы Тәгаләгә шундый гыйбадәтне кылыгыз ки, ул гыйбадәт гыйлем алуда сезгә зарар итмәсен. Чөнки гыйлем гамәл өчен генә файдаланыла. Гыйлем алуны ташлаган халык кебек булмагыз. Гыйбадәткә генә ябышкан халык кебек булыгыз. Хәтта тиреләре тәннәренә ябышса да, кылычлары белән кешеләр хозурына чыгарлар. Әгәр алар гыйлем теләгән булсалар иде, гыйлем аларны кылган гамәлләреннән тыяр иде. Гыйлемнән башка гамәл кылучы, юлдан тайган кеше кебектер. Ул кеше никадәр тырышлыгын арттырса да, ераклыкны гына арттырадыр. Ул кешенең төзәтүеннән бозу күбрәктер». «Әй Әбү Сәгыйд, моны кемнән риваять кылдың?» – дип сорадылар. Ул әйтте: «Ул хакта Бәдердә үтерелгән җитмеш кешегә очрадым һәм ул хәдисне эзләүдә кырык ел гариблек күрдем».

Әбү Дәрдәдән риваять ителде. Ул әйтте: «Әй кешеләр, ни булды миңа, галимнәрегезнең киткәнен күрәм. Һәм наданларыгыз өйрәнмиләр. Гыйлем күтәрелмәстән элек өйрәнегез. Чөнки гыйлемнең күтәрелүе – галимнәрнең китүедер».

وروى عبد الله بن عمرو بن العاص ﷺ ، عن رسول الله ﷺ أنه قال : "إن الله لا يرفع العلم بقبض يقبضه ، ولكن بقبض العلماء بعلمهم ، حتى إذا يبق عالم اتخذ الناس رؤساء جهالا فيسألون فيحدثون ، فضلوا وأضلوا".

Габдулла бине Гамру Рәсүлебез галәйһиссәләмнән риваять итте. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең гыйлемне күтәрүе гыйлемнең үзен алу белән түгелдер. Шулай булса да, Аллаһы Тәгалә галимнәрне гыйлемнәре белән алыр.

Хэтта һичбер галим дә калмас. Кешеләр наданнарны баш итәрләр, алардан сорарлар да, гыйлемне сөйләрләр. Үзләре дә азарлар һәм башкаларны да аздырырлар».

Ибен Мөбарәктән риваять ителде, аңардан: «Әгәр Аллаһы Тәгалә синең кичкә мәет буласыңны сиңа вәхи кылса, син бу көнне нишләр идең?» – дип сорадылар. Ибен Мөбарәк әйтте: «Ул көндә да гыйлем алыр идем».

Ибраһим Нәхгыйдән риваять ителде. Ул әйтте: «Галим кеше намазда даим булыр». «Бу ничек булыр?» – дип сорадылар. Ул әйтте: «Чөнки аңа юлыкмассың, мәгәр юлыктың исә, аның телендә Аллаһының зикерен табарсың. Хәләлне – хәләл дип, хәрамны – хәрам дип белер».

Әйтелде: «Галимнәр заманының шәмнәредер. Һәрбер галим заманысының яктыртучысы. Ул галим гыйлеме белән заманасының халыгын яктыртыр».

Сәлим бине Әбү Җәгъдтән риваять ителде: «Мине хуҗам өч йөз дирһәм бәрабәренә сатып алып, азат итте. Үз-үземә: «Инде нинди һөнәр белән шөгыльләним?» – дидем. Һәм мин һәрбер һөнәргә караганда гыйлемне ихтыяр кылдым. Күп вакыт та үтмәде мине күрергә патша килде. Мин аңа керергә рөхсәт итмәдем».

Салих Мәридән риваять ителде, ул патшага кергән иде. Патша аны урындыгына утыртты. Салих әйтте: «Хәсәннең сүзе дөрес булды». Патша: «Хәсән ни әйтте?» – дип сорады. Салих әйтте: «Хәсән шулай әйткән иде: «Дөреслектә, гыйлем шәрифкә шәрифне арттыра. Колны азатлар дәрәҗәсенә кадер ирештерәдер». Юкса Салих Мәри кем ул? Әгәр гыйлеме булмаса, патша урындыгына утырырга кем ул?»

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде, ул әйтте: «Кытайга барып булса да, гыйлемне эзләгез. Чөнки гыйлем алу һәрбер мөселман кешегә фарыздыр».

Мүсәййиб Әбү Бәкердән, ул Гаун бине Габдулладан риваять итте, ул әйтте: «Әбү Зәрр Гафәри разыяллаһү ганһүгә бер кеше килде һәм әйтте: «Мин өйрәнергә телим, ләкин ул гыйлемне тар итүдән һәм аның белән гамәл кылмаудан куркамын». Әбү Зәрр әйтте: «Аң бул, синең өчен гыйлемгә ябышуың наданлыкка ябышуыңнан артыктыр». Моннан соң Әбү Дәрдәгә китте һәм аңа да Әбү Зәрргә әйткән сүзләрне әйтте. Әбү Дәрдә әйтте: «Дөреслектә, кешеләр нинди хәлдә вафат булсалар, шул ук хәлдә кубарылырлар. Галим – галим булып, надан исә надан булып кубарылыр». Моннан соң ул кеше Әбү Һөрәйрәгә китте һәм аңа шул ук сүзне кабатлады. Әбү Һөрәйрә әйтте: «Син ташлаудан үкенечлерәк нәрсәне һич тә таба алмассың».

عن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "ما عبد الله بشيء أفضل من فقه الدين ، ولفقيه واحد أشد على الشيطان من ألف عابد ، وإن لكل شيء عمادا ، وعماد الدين الفقيه".

Әбү Һөрәйрә Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән риваять итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Дин гыйлемнән артык һичнәрсә белән Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт ителмәде. Ягъни гыйбадәтләр эчендә Аллаһы каршында дин гыйлемен өйрәнүдән артыгы юктыр. Бер галим кеше шайтан хозурына мең гыйбадәт кылучыдан катырактыр. Дөреслектә, һәр нәрсәнең терәкләре бар. Диннең терәге гыйлемдер».

Риваять ителде: «Басра халкы ихтиләф итештеләр. Кайберләре, гыйлем малдан артыграк һәм кайберләре, мал гыйлемнән артыграктыр, диделәр.

Бу мәсьәләне ачыклар өчен Ибен Габбас разыяллаһү ганһүгә илче җибәрделәр. Илче Ибен Габбастан шул хакта сорагач, Ибен Габбас: «Гыйлем артыграктыр», – диде. Илче әйтте: «Әгәр Басра халкы миннән гыйлемнең артыклыгына дәлил сорасалар, мин ни әйтергә тиеш?» Ибен Габбас әйтте: «Аларга гыйлем пәйгамбәрләр мирасы, мал исә фиргавеннәрнең мирасы, дип әйт. Гыйлем сине саклый, әмма малны син саклыйсың. Аллаһы Тәгалә гыйлемне сөйгән кешесенә генә бирә, малны исә сөйгәненә дә, сөймәгәненә дә бирер. Бәлки сөймәгәненә күбрәк тә бирәдер. Аллаһы Тәгаләнең сүзен күрмисеңме:

﴿ وَلَوْلَا أَنْ يَكُونَ النَّاسُ أُمَّةً وَاحِدَةً لَجَعَلْنَا لِمَنْ يَكْفُرُ بِالرَّحْمَانِ لِبُيُوتِهِمْ سُقُفًا مِنْ فِضَّةٍ وَمَعَارِجَ عَلَيْهَا يَظْهَرُونَ ﴾

«Әгәр кешеләрнең бай кеферләрне күргән вакытларында барчасы байлык өчен кеферлеккә кызыгулары булмаса иде, Коръәнне инкарь итүче кәферләрнең өйләренә көмештән түбәләр, һәм аның өстенә менәр өчен көмештән баскычлар кылыр идек». (Зухруф: 33)

Гыйлем сарыф итү белән кимеми, мал бирү белән кими. Мал иясе вафат булса, аның зикере киселә, галим кеше вафат булса, аның исеме кала. Мал иясе мәеттер, галим кеше исә үлми, ягъни яхшы исеме үлми. Мал иясенең һәрбер дирһәменнән соралыр: кайдан тапкан һәм кайсы җиргә сарыф иткәне хисап ителер. Гыйлем иясенең исә һәрбер хәдис бәрабәренә җәннәттә бер дәрәҗә булыр».

Гали бине Әбү Талибтән риваять ителде, ул әйтте: «Кешеләр өч төрледер. Бер төре Раббәни галим; икенчесе, котылу юлына таба барырга өйрәнүчеләр. Башкалары исә бугазларына гына

хезмәт итүчеләрдер. Һәрбер кычкыручының иярүчеләре һәм һәрбер җилгә авалар».

Ибен Габбас әйтте: «Гыйлем малдан хәерлерәктер. Гыйлем сине саклый, әмма малны син саклыйсың. Гыйлем сарыф кылу белән матурая, малны сарыф кылу киметә. Замана мәңге булса, галимнәр мәңгеләрдер. Үзләре югалсалар да, мисаллары күңелләрдә каладыр».

Әбү Дәрдәдән риваять ителде, ул әйтте: «Галим белән өйрәнүче әҗердә бертигез. Кешеләр ике бүлектер, яки галимнәр яки шәкертләр. Болардан башкаларында хәер юк».

## Гыйлем белән гамәл кылу турында

عن أنس بن مالك ﷺ قال : قال رسول الله ﷺ : "العلماء أمناء الرسل على عباد الله ما لم يخالطوا السلطان ، ويدخلوا في الدنيا ، فإذا دخلوا في الدنيا ، فقد خانوا الرسل ، فاعتزلوهم واحذروهم".

Әнәс бине Мәлик разыяллаһү ганһүдән риваять ителде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Галимнәр түрәләргә катнашмасалар һәм дөньяга кермәсәләр, Аллаһының бәндәләре өстендә, пәйгамбәрләрнең ышанычлы кешеләредер. Әгәр галимнәр дөньяга керсәләр, тәхкыйк, пәйгамбәрләргә хыянәт иттеләр. Сез ул галимнәрдән башыгызны тартыгыз, алардан сакланыгыз».

Әбү Дәрдә разыяллаһү ганһүдән риваять ителде, ул әйтте: «Өйрәнүче булганга кадәр кеше галим булмый, ягъни укымыйча кеше галим була алмый. Гыйлеме белән гамәл кылганга кадәр кеше галим булмый, ягъни Аллаһы Тәгалә каршында мактаулы, әҗерле галим, Пәйгамбәр варисы булмас».

Әбү Дәрдәдән риваять ителде, ул әйтте: «Белмәгән, надан кешегә бер үкенеч, белеп тә, гамәл итмәгән кешегә җиде мәртәбә үкенечтер».

Янә аңардан риваять ителде, ул әйтте: «Әй Гувәймир, Кыямәт көнендә ни белдең, дип әйтелүдән курыкмыймын. Ләкин Кыямәт көнендә белгәнең белән ни гамәл кылдың, дип әйтелүдән куркамын».

Гайсә галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул әйтте: «Берәү белсә һәм белгәне белән гамәл кылса һәм гыйлемен өйрәтсә, күк йөзендә олуг, дип аталыр».

Гомәр бине Хаттабтан риваять ителде, ул Габдулла бине Сәләмгә әйтте: «Галим кешеләр кемнәр?» Габдулла әйтте: «Гыйлем белән гамәл кылган кешеләр». Гомәр әйтте: «Кешеләрнең күкрәкләреннән гыйлемне нәрсә ала?» Әйтте: «Тамгъ, ягъни хаксыз кешедән өмет итү гыйлемне ала».

Гайсә галәйһиссәләм әйтте: «Сукырның шәмне тотып, башкалар өчен яктыртуы сукырга ни файда бирә? Тышкы якта шәмнең булуы караңгы өйгә ни файда бирә? Үзегез гамәл кылмагач, гыйлемне кешегә сөйләвегез ни файда бирер?»

Янә Гайсә галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул әйтте: «Агачлар бик күп, ләкин барчасы да җимешле түгел. Галимнәр дә бик күп, ләкин барчасы да тугры юлга күндерүче түгел. Җимешләр бик күп булса да, барчасы да яхшы түгел. Галимнәр дөньяда ни күп, барысы да файдалы түгел».

Әүзәгыйдән риваять ителде, ул әйтте: «Кем дә кем белгәне белән гамәл кылса, белмәгәненә ирешер».

Сәһел әйтте: «Галимнәрдән башка кешеләр – мәетләрдер. Гыйлеме белән гамәл кылучылардан башка галимнәр барысы да исерекләрдер. Ихлас-

лыларыннан башкалар гамәлләрдә алданган кешеләр. Ихласлылары да курку хозурындадыр».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "لا تجلسوا عند كل عالم إلا الذي يدعوكم من الخمس إلى الخمس : من الشك إلى اليقين ، ومن التكبر إلى التواضع ، ومن العداوة إلى النصيحة ، ومن الرياء إلى الإخلاص ، ومن الرغبة إلى الزهد".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул әйтте: «Һәрбер галим янында утырмагыз, мәгәр биш төрле нәрсәдән чыгарга һәм биш төрле нәрсәгә керергә өндәгән галим янына гына утырыгыз. Шиктән якыйнга (шиксезлеккә), тәкәбберлектән түбәнчелеккә, дошманлыктан дуслыкка, риядан ихласка, дөньяга кызыгудан дөнья ташлауга, ягъни хаксыз нәрсәгә катнашудан хаклы нәрсә белән генә шөгыльләнүгә өндәүчеләр янына гына утырыгыз».

Гали бине Әбү Талибтән риваять ителде. Ул әйтте: «Әгәр галим кеше гыйлеме белән гамәл кылмаса, надан кеше аннан гыйлем өйрәнүгә чиркәнер, чөнки галим кеше гыйлеме белән гамәл итмәсә, гыйлеме үзенә дә, башкаларга да файда бирмәс. Гәрчә ул галим гыйлемне бик күп җыйса да, чөнки безгә бу хәбәр ирешге: Бәни Исраилдән бер кеше сиксән сандык гыйлем җыйган иде. Аллаһы Тәгалә бер пәйгамбәргә боерды: «Бу хәкимгә әйт, шуның янына тагы бер өлеш җыйсаң да ул гыйлем белән файдаланмассың, мәгәр ошбу өч төрле нәрсәне эшләсәң генә файдаланырсың. Әүвәлгесе, бу дөньяны сөймәсәң, чөнки дөнья мөэминнәр йорты түгедер. Икенчесе, шайтанга иптәш булмасаң, чөнки шайтан мөэминнәргә иптәш түгел. Өченчесе, мөэминнәрне рәнҗетмәсәң, чөнки аларны рәнҗетү мөэминнәрнең һөнәре түгелдер».

Суфьян бине Гуйәйнә әйтте: «Адәмнәргә наданлык күркәм түгел. Кем дә кем гыйлеме белән гамәл кылса, ул кеше адәмнәрнең иң галимрәгедер. Кем дә кем гыйлеме белән гамәл кылмаса, ул кеше надандыр». Суфьян әйтте: «Әйтелә иде: «Галимнең бер гөнаһысы ярлыканмаганда, надан кешенең җитмеш гөнаһысы ярлыканыр», – дип».

Хәбәрләрдә килә: «Фәрештәләр өч нәрсәдән гаҗәпләнерләр: үзе кылмаганын кешеләргә сөйли торган фасикъ галимнән; известь һәм кирпич белән бина ителгән фасикъның кабереннән һәм гөнаһлы кешенең җәназасы хозурындагы бизәктән».

Әйтелде: «Кыямәт көнендә өч төрле кешегә хәсрәтнең иң катысыдыр: дөньяда вакытта изге колы яки кәнизәге булып, ул кол җәннәткә керер, үзе исә тәмугка ташланыр. Икенчесе, мал җыеп, Аллаһы Тәгаләнең фарыз кылган хакларын үтәмичә вафат булыр. Варислары ул малны Аллаһы Тәгаләнең гыйбадәтенә сарыф итерләр һәм шуның сәбәпле уңышка ирешерләр, тәмугтан котылырлар. Ә малны җыйган кеше тәмугта калыр. Өченчесе, гыйлем өйрәтүче явыз галим, кешеләр аның гыйлеме сәбәпле котылу табарлар. Үзе исә тәмугка китәр».

Бер кеше Хәсән Басрига әйтте: «Безнең галимнәребез шулай әйтәләр», – дип. Хәсән әйтте: «Минем һич галим кеше күргәнем юк. Фәкыйһ шул була – дөньядан харислыгын кискән һәм ахирәткә кызыгучы булыр, үз гөнаһысын үзе күрер, Раббының гыйбадәтенә даимчылык кылыр».

Әйтелде: «Әгәр галимнәр хәләл җыю белән мәшгуль булсалар, гомуми халык шөбһә ашаучылар булып калырлар. Әгәр галимнәр шөбһә ашаучы булса, барча халык хәрам ашаучы булып калырлар.

Әгәр галимнәр хәрам ашаучы булып китсәләр, барча халык кәферләр булырлар».

Фәкыйһ әйтте: «Чөнки галимнәр хәләлне җыйсалар, барча халык аларга иярер. Яхшылап белмәүләреннән шөбһәгә төшәләр. Әмма галимнәр шөбһәле нәрсәдән алып, хәрамнан саклансалар, аларга наданнар иярерләр. Алар шөбһә белән хәрам арасын аерә белмиләр, шул сәбәпле хәрамга төшәрләр. Әмма галимнәр хәрамнан алсалар, наданнар аларга ияреп, хәрам нәрсәне – хәләл дип белерләр. Һәм хәрамны хәләлгә санаулары сәбәпле кәфер булырлар».

Әйтелде: Кыямәт көне җиткәч, наданнар галимнәргә ябышырлар. «Сез белдегез, ни өчен безне димләдегез, безне тыймадыгыз, хәтта без кылганыбызны кылдык», – диярләр.

وعن النبي ﷺ أنه سئل : أي الناس شر؟ قال : "عالم إذا فسد".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде. Аңардан: «Кешеләрнең кайсылары явызлар?» – дип сорадылар. Ул: «Әгәр бозык булса, галим иң явыз кеше», – дип җавап бирде.

Әйтелде: «Галим бозык булса, аның бозыклыгы сәбәпле галәм бозык булыр».

Бәшир бине Хәристән риваять ителде, ул хәдис иярәренә: «Бу хәдисләрнең зәкәтен бирегез», – дип әйтә иде. Әйттеләр: «Ул хәдисләрнең зәкәтен ничек бирик?» Бәшир әйтте: «Һәрбер ике йөз хәдистән биш хәдис белән гамәл кылыгыз».

Галимнәрдән кайберәүләре әйтте: «Безнең заманыбызда гыйлем өйрәнү шикләнүгә сәбәптер. Ул гыйлемне тыңлау иялешүдер. Ул гыйлем өйрәтү нәфес теләге. Ул гыйлем белән гамәл кылу нәфесне

тышка чыгарудыр, ягъни гыйлем пәрдәсенә ябынып, кабәхәтлекне кылыр».

وروى عن النبي ﷺ أنه قال : "من تعلم لأربع دخل النار : ليباهي به العلماء ، أو يماري به الشفهاء ، أو يقبل به زجزه الناس إليه ، أو يأخذ به من الأمراء المار والحرمة والجاه والمنزلة".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул әйтте: «Кем дә кем гыйлемне дүрт төрле нәрсә өчен өйрәнсә, тәмугка керер: гыйлеме белән галимнәргә мактану өчен, яки ахмакларга тәкәбберләнү өчен, яки халыкны үзенә карату өчен, яки ул гыйлем белән түрәләрдән мал, хөрмәт һәм дәрәҗә алыр өчен өйрәнүдер».

Суфьян әйтте: «Гыйлемнең башы тик тору, икенчесе – тыңлау, өченчесе – гыйлемне ятлау, дүртенчесе – ул гыйлем белән гамәл кылу, бишенчесе – ул гамәлне тарату, ягъни кешеләргә өйрәтү».

Әйтелде: «Галимнәр өч төрле: Аллаһыны һәм Аллаһының әмерен белүче; Аллаһыны белеп, Аның әмерен белмәүче һәм Аллаһының әмерен белеп, Аллаһыны белмәүче».

Әмма Аллаһыны һәм Аның әмерен белүче кеше шулдыр ки, Аллаһыдан куркыр һәм Аллаһы Тәгаләнең чикләрен һәм фарызларын белер. Әмма Аллаһыны белеп тә, Аның әмерләрен белмәүче шулдыр ки, Аллаһыдан куркыр, ләкин Аллаһы Тәгаләнең чикләрен һәм фарызларын белмәс. Әмма Аллаһының әмерен белеп, Аллаһыны белмәүче кеше шулдыр ки, чикләрне һәм фарызларны белер, ләкин Аллаһыдан курыкмас».

Фәкыйһ иснәде белән Әбү Хафсәдән риваять итте: «Галимгә ун төрле нәрсә ләземдер: уйлау, Аллаһыдан курку, хәерне теләү, шәфкать кылу,

мәшәкать йөкләү, түзү, йомшаклык, кешеләрнең малларын теләмәү, даими китапларга карау, гыйлем алганда оялмау, олуг һәм кечкенәләргә ишеге ачык булу. Чөнки безгә риваять беләң ирешите, Давыд галәйһиссәләм бик оялчан булуда бәлаләнде».

Әбү Хафс әйтте: «Ун төрле нәрсә кешеләрнең ун төрлесендә начар сыйфаттыр: патшаларда катылык, байларда саранлык, галимнәрдә теләк, ягъни хаксыз кешедән мал, ризык көтү, фәкыйрьләрдә хирыслык, мәртәбә ияләрендә оятның аз булуы, картларда яшьләр акылы булуы, ирләрнең хатыннарга охшавы, хатыннарның ирләргә охшарга тырышуы, заһидләрнең дөньяга комсыз булган кешеләрнең ишекләренә килүе, гыйбадәттә наданлык».

Фудаил әйтте: «Әгәр галим кеше дөньяга комсыз булса, ул галимгә утырдаш булу җаһилнең җаһиллеген, гөнаһлының гөнаһын арттыра, мөэмин кешенең күңелен каралта».

Хәкимнәрнең кайберәүләре әйттә: «Хәкимнәрнең сүзе ахмакларга буш сүз була. Ахмакларның сүзләре хәкимнәргә гыйбрәт була».

Фәкыйһ әйтте: «Ахмак кешеләр хәкимнәрнең сүзләрен ишетсәләр, аларның сүзләрен кызыкка санарлар. Һәм ул сүз ахмаклар өчен уен булыр. Әмма хәкимнәр ахмакларның сүзләрен ишетсәләр, ошбу сүзнең начарлыгын сизәрләр дә, бу сүз белән гыйбрәтләнәләр. Ошбуның охшашыннан сакланырлар. Ахмакларның тырышлыгы бары тик тыңлауда гына. Галимнәрнең тырышлыгы риваять кылу. Заһидләрнең тырышлыгы саклау. Ягъни ул сүздә булган файдаларны алып, алар белән гамәл кылалар».

## Гыйлем ияләре белән утыруның фазыйләте

عن أبي واقد الليثي أن رسول الله ﷺ بينما هو جالس والناس معه إذ أقبل ثلاثة نفر ، فأما أحدهم فرأى فرجة في الحلقة فجلس إليها ، وأما الآخر فجلس خلفهم ، وأما الثالث فأدبر ذاهبا ، فلما فرغ رسول الله ﷺ من كلامه قال : "ألا أخبركم عن النفر الثلاثة ؟ فأما الأول فآوى إلى الله فآواه الله ، وأما الثاني فاستحي من الله أن يؤذي الناس فاستحي الله منه ، وأما الثالث فأعرض فأعرض الله عنه".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Вәкыйд әл-Ләйсидән риваять итте. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм сәхабәләре белән утырып торган вакытта мәчеткә өч кеше керде. Берсе түгәрәк мәҗлестә урын табып, шунда утырды. Икенчесе кешеләр артына утырды. Әмма өченчесе чыгып китте. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм үзенең сүзеннән бушагач, әйтте: «Сезгә бу өч кешенең хәленнән хәбәр биримме? Беренчесе, Аллаһының рәхмәтенә керде, Аллаһы Тәгалә аны рәхмәтенә кертсен иде. Икенчесе, кешеләрне рәнҗетүдән Аллаһыдан оялды, Аллаһы Тәгалә аны газап итәргә оялса иде. Өченчесе, Аллаһыдан йөзен алды, Аллаһы Тәгалә дә аннан йөзен алса иде».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Шәһр бине Хәүшәбтән риваять итте, ул әйтте: «Локман Хәким үзенең улына әйтте: «Әй улым, әгәр син Аллаһының зикерен әйтә торган халык күрсәң, алар белән син дә утыр. Чөнки әгәр син галим булсаң, гыйлемең сиңа файда бирер, әгәр надан булсаң, алар сине өйрәтерләр. Шаять, Аллаһы Тәгалә аларга рәхмәтен иңдерер һәм ул рәхмәт алар белән сиңа да ирешер. Әгәр син Аллаһыны зекер кылмый торган халыкны

күрсәң, алар белән утырма. Чөнки син галим булсаң, гыйлемең сиңа файда бирмәс. Әгәр надан булсаң, сиңа гөнаһны гына арттырыр. Шаять, Аллаһы Тәгалә аларга ачуын иңдерер, сиңа да шулар белән утыруың сәбәпле ачуы ирешер».

عن أبي سعيد الخدري ﷺ أن النبي ﷺ قال : "إن الله تعالى ملائكة سياحين في الأرض ، فإذا وجدوا قوما يذكرون الله تعالى تنادوا وقالوا : هلموا إلى بغيتكم ، فيجيءون فيحفون بهم ، فإذا صعدوا إلى السماء فيقول الله تعالى : على أي شيء تركتم عبادي يصنعون ؟ وهو أعلم بهم ، قالوا : تركناهم يحمدونك ، ويسبحونك ، ويذكرونك ، فيقول : فأي شيء يطلبون ؟ فيقولون : الجنة ، فيقول الله عز وجل : هل رأوها ؟ فيقولون : لا ، فيقول : كيف لو رأوها ؟ فيقولون: لو راوها لكانوا أشد لها طلبا ، وأشد عليها حرصا ، فيقول : من أي شيء يتعوذون ؟ فيقولون: يتعوذون من النار ، فيقول الله تعالى : هل راوها فيقولون: لا ، فيقول : لو رأوها لكانوا أشد منها هربا ، أشد منها خوفا ، فيقول : إلي أشهدكم يا ملائكتي أني قد غفرت لهم ، فيقولون : إن فيهم فلانا الخاطئ لم يردهم ، وإنما جاءهم لحاجة ، فيقول : هم القوم لا يشقى بهم حليسا".

Әбү Сәгыйд Худрийдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең җирдә сәяхәт кыла торган фәрештәләре бар. Әгәр Аллаһыны зекер итә торган халыкны тапсалар, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итәрләр. Әгәр фәрештәләр күккә ашсалар, Аллаһы Тәгалә аларга әйтер: «Минем бәндәләрем нәрсә кыла калдылар?» Хәлбуки, Аллаһы Тәгалә үзе ул бәндәләрне бигрәк тә белә. Фәрештәләр әйтерләр: «Әй безнең Раббыбыз, Без аларны Сине зекер кылганнары һәм Сиңа тәсбих

һәм хәмед әйткән хәлдә калдырдык». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Ни-нәрсә телиләр?» Фәрештәләр әйтерләр: «Җәннәтне телиләр». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Ул җәннәтне күргәннәрме соң?» Фәрештәләр әйтерләр: «Юк, күрмәгәннәр». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әгәр күрсәләр, ни эшләрләр иде?» Фәрештәләр әйтерләр: «Әгәр җәннәтне күрсәләр, бигрәк тә теләрләр һәм бигрәк тә омтылырлар иде». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Ни нәрсәдән сыгыналар?» Фәрештәләр әйтерләр: «Уттан бик сыгыналар». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Җәһәннәмне күргәннәре бармы соң?» Фәрештәләр әйтерләр: «Юк, күргәннәре юк». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әгәр күрсәләр ни эшләрләр иде?» Фә-рештәләр әйтерләр: «Әгәр утны күрсәләр бигрәк тә качарлар иде һәм аннан бигрәк тә куркырлар иде». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй фәрештәләр, Мин сезне шаһид кыламын ки, тәхкыйк, Мин аларны ярлыкадым». Фәрештәләр: «Алар арасында фәлән гөнаһлы бар, ул кеше аларны теләми, бары тик йомышы өчен генә алар янына килгән», – дип әйтерләр. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Алар шундый халыктыр, аларның мәҗлестәшләре яман кеше булмыйдыр».

Габдулла бине Мәсгуд әйтте: «Изге кешеләр белән утыруның мисалы җәфәр таккан кешенең мисалы кебек. Әгәр җәфәрне бирмәсә дә, сиңа аның исе ирешер. Яман кеше белән утыру тимерче кебек. Киемеңне яндырмаса да, төтен исе сиңа ирешер».

Кәгъб Әхбәрдән риваять ителде, ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә ике сүзне язды, халыкны яратканга кадәр аларны Гареш астына куйды, аларны фәрештәләргә белдермәде. Мин ул ике сүзне беләм». «Әй Әбү Исхак, аларниләр?» – дип сорадылар. Кәгъб әйтте: «Ул икенең берсе, Аллаһы Тәгалә язды: берәү фасикълар белән утырганнан соң бөтен

яхшыларның гамәлләрен кылса да, Мин аның гамәлен гөнаһ итеп язармын. Кыямәт көнендә аны фасикълар белән кубарырмын. Икенче сүзе: изге һәм яхшылар белән утыра торган кеше бөтен явызларның гамәлләрен кылса да, шул изгеләрне сөйсә, Мин аның явызлыкларын изгелекләр кылырмын. Кыямәт көнендә аны яхшылар белән кубарырмын».

Фәкыйһ әйтте: «Әйтелде: «Кем дә кем галим кеше янына килеп утырса, гыйлемне күңеленә ала алмаса да, аңа җиде төрле әҗер булыр: шәкертләр әҗере ирешер; галим янында торган вакытта гөнаһлардан котылып торыр; өеннән шул галим янына дип чыкса, аңа рәхмәт ирешер; тыңлаган вакытта аңа изгелек язылыр; фәрештәләр риза булулары сәбәпле галимнәрне канатлары белән чолгарлар, ул кеше дә шулар арасында булыр; һәрбер аяк адымы аның гөнаһларына кәффарәт булыр; дәрәҗәсе күтәрелер һәм изгелекләренә арттыру булыр. Моннан соң Аллаһы Тәгалә аны янә икенче алты төрле кәрамәт белән хөрмәтләр. Галимнәр мәҗлесендә булуын сөю белән хөрмәтләр. Ул галимнәргә ияручеләрнең һәрберсенә ул галимнәрнең әҗереннән һич кимсез аларның әҗере охшашлы әҗерләр булыр. Әгәр ул галимнәрнең берсе ярлыканса, ул галим бу кешегә дә шәфәгать кылыр. Аның күңеле фасикълар мәҗлесеннән суыныр. Ул кешеләр шәкетләр һәм изгеләр юлына керерләр. Аллаһының әмерен юлына китергән булырлар, чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ كُونُوا رَبَّانِيِّينَ بِمَا كُنتُمْ تُعَلِّمُونَ الْكِتَابَ ﴾

«Аллаһы Тәгаләнең китабын белүегез белән Раббани галимнәр булыгыз». (Әли Гыймран: 79) Ягъни, галимнәр һәм фәкыйһләр булыгыз. Бу кадәр

әҗергә һичнәрсә ятламаган кеше ирешә. Әмма ятлаган кешегә ничә өлешләр артык булыр».

Хәкимнәрнең кайберәүләре әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең дөньяда җәннәте бар. Кем дә кем бу җәннәткә керсә, аның тормышы хуш булыр». «Ул җәннәт нәрсә ул?» – дип сорадылар. «Зикер мәҗлесе», – диде.

وعن النبي ﷺ أنه قال : "المجلس الصالح يكفر عن المؤمن ألفي ألف مجلس من مجالس السوء".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде. Ул әйтте: «Бер яхшы мәҗлес яхшы мөэминнең ике җирдә мең-мең яман мәҗлесенә кәффарәт булыр».

Гомәр бине Хаттабтан риваять ителде. Ул әйтте: «Дөреслектә, кеше урыннан чыгар. Хәлбуки ул кешенең өстендә тәһәмә таулары кадәр гөнаһлары булып, ул гыйлемне ишетеп курыкса һәм гөнаһлардан кайтуны теләсә һәм ул кеше урынына кайтса, аның хозурында һич гөнаһ булмас. Сез галимнәр мәҗлесеннән аерылмагыз. Чөнки Аллаһы Тәгалә җир йөзендә галимнәр мәҗлесеннән хөрмәтлерәк һичбер кисәкне яратмады».

Хәмид Әнәс бине Мәликтән риваять итте. Ул әйтте: «Бер кеше Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә килеп: «Кыямәт көне кайчан була?» – дип сорады. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Мин аның вакытын санаганым юк». Әйтте: «Бел, мин Аллаһыны һәм Аның Рәсүлен сөямен». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кеше сөйгәне белән һәм син дә сөйгәнең белән булырсың». Әнәс әйтте: «Мөселманнарның бу сүзгә шатланганнары кебек һичбер нәрсәгә шатланганнарын күргәнем юк».

Ибен Мәсгудтән риваять ителде, ул әйтте: «Өч төрле нәрсәне мин хак дип әйтәмен. Аллаһы Тәгалә

бәндәгә вәли булмаса, Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә башкага вәли булыр. Исламда өлеше булмаган кеше, аның һич өлеш булмаган кеше кебектер. Бәндә үзе сөйгән кеше беләндер. Әгәр ул нәрсәгә ант итсәм дә, дөрес әйтәмен, антымны бозучы булмам. Әгәр Аллаһы Тәгалә бәндәгә дөньяда бер нәрсәне капласа, Кыямәт көнендә дә капламый булмас».

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде, ул базарга керде һәм андагы кешеләргә әйтте: «Сез монда икәнсез, ә Мөхәммәд галәйһиссәләмнең мирасы мәчеттә бүленә». Кешеләр мәчеткә киттеләр, базарны калдырдылар, соңыннан әйләнеп кайттылар. Әйттеләр: «Әй Әбү Һөрәйрә, без бүленә торган мирас күрмәдек». Әбү Һөрәйрә: «Нәрсә күрдегез?» – дип сорады. Әйттеләр: «Без тик Аллаһыны зекер кыла торган һәм Коръән укый торган халыкны гына күрдек». Әбү Һөрәйрә әйтте: «Алайса шул инде Мөхәммәд галәйһиссәләмнең мирасы».

Галкамә бине Кайстән риваять ителде, ул әйтте: «Миңа Аллаһы Тәгаләнең боерыклары хакында мин сорый торган, яисә алар миннән сорый торган халык эчендә булуым, Аллаһы юлына ат йөкләп чыгаруымнан артыграктыр».

وروى عن النبي ﷺ أنه قال : "ما جلس قوم يذكرون الله تعالى إلا ناداهم مناد من السماء : قوموا فقد بدلت شيئاتكم حسنات ، وغفرت لكم جميعا ، وما قعدت عدة من أهل الأرض يذكرون الله تعالى إلا قعدت معهم عدتهم من الملائكة".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул әйтте: «Халык Аллаһы Тәгаләне зекер кылырга утырды исә, күктән бер кычкыручы: «Торыгыз,

тәхкыйк, сезнең явызлыкларыгыз изгелекләргә алмаштырылды, барчагызның гөнаһлары ярлыкандыы», – дип кычкырыр. Җирдә никадәр халык булса, Аллаһы Тәгаләне зекер кылырга утыручылар янына шуның чаклы фәрештәләр утырырлар».

Шәкыйкъ әйтте: «Минем мәҗлесемнән кешеләр өч төрле булып торырлар. Бер төрлесе – чын кәфер, икенчесе – чын монафыйк һәм өченчесе – чын мөэминдер. Чөнки Коръәнне тәфсир кыламын. Аллаһы Тәгаләдән һәм Аның Рәсүленнән хикәят итеп әйтәмен: «Кем дә кем миңа ышанмаса, ул кеше – чын кәфердер. Кем дә кемнең мин әйткәнгә күңеле тарайса, ул кеше – чын монафыйктыр. Кем дә кем эшләгән эшенә үкенсә, һәм моннан соң гөнаһ кылмаска ният итсә, ул кеше – чын мөэмин».

Фәкыйһ әйтте: «Әйтелде: «Берәү кешеләрнең сигез төрлесе белән утырса, ул кешегә Аллаһы Тәгалә сигез төрле нәрсәне арттырыр. Кем дә кем байлар белән утырса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә дөнья сөюне һәм дөньяга кызыгуны арттырыр. Кем дә кем фәкыйрьләр белән утырса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә шөкранә, Аллаһының биргән өлешенә риза булуны арттырыр. Кем дә кем түрә белән утырса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә тәкәбберлекне һәм күңел каралыгын арттырыр. Кем дә кем хатыннар белән утырса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә наданлык, шәһвәтне һәм аларның акылларына омтылуны арттырыр. Кем дә кем фасикълар белән утырса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә тәүбә кылуда соңга калуны арттырыр. Кем дә кем балалар белән утырса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә уен һәм шаяртуны арттырыр. Кем дә кем изгеләр белән утырса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә гыйбадәт кылуга омтылуны һәм хәрамнәрдән саклануны арттырыр. Кем дә кем

галимнәр белән утырса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә гыйлемне һәм тәкъвалыкны арттырыр».

Әйтелде: «Аллаһы Тәгалә йокының һәм көлкенең өч төрлесенә ачуланыр: зекер мәҗлесендә, иртә намазыннан соң һәм ястүдән элек йокыга һәм иртә намаз вакытында йоклауга ачулана. Җәназа артында, зекер мәҗлесендә һәм каберләр янында көлүгә ачулана».

Әбү Яхъя Вәррак әйтте: «Кайгылар дүрт төрледер: тәкбир тәхримәнең үтүе, ягъни имам тәкбиренә өлгермәү, зекер мәҗлесенең үтүе, сугыш вакытында дошманга очрауның үтүе, хаҗ вакытында Гарафәт тавында торуның үтүе, ягъни хаҗга чыкса, һәм аннан хаҗы үтсә».

Әйтелде: «Галимнәр белән утыру динне ислах кылу, тәнгә зиннәттер. Фасикълар белән утыру дингә җәрәхәт, тәнгә хурлыктыр».

وروى عن النبي ﷺ أنه قال : "النظر في وجه الوالد عبادة ، والنظر في الكعبة عبادة ، والنظر في المصحف عبادة".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде. Ул әйтте: «Галим йөзенә карау гыйбадәттер, Кәгъбәгә карау да гыйбадәттер һәм Коръәнгә карау да гыйбадәттер».

Фәкыйһ әйтте: «Галимнең йөзенә караудан башка гыйлем мәҗлесендә файда булмаса да, шул мәҗлескә омтылу акыллы кешегә ваҗиб булыр иде. Ничек ваҗиб булмасын, Пәйгамбәр галәйһиссәләм галимне үз урынына куйды һәм әйтте: «Кем дә кем галим кешене күрергә барса, тәхкыйк, мине күрергә килде. Кем дә кем галим белән күрешсә, тәхкыйк, ул кеше минем белән күреште. Кем дә кем галим белән утырса, тәхкыйк, минем белән утырды. Кем дә кем

минем белән дөньяда утырса, ул кешене Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә минем белән утыртыр».

Хәсән Басридән риваять ителде, ул әйтте: «Галимнәрнең мисалы йолдызлар кебектер. Әгәр йолдызлар чыксалар, юлчылар алар сәбәпле юлга күнерләр. Әгәр ул йолдызлар капланса, хайран булырлар, кая баруны белмәсләр. Галимнең үлүе Исламда сыныклыктыр. Ул сыныклыкны кич һәм көндез бере артыннан бере килә торганда һичнәрсә биләмидер».

## Шөкер кылу

عن أنس بن مالك ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "إن الله تعالى ليرضى عن العبد أن يأكل الأكلة أو يشرب الشربة فيحمده عليها".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әнәс бине Мәликтән, ул Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә. Ул әйтте: «Әгәр бәндә бер ашамлык ашап, яки бер эчемлек эчеп, Аллаһы Тәгаләгә хәмед әйтсә, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә аңардан разый булыр».

عن أسماء بنت زيد ، قالت سمعت رسول الله ﷺ يقول : "إذا جمع الله الأولين والآخرين يجيء مناد فينادي بصوت يسمعه الخلائق : سيعلم أهل الجمع اليوم من أولى بالكرم ، ليقم الذين تتجافي جنوبهم عن المضاجع ، فيقومون وهم قليل ، ثم ينادي : ليقم الذين كانت لا تلهيهم تجارة ولا بيع عن ذكر الله ، فيقومون وهم قليل ، ثم ينادي : ليقم الذين كانوا يحمدون الله تعالى في السراء والضراء ، فيقومون وهم قليل ، ثم يحاسب سائر الناس".

Әсма бинтү Язидтән риваять ителде. Рәсүлуллаһтан ишеттем ди, ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә

беренчеләр белән соңгыларны җыйса, ягъни Кыямәт көне булса, бер кычкыручы килер, халык ишетә торган тавыш белән кычкырыр: «Бу көнне җыелган халык хөрмәткә кем лаек икәнен тиз белер? Урыннардан кабыргалары буш булган кешеләр, ягъни төнлә аз йоклаган кешеләр торсын». Һәм алар торырлар, ләкин алар аздыр. Моннан соң тагын чакырылырлар. «Сәүдә һәм сатулары аларны Аллаһының зикереннән алмаган кешеләр, ягъни сәүдә сылтавы белән гыйбадәткә кимчелек китермәгән кешеләр торсыннар». Алар да торырлар, мәгәр алар аздыр. «Киңлек вакытында да, тарлыкта да Аллаһы Тәгаләгә хәмед әйтә торган кешеләр торсыннар», – дип чакырырлар. Алар торырлар, мәгәр алар аздыр. Соңыннан башка халык хисап ителә башлар».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Хәсәннән риваять итте. Ул әйтте: «Муса галәйһиссәләм Раббысына әйтте: «Әй Раббым, Үз кодрәт кулың белән ясаган кыяфәтенең шөкерен үтәүгә Адәм галәйһиссәләмнең ничек көче җитте? Ул Адәмгә Үзенең рухыңнан өрдең һәм аны оҗмахка җирләштердең, фәрештәләргә аңа сәҗдә итәргә боердың». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй Муса, боларның Миннән икәнен Адәм белде, шуның бәрабәренә Миңа хәмед әйтте. Ошбу хәмед әйтүе Минем аңа эшләгәнем өчен шөкер булды».

وروى عن سعيد بن قتادة أن النبي ﷺ قال : "أربع من أعطيهن فقد اعطى خيري الدنيا والأخرة : لسان ذاكر ، وقلب شاكر ، وبدن صابر ، وزوجة مؤمنة صالحة".

Сәгыйд Котәдәдән риваять итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Дүрт төрле нәрсә бардыр ки, кемгә шул дүрт нәрсә бирелгән булса, дөнья һәм

ахирәтнең изгелеге бирелгән булыр. Беренчесе, зекер итүче тел. Икенчесе, шөкер итүче йөрәк. Өченчесе, түзүче тән. Дүртенчесе, изге һәм иманлы хатындыр».

Әйтелде: «Давыд галәйһиссәләмнең догалары җөмләсеннән шул дога булды: «Әй Аллаһым, мин Синнән дүрт нәрсәне сорыйм һәм дүрт нәрсәдән сыгынамын. Мин сораганы: зекер итүче тел, шөкер итүче күңел, түзүче тән, дөньяда да, ахирәттә дә миңа ярдәм итүче хатын. Мин сыгына торган нәрсәләр: минем өчен хуҗа була торган баладан, картлык вакыты җитмәстән элек мине картайта торган хатыннан, минем өчен вәбәл була торган малдан һәм миннән изгелек күрсә, аны яшерә, начарлык күрсә, кешегә сөйли торган күршедән сыгынамын».

Мугавия бине Әбү Суфьяннан риваять ителде. Ул мәҗлестәш кешеләренә әйтте: «Сез уйлаганча тынычлык нәрсә ул?» Алардан һәрберсе берәр сүз әйттеләр. Мугавия әйтте: «Кеше өчен тынычлык дүрт нәрсәдер: кирәк булган өй, җитәрлек тереклек, аны риза кыла торган хатын һәм без белмәгән кешене рәнҗетмәвебез. Ягъни патшаның белмәгән кешесен рәнҗетүе». Чөнки Мугавия хәлифә һәм солтан булганлыктан, бу аның өчен мөһим нәрсә иде.

Суфьян Сәүри әйтте: «Ике нигъмәт бардыр ки, әгәр ул ике нигъмәтне Аллаһы Тәгалә сиңа бирсә, шуның өчен Аллаһыга хәмед әйт, Аңа шөкер ит. Туры ишегенә барудан саклануың – берсе, табиб ишеге янына бармавың – икенчеседер».

Бәкер бине Габдулладан риваять ителде, ул әйтте: «Кем дә кем мөселман булып, тән сәламәтлек хозурында булса, дөнья һәм ахирәт нигъмәтләренең олугысы ул кешедә җыелды. Дөнья

нигъмәтләренең сәйийде (хуҗасы) сәламәтлек. Ахирәт нигъмәтләренең олугысы Ислам динедер».

وعن ابن عباس ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "نعمتان معبود فيهما كثير من الناس : الصحة والفراغ".

Ибен Габбас Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән риваять итте. Ул әйтте: «Ике нигъмәт бардыр, ул нигъмәтләр хакында кешеләрнең күбесе алдана. Ул ике нигъмәт сәламәтлек белән тынычлыктыр».

Тәбигыйннәрдән кайберәүләреннән риваять ителде, әйтте: «Кем дә кемгә нигъмәтләр җыелса, «әлхәмдүлилләһ» зикерен күп кылсын. Кем дә кемнең кайгысы күп булса, аңа истигъфар кылу лязем булсын. Кем дә кемне фәкырьлек йөдәтсә, «лә хәүлә вә лә күввәтә иллә билләһил-галийййүл-газыйм»не күп әйтсен».

وروى عن النبي ﷺ أنه قال : "إذا كان في الطعام أربعة فقد كمل شأنه كله : إذا كان من حلال ، وإذا أكل ذكر اسم الله عليه ، ثم تكثر عليه الأيدي ، وإذا فرغ منه حمد الله".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде. Ул әйтте: «Әгәр ашамлыкта дүрт нәрсә булса, тәхкыйк, ул кешенең һәр теләге тәмам булды: әгәр аның ашамлыгы хәләлдән булса, ашар алдыннан «бисмилләһ» әйтсә, соңыннан ул ашамлык өчен куллар күбәйсә һәм ашаганнан соң «әлхәмдүлилләһ», дип әйтсә».

وروى الحسن عن النبي ﷺ انه قال : "ما أنعم الله على عبد من نعمة صغرت أو كبرت ، فقال : الحمد لله إلا كان قد أعطى أفضل مما أخذ".

Хәсән Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте. Ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә бәндәгә кечкенә яки

зур нигъмәт биргәч, бәндә «әлхәмдүлилләһ» дип әйтсә, бәндә алган кадерледән артыгы бирелер».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "عجبت لأمر المؤمن ، أمر كله خير له ، إن أصابه خير فشكر كان خيرا له ، وإن أصابه شر فصبر كان خيرا له".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул әйтте: «Мөэмин кешенең хәленә исем китә. Ул мөэминнең һәрбер эше изгедер. Әгәр аңа хәер ирешеп, шөкрана кылса да, яки начарлык ирешеп, сабыр кылса да, аңа хәер буладыр».

Мәкхулдән риваять ителде, ул Аллаһы Тәгаләнең:

﴿ ثُمَّ لَتُسْأَلُنَّ يَوْمَئِذٍ عَنِ النَّعِيمِ ﴾

«Соңыннан ул көндә, ягъни Кыямәт көнендә ул бирелгән нигъмәтләр турында соралыр», – дигән аятьнең мәгънәсе турында соралды. Ул «нәгыйм» (нигъмәтләр) дигән сүзнең тәфсирендә әйтте: «Салкын эчемлек тора торган урыннарның күләгәсе, корсакларның туклыгы, яратылышның матурлыгы, йокының тәме».

Гайсә галәйһиссәләмнән риваять ителде. Көннәрдән бер көнне сәхабәләре янына чыккан иде. Гайсә галәйһиссәләмнең өстендә йон чикмән һәм йон күлмәк һәм башка төрле кием, барысы да йоннан иде. Чәче һәм ике мыегы киселгән хәлдә, ачлыктан төсе үзгәргән һәм елаган хәлдә чыкты, сусызлыктан ике ирене көйгән, ике беләге һәм күкрәгенең йоннары озын. «Әссәләму галәйкүм, Аллаһының рөхсәте белән мин дөньяны үз дәрәҗәсенә куйган кешемен. Ис тә китә торган һәм мактана торган да түгел. Дөньяны түбән санагыз. Әгәр аны фәкыйрь, түбән санасагыз, сезгә дөнья түбән күренер. Дөньяны хур күрегез, сезгә ахирәт йорты хөрмәтле ителер. Дөнья

сезнең өчен хөрмәтле саналып, ахирәтне түбән санамагыз. Чөнки дөнья кәрамәт иясе түгел. Дөнья һәр көн фетнәгә һәм зыянга өнди. Әгәр сез минем мәҗлестәшләрем һәм иптәшләрем булсагыз, күңелегезгә дөньяның дошманлыгын урнаштырыгыз. Әгәр шулай итмәсәгез, сез минем иптәшләрем һәм кардәшләрем түгелсез. Әй Бәни Исраил, мәчетләрне үзегезгә өй ясагыз, каберләрне йорт итегез, кунаклар кебек булыгыз. Күрмисезме, күк йөзендәге кошларны, алар чәчмиләр дә, урмыйлар да. Хәлбуки, Аллаһы Тәгалә аларны ризыкландырадыр. Әй Бәни Исраил, арпа икмәгенең җирдәге борчакларыны ашагыз. Белегез ки, шуның да шөкерен үти алмассыз. Моннан артыкның шөкерен ничек кылырсыз?!», – диде.

Сәгыйд бине Җубәердән риваять ителде, ул әйтте: «Киңлектә һәм тарлыкта Аллаһы Тәгаләгә хәмед әйтүче кеше беренче булып җәннәткә керә».

Фәкыйһ әйтте: «Бел, хәмед белән шөкер әүвәлгеләрнең һәм соңгыларның, фәрештәләрнең, пәйгамбәрләрнең гыйбадәтедер. Әмма пәйгамбәрләрнең гыйбадәте шулдыр ки: Адәм галәйһиссәләм төчкергәч, «әлхәмдүлилләһ», диде. Нух галәйһиссәләмнең халкы батырылгач, үзе һәм үзенең янындагы мөэмин кешеләрне коткаргач, Аллаһы Тәгалә аңа хәмед белән боерды. Аллаһы Тәгалә аңа әйтте:

﴿ فَإِذَا اسْتَوَيْتَ أَنْتَ وَمَنْ مَعَكَ عَلَى الْفُلْكِ فَقُلِ
الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي نَجَّانَا مِنَ الْقَوْمِ الظَّالِمِينَ ﴾

«Әгәр син һәм синең белән көймәдә булган кешеләр корыга утырсагыз, «безне залим халыктан коткарган Аллаһы Тәгаләгә хәмед булсын», дип әйт». (Мөэминүн: 28)

Ибраһим галәйһиссәләм әйтте:

﴿ الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي وَهَبَ لِي عَلَى الْكِبَرِ

إِسْمَاعِيلَ وَإِسْحَاقَ إِنَّ رَبِّي لَسَمِيعُ الدُّعَاءِ ﴾

«Картлыкта миңа Исмәгыйл белән Исхакны бүләк иткән Аллаһыга хәмед булсын. Дөреслектә, минем Раббым, әлбәттә, доганы кабул итәдер». (Ибраһим: 39)

Давыд галәйһиссәләм белән Сөләйман галәйһиссәләм әйтте:

الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي فَضَّلَنَا عَلَى كَثِيرٍ مِنْ عِبَادِهِ الْمُؤْمِنِينَ

«Мөэмин бәндәләренең күбесе арасында безне артык кылган Аллаһы Тәгаләгә хәмед булсын». (Нәмел: 15)

Җәннәт халкы алты урында Аллаһы Тәгаләгә хәмед әйтерләр.

وَامْتَازُوا الْيَوْمَ أَيُّهَا الْمُجْرِمُونَ

Беренчесе, Аллаһы Тәгалә: «Әй гөнаһлы кешеләр, бу көн аерылыгыз»(Ясин: 5), – дип әйткән вакытта җәннәт халкы: «Безне залим кешеләрдән коткарган Аллаһыга хәмед булсын» (Мөэминүн: 28), – дип әйтерләр, ягъни:

الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي نَجَّانَا مِنَ الْقَوْمِ الظَّالِمِينَ

Икенчесе, сираттан үткән вакытта әйтерләр:

الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي أَذْهَبَ عَنَّا الْحَزَنَ إِنَّ رَبَّنَا لَغَفُورٌ شَكُورٌ

«Бездән кайгыны җибәргән Аллаһыга хәмед булсын. Дөреслектә, Раббыбыз гөнаһларны ярлыкаучы һәм шөкерне кабул итүчедер». (Фатыр: 34)

Өченчесе, хәят суы белән госелләнгәч җәннәткә керерләр һәм әйтерләр:

الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْلَا أَنْ هَدَانَا اللَّهُ

«Ошбуга безне күндергән Аллаһыга хәмед булсын. Әгәр безне Аллаһы Тәгалә Үзе күндермәгән булса, без күнмәс идек». (Әгъраф: 43) Дүртенчесе, ул җәннәткә кергән вакытта әйтерләр:

الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي صَدَقَنَا وَعْدَهُ وَأَوْرَثَنَا الْأَرْضَ

«Безгә вәгъдәсен рас кылган һәм җәннәт җирен безгә мирас иткән Аллаһы Тәгаләгә хәмед булсын». (Зүмәр: 74) Бишенчесе, урыннарына карарланган вакытларында әйтерләр:

الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي أَذْهَبَ عَنَّا الْحَزَنَ إِنَّ رَبَّنَا لَغَفُورٌ

شَكُورٌ . الَّذِي أَحَلَّنَا دَارَ الْمُقَامَةِ مِنْ فَضْلِه

«Безләрдән кайгыны җибәргән Аллаһы Тәгаләгә хәмед булсын һәм дөреслектә, безнең Раббыбыз гөнаһларны ярлыкаучы һәм даим торыла торган йортка безне керткән Раббыбыз шөкраналарны кабул итүчедер». «Фатыр: 34, 35» Алтынчысы, ашаудан бушангач әйтерләр:

الْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

«Барча галәмне тәрбия итүче Аллаһыга хәмед булсын». (Фатихә: 2)

Кайбер хәкимнәр әйттеләр: «Дүрт нәрсәнең шөкере белән шөгыльләндем. Мәхлүкатны мең сыйныф итеп яратты. Адәм улларын иң хөрмәтлесе итеп таптым. Мине Адәм балаларыннан кылды. Ирләрне хатыннардан артык кылды, мине дә ирләрдән кылды. Ислам динен башка диннәрдән артык, Аллаһы Тәгаләгә иң сөекле дин дип таптым, мине дә Аллаһы Тәгалә мөселман кылды. Мөхәммәд галәйһиссәләм өммәтен өммәтләрнең иң артыгы дип

таптым, мине дә Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәтеннән кылды».

وروى عن أبي هريرة ﷺ أن النبي ﷺ قال : "إن الله تعالى خلق الخلق حين خلقهم ، وهم أربعة أصناف ، الملائكة ، والجن ، والإنس ، والشياطين ، وجعلهم عشرة أجزاء ، تسعة منهم الملائكة ، وجزء واحد الجن والإنس والشياطين".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде, пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә халыкны яраткан вакытта дүрт сыйныф итеп яратты: фәрештәләр, җеннәр, адәмнәр һәм шайтаннар. Аларны ун өлешкә бүлде. Алардан тугызы фәрештәләр һәм бер өлеше җеннәр һәм адәмнәр».

Әйтелде: халык ун өлештер. Ул уннан тугызы шайтаннар белән җеннәр. Алардан берсе адәмнәрдер. Адәмнәрне йөз егерме биш сыйныф кылды. Шуннан йөзе Йәэҗүҗ-Мәэҗүҗ, Сәтүҗ, Мәлук исемле халыклардыр. Һәрберсе кәферләр, бара торган урыннары тәмугтыр. Егерме бише исә башка халыклар. Болардан унике өлеше рум, сәкләбә һәм моңа охшашлар. Алтысы мәгриб тарафындагы зат, хәбәш һәм моңа охшашлылардыр. Алтысы мәшрикъ тарафындадыр, төрек, хакан һәм моңа охшашлылардыр. Боларның һәркайсысы тәмугтадыр. Мәгәр мөселман булган кеше генә тәмугта булмас. Йөз егерме биш сыйныфтан бары мөселманнар сыйныфы, бер генә сыйныф калды. Һәрбер мөэмин булган кешегә Аллаһы Тәгаләгә хәмед әйтү, нигъмәтне белү, Аллаһы Тәгалә аны халык арасында сайлаулы иткәнен белү важибтер. Мөэминнәр төркеменнән кылды, шуны белү тиештер. Моннан соң мөселманнар сыйныфын җитмеш өч төркемгә бүлде.

Ошбудан җитмеш ике фирка төрле-төрле азгынлыкларда булды. Аларның һәрберсе адашу хозурында, берсе генә сөннәт юлындадыр».

Әйтелде: «Шөкер ике төрледер: гомуми һәм хас шөкер. Әмма гомуми шөкер: тел белән хәмед әйтү, Аллаһының нигъмәтеу Аллаһыдан дип тел белән икрар итү. Әмма хас шөкер: тел белән хәмед әйтү, күңел белән тану, әгъзалар белән хезмәт итү, телне һәм башка әгъзаларны хәләл булмаган нәрсәләрдән саклау».

Мөхәммәд бине Кәгъбтән риваять ителде, ул әйтте: «Шөкрана кылу гамәлдер. Чөнки бу хакта Аллаһы Тәгаләнең сүзе бар:

اعْمَلُوا آلَ دَاوُودَ شُكْرًا

«Әй Давыд балалары, шөкрана кылыгыз». Ягъни, шөкерне үти торган гамәлне кылыгыз дигән сүз буладыр.

وعن عمرو بن شعيب ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "خصلتان من كانتا فيه كتبه الله عنده شاكرا صابرا إحداهما : أن ينظر في دينه إلى من هو فوقه ، فيقتدي به وينظر في دنياه إلى من هو دونه فيحمده الله".

Гамрү бине Шөгаеб Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте. Ул әйтте: «Берәүдә ике төрле хасыят булса, Аллаһы Тәгалә аны Үз каршында шөкер һәм сабыр итүче дип язар. Ул ике хасыятнең берсе, дин әмерендә үзеннән югарыга карау. Ул кеше үзеннән өстен булганга иярер. Дөнья әмерендә үзеннән түбәнгә карау, бәс Аллаһыга хәмед әйтер».

Фәкыйһ әйтте: «Шөкернең тәмамы өч нәрсәдер. Әгәр Аллаһы Тәгалә сиңа бирәр нәрсәне бирсә, син ул нигъмәтне биргән Затка карарсың һәм шул нигъмәт бәрабәренә Аллаһыга хәмед итәрсең. Сиңа

биргән нәрсәгә риза булырсың. Шул бирелгән нигъмәтнең файдасы синең белән даим булганда һәм төнеңдә аның куәте даим булганда, Аллаһыга гөнаһ кылма».

Мәймүн бине Мәһран Ибен Габбастан риваять итте. Ул әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең шундый яхшы кешеләре бардыр ки, яхшылык кылсалар сөенерләр, явызлык эшләсәләр, истигъфар итерләр. Нигъмәт бирелсә, шөкрана кылырлар, кайгы-хәсрәт ирешсә, түзәрләр».

Мөхәммәд бине Кәгъб риваять итте, ул әйтте: «Сөләйман бине Давыд галәйһиссәләм атлана торган нәрсәгә атланды. Аның янына халыгыннан кешеләр килделәр һәм әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, синнән алда һичкемгә бирелмәгән нәрсә сиңа бирелде». Сөләйман галәйһиссәләм әйтте: «Дүрт төрле хасыйләт бардыр, кемдә ул хасыятьләр булса, тәхкыйк, аңа дөньяда Давыд балаларына бирелгәннән артык бирелде. Ачык һәм яшерендә Аллаһыдан куркудыр; байлыкта һәм фәкыйрьлек вакытында ният кылу; ачу һәм разый вакытында гаделлек кылу; киң һәм тар вакытта Аллаһы Тәгаләгә хәмед әйтү».

Әбү Зәрр Гафаридән риваять ителде, аңардан: «Кешеләрнең кайсысы нигъмәтләнде?» – дип сорадылар. Ул әйтте: «Газаптан имин булган туфрактагы бәдән, савап көтүчедер».

## Кәсеп итү фазыйләте

عن أبي هريرة ﷺ عن رسول الله ﷺ أنه قال : "من طلب الدنيا حلالا استعفافا عن المسألة ، وسعيا على أهلع ، وتعطفا على جاره بعثه الله يوم

القيامة ووجهه كالقمر ليلة البدر ، ومن طلب الدنيا حلالا مكاثرا مفاجرا مرائيا لقي الله يوم القيامة وهو عليه غضبان".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Берәү кешедән сорарга бармас өчен, үз җәмәгатенә киңлек өчен һәм күршесенә шәфкать кылыр өчен хәләл малны кәсеп итсә, Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә бу кешенең йөзен айның ундүртенче кичәсендәге кебек булган хәлдә кубарыр. Берәү дөньяны күбәйтү, мактану өчен генә таләп итсә, Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә аңа ачулы хәлдә юлыгыр».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Һәсыр бине Яхъядан риваять итте, дөреслектә, Давыд галәйһиссәләм белдермичә генә чыгып йөри торган иде. Үзенең мәмләкәт халкының һәрбер күргән кешесеннән үзенең рәвешләре хакында сораша иде. Көннәрдән бер көнне аңа адәм кыяфәтендә Җәбраил галәйһиссәләм очрады. Давыд галәйһиссәләм аңардан: «Давыд турында нәрсә әйтерсең?» – дип сорады. Җәбраил галәйһиссәләм әйтте: «Бер фигыленнән башкасы бик яхшыдыр». Давыд галәйһиссәләм әйтте: «Ул ярамас нәрсә ни?» Җәбраил галәйһиссәләм әйтте: «Мөселманнарның бәйт малыннан (казнадан) ашый. Бәндәләр арасында үз кул көченнән ашый торган бәндәдән Аллаһы Тәгалә каршында сөеклерәк кеше юк». Давыд галәйһиссәләм елап һәм ялварып үз михрабына кайтты. Әйтте: «Әй Раббым, мөселманнар малына мохтаҗ булмас өчен, кулым белән эшләрлек миңа бер һөнәр өйрәт». Аллаһы Тәгалә аңа сугыш киеме ясый торган һөнәр өйрәтте һәм аңа тимерне йомшак кылды. Хәтта аның кулында тимер камыр урынына йомшак булды. Хәтта хөкемнән һәм җәмәгатенә кирәк-ярак

нәрсәне караудан бушагач, тимер күлмәк ясар иде. Аны сатып, шул акчага үзе һәм җәмәгате яши иделәр. Моңа Аллаһы Тәгаләнең аяте катгый дәлил булып тора:

وَأَلَنَّا لَهُ الْحَدِيدَ

«Давыд пәйгамбәргә тимерне йомшак кылдык».

وَعَلَّمْنَاهُ صَنْعَةَ لَبُوسٍ لَكُمْ لِتُحْصِنَكُمْ مِنْ بَأْسِكُمْ

«Сезне кайгыдан һәм зарардан саклар өчен аңа тимер күлмәк һөнәре өйрәттек». Ягъни сугышканда сезне саклар өчен өйрәттек димәктер.

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Сәбит Бәннәнидән риваять итте, ул әйтте: «Миңа ирешәте: сәламәтлек ун өлештер, тугызы тик торуда, берсе кешеләрдән катнашмастан качуда. Гыйбадәт тә ун өлештер. Тугызы – тереклек кылуда, берсе – гыйбадәттә».

وروى عن جابر بن عبد الله ﷺ عن رسول الله ﷺ انه قال : "ما فتح الرجل على نفسه باب مسألة إلا فتح الله عليه باب الفقر ، ومن يستعفف يعفه الله ، ومن يستغن يغنه الله ،لأن يأخذ أحدكم حبلا فيعمد إلى هذا الوادي ، فيحتطب فيه ، ثم ياتي سوقكم هذا فيبيعه بمد من تمر ، لكان خيرا له من أن سيأل الناس أعطوه أو منعوه".

Җәбир разыяллаһү ганһү Рәсүлуллаһтан риваять итте, ул әйтте: «Кеше үзенә сорау ишеген ачты исә, Аллаһы Тәгалә аңа фәкыйрьлек ишеген ачар. Кемдер кеше йөзенә барудан сакланса, аны Аллаһы Тәгалә саклар. Кемдер хөрмәтле булырга тырышса, Аллаһы Тәгалә ул кешене хөрмәтле итәр. Арагыздан берәрегез җеп алып бер далага барып, утын җыйса һәм соңыннан базарыгызга килеп, ул утынны бер савыт хөрмәгә сатса, бу аның өчен кешеләрдән сорауга караганда

изгерәк булыр. Кирәк ул сораган нәрсәне бирсеннәр һәм кирәк бирмәсеннәр».

وعن النبي ﷺ انه قال : "عليكم بالبز ، فإن أباكم

إبراهيم عليه الصلاة والسلام كان بزازا".

Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул әйтте: «Сезнең өчен һәртөрле тукыма җитештерү лязем булсын. Чөнки атагыз Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәләм тукучы булды».

وروى أبو هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال :

"إن زكريا عليه الصلاة والسلام كان نجارا".

Әбү һөрәйрә разыяллаһү ганһү Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте. Ул әйтте: «Зәкәрия галәйһиссәләм балтачы иде».

Һишам бине Гурвә Гайшә разыяллаһү ганһәдән риваять итте. Ул әйтте: «Сөләйман галәйһиссәләм минбәрдә кешеләргә хөтбә кылганда һәм аның кулында кумач суга торган корал яисә кайбер эшләнгән нәрсәсе бар иде. Хөтбәдән бушагач, аны берәүгә бирде дә: «Аны алып кит һәм сат», – диде.

Шәкыйкъ бине Ибраһим Аллаһы Тәгаләнең:

وَلَوْ بَسَطَ اللَّهُ الرِّزْقَ لِعِبَادِهِ لَبَغَوْا فِي الْأَرْضِ

аятенең тәфсирендә әйтте: «Әгәр Аллаһы Тәгалә бөтен халкына ризыкны киң кылса, ул халык җир йөзендә фәсәд кылырлар иде». Ягъни Аллаһы Тәгалә бәндәләрен кәсепсез ризыкландырса, бушанырлар иде дә, җир йөзендә фәсәд итешерләр иде. Мәгәр Аллаһы Тәгалә аларны кәсеп белән шөгыльләндергәч, фәсәдкә бушамадылар».

Сәгыйд бине Мүсәййәб әйтте: «Хәләл мал җыелмаган кешедә, малның хакын чыгармаган

кешедә һәм малы белән намусын сакламаган кешедә хәер юк».

Гомәр бине Хаттаб разыяллаһү ганһүдән риваять ителде, ул әйтте: «Әй фәкыйрьләр җәмәгате, башыгызны күтәрегез сату итегез һәм, тәхкыйк, юлы ачыктыр. Кешеләр өстенә мәшәкать булмагыз».

Гавәм бине Хәүшәб Әбү Салихтән риваять итте, ул әйтте: «Гомәр разыяллаһү ганһү безгә өч кеше иптәш булыгыз, дип боера иде. Берегез алсын, икенчегез сатсын, өченчегез сугышка чыксын».

Гавәм әйтте: «Бу сүзне Әбү Салих миңа сөйләде дә, мин аңы хәзерләнгән күрдем. Ул: «Без өч иптәш, бу юлы сугышка чыгуга минем чиратым», – диде».

Ибен Мөбарәктән риваять ителде, ул әйтте: «Кем дә кем базарны ташласа, аның мәрвәте китәр һәм холкы начарланыр».

Ибраһим бине Юсуф Мөхәммәд бине Сәлмәткә әйтте: «Базарга чыгу сиңа лязем булсын, чөнки базар иясенә газиздер».

وعن جابر بن عبد الله ﷺ أن النبي ﷺ قال : "من غرس غرسا أو زرع زرعا ، فأكل منه إنسان أو دابة أو طير أو سبع فهو له صدقة".

Җәбир бине Габдулладан риваять ителде, пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем иген чәчсә яки җимеш агачы утыртса һәм аннан адәм яки хайван яки кош яки ерткыч ашаса, бу гамәле аның өчен садакадыр».

وعن أنس بن مالك ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "لو قامت القيامة وفي يد أحدكم فسيلة ، فإن استطاع أن لا يقوم حتى يغرسها فليفعل".

Әнәс бине Мәлик разыяллаһү ганһү Пәйгамбәр галәйһиссләмнән риваять итте, ул әйтте: «Берәрегезнең кулында чыбык булган чагында Кыямәт

көне купса, әгәр шул чыбыкны кадаганга кадәр Кыяматкә тормаска көче җитсә, шулай кылсын. Ягъни утырта торган агачны утыртсын».

وعن محكول ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "إياكم أن تكونوا غيابين أو مداحين أو طعانين أو متماوتين".

Мәкхүл Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән ривәять итте, ул әйтте: «Гайбәтчеләр, яки мактаучылар, яки һич кәсепсез мәетләр кебек булудан сакланыгыз».

عن أبي المخارق قال : كان رسول الله ﷺ مع أصحابه إذ مر عليهم اعرابي شاب جلد ، فقال أبو بكر وعمر ﷺ : ويحه لو كان شبابه وقوته في سبيل الله كان أعظم لأجره ، فقال رسول الله ﷺ : "غن كان يسعى على ابوين كبيرين ليعينهما فهو في سبيل الله ، وإن كان يسعى على أولاده الصغار فهو في سبيل الله ، وإن كان يسعى على نفسه ليستغني عن الناس فهو في سبيل الله ، وإن كان يسعى رياء وسمعة فهو في سبيل الشيطان".

Әбү Мухариктән ривәять ителде. Ул әйтте: «Рәсүлуллаһ сәхабәләре белән утырганда алар янынннан куәтле, яшь гарәп егете үтте. Әбү Бәкер белән Гомәр разыяллаһү ганһүмә әйттеләр: «Чү, әгәр бу егетнең яшьлеге һәм көче Аллаһы юлында булса, аның әҗере олуграк булыр иде». Рәсүлуллаһ әйтте: «Әгәр ул егет картайган ата-анасына ярдәм кылып йөрсә, тырышса, шул эше Аллаһы юлында булыр. Әгәр яшь балалары өчен тырышса, ул да Аллаһы юлындадыр. Әгәр дә кешеләргә бармас өчен үз-үзенә тырышса, ул да Аллаһы Тәгаләнең юлында булыр. Әгәр дә ул кеше рия һәм шөһрәт өчен кәсеп кылса, ул кәсеп шайтан юлындадыр».

وعن ابن عمر ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "إن الله تعالى يحب كل مؤمن محترف أبا العيال ، ولا يحب الفارغ الصحيح ، لا في عمل الدنيا ولا في عمل الآخرة".

Ибен Гомәр Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә балалар атасы булган, һөнәрле һәрбер мөэминне сөядер. Сәламәт хәлендә дөнья һәм ахирәт эшеннән буш булган кешене сөймидер».

وعن جعفر بن محمد ، عن أبيه قال : كان النبي ﷺ يخرج إلى السوق ويشتري حوائج اهله ، فسءل عن ذلك فقال : "اخبرني جبريل فقال : "من سعى على عياله ليكفهم عن الناس ، فهو في سبيل الله".

Җәгъфәр бине Мөхәммәд атасыннан риваять итте. Ул әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм базарга чыга торган иде һәм җәмәгатенә кирәкле нәрсәләрне ала иде. Моның хикмәтеннән соралды. Әйтте: «Миңа Җәбраил галәйһиссәләм хәбәр бирде һәм әйтте: «Кем дә кем балаларын кеше йөзенә чыгуыннан тыяр өчен кәсеп итсә, ул кеше Аллаһы Тәгаләнең юлындадыр».

عن أناس بن مالك ﷺ أن رجلا جاء إلى النبي ﷺ فسأل منه حاجة ، فقال له رسول الله ﷺ : "أو ما في بيتك شيء" ، قال : بلى يا رسول الله ، حلس قد تخرق بعضه ، نحن نجلس عليه ، وننام فيه ، ونجعل بعضه تحتها وبعضه فوقها ، وقصعة نأكل فيها ونشرب فيها ونغسل فيها رؤوسنا ، فقال رسول الله ﷺ : "ائتني بهما جميعا" ، فاتاه بهما فأخذهما رسول الله ﷺ بيده وقال : "من يشتري هذين؟" فقال رجل : انا آخذهما بدرهم ، فقال : "ألا من يزيد على درهم" مرتين ، فقال رجل آخر : ألنا آخذهما بدرهمين ، فاعطاهما إياه وقبض الدهمين

، ودفعهما إلى الرجل ن وقال له : "اشتر بأحدهما طعاما واحمله إلى منزلك ، واشتر بالآخر قدوما وائتني به" فأتاه فشد واكتسب عشرة دراهم ، فاشتري ببعضها طعام ، وببعضها ثوبا فقال رسول الله ﷺ : "اليس هذا خير لك من أن تجيء يوم القيامة ، ومسالتك في وجهك نكتة سوداء لا يمحوها إلا النار".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде. Бер кеше Пәйгамбәр галәйhиссәләмгә килеп, йомышын сорады. Рәсүлуллаh әйтте: «Өеңдә бер нәрсәң дә юкмы?» Әйтте: «Юк, бер палас бар аның да кайбер җире янган, шуның өстенә утырабыз һәм аның өстендә йоклыйбыз. Аның бер тарафын аска салабыз һәм бер тарафын өскә ябабыз. Янә бер табак бар, аннан ашыйбыз, эчәбез һәм ул савыт белән башыбызны да юабыз». Рәсүлуллаh галәйhиссәләм аңа әйтте: «Икесен дә миңа китер». Һәм ул кеше аларны китерде. Рәсүлуллаh үз кулы белән аларны алды һәм әйтте: «Бу ике нәрсәне кем сатып алыр?» Бер кеше әйтте: «Мин боларны бер дирhәмгә сатып алам». Рәсүлуллаh ике мәртәбә: «Дирhәмнән арттыручы бармы?» – дип сорады. Икенче бер кеше әйтте: «Мин бу әйберләрне ике дирhәмгә алам». Пәйгамбәр галәйhиссәләм аларны ул кешегә бирде, ике дирhәм көмеш акчаны алып, әйберләр иясенә бирде һәм әйтте: «Берсе бәрабәренә ашарга ал да өйгә күтәреп кит, икенчесенә балта ал да аны миңа китер». Ул кеше Пәйгамбәр галәйhиссәләмгә килде, Рәсүлуллаh галәйhиссәләм ул балтага гуд агачын бәйләде һәм әйтте: «Бар кит, утын җый һәм сат, мин сине унбиш көн күрмим». Ул кеше китте. Ун дирhәм кәсеп итеп тапты. Ул ун дирhәмнең кайсына ашарга, кайсына кием алды. Рәсүлуллаh әйтте: «Бу эш синең Кыяматкә йөзеңдә сорауның кара ноктасы булып

килүеңнән хәерлерәк түгелме? Ул кара ноктаны тәмуг утыннан башка нәрсә бетермәс».

Кайбер хәкимнәр әйттеләр: «Биш нәрсәсе булмаган шәһәрдә тору акыллы кешегә тиешле түгел: хөкем итә торган түрә; гадел казый; даими базары; ага торган елгасыдыр һәм галим табибтыр».

Кайбер хәкимнәрдән: «Кәсепләрнең хәерлесе ни?» – дип сорадылар. Әйтте: «Дөнья кәсепләренең изгесе: кирәк нәрсәнең бетүе өчен хәләлне теләү, ул хәләлдән гыйбадәт өчен бер вакыт тоту. Кыямәт көненең азыгының артыгын илтер өчен хәләлне теләү. Ахирәт кәсепләренең изгесе исә, аның белән гамәл ителгән һәм кешегә өйрәткән гыйлем, ахирәткә илткән изге гамәлең һәм торгызган изге сөннәттер».

Әйтелде: «Кәсепләрнең начары ни?» Ул хәким әйтте: «Дөнья кәсепләренең яманы: җыйган хәрамың, гөнаһ урынга сарыф иткәнең, малыңны фасикъ кешегә мирас итеп калдыруыңдыр. Ахирәт кәсепләренең яманы исә: көнчелек итеп инкарь иткән хак эштер, һичтуктаусыз кылып, ахирәткә илткән гөнаһ эшең, золым йөзеннән торгызган яман гамәлең, бидгатеңдер».

Кәсепкә кызыктыру һәм хәрамнан тыю турында

عن قتادة ﷺ قال : قال النبي ﷺ : "إن شءتم لأحلفن أن التاجر فاجر".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Котәдәдән риваять итте. Ул әйтте: «Безгә риваять ителде Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әгәр теләсәгез, ант тә итәрмен, дөреслектә, сәүдә итүче фасикътыр».

قال قتادة : وكان يقول ﷺ : "عجبت للتاجر

أن يتخلص يحلف بالنهار ويحسب بالليل".

Котәдә әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтә торган иде: «Сәүдәгәрнең котылуына гаҗәпләнәм, көндез – ант итә, кич – хисап кыла».

Фәкыйһ иснәде белән Нәсыйр бине Яхъядан риваять итте, ул әйтте: «Гыйлем әһелләренең кайберләре әйтә иде: «Дөнья һәм дин дүрт нәрсә белән генә тора: галимнәр, түрәләр, сугышчылар һәм сәүдә ияләредер».

Фәкыйһ әйтте: «Заһидләрнең кайберәүләреннән бу сүзне тәфсир кылганын ишеттем: «Түрәләр караучылардыр, халыкны карыйлар. Галимнәр исә пәйгамбәрләрнең варислары, алар халыкны ахирәткә димлиләр. Кешеләр аларга ияреләр. Сугышчылар җир йөзендә Аллаһының гаскәрләредер. Сәүдә кешеләре халыкның мәслихәтен карар өчен куелган Аллаһының ышанычлы кешеләредер. Әгәр сакчыларга һәм галимнәргә халык иярә торган булса, сугышчылар тик мактану һәм халыкның күзен алдау өчен генә атларына менсәләр, саранлык өчен генә сугышка чыксалар, кайчан алар дошманны җиңәрләр? Әмма сәүдә халкы кешеләргә хыянәт итсәләр, ничек аларга кешеләр инансыннар?»

Хәкимнәрнең кайберләре: «Әгәр сәүдәгәрдә өч нәрсә булмаса, дөньяда һәм ахирәттә фәкыйрьлеккә төшәр», – дип әйттеләр. «Беренчесе, өч нәрсәдән пакь тел: ялганнан, анттан һәм буш сүздән. Икенчесе, өч төрле нәрсәдән пакь күңел: кинәдән, хыянәттән һәм көнчелектән. Өченчесе, өч төрле нәрсәне саклый торган нәфес: җомганы, җәмәгать намазын, кайбер вакытларда гыйлем алуны саклаучы нәфестер».

Гали бине Әбү Талибтән риваять ителде, ул әйтте: «Әгәр сәүдәгәр кеше галим булмаса, рибага чумганнан чумар».

Гомәр бине Хаттаб разыяллаһү ганһүдән риваять ителде. Ул әйтте: «Кем дә кем диндә галим булмаса, безнең базарларда сәүдә кылмасын».

Суфьян әйтте: «Байларга күрше булудан, базар кариәләреннән һәм түрәләрнең галимнәреннән, ягъни түрәләр ялчысы булган галимнәрдән сак булыгыз».

Мөхәммәд бине Сәмәлдән риваять ителде. Ул базарга керде һәм әйтте: «Әй базар халкы, базарда ихтыяҗ юк. Сатуыгыз бозык, күршегез көнче, барачак җирегез тәмугтыр».

Ибен Габбастан риваять ителде, ул әйтте: «Хәләлне кәсеп итү тауны тауга күчерүдән катырактыр».

Йоныс бине Гөбәедтән риваять ителде, ул әйтте: «Бу заманда сарыф кылына торган пакь дирһәмнән, Исламда аның тарафына күңел утыра торган кардәштән, Пәйгамбәрнең тормыш юлы хозурында гамәл кыла торган гамәлдән аз нәрсәләрне белмим. Болар аздан азая бара. Әгәр хәләлдән булган бер дирһәмне тапсак, аның белән авыруларыбызны дәвалар идек».

Мөгаз бине Җәбәл разыяллаһү ганһү әйтте: «Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгаләнең хозурына бармый калган һичбер бәндә булмас. Дүрт төрле нәрсәдән соралганга кадәр ике аягы даим булыр, ягъни аяк хозурында торыр, һич купмас. Тәненнән соралыр, ул тәнне нәрсә хакында черетте. Гомереннән соралыр, ул гомерен нәрсәдә үткәрде. Гыйлемнән соралыр, ул гыйлем белән ничек гамәл кылган. Малыннан соралыр, ул малны кайдан тапкан һәм кайда сарыф кылган». Хәкимнәрнең кайберләре әйтте: «Монафыйк дөнья малыннан алганда, хирыс белән алыр; шик белән бирмәс; рия белән сарыф

итәр. Күңел күзе ачык мөэмин кеше малны алса, курку белән алыр; шөкер белән тотар; сарыф кылса, Аллаһы *ризалыгы өчен генә сарыф итәр».*

Яхъя бине Мөгаз әйтте: «Гыйбадәт – Аллаһы Тәгаләнең хәзинәләре арасында бер хәзинәдер. Ул хәзинәнең ачкычы догадыр. Ул ачкычның тешләре хәләл ризык ашау».

Ибен Шүбрәмәдән риваять ителде. Ул әйтте: «Авыруда куркып, хәләлдән саклана торган кешедән гаҗәеврәк юктыр. Ничек инде ул тәмугтан куркып хәрамнан сакланмый».

وروى عن جابر ﷺ عن رسول الله ﷺ أنه قال : "يا أيها الناس إن أحدكم لن يموت حتى يستكمل رزقه ، فلا تستبطءوا الرزق فاتقوا الله وأجملوا في الطلب ، فخذوا ما حل لكم ، وذروا ما حرم الله".

Җәбир разыяллаһү ганһү Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять итте. Ул әйтте: «Әй кешеләр, сезнең берегез дә ризыгын тәмам ашап бетергәнче вафат булмый. Ризыкның әкрен килгәнен дә теләмәгез, Аллаһыдан куркыгыз, кәсептә күркәмлек кылыгыз, Аллаһы Тәгалә сезгә хәләл кылганны алыгыз һәм Аллаһы Тәгалә хәрам кылганны ташлагыз».

Хәким әйтте: «Кешеләр сәүдәдә биш төрледер. Ризыгын Аллаһыдан да, кәсептән дә күрә торганнары бар, ул мөшриктер. Кайберәүләре ризыкны Аллаһыдан дип белә, ләкин бирәме, юкмы икәнен белми, бу кеше шик кылучы монафыйктыр. Алардан кайберәүләре ризыкны Аллаһыдан дип белә, ләкин ул ризыкның хакын бирми һәм Аллаһы Тәгаләгә гөнаһ кыла, ул кеше фасикътыр. Алардан кайберәүләре ризыкны Аллаһыдан дип белә һәм кәсепне сәбәп дип әйтәдер һәм ризыгының хакын

чыгара, кәсебе өчен Аллаһыга һич гөнаһ кылмый. Бәс ул кеше чын мөэминдер».

Зәйд бине Әркамнән риваять ителде. Ул әйтте: «Әбү Бәкернең колы бар иде, ул егет Әбү Бәкергә һәркөн ашамлык китерә иде, Әбү Бәкер разыяллаһү ганһү һәрвакыт кайдан кәсеп кылганын сорашмыйча, ул ашамлыкны ашамас иде. Бер кичтә бу егет Әбү Бәкергә ашарга алып кайтты, ул ашамлыкка кулын сузды, ул егеттән сорашмыйча бер кисәк ашады. Егет: «Һәр кичне миннән китергән ризыгым хакында сораша идең, бүген берни дә сорамадың», – дип сорады. Әбү Бәкер әйтте: «Чү, чү, мине ачлык сораттырмады. Миңа бу ризыгың хакында сөйлә». Егет әйтте: «Җаһилият вакытында кешеләр өчен югары менә идем, шуның бәрабәренә миңа бер микъдар ризык вәгъдә кылалар иде. Бүген аларның туйларын күрдем, вәгъдә кылганнарын исләренә төшердем. Һәм алар миңа бу ашамлыкны бирделәр». Бәс Әбү Бәкер бу вакытта кайтаруны теләде. Моннан соң коса башлады, үзен көчләде һәм мәшәкатьләде, эченнән бер кисәк ашамлыкны чыгарырга теләде. Бик җәфаланды. Аның дәвалануын күргәч, әйттеләр: «Шуның өстенә берәр савыт су эчсәң ни булыр?» Зур савыт белән суны китерделәр, аны эчте, моннан соң янә косты. Үз-үзен дәваларга тырышты, бик озак җәфаланса да, ахырда ашаган кисәген чыгарды. Әйттеләр: «Бу кадәр мәшәкать шул кисәк өченме?» Әбү Бәкер әйтте: «Мин Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән ишеткән идем, ул әйтте:

رسول الله ﷺ قال : "إن الله تعالى حرم الجنة

على كل جسد تغذى أو غذي بحرام".

«Аллаһы Тәгалә хәрам белән тәрбияләнгән һәрбер тәнгә оҗмаһны хәрам кылды».

Фәкыйһ әйтте: «Кем дә кем кәсебе пакь булуын теләсә, ул кешегә биш нәрсәдә даимчылык кылу лязем булсын. Беренчесе, Аллаһы Тәгаләнең фарызларыннан һичнәрсәне кичектермәү һәм фарызларга һичнинди кимчелекләр кертмәү. Икенчесе, кәсеп өчен Аллаһы Тәгаләнең халыкларыннан һичберәүне рәнҗетмәү. Өченчесе, кәсептән үзе һәм җәмәгатенең намусын саклауны ният итү һәм аның максаты җыю һәм күбәйтү булмас. Дүртенчесе, сәүдәдә үз-үзен бик мәшәкатьләмәү. Бишенчесе, ризыкны кәсептән күрмәү. Ризыкны Аллаһыдан, кәсепне сәбәп, дип белү».

وروى عن النبي ﷺ أنه قال : "من اكتسب مالا من مأثم ، فتصدق به أو وصل به رحما أو أنفقه في سبيل الله جمع ذلك كله وألقى في النار".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул әйтте: «Кем дә кем гөнаһ урыныннан мал тапса һәм аны садакага яки туганнарына бирсә, яки Аллаһы юлында сарыф кылса. Боларның һәрберсен җыйды һәм тәмугка ташлады».

Гыймран бине Хасыйннән риваять ителде. Ул әйтте: «Кешенең хаҗын, гумрасын, садакасын, сугышын, азат кылуын, малын сарыф кылуын Аллаһы Тәгалә кабул итмәс, әгәр аның малы рибадан, яки ришвәттән, яки хыянәттән, яки золымнан, яки урлаудан җыелган булса». Соңыннан әйтте: «Биш нәрсә биш нәрсә сәбәпле кабул ителмәс».

وعن ابن مسعود ﷺ انه قال : قال النبي ﷺ : "لا يكسب عبد مالا حراما فيتصدق به ، فيؤجر عليه ، ولا ينفق منه فيبارك له فيه ، ولا يتركه خلف ظهره ، إلا كان زاده إلى النار وإن الله تعالى لا يمحو الشيء بالشيء ولكن يمحو الشيء بالحسن".

Ибен Мәсгудтән риваять кылына. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әгәр бәндә хәрам юл белән мал җыеп, садака бирсә, аннан сарыф итсә һәм үзеннән соң да калдырса, ул мал аңа газапны гына арттырыр. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә явызлыкны явызлык белән бетермидер. Мәгәр явызлыкны изгелек белән генә бетерәдер».

Хәсән Басридән риваять ителгәнчә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Мал, табучының малы гынадыр, сәүдәгәрләрегезнең иң явызлары үз арагызда торучылар. Сез аларга, алар сезгә ант итешерсез, соңыннан алар сезгә һәм сез аларга хыянәт итешерсез».

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән: «Кәсепнең хәерлесе ни?» – дип сорадылар, ул әйтте: «Кешенең үз кулы белән эшләгәне һәм һәр шөбһәсез һәм хыянәтсез булган сәүдә».

Котәдәдән риваять ителде. Ул әйтте: «Әйтелде: «Рас сөйләүче сәүдәгәр, Кыямәт көнендә Гареш күләгәсе астындадыр».

## Ризык ашату һәм күркәм холык

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Гатая Гауфийдән риваять итте. Ул әйтте: «Җәбир бине Габдулла миңа әйтте: «Әй Гатая, минем васыятемне күңелеңә ал. Бу сәфәремнән башкада мин сине иптәш дип күрмәм. Мөхәммәд галәйһиссәләмнең балаларын һәм аның сәхабәләрен һәм Мөхәммәд галәйһиссәләм балаларын сөючеләрне сөй. Әгәр алар гөнаһларга һәм хаталарга төшсәләр дә. Мөхәммәд галәйһиссәләмнең балаларын яратмаганнарга ачулан. Әгәр ул кешеләр ураза тотучы, төннәрен аяк хозурында

торып үткәрүчеләр булсалар да. Ризык ашат, сәлам бир, кешеләр йоклаган вакытта кич намаз укы».

سمعت رسول الله ﷺ يقول : "ما اتخذ الله إبراهيم خليلا إلا لإطعامه الطعام وإفشائه السلام ، وصلاته بالليل والناس نيام".

Чөнки мин Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән ишеттем. Ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәләмне бары ризык ашатканы, сәлам җәйгәне һәм кешеләр йокыда вакытта кич намаз укыганы өчен генә дус кылды».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Гайрән бине Хәбибтән риваять итте, ул әйтте: «Ибен Габбас разыяллаһү ганһүмәгә бер кеше килде һәм әйтте: «Бу мөһәҗир һәм ансар сәхабәләр, без бер савап хозурында түгелбез, дип әйтәләр. Бу бик гаҗәптер». Ибен Габбас әйтте: «Юк, алар әйткәнчә түгел. Әгәр син намаз укысаң, ураза тотсаң, зәкәт түләсәң, Аллаһының өенә хаҗ кылсаң һәм кунакны хөрмәтләсәң, җәннәткә керерсең».

عن أبي شريح الخزاعي ، قال : سمعت رسول الله ﷺ يقول : "من كان يؤمن بالله واليوم الآخر فليكرم ضيفه ، جائزته يوم وليلة ، والضيافة ثلاثة أيام ، فما كان بعد ذلك فهو صدقة".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Шәрихтән риваять итте, ул әйтте: «Рәсүлуллаһтан ишеттем, ул әйтә иде: «Кем дә кем Аллаһыга һәм ахирәт көненә ышанса, кунагын хөрмәтләсен. Тиешлесе бер тәүлек, кунак итү өч көндер. Шул өч көннән артык кунак итү нәфел садакадыр».

Гатадан риваять ителде. Ул әйтте: «Ибраһим галәйһиссәләм иртәнге ашны ашарга теләсә, үзе белән бергә ашаучыны тапмаса, үзе белән бергә ашаучыны эзләп, бер-ике миль йөри иде».

Гәкрәмәдән риваять ителде. Ул әйтте: «Ибраһим галәйһиссәләм кунакларның атасы, дип аталды. Өенең дүрт ишеге бар иде. Кайсыннан кеше килер, дип карар иде».

Гали бине Әбү Талиб разыяллаһү ганһүдән риваять ителде, ул әйтте: «Бер яки ике савыт ашамлык өстенә кардәшләремнән бер җәмәгатьне җыюым, миңа базарыгызга чыгып, кол азат итүемнән сөеклерәк».

Ибен Гомәрдән риваять ителде: «Аш әзерләгәч, аның яныннан чибәр рәвешле кеше үтсә, аны өндәми иде. Әгәр аның яныннан мескен кеше үтсә, аны өнди иде. Һәм әйтә иде: «Теләми торган кешене өндисезме, ашыйсы килгән кешене калдырасызмы?»

وروى عن النبي ﷺ أنه سئ : ما أكثر ما يلج به الناس في الجنة ؟ قال : "تقوى الله وحسن الخلق" ، فقلت : ما أكثر ما يلج به الناس في النار؟ قال : "الأجواف : الفم والفرج ، وسوء الخلق".

Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән риваять ителде. Аңардан сорадылар: «Кеше күбрәк ни сәбәпле җәннәткә керә?» Әйтте: «Аллаһының хәрамыннан саклану белән күркәм холык сәбәпле кешеләрнең күбрәге җәннәткә керер». «Кеше күбрәк ни сәбәпле утка керер?» – дип сорадылар. Әйтте: «Кешеләр утка күбрәк тел, фәраҗ һәм тел, холык сәбәпле керер».

Гайшә разыяллаһү ганһәдән һәм аның ата-анасыннан риваять ителде, ул әйтте: «Дөреслектә, күркәм холык, күркәм күршелек һәм кардәшлекне саклау – мәмләкәтне төзи һәм гомерләрне арттыра, әгәр халык фасикъләр булса да».

عن ابن عمر قال : كنت عاشر عشرة رهط في مسجد رسول الله ﷺ أبو بكر ، وعمر ، وعثمان ، وعلي ، وعبد الرحمن ، وابن مسعود ، ومعاذ ، وحذيفة ، وأبو سعيد الخدري ، وعبد الله بن عمر ﷺ فجاء فتى من الانصار ، فسلم على النبي ﷺ ثم جلس فقال : أي المؤمنين أفضل ؟ قال : أحسنهم خلقا ، قال : فأي المؤمنين أكيس ؟ ، قال : "أكثرهم للموت ذكرا ، وأحسنهم له استعداد قبل أن يترل به أولءك هم الاكياس".

ثم سكت الفتى ، وأقبل علينا النبي ﷺ وقال : "يا معشر المهاجرين والأنصار ، خمس خصال إذا ابتليتم بهن ، وأعوذ بالله أن تدركهن : لم تظهر الفاحشة في قوم حتى يعلنوا بها إلا فشى فيهم الطاعون والاوجاع التي لم تكن فيما مضى من أسلافهم الذين مضوا ، ولم ينقصوا المكيال والميزان ، إلا أخذوا بالسنين : شدة المؤونة ،وجور السلطان عليهم ، ولم يمعوا زكاة أمواهم إلا منعوا القطر من السماء ، ولو لا الهائم لم يمطروا ، ولم ينقضوا عهد الله وعهد رسوله إلا سلط الله عليهم عدوهم من غيرهم ، وما ترك أئمتهم الحكم بكتاب الله تعالى إلا جعل باسهم بينهم".

Гата бине Әбү Рубәхтән, ул Ибен Гомәрдән риваять итте, ул әйтте: «Рәсүлуллаһның мәчетендә ун кешенең мин унынчысы идем. Алар Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали, Габдрахман, Ибен Мәсгуд, Мүгаз, Хузәйфә, Әбү Сәгыйд Худрий һәм Габдулла бине Гомәр иделәр. Ансардан булган бер егет килде, Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә сәлам бирде, моннан соң утырды һәм әйтте: «Мөэминнәрнең кайсысы артык?» Рәсүлуллаһ әйтте: «Ул мөэминнәрдән яхшы холыклысыдыр». Егет әйтте: «Мөэминнәрнең кайсы киемгә өсте бөтенрәк?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм

әйтте: «Үлемне күбрәк истә тотканы. Башына килүдән әүвәл шул үлем өчен чибәррәк хәзерләнгәне. Алардыр киемлеләр». Моннан соң егет дәшмәде. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм безгә таба карап әйтте: «Әй җәмәгать! Биш нәрсә бардыр ки, сезнең ул биш нәрсәгә ирешүегездән Аллаһыга сыгынам. Ачык зина кылган халык арасында тагун (чума) авыруы таралмыйча калмас. Янә зина таралган халык эчендә элекке заман кешеләренә килмәгән ачлыклар булыр. Үлчәүне киметүче кешеләр ике төрле явыз җәза белән тотылмый калмаслар. Ул ике төрле җәза каты мәшәкатьтер: берсе, өстләрендәге түрәнең золымы, икенчесе, малларының зәкәтләрен бирмәгән халыкка күктән яңгыр бирелмәс. Әгәр хайваннар булмаса, яңгыр яудырылмас иде. Аллаһының һәм Рәсүленең гаһеден бозган халыкка үзләреннән булмаган кешене өстләренә дошман җибәрми калмас. Кайсы халыкның патшасы Аллаһының китабы белән хөкем кылуны ташласа, араларында хәвеф-хатәр булмыйча кылмас».

وروى أبو هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "إنكم لا تسعون الناس بأموالكم ، فليسعهم منكم بسط وجه ، وحسن خلق".

Әбү Һөрәйрә Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Сез кешеләрне малларыгыз белән киңәйтеп бетерә алмассыз. Һәм сездән булган кешеләрнең ачык йөзе һәм күркәм холыгы аларны киңәйтсен».

عن عواس بن سمعان الانصاري ﷺ قال : سألت رسول الله ﷺ عن البر والإصم فقال : "البر حسن الخلق ، والإثم ماحاك في صدرك ن ومرهت أن سطلع عليه الناس".

Нәвәс бине Сәмган Ансаридән риваять ителде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән: «Яхшылык белән гөнаһ нәрсәләр?» – дип сорадым. Әйтте: «Изгелек күркәм холыктыр. Явызлык исә синең күкрәгеңне тырный торган нәрсәдер. Шул эчеңдәге нәрсәне халыкның белүен сөймәссең».

وروى أبو هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "كرم المرء دينه ومروءته عقله، وحسنه خلقه".

Әбү Һөрәйрә Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Кешенең чибәрлеге – динедер, кешелеге – акылыдыр, югары дәрәҗәсе – холкыдыр».

وعن أبي ثعلبة الخشني عن النبي ﷺ انه قال : "أن من أحبكم غلي وأدناكم مني مجلسا في الآخرة أحسنكم أخلاقا ، وأن من ابغضكم إلي وأبعدكم مني مجلسا في الآخرة اساوئكم أخلاقا".

Әбү Сәгъләбә Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте. Ул әйтте: «Сезнең миңа сөеклерәгегез һәм ахирәт мәҗлесендә миңа якынрагыгыз – холкы күркәмрәгегездер. Дөреслектә, сезнең миңа иң нәфрәтлерәгегез һәм ахирәт мәҗлесендә миннән ераграгыгыз холкы иң явыз булганыгыз».

Ибен Габбастан риваять ителде. Ул әйтте: «Күркәм холык кояш карны эреткән сыман бөтен гөнаһларны эретә. Серкә балны бозган кебек, начар холык та яхшы гамәлне боза».

عن معاذ بن جبل ﷺ قال : كان آخر ما اوصاني به رسول الله ﷺ حين جعلت رحلي في الغرز فقال : "حسن خلقه مع الناس يا معاذ بن جبل".

Яхъя бине Сәгыйд Мүгаз бине Җәбәлдән риваять итте. Ул әйтте: «Аякларымны өзәңгегә куйган вакытта

Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнең миңа васыять иткәненең иң соңгысы булды. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әй Мугаз бине Җәбәл, кешеләр белән холкыңны күркәм кыл».

وروى جابر بن عبد الله ﷺ عن رسول الله ﷺ أنه قال : "حسن الخلق ومام من رحمة الله في انف صاحبه ، والزمام بيد الملك ، والملك يجره إلى الخير ، والخير يجره إلى الجنة ، وسوء الخلق زمام من عذاب الله في أنف صاحبه ، والزمام بيد الشيطان ، والشيطان يجره غلى الشر ، والشر يجره إلى النار".

Җәбир бине Габдулладан риваять ителә. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Күркәм холык иясенең борынында Аллаһының рәхмәтеннән булган тезгенчек, ул фәрештә кулындадыр, фәрештә аны хәергә өстери. Хәер исә ул кешене җәннәткә илтә. Явыз холык иясенең борынында Аллаһының газабыннан булган тезгенчек, ул шайтан кулындадыр. Шайтан ул кешене явызлыкка өстери. Явызлык исә аны утка алып бара».

وروى جابر بن عبد الله ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "غن هذا الدين هو الذي ارتضيته لنفسي ، ولا يصلحه إلا خصلتان : السخاء وحسن الخلق ن فأكرموه بهما ما صحبتموه".

Җәбир бине Габдулладан риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Дөреслектә, бу динне үзем өчен сайладым. Ул динне ике нәрсәдән башка нәрсәләр төзәтә алмыйдыр. Алар юмартлык белән күркәм холыктыр. Ул дин иясе булганыгыз вакытта, аны шул күркәм холык һәм юмартлык белән хөрмәтләгез».

Әйтелде: «Әгәр бер кеше кунаклар чакырса, өй хуҗасына өч һәм кунак булып килгән кешегә өч нәрсә

важиб булыр. Хуҗасына кунак өчен хәлдән тыш тырышмаска, кунак итүдә сөннәт эштән чыкмаска; кунакны хәләлдән генә ашатырга; кунак хозурына намаз вакытын үткәрмәскә важиб булып тора. Әмма кунакка кайсы урынга утыртсалар, шул урынга утыру; китерелгән нәрсәгә разый булу; өйдән чыкканда өй хуҗасына бәракәт. белән дога кылу важиб булып тора».

وعن النبي ﷺ انه قال : "من أدى زكاة ماله ، وقرى الضيف ن وأعطى قومع في التائبة ، فقد وقى شح نفسه".

Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем малның зәкәтен бирсә, кунакны хөрмәтләсә, хуҗалыкта ихтыярны халкына бирсә, тәхкыйк, ул кеше үзен саранлыктан саклады. Ягъни саранлыкка омтылмады».

## Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл булу

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Җәгъдәттән риваять итте, ул әйтте: «Гайсә галәйһиссәләм әйтте: «Киләчәк көн өчен ашамлыкны качырмагыз. Чөнки киләчәк көн үзенең ризыгы белән бергә килер. Җирдәге кортлар һәм аларны ризыкландыручы хакында уйлагыз. Әгәр сез кортларның корсаклары кечкенә дип әйтсәгез, кошларга карагыз. Әгәр сез кошларның канатлары бар дип әйтсәгез, су эчендәге җанварларга карагыз. Ни гаҗәп, аларның тәннәре зур һәм ни гаҗәп, алар симезләрдер».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Мәҗлиздән риваять итте, Гомәр разыяллаһү ганһү әйтте: «Күңелем сөйгән, яки күңелем нәфрәтле күргән нәрсә хозурына таңга керсәм дә, һич тә кайгырмыйм. Чөнки изгелек кайсында икәнен белмим».

عن المطلب بن حنطب ان النبي ﷺ قال : "ما تركت شيئا مما أمركم الله به إلا وقد أمرتكم به ، وما تركت شيئا مما نهاكم الله عنه إلا وقد نهيتكم عنه ، ألا وإن الروح الامين جبريل قد ألقى في روعي أنه لن تموت نفس حتى تستوعب كل الذي كتب لها ن فمن أبطأ عنه شيء من ذلك فليجمل في الطلب ، فغنكم لا تدركون ما عند الله بمثل طاعته".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Муталлиб бине Хантабтан риваять итте. Дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә сезгә боерган нәрсә белән мин дә сезне боермыйча калдырмадым. Аллаһы Тәгалә сезне тыйган нәрсәләрдән мин дә сезне тыймыйча калдырмадым. Белегез, Җәбраил галәйһиссәләм минем күңелемә салды. Дөреслектә, минем нәфесем өчен язылган нәрсәне алып бетермичә, минем нәфесем һич үлмәс, вафат булмас. Берәүгә ошбу язылган кадәре акрын килсә, табуда күркәмлек кылсын. Аллаһы Тәгалә каршында тәгате бәрабәрендә булган нәрсәгә һич ирешмәссез».

Ибен Габбастан риваять ителде, Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Берәүнең күңеленә кешеләрнең иң байрагы булуы төшсә, үз кулындагы нәрсәгә караганда Аллаһы Тәгаләнең кодрәтенә ышанучырак булсын. Кешеләрнең куәтлерәге булу күңеленә килсә, Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кылсын. Берәүнең күңеленә кешеләрнең иң хөрмәтлесе булу нияте төшсә, Аллаһы Тәгаләнең хәрамыннан саклансын».

Давыд галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул үзенең улы Сөләйман галәйһиссәләмгә әйтте: «Әй улым, кешенең тәкъвалыгына өч нәрсә дәлил булыр: ирешмәгән нәрсә хакында күркәм тәвәккәл; тапкан

нәрсәгә күркәм ризалык һәм кулыннан киткән нәрсә хакында күркәм түземлектер».

Әбү Мутыйгътан риваять ителде, ул Хатим Әсамга әйтте: «Миңа, син азыксыз гына тәвәккәл сәбәпле котыла торган урыннарны үтәсең икән, дигән хәбәр иреште». Хатим әйтте: «Юк, мин ул урыннарны азык белән үттем». Әбү Мутыйгъ әйтте: «Азыгың нәрсә?» Хатим әйтте: «Ул урында минем азыгым дүрт нәрсәдер. Бөтен дөньяны Аллаһының патшалыгы, дип беләмен; халыкны Аллаһы Тәгаләнең кешеләре, дип беләмен; ризыкларны һәм сәбәпләрне, һәрберен Аллаһының кодрәтендә, дип беләмен; Аллаһының хөкеме бөтен халык арасында, Ул әйткәненчә була, дип беләм». Әбү Мутыйгъ әйтте: «Әй Хатим, синең азыгың бигрәк яхшы азык икән. Дөреслектә, син шул нәрсәләр белән ахирәт урыннарына кичәрсең. Инде дөнья кичүләрен ничек кичмәссең?!»

Риваять ителде. Бер кеше Шәкыйкъ янына килде һәм: «Миңа васыять ит», – диде. Шәкыйкъ әйтте: «Өч нәрсәне күңелеңә сал: Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кыл, Аллаһы Тәгалә сине нык итәр; Аллаһының дошманы белән сугыш, Аллаһы Тәгалә сиңа ярдәм кылыр; Аллаһының вәгъдәсенә ышан, Аллаһы Тәгалә шул вәгъдәне сиңа җиткерер».

وعن ابن مسعود ﷺ قال : لو ان اهل العلم صانوا علمهم وبذلوه لأهله لسادوا به أهل زمانهم ، ولكنهم بذلوه لأهل الدنيا لينالوا من دنياهم فهانوا على أهلها ، سمعت نبيكم ﷺ يقول : "من جعل الهموم هما واحدا كفاه الله ما أهمه من امر دنياه ، ومن سغلته هموم احوال الدنيا لم يبال الله تعالى في اي اودبة النار أهلكه ، وأي أودية النار عذبه".

Ибен Мәсгуд разыяллаһү ганһүдән риваять ителде. Ул әйтте: «Әгәр дә гыйлем әһелләре үзләренең гыйлемнәрен сакласалар, ул гыйлемне

кешесенә бирсәләр, шул гыйлем сәбәпле замана халкына хуҗа булырлар иде. Ләкин дөньяларына ирешер өчен алар дөнья халкына ул гыйлемне бирделәр. Һәм дөнья халкы алдында алар хур булып калдылар». Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән ишеттем. Ул әйтте: «Кем дә кем бөтен кайгыларын ташлап, ахирәт кайгысы белән генә калса, дөнья эшендә кайгыртырлык нәрсәсендә Аллаһы Тәгалә аңа ярдәм итәр. Әгәр дөнья кайгылары кешене шөгыльле кылса, тәмугның теләсә кайсы чокырында булса да, Аллаһының аны һәлак итәргә һәм теләсә нинди чокырда газапларга исе китмәс».

Әйтелде: «Тәүратта язылган: «Әй адәм улы, кулыңны селкет. Әгәр хәрәкәтләндерсәң, ризыгыңны киң кылырмын. Боерган нәрсәмдә Миңа буйсын, синең хәлеңне төзәтә торган нәрсәне Миңа өйрәтмә».

Гали разыяллаһу ганһүдән риваять ителде. Ул әйтте: «Исламның терәге дүрттер: анык булу; эшне уртага салып кылу; сабырлык; сугыш кылу».

Бу дүрт нәрсәне галимнәр болай тәфсир иттеләр:

Якыйн ике төрледер: Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен генә чын күңелдән гамәл кылу. Гамәле белән дөнья максатын һәм халыкның ризалыгын теләмәү; Аллаһының ризык бирергә кылган вәгъдәсенә ышану.

Гадел ике төрледер: әгәр аның өстендә кеше хакы булса, аны соралмастан элек үтәү; аның үзенең кеше өстендә хакы булса, ул хакны теләүдә йомшаклык күрсәтү.

Сабырлык ике төрледер: Аллаһы Тәгаләнең фарызларын үтәүдә сабырлык кылу һәм Аллаһы Тәгалә тыйган нәрсәгә түзү.

Сугыш кылу ике төрле: шайтан дошманыңнан гафил булмавыңдыр. Чөнки әгәр син аннан гафил булсаң, ул синнән гафил түгел. Ул шайтан бүре кебек. Әгәр бүре куй көтүе эченә керсә һәм һәрбер куй ул бүредән гафил булса, ул бүре куйларны аладыр. Дөреслектә, адәм баларының фетнәсенең күбрәге мал өчендер. Сине алдамасын өчен малның азы белән риза бул.

Шәкыйкътән риваять ителде, ул Хатим Әсамгә әйтте: «Миңа күптән бирле киләсеңме?» Хатим Әсам әйтте: «Утыз елдан бирле киләм». Шәкыйкъ әйтте: «Бу утыз елда нәрсә белдең?» Әйтте: «Алты сүзне өйрәндем. Әгәр шул алты сүз белән гамәл кылган булсам, мине дөнья фетнәсеннән коткаруларын өмет итәр идем. Шәкыйкъ әйтте: «Миңа ул алты сүзне сөйлә, шаять, мин ул алты сүз белән гамәл кылырмын да, дөнья фетнәсеннән котылырмын». Хатим әйтте: «Беренчесе: Аллаһы Тәгаләнең аяте тәфсирендә уйладым:

وَمَا مِنْ دَابَّةٍ فِي الْأَرْضِ إِلَّا عَلَى اللَّهِ رِزْقُهَا

«Җир йөзендә нинди генә җан иясе булсын, аның ризыгы Аллаһы Тәгалә хозурындадыр». Аллаһы Тәгалә ризыкландыра торган шул хайваннардан үземне күрдем дә, минем өчен булган ризык миңа ирешер, дип белдем. Зур булса да, Аллаһы Тәгалә филне ризыкландыра, кечкенә булса да, чебенне дә онытмый. Инде эшемне Аллаһы Тәгаләгә тапшырдым һәм гыйбадәт белән шөгыльләндем, гыйбадәттән башканы кайгыртмас булдым. Шәкыйкъ әйтте: «Син аңлаган әйбер хушдыр. Икенчесе нәрсә?» Әйтте:

إِنَّمَا الْمُؤْمِنُونَ إِخْوَةٌ

«Мөэминнәр бер берсенә кардәшләрдер», – дигән, аятькә карадым. Барча мөэминнәрне үземә кардәш дип белдем. Кардәш булган кеше үзенең кардәшенә миһербанлы булырга тиеш. Күрдем ки, кешеләр арасында пәйда була торган дошманлыкның асылы көнчелектәндер, көнчелекне күңелемнән тәмам чыгарганга кадәр тырыштым. Хәтта күңел шундый хәл хозурында калды, әгәр дә мәшрикъта бер мөэмингә кайгы ирешсә, мин аны кайгырта торган булдым. Гуя ул кайгы минем үземә ирешкән кайгы кебек булды. Әгәр мәгърибтә бер мөселманга изгелек ирешсә, мин шатланам, хәтта ул шатлык миңа ирешкән кебек булыр». Шәкыйкъ әйтте: «Уйлаганың, аңлаганың ни хуштыр! Өченчесе нәрсә?» Әйтте: «Уйладым һәм һәрбер мөселманга дүс барлыгын таптып. Дус кеше дустына дуслыгын белдерергә тиеш. Үземнең дустымны Аллаһының гыйбадәте, дип таптым. Аллаһының тәгатеннән башкасы, бөтен дуслар миннән киселәчәкләр, мәгәр Аллаһының тәгате генә киселмиячәк. Чөнки ул тәгать кабердә дә, Кыяматтә дә, сират өстендә дә минем беләндер. Бәс мин бөтен дуслардан аерылдым. Аллаһы Тәгаләнең тәгатен дус тоттым». Шәкыйкъ әйтте: «Аңлаганың ни хушдыр! Дүртенчесе нәрсә?» Хатим әйте: «Уйладым һәм һәрбер адәмдә дошман булуын таптым. Дошманга дошманлык кылу да, аннан саклану да тиештер. Үземнең дошманым, дип кәферне һәм шайтанны белдем. Кәфернең дошманлыгын җиңелрәк таптым, чөнки кәфер минем белән сугышса, мине үтерсә, мин шәһид булам. Әгәр мин аны үтерсәм, әҗерле булам. Шайтанның дошманлыгын катырак күрдем. Чөнки ул мин аны күрмәгән

урыннан күрәдер. Үзе белән бергә минем дә утта булуымны телидер. Тереклегем кадәре мин аның дошманлыгы белән шөгыльләндем. Шайтаннан башканың дошманлыгын ташладым». Шәкыйкъ аңа әйтте: «Аңлаган нәрсәң ни хуштыр? Бишенчесе нәрсә?» Хатим әйтте: «Уйладым, һәрбер кешегә өй таптым. Өйне төзү лязем дер. Үз урынымны кабер белдем. Бәс мин кабер зиннәтләү белән шөгыльләндем». Шәкыйкъ әйтте: «Аңлаганың ни хушдыр, алтынчысы нәрсә?» Хатим әйтте: «Уйладым да, һәр нәрсәне теләүче бардыр. Минем теләүчем үлем фәрештәсе, дип белдем. Ул үлем фәрештәсе миңа кайчан килүен белмим. Иренең өенә бара торган яшь хатын төсле мин дә үлем өчен хәзерләндем. Кайчан гына миңа килсә дә, мин аннан кичектерүне теләмим». Шәкыйкъ әйтте: «Аңлаганың гаҗәеп яхшы. Әгәр шуның белән гамәл кылсаң син дә, мин дә котылу табарбыз».

Габдрахман бине Әбү Ләйләдән риваять ителде. Ул әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә бер кеше килде һәм әйтте: «Әй Пәйгамбәр, дөямне буш җибәреп, Аллаһыга тапшырыйммы яки бәйләп, Аллаһы Тәгаләгә тапшырыйммы?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Юк, бәйлә дә, Аллаһы Тәгаләгә тапшыр».

Кайбер хәкимнәр әйттеләр: «Аллаһы Тәгаләнең вәлиләренең сыйфаты өч нәрсәдер: һәрнәрсәдә Аллаһы Тәгаләгә ышану; һәрнәрсәдә Аллаһы Тәгаләгә мохтаҗ булу һәм һәрнәрсәдә Аллаһы Тәгаләгә кайтудыр».

Фудайл әйтте: «Кешеләрнең кешеләргә иң сөеклесе кешеләргә ихтыяҗы төшмәгәннәредер, алардан һичнәрсә сорамас. Кешеләрнең кешеләргә нәфрәтләрәге аларга мохтаҗ булганыдыр. Кешеләрнең

Аллаһы Тәгаләгә иң сөеклесе Аллаһы Тәгаләгә мохтаҗ булганы һәм аннан сораганыдыр. Адәмнәрнең Аллаһы Тәгаләгә иң ачулысы Аллаһы Тәгаләдән һич сорамаганыдыр».

Риваять ителде, Локман хәким үлеме якынлашкач, улына әйтте: «Әй улым, бу вакытка кадәр мин сиңа бик күп васыятьләр әйткән идем. Инде сиңа алты төрле нәрсәләр белән васыять итәм, аларда әүвәлгеләр һәм соңгыларның гыйлеме бардыр. Беренчесе, нәфесең дөнья белән шөгыльләнмәсен, мәгәр гомер итәр өчен кирәккән микъдар кадәр генә шөгыльләнсен. Икенчесе, йомышың кадәр Раббыңа гыйбадәт кыл. Өченчесе, никадәр торуны теләсәң шулкадәр ахирәт өчен гамәл кыл. Дүртенчесе, эшең үзеңне уттан коткару хакында гына булсын, сиңа уттан котылу беленмәгәндә. Бишенчесе, Аллаһы Тәгаләнең газабына түзгән кадәр гөнаһка батырчылык ит. Алтынчысы, әгәр Аллаһы Тәгаләгә гөнаһ кылуны теләсәң, Аллаһы һәм Аның фәрештәләре сине күрми торган урынны эзлә».

Бер хәкимнән: «Тәвәккәл белән якыйн арасында аерма ни?» – дип сорадылар. Ул хәким әйтте: «Бөтен ахирәт сәбәпләре белән Аллаһы Тәгаләгә ышануың якыйндыр. Бөтен дөнья сәбәпләре белән Аллаһыга ышануың тәвәккәлдер».

Әйтелде: «Тәвәккәл ике төрледер. Берсе ризык турында, ул тәвәккәл хакында ышанудан башка һич нәрсә дөрес түгел. Икенчесе, гамәл савабын таләп итү. Аллаһы Тәгаләнең сәваб хакындагы вәгъдәсенә ышану һәм гамәле хакында курку, ул гамәл аңардан кабул ителгәнме яисә юкмы».

Гата бине Сәбит Ягъlә бине Мәрәдән риваять итте, ул әйтте: «Гали разыяллаһү ганһүнең сәхабәләреннән булган кешеләр белән җыелдык һәм

«Мөэминнәрнең әмере Галине сакласак яхшы булыр, чөнки Гали сугышчыдыр. Аның өстенә золымлык кылынмас дип ышана алмыйбыз», – дидек. Без аның бүлмәсенең ишеге янында булган вакытта, хәзрәти Гали намазга чыкты һәм сорады: «Ни эшлисез?» Без әйттек: «Сине сакладык, чөнки син сугышчысың, золым ителүеңнән курыктык». Гали әйтте: «Мине күк яисә җир әһелләреннән саклыйдыгызмы?» Әйттек: «Юк, җир халкыннан сакладык. Сине күк әһелләреннән сакларга безнең ничек көчебез җитсен». Гали разыяллаһү ганһү әйтте: «Аллаһының көче җитмәгән җирдә һичнәрсә юк. Һәм ике саклаучы фәрештәсе булмаган һичберәү дә юктыр, хәтта аның тәкъдире җиткәнгә кадәр. Әгәр ул кешенең тәкъдире җитсә, ул ике фәрештә тәкъдир һәм кеше арасына катышмыйлар».

## Тәкъвалык турында

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Котәдәдән риваять итте, ул әйтте: «Габдулла бине Мутраф әйтә иде: «Ике кешегә очрарсың, берсе – бик күп ураза тотучы, намаз укучы һәм садака бирүче, ә икенчесенең исә савабы аңардан күбрәк». Әйтелде: «Бу ничек булыр?» Әйтте: «Ул савабы күбрәге бигрәк тә хәрамнан һәм шөбһәдән сакланучырагыдыр».

عن عمارة أنه قال : لما توجه عبد الله بن رواحة نحو مؤنة ، قال : يا رسول الله أوصني ، قال : "إنك تقدم أرضا السجود بها قليل ، فاستكثر من السجود بها" ، قال : زدني ، قال : "اذكر الله فإنه عون لك على ما تطلب" ، فولي ثم رجع إليه ، فقال : يا رسول الله زدني ، قال : "اذكر الله تعالى ، فإن الله تعالى وتر

يجب الوتر" ، قال زدني ، قال : "نعم لا تعجزن ، لا تعجزن ، إن أسأت عشرا أن تحسن واحدة".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Гыймәрадән риваять итә. Ул әйтте: «Габдулла бине Рәваха Мөэнә авылына таба юнәлгәндә: «Әй Рәсүлуллаһ, миңа васыять ит», – диде. Рәсүлуллаһ әйтте: «Син сәҗдә аз кылынган җиргә барасың, ул җирдә сәҗдәне күп кыл». Габдулла бине Рәвахә әйтте: «Миңа васыятеңне арттыр». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгаләне зекер кыл, чөнки Аллаһының зикерендә син тели торган нәрсәгә ярдәм булыр». Габдулла бине Рәвахә китте соңыннан янә Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә кайтты һәм әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, миңа арттыр». Рәсүлуллаһ әйтте: «Аллаһы Тәгаләне зекер ит, чөнки Аллаһы Тәгалә тактыр гамәлдә такны сөядер». Габдулла әйтте: «Арттыр». Рәсүлуллаһ әйтте: «Дөрес, аптыратма, аптыратма, аптыратма, ун явызлык кылсаң, аның бәрабәренә бер изгелек кылуың җитә».

عن أنس بن مالك ﷺ أن رسول الله ، قال : "تقبلوا لي ستا أتقبل لكم الجنة : إذا حدثتم فلا تكذبوا ، وإذا وعدتم فلا تخلفوا ، وإذا ائتمنتم فلا تخونوا ، وغضوا أبصاركم ، واحفظوا فروجك ، وكفوا أيديكم وأرجلكم عن الحرام ، تدخلوا جنة ربكم".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әнәс бине Мәликтән риваять итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Минем өчен алты нәрсәне кабул итегез, сезнең өчен җәннәтне кабул итәрмен, ягъни сезнең җәннәткә керүегезне өстемә алырмын: әгәр сүз сөйләсәгез, ялганламагыз; вәгъдә кылсагыз, бозма-

гыз; әманәт алсагыз, хыянәт итмәгез; күзегезне йомыгыз; гыйффәтегезне саклагыз; кулларыгыз һәм аякларыгыз хәрамнан ерак булсын, Раббыгызның оҗмахына керерсез».

وعن الحسن ، عن عمران بن الحصين ﷺ أن النبي ﷺ قال : "قال الله تعالى : عبدي ، أد ما افترضت عليك تكن من أعبد الناس ، وانته عما نهيتك تكن من أورع الناس ، واقنع بما رزقتك تكن من أغنى الناس".

Хәсән Гыймран бине Хасыннән риваять итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй Минем бәндәм! Мин синең өчен фарыз кылган нәрсәне үтә. Әгәр үтәсәң, кешеләрнең иң гыйбадәтчәннәреннән булырсың. Мин тыйган нәрсәдән тыел, адәмнәрнең иң тәкъваларыннан булырсың. Мин сиңа биргәнгә канәгать бул, кешеләрнең иң байларыннан булырсың».

Фудайл бине Гаядтән риваять ителде, ул әйтте: «Биш төрле нәрсә ахирәт бәхетенең галәмәтләреннәндер: күңелдә тәмам Аллаһыга ышану; диндә тәкъвалык; дөньяда заһидлык; ике күздә оят; тәндә куркудыр. Һәм биш нәрсә ахирәттә бәхетсезлек галәмәтләреннәндер: күңелдә каралык; ике күздә тынлык, яшьнең юклыгы; оятның азлыгы; дөньяга омтылу; үлемне оныткан кебек теләкләргә иярү».

Гомәр бине Хаттабтан риваять ителде, ул әйтте: «Шөбһәгә яисә хәрамга төшүебездән курыкканлыктан, хәләлнең дә уннан тугыз өлешен кылмый, ташлый идек».

Габдулла бине Мәсгудтән ошбуның охшашы риваять ителде.

Тәҗрибәле кешеләрнең кайберләре әйттеләр: «Дөнья эшенең барчасы гаҗәептер. Ләкин мин биш төрле нәрсәгә алданган адәм баласына гаҗәпләнәм.

Беренчесе, дөньяда артык мал иясенә гаҗәпләнәм. Мохтаҗ һәм фәкыйрь булачак көненең артыгы өчен ничек бер дә аяк басмый икән? Икенче, сөйли торган телгә гаҗәпләнәм. Ничек ул тел үз нәфесенә буйсына, Аллаһы Тәгаләнең зикереннән һәм Коръән укудан йөз чөерә? Өченчесе, эшсез, буш һәм сәламәт кешегә гаҗәпләнәм. Мин аны һәрвакыт уразасыз күрәмен. Ничек ул кеше айда өч, яки шуңа охшаш көн ураза тотмый һәм ничек ул кеше Кыямәт уразасы хакында бер дә фикерләми? Дүртенчесе, түшәгенә ятып таңга кадәр йоклаучыга гаҗәпләнәм. Ничек ул төнге ике рәкәгать намазның әҗере хакында бер дә фикерләми? Әгәр фикерләсә, бер вакытка гына торыр иде. Бишенчесе, Аллаһы Тәгаләнең хәрамына батырчылык иткән кешегә гаҗәпләнәм. Аллаһы Тәгалә тыйган нәрсәгә дучар була. Һәм ул эше аңа Кыямәт көнендә күрсәтеләчәген белә. Тыелыр өчен, соңгы эш хакында ничек бер дә уйламый?»

Ибен Мөбарәктән риваять ителде. Ул әйтте: «Хәрамнан булган бер акчаны алмавым садака кыла торган йөз мең акчадан артыграктыр».

Янә аннан риваять ителде, ул Габдулла бине Мөбарәк Шамга барып, хәдис язганда каләме сынды, язуын дәвам итәр өчен бер кешедән каләм алып торды. Язудан туктагач, каләм алганын онытты, каләмне савытына салды. Мәрвәгә кайткач каләмне күрде һәм бирмәгәнен исенә төшерде. Каләмне кайтарыр өчен Шамга чыгарга әзерләнде.

وعن الشعبي أنه قال : سمعت النعمان بن بشير يقول : سمعت رسول الله ﷺ يقول : "الحلال بين والحرام بين ، وبينهما أمور مشتبهات لا يعلمها كثير من الناس ، فمن اتقى الشبهات ، فقد استبرأ لدينه وعرضه ، ومن وقع في الشبهات وقع في

الحرام ، كالراعس الذي يرعى الغنم حول الحمى يوشك أن يقع فيه ، ألا وإن لكل ملك حمي ، وإن حمي الله محارمه ، ألا وإن في الجسد مضغة ، فإن صلحت صلح الجسد كله ، وإن فسدت فسد الجسد كله ألا وهي القلب".

Шәгъбидән риваять ителде. Ул әйтте: «Ногман бине Бәширдән ишеттем, ул әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнең шулай әйткәнен ишеттем: «Хәләл нәрсә ачык һәм хәрам нәрсә ачык. Болар арасында шөбһәле нәрсәләр бардыр. Аларны кешеләрнең күбесе белми. Кем дә кем шөбһәләрдән сакланса, тәхкыйк, ул кеше дин белән йөзен саклады. Кем дә кем шөбһәләргә төшсә, хәрамга төшәр. Койма янында куйларны ашата торган көтүче кебек. Ул куйның койма эченә, бакчага керү ихтималы бик якын. Белегез, һәрбер патшаның калын коймасы бар. Дөреслектә, Аллаһы Тәгаләнең коймасы хәрам ителгән нәрсәләредер. Белегез тәндә бер ит кисәге бар, әгәр ул ит кисәге төзәлсә, бөтен тән төзәлер, әгәр ул ит кисәге бозылса, бөтен тән бозылыр. Ул ит кисәге – йөрәктер».

Әбү Муса Әшгаридән риваять ителде, ул әйтте: «һәрнәрсәнең бер чиге бардыр. Исламның чикләре тәкъвалык, түбәнчелек һәм шөкердер. Тәкъвалык, бөтен эшләрнең патшасы. Түбәнчелек, тәкәббер-лектән бизү. Сабырлык, җәһәннәмнән котылу. Шөкер кылу исә оҗмах белән өстенлек табу».

وعن النبي ﷺ انه قال : "لو صليتم حتى تكونوا كالحنايا ، وصمتم حتى تكونوا كالأوتار ، فما ينفعكم إلا بالورع".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Сезгә файда бирелмәс, мәгәр тәкъвалык белән генә бирелер».

Фәкыйһ әйтте: «Тәкъвалык галәмәте, үз-үзенә ун нәрсәне фарыз дип белү. Беренчесе, телне гайбәт сөйләүдән саклау. Аллаһы Тәгалә әйтте:

وَلَا يَغْتَبْ بَعْضُكُمْ بَعْضًا

«Бер-берегезне гайбәт итмәгез». (Хуҗүрат: 12) Икенчесе, явыз уйлардан саклану. Аллаһы Тәгалә әйтте:

اجْتَنِبُوا كَثِيرًا مِنَ الظَّنِّ إِنَّ بَعْضَ الظَّنِّ إِثْمٌ

«Уйларның күбрәгеннән сакланыгыз, чөнки уйларның кайберләре гөнаһтыр». (Хуҗүрат: 12) Һәм Пәйгамбәр галәйһиссәләмнең сүзе бар:

لقول النبي ﷺ : "إياكم والظن ، فإنه أكذب الحديث"

«Сез начар уйлардан сакланыгыз. Чөнки ул уй белән әйтелгән сүз, сүзләрнең ялганрагыдыр». Өченчесе, мәсхәрә кылудан саклану. Аллаһы Тәгалә әйтте:

لَا يَسْخَرْ قَومٌ مِنْ قَوْمٍ عَسَى أَنْ يَكُونُوا خَيْرًا مِنْهُمْ

«Һичбер кавем икенче халыкны мыскыл итмәсен. Шаять, мыскыл ителгән халык мыскыл итүчеләрдән изгерәктер». (Хуҗүрат: 11) Дүртенчесе, хәрамнардан күзне йому.

قُلْ لِلْمُؤْمِنِينَ يَغُضُّوا مِنْ أَبْصَارِهِمْ

«Мөэминнәрә әйт: алар күзләрен йомсыннар». (Нур: 30) Бишенчесе, телнең раслыгы. Аллаһы Тәгалә әйтте:

وَإِذَا قُلْتُمْ فَاعْدِلُوا

«Сөйләшсәгез, уртага салып сөйләгез». (Әнгам: 152) Алтынчысы, үз-үзенә исе китмәсен өчен, нигъмәтләрне Аллаһы Тәгаләдән дип тану. Аллаһы Тәгалә әйтте:

بَلِ اللَّهُ يَمُنُّ عَلَيْكُمْ أَنْ هَدَاكُمْ لِلْإِيمَانِ إِنْ كُنتُمْ صَادِقِينَ

«Әгәр сез тугрылыклы булсагыз, Аллаһы Тәгалә сезне нигъмәтләндереп иманга күндерер». Җиденчесе, тиешле урынга малны сарыф итү, тиешсез урынга сарыф итмәү. Аллаһы Тәгалә әйтте:

وَالَّذِينَ إِذَا أَنفَقُوا لَمْ يُسْرِفُوا وَلَمْ يَقْتُرُوا وَكَانَ بَيْنَ ذَلِكَ قَوَامًا

«Ул мөэминнәр шундый кешеләрдер ки, малларын гөнаһ урынга сарыф итмиләр, гыйбадәт урыныннан тыймыйлар. Ул мөэмин кеше ике уртада гадел булды». (Фуркан: 67) Сигезенчесе, үзенә зурлыкны һәм тәкәбберлекне теләмәү. Аллаһы Тәгалә әйтте:

تِلْكَ الدَّارُ الْآخِرَةُ نَجْعَلُهَا لِلَّذِينَ لَا يُرِيدُونَ عُلُوًّا فِي الْأَرْضِ وَلَا فَسَادًا

«Ул ахирәт йортын, җир йөзендә олуглык теләмәгән һәм бозыклык кылмаган кешеләргә кылдык». Тугызынчысы, рөкугъ һәм сәҗдәләрен саклап, биш вакыт намазны тәмам кылу. Аллаһы Тәгалә әйтте:

حَافِظُوا عَلَى الصَّلَوَاتِ وَالصَّلَاةِ الْوُسْطَى وَقُومُوا لِلَّهِ قَانِتِينَ

«Намазларны һәм урта намазын саклагыз. Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен буйсынып торыгыз». (Бакара: 283) Унынчысы, сөннәт хозурында һәм җәмәгать арасында булу. Аллаһы Тәгалә әйтте:

وَأَنَّ هَذَا صِرَاطِي مُسْتَقِيمًا فَاتَّبِعُوهُ وَلَا تَتَّبِعُوا السُّبُلَ

فَتَفَرَّقَ بِكُمْ عَنْ سَبِيلِهِ ذَلِكُمْ وَصَّاكُمْ بِهِ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ

«Дөреслектә, бу Минем тугры юлымдыр. Бәс шуңа иярегез, башка юлларга иярмәгез. Әгәр иярсәгез, алар сезне Аллаһының юлыннан аерырлар.

Аллаһы Тәгалә сезгә шуның белән боерды. Шаять, сез сакланырсыз». (Әнгам: 153)».

Мөхәммәд бине Кәгъб әйтте: «Өч нәрсә бар, әгәр дә мәңге шул өч нәрсәне куймаска көчең җитсә, шулай эшлә. Һичберәүгә золым итмә. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

إِنَّمَا بَغْيُكُمْ عَلَى أَنْفُسِكُمْ

«Золымыгыз тик үзегезгә генә һәм һичкемгә түгел». (Юныс: 23)

Һичкемгә мәкер кылма, чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

وَلَا يَحِيقُ الْمَكْرُ السَّيِّئُ إِلَّا بِأَهْلِه

«Яман мәкер мәкер кылучының үзенә генә буладыр». (Фәтыр: 43)

Вәгъдәңне мәңге бозма, чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

فَمَنْ نَكَثَ فَإِنَّمَا يَنْكُثُ عَلَى نَفْسِه

«Вәгъдәне бозган кеше үз зарарына гына бозадыр». (Фәтех: 10).

Ибраһим бине Әдһәм әйтте: «Заһидлек өч төрледер. Бер төре фарыз зөһед, икенчесе савап зөһет, өченчесе гафиять зөһедтер. Фарыз зөһед – хәрамнан саклану. Савап зөһед – хәләл нәрсәне саклау. Гафиять зөһед – шөбһәле нәрсәләрдән саклануДЫР».

Ибраһим бине Әдһәм әйтте: «Тәкъвалык ике төрледер: фарыз тәкъвалык һәм саклану өчен тиешле тәкъвалык. Фарыз булган тәкъвалык Аллаһы Тәгаләнең гөнаһ дип әйткән эшләреннән саклану. Саклык тәкъвалык шөбһәләрдән саклануДЫР. Кайгы да ике төрледер: бер кайгы – синең файдаңдыр, икенче кайгы – синең зарарыңадыр. Синең файдаңа булган

кайгы – ахирәт өчен кайгыруың, синең зарарыңа булган кайгы исә – дөньяга һәм аның зиннәтләренә кайгыруыңдыр».

Фәкыйһ әйтте: «Чын тәкъвалык шулдыр ки, күзен хәрамнан йому, телне ялган һәм гайбәттән тыю, бөтен әгъзаларын хәрамнан саклаудыр».

Гомәр бине Хәттабтан риваять ителде: «Шамнан зәйтүн мае китерелде. Зәйтүн мае мичкәдә иде. Гомәр ул зәйтүн маен кешеләргә чынаяклар белән бүлде. Хәзрәти Гомәрнең янында улы бар иде, аның чәчләре җитүле иде. Май савыты бушаган саен, ул майның калганы белән башын сыйпый иде. Гомәр разыяллаһү ганһү аңа әйтте: «Чәчеңнең мөселманнар маена бик кызыкканын күрәм». Соңыннан кулыннан тотып, аны чәч алучыга алып барды һәм чәчен алдыртты. «Синең өчен бу җиңелрәктер», – диде.

Ибраһим бине Әдһәмнән риваять ителде, Гоммәнгә барыр өчен бер хайванны хезмәткә алды. Барган вакытта камчысы төште. Хайваннан төште, ул хайванны бәйләп куйды, җәяү кайтып, камчысын алды. Аңа: «Атыңның башын борып, камчыны алсаң, ни булыр иде?» – диделәр. Әйтте: «Мин аны барырга, дип яллалым, кайтырга дип түгел».

عن معاذ ﷺ قال كنت مع النبي ﷺ وهو على حمار عليه برذعة فقال : "يا معاذ هل تدري ما حق الله على العباد؟" قلت : الله ورسوله اعلم ، قال : "أن يعبدوا الله ولا يشكروا به شيئا" ثم قال : "وهل تدري ما حق العباد على الله تعالى إذا فعلوا ذلك" ، فقلت : الله ورسوله اعلم ، قال : "أن يدخلهم الجنة".

Мөгаз разыяллаһү ганһүдән риваять ителә, ул әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм белән бардым, ул ишәк өстендә бара иде. Әйтте: «Әй Мөгаз, бәндәләр

өстендә Аллаһының хакы нәрсә?» Мин әйттем: «Аллаһы һәм Аның Рәсүле – белүчерәктер». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Бәндәләрнең Аллаһыга гыйбадәт кылу һәм гыйбадәттә Аңа һичкемне ширек итмәүләре Аллаһының бәндәләре өстендә булган хакыдыр». Моннан соң әйтте: «Әгәр бәндәләр шуны эшләсәләр, бәндәләрнең Аллаһы Тәгалә өстендә хаклары нәрсә?» Мин: «Аллаһы һәм Аның Рәсүле белүчерәктер», – дидем. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы каршында хаклары – ул бәндәләрне җәннәткә кертүедер».

## Оялу турында

عن أبي أيوب الانصاري ﷺ أن النبي ﷺ قال : "أربع من سنن المرسلين : التعطر ، والنكاح ، والسواك ، والحياء".

Әбү Әюб Ансари Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Дүрт төрле нәрсә пәйгамбәрләр сөннәтеннәндер: хушбуй куллану; никахлану; мисвак куллану; оялчан булу».

عن عقبة بن عمرو ﷺ عن النبي ﷺ انه قال : "إن مما أدرك الناس من كلام النبوة الأولى إذا لم تستح فافعل ما شئت".

Гокъбә бине Гамир разыяллаһү ганһүдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Оялу әүвәлге пәйгамбәрлектән адәмнәргә ирешкән нәрсә җөмләсеннәндер. Оялмасаң, теләгәнеңне эшлә».

عن عبد الله بن مسعود ﷺ قال : قال رسول الله ﷺ : "استحيوا من الله تعالى حق الحياء" ، فقالوا : إنا نستحي من الله والحمد لله ، قال : "ليس ذلك من الحياء ، ولكن من استحي من الله الحياء ، فليحفظ الرأس وما حوى ، ةالبطن

وما وعى ، وليذكر الموت والبلى ، ومن اراد الآخرة ترك زينة الدنيا ، فمن فعل ذلك ، فقد استحي من الله حق الحياء".

Габдулла бине Мәсгудтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгаләдән чын оялу белән оялыгыз». Әйттеләр: «Әлхәмдүлилләһ, без Аллаһыдан оялабыз». Әйтте: «Ул оялу, оялу түгел. Мәгәр Аллаһыдан оялган кеше башын һәм корсагын сакласын. Үлем белән черүне искә алсын. Кем дә кем ахирәтне теләсә, дөнья зиннәтен куяр. Кем дә кем шуны эшләсә, Аллаһыдан чын оялу белән оялыр».

وعن الحسن ، عن النبي ﷺ أنه قال : الحياء من الإيمان ، والإيمان في الجنة ، والبذاء من الجفاء ، والجفاء من النار".

Хәсән Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Оялу – иманнан, иман – җәннәттәдер. Оятсызлык – гөнаһтан, гөнаһ исә – җәһәннәмдәдер».

Салман Фарсидән риваять ителде. Ул әйтте: «Өч мәртәбә үлеп, өч мәртәбә терелүем, минем кемнең булса да гаурәтенә каравымнан, яисә минем гаурәтемә икенче берәүнең каравыннан артыграктыр».

Гали разыяллаһү ганһүдән риваять ителде. Ул әйтте: «Караучыга һәм күрсәтүчегә Аллаһы Тәгаләнең ләгънәте булсын».

عن النبي ﷺ أنه قال : "ر يحل لأحد أن يدخل الحمام إلا بمئزر".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Япмасыз мунчага керү һичкемгә дөрес түгел».

Хәсән Басридән риваять ителде, ул әйтте: «Мунчага ике төрле изар белән генә керү лаектыр. Беренчесе гаурәт өчен булса, икенчесе күз өчен

булыр». Ягъни кешеләрнең гаурәтләреннән күзен йомар.

Гайсә бине Мәрьям галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул әйтте: «Караудан сак булыгыз. Чөнки ул карау күңеленә шәһвәт орлыгы чәчер. Иясенә фетнә булырга күңелендә шәһвәт булу җитәдер».

Бер хәкимнән: «Фәсикъ кем?» – дип сорадылар. Ул әйтте: «Кешеләрнең ишегеннән һәм аларның гаурәтләреннән күзен йоммаган кеше».

وعن عطاء أنه قال : مر النبي ﷺ برجل يغتسل فقال : "يا أيها الناس ، إن الله حيي حليم ستير ويحب الحياء والستر ، فإذا اغتسل أحدكم فليتوار عن أعين الناس".

Гатадән риваять ителде, Пәйгамбәр галәйһиссәләм госел кыенучы кеше янынннан үтте һәм әйтте: «Әй кешеләр, Аллаһы Тәгалә терек, хәлим һәм гөнаһларны каплаучыдыр. Оят белән каплануны сөя. Әгәр берегез госел алса, кешеләр күзеннән яшеренсен».

Әнәс бине Мәлик разыяллаһү ганһүдән риваять ителә: «Рәсүлуллаһ кадаи хаҗәт итүне теләсә, җиргә якынлашмыйча киемен күтәрми иде».

Фәкыйһ әйтте: «Оят ике төрле: синең белән кешеләр арасында һәм Аллаһы белән синең арада. Үзең белән башка кешеләр арасында булган оялу – хәләл булмаган нәрсәдән күзеңне йомудыр. Әмма синең белән Аллаһы Тәгалә арасында була торган оялу – Аның нигъмәтен танып, Аңа гөнаһ кылудан оялуыңдыр».

Гомәр разыяллаһү ганһүдән риваять ителде. Гомәр Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмгә кергәч, аны елаган хәлдә тапты. «Әй Рәсүлуллаһ, сине нәрсә елатты?» – дип сорады. Пәйгамбәр галәйһиссәләм

әйтте: «Җәбраил галәйһиссәләм миңа, Аллаһы Тәгалә Ислам динендә картайган бәндәне газап кылырга ояла, дип хәбәр бирде. Исламда картайганнан соң ул карт кеше гөнаһ кылудан оялмыймы?»

وروى بهز بن حكيم ، عن أبيه ، عن جده ، قال : قلت : يا رسول الله عورتنا ، ما نأتي منها وما نذر؟ قال : "احفظ عورتك إلا من زوجتك أو ما ملكت يمينك" قال : قلت يا رسول الله أرأت إن كان احدنا خاليا ؟ قال : "فالله أحق أن يستحي منه".

Бәһз бине Хәким риваять итте. Ул әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, безнең гаурәтебез нәрсәдән килә һәм нәрсәдән кисәтелгән?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Гаурәтеңне хатыныңнан һәм мөлкәтең булган җәриядән башкадан сакла». Әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, безнең берәребез буш җирдә булса да, гаурәтен күрсәтмәсенме?» Әйтте: «Аллаһы Тәгаләдән оялу бигрәк тә тиешле».

Борынгыларның берсе үзенең улына әйтте: «Әгәр синең нәфсең сине олуг гөнаһ кылырга өндәсә, күккә кара, ул күктә булган күк әһелләреннән оял. Әгәр син аны эшләмәсәң, күзеңне җиргә ташла, ул җирдә булган кешеләрдән оял. Әгәр син күктәге халыктан да курыкмасаң һәм җирдәге кешеләрдән дә оялмасаң, үзеңне башка хайваннар җөмләсеннән сана».

Фудайл әйтте: «Ишегеңне биклисең, пәрдәңне каплыйсың һәм кешеләрдән ояласың. Ләкин күкрәгеңдәге Коръәннән һәм һичбер яшерен нәрсә яшеренә алмый калган Заттан оялмыйсың».

Мансур бине Гамәр әйтте: ««Хикмәт» мәҗмугасында шундый нәрсә бардыр: кем дә кем үз гаебен күрсә, башканың гаебен күрергә вакыты калмас. Кем

дә кем тәкъвалык киеменнән ялангач булса, һич нәрсә белән томалана алмас. Кем дә кем Аллаһының ризыгына разый булса, башканың милкендәге нәрсәгә кайгырмас. Кем дә кем золым кылычын чыгарса, аның белән үз кулы киселер. Кем дә кем кардәшенә кое казыса, аңа үзе төшәр. Кем дә кем башканың пәрдәсен ертса, үз гаурәте ачылыр. Кем дә кем үзенең хаталарын онытса, кешенең бер хатасын зурга санар. Кем дә кем күп эшкә чумса, тапталыр, ягъни олуг нәрсәләргә төшәр. Үзен генә уйласа, һәлак булыр. Үз акылына гына ышанса, таяр. Тәкәбберләнсә, кечерәер. Гамәлгә чумса, ялкаулаңыр. Кем дә кем халыкка мактанса, сынар. Ахмаклык күрсәтсә, шелтәләнер. Вак кешеләр белән иптәшлек итсә, хурга калыр. Галимнәр белән утырса, хөрмәтле булыр. Явыз урынга керсә, гаепләнер. Кем дә кем динне җиңелгә санаса, батар. Кем дә кем кешеләрнең малларын ганимәт санаса, фәкыйрьлеккә төшәр. Кемдер гафиятне көтсә, сабыр итәр. Кем дә кем үзенең баскан урынын белмәсә, үкенечтә йөрер. Кемдер Аллаһыдан курыкса, котылу табар. Кемдер эшләрен тәҗрибә кылмаса, алданыр. Кем дә кем хак ияләренә какса, үзе кагылыр. Кем дә кем көче җитмәгәнне өстенә алса, гаҗиз булыр. Кем дә кем үзенең әҗәлен белсә, өмете кыскарыр. Кем дә кем наданлык юлына гадәтләнсә, туры юлны ташлар».

## Ният белән гамәл кылу

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Зәйд бине Мәйсәрәдән риваять итте, ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйтәдер: «Мин һәрбер хәкимнең сүзен кабул итмим. Мәгәр Мин аның нияте белән теләгенә карыймын. Әгәр ул хәкимнең нияте һәм теләге Мин булсам,

аның сөйләшмәвен фикерләү кылам һәм сөйләмәсә дә аның сүзен зекер кылам».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Ибраһим Нәхгыйдән риваять итте, ул әйтте: «Бер кеше шундый сүзне сөйләр, хәлбуки сүзе арасында ачу бардыр. Ул ачуда яхшылыкны ният кылса, Аллаһы Тәгалә ул кешенең сүзе өчен кешеләрнең күңелләренә гозерне салыр. Хәтта ул кешеләр әйтерләр: «Бу сүзе белән яхшылыктан башканы теләмәде». Бер кеше хәер ният итмичә, матур сүзне сөйләсә, ул сүзне Аллаһы Тәгалә кешеләрнең күңеленә салыр. Хәтта әйтерләр: «Бу сүзе белән изгелекне теләмәде».

Гаун бине Габдулладан риваять ителде, ул әйтте: «Хәер ияләре үзара өч сүзне язышалар иде: «Кем дә кем ахирәт өчен гамәл кылса, Аллаһы Тәгалә аның дөнья эшләрен төзек кылыр. Кем дә кем эчен төзәтсә, Аллаһы Тәгалә аның тышын төзек кылыр. Кем дә кем үзе белән Аллаһы Тәгаләнең арасын төзек кылса, Аллаһы Тәгалә аның белән халык арасын төзек кылыр».

Хәсәннән, Аллаһы Тәгаләнең قل كل يعمل على شاكلته, ягъни «Һәркем нияте хозурына гамәл кыла» дигән сүзенең тәфсирендә риваять итте, гамәлнең дөреслеге ният беләндер».

قال النبي ﷺ : "نية المؤمن خير من عمله"

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Мөэминнең нияте гамәленнән изгедер».

Гыйлем ияләренең кайберләре әйтте: «Ни өчен нияте гамәлдән артык була? Чөнки эшләмәсә дә, яхшы нияте өчен саваплы була. Ниятсез гамәлгә савап булмый».

Гыйлем ияләреннән икенчеләре әйттеләр: «Чөнки нияте озын гамәле кыска булганы өчен мөэминнең

нияте гамәленнән артык була. Дөньяда калган чаклы изгелекне кылырга ният итә, ләкин калган гомерендә ниятләгән изгелекне кылырга көче җитми».

Кайберәүләре әйтте: «Чөнки ният йөрәк гамәле була. Йөрәк исә мәгърифәт урыныдыр. Мәгърифәт урыны булган нәрсә башка урыннарга караганда артыграк булыр».

وروى عن النبي ﷺ أنه قال : "يؤتى بالعبد يوم القيامة ، ومعه من الحسنات أمثال الجبال الرواسي فينادي مناد : من كان له على فلان مظلمة فليجيء وليأخذها ، فيجيء أناس فيأخذون من حسناته حتى لا يبقى له من الحسنات شيء ، فيبقى العبد حيران ، فيقول له ربه : إن لك عندي كنزا لم أطلع عليه ملائكتي ، ولا احدا من خلقي ، فيقول : يا رب ما هو؟ فيقول : نيتك التي كنت تنوي من الخير كتبتها لك سبعين ضعفا".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кыямәт көнендә олуг таулар кебек изгелекләре белән бергә бәндәне китерерләр. Бер чакыручы чакырыр: «Кемдә кемнең фәлән өстендә золым күргән хакы булса, килсен дә алсын». Бәс кешеләр килер дә ул бәндәнең изгелекләреннән алырлар, хәтта аның изгелекләреннән һичнәрсә калмас. Бәндә исе китеп калыр. Раббысы аңа әйтер: «Фәрештәләремә һәм башка һичбер халыкка белдермәгән синең Минем каршымда хәзинәң бар». Бәндә әйтер: «Әй Раббым, ул нәрсә?» Аллаһы Тәгалә әйтер: «Изгелеккә кылган ниятең, Мин аны җитмеш өлеш артык итеп яздым».

Хәбәрдә риваять ителде, Бәни Исраил гыйбадәт кылучылардан булган бер кеше комнан булган бер таучык яннан үтте. Үз-үзенә әйтте: «Әгәр шул тау он булып, Бәни Исраилгә ирешкән ачлык вакытында аларны туйдырсам иде». Үзләрендә булган пәйгам-

бәргә Аллаһы Тәгалә вәхи иңдерде: «Бу бәндәгә әйт: тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә әйтте: «Ул ком тавы он булып, садака итеп биргәнең кадәр савапны синең өчен важиб иттем».

Хәбәрләрдә килә, Кыямәт көнендә бәндә китерелер. Аның дәфтәре уң кулына бирелер, ул гамәл дәфтәрендә хаҗ, гомрә, җиһад, зәкәт һәм садака кебек изгелекләр күрер. Үз-үзенә: «Мин болардан һичберне дә кылганым юк, минем дәфтәрем түгелдер», – дип әйтер. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Укы, чөнки ул синең дәфтәреңдер. Чөнки син әгәр минем малым булса, хаҗ кылыр идем, дип гомер буенча яшәдең. Әгәр минем малым булса, җиһад кылыр идем, дидең. Ниятеңнән Мин сине рас дип белдем. Сиңа боларның һәрберсеннән савап бирдем».

Фәкыйһ әйтте: «Ниятнең раслыгы шуннан беленер, үзенең каршында булган аз белән саранланмас. Ул кешенең хаҗ кылырга акчасы җитмичә, юлда хаҗ кылыр өчен чыккан кешене күрсә, үз-үзенә әйтер: «Әгәр малым булса, чиксез хаҗ кылыр идем. Инде минем көчем юк икән, ошбу ике дирһәмне шул юлда калган хаҗига бирим». Әгәр сугышка барырга хәле җитмичә, юлда калган сугышчыны күрсә, әйтер: «Әгәр минем малым булса, сугыш кылыр идем. Инде минем көчем җитми икән, һич булмаса бу дирһәмнәрне ошбу мохтаҗ сугышчыга, яисә янындагы мескенгә бирим». Әмма үзендә булган аз акчасы белән саранлык кылса, ул кеше аз белән саранлык кылгач, күп булса да, саранлык кылачагын Аллаһы Тәгалә беләдер. Аның ниятендә саваб булмас. Шулай ук Коръәнне ятлау белән булыр. Әгәр мин Коръән ятласам, төн урталарында да, көндезләрдә дә Коръән укыр идем,

дип әйткән кеше ятлаган сүрәләрен укыса, Аллаһы Тәгалә беләдер ки, ул кеше калган сүрәләрен дә ятласа, укыячактыр. Аллаһы Тәгалә аңа бөтен Коръәнне ятлаган кешенең әҗерен бирер. Әгәр ул кеше ятлаганын да укымаса, аның нияте изге түгел икәнен, Аллаһы Тәгалә беләдер».

وروى سهل بن سعد الساعدي ، عن النبي ﷺ أنه قال : "نية المؤمن خير من عمله ، وعمل المنافق خير من نيته".

Сәһел бине Сәгъд Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Мөэминнең нияте гамәленнән изгедер. Монафыйкның гамәле ниятеннән изгедер. Һәрбер кеше үзенең нияте хозурында гамәл кыладыр».

وروى محمد بن علي ، عن النبي ﷺ انه قال : "من احب رجلا في الله لعدل ظهر منه ، وهو في علم الله من اهل النار ، آخره الله على حبه إياه ، كما لو أحب رجلا من اهل الجنة ، ومن ابغض رجلا في الله لجور ظهر منه ، وهو في علم الله من أهل الجنة آجره الله على بغضه إياه كما لو كان يبغض رجلا من أهل النار".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде. Ул әйтте: «Кем дә кем берәүне хаклыгы өчен Аллаһы ризалыгы өчен сөйсә, һәм ул сөюче кеше Аллаһының гыйлемендә тәмуглы булса, хаклыкны сөйгән кешене сөйгәне өчен Аллаһы Тәгалә аны әҗерле итәр. Җәннәт халкыннан булган кешене сөйгән кебек. Кем дә кем Аллаһы ризалыгы өчен бер кешегә, аннан чыккан золым, җәфа өчен ачуланса, ул ачуланган кеше Аллаһы Тәгалә гыйлемендә җәннәт әһеленнән булса, Аллаһы Тәгалә шул кешегә ачуланганы өчен аны әҗерле итәр. Җәһәннәм әһеленнән булган кешегә ачуланган кебек булыр».

Хәбәрдә риваять ителде: «Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәләмгә әйтте: «Әй Муса, кайчан булса да Минем өчен генә гамәл кылганың бармы?» Муса әйтте: «Әй Раббым, Синең өчен намаз укыдым, ураза тоттым, садака бирдем һәм сине зекер кылдым». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Намаз үзең өчен борһан, ягъни синең өчен дәлил, ураза калкан, садака Гарештән күләгә, зикер исә синең өчен яктыдыр. Инде кайсы гамәлне Минем өчен кылдың?» Муса галәйһиссәләм әйтте: «Әй Раббым, миңа Синең өчен була торган гамәлгә күндер». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй Муса, Минем өчен бер дус яисә дошман ясадыңмы?» Муса галәйһиссәләм, гамәлләрнең артыгы, Аллаһы юлында сөю һәм Аллаһы юлында ачулану икәнен белде».

وروى أبو هريرة ﷺ عن النبيﷺ انه قال : "إن الله تعالى لا ينظر إلى صوركم ن ولا إلى أموالكم ، ولا إلى أحوالكم ، وإنما ينظر إلى اعمالكم وإلى قلوبكم".

Әбү һөрәйрә Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә сезнең кыяфәтләрегезгә, малларыгызга һәм хәлләрегезгә карамый. Мәгәр Аллаһы Тәгалә сезнең гамәлләрегез белән күңелләрегезгә карыйдыр».

وروت عائشة ﷺ عن النبي ﷺ انه قال : "من التمس رضا الله بسخط الناس رضي اللهعنه وأرضى عنه الناس ، ومن التمس رضا الناس بسخط الله ، سخط الله عليه وأسخط عليه الناس".

Гайшә разыяллаһү ганһә Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Кем дә кем башка кешеләрнең ачуы сәбәпле Аллаһының ризылыгын теләсә, Аллаһы Тәгалә ул кешедән разый булыр һәм башка кешеләрне дә аннан разый итәр. Кем дә кем кешеләрнең ризалыгын Аллаһының ачуы белән

теләсә, Аллаһы Тәгалә аңа ачуланыр һәм кешеләрне дә аның хозурына ачуландырыр».

وروى الاعمش عن أبي عمرو الشيباني ، عن أبي مسعود الانصاري ﷺ انه قال : جاء رجل إلى النبي ﷺ واراد الجهاد ، فقال : احملني يا رسول الله ، فقال رسول الله ﷺ : "ائت فلانا فإنه يحملك" فاتاه فاعطاه بعيرا ، فرجع إلى رسول الله ﷺ فاخبره ، فقال رسول الله ﷺ : "من دل على خير فله مثل اجر فاعله" ، وفي خبر آخر : "الدال على الخبر كفاعله".

Әгъмәш Әбү Мәсгуд Ансаридән риваять ителде. Ул әйтте: «Бер кеше Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә килде һәм сугышуны теләде. «Әй Рәсүлуллаһ, мине йөкләт», – диде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Фәлән кешегә бар, ул кеше сине йөкләтер». Ул кеше Пәйгамбәр галәйһиссәләм җибәргән кешегә барды, ул аңа дөя бирде. Сугышка барырга теләүче Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм янына кайтты һәм аңа хәбәр бирде. Рәсүлуллаһ әйтте: «Кем дә кем изгелеккә дәләләт итсә, ул кешегә изгелекне кылучының әҗере булыр». Икенче бер хәбәрдә: «Изгелеккә өндәүче аны кылучы кебектер».

وعن حذيفة بن السمان ﷺ قال : قدم شائل على عهد رسول الله ﷺ فسال ، فسكت القوم ، ثم إن رجلا أعطاه القوم ، فقال رسول الله ﷺ : "من استن خيرا أو استن به فله اجره ومثل اجور من تبعه غير ان ينقص من أجورهم شيئا ، ومن استن شرا واستن به فعليه وزره من تبعه من غير أن ينقص من أوزارهم شيئا".

Хөзәйфә бине Йәмәнидән риваять ителде. Ул әйтте: «Рәсүлуллаһ заманасында бер кеше килде һәм сорады. Халык тик торды. Соңыннан аңа бер кеше хәер бирде, халык та аңа ияреп бирделәр. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем

хәергә ияртсә һәм шуңа иярелсә, ул иярткән кешегә аңа ияргән кешеләрнең әҗеренең охшашы булыр. Ул иярепкылучыларның әҗерләреннән һичбер нәрсә киметелмәс. Кем дә кем явызлыкка ияртсә һәм аңа иярелсә, ул ияртүче кешегә һич киметелмичә аңа ияргән кешеләрнең гөнаһысы булыр».

وروى تميم الداري عن النبي ﷺ انه قال : "خمس من جاء بهن يوم القيامة لم يضل عن الجنة : النصيحة لله ولرسوله ولكتابه ولأئمة المسلمين وللعامة".

Тәмим Дәрий Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять итте. Ул әйтте: «Биш нәрсә бардыр, берәү аларны Кыямәт көнендә китерсә, җәннәттән аерылмас: Аллаһы, Аның Рәсүле яки Аның китабы өчен хәергә димләү һәм мөселманнарның имамнарына һәм бөтен халыкка нәсыйхәттер».

وروى في خبر آخر تنه ﷺ قال : "ألا إن الدين النصيحة" قيل : لمن يا رسول الله؟ قال : "لله ولرسوله ولكتابه ولجميع المسلمين".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Белегез, дин нәсыйхәттер». Әйтелде: «Кемнәр өчен?» Әйтте: «Аллаһыга, Аның китабына, Аның Пәйгамбәренә һәм бөтен мөселманнарга».

Фәкыйһ әйтте: «Аллаһы Тәгалә өчен нәсыйхәт дигәне – Аллаһы Тәгаләгә ышану һәм ошбу иманга кешеләрне дә өндәү, бөтен халыкның мөэминнәр булуларын теләү. Әмма Рәсүлуллаһ өчен нәсыйхәт дигәне – Аллаһы Тәгалә тарафыннан китергән нәрсәсе белән Рәсүлуллаһка ышану, аның сөннәте белән гамәл кылу һәм бөтен кешеләрне дә шуңа чакырудыр. Әмма Аның китабы өчен нәсыйхәт дигәне – ул китапны уку белән анда булган хөкемнәр белән гамәл кылудыр. Бөтен халык ул китапны укысын һәм ул кушканча гамәлләр кылсын, дип

теләү. Әмма мөселманнарның имамнарына нәсыйхәт дигәне – аларга әмер иткән нәрсәләрендә буйсыну һәм тыйган нәрсәләреннән тыелу. Аларны яхшылыкка өндәү һәм ярамас эштән тыю. Алар хозурына кылыч белән чыкмау. Әмма мөселманнарга нәсыйхәт – үзеңә сөйгәнне аларга да сөю, үзеңә мәкрүһ күргәнне аларга да яратмау. Үзара мәхәббәт һәм өлфәт белән булуларын теләү».

Фәкыйһ әйтте: «Намаз укучылар әҗере язылган йоклаучылар, яисә киресенчә, йоклаучылар җөмләсеннән язылган төндә торып, намаз укучылар азмы? Бу эш, әлбәттә, шулайдыр. Берәүнең гадәтендә сәхәр вакытында торып, тәһарәт алып намаз уку булса, бер кичтә шул ук ният белән ятып, тәмам таң беленгәнчегә кадәр йокласа, йокысыннан уянып, ошбу хәлгә кайгыртып, кичнең кайтуын теләсә, дөреслектә, шул кеше намаз укучылардан язылыр. Нияте аркасында кич торучылар савабына ирешер. Берәүнең кич торганы булмыйча, бер көнне таң аткан дип уйлап, торса һәм тәһарәт алып, мәчеткә керсә һәм шул ук вакытта таң атмаганын белеп, үз-үзенә: «Әгәр таң атмаганын белгән булсам, түшәгемнән тормаган булыр идем», – дисә, ул кеше уяу булса да, йоклаучылардан язылыр».

## Үз-үзеңә соклану турында

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Габдулла бине Мәсгудтән риваять итте, ул әйтте: «Котылу ике нәрсәдә: тәкъвалык белән яхшы нияттә. Һәлакәт тә ике нәрсәдә: өмет өзү белән үз-үзеңә ис китүдәдер».

Вәһаб бине Мөнбиһтән риваять ителә. Ул әйтте: «Сездән элек булган өммәт арасында бер кеше бар иде. Аллаһы Тәгаләгә җитмеш ел гыйбадәт кылды.

шимбәдән шимбәгә генә авыз ача иде. Аллаһыдан хаҗәтен сорады да, Аллаһы Тәгалә аңа бирмәде. Үз-үзенә әйтте: «Әгәр синдә изгелек булса, синең йомышың үтәлер иде. Ул йомыш синнән элек булган кешеләргә генә бирелде». Шул вакытта аңа фәрештә иңде һәм әйтте: «Әй адәм баласы! Дөреслектә, нәфсеңне орышкан вакытың үткән гыйбадәтеңнән изгерәктер».

Шәгъби әйтте: «Бер кеше булды, ул йөргәндә болыт аңа кояштан күләгә булып торыр иде. Икенче берәү моны күреп, мин дә аның күләгәсендә йөрермен, дип әйтте. Әүвәлге кеше үз-үзенә сокланып: «Моның кебек кеше дә минем күләгәмдә йөрерме икән», – диде. Аерылышкач, күләгә бу соңыннан кушылган кеше белән китте».

Гомәр бине Хаттабтан риваять ителде. Ул әйтте: «Гөнаһыңны белү тәүбәңнең төзеклегеннән. Үз-үзеңә соклануны кире кагу гамәлнең төзеклегеннән. Кимчелегеңне тану шөкереңнең төзеклегеннәндер».

Гомәр бине Габдулгазиздән риваять ителде. Гомәр бине Габлулгазиз хөтбәне укыса үз-үзенә сокланудан куркып, хөтбәсеннән туктый иде. Язганда үз-үзенә сокланудан куркып, язудан туктады. Әйтә иде: «Әй Аллаһым, Сиңа нәфсемнең явызлыгыннан сыгынамын».

Мутраф бине Габдулла әйтте: «Минем өчен төнне йокыда үткәреп, таңга үкенеп керүем, төнне уяу торып, таңга үз-үземә сокланган хәлдә керүемнән сөеклерәк».

Гайшә разыяллаһү ганһәдән риваять ителде. Аңардан бер кеше сорады: «Мин үземнең изге икәнемне кайчан белермен?» Гайшә әйтте: «Үзеңнең явыз икәнеңне белгәндә». Ул кеше әйтте: «Мин

үземнең явыз икәнемне кайчан белермен?» Гайшә әйтте: «Үзеңне яхшы дип белсәң, шул вакыт явыз икәнеңне белерсең».

Риваять ителде, Бәни Исраил кавеменнән бер егет дөньясын ташлады, кешеләр арасыннан чыкты, мөгамәләләрен өзде. Бер читтә гыйбадәт кыла башлады. Аны кайтарыр өчен, кавеменнән ике карт кеше килде һәм аңа әйттеләр: «Әй егет, син авыр эшкә тотынгансың, аңа түзә алмассың». Егет әйтте: «Халыкның Аллаһы Тәгалә каршында торулары минем бу торуымнан катырактыр». Әйттеләр: «Синең якын кардәшләрең бар, алар янында гыйбадәт кылуың артыграктыр». Егет әйтте: «Әгәр Раббым миннән разый булса, һәрбер якын һәм дус кешене миннән разый кылыр». Әйттеләр: «Син әле яшь кеше белмисең, без бу эшне сынап беләбез. Синең хозурыңа үз-үзеңә сокланудан куркабыз». Егет әйтте: «Кем дә кем үзен таныса, үз-үзенә сокланмас». Ул икесенең берсе иптәшенә карады һәм әйтте: «Тор, чөнки бу егет оҗмах исен тапкан. Безнең сүзебезне тыңламас».

Риваять ителде, Давыд галәйһиссәләм диңгез буенда Аллаһы Тәгаләгә бер ел гыйбадәт кылды. Бер ел тулгач әйтте: «Әй Раббым, аркам бөкрәйде, күзләрем арыды, яшьләр бетте. Минем эшем соңыннан ни булачак?» Аллаһы Тәгалә бакага вәхи иңдерде: «Минем бәндәм Давыд галәйһиссәләмгә җавап бир», – диде. Бака әйтте: «Әй Аллаһының пәйгамбәре, син бер ел гыйбадәт хакында да Раббыңа әйтәсеңме? Сине хак пәйгамбәр итеп җибәргән Аллаһы белән ант итәм, мин корылыкта утызмы, алтмышмы елдан бирле аңа тәсбих һәм хәмед әйтәмен. Һәм минем тамырлар Раббымнан куркуымнан калтырыйлар». Моннан соң Давыд

галәйһиссәләм елады. Кайберләре бу кыйсса Муса галәйһиссәләм белән булды, дип риваять итәләр.

Фәкыйһ әйтте: «Кем дә кем үз-үзе белән сокланудан сакланырга теләсә, аңа дүрт төрле әйбер лязем булсын. Беренчесе, гамәлгә ирешүне Аллаһыдан дип белү. Әгәр гамәл кылуын Аллаһыдан дип белсә, шөкер кылу белән мәшгуль булыр, үз-үзенә исе китмәс. Икенчесе, Аллаһы Тәгалә аның хозурына кылган нигъмәтләргә карарга кирәк. Әгәр Аллаһы Тәгалә нигъмәтләре турында фикерләсә, шөкер белән шөгыльләнер, үзенең кылган гамәлен азга санар, үз-үзенә сокланмас. Өченчесе, аннан кабул ителмәүдән курку. Әгәр кабул булу, булмау куркынычы белән шөгыльләнсә, үз-үзенә исе китмәс. Дүртенчесе, шул гамәленнән элек кылган гөнаһлардан оялу тиештер. Әгәр явызлыкларның изгелекләренә караганда артык булуыннан курыкса, тәхкыйк, ул кешенең үзе-үзенә соклануын бетерер. Кеше үзенең гамәленә ничек гаҗәпләнсен, Кыямәт көнендә аның гамәл дәфтәреннән нәрсә чыгасын белмидер. Дәфтәрен укыганнан соң аның үзенә ис китүе һәм шатлыгы беленер. Шунда гына шатланырга тиеш булыр».

Ибен Габбастан риваять ителде, ул әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең: «Дәфтәрен алыгыз да, укыгыз», – дип әйткән сүзен ишеттем. Аллаһы Тәгалә кем хакында аны әйткәнен белмәдем. Хәтта Кәгъб Гомәр разыяллаһү ганһү янына керде һәм без дә аның янында утыра идек. Гомәр разыяллаһү ганһү әйтте: «Әй Кәгъб, безгә мәгънәдә Аллаһының китабына охшаган хәдисне сөйлә». Кәгъб әйтте: «Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә халыкны бик киң сахрада кубарыр. Өндәгән кеше аларга ишеттерер һәм аларны күздән алыр. Һәр халык үзләренең туры

юлга, яисә азгынлык юлына өйрәткән халыклары белән бергә чакырылыр. Шәкертләреннән элек туры юлга өндәүче имамны өндәрләр. Ул күтәрелер һәм аның гамәл дәфтәре уң кулына бирелер. Тәхкыйк, ул кешенең явызлыклары яшерелгән булыр. Гамәлем сәбәпле җәннәткә кердем, дип әйтмәсен өчен, дәфтәрен үз алдында укыр. Ул кешенең изгелекләре кешеләргә беленер, алар ул дәфтәрне укырлар: «Изгелек заһир булуыннан фәлән кешегә ни сөенеч!» – дип әйтерләр. Моннан соң ул кеше үз алдына явызлыкларын укыр. Хәтта үз алдына: «Мин һәлак булдым», – дип әйтер. Ул дәфтәрнең соңгы битендә: «Дөреслектә, Мин сине ярлыкадым», – дигән сүз язылган булыр. Ул имам яктылыгы каплаган нурдан булган таҗ белән таҗланыр. Соңыннан әйтелер: «Шәкертләрең янына бар, сиңа булган әҗернең охшашы аларның һәрберсенә дә, дип сөендер». Шәкертләре янына юнәлгәндә, аңа мәйдан халыгы карар. «Әй Аллаһы, ул кешене безләрдән кыл, аны безгә китер», – дип әйтерләр. Соңыннан шәкертләре янына килеп әйтер: «Минем дәфтәремне алыгыз һәм укыгыз. Тәхкыйк, минем гөнаһларым ярлыканды. Сөенегез, чөнки сезнең һәрберегезгә дә миңа булган әҗер кебек булыр». Азгынлыкка имам булса, ул да өндәлер. Урыныннан торгач, дәфтәре бирелер. Дәфтәрен алыр өчен уң кулын сузса, кулы муенына багланыр, дәфтәрен сул кулы белән алыр. Соңыннан сул кулы арка тарафына ителер, муены бөгелер. Минем явызлыкларымны сакладың, изгелекләремне сакламадың, дип әйтмәсен өчен, үз-үзенә изгелекләрен укыр. Әйтер: «Шулай гамәл кылдың да, гамәлең бәрабәренә Мин сине шулай әҗерле һәм саваплы иттем, башкалар да шулай ук». Кешеләргә аның изгелекләре һәм явызлыклары укылыр. Алар:

«Явызлыгы сәбәбеннән фәлән кешегә ни үкенеч!» – дип әйтерләр. Ул кеше соңгы биттә: «Синең өчен газап вәҗиб булды», – дигән сүзне табар. Аның йөзе караңгы төн уртасы кебек каралыр. Төтене бөтенләй каплаган уттан булган таҗ белән таҗланыр. Соңыннан аңа әйтелер: «Шәкертләрең янына бар, аларның һәрберсенә ошбуның охшашы кебек җәза булыр, дип сөендер». Шәкертләренә таба юнәлгәч, мәйдан халкының һәрберсе әйтер: «Әй Аллаһы, моны безләрдән кылма. Әй Аллаһы, аны безгә китермә». Нинди генә халык яныннан үтсә дә, аңа ләгънәт әйтерләр. Соңыннан үзенең шәкертләре янына килер. Ул шәкертләр имамларын күреп, аңа ләгънәт әйтерләр, анардан бизәрләр. Бәс имам да шәкертләренә ләгънәт кылыр. Аллаһы Тәгалә әйткәнчә:

ثُمَّ يَوْمَ الْقِيَامَةِ يَكْفُرُ بَعْضُكُمْ بِبَعْضٍ وَيَلْعَنُ بَعْضُكُمْ بَعْضًا

«Кыямәт көнендә бер-берегезгә көфран кылырсыз», ягъни инкарь итәрсез, бер-берегезгә ләгънәт әйтерсез». (Ганкәбут: 25) Ул имам шәкертләренә әйтер: «Сөенегез, һәрберегезгә ошбуның охшашы булыр».

Мәсрукъ әйтте: «Аллаһыдан курку кадәр булса, кешегә шул гыйлем җитәр. Үз гамәленә соклану кешенең наданлыгына җитәр».

وعن مجاهد ﷺ أنه قال : بعث سعيد بن العاص قوما يثنون عليه عند عثمان ﷺ ، فقام المقداد ، فحثا في وجوههم التراب ، و قال : سمعت رسول الله ﷺ يقول : "إذا رايتم المداحين فأحثوا التراب في وجوههم".

Мөҗәһидтән риваять ителде, ул әйтте: «Сәгыйд бине Гас бер кавемгә түрә итеп җибәрелде, ул кавем Сәгыйд бине Гасны Госман каршында мактыйлар

иде. Микдад разыяллаһү ганһү торды да, аларның йөзләренә туфрак сипте һәм әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнең: «Мактаучылар йөзенә туфрак сибегез», – дип әйткәнен ишеттем».

## Хаҗ фазыйләте турында

عن عبد الله بن عباس ﷺ قال : كنا مع النبي ﷺ بمني إذ أقبلت طائفة من اليمن ، فقالوا : فداك الامهات والآباء ، أخبرنا بفضائل الحج ، قال : "بلى ، أي رجل خرج من منزله حاجا أو معتمرا ، فكلما رفع قدما ووضع قدما تناثرت الذنوب من بدنه كما يتناثر الورق من الشجر ، فإذا ورد المدينة وصافحني بالسلام صافحته الملائكة بالسلام ، فإذا ورد ذا الحليهة ، واغتسل طهره الله من الذنوب ، وإذا لبس ثوبين جديدين جدد الله له الحسنات ، وإذا قال دخل مكة وطاف وسعى بين الصفا والمروة ، وصل الله له الخيرات.

فإذا وقفوا في عرفات ، وضجت الصوات بالحاجات ـــ باهي الله بهم ملائكة السبع سماوات ن ويقول : ملائكتي وسكان سماواتي ، أما ترون إلى عبادي ، اتوني من كل فج عميق شعثا غبرا قد أنفقوا الأموال ، وأتعبوا الأبدان.

فوعزتي وجلالي لأهبن مسيئهم بمحسنهم ولأخرجنهم من الذنوب كيوم ولدقم أمهاقم ن فإذا رموا الجمار ، وخلقوا الرؤوس ، وزاروا البيت ، نادي مناد من بطنان العرش : ارجعوا مغفورا لكم ، واستانفوا العمل".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Ибен Габбастан риваять итте. Ул әйтте: «Без Рәсүлуллаһ белән Минада булдык. Шул вакытта Йәмәннән бер төркем халык килеп чыкты. «Ата-аналар сиңа фида булсын, безгә хаҗның әҗерләре турында сөйлә», – диделәр.

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Нинди генә кеше йортыннан хаҗ яки гомрә нияте белән чыкса да, һәр аяк адымы саен агачтан яфраклар коелган кебек аның гөнаһлары коелыр. Ул кеше Мәдинәгә килеп, сәлам биреп, минем белән күрешсә, фәрештәләр сәлам биреп, аның белән күрешерләр. Ул кеше ихрам микатына килеп госел коенса, Аллаһы Тәгалә аны гөнаһлардан пакь кылыр. Ул кеше ике яңа кием кисә, Аллаһы Тәгалә аның изгелекләрен яңартыр. Әгәр «ләббәйкәллаһүмма ләббәк», дип әйтсә, Аллаһы Тәгалә аңа «ләббәйк вә сәгадәйк» белән җавап бирер. Ягъни «сүзеңне ишетәмен һәм сиңа карыймын». Мәккәгә кереп, Кәгъбәне таваф кылса һәм Сафа белән Мәрвә арасында йөрсә, Аллаһы Тәгалә аңа изгелекләрне ирештерер. Кайчан ки Гарәфәттә торып, көчле тавыш белән хаҗәтләрен сораса, Аллаһы Тәгалә ул халык белән җиде кат күкләрнең фәрештәләренә мактаныр. Әйтер: «Әй Минем фәрештәләрем, әй Минем күкләрдә торучыларым. Минем бәндәләремне күрмисезме? Һәр ерак җирләрдән чәчләре тузанланып, Миңа килделәр. Малларын сарыф кылдылар, тәннәрен мәшәкатьләделәр. Үземнең олуглыгым, кәрамем белән ант итәм, аларның явызларына, яхшыларына бүләк бирермен. Аналары тудырган көндәге кебек гөнаһлардан чыгарырмын. Вак ташларны атсалар һәм чәчләрен кыскартсалар, Кәгъбәне зиярәт итсәләр, Гареш янында бер кычкыручы кычкырыр: «Ярлыканып кайтыгыз һәм гамәлне баштан кыла башлагыз».

عن علي ﷺ قال : كنت طائفا مع النبي ﷺ ببيت الله الحرام ، فقلت : فداك أبي وأمي ما هذا البيت ؟ فقال لي : "يا علي ، أسس الله سبحانه وتعالى هذا

البيت في دار الدنيا كفارة لذنوب أمتي" فقلت : فداك أبي وأمي ما هذا الحجر الأسود ؟ ، قال : "تلك جوهرة كانت في الجنة أهبطها الله إلى الدنيا لها شعاع كشعاع الشمس ، واشتد سوادها وتغير لونها لما مستها ايدي المشركين".

Гали разыяллаһү ганһүдән риваять ителә. Ул әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм белән бергә Кәгъбәне таваф кылыр булдым. Мин әйттем: «Ата-анам сиңа фида булсын, әй Рәсүлуллаһ, бу йорт нәрсә?» Ул миңа әйтте: «Минем өммәтемнең гөнаһларына кәффарәт булсын өчен Аллаһы Тәгалә дөнья йортында бу йортны салды». Мин сорадым: «Әй Рәсүлуллаһ, бу таш нәрсә ул?» Ул әйтте: «Ул, җәннәттә булган бер җәүһәр таш иде. Аллаһы Тәгалә аны дөньяга иңдерде. Аның кояш нуры кебек ялтыравыклы нуры бар иде. Аның каралыгы катыланды, мөшрикләр куллары тотуыннан төсе үзгәрде».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Габбас бине Мәрдәстән риваять итте. Гарәфә кичәсендә Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм өммәте өчен рәхмәт һәм мәгъфират белән бик күп дога кылды. Аллаһы Тәгалә: «Мин шулай кылырмын, ягъни рәхмәт кылыр идем, ләкин кайберләре каберләренә золым кылды. Шуның өчен ярлыкамыйм, ярлыка алмам», – дип җавап бирде. Әйтте: «Әй Раббым, залимнең золымы сәбәбеннән золым ителгән кешегә хәер савап бирергә көчең җитүчедер». Аллаһы Тәгалә Рәсүлуллаһка ул кичәдә җавап бирмәде. Мөздәлифә көненең таңы аткач, Рәсүлуллаһ яңадан дога кылды. Аллаһы Тәгалә Рәсүлүлаһка: «Мин өммәтеңнең гөнаһларын ярлыкадым», – дип җавап бирде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм елмаеп көлде. Сәхабәләрнең кайберләре: «Һич көлми торган вакытыңда көлдең, әй Рәсүлуллаһ», – дип әйттеләр. Рәсүлул-

лаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһының дошманы иблистән көлдем. Өммәтем хакында кылган догамны Аллаһы Тәгаләнең кабул иткәнен белгәч: «Ни үкенеч, ни һәлакәт!» – дип кычкырып егылды. Башына туфрак сипте».

عن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ انه أنه قال : "من حج البيت ولم يفرث ولم يفسق ، رجع كيوم ولدته أمه".

Әбү Һөрәйрә Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Кем дә кем хаҗ кылып, бозыклык кылмаса, өенә анасы тудырган көндәге кебек гөнаһсыз булып кайтыр».

Гомәр бине Хаттаб разыяллаһү ганһүдән риваять ителде, ул әйтте: «Берәү бу йортка килеп, шул йорттан башка теләге булмаса һәм ул йортны таваф кылса, анасы тудырган көндәге кебек гөнаһларыннан арыныр».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "ما رؤي الشيطان يوما قط هو فيه أضعف ولا أحقر ولا اغيظ من يوم عرفه ، وما ذلك إلا لما رأى من نزول الرحمة وتجاوز الله عن الذنوب العظام ، ولم ير قبل ذلك مثله إلا ما رؤي من يوم بدر".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Шайтан һичбер көндә Гарәфә көнендәгедән ачуланганрак, кечкенәрәк һәм зәгыйфьрәк күренмәде. Бу хәл исә шайтанның рәхмәт иңүен, Аллаһы Тәгаләнең олуг гөнаһларны гафу кылганын күгәннән генәдер. Гарәфә көненнән элек шайтан бу рәвештә күренмәде, мәгәр Бәдер сугышы көнендә генә».

Гомәр бине Габделгазиздән риваять ителде. Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәләмгә вәхи кылганда, Кәгъбә һәм аның әҗере һәм фазыйләте бәян ителде. Әйтте: «Әй минем Раббым, хаҗ нәрсә ул?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Бөтен йортлардан артык

итеп сайлаган йортымдыр. Минем хәлилем (дустым) хәрам иткән хәрамымдыр. Җирнең һәрбер тарафыннан аңа киләләр, кол ничек үзенең хуҗасына «ләббәйк» дип әйтә, шуның кебек үк тәлбия белән тәһлил әйтәләр». Муса галәйһиссәләм әйтте: «Әй Раббым, ул бәндәләреңнең савабы нәрсә булыр?» Аллаһы Тәгалә әйтте: «Ул бәндәләргә мәгъфиратны тоташтырырмын, хәтта күршеләре хакында һәм якыннары хакында аларны шәфәгатьче кылырмын». Муса галәйһиссәләм әйтте: «Әй Раббым, алар арасында малы пакь түгелләр һәм күңелләре чын түгелләр бар». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Дөреслектә, Мин аларның гөнаһларын күркәм гамәлләренә бүләк кылам».

Әбү Һарун Габидий Әбү Сәгыйд Худрийдән риваять итә. Әбү Сәгыйд әйтте: «Гомәр бине Хаттаб разыяллаһү ганһү белән хәлифәлегенең башында хаҗ кылдык. Хәрам мәчетенә кереп, кара таш янында туктады һәм әйтте: «Син файда да, зарар да итми торган таш. Рәсүлуллаһның сине үпкәнен күрмәгән булса идем, сине үпмәс идем». Гали әйтте: «Әй мөэминнәрнең әмире, моның кебек сүзне әйтмә. Чөнки ул таш Аллаһының рөхсәте белән зарар да, файда да кылыр. Әгәр мин Коръән укымасам һәм аның эчендәге хөкемнәрне белмәсәм иде, мин сиңа инкарь итмәс идем». Аңа Гомәр әйтте: «Әй Әбү Хәсән, Аллаһы Тәгаләнең китабында булган аятьнең тәфсире нәрсә?» Гали әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَإِذْ أَخَذَ رَبُّكَ مِنْ بَنِي آدَمَ مِنْ ظُهُورِهِمْ ذُرِّيَّتَهُمْ
وَأَشْهَدَهُمْ عَلَى أَنفُسِهِمْ أَلَسْتُ بِرَبِّكُمْ قَالُوا بَلَى ﴾

«Шуны зекер ит, синең Раббың адәм балаларының аркаларыннан үзләренең нәселләрен алды һәм үз-үзләренең өстенә үзләрен үк танык

ясады. «Мин сезнең Раббыгыз түгелме?» – дип әйткәч, «Әйе, безнең Раббыбыз Син», – диделәр». Ул адәм нәселе бәндәчелек белән икрар кылгач, аларның икрарын тире өстенә язды. Соңыннан ошбу ташны чыгарды. Ул ташка ошбу тирене йоттырды. Шулай исә, ул таш ошбу тире хозурына ышанган затыдыр. Ул таш гаһеденә тугры булган кешегә Кыямәт көнендә таныклык итәр». Гомәр әйтте: «Әй Әбү Хәсән, Аллаһы Тәгалә сезгә гыйлемне аз бирмәде».

Ибен Габбас разыяллаһү ганһүмәдән риваять ителде. Күзе йомылганнан соң ул әйтте: «Җәяүләп хаҗ кылмаганыма үкенгәнем кебек һичнәрсәгә үкенгәнем юк. Чөнки мин ишеттем, Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ يَأْتُوكَ رِجَالًا وَعَلَىٰ كُلِّ ضَامِرٍ ﴾

«Әй Ибраһим, кешеләрне хаҗга чакырсаң, җәяүлеләр һәм арык дөяләргә атланган хәлдә сиңа килерләр». (Хаҗ: 27)

Фәкыйһ әйтте: «Әгәр юл якын булса, җәяүләп хаҗ кылуда зарар юк, ул артыграк булыр. Әгәр юл ерак булса, атланып килү артыграк. Чөнки җәяүле кеше үз-үзен мәшәкатьли, холкы явызлана. Әгәр шул сердән имин булса, ул вакытта җәяү бару артыграктыр».

Хәсән Басридән риваять ителде. Ул әйтте: «Фәрештәләр хаҗ кылучыга очрарлар. Дөя ияләренә сәлам бирерләр, ишәк һәм качыр ияләре белән күрешерләр, җәяүлеләр белән кочаклашырлар».

وروى الضحاك ، عن النبي ﷺ أنه قال : "أيما مسلم خرج من بيته قاصدا في سبيل الله فوقصته دابته قبل القتال ، أو لدغته هامة ، أو مات باي حتف ،

مات وهو شهيد ، وأيما مسلم خرج من بيته حاجا إلى بيت الله الحرام ، ثم نزل به الموت قبل بلوغه أوجب الله له الجنة".

Даххак Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә. Ул әйтте: «Нинди генә мөселман йортыннан Аллаһы Тәгалә юлын ният итеп чыкса, сугыштан элек, аны хайваны таптаса яки елан кебек нәрсә чакса, яки теләсә нинди сәбәп белән вафат булса, ул кеше шәһидтер. Кайсы гына мөселман үз йортыннан Кәгъбәне хаҗ кылам дип чыкса, Кәгъбәгә ирешкәнгә кадәр аңа үлем ирешсә, Аллаһы Тәгалә ул кешегә җәннәтне важиб итәр».

وروى عن النبي ﷺ أنه قال : "اللهم اغفر للحاج ولمن استغفر له الحاج".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Аллаһы, хаҗ кылучыны һәм аның догаларында мәгъфират белән искә алынган кешене ярлыка».

وروى عن عطاء عنعمر ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "صلاة في مسجدي تعدل ألف صلاة غيره إلا المسجد الحرام".

Гата Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Минем мәчетемдәге бер намаз башка мәчетләрдәге мең намазга бәрабер булыр. Мәгәр мәчет Хәрамдагы мең намазга бәрабәр булмас».

وفي خبر آخر : "صلاة في مسجدي هذا أفضل من عشرة آلاف في غيره إلا المسجد الحرام ، وصلاة في المسجد الحرام أفضل من مائة ألف صلاة في غيره ، وصلاة في سبيل الله افضل من مائتي ألف صلاة" ثم قال : "ألا ادلكم على ما هو أفضل من ذلك ، رجل قام في سواد الليل فأحسن الوضوء ، وصلى ركعتين يريد بهما ما عند الله".

Икенче бер хәбәрдә әйтелде: «Минем мәчетемдәге бер намаз башкалардагы ун мең намаздан артыгракдыр. Мәгәр Хәрам мәчетендәге ун мең намаздан артык булмас. Хәрам мәчетендәге бер намаз башкалардагы йөз мең намаздан артык. Аллаһы юлында бер намаз ике мең намаздан артыктыр». Соңыннан Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Мин сезне моннан да артыгракка димлимме? Бер кеше кара төндә торып, яхшы тәһарәт төзесә һәм ике рәкәгать намаз укыса, шул ике рәкагәть намазны вәсилә итеп, Аллаһы Тәгаләнең каршындагы рәхмәтен теләсә, Хәрам мәчетендәге намаздан да артыграк булыр».

عن ابن عمر ﷺ أنه قال : قال رسول الله ﷺ : "بني الإسلام على خمس : شهادة ان لا إله إلا الله ، وأن محمدا رسول الله وإقام الصلاة وإيتاء الزكاة وثوم رمضان ، وحج البيت".

Йәзид бине Бәшәр Ибен Гомәрдән риваять итә. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Ислам дине биш нәрсәдә бина ителде: гыйбадәт кылырга лаек булган зат Аллаһы Тәгалә генә һәм Мөхәммәд галәйһиссәләм аның рәсүле, дип таныклык бирү, намаз уку, зәкәт чыгару, Рамазан аенда ураза тоту һәм хаҗ кылу».

وروى عن سعيد بن المسيب ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "إن الله تعالى ليدخل ثلاثة نفر في الجنة الواحدة الجنة ، والموصي بها ، والمنفذ لها ، والحاج عنه ، والعمرة كذلك".

Сәгыйд бине Мөсәййибтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә бер хаҗда өч кешене җәннәткә кертер. Хаҗны васыять иткән кешене, хаҗ белән васыятьне җиренә

җиткергән кешене, васыять итеп вафат булучы өчен хаҗ кылучыны. Гомрә белән җиһад та шулай ук».

### Аллаһы юлында сугышуның фазыйләте

عن أبي هريرة ﷺ قال ك قال رسول الله ﷺ: "لا يجتمع غبار في سبيل الله ، ودخان جهنم في جوف عبد أبدا ، ولا يجتمع الشح والإسمان في قلب عبد أبدا"

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Әбү Һөрәйрәдән риваять итте. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы юлындагы тузан белән җәһәннәм төтене бер бәндәнең эчендә мәңге бергә җыелмас. Саранлык белән иман бер бәндәнең күңелендә мәңге җыелмас».

عن الحسن ﷺ أن البين ﷺ قال : "لغدوة أو روحة في سبيل الله أفضل من الأرض ومن عليها واموفق الرجل في الصف أفضل من عبادة ستين سنة".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Хәсәннән риваять итте. Дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы юлында бер иртә яки бер кичкә күнүем җир һәм аның өстендә булган кешеләрдән артыктыр. Кешенең сафта бер мәртәбә булуы, алтмыш ел гыйбадәттә булуыннан артыграктыр».

عن ابن عباس ﷺ أن النبي ﷺ بعث عبد الله بن رواحة في سرية ، فوافق ذلك يوم الجمعة ، فقال عبد الله : أصلي الجمعة مع النبي ﷺ ثم ألحق بأصحابي ، وقد غدا أصحابه ، فلما رآه النبي ﷺ قال : "مالك لم تغد مع أصحابك ؟ " قال : أحببت أن أصلي معك الجمعة ، ثم ألحق بأصحابي ، فقال له : "لو أنفقت ما في الأرض جميعا ما أدركت فضل غدوقم".

Ибен Габбастан риваять ителә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм Габдулла бине Рәвәхәне бер сугышка

башлык итеп җибәрде. Бу эш җомга көненә туры килде. Габдулла әйтте: «Пәйгамбәр белән җомганы укыйм, соңыннан иптәшләремә тоташырмын». Ә аның юлдашлары иртә белән юлга чыкканнар иде. Намаз укыгач, Пәйгамбәр Габдулланы күреп: «Ни булды сиңа, ни өчен иртән юлдашларың белән бергә китмәдең?» – дип сорады. Габдулла әйтте: «Синең белән намаз укыйсым килде, соңыннан юлдашларыма тоташырмын». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Бөтен җир йөзендәге нәрсәне сарыф кылсаң да, иптәшләреңнең иртәнге савапларына ирешә алмассың».

Салман Фарсидән риваять ителде. Ул әйтте: «Бер кешенең бер кичә диңгез янында дошманны саклау, үз җәмәгате янында бер ай микъдары көндез ураза тотып, кич аяк хозурында торуыннан артыграктыр. Кем дә кем Аллаһы юлында дошман саклаган хәлдә вафат булса, Аллаһы Тәгалә ул кешене кабер фетнәсеннән, олуг кайгысыннан саклар һәм аның гамәлен һәр кичә һәм көндез Кыяметкә кадәр агызыр. Аның каберен зиярат кылуда Кыямәт көненә кадәр рабит әҗере бардыр».

وعن عبيد بم همير عن أبيه قال : شءل رسول الله ﷺ ما الإسلام ؟ قال : "طيب الكلام ، وإطعام الطعام ، وإفشاء السلام" ، قيل : وأي الإسلام أفضل ؟ قال : "من سلم الناس من يده ولسانه" ، قيل : فأي الصلاة أفضل ؟ قال : "طول القيام" ، قيل : فأي الإيمان أفضل ؟ قال : "الصبر والسماحة" قسل : فأي الجهاد أفضل ؟ قال : "من عقر جواده ، واهريق مده" ، قسل : فأي الرقاب أفضل ؟ قال : "أغلاها ثمنا".

Габдулла бине Гобәедтән, ул атасыннан риваять итеп әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән:

«Ислам нәрсә?» – дип сорадылар. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Күркәм сүз, ризык ашату, сәлам тарату». Әйтелде: «Исламның кайсысы артыграк?» Әйтте: «Телennән һәм кулыннан мөселманнар сәламәт булган кешенең Исламы артыграк». Әйтелде: «Намазның кайсысы артыграк?» Әйтте: «Кыямы, рөкүгә озынрак булганы артыграк». Әйтелде: «Садаканың кайсысы артыграк?» Әйтте: «Фәкыйрьнең мәшәкать белән тапкан акчасыннан булган садака артыграк». Әйтелде: «Кайсы иман артыграк?» Әйтте: «Сабыр кылу белән юмартлык иманда булган кешенең артыграк булган гамәлләреннәндер». Әйтелде: «Кайсы җиһад артыграк?» Әйтте: «Үзенең яхшы хайванын бугазлап, канын агызган кешенең җиһады артыграктыр». Әйтелде: «Кайсы колны азат итү артыграк?» Әйтте: «Акчасы авыр булганны азат итү артыграктыр».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "لا يجتمع غبار في سبيل الله تعالى ودخان جهنم في منخري عبد مسلم"

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Бер мөселман кешенең ике борын тишегендә җәһәннәм төтене белән сугыштагы тузан җыелмас».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "كل عين باكية يوم القيامة إلا ثلاثة أعين : عين بكت من خشية الله ، وعين غضت عن محارم الله تعالى ، وعين حسرت في سبيل الله تعالى".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кыямәт көнендә өч күздән башкасы елаучыдыр. Дөньяда Аллаһыдан куркып елаган күз, Аллаһының хәрам булган әйберләреннән йомылган күз һәм Аллаһы юлында дошман саклаган күздер, алар Кыямәттә еламас».

وعن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "عرض علي أول ثلاثة من امتي يدخلون الجنة وأول صلاصة يدخلون النار ، فأما اول الثلاثة يدخلون الجنة : فلاشهيد والعبد المملوك لم يشغله رق الدنيا عن طاعة الله تعالى ، وفقير متعفف ذو عيال ، وأما اول ثلاثة يدخلون النار : فأمير المسلط ، وذو ثروة من مال لا يؤدي حق الله تعالى من ماله ، وفقير فخور".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Миңа җәннәткә беренче керә торган өч фирка һәм җәһәннәмгә беренче керә торган өч фирка күрсәтелде. Әмма җәннәткә беренче керә торган өч фирка: Аллаһы Тәгаләнең юлында шәһид булган кеше; Аллаһы Тәгаләгә буйсынуда кеше кулында кол булуы зарар итмәгән бәндә; җәмәгать иясе булып хәрамга иярмәгән һәм кеше йөзенә сорарга бармаган фәкыйрьдер. Җәһәннәмгә беренче керә торган өч төрле фирка: җәберләүче түрә; малыннан Аллаһының хакын үтәми торган бай кеше; ярлы тәкәббер».

وعن النبي ﷺ أنه سئل : أي الأعمال أفضل؟ قال : "الصلاة لوقتها وبر الوالدين والجهاد في سبيل الله تعالى".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән: «Гамәлләрнең кайсысы артыграк?» – дип сорадылар. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Намазны вакытында үтәү, ата-анага изгелек кылу, Аллаһы юлында сугышу – гамәлләрнең артыграгыдыр».

Мәймун бине Мәһраннән, ул Ибен Габбастан риваять итте: «Кем дә кем Аллаһы Тәгаләнең юлында бер ат бирсә, аңа Аллаһы юлында малы һәм үзе белән сугыш кылган кешенең әҗере кебек булыр. Кем дә кем Аллаһы юлына кылыч бирсә, ул кылыч

Кыямәт көнендә: «Мин фәлән кешенең кылычы, бу көнемә чаклы һәрвакыт шул биргән кешем өчен сугыш кылдым», – дип әйтер. Кем дә кем Аллаһы юлына ук бирсә, Аллаһы Тәгалә ул укны хәзерләр, хәтта ул ук Кыямәт көнендә адәмнәрнең баш очларына Өхед тавыннан да зуррак булып килер. Кем дә кем Аллаһы юлында бер сугышчыны әзерләп җибәрсә, Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә ул кешегә билге ясар. Кем дә кем Аллаһы юлына калкан бирсә, Аллаһы Тәгалә ул калканны Кыямәт көнендә аңа пәрдә кылыр. Кем дә кем Аллаһы юлында бер авыру белән авырса, Аллаһы Тәгалә ул җәрәхәтне аның алдында нур кылыр. Ул авыру Кыямәт көнендә яфәр исе кебек хуш ис таратыр, бөтен халык аны сизәр. Бер кеше Аллаһы юлындагы кардәшен эчерсә, Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә ул кешегә мөһерләнгән савыттан чын хәмерне эчертер. Кем дә кем Аллаһы юлындагы кардәшен зиярат кылса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә һәрбер адымы өчен изгелек язар һәм аның дәрәҗәсен күтәрер. Шуның өчен аның явызлыгын төшерер. Кем дә кем Аллаһы юлында атын васыять итеп калдырса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә һәрбер төге саен изгелекне язар һәм дәрәҗәсен күтәрер һәм аңардан явызлыкны кичерер. Кем дә кем Аллаһы юлында сакчылык итсә, Аллаһы Тәгалә ул кешене Кыямәт көнендә олуг кайгыдан тыныч итәр».

Ибен Габбас әйтте: «Аллаһы юлында бер кечкенә генә сугышта булсаң, ул гаскәрнең артында кешеләрнең зәгыйфьләрен сөрер бул һәм курыкканнарын тынычландыр. Әгәр шулай итсәң, сиңа шул гаскәрдәге кешеләрнең саваплары кебек савап булыр һәм аларның савапларыннан һичнәрсә ким булмас».

Сәхабәләрнең кайберләреннән риваять ителде. Ул әйтте: «Кылычлар оҗмахның ачкычларыдыр. Аллаһы юлында ике саф капма-каршы очрашсалар, хурлар бизәнер һәм каршы чыгарлар. Әгәр бер кеше сугышта алда булса, ул хурлар: «Әй Аллаһы, ул кешегә ярдәм бир», – дип әйтерләр. Әгәр ул кеше сугыштан йөзен алса, алар яшеренерләр, «Әй Аллаһы, аны ярлыка», – дип әйтерләр. Әгәр үтерелсә, Аллаһы Тәгалә каннан иң элек чыккан тамчысы белән аның хозурында булган һәрбер гөнаһысын ярлыкар. Аның хозурына хурлардан ике кыз иңеп, аның йөзеннән тузанны сөртерләр».

وذكر أن رجلا حبشيا جاء إلى رسول الله ﷺ فقال : يا رسول الله ، أنا كما تراني دميم الوجه منتن الريح غير زاكي الحسب ، فأين انا إن قاتلت حتى أقتل ؟ قال : "أنت في الجنة" ، فأسلم ، فقال : عندي غنم فكيف أصنع بها ؟ قال : "وجهها إلى المدينة ، ثم صح بها ، فإنها سترجع إلى أهلها" ، ففعل ذلك ، ثم اقتحم القتال فاقتتلوا ، فلما تحاجز القوم قال النبي ﷺ : "تفقدوا إخوانكم" ، ففعلوا ، فقالوا : يا رسول الله ذلك الحبشي قتيل فس وادي كذا ، فقام النبي ﷺ معهم ، فلما أشرف النبي عليه قال : "اليوم حسن الله وجهك ، وطيب ريحك ، وزكي حسبك" ، فبكى ، فأعرض عنه ، فقالوا : رأيناك اعرضت عنه ! فقال ك "والذي نفسي بيده لقد رايت ازواجه من الحور العين ابتدلان حتى بدت خلاخلهن".

Риваять ителә, бер хәбәш кешесе Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмгә килеп: «Әй Рәсүлуллаһ, мин, күргәнеңчә, йөзе канлы, исе сасы, нәсебе күркәм булмаган кешемен. Тәмам үтерелгәнемә кадәр сугышсам, мин кайда булырмын?» – дип сорады.

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Ул вакытта җәннәттә булырсың». Ул кеше мөселман булды. Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә әйтте: «Минем каршымда әманәт булган куй көтүе бар, ул куйлар белән нишлим?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Ул куйларны Мәдинәгә таба юнәлдер, соңыннан аларга кычкыр һәм алар тиз генә үз ияләренә кайтырлар». Шулай эшләде. Соңыннан нык итеп сугышка ябышты. Бәс сугыштылар, халык сугыштан тыелышкач, Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кардәшләрегезне эзләгез, барлагыз». Шулай эшләделәр. Әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, теге хәбәши кеше шул чокырда үтерелгән». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм алар белән торып, аның янына килеп җиткәч әйтте: «Бу көн Аллаһы Тәгалә синең йөзеңне күркәм ясады, исеңне хуш итте һәм нәселеңне мөбарәк кылды». Бәс Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм елады. Аннан йөзен алды. Әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, ни өчен аннан йөзеңне аласың?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Үзем Аның кулында булган Зат белән ант итәм, хурлар булган хатыннарны күрдем, зиннәтләре күренгәнгә кадәр ачылдылар».

Сугышчылар өч төрле сыйныфтыр, диделәр. Бер сыйныфы, сугышчыларның атларын ашаталар. Икенче сыйныфы, сугышчыларга хезмәт итәләр. Өченче сыйныфы, сугышка керәләр. Аларның һәркайсы әҗердә тигезләрдер. Араларында артыграгы атларны ашата торганы, сугыш вакыты җитсә, сугыша да. Соңыннан әҗердә артыгы хезмәт итә торганы, ул да сугыш җитсә, анарда катнаша.

وروى عن أنس بن مالك ﷺ ان النبي ﷺ قال : "ما من عبد يموت وله عند الله خير يتمنى ان يرجع إلى الدنيا ، وإن كانت له الدنيا وما فيها" يعني لا

يتمنى الرجوع إلى الدنيا ، وإن اعطى له جميع الدنيا لما يخاف من هول الموت
"إلا الشهيد لما يرى من فضل الله الشهادة ، فإنه يتمنى أن يرجع إلى الدنيا
فيقتل مرة أخرى".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Шәһид булып, вафат булган кешедән башка, адәм Аллаһы Тәгалә хозурында аның изгелеге булса да, үлем катылыгыннан куркып, аңа бөтен дөнья бирелсә дә, яңадан дөньяга кайтуны теләмәс. Мәгәр шәһид булган кеше генә дөньяга яңадан кайтып, үтерелүне теләр».

Аллаһы Тәгаләнең:

فَصَعِقَ مَنْ فِي السَّمَاوَاتِ وَمَنْ فِي الْأَرْضِ إِلَّا مَنْ شَاءَ اللَّهُ

«Аллаһы Тәгалә теләгән кешеләрдән башка җирдә һәм күкләрдәге мәхлуклар һәрберсе кайгы белән кычкырышырлар» (Зүмәр: 68), дигән аятьнең тәфсирендә Сәгыйд бине Җөбәер әйтте: «Ул Аллаһы Тәгалә теләгән кешеләр»дән морад – Гареш хозурында кылычларын чыгарган шәһидләр. Кылычларын муеннарына аскан хәлдә Гареш тирәсендә булырлар».

Котәдәдән риваять ителде. Ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә сугышчыларга өч хасыйләт бирде. Кем дә кем сугышта үтерелсә, ризыклы һәм терек булып әверелер. Кем дә кем өстен калса, җиңсә, Аллаһы Тәгалә ул кешегә олуг әҗер бирер. Кем дә кем сугыштан кайтып яшәсә, Аллаһы Тәгалә ул кешене күркәм ризык белән ризыкландырыр».

وعن الحسن البصري ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "من سأل الله شهادة فمات
كان له أجر الشهيد".

Хәсән Басридән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Берәү Аллаһыдан шәһид булуны теләп вафат булса, аңа шәһид әҗере булыр».

Ибен Мәсгуд Аллаһы Тәгаләнең:

بَلْ أَحْيَاءٌ عِنْدَ رَبِّهِمْ يُرْزَقُونَ

«Бәлки ул үтерелгән кешеләр Раббылары янында хәер җәза белән ризыкландырылган хәлдә терекләрдер» (Әли Гыймран: 169), дигән аятенең тәфсирендә әйтте: «Аларның җаннары яшел кошларның корсакларында. Җаннар теләгән җәннәткә очарлар. Соңыннан Гареш астына бәйләнгән кандилләр арасына керерләр».

زعن معاذ بن جبل ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "من قاتل في سبيل الله فواق ناقة ، فقد وجبت له الجنة ، ومن سأل الله الشهادة من عند نفسه صادقا ثم مات أو قتل فله أجر شهيد ن ومن جرح في سبيل الله جرحا أو نكب نكبة فإنه يجئ يوم القيامة لونه كالزعفران وريحه كالمسك".

Могаз бине Җәбәлдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем Аллаһы юлында дөя төчкергән кадәр вакыт кына сугышып үтерелсә, аңа җәннәт важиб булыр. Кем дә кем чын күңеле белән Аллаһыдан шәһид булуны сораса, соңыннан вафат булса яки үтерелсә, аңа шәһид әҗере булыр. Кем дә кем Аллаһы юлында бер җәрәхәт белән җәрәхәтләнсә, Кыямәт көнендә төсе зәгыйфрән, исе яфәр кебек булган хәлдә килер».

وروى الحسن البصري ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "كل عين باكية يوم القيامة إلا أربعة : عين فقئت في سبيل الله ، وعين فاضت من خشية الله ، وعين بتت سهرة من خشية الله ، وعين باتت تحرس سرية من وراء المسلمين".

Хәсән Басридән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кыямәт көнендә һәр күз елар, мәгәр дүрт күз генә еламас: Аллаһы юлында авырткан күз; Аллаһыдан куркып елаган күз; Аллаһыдан куркып төне буе уяу торган күз; мөселманнарның тышыннан гаскәрне дошманнан саклаган күздер».

## Сугышта сакта тору

عن عثمان ﷺ قال : قنت أسر واليوم اعلن ، وما كان يمنعني أحد أن أحدثكم إلا الظن بكم ن سمعت رسول الله ﷺ يقول : "رباط في سبيل الله أفضل من صيام ألف يوم ، وقسام ألف ليلة".

Госман разыяллаһү ганһүдән риваять ителә, ул әйтте: «Яшереп тора идем, инде бу көн белдерәмен. Ул хәдисне сезгә сөйләүдән мине, фәкать сезнең хакта начар уем гына тыйды. Рәсүлуллаһтан ишеттем. Ул әйтте: «Бер көн Аллаһы юлында дошман саклау, мең көн ураза тоту һәм мең төн аяк хозурында торып, гыйбадәт кылудан артыграк».

عن مكحول أن سلمان الفارسي ﷺ مر يشرحبيل بن السمط ، وهو مرابط في قلعة بأرض فارس ، فقال : ألا أحدثكم بحديث سمعته من رسول الله ﷺ يقول : "لرباط يوم في سبيل الله أفضل من صيام شهر وقيامه ، ومن مات وهو مرابط أجير من فتنة القبر ن ونماله كل عمل كأحسن ما كان يعمل إلى يوم القيامة".

Мәкхүлдән риваять ителде. Салман Фарси разыяллаһү ганһү Шүрхәбил бине Сәмт яныннан үтте. Шүрхәбил Фарсы җиренең бер шәһәрендә

сакчы иде. Салман әйтте: «Сезгә Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән ишеткән хәдисне сөйлимме? Бер көн дошманны саклау бер ай ураза тотудан һәм бер ай аяк хозурында торып гыйбадәт кылудан артыграктыр. Кем дә кем сакчы булган хәлдә вафат булса, кабер фетнәсеннән сакланыр. Ул кешегә Кыямәт көненә кадәр кыла торган гамәлләрнең иң күркәме шикеллесе барыр».

عن ابن عمر ﷺ قال ك قال رسول الله ﷺ : "من كبر تكبيرة في سبيل الله ، كانت كصخرة في ميزانه يوم القيامة أثقل من السماوات والأرض وما فيهن ومن قال في سبيل الله لا إله إلا الله ، والله أكبر رافعا صوته بها كتب الله له بها رضوانة الأكبر ، ومن يكتب له رضوانه الأكبر جمع الله بينه وبين محمد وإبراهيم وسائر الانبياء عليهم الصلاة والسلام".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Ибен Гомәр разыяллаһү ганһүдән риваять итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем Аллаһы юлында бер тәкбир әйтсә, ул тәкбир Кыямәт көнендә мизанда җир һәм күкләрдән һәм аларда булган нәрсәләрдән авыррак таш кебек булыр. Кем дә кем Аллаһы юлында «лә иләһә илләллаһү, вәллаһү әкбәр», дип кычкырса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә шул зикере өчен олуг ризалыгын язар. Берәүгә Аллаһының олуг ризалыгы язылса, аны Мөхәммәд, Ибраһим һәм башка пәйгамбәрләр белән бергә кылыр».

Фәкыйһ әйтте: «Олуг ризалыгы» дигән сүзнең мәгънәсендә төрлечә сөйләделәр. Кайберләре, ул Аллаһы Тәгаләне күрү, кайберләре исә, ул ризалыктан соң Аллаһы Тәгалә аңа һич тә ачуланмас, диделәр».

عن أبي هريرة ﷺ قال : جاء رجل إلى رسول الله ﷺ فقال : يا رسول الله كيف لي أن انفق من مالي حتى أبلغ عمل المجاهد في سبيل الله ؟ قال : "ومالك؟" قال : ستة آلاف ، قال : "لو تصدقت بها كان عدل نومة الغازي في سبيل الله".

Әбү Һөрәйрә разыяллаһү ганһүдән риваять ителде, ул әйтте: «Бер кеше Пәйгамбәр галәйһиссәләм янына килеп: «Әй Рәсүлуллаһ, Аллаһы юлындагы сугышчының әҗеренә ирешер өчен малымны ничек сарыф итим?» – диде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм: «Малың нәрсә?» – дип сорады. Әйтте: «Алты мең алтын». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әгәр ул малыңның бөтенесен садака итсәң дә, Аллаһы юлында сугышучыларның бер йокысына да тормас».

Мөхәммәд бине Мукатилдән риваять ителде. Ул әйтте: «Кем дә кем сакта торганда чәчен кисеп соңыннан күмсә, ул кешегә шул күмелгән чәч черегәнгә кадәр сакчы әҗере булыр».

Госман бине Гата атасыннан риваять итте. Ул әйтте: «Габдрахман бине Гауф утыз кол азат итте. Бер кеше моны белеп, бик гаҗәпләнде. Аңа Габдрахман әйтте: «Сиңа аннан да артыграк гамәлне хәбәр итимме?» Теге кеше: «Әйе», – диде. Габдрахман әйтте: «Бер кеше Аллаһы юлында кулында камчысы булган хәлдә ат өстендә барганда, йокымсорап китсә, ул камчы төшеп, аты аны куркытса, син күргән эшләремнән артыграк булыр».

وذكر عبد الله بن المبارك بلإسناده عن رسول الله ﷺ قال : "يبعث يوم القيامة أفواما يمرون على الصراط كهيئة الريح ليس عليهم حساب ولا عذاب".

Габдулла бине Мөбәрак үзенең иснәде белән риваять итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә сираттан җил

рәвешендә үтә торган халыкны кубарыр. Аларга хисап та, газап та булмас». «Әй Рәсүлуллаһ, алар кемнәр?» – дип сорадылар. Ул әйтте: «Үлемнәре дошман каравыллаганда ирешкән халыклардыр».

وروى أبو امامة الباهلي ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "أربعة تجرى عليهم أجورهم بعد موتهم : من مات مرابطا في سبيل الله ن ومن علم علما أجري له اجر من عمل به ، ومن تصدق بصدقة جارية من ماله فأجرها يجري له مادامت الصدقة ن ورجل ترك ولدا صالحا وهو يدعو له".

Әбү Өмәмә разыяллаһү ганһү Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте. Ул әйтте: «Дүрт төрле нәрсә бардыр, аларның әҗереияләре үлгәч тә агып торыр. Берәү сакчылыкта яисә гыйлем өйрәтеп вафат булса, ул гыйлем белән гамәл кылган кешенең әҗере аңа агар. Берәү малыннан җәрия садакасын калдырса, шул садака бар булып торганда, аның әҗере иясенә агып торыр. Бер кеше изге бала калдырса, ул бала аңа дога кылыр».

## Атышу һәм атка атланып йөрүнең фазыйләте турында

عن جابر بن زيد قال : كنت أرامي رجلا من أصحاب رسول الله ﷺ ففقدني يوما ، فقال لي : ما أبطأ بك ؟ فأخبرته بعذري ، فقال : ألا أحدثك بحديث سمعته من رسول الله ﷺ يكون لك عونا على الرمي ؟ فقلت : سمعت رسول الله ﷺ يقول : "إن اله تعالى يدخل بسهم واحد ثلاثة نفر الجنة : الرامي ، والمحتسب بصنعته ، والمقوي به".

Җәбир бине Зәедтән риваять ителде. Ул әйтте: «Мин Рәсүлуллаһның сәхабәләреннән бер кеше

белән атыша торган идем. Көннәрдән бер көнне ул мине югалтты. «Сине нәрсә акрынайтты?» – диде. Мин аңа үз гозеремне сөйләдем. Ул әйтте: «Рәсүлуллаһтан ишеткән хәдисне сиңа сөйлимме? Ул хәдис ату гамәленә сиңа ярдәм булыр». Мин әйттем: «Сөйлә». Ул әйтте: «Рәсүлуллаһтан ишеттем, ул әйтте: «Атыгыз һәм атланыгыз. Атуыгыз сезнең өчен изге һәм минем өчен атлануыгыздан сөеклерәктер. Чөнки мөэмин кеше уйнаган һәр уен батыйльдер, мәгәр өч төрлесе генә батыйль булмас: уктан ату, атыңны өйрәтү, хатының белән уйнау. Дөреслектә болар тиешледәндер».

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Бер ук сәбәпле Аллаһы Тәгалә өч кешене оҗмахка кертер: атучыны, аның һөнәрен яхшыга хисаплаган кешене, шул атуны куәтләгән кешене».

Мәкхүлдән риваять ителде, Гомәр разыяллаһү ганһү Шам халкына язды: «Балаларыгызга суда йөзүне, атуны һәм атка атлануны өйрәтегез».

وروى عن رسول الله ﷺ أنه قال لسعد يوم أحد : "ارم يا سعد ، فداك أبي وأمي"

Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять ителде, ул Сәгыйдкә әйтте: «Ата-анам сиңа фида булсын, әй Сәгыйд, ат».

Фәкыйһ әйтте: «Бу хәбәрдә атуның артыклыгының бәяне бардыр. Чөнки Пәйгамбәр галәйһиссәләм һичкемгә ата-анам фида булсын дип әйткәне юк иде. Атучы булуыннан Сәгыйдкә генә болай әйтте һәм Сәгыйдкә дога кылды: «Әй Аллаһым, ул Сәгыйднең атуын яхшы кыл һәм догасын кабул ит».

وعن عمرو بن شرحبيل أن النبي ﷺ قال : "الإبل عز لأهلها ، والغنم بركة ، والخيل معقود في نواصيها الخير إلى يوم القيامة".

Гамру бине Шурхабилдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Дөя иясе өчен хөрмәттер. Куй исә бәрәкәттер. Әмма ат, Кыямәт көненә кадәр маңгаенда хәер бәйләнгәндер».

Икенче бер хәбәрдә: «Хөрмәт атларның маңгайларында, хурлык сыерларның койрыкларындадыр. Ягъни кешеләр сугыш белән шөгыльләнсәләр, шунда Исламның хөрмәтедер. Әгәр сугышны куеп, сыерларның койрыкларына иярсәләр, хур булырлар».

وعن عمرو بن عبسة عن المبي ﷺ أنه قال : "من رمى سهما في سبيل الله فهو عدل محرر".

Гамру бине Ганбәсәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Берәү Аллаһы юлында бер ук атса, атуы бер кол азат итүенә бәрабәр булыр».

وعن عقبة بن عامر أن النبي ﷺ قال : "ستفتح لكم الأرض ، وتكفون المؤونة ، فلا يعجزن أحدكم أن يلهو باسهمه".

Гокбәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Сезгә җир йөзе ачылыр һәм мәшәкатьне күтәрерсез, уклар белән уйнау һичберегезне гаҗиз кылмасын».

Гомәр бине Хаттаб әйтте: «Җәя җәннәт бакчаларыннан бер бакчадыр. Җәягә атучы дошманга атучы кебектер. Уклар аңа кайтарыла торган кешегә һәрбер адымы саен бер кол азат итү әҗере булыр».

وعن عقبة بن عامر ﷺ أن رسول الله ﷺ قرأ على المنبر هذه الآية ﴿وَأَعِدُّوا لَهُمْ مَا اسْتَطَعْتُمْ مِنْ قُوَّةٍ﴾ ثم قال : "ألا إن القوة الرمي" قالها ثلاثا.

Гокбәдән риваять ителде: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм минбәр өстендә ошбу аятьне укыды: «Көчегез җиткән кадәр алар өчен куәтне хәзерләгез». (Әнфәл: 60) Аннан соң: «Белегез, куәттән морад – атудыр», – дип өч мәртәбә кабатлады».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "من ترك الرمي بعد ما علمه فقد ترك سنة"

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем ату һөнәрен белгәннән соң ташласа, ул сөннәтне ташлады». Икенче бер риваятьтә: «Нигъмәтне ташлады».

Әйтелде: «Әмир булса да, олуг кешегә дүрт төрле нәрсәдән баш тартмаска тиештер. Ата-анасын күрсә, утырган җиреннән тору, кунагына, атына һәм гыйлем, әдәп өйрәтә торган остазына хезмәт итү».

## Сугыш кылуның әдәбе

عن عبد الله بن عمرو ﷺ عن رسول الله ﷺ أنه قال : "لا تتمنوا لقاء العدو ، واسألوا الله العافية ، فإذا لقيتموهم فاثبتوا ، وأكثروا ذكر الله".

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Дошманга юлыгуны теләмәгез, тынычлыкны сорагыз. Әгәр сез ул дошманнарга юлыксагыз, нык булыгыз һәм Аллаһыны күп зекер итегез».

Гауф бине Мәликтән риваять ителде, ул әйтте: «Кем дә кем Аллаһы юлында хак сугышчы, сөннәт хозурында булуны теләсә, ун төрле хасыятне җиренә җиткерсен. Ул унның беренчесе, сугышка ата-ана ризалыгы белән генә чыгу. Икенчесе, муенында

булган Аллаһының әманәтләрен үтәү, ягъни өстендәге золымнардан, гайбәттән һәм ялган сүзләрдән булган адәмнәрнең амәнәтләрен үтәү. Өченчесе, йорт җәмәгатенә сугышта торган вакыт мөддәтенә җитәрлек итеп азык калдыру. Дүртенчесе, азыгы хәләл кәсептән булу, чөнки Аллаһы Тәгалә пакь ризыктан башканы кабул итми. Бишенчесе, түрәсенә буйсыну, әгәр ул түрә түрә булганнан соң Хәбәш җирендә кол булса да. Алтынчысы, иптәш хакын үтәү. Һәр очраган вакытында йөзенә көлеп карау, иптәш ашатканнан күбрәк аңа нәфәка кылу, әгәр авырса, хасталыгын карау, йомышларын үтәү. Җиденчесе, сугыш юлында һичбер мөселманны һәм һичбер гаһедле кешене рәнҗетмәү. Сигезенчесе, сугыш сафыннан качмау. Тугызынчысы, ганимәт малының һичнәрсәсенә хыянәт итмәү. Аллаһы Тәгалә әйтте:

وَمَنْ يَغْلُلْ يَأْتِ بِمَا غَلَّ يَوْمَ الْقِيَامَةِ

«Хыянәт иткән кеше Кыямәт көнендә хыянәт ителгән нәрсәсен китерер». (Әли Гыймран: 161) Унынчысы, сугышыннан динне газизләндерү, мөэминнәргә җиңүне теләр».

Әйтелде: «Сугышчыга сугышта булган вакытта түбәндәге хасыятьләр тиештер: һич курыкмый торган, арыслан йөрәкле булу; кырмыска кадәр булса да, дошманына түбәнчелек кылмау; дошманнан артка чигенүне белмәү; бүре гарьсезлегендә булу; бер тарафтан өметен өзсә, икенче тарафтан һөҗүм итү; авырлыкны йөкләүдә кырмыска кебек булу, кырмыска үз авырлыгыннан ничә өлешне артык йөкләр; ныклыкта таш кебек булу; урыннан һич китмәү; түземлектә ишәк кебек булу; ук тимерләре һәм кылыч сугулары авыр булса да, эт кебек тугрылыклы булу.

Этнең хуҗасы утка керсә, калмас, артыннан керер. Форсат эзләүдә әтәч кебек, гаскәре эчендә төлке кебек булу».

## Мөхәммәд саллаллаһү галәйһи вә сәлләм өммәтенең фазыйләте турында

Фәкыйһ үзенең иснәде белән риваять итте. Муса галәйһиссәләм әйтте: «Әй Раббым, мин такталарда шундый өммәтне таптым, алар үзләре дә шәфәгатьчеләр, шәфәгать тә ителерләр. Шуларны минем өммәтем кылсана». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Алар Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәтедер». Әйтте: «Әй Раббым, мин такталарда шундый өммәтне күрдем, биш вакыт намаз аларның гөнаһларына кәффарәт булачак, бәс аларны минем өммәтем кылсана». Әйтте: «Алар Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәте, синең өммәтең түгел». Әйтте: «Әй Раббым, мин такталарда шундый өммәтне күрдем, алар бидгать һәм азгынлык ияләрен, хәтта дәҗҗалны дә үтерәчәкләр. Аларны минем өммәтем кылсана». Әйтте: «Алар Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәтедер». Әйтте: «Әй Раббым, мин такталарда шундый өммәтне таптым, аларның пакьләнүләре су белән, әгәр су булмаса, туфрак белән пакьләнерләр. Аларны минем өммәтем кылсана». Әйтте: «Алар Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәтедер, синең өммәтең түгел». Әйтте: «Әй Раббым, мин такталарда шундый өммәтне күрдем, алар садаканы алып ашыйлар. Хәлбуки, әүвәлгеләр ул садаканы ут белән яндыралар иде. Аларны минем өммәтем кылсана». Әйтте: «Алар Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәте, синең түгел». Әйтте: «Әй Раббым, мин такталарда шундый өммәтне күрдем,

аларның берсе изгелек кылырга ниятләп, кылмый калса, аңа бер изгелек языла. Әгәр ниятләгән изгелекне эшләсә, аңа уннан алып җиде йөзгә кадәр, яки артык изгелек языла. Әгәр аларның берсе явызлык кылырга ниятләсә һәм кылмый калдырса, аңа һич нәрсә язылмас. Әгәр шул ният иткән явызлыкны эшләсә, аңа бер явызлык язылыр. Бәс аларны минем өммәтем кылсана». Әйтте: «Алар Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәтедер». Әйтте: «Әй Раббым, мин такталарда шундый өммәтне күрдем, аларның җитмеш меңе җәннәткә хисапсыз керер. Син аларны минем өммәтем кылсана». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Алар Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәтедер».

Мугаммәр Котәдәдән шундый ук хәбәр риваять ителде һәм өстәде: «Муса га-ләйһиссәләм әйтте: «Әй Раббым, мин шундый өм-мәтне күрдем, алар барча өммәтләрнең артыграгы, алар изгелек кылу белән боералар һәм шәригатьтә тыелган нәрсәләрдән тыялар. Аларны минем өммәтемнән кылсана». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Алар Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәте, синең түгел». Муса галәйһиссәләм әйтте: «Әй Раббым, мин такталарда шундый өммәтне таптым, алар дөньяда соңгы өммәтләрдән һәм Кыямәт көнендә алдагылардыр. Аларны минем өммәтемнән кылсана». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Алар Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәтеннәндер». Муса галәйһиссәләм әйтте: «Әй Раббым, мин такталарда шундый өммәтне таптым, аларның китаплары күкрәкләрендәдер, борынгылар исә карап укыйлар иде. Аларны минем өммәтеннән кылсана». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Алар Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәте, синең өммәтең түгел». Гүя Муса галәйһиссәләм үзе Мөхәммәд галәйһис-

сәләмнең өммәтеннән булуны теләде. Аллаһы Тәгалә аңа вәхи кылды:

يَامُوسَى إِنِّي اصْطَفَيْتُكَ عَلَى النَّاسِ بِرِسَالَاتِي وَبِكَلَامِي فَخُذْ مَا آتَيْتُكَ وَكُنْ مِنَ الشَّاكِرِينَ

«Әй Муса! Мин сине адәмнәр хозурына пәйгамбәр һәм рәсүл итеп сайладым. Мин биргәнне тот һәм шөкер кылучылардан бул». (Әгъраф: 144) Муса галәйһиссәләм кавеме җөмләсеннән шундый өммәт бардыр, тугры юлга күнәрләр һәм шуның белән барырлар. Муса галәйһиссәләм разый булды».

Мукатил бине Хәббән разыяллаһү ганһү риваять итте. Дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Мине күктә йөрткән вакытта, Җәбраил галәйһиссәләм мине Сидратүл-мүнтәһә каршындагы олуг пәрдә янында туктатты. Җәбраил галәйһиссәләм әйтте: «Әй Мөхәммәд, алга атла». «Әй Җәбраил, бәлки син алдымнан атла», – дидем. Җәбраил әйтте: «Әй Мөхәммәд, синнән башка кешегә бу урыннан үтү һич тиеш түгел». Аллаһы Тәгалә каршында син хөрмәтлерәк». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Атладым, хәтта алтыннан булган урындыкка терәлдем. Ул урындык өстендә җәннәт ефәгеннән түшәк бар иде. Минем артыннан Җәбраил галәйһиссәләм: «Әй Мөхәммәд, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә сиңа сәнә кыла. Тыңла һәм буйсын. Аның сүзе сине куркытмасын», – диде. Мин дә Аллаһы Тәгаләгә мактап: «Тел, тән һәм мал гыйбадәтләре Аллаһы Тәгаләгә булсын», – дидем. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй Пәйгамбәр, сиңа сәлам, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һәм бәрәкәте булсын». Әйттем: «Безгә һәм Аллаһының изге бәндәләре сәлам булсын». Җәбраил галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһыдан башка гыйбадәт кылуга лаек Зат булмавына һәм

Мөхәммәд галәйһиссәләм Аның бәндәсе һәм туры юлга өндәр өчен җибәрелгән илчесе икәненә таныклык кылам». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Пәйгамбәр Раббысы тарафыннан иңдерелгән нәрсәгә иман китерде». Мин әйттем: «Сиңа инандым. Һәм мөэминнәр дә һәрберсе Аллаһы Тәгаләгә, Аның фәрештәләренә, Аның китапларына, Аның рәсүлләренә иман китерделәр. Пәйгамбәрләр арасын һичкайчан аермыйбыз. Ягъни иман китергәндә барысы да Аллаһы Тәгаләнең хак илчеләре, дип әйтәбез. Яһүд кавеме Муса белән Гайсә галәйһимәссәләм арасын аералар. Насара халкы да алар арасын аерды. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Аллаһы Тәгалә кешене көче җиткән нәрсә белән генә боерадыр. Хәердән тапкан нәрсәнең савабы шул нәфескә, ягъни үзенә булыр. Явызлыктан кәсеп кылганның газабы нәфес зарарынадыр». Моннан соң Аллаһы Тәгалә әйтте: «Сора, бирермен». Мин әйттем: «Әй Раббыбыз, Синең ярлыкавыңны сорыйм һәм Синең хозурыңа кайтачакбыз. Ягъни безнең гөнаһларыбызны ярлыка, чөнки Кыямәт көнендә безнең кайтачак урыныбыз Сиңадыр». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Сине һәм синең өммәтеңне ярлыкадым. Кем дә кем Мине берләсә һәм сине хак пәйгамбәр дип ышанса, шуны ярлыкадым». Соңыннан Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй Мөхәммәд, сора бирермен». Мин әйттем: «Әй Раббыбыз, әгәр без онытсак, яки хата кылсак, безне җәза кылма». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Бу әҗер сиңа гынадыр. Онытканыгыз, яки хата кылганыгыз яки мәкрүһ күргәнегез өчен сезне җәза кылмам». Соңыннан Аллаһы Тәгалә әйтте: «Сора, әгәр сорасаң, бирермен». Мин әйттем: «Бездән элек булган халыкка йөкләгәнең кебек безгә мәшәкатьне йөкләмә. (Әгәр Бәни Исраил кавеме хаталык белән

берәр эшне эшләсәләр, Аллаһы Тәгалә аларга ашамлыкларның иң яхшысын хәрам итә иде. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Хәләл булган яхшы ашамлыкларны яһүди булган кешеләргә золым бәрабәренә хәрам кылдык»). Аллаһы Тәгалә әйтте: «Ул, ягъни яһүдләргә кылганны сезгә кылмавым, синең өчен генә. Сора, әгәр сорасаң, бирелер». Мин әйттем: «Әй безнең Раббыбыз, безне көчебез җитмәгән нәрсәгә көчләмә. Чөнки минем өммәтем зәгыйфьләр, күтәрә алмаслар». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Ул сораганың сиңа. Сора, бирелер». Мин әйттем: «Безне кичер, гөнаһларыбызны ярлыка, безгә рәхмәт кыл, Син безнең хуҗабыз, кәфер халыклар хозурына безгә ярдәм бир». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Ул сораганың сиңа бирелер. Әгәр сездән түземле егерме кеше булса, ике йөзгә өстен булырлар».

عن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "أعطيت خمسا يعطهن أحد من الأنبياء قبلي : أرسلت إلى الأحمر والأسود ، وجعلت لي الأرض مسجدا وطهورا ، ونصرت بالرعب مسيرة شهر ن وأحل لي المغنم ، وأعطيت الشفاعة فاخرتها لأمتي".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Миңа миннән элек булган пәйгамбәрләргә бирелмәгән биш нәрсә бирелде. Мин кызыл халыкка да, кара халыкка да, ягъни барча кеше һәм җеннәргә пәйгамбәр итеп җибәрелдем. Миңа бөтен җир йөзе мәчет һәм су кулланырга гозер булса, пакьләнергә яраклы нәрсә ителде. Бер айлык юл барганда Аллаһының дошманнарын куркыту белән ярдәм бирелде. Сугыштан калган ганимәт малы миңа хәләл ителде. Һәм миңа шәфәгать

бирелде. Ул шәфәгатьне Кыямәт көнендә өммәтем өчен азык иттем».

Фәкыйһ Әбү Җәгъфәрдән риваять итте. Ул әйтте: «Хәзрәти Гомәр разыяллаһү ганһүнең бер яһүди өстендә аласы хакы бар иде. Гомәр аңа очрады һәм әйтте: «Мөхәммәд галәйһиссәләмне бөтен адәмнәргә пәйгамбәр итеп сайлаган зат белән ант итәм, синнән әйберемне таләп итмичә, синнән аерылмам». Яһүд әйтте: «Аллаһы Тәгалә Әбү Касимне бөтен адәмнәр хозурына сайламады». Гомәр разыяллаһү ганһү кулын күтәрде һәм ул яһүднең яңагына сукты. Яһүд әйтте: «Синең белән минем арада Әбү Касим бар, хөкем итсен». Икесе дә Пәйгамбәр галәйһиссәләм янына килделәр. Яһүди әйтте: «Гомәр, Аллаһы Тәгалә сине бөтен адәмнәргә пәйгамбәр итеп сайлады, дип әйтте. Мин исә моны инкарь иттем, шул сәбәпле ул минем яңагыма сукты». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Гомәр, аны битенә сукканыннан разый ит». Моннан соң әйтте: «Әй яһүд, Адәм галәйһиссәләм сафийуллаһ, Ибраһим халилүллаһ, Муса нәҗийүллаһ, Гайсә рухуллаһ, мин исә хәбибуллаһ. Әй яһүд, Аллаһы Тәгаләнең исемнәреннән ике исеме бардыр. Ул алар белән минем өммәтемне атады. Үзен Сәлям, өммәтемне мөселманнар, дип атады. Үзен Мөэмин, өммәтемне мөэминнәр, диде. Әй яһүд, сез безнең көнебездә, ягъни җомгада дәгъва кылдыгыз. Бу көн безнең өчен, иртәге көн сезнең өчен, иртәдән соңгысы насара халкы өчен. Әй яһүд, сез әүвәлге өммәтләрсез, без соңгылар, Кыямәт көнендә алда булучыларбыз. Әй яһүд, мин кергәнгә кадәр оҗмах барча пәйгамбәрләргә хәрамдыр. Минем өммәтем кергәнгә кадәр оҗмах башка өммәтләргә хәрамдыр».

Кәгъб әйтте: «Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләрне хөрмәтләгән кебек бу өммәтне дә өч нәрсә белән хөрмәтләде. Беренчесе, һәрбер пәйгамбәрне үзенең халкына шаһид ясады. Бу өммәтне дә адәмнәргә шаһид итте. Икенчесе, Аллаһы Тәгалә рәсүлләргә:

يَاأَيُّهَا الرُّسُلُ كُلُوا مِنْ الطَّيِّبَاتِ وَاعْمَلُوا صَالِحًا

«Әй пәйгамбәрләр, яхшы ашамлыклар ашагыз һәм изге гамәлне кылыгыз», – диде. (Мөэминүн: 51) Бу өммәткә исә әйтте:

كُلُوا مِنْ طَيِّبَاتِ مَا رَزَقْنَاكُمْ

«Мин ризыкландырган нәрсәнең хушыннан ашагыз». (Бәкара: 172) Өченчесе, һәрбер пәйгамбәргә кабул була торган дога кылды. Бу өммәткә әйтте:

ادْعُونِي أَسْتَجِبْ لَكُمْ

«Миңа дога кылыгыз, әгәр дога кылсагыз, догагызны кабул итәрмен» (Гафир: 60)».

Әйтелде: «Аллаһы Тәгалә бу өммәтне биш төрле кәрамәт белән хөрмәтләде: тәкәбберләнмәсеннәр өчен аларны зәгыйфь итеп яратты; ризык һәм кием мәшәкате аз булсын өчен үзләрен кечкенә итеп яратты; гөнаһлары аз булсын өчен гомерләрен кыска итте; ахирәттә хисаплары аз булсын өчен аларны фәкыйрь кылды; кабердә калулары аз булсын өчен өммәтләрнең ахыры кылды».

Зекер ителде, Адәм галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә миңа бирмәгән дүрт кәрамәтне Мөхәммәд галәйһиссәләм өммәтенә бирде. Беренчесе, тәүбәм кабул булсын өчен Мәккәгә барырга әмер итте. Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәте һәр урында тәүбә итсә дә, Аллаһы Тәгалә тәүбәләрне кабул итә. Икенчесе, киемле идем, гөнаһ кылгач, Аллаһы Тәгалә мине киемсез калдырды.

Хәлбуки, Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәте ялангач хәлдә гөнаһ кылсалар да, Аллаһы Тәгалә аларны киендерер. Өченчесе, гөнаһ кылуым сәбәпле, минем белән хатыным арасын аерды. Хәлбуки Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәте гөнаһ кылсалар да Аллаһы Тәгалә алар белән хатыннар арасын аермый. Дүртенчесе, җәннәттә гөнаһ кылгач, мине аннан чыгарды. Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәте җәннәтнең тышында гөнаһ кылалар да, тәүбә кылып, җәннәткә керәләр».

Гали разыяллаһү ганһүдән риваять ителде, ул әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм сәхабәләр белән бергә утырганда аның янына яһүд халкыннан бер төркем килеп, әйттеләр: «Әй Мөхәммәд, без синнән Муса галәйһиссәләмгә бирелгән сүзләр хакында сорарга килдек. Аллаһы Тәгалә ул сүзләрне пәйгамбәрләренә дә, якын фәрештәләренә дә бирмәде». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Сорагыз». Алар әйттеләр: «Әй Мөхәммәд, синең өммәтеңә фарыз кылынган биш вакыт намаз турында хәбәр бир». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кояш авышкач һәрнәрсә Аллаһы Тәгаләгә тәсбих әйтә, шул сәбәпле өйлә намазы фарыз ителде. Адәм галәйһиссәләм тыелган агачтан ашаган вакытында икенде намазын уку фарыз булды. Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәләмнең тәүбәсен кабул иткән вакытта ахшам намазын уку фарыз ителде. Кем дә кем ошбу намазларны тәмам әҗерләренә ышанып укыса һәм Аллаһы Тәгаләдән хаҗәтен сораса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә сораганын бирмичә калмас. Ястү намазын исә миннән элек булган пәйгамбәрләр укыды. Кояш шайтанның ике мөгезе арасыннан чыга һәм аңа барча кәферләр сәҗдә кыла. Кояш чыкканнан соң иртәнге намазны уку

фарыз ителде». Яһүдләр әйттеләр: «Әй Мөхәммәд, дөрес әйттең. Укыган кешенең савабы ни?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Өйлә намазының вакыты җәһәннәм кыздырылган вакыттыр. Кем дә кем бу намазны укыса, Кыямәт көнендә җәһәннәмнең көйдерүе аңа хәрам булыр. Икенде намазының вакыты, Адәм галәйһиссәләмнең тыелган агачтан ашаган вакытыдыр. Кем дә кем икенде намазын укыса, ул кеше анасы тудырган көндәге кебек гөнаһларыннан чыгар». Соңыннан бу аятьне укыды:

حَافِظُوا عَلَى الصَّلَوَاتِ وَالصَّلَاةِ الْوُسْطَى

«Намазларны укыгыз һәм бигрәк тә урта намазны саклагыз». (Бәкара: 238) Ахшам вакытында Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәләмнең тәүбәсен кабул итте. Кайсы гына мөэмин кеше әҗеренә ышанып бу намазны укыса һәм Аллаһы Тәгаләдән хаҗәтен сораса, аны бирмичә калмас. Кабер һәм Кыямәт көне караңгыдыр. Кайсы гына мөэмин кеше кич караңгылыгында ястү намазына барса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә тәмуг ялкынын хәрам итәр, аңа нур бирер. Ул нур аны сираттан кичерер. Әмма иртәнге намаз, кем дә кем ул намазны кырык көн җәмагать белән укыса, ул кешегә тәмугтан һәм монафыйклыктан бизүне бирер». Яһүдләр әйттеләр: «Әй Мөхәммәд, дөрес әйттең. Ни өчен Аллаһы Тәгалә синең өммәтеңә утыз көн уразаны фарыз кылды?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Адәм галәйһиссәләм тыелган агачтан ашаган нәрсәсе корсагында утыз көнгә кадәр калды. Аллаһы Тәгалә Адәм балаларына утыз көн ачлыкны фарыз итте. Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәт кылуы сәбәпле генә кич ашыйлар». Яһүдләр әйттеләр: «Әй Мөхәммәд, дөрес әйттең. Өммәтеңнең уразасының савабы ни?»

Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Кайсы гына бәндә әҗеренә ышанып, Рамазан аенда ураза тотса, Аллаһы Тәгалә аңа җиде төрле нәрсәне бирер: аның тәненнән хәрам ит арыр; аны рәхмәтенә якын кылыр; аңа гамәлләрнең изгесен бирер; аны ачлыктан һәм сусызлыктан саклар; аңа кабер газабын җиңел кылыр; Кыямәт көнендә кешегә нур бирер, хәтта аның белән, ягъни шул яктылык белән сиратны үтәр һәм Аллаһы Тәгалә аңа җәннәттә кәрамәтләр бирер». Яһүдләр әйттеләр: «Әй Мөхәммәд, дөрес әйттең. Башка пәйгамбәрләрдән артыклыгың нәрсә?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Нинди пәйгамбәр генә булсын, үз кавеменә һәлак белән явыз дога кылды. Мин үз өммәтемә изге доганы, ягъни шәфәгать кылуны ихтыяр иттем». Яһүдләр әйтте: «Әй Мөхәммәд, дөрес әйттең. Хаклык хозурына коллык ителмеш зат Аллаһы Тәгалә генә һәм син Аның рәсүле икәненә шәһадәт бирдек».

Кәгъбтән риваять ителде, ул әйтте: «Муса галәйһиссәләмгә Аллаһының иңдергән нәрсәләренең кайберләрендә укыдым, Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй Муса, ике рәкәгать намаз бардыр ки, аны Мөхәммәд галәйһиссәләм белән аның өммәте укыр. Ул намаз иртәнге намаздыр. Берәү аны укыса, шул кичә, көндез ирешкән гөнаһларын ярлыкармын. Һәм аны ярлыкау һәм аңа рәхмәт итү Минем өстемдә бурыч булыр. Әй Муса, дүрт рәкәгать намаз бардыр, аны Мөхәммәд галәйһиссәләм һәм аның өммәте укыр. Ул дүрт рәкәгать намаз өйлә намазыдыр. Әүвәлге рәкәгате бәрабәренә мәгъфират бирермен. Икенчесе белән мизаннарын авыр итәрмен. Өченче рәкәгате белән алар хозурына фәрештәләрне вәкил кылырмын. Ул фәрештәләр тәсбих әйтерләр һәм аларга ярлыкау сорарлар. Дүртенчесе бәрабәренә

аңа күк ишекләрен ачармын. Алар хозурына хурлар чыгарлар. Әй Муса, дүрт рәкәгать намаз бардыр ки, аны Мөхәммәд галәйhиссәләм hәм аның өммәте укырлар. Ул дүрт рәкәгать икенде намазыдыр. Җир hәм күкләрдә hичбер фәрештә алар өчен истигъфар кылмый калмас. Берәүгә фәрештәләр истигъфар кылса, аны газапламам. Әй Муса, кояш батканда Мөхәммәд галәйhиссәләм hәм аның өммәте укый торган өч рәкәгать намаз бардыр, ул өммәт өчен күк ишекләрен ачармын. Нинди генә хаҗәтне сорасалар да, аларның хаҗәтләрен үтәрмен. Әй Муса, дүрт рәкәгать бардыр ки, шәфәкъ батканда Мөхәммәд hәм аның өммәте аны укырлар. Ул дүрт рәкәгать алар өчен бөтен дөнья hәм анда булган нәрсәләрдән хәерлерәктер. Аналары тудырган көндәге кебек гөнаhларыннан чыгарлар. Әй Муса, Мөхәммәд hәм аның өммәте Мин боерганча тәhарәт төзесәләр, hәрбер тамчы бәрабәренә аларга җәннәтне бирермен. Ул җәннәтнең киңлеге җир hәм күкләр киңлеге кебектер. Әй Муса, Әхмәт hәм аның өммәте Рамазан аенда ураза тотарлар. Һәрбер көн ураза өчен аларга җәннәттә бер шәhәр бирермен. Ул уразада hәрбер кылган нәфел гамәлләре өчен фарыз гамәл әҗерен бирермен. Ул Рамазанда кадер кичәсе кылырмын. Кем дә кем ул кичәдә чын күңелдән үкенеп истигъфар кылса hәм шул кичәдә, яки шул айда вафат булса, аңа утыз шәhид әҗерен бирермен. Әй Муса, Мөхәммәд галәйhиссәләмнең өммәте арасында шундый кешеләр бардыр, югарыга чыгып «лә иләhә илләллаh» шәhадәтен бирсәләр, аларның җәзалары пәйгамбәрләр җәзасыдыр. Рәхмәтем аларга тиеш, ачуым алардан ерактыр. «Лә иләhә илләллаh» дип шәhадәт биреп торганда, аларның берсенә дә тәүбә ишеген япмам».

عن أبي هريرة ﷺ أن النبي ﷺ قال : "إن أول من يدعى يوم القيامة نوح عليه السلام وأمته ، ثم يقال له : هل بلغت ما أرسلت به ؟ فيقول : نعم يا رب ، ثم يقال لقومه : هل بلغكم نوح رسالة الله ، فيقولون : لا والله ، ولئن كنت ارسلت إلينا رسولا لنتبع آباتك ، ونكن من المؤمنين ، فما بلغنا ما امرته به ، فقال لنوح عليه السلام : إت هؤلاء يزعمون أنك لم تبلغهم ، فهل لك عليهم من شهيد ؟ فيقول : نعم ، فيقال : من هم ؟ قيقول : هم امو محمد عليه السلام ، فيدعون ويسألون فيقولون : نعم نشهد أن نوحا عليه السلام قد بلغ قومه ، فيقول قوم نوح : كيف تشهدون علينا ن ونحن أوا الأمم ، وانتم آخر الأمم ؟ فيقولون : نشهد أن الله تعالى بعث إلينا رسولا ، وأنزل عليه الكتاب ، وكان فيما أنزل عليه خبركم".

Әбү Һөрәйрә разыяллаһү ганһү риваять итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кыямәт көнендә иң беренче итеп чакырылган кеше Нух галәйһиссәләм белән аның өммәте булыр. Нух галәйһиссәләмгә әйтелер: «Мин күндергән нәрсәне ирештердеңме?» Ул әйтер: «Әйе, Раббым». Моннан соң әйтелер: «Нух галәйһиссәләм сезгә җибәрелгән нәрсәне ирештердеме?» Әйтерләр: «Аллаһы белән ант итәбез, юк, ирештермәде. Әгәр Син безгә илче җибәргән булсаң, Синең аятьләреңә ияргән булыр идек. Шулай исә, Нух Син кушканны безгә ирештермәде». Аллаһы Тәгалә Нух галәйһиссәләмгә әйтер: «Алар, син ирештермәдең, дип әйтәләр. Синең яклаучы таныкларың бармы?» Әйтер: «Әйе, бар». Әйтелер: «Ул таныкларың кем?» Әйтелер: «Ул таныклар Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәтедер». Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәте чакырылыр

һәм соралыр. «Дөрес, Нух галәйһиссәләм пәйгамбәрлекне үзенең халкына ирештерде», – дип җавап бирерләр. Нух галәйһиссәләмнең халкы әйтер: «Сез безнең өскә ничек таныклык итәсез? Хәлбуки, без халыкның әүвәлгеләре, ә сез исә соңгыларыдыр». Алар әйтерләр: «Таныклык итәбез ки, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә безгә илче җибәрде, һәм китап иңдерде. Аңа иңдерелгән нәрсәдә сезнең хәбәрегез бар иде».

Әбү Һөрәйрә әйтте: «Без дөньяда – соңгылар, ә Кыямәт көнендә – беренчеләр. Моны Аллаһы Тәгаләнең сүзе исбатлый:

وَكَذَٰلِكَ جَعَلْنَاكُمْ أُمَّةً وَسَطًا لِتَكُونُوا شُهَدَاءَ

عَلَى النَّاسِ وَيَكُونَ الرَّسُولُ عَلَيْكُمْ شَهِيدًا

«Шулай ук, халыкларга шаһидлар булуыгыз өчен һәм сезгә Рәсүлегез шаһид булсын өчен, сезне урта өммәт кылдык». (Бәкара: 143)

## Ир кешенең хатынына карата булган хаклары

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Габдулла бине Бүридәдән, ул атасыннан риваять итте, атасы әйтте: «Бер гарәп Пәйгамбәр галәйһиссәләм янына килеп: «Мин мөселман булдым. Миңа шундый нәрсә күрсәт ки, аның сәбәпле ихласым артсын», – диде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм: «Нәрсә телисең?» – дип сорады. Ул әйтте: «Ана теге агачны чакыр, сиңа килсен». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Бар да, аны чакыр». Гарәп агач янына килеп: «Рәсүлуллаһның дәгъватын тыңла», – диде. Агач бер тарафтан икенче тарафка селкенде, алга һәм артка бөгелде. Тамырлары киселеп, ботак һәм тамырларын

өстери башлады, хәтта Пәйгамбәр галәйһиссәләм янына килеп туктады һәм аңа сәлам бирде. Гарәп: «Җитәр, җитәр», – диде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм ул агачка кайтырга боерды. Агач урынына кайтты, тамырларын төшереп, әүвәлге урынында карарланды. Гарәп: «Әй Рәсүлуллаһ, миңа рөхсәт бир, мин синең башың белән ике аягыңны үбим», – диде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм гарәпкә рөхсәт бирде. Пәйгамбәр галәйһиссәләмнең башын һәм ике аягын үпте. Гарәп әйтте: «Үзеңә сәҗдә кылсам, рөхсәт итәрсеңме?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Миңа сәҗдә кылма, һичкем мәхлуклардан һичберәүгә сәҗдә кылмасын. Әгәр мин берәүгә сәҗдә кылырга боерсам иде, хакны олуглау йөзеннән хатынның иренә сәҗдә кылуы белән боерыр идем».

عن ابن عمر ﷺ قال : جاءت امرأة إلى النبي ﷺ فقالت ك يا رسول الله ، ما حق الزوج على الزوجة ؟ قال : "أن لا تمنع نفسها ولو كانت على ظهر قتب ، ولا تصوم يوما إلا بإذنه إلا رمضان ن فإن فعلت كان الأجر له والورز عليها ، ولا تخرج إلا بإذنه ن فإن خرجت لنفسها لعنتها ملائكة الرحمة وملائكة العذاب حتى ترجع".

Ибен Гомәрдән риваять ителде. Бер хатын Пәйгамбәр галәйһиссәләм янына килде һәм әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, ирнең хатын өстендә хакы нәрсә?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Иң зур мәшәкать өстендә дә үзен иреннән тыймас. Рамазаннан башка айларда ирнең рөхсәтеннән башка ураза тотмас. Әгәр ирнең рөхсәтеннән башка ураза тотса, әҗере иренә, гөнаһысы үзенә булыр. Иренең рөхсәтеннән башка өеннән чыкмас. Әгәр чыкса, кайтканчыга кадәр рәхмәт һәм газап фәрештәләре аңа ләгънәт әйтерләр».

Котәдәдән риваять ителде. Ул әйтте: «Безгә Кәгъбнең сөйләгәне риваять ителде. Ул әйтте: «Кыямәт көнендә хатын-кыз иң элек намаз турында соралганнан соң, иренең хакыннан соралыр».

عن الحسن ، عن النبي ﷺ أنه قال : "إذا هربت المرأة من بيت زوجها لن تقبل لها صلاة حتى ترجع وتضع يدها في يده ، وتقول : اصنع ما شءت ، وإن المراة إذا صلت ولم تدع لزوجها ، ودت عليها صلاتها حتى تدعو لزوجها".

Хәсәннән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әгәр бер хатын иренең өеннән качса, кайтып кулын иренең кулына куеп: «Мине теләсәң нәрсә эшләт», – дип әйткәнгә кадәр, аның намазы кабул булмас. Әгәр бер хатын намаз укып, иренә дога кылмаса, иренә дога кылганга кадәр аның намазы кайтарылган булыр».

وعن قتادة قال : ذكر لنا ان رسول الله ﷺ قال في خطبته وهو يومئذ مبني : "أيها الناس إن لكم على نسائكم حقا ، وإن لهن عليكم حقا ، وإن من حقكم عليهن أن يحفظن فرشكم ، ولا يأذن في بيوتكم لأخد تكرهونه ، ولا يأتين بفاحشة مبينة ، فإن هن فعلن ذلك ، فقد أحل الله لكم أن تضربوهن ضربا غير مبرح ، وإن من حقهن عليكم : الكسوة والنفقة بالمعروف".

Котәдәдән риваять ителде. Ул әйтте: «Безгә иреште, дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм Минада булган вакытта, үзенең хөтбәсендә әйтте: «Сезнең хатыннарыгыз өстендә хакыгыз һәм хатыннарыгызның да сезнең өстегездә хаклары бардыр. Сезнең алар өстендәге хаклар җөмләсеннән – сезнең түшәгегезне саклаулары. Сез яратмаган кешеләрне өегезгә кертмәсләр, хәрамлыгы ачык ителгән фәхеш эшне кылмаслар. Әгәр шуны

кылсалар, аларга авырттырмыйча сугу сезгә хәләл булыр. Аларның сезнең өстегездә хаклары җөмләсеннән – тиешенчә кием, нәфәка бирүдер».

وروى عن انس بن مالك ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "إن المرأة إذا صلت خمسها ، وصامت شهرها ، وأحصنت فرجها ، وأطاعت بعلها ، فلتدخل من أي ابواب الجنة شاءت".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әгәр бер хатын биш вакыт намазын укыса, Рамазан аенда ураза тотса, үзен сакласа һәм иренә буйсынса, теләсә кайсы җәннәт ишегеннән керсен».

عن أنس بن مالك ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "لو أن الزوج سال من أحد منخريه دم ن ومن الآخر ضديد ، ولحسته المراة ما أدت حق زوجها".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителә. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әгәр бер кешенең ике борын тишегенең берсеннән – кан, икенчесеннән – сары су акса, аны хатыны җайласа, ирнең хакын үтәп бетермәде».

## Хатынның иренә карата булган хаклары

عن انس بن مالك قال : شءل رسول الله ﷺ أي المؤمنين اكمل أيمانا ؟ قال : "أحسنكم خلقا مع اهله".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән: «Иман йөзеннән кайсы мөэмин камилрәк?» – дип сорадылар. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Өй җәмәгате белән мөгамәләдә күркәмрәк холыклысы».

عن ابن عمر ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "كلكم راع ، وكلكم مسؤول عن رعيته ، والإمام الذي على الناس راع وهو مسؤول عن رعيته ، والرجل راع على أهل بيته وهو مسرول عنهمن ، والعبد راع على مال سيد وهو مسؤول عنه ، والمرأة راعية في بيت زوجها وهي مسؤولة عن رعيتها ، ألا كلكم راع ، وكلكم مسؤول عن رعيته".

Ибен Гомәрдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Һәркайсыгыз көтүчеләрсез һәм һәр көтүче үзенең өммәтеннән соралыр. Адәмнәр өстенә куелган имам да көтүчедер. Ул үзенең халыгы турында соралыр. Кеше үзенең җәмәгатенә көтүчедер. Ул кеше өй халкы турында соралачак. Кол хуҗасының малына көтүчедер. Ул малының хәленнән соралыр. Хатын ирнең йортына көтүчедер, ул үзенең көтүчелектән соралыр. Белегез, барыгыз да көтүчедер һәм һәркайсыгыз көтүеннән соралачак».

عن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "من تزوج امراة بصداق مثلها ، وهو ينوي ألا يؤديه إليها ، فهو زان ومن استدان دنيا وهو ينوي إلا يقضيه فهو سارق".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем бер хатынга мәһәр мисл (билгеләнгән мәһәр) бәрабәренә никахланып, ул мәһәрне хатынга бирмәскә ният кылса, ул кеше зиначыдыр. Кем дә кем бурыч алып аны бирмәскә ният итсә, ул кеше урлаучыдыр».

عن الحسن البصري عن النبي ﷺ أنه قال : "استوصوا بالنساء خيرا ، فإنهن عندكم عوان لا يملكن لأنفسهن شيئا ، وإنما أخذتموهن بأمانة الله ، واستحللتم فروجهن بكلمة الله تعالى".

Хәсән Бәсридән риваять итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Хатыннарга изгелек итегез. Чөнки ул хатыннар сезнең каршыгызда, бернәрсәгә дә хуҗа түгелләрдер. Аларны Аллаһының әманәт итүе белән генә алдыгыз. Аларның фәрежләрен Аллаһының кәлимәсенә нигезләнеп кием булып хәлләндегез».

Фәкыйһ әйтте: «Хатынның ире өстендә биш хакы бардыр. Беренчесе, хатынны өйдән ят кеше күрми торган урында гына хезмәт иттерү. Өйдән чыгып хезмәт итәрлек итмәс, чөнки ул гаурәт, хатынның чыгуы гөнаһтыр. Янә шәфкатьне ташлау булыр. Икенчесе, хатынына кирәк кадәр намаз, тәһарәт, ураза кебек дин эшләрендәге хөкемнәрне өйрәтү. Өченчесе, ул хатынга хәләл нигъмәт ашату. Чөнки хәрамнан үскән ит ут белән эридер. Дүртенчесе, ул хатынга золым итмәү, чөнки хатын ирдә әманәт нәрсәдер. Бишенчесе, әгәр ул хатын ир өстенә тиешсезлек итсә, хатын кылган эшкә караганда да начаррак эшкә төшмәсен өчен, үгет йөзеннән ул хатынның хаксызлыгын кутәрер».

Риваять ителде, бер кеше үзенең хатыннан зарланыр өчен Гомәр бине Хаттаб разыяллаһү ганһүгә килде. Ул кеше Гомәрнең ишеге янына җиткәч, хәзрәти Гомәрнең Өмме Гөлсүм исемле хатынның Гомәргә тиешсезлек эшләгәнен ишетте. Үз-үзенә: «Мин Гомәргә хатынымнан зарланырга теләдем, хәлбуки аның да минем кебек бәласе бар икән», – дип, өенә кайтып китте. Гомәр разыяллаһү ганһү аны чакырып, хәлен сорады. Ул кеше әйтте:

«Мин сиңа үз хатынымнан зарланырга теләгән идем. Синең хатыныңнан ишеткәнемне ишеткәч, кайтып киттем». Гомәр әйтте: «Аның минем өстемдәге хаклары өчен ул хатынны гафу кыламын. Ул хакларның беренчесе, ул хатын минем белән тәмуг арасында пәрдә, аның сәбәпле минем күңелем хәрамнан тuктыйдыр. Икенчесе, өемнән чыксам, ул минем хәзинәче, малыма сакчы буладыр. Өченчесе, керемне юа. Дүртенчесе, баламны имезә. Бишенчесе, минем өчен икмәк һәм аш пешерә». Ул кеше әйтте: «Минем дә шундый хезмәтләрем хатыным өстендә. Син кичерсәң, инде мин дә кичерермен».

وروى أنس بن مالك ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "أربع نفقات لا يحاسب العبد بهن يوم القيامة : نفقته على أبويه ، ونفقته على إفطاره ، ونفقته على سحوره ، ونفقته على عياله".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Бәндә дүрт төрле нәфәка сәбәпле Кыямәт көнендә хисап ителмәс. Бер төрлесе, ата-анасына биргән нәфәкасы. Икенче төрлесе, ифтарына кылган нәфәкасы. Өченчесе, сәхәрләренә кылган нәфәкасы. Дүртенчесе, әһел-балаларына кылган нәфәкасыдыр».

وعن رسول الله ﷺ أنه قال : "الدنانير أربعة : دينار تنفقه في سبيل الله تعالى ، ودينار تعطيه للمساكين ، ودينار تعطيه في رقبة ، ودينار تنفقه على اهلك ، وأعظمها أجرا الدينار الذي تنفقه على أهلك".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Акча дүрт төрле булырга тиеш. Бер төрлесен, Аллаһы юлына сарыф кылырсың. Икенчесен, мескеннәргә бирерсең. Өченчесен, кол азат итүгә сарыф кылырсың.

Дүртенчесен, әһел-гаиләңә сарыф итәрсең. Ул дүрт төрле акчаның әҗере йөзеннән зуррагы – гаиләңә тоткан малыңдыр».

**Ике араны төзәтү һәм үпкәләшеп торудан тыю**

عن أبي أيوب الانصاري ﷺ أن رسول الله ﷺ قال : "لا يحل لمسلم أن يهجر فوق ثلاث ليال . يلتقيان ، فيعرض هذا بوجهه وهذا بوجهه ن وخيرهما الذي يبدأ بالسلام".

Әбү Әюб Ансаридән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Өч көннән артык кардәшен ташлап тору һичбер мөселманга хәләл булмас. Икесе очрашсалар, икесе дә бер-берсенә ачык йөз белән карарлар. Боларның изгерәге сәлам биреп, сүз башлаганыдыр».

عن الحسن البصري ﷺ أن رسول الله ﷺ قال : "لا تهجروا فإن كنتم مهتجرين لا محالة ، فلا تهجروا فوق ثلاثة أيام ، وأيما مسلمين ماتا وهما مهتجران لا يجتمعان في الجنة".

Хәсән Басридән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Үпкәләп, бер-берегездән аерылмагыз, шиксез, өч көннән артык ташлашып йөрмәгез. Нинди генә ике мөселман кеше ташлашкан хәлдә вафат булсалар, җәннәттә бергә була алмаслар».

عن أنس بن مالك ﷺ قال : قال رسول الله ﷺ : "إن لله عبادا يوضع لهم يوم القيامة منابر من نور ، ليسوا بأنبياء ولا شهداء ، يغبطهم الانبياء والشهداء" فقالوا : من هم يا رسول الله ؟ قال : "هم المتحابون في الله".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең шундый бәндәләре бардыр, аларга Кыямәт көнендә нурдан ясалган минбәрләр куелыр. Алар үзләре шәһидләр дә, пәйгамбәрләр дә түгел. Аларга пәйгамбәрләр һәм шәһидләр кызыгырлар». Әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, алар кемнәр?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Алар Аллаһы ризалыгы өчен бер-берсен сөючеләрдер».

وعن أبي هريرة ﷺ أن النبي ﷺ قال : "تفتح ابواب الجنة يوم الإثنين ويوم الخميس ، فيغفر لكل عبد مسلم ، لا يشرك بالله شيئا إلا عبد كانت بينه وبين اخيه شحناء ، فيقال : انظروا هذين حتى يصطلحا ، قال : فإذا رفع عمل المتصارمين فوق ثلاث رد".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Җәннәт ишекләре дүшәмбе белән пәнҗешәмбе көннәрендә ачылыр. Ул ике көндә гыйбадәттә Аллаһыга берәр нәрсәне ширек иткән кешедән башка һәр бәндәнең гөнаһлары ярлыканыр. Мәгәр ул көннәрдә кардәше белән ике арада кинәсе булган кеше ярлыканмас. Алар килешкәнгә кадәр: «Карагыз әле бу ике кешегә...», – дип әйтелер. Ике арасы кисешкән кешеләрнең изгелекләре күккә күтәрелсә, кире кайтарылыр».

عن أبي امامة ﷺ أن النبي ﷺ قال : "إذا كانت ليلة النصف من شعبان ، يهبط إلى سماء الدنيا ، فيطلع على أهل الارض ، فيغفر لأهل الارض جميعا إلا الكافر والمشاحن".

Әбү Өмәмәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә шәгъбанның уртасы булса, дөнья күгенә иңәр. Җир халкы

хозурына тулугъ итәр. Кяфер белән кинәчеләрдән башка бөтен җир халкын ярлыкар».

Фәкыйһ әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең иңүеннән морад – фәрманының иңүедер. Аллаһы Тәгалә әйткәнчә:

فَأَتَاهُمُ اللَّهُ مِنْ حَيْثُ لَمْ يَحْتَسِبُوا

«... Аллаһы Тәгалә халык хозурына уйламаган тарафтан килде...». (Хәшер: 2) Ягъни, аларга Аллаһының әмере килде.

عن انس بن مالك ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "خمسة ليست لهم صلاة : المراة الساخط عليها زوجها ، والعبد الآبق من يسده ، والمشارم الذي لا يكلم أخاه فوق ثلاثة أيام ، ومدمن الخمر ، وإمام قوم يصلي بهم وهم له كارهون".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Биш кешенең намазы кабул булмас. Ире аңа ачулы булган хатын; хуҗасыннан качкан кол; өч көннән артык сөйләшми йөрүче, кардәшлекне өзүче кеше; һәрвакыт хәмер эчүче һәм халыкның имамының намазы, ул алар белән имам булып намаз укый, алар исә аның имам булуын мәкрүһ күрәләр».

وعن النبي ﷺ انه قال : "ألا أنبئكم بصدقة يسيرة يحبها الله تعالى ؟" قالوا : بلى يا رسول الله ، قال : "إصلاح ذات البين إذا تقاطعوا".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Сезгә Аллаһы Тәгалә сөя торган җиңел садака турында хәбәр биримме?» Әйттеләр: «Әйе, бир». Әйтте: «Аерылсалар, ике араны төзәтүдер».

وعن أبي درداء ﷺ عن النبي ﷺ قال : "ألا اخبركم بأفضل من درجة الصيام والصلاة والصدقة ؟ " قالوا : بلى ، قال : "إصلاح ذات البين إذا تقاطعوا".

Әбү Дәрдәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Сезгә ураза, намаз, садака дәрәҗәсеннән артык гамәлне сөйлимме?» Әйттеләр: «Әйе, әй Рәсүлуллаһ». Әйтте: «Әгәр үпкәләшсәләр, ике араны төзәтү».

Сәхабәләрнең кайберләреннән риваять ителде: «Берәүнең сигез нәрсәгә хәле җитмәсә, аңа гаҗиз булган сигез нәрсәнең әҗеренә ирешү өчен, икенче төрле хәле җитә торган сигез нәрсә лязем булсын. Кем дә кем кичтәге намазның әҗеренә ирешергә теләсә, көндез гөнаһ кылмасын. Кем дә кем нәфел уразасының әҗеренә ирешергә теләсә, үзе ураза тотмаса, телен сакласын. Кем дә кем галимнәр әҗеренә ирешергә теләсә, аңа фикерләү лязем булсын. Кем дә кем өендә торган хәлдә сугышчылар әҗеренә ирешергә теләсә, ул кеше шайтан белән сугышсын. Кем дә кем садака әҗеренә ирешергә теләсә һәм үзе садакадан гаҗиз булса, гыйлемнән ишеткән кадәрен кешеләргә өйрәтсен. Кем дә кем хаҗ әҗеренә ирешүне теләсә һәм хаҗга барудан гаҗиз булса, җомгага даимчылык итсен. Кем дә кем гыйбадәт кылучылар әҗеренә ирешергә теләсә, кешеләр арасын төзәтсен, аларның арасына дошманлык белән ачуны салмасын. Кем дә кем изгеләр әҗерен теләсә, үзе нигә разый булса, кардәше өчен дә разый булсын».

Гали бине Хәсәннән риваять ителде. Ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә әүвәлгеләр белән соңгыларны җыйганда, бер кычкыручы: «Әҗер ияләре кайда?» – дип чакырыр. Җәннәтне теләп баручы бер төркем торырлар. Аларга фәрештәләр очрап: «Кая барасыз?» – дип сорарлар. «Җәннәтне теләп барабыз», – дип әйтерләр. «Хисаптан элекме?» «Әйе, хисаптан элек», – дип җавап кайтарырлар. «Сез кемнәр?» –

дип сорарлар. «Без әҗер иярәребез», – диярләр. «Дөньяда артыклыгыгыз нәрсә булды?» «Безнең хозурыбызга ахмаклык ителсә, йомшаклык кылдык. Явызлык кылсалар, гафу итә идек, – дип әйтерләр. Фәрештәләр: «Җәннәткә керегез, гамәл кылучыларның әҗере ни күркәмдер!» – дип әйтерләр. Моннан соң кычкыручы: «Түзем иярәре кайда?» – дип кычкырыр. Кешеләрдән бер төркем торыр. Җәннәткә керүне теләрләр. Фәрештәләр алардан: «Кая барасыз?» – дип сорарлар. «Җәннәтне теләп барабыз», – диярләр. «Хисаптан элек укмы?» «Әйе, хисаптан элек», – дип җавап бирерләр. «Сез кем?» – дип сорагач, без сабыр иярәре, дип җавап бирерләр. «Түзгәнегез ни иде?» «Нәфесләребезне Аллаһы Тәгаләнең гыйбадәтенә чыдаттык һәм гөнаһ кылмаска сабыр иттек», – дип әйтерләр. Фәрештәләр: «Җәннәткә керегез, гамәл кылучыларның әҗере ни хуштыр!» – диярләр. Кычкыручы: «Аллаһы Тәгаләнең йортындагы күршеләр кайда?» – дип кычкырыр. Бер төркем торып, оҗмахка керергә теләрләр. Фәрештәләр: «Кая барасыз?» – дип сорарлар. «Җәннәтне телибез», – диярләр. «Хисаптан элекме?» «Дөрес, хисаптан элек». Фәрештәләр: «Сез кем?» – дип сорарлар. «Без Аллаһы Тәгаләнең җирендә күршеләре идек», – диярләр. «Күршелегегез нәрсә иде?» – дип сорагач, «Аллаһы ризалыгы өчен сөешә идек, Аллаһы ризалыгын теләп, бүлешә идек һәм Аллаһы ризалыгы өчен бер-беребезнең хален белергә бара идек», – дип җавап бирерләр. Фәрештәләр әйттеләр: «Оҗмахка керегез, гамәл кылучыларның әҗере ни дәрәҗәдә яхшыдыр!»

وعن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ انه قال : "أن الله تعالى يقول يوم القيامة اين المتحابون في؟ فوعزتي وجلالي اليوم أظلهم بظلي يوم لا ظل إلا ظلي".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә әйтер: «Минем ризалыгым өчен бер-берсен яраткан кешеләр кайда? Минем күләгәмнән башка күләгә булмаган көндә, Мин аларны Үз күләгәм белән күләгәләрмен».

Әбү Өмәмәдән риваять ителде. Ул әйтте: «Бер мил җәяү барып, авырган кешенең хәлен бел. Ике мил йөреп, Аллаһы өчен булган кардәшне күрергә бар. Өч мил җәяү бар да, ике кеше арасына төзәт».

Әнәстән риваять ителде. Ул әйтте: «Кем дә кем ике кеше арасын төзәтсә, Аллаһы Тәгалә ул кешегә һәрбер сүзе бәрабәренә бер кол азат итү әҗерен бирер».

Әбү Бәкер Вәррак әйтте: «Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрне халыкны иманга өндәр өчен җибәрде. Алардан күңел, тел, башка әгъзалар һәм холыкның гамәлен теләде. Бу дүртнең һәрберсеннән ике нәрсәне таләп итте. Күңелдән Аллаһы Тәгаләнең эшләрен олугка санауны һәм Аллаһы Тәгаләнең халкына шәфкать кылуны теләде. Телдән һәрвакыт Аллаһы Тәгаләнең зикерен һәм халыкны көйләвен теләде. Әгъзалардан Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуны һәм мөселманнарга ярдәм итүне теләде. Холыктан исә Аллаһы Тәгаләнең казасына риза булуны, халык белән күркәм мөгамәлә кылуны һәм халыкның рәнҗетүен күтәрүне теләде».

عن تميم الداري ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "أر إنما الدين النصيحة" قالها : ثلاثا ن

قالوا : لمن يا رسول الله ؟ قال : "لله ولرسوله ولكتابه وأئمة المؤمنين ولعامتهم".

Тәмим Дәрийдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Белегез, дин нәсыйхәттер». Бу сүзне өч мәртәбә әйтте. Әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, кемгә нәсыйхәт?» Пәйгамбәр галәйһис-

сәләм әйтте: «Аллаһыга, Аның Рәсүленә, Аның китабына, мөселман өммәтенә һәм халыкның барчасына».

Фәкыйһ әйтте: «Аллаһы Тәгалә өчен нәсыйхәт шулдыр ки, Аллаһы Тәгаләгә ышану, Аңа һичкемне ширек кылмау, Аллаһы Тәгалә боерганны үтәү, тыйганыннан тыелу һәм моңа барча кешеләрне өндәү. Рәсүле өчен нәсыйхәт шулдыр, аның сөннәте белән гамәл кылу һәм кешеләрне дә шуңа чакыру. Китабы өчен булган насыйхәт, ул китапка ышану, аны уку, шунда булган нәрсәләр белән гамәл кылу һәм кешеләрне дә шуңа өндәү. Имамнарга нәсыйхәт итү – алар хозурына кылыч белән чыкмау, аларга тигезлек һәм инсаф белән дога кылу, адәмнәрне дә шуңа өндәү. Барча халык өчен нәсыйхәт кылу – үзеңә сөйгәнне аларга да сөю, араларын төзәтү, аларны ташламау һәм аларга төзеклек белән дога кылу». Гали бине Әби Талиб әйтте: «Мәгъфиратны важиб иттерә торган нәрсәләр җөмләсеннән – мөселман кардәшеңә шатлык китерү».

عن النبي ﷺ أنه قال : "ليس بالكاذب من أصلح بين الناس فقال خيرا أو نمى خيرا".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Адәмнәр арасын төзәткән кеше изге дип әйтсә яисә изгегә ирештерсә ялганчы түгелдер. Адәмнәр арасын төзәтү пәйгамбәрлек өлешеннән бер өлештер. Адәмнәр арасын өзү сихер кисәкләреннән булган бер кисәктер».

وروى عن النبي ﷺ أنه قال : "أفضل الناس عند الله تعالى يوم القيامة ثوابا انفعهم للناس في الدنيا ن وإن المقربين عند الله يوم القيامة المصلحين بين الناس".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кыямәт көнендә савап йөзеннән Аллаһы Тәгалә каршында адәмнәрнең артыграгы – дөньяда вакытта кешеләргә файдалырагыдыр. Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгаләгә якын кешеләр – адәмнәр арасын төзәтүчеләрдер».

## Авыруның хәлен белергә бару турында

عن عطاء بن يسار ، أن رسولالله ﷺ قال : "إذا مرض العبد بعث الله إليه
ملكان ، فقال : انظروا ماذا يقول عبدي لعواده ،فإن هو إذا جاؤوه حمد الله
رفعا ذلك إلى الله عز وجل وهو اعلم ، فيقول الله : فولا لعبدي إن انا توفيته
أدخله الجنة ، وإن شهيته بدلت له لحما خيرا من لحمة ، ودما خيرا من دمه ،
وأكفر عنه سيئاته".

Гата бине Ясәрдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әгәр бәндә авыру булса, Аллаһы Тәгалә аңа ике фәрештәне җибәрер һәм әйтер: «Ул бәндә үзен күрергә килгән кешеләргә нәрсә әйткәнен карагыз». Әгәр кешеләр килгәндә, Аллаһыга хәмед әйтсә, ул хәмедне Аллаһы Тәгаләгә күтәрерләр. Хәлбуки, Аллаһы Тәгалә аннан башка да – белүчедер. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Минем бәндәмә әйтегез: «Әгәр Мин аны вафат иттерсәм, җәннәткә кертермен. Әгәр терелтсәм, әүвәлге итеннән изге итне һәм әүвәлге каннан хәерле канны алыштырырмын. Аның явызлыкларына кәффарат итәрмен».

Сәгыйд бине Вәһабтән риваять ителде, ул әйтте: «Салман Фарси белән аның дустына кердем. Сәлман дустына әйтте: «Аллаһы Тәгалә бер мөэмин бәндәсен бәлаләндереп, соңыннан аны сәламәт-

ләндерсә, үткәненә кәффарәт, калганына ризык булыр. Аллаһы Тәгалә бозык бәндәсен бәлаләндереп, соңыннан аны сәламәтләндерсә, иясе бәйләгән дөя кебек булыр. Соңыннан аны ычкындырып җибәрсәләр, ул дөя ни өчен аны бәйләгәннәрен һәм ни өчен җибәргәннәрен белмидер».

عن ابن مسعود ﷺ قال : دخلت على النبي ﷺ وهو يوعك وعكا شديدا فمسسته ، فقلت : إنك لتوعك وعكا شديدا ؟ فقال : "اجل إني أوعك كما يوعك رجلان منكم" ، فقلت : إن لك أجرين ، قال : "نعم ، والذي نفسي بيده ما على الأرض مسلم يصبه مرض فما سواه إلا حط الله عنه خطاياه كما تحط الشجرة ورقها".

Ибен Мәсгуд әйтте: «Мин Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә кердем, ул бик каты авырый иде, мин аны тотып: «Син каты авыру белән авырыйсың», – дидем. Ул әйтте: «Дөрес, мин сездән ике кеше авырган кадәр авырыйм». Мин әйттем: «Сиңа ике әҗер булыр». Ул әйтте: «Дөрес, мин үзем Аның кодрәте кулында булган зат белән ант итәм ки, җир йөзендә нинди генә мөселман авырса, Аллаһы Тәгалә аның гөнаһларын агач үзенең яфракларын койган шикелле кояр».

عن سلمان الفارسي ﷺ قال : قال رسول الله ﷺ : "إا جاءت الحمى للنفس المؤمنة ، فتناديها الروح من جوف النفس ، فتقول : أيتها الحمى ما تريدين من هذه النفس المؤمنة ؟ فتجيبها الحمى فتقول : أيتها الروح الطيبة — إن نفسك هذه كانت طتهرة ، فقذرتها الذنوب والخطايا ، فانا اطهرها ن فتجيبها الروح : ادني إذا ثلاث مرات فطهريها".

Салман Фарсидән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Мөэмин кешегә бизгәк авыруы килсә, рух эчтән аңа: «Әй бизгәк авыруы, бу мөэмин кешедән ни телисең?» – дип сорар. Бизгәк аңа: «Әй пакь рух, элек синең нәфсең пакь иде, гөнаһлар аны пычратты, мин аны пакьлимен», – дип җавап бирер. Рух моны ишетеп, өч мәртәбә: «Алай булса, кил, аны пакьлә», – дип әйтер».

Мөһәҗирләрдән булган бер кеше әйтте: «Миңа иреште ки, авыруның дүрт төрле хасияте бар: каләм аның гөнаһысын язудан күтәрелер; аңа әүвәл кылган яхшы гамәлнең охшашы агар; һәрбер хаталарын бармак очларына кадәр куар, ул хаталарны чыгарыр; әгәр вафат булса, ярлыканган хәлдә вафат булыр, әгәр тереклек итсә дә, ярлыканып тереклек итәр».

Мөгаз бине Җәбәлдән риваять ителде. Ул әйтте: «Әгәр Аллаһы Тәгалә мөэминне авыру белән бәлаләндерсә, сул як фәрештәгә әйтер: «Аңардан каләмне күтәр». Уң як фәрештәгә әйтер: «Сәламәт вакыттагы хәлендә кыла торган изге гамәленнән дә күркәмрәк гамәлләрне яз. Чөнки ул ышанычлы».

Әбү Һөрәйрә риваять итте. Ул әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмгә бизгәк кара хатынга охшап килде. Рәсүлуллаһ аңардан: «Син кем?» – дип сорады. Ул әйтте: «Мин Өммү Мүлдәм». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Өммү Мүлдәм, син нәрсә эшлисең?» – диде. Ул әйтте: «Мин ит ашыйм һәм кан эчәм». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм аның бизгәк икәнен белде. Ул әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, мине үзеңнең иң сөйгән кешеңә җибәр». Әбү Һөрәйрә әйтте: «Ул бизгәкне ансарларга җибәрде. Бизгәк аларны җиде көн тотканнан соң, алар Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмгә үзенең илчеләрен җибәрделәр. Рәсүлуллаһ дога кылды. Аллаһы Тәгалә алардан

бизгәкне алды. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм ансарларны күрсә: «Чын пакьләү белән пакьләнгән халыкка ни зур шатлык!» – дип әйтә торган булды».

عن ابن عمر ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "لا تكرهوا مرضاكم على الطعام والشراب ، فإن الله تعالى يطعمهم ويسقيهم".

Ибен Гомәрдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Сырхауларыгызны ашау-эчүгә көчләмәгез. Чөнки Аллаһы Тәгалә аларны ашата да, эчертә дә».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "أنين المريض تسبيح ، وصياحه تهليل ، ونفسه صدقة ، ونومه عباده ، وتقلبه من جانب إلى جانب جهاد في سبيل الله ، ويكتب له أحسن ما كان يعمل في الصحة".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Авыру кешенең ыңгырашуы тәсбих, аның кычкыруы тәһлил, сулышы садака, йокысы гыйбадәт, бер яктан икенче якка әйләнүе Аллаһы юлында җиһадтыр. Аңа сәламәт вакытта кыла торган гамәлдән изгерәк гамәл языла».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "أربع سيتانفون العمل : المريض إذا بريء ، والمشرك إذا أسلم ن والمنصرف من الجمعة إيمانا واحتسابا ، والحاج من كسب حلال".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Дүрт төрле кеше гамәлне яңадан кыла: авыру сихәтләнсә, мөшрик кеше мөселман булса, чын күңеле белән әҗер-савабына ышанып, җомгадан кайткан кеше һәм хәләл кәсептән тапкан малы белән хаҗ кылган кеше».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "ثلاثة من كنوز البر : كتمان المرض ، وكتمان الصدقة ، وكتمان المصيبة".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Өч төрле нәрсә изгелек хәзинәләреннәндер: авыруны качыру, садаканы һәм кайгыны яшерү».

وروى عن رسول الله ﷺ أنه دخل على سلمان ﷺ وهو مريض ، فقال : "إن لك في مضجعك ثلاث خصال ، أولها : تذكرة من ربك ، زالثاني : تمحيص وكفارة لما سلف من ذنوبك ، والثالث : أن دعاء المبتلى مستجاب فادع الله ما استطعت".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителә. Ул Салман Фарсигә керде һәм ул авыру иде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Синең бу ятуыңда өч төрле хасият бар. Беренчесе, Раббың тарафыннан бүләк. Икенчесе, элек кылган гөнаһларыңа кәффарәт. Өченчесе, бәлаләнгән кешенең догасы кабул булачак. Инде көчең җиткән кадәр Аллаһы Тәгаләгә дога кыл».

Ибен Мәсгудтән риваять ителде. Ул әйтте: «Авыру кешегә әҗер язылмас, чөнки әҗер гамәлдә генә буладыр. Мәгәр ул авыруы гөнаһларына кәффарат буладыр».

Фәкыйһ әйтте: «Авыру кешегә әҗер авыруы сәбәпле язылмас, мәгәр ул кеше изге булган булса, кылган гамәленең охшашы язылыр. Ул кеше гамәлдән гаҗиз калган. Сәламәт булса, аның шул кыла торган рәвештә кыласын Аллаһы Тәгалә беләдер. Аңа шул гамәлләрнең савабы язылыр. Әгәр ул кеше гөнаһларыннан тәүбә итсә, авыруы гөнаһларына кәффарәт булыр. Әмма тәүбә итмәсә, ниятендә шул явыз гамәлләренә кайту булса, авыруы аның гөнаһысына кәффарәт булмас».

وعن الحسن البصري ﷺ أن النبي ﷺ قال : "الحمى حظ كل مؤمن من النار".

Хәсән Басридән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Бизгәк авыруы һәрбер мөэмин кешенең уттан булган өлешедер».

وعن أبي سعيد الخدري ﷺ عن النبي ﷺ قال : "قال ربكم : وعزتي وجلالي لا أخرج عبدا من الدنيا ، وأنا اريثد ان أرحمه حتى أنقيه من كل خطيئة عملها بسقم في جسده ، أو ضيق في معيشته ، فإن بقى عليه منها شيء شددت عليه الموت حتى يجئ إليّ كما ولدته أمه ، ولا أخرج عبدا من الدنيا وأنا أريد أن اعذبه حتى أوفيه بكل حسنة عملها بصحة في جسده ، أو سعة في رزقه ، فإن بقى منها شيء هونت عليه الموت ، حتى يجئ إليّ وليست له حسنة".

Әбү Сәгыйд Худрийдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Сезнең Раббыгыз әйтте: «Гыйззәтем һәм җәләлем белән ант итеп әйтәм ки, мәрхәмәт кылырга теләгән бәндәмне тәнендә бер төрле хасталык, яки тормышында тарлык белән хатасыннан пакьләнгәнгә кадәр дөньядан чыгармам. Әгәр аның өстендә хатасы калса, үлем аңа каты ителер, хәтта ул Минем каршыма тәмам анасы тудырган көндәге кебек гөнаһсыз булып килер. Мин аны газапларга теләгән булсам, аны дөньядан сөенгәнче, үзе эшләгән изгелекне тәнендә сәламәтлек, яки ризыгында киңлек белән аңа биргәнгә кадәр чыгармам. Әгәр изгелек бирелеп бетмәгән булса, аның өчен үлем җиңел ителер, хәтта Миңа аның һич бер изгелеге булмаган хәлдә килер».

Гасыйм Әбү Галиядән риваять итте. Ул әйтте: «Без илле елдан бирле хәдис сөйлибез ки, әгәр бер кеше бер авыру белән бәлаләнсә, анасы тудырган көндәге кебек гөнаһларыннан чыгар». Аллаһы Тәгалә әйтте:

«Җанын алганыма, яки юлына җибәргәнемә кадәр, сәламәт вакытта кыла торган изгелеген бәндәмә языгыз».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "من عاد مريضا لم يزل يخوض في الرحمة فإذا جلس عنده أنغمس فيها".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем авыру кешенең хален сорарга барса, һәрвакыт рәхмәт дәрьясына чумуда булыр. Әгәр авыру кеше янында утырса, баштанаяк ул рәхмәт дәрьясын табар».

عن ابن عمر ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "من عاد مريضا فكأنما صام يوما في سبيل الله تعالى ، اليوم بسبعمائة يوم ، ومن اتبع جنازة فكأنما صام يوما في سبيل الله ، اليوم بسبعمائة يوم".

Ибен Гомәр разыяллаһү ганһүмәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем хаста кешенең хәлен сорарга барса, ул кеше Аллаһы юлында бер көн ураза тоткан кебек булыр. Бер көн гадәттәге көннәрнең җиде йөз көненә торадыр. Кем дә кем җәназа артыннан барса, Аллаһы юлында, бер көне җиде йөз көнгә тора торган, бер көн ураза тоткан кебек булыр».

Өммү Дәрдә разыяллаһү ганһәгә бер кешенең килгәне риваять ителде. Ул кеше Өммү Дәрдә разыяллаһү ганһәгә күңеленең каралыгыннан зарланды. Өммү Дәрдә әйтте: «Ул күңел каралыгы сырхауның бик олугысыдыр. Шулай булса да, сырхау кешене күрергә бар, җәназаны озат, каберләр арасына чык». Бәс ул кеше шулай эшләде, үз-үзендә шатлыкны тоя башлады. Ул кеше Өммү Дәрдә янына кайтты да: «Аллаһы Тәгалә сиңа изге җәза бирсен», – дип әйтте.

## Нәфел намазларының фазыйләте

عن الحسن البصري ﷺ أن رسول الله ﷺ قال : "للمصلى ثلاث خصال : تحف به الملائكة من قدمة إلى عنان السماء ، ويسقط عليه البر من عنان الشماء إلى مفرق رأسه ن وملك ينادي : لو يعلم هذا المصلي من يناخي ما انفتل".

Хәсән Басридән риваять ителде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Намаз укучының өч төрле хасыяте бардыр. Ул намаз укучының аягыннан алып күк йөзенә кадәр фәрештәләр торыр. Күк йөзеннән алып башына кадәр изгелек төшәр һәм бер фәрештә нида кылыр. Әгәр намаз укучы кеше кем мөнәҗәт кылганын белсә, намаздан һич чыкмас иде».

Гомәр бине Хаттаб разыяллаһү ганһү Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм сугышка гаскәр җибәрде. Тиз генә җиңеп, зур ганимәт алдылар. Әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, бу сугышта кебек тиз җиңеп, күп ганимәт малы алган сугышны һич күргәнебез юк». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Сезгә бу сугыштан да зуррак ганимәт малы турында сөйлимме?» Әттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, сөйлә». Рәсүлуллаһ әйтте: «Иртә намазын укый торган халык бардыр, намаздан соң утырган урыннарында калырлар, кояш чыкканчы Аллаһы Тәгаләне зекер итәрләр. Моннан соң ике рәкәгать нәфел намазын укып, өйләренә кайталар. Мона инде болар тизрәк җиңеп, ганимәт малы күбрәк алган кешеләр».

Әбү Зәрдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Яхшы эшкә боеруың садака, яман эштән тыюың садака, Аллаһы Тәгаләнең зикере садака, әһелең белән хаҗәт үтәү садакадыр». Без әйттек: «Әй Рәсүлуллаһ, кеше үзенең теләген үтәгәч

тә садака буламы?» Рәсүлуллаһ әйтте: «Әгәр берәү шәһвәтен Аллаһы Тәгалә хәрам кылган урында үтәсә аңа гөнаһ булмасмы, ничек уйлыйсыз?» Әйттеләр: «Гөнаһ була, дип уйлыйбыз». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әгәр шәһвәтен Аллаһы Тәгалә хәләл иткән нәрсәдә каза кылса, аңа садака булыр. Боларның һәркайсыннан ике рәкәгать иртә намазы җитәр».

Әбү Рафигътән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм Ибен Габбаска әйтте: «Әй абыем! Сине күрергә барып, сиңа файда кылыйммы?» Ибен Габбас әйтте: «Ата-анам сиңа фида булсын, әй Рәсүлуллаһ, файда кыл». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Тор, дүрт рәкәгать намаз укы. Һәрбер рәкәгатендә «Фатихә» белән бер сүрә укы. Кыйраәтен тәмамлагач, ун биш мәртәбә: «Сүбхәнәллаһи вәл-хәмдү лилләһи вә ләә иләәһә илләәллааһү вәллаһү әкбәр», – дип әйт. Соңыннан рөкугъ кылып, анда да бу тәсбихне ун мәртәбә кабатла. Соңыннан башыңны күтәр. Торуыңнан элек янә шул сүзләрне ун мәртәбә әйт. Ошбу тәсбих һәр рәкәгатьтә җитмеш биш мәртәбә, дүрт рәкәгатьтә барчасы өч йөз булыр. Әгәр гөнаһларың сахра комы кадәр булса да, Аллаһы Тәгалә аны ярлыкар». Габбас разыяллаһү ганһү әйтте: «Берәүнең моңа да көче җитмәсә?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Һәрбер җомгада кылыр». «Аңа да көче җитмәсә?» «Һәр айда бер мәртәбә кылыр». Габбас әйтте: «Аңа да көче җитмәсә?» Рәсүлуллаһ әйтте: «Һәр елда бер мәртәбә кылыр».

Кәгъбтән риваять ителде, ул әйтте: «Берәрегез ике рәкәгать нәфел намазының савабын күрсә, әлбәттә, бәрәкәте таулардан зур икәнен күрер иде.

Шулай булса, фарыз намазының савабы нәфел намаз хакында әйтелә торганнан да зурырактыр».

وعن زيد بن خالد عن رسول الله ﷺ أنه قال : "صلوا في بيوتكم ولا تتخذوها قبورا".

Зәйд бине Халидтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Өйләрегездә намаз укыгыз, өйләрдән каберләр ясамагыз».

Сәмра бине Җүндәб Рәсүлуллаһның сәхабәләреннән булган бер кешедән риваять итте, ул әйтте: «Җәмәгать намазының ялгыз укыган намазга караганда артык булганы кебек, кешенең өендә нәфел намазын укуы да кешеләр каршындагы нәфел намазыннан артыграк булыр».

وعن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ انه قال : "من صلى بين النغرب والعشاء عشرين ركعة ، حفظ الله له اهله وماله ودينه ودنياه وىخرته ، ومن صلى الغداة فقعد في مصلاه حتى اطلع الشمس ، ثم صلى ركعتين ، جعل الله له حجابا من النار يوم القيامة".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем ястү белән ахшам арасында егерме рәкәгать намаз укыса, Аллаһы Тәгалә ул кешенең җәмәгатен, малын, динен, дөнья һәм ахирәтен саклар. Кем дә кем иртә намазын укып, укыган урынында кояш чыкканга кадәр утырса, соңыннан торып ике рәкәгать укыса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә Кыямәт көнендә пәрдә кылыр».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "صلاة الرجل في بيته تطوعا نور ، فنوروا بيوتكم".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кешенең өендә нәфел намазын укуы нурдыр. Бәс йортларыгызны нурландырыгыз».

Ибен Гомәрдән риваять ителде. Ул әйтте: «Әбү Зәрргә әйттем: «Әй абыем! Миңа васыять кыл». Әбү Зәрр әйтте: «Рәсүлуллаһтан син миннән сораган шикелле сорадым. Һәм ул миңа әйтте: «Берәү кояш чыкканнан соң ике рәкәгать намаз укыса, ул кеше гафилләрдән язылмас. Берәү ул намазны дүрт итеп укыса, гыйбадәт кылучылар җөмләсеннән язылыр. Берәү ул намазны алты итеп укыса, аңа шул көн гөнаһ иярмәс. Берәү аны сигез итеп укыса, канитиинләрдән язылыр. Берәү ул намазны ун ике итеп укыса, ул кеше өчен җәннәттә йорт төзелер».

عن أبي هريرة ﷺ أن النبي ﷺ قال : "أن للجنة بابا يقال له باب الضحى فإذا كان يوم القيامة نادى مناد : أين الذين كانوا يديمون على صلاة الضحى ، هذا بابكم فادخلوه".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Җәннәтнең шундый ишеге бардыр, аңа духа ишеге, дип әйтелер. Әгәр Кыямәт көне булса, бер кычкыручы: «Ишрак намазына даимчылык кылган кешеләр кайда? Бу сезнең ишегегез, керегез – дип кычкырыр».

Габдулла бине Мәсгудтән риваять ителде. Ул әйтте: «Әгәр бер кеше үзенең намазында булса, ул Мәлик ишеген кагадыр. Кем дә кем Мәлик ишеген кагуда даимчылык итсә, ул ишекнең ачылуы якын буладыр».

Әйтелде: «Көндезге намазга караганда кичтәге намазның артыклыгы, яшерен бирелә торган садаканың ачык бирелгән садаканың артыклыгы кебектер».

عن أنس بن مالك ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "ما من بقعة يصلي فيها صلاة أو ذكر الله عليها ، إلا استبشرت بذلك إلى منتهاها إلى سبع أرضين ،

وفخرت على ما حولها من البقاع ، وما من عبد يوقم بفلاة من الأرض يريد الصلاة إلا تزخرفت له الأرض".

Әнәс бине Мәлик Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Җир йөзендә намаз укылса, яки Аллаһы Тәгалә зекер ителсә, җирнең кырыена кадәр сөенеч ирешер, намаз укылган җир тирәсендәге җирләргә мактаныр. Әгәр кеше намаз укырга теләп җиргә басса, ул җир аңа зиннәтләнми калмас».

Халид бине Мәгъдәннән риваять ителде. Ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә өч кеше белән мактаныр. Бер төрлесе, үләнсез, сусыз җирдә яшәр. Азан, камәт әйтеп, ялгызын намаз укыр. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Намаз укый торган һәм Миннән башка һичкем аны күрми торган бәндәмә карагыз. Җитмеш мең фәрештә иңсен дә, аның артында намаз укысыннар». Икенче төрле кеше исә төнлә торып, үзе генә намаз укыр һәм сәҗдә кылган хәлдә йоклар. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Минем бәндәмә карагыз, рухы Минем каршымда һәм тәне Минем өчен сәҗдә кылган». Өченче төрлесе сугыш сафындадыр. Башкалары качтылар, ул исә үтерелгәнчегә кадәр нык булды».

Могафи бине Гыймраннән риваять ителде. Ул әйтте: «Мөэминнең хөрмәте кешеләргә ихтыяҗы төшмәве беләндер. Ул мөэминнең олуглыгы төнлә уяу тору беләндер».

## Намазның камиллеге турында

Салман Фарсидән риваять ителде. Ул әйтте: «Намаз үлчәүдер, кем дә кем ул үлчәүдә тугрылык кылса, аңа да тугрылык кылыныр. Кем дә кем хыянәт

итсә, Аллаһы Тәгаләнең «Мутаффифин» сүрәсендә нәрсә әйткәнен, тәхкыйк, белдегез».

Хозәйфә разыяллаһү ганһүдән риваять ителде. Ул рәкүгъ һәм сәҗдәсен тәмам кылмыйча намаз укый торган кешене күрде һәм әйтте: «Әгәр шул рәвештә вафат булсаң, әлбәттә, мисактагы иман хозурында үлмәссең».

Хәсән Басридән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Сезгә урлаучының иң яманын әйтимме?» Әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, әйт». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Намаздан урлый торган кешедер». Әйтелде: «Намазыннан ничек урласын?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Рәкүген һәм сәҗдәсен тәмам кылмаса, намаздан урлар».

Ибен Мәсгудтән риваять ителде. Ул әйтте: «Кемнең намазы яхшылык белән боермаса һәм яманлыктан тыймаса, ул намаз Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән яраклыгын гына арттырыр». Һәм: «Намазыгызны торгызыгыз, тәхкыйк, ул намаз бозык һәм ярамас эшләрдән тыядыр», – дигән аятьне укыды».

Хәкәм бине Гуйәйнәдән риваять ителде. Ул әйтте: «Кем дә кем намаз укыганда уңда һәм сулда булган кешеләр турында уйласа, ул кешенең намазы юктыр».

Мөслим бине Ясәрдән риваять ителде, ул хатынына әйтә иде: «Мин намазда вакытта сөйләшсәгез, мин сезнең сүзегезне ишетмим».

Ягъкуб Каридән риваять ителде, ул намаз укыганда, карак килеп, Ягъкубның киемен алып китте. Ул киемне үзенең юлдашлары янына алып килде. Алар Ягъкубның киемен танып: «Ул киемнәрне кайтар. Чөнки без аның догасыннан куркабыз», – диделәр. Карак киемне Ягъкубның иңенә салды,

үзенең эшеннән гозер сорады. Намазыннан бушангач, Ягъкубка бу хәлдән хәбәр бирделәр. Ул әйтте: «Мин аның өстемнән алуынан да, куюыннан да хәбәрсез булдым, берни сизмәдем».

Рабига Гадәвиййәдән риваять ителде. Ул намаз вакытында камыш паласка сәҗдә кылды. Камыш кисәге күзенә керде, намаздан бушанганчы шуны сизмәде.

Хәсән бине Галидән риваять ителде. Тәһарәт ала башласа төсе үзгәрә иде. Бу хикмәте турында соралды. Хәсән әйтте: «Мин Аллаһының хозурында торырга телим». Мәчет ишегенә җитсә, башын күтәреп: «Әй изгелек кылучы илаһым, синең ишегең төбендә бәндәңдер. Тәхкыйк, сиңа явызлык эшләүче килде. Син безнең арадагы яхшы кешегә явызлыкны кичерергә боердың. Син изгелек итүче һәм мин явызлык итүче. Әй Кәрим, Үзеңнең каршыңда булган рәхмәтеңнең күркәме белән минем каршымдагы начарлыкны кичер», – дип әйтә иде. Соңыннан мәчеткә керде».

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде. Ул намазда сакалы белән уйный торган кешене күрде һәм әйтте: «Әгәр аның күңеле курыкса, аның әгъзалары да куркыр иде».

Гали бине Әбү Талибтән риваять ителде, намаз вакыты җитсә, төсе үзгәреп, тамырлары авазлы булыр иде. Моннан соралды. Ул әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең җир, күкләргә һәм тауларга биреп караганда, алар алмыйча, инсан алган әманәт вакыты җитте. Өстемә алган нәрсәне күркәм кылырмынмы, йә юкмы. Куркам, ничек үтәгәнемне белмим».

Гали бине Хусәйн бине Гали бине Әбү Талибтан риваять ителде, ул әйтте: «Таифә мәчетендә Ибен Габбас разыяллаһү ганһү янында мин, Гәкрәмә,

Мәймүн бине Мәһран, Әбү Галия һәм башкалар булдык. Мөәззин азан әйтте. Ибен Габбас разыяллаһү ганһүмә елады, хәтта киеме юешләнде, бугаз тамырлары кабарды, ике күзе кызарды. Әбү Галия әйтте: «Әй Рәсүлуллаһның абыйсының улы, бу нинди елау һәм нинди хәсрәт. Без азанны ишеткәндә, еламыйбыз, мәгәр син елаганга гына еладык». Ибен Габбас әйтте: «Әгәр кешеләр мөәзин әйткәнен белсәләр, йокламаслар һәм тынычланмаслар иде». Без әйттек: «Безгә мөәзиннең әйткәнен сөйлә». Ибен Габбас әйтте: «Әгәр мөәзин «Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр» дип әйтсә, «әй эшли торган кешеләр, азан вакытында бушаныгыз, тәннәрегезне тынычландырыгыз, гамәлләрегезнең изгесенә барыгыз», дип әйтер. Әгәр мөәзин «әшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһ» дип әйтсә, әйтәдер: «Җир һәм күкләрдә булган кешеләрнең барчасы минем сезне өндәгәнемә Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә хозурында шаһидлык бирерләр». «Әшһәдү әннә мүхәммәдән рәсүллаһ» дип әйтсә: «Көн саен биш мәртәбә хәбәр биргәнемә бөтен пәйгамбәрләр һәм Мөхәммәд галәйһиссәләм шаһидлык бирерләр», дип әйтер. Әгәр «хәййә галәс-саләх» дип әйтсә, әйтәдер: «Аллаһы Тәгалә бу динне сезгә торгызды, аны торгызыгыз». Әгәр «хәййә галәл-фәләх» дип әйтсә, әйтәдер: «Рәхмәткә чумыгыз, һидаяттән булган өлешләрегезне алыгыз». Әгәр «Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр» дип әйтсә, әйтәдер: «Намаздан элек гамәлләр хәрам ителде». Әгәр «лә иләһә илләллаһ» дип әйтсә, әйтәдер: «Җиде күк һәм җиде җир әманәте сезнең муеннарыгызга куелды, әгәр теләсәгез үтәгез, теләсәгез ташлагыз».

وعن النبي ﷺ أنه قال : "إن الرجلين ليقومان في الصلاة ، وركوعهما وسجودهما واحد ، وإن بين صلاتهما كما بين السماء والأرض".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Ике кеше намазга торырлар. Рөкугъләре дә, сәҗдәләре дә бердер. Ләкин боларның намазлары арасы җир белән күк арасы кебектер». Әйтелде: «Ни өчен михрабны михраб дип атадылар, чөнки ул сугыш урыныдыр, ягъни күңелен Аллаһы Тәгаләнең зекереннән алмасын өчен шайтан белән сугышудыр».

Риваять ителде, Хатим Зәһид Гасыйм бине Йосыфка керде. Гасыйм: «Әй Хатим, намазыңны күркәм кыласыңмы?» – дип сорады. Хатим әйтте: «Әйе, яхшы укыймын». Әйтте: «Ничек укыйсың?» Әйтте: «Намаз вакыты якынлашса, камил тәһарәт кылам, намаз укый торган урыныма басам, тәмам әгъзаларым карарланганга кадәр көтәм. Кәгъбәне ике кашым арасында, мәкам Ибраһимне исә күкрәгем турысында күрәм. Күңелемдә булган нәрсәне Аллаһы Тәгалә беләдер, аякларым сират өстендә була, җәннәтне уңымда, җәһәннәмне сулда күрәм, Газраил галәйһиссәләмне артымда, дип беләм. Һәм кирешәчәк намазны соңгы намазымдыр, дип уйлыйм. Тәкбир тәхримне курку һәм түбәнчелек белән кылам, уйлап кыйраәт укыйм, түбәнчелек белән рөкугъ кылам, ялварып сәҗдәгә китәм, тәмам утырам. Өмет һәм курку хозурына «Әттәхиййәт» утыруын утырам, сөннәт рәвеш хозурына сәлам бирәм. Соңыннан ул намазны тәмам ихлас белән тапшырам. Намаздан өмет белән курку арасында торам, түзем белән үтим». Гыйсам әйтте: «Әй Хатим, намазың шул рәвешлеме?» Хатим әйтте: «Минем намазым шулай». Гыйсам әйтте: «Бу сыйфат рәвешчә күптәнме?» Хатим әйтте: «Утыз елдан бирле». Гыйсам

елады һәм әйтте: «Намазларымнан мондый намазны һич вакытта укыганым юк».

Риваять ителде, Хатимның бер мәртәбә җәмәгать намазы калды, юлдашларының кайберләре аны күрергә килде. Хатим елады. Әйтте: «Әгәр минем берәр улым вафат булган булса, Бәлх шәһәренең яртысы мине зиярат кылыр иде. Ә хәзер миннән бер җәмәгать намазы калды һәм юлдашларымның кайберләре генә мине күрергә килде. Әгәр минем барча улларым вафат булса, бу җәмәгать намазы үтүдән миңа җиңелрәк булыр иде».

Хакимнәрнең кайберләре әйтте: «Намаз – кунаклык хөкемендәдер. Аллаһы Тәгалә аны Үзен берләүчеләргә хәзерләде, һәр көндә биш мәртәбә. Кунак итүдә төрле-төрле нигъмәтләр булган шикелле һәрбер ашамлыкта берәр төрле ләззәт һәм берәр төрле төс бар. Шулай ук намазның да төрле-төрле гамәлләре һәм зикерләре бар. Һәрбер фигыле өчен савап һәм гөнаһларга кәффарәт буладыр. Намаз укучылар күп, намазны торгызучылар исә аздыр. Аллаһы Тәгалә мөэминнәрне намазларын торгызучылар, дип сыйфатлады. Ул әйтте:

﴿ وَالْمُقِيمِ الصَّلَاةِ ﴾

«Намазны торгызучылар». (Хаҗ: 35)

Монафыйкларны сыйфалап, намаз укучылар дип атады. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ فَوَيْلٌ لِلْمُصَلِّينَ . الَّذِينَ هُمْ عَنْ صَلَاتِهِمْ سَاهُونَ ﴾

«Намазларыннан ялгыша торган намазчыларга ни үкенечтер». (Мәгун: 4, 5)

Мөэминнәр хакында Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَيُقِيمُونَ الصَّلَاةَ ﴾

«Намазны торгызучылар». (Бәкара: 3)

Ул намазны торгызу намазны даим укудыр, ягъни вакыт керсә, калдырмаудыр. Намазны вакытында уку – рөкугъләрен, сәҗдәләрен тәмам кылудыр».

Хакимнәрнең каберләре әйттеләр: «Кешеләр намаз каршында ике төрледер: хас фирка һәм гомуми фиркадыр. Хас фирка намазга ихтирам белән килер, чын күңел һәм мәхәббәт белән торгызыр. Ул намазны олуглау белән үтәр, намаздан курку белән кайтыр. Әмма гомуми фирка намазга гафиллек белән килер. Наданлык белән намазда торыр, аны вәсвәсә белән үтәр. Намаздан һич куркусыз кайтыр».

Хәкимнәрнең кайберләре әйттеләр: «Олугламыйча гына вәсвәсә белән тәһарәтләнсә һәм вәсвәсә, дөнья эшләре турында фикерләп укыса, аннан намаз кабул ителмәс».

Хәкимнәрнең кайберләре әйттеләр: «Дүрт төрле нәрсә дүрт урынга чумган. Ул дүрт төрле нәрсә башын дүрт урында чыгарган. Беренчесе, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгыдыр. Тәхкыйк, ул Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы итагать һәм гыйбадәткә чумган. Башын юмартлар йортында чыгарды. Икенчесе, Аллаһының ачуыдыр, ул ачу гөнаһларга чумган. Башын сараннар йортында чыгарды. Өченчесе, хуш тереклек һәм киң ризыктыр. Саваплы нәрсәләргә яшеренде. Ул хуш тормыш башын намаз укучыларның өйләрендә чыгарды. Дүртенчесе, тереклекнең тарлыгыдыр. Гөнаһ эшләргә чумды, башын намазны җиңелгә санаучыларның өендә чыгарды».

Хакимнәрнең кайберәүләре әйтте: «Әгәр кешеләр алты төрле нәрсә белән шөгыльләнсәләр, сез инде икенче алты төрле нәрсә белән шөгыльләнегез. Беренчесе, әгәр кешеләр гамәлләрнең күплеге белән шөгыльләнсәләр, сез күркәм гамәлләр белән шөгыльләнегез. Икенчесе, әгәр кешеләр нәфелләр

белән шөгыльләнсәләр, сез фарызларны тәмам итү белән шөгыльләнегез. Өченчесе, әгәр кешеләр ачык эшне төзәтү белән шөгыльләнсәләр, сез яшеренне төзәтү белән шөгыльләнегез. Дүртенчесе, әгәр кешеләр башкаларның гаепләрен күрү белән шөгыльләнсәләр, сез үзегезнең гаепләрегезне күрү белән шөгыльләнегез. Бишенчесе, әгәр кешеләр дөнья төзү белән шөгыльләнсәләр, сез ахирәт төзәтү белән шөгыльләнегез. Алтынчысы, әгәр кешеләр мәхлукларның ризалыгын теләү белән шөгыльләнсәләр, сез Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын теләү белән шөгыльләнегез».

## Дога кылу турында

Әбү Әуфәдән риваять ителде: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм янына бидуин гарәпләреннән бер кеше килде һәм әйтте: «Әй Аллаһының илчесе, миңа Коръән урынына укырга ярый торган нәрсәне өйрәт. Чөнки мин Коръәннән һичнәрсәне яттан белмим». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Сөбхәнәллаһи вәл-хәмдүлилләһи вә ләә иләһә илләәллаһү вәллаһү әкбәр вә ләә хәүлә вә ләә куввәтә илләә билләһил-галиййил-газыйм», – дип әйт». Гарәп ул сүзләрне кулында биш мәртәбә санады, бераз вакытка китеп торды. Соңыннан кайтты һәм әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, бу сүзләр Раббым өчен, үзем өчен нәрсә?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әй Аллаһым, мине ярлыка, тугры юлга күндер, миңа рәхмәт кыл, мине ризыкландыр һәм мине сәламәт ит», – дип әйт». Гарәп янә икенче кулы белән санады, соңыннан китте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әгәр әйткән нәрсәгә тугрылыклы булса, гарәп ике кулын да изгелек белән тутырды».

Фәкыйһ әйтте: «Миңа Коръән урынына тора торган нәрсәне өйрәт», дип әйткән сүзенең мәгънәсе – Коръәннән намазда укыла торган кадәрен белсә, анысы чарасыз кирәктер. Әгәр намазда укыла торганнан артык белмәсә, бу сүзләрне әйтеп йөрсә, Коръән укыган кешенең әҗеренә ирешү өмете бардыр».

عن عثمان بن أبي العاص قال : أتان رسول الله ﷺ وبي وجع كاد أن يهلكني فقال النبي ﷺ : "امسحه بيمينك سبع مرات ، وقل اعوذ بعزة الله وقوته من شر ما أجد وأحاذر" ، قال : ففعلت ذلك فأذهب الله ما كان بي.

Госман бине Әбү Гастан риваять ителде. Ул әйтте: «Һәлак итәргә якын булган авыруым булган хәлдә миңа Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм килде һәм әйтте: «Авырткан урыныңны җиде мәртәбә сыйпап: «Әгүзү бигыйззәтилләһи вә кудратиһи мин шәрри мәә әҗидү вә үхаазиру»,– дип әйт». Госман әйтте: «Шулай иттем, Аллаһы Тәгалә минем белән булган нәрсәне җибәрде».

Гатадан риваять ителде, ул әйтте: «Кем дә кем һич сөйләшмичә уникe рәкәгать намаз укыса, соңыннан җиде мәртәбә «Фатихә» сүрәсен һәм җиде мәртәбә «Аятелкөрси»не укып, ун мәртәбә: «ләә иләәһә илләәллаһү вәхдәһү ләә шәриикә ләһ, ләһүлмүлкү вә ләһүл-хәмдү вәһүвә галәә күлли шәйин кадиир» дип әйтсә, соңыннан сәҗдә кылып, сәҗдәдә «аллаһүммә инни әсәлүкә бимәгаакадил-гыйззи мин гаршикә вә мүнтәһәр-рахмәтә мин китәәбикә вә бисмикәл-газыйм вә җәддүкәл-әгълә вә кәлимәтүкәт-тәәммәтә» дип әйтсә, соңыннан дога кылса, аның догасы кабул булыр».

Мәймүнә бинте Сәгъдтән риваять ителде, Мәймүнә Рәсүлуллаһның хезмәтче хатыны иде. Ул

әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм Салман янынннан үткәндә, ул намаздан соң дога кыла иде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Салман, Раббыгыңнан кирәк нәрсәң бармы?» Әйтте: «Дөрес, бар». Рәсүлуллаһ әйтте: «Догаң алдыннан Раббыңа сәнә әйт. Аны Үзе сыйфатлаган кебек сыйфатла. Аңа тәсбих, тәхмид һәм тәһлил әйт». Салман әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, алдан нинди сәнә әйтим?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Өч мәртәбә «Фатихә» сүрәсен укырсың, чөнки «Фатихә» сүрәсе Аллаһыга сәнә буладыр». Салман: «Аны нинди сыйфатлар белән сыйфатлыйм?» – дип сорады. Рәсүлуллаһ әйтте: «Өч мәртәбә «Ихлас» сүрәсен укырсың, чөнки «Ихлас» сүрәсе Аллаһының сыйфатыдыр. Ул сүрә белән Үз-үзен сыйфатлады». Салман әйтте: «Ничек тәсбих әйтим?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Сүбхәнәллаһи вәл-хәмдүлилләһи вә ләә иләһә илләллаһү вәллаһү әкбәр», дип әйт. Соңыннан Аллаһыдан кирәгеңне сорарсың».

Габдулла бине Мәсгудтән риваять ителде. Ул әйтте: «Кем дә кем намаздан соң өч мәртәбә «әстәгъфируллаһил-газыймәл-ләзии ләә иләһә илләә һүвәл-хаййүл-каййүүмү вә әтүүбү иләйһи», дип әйтсә, Аллаһы Тәгалә аның гөнаһларын ярлыкар. Гәрчә ул гөнаһлар диңгез күбеге кадәр булса да».

Фәкыйһ әйтте: «Әгәр истигъфәр чын күңел үкенүе белән булса, хаталары күп булса да, ярлыканыр».

Хәсән бине Галидән риваять ителде. Ул әйтте: «Мин өстемә алам, әгәр кеше егерме аять укыса, савабы булачак һәм һәр бозыклык кылучы шайтанның һәм золым кылучы түрәнең явызлыгы, дошман, карак, ерткычның зарары аңа ирешмәячәк. Ул егерме аятьләр: «Аятелкөрси», «Әгъраф» сүрә-

сенең өч аяте (54-56), «Саффәт» сүрәсенең әүвәлге ун аяте, «Рахмән» сүрәсеннән өч (33-35) һәм «Хашер» сүрәсенең ахыргы өч аятедер».

Мөгаз бине Җәбәлдән риваять ителде. Дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәләм җомга көнне Мөгаз бине Җәбәлне юксынды. Намаз укыгач, ул Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә килде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Ни булды, сине күрмәдем?» Мөгаз әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, фәлән яһүдигә бурычым бар иде, сиңа барырга чыксам, туктатыр, дип курыктым». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Мөгаз, мин сине өйрәтмимме, шуның белән дога кылырсың. Синең өстеңдә шулкадәр күп бурыч булса да, Аллаһы Тәгалә ул бурычны синнән үтәр». Мөгаз: «Өйрәт», – диде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Укыганнан соң «аллаһүммә мәәликүл-мүлк» сүзеннән алып «бигайри хисәб» дигән сүзенә кадәр укы. «Йә рахмәнүд-дунйәвәл-әхирати вә рахимүһүмә түгъты минһүмә мәң тәшәә-у вә тәмнәгу минһүмә мәң тәшәә-у фәрхәмни рахмәтән тугънини биһә ган рахмәти мән сивак», дип әйт».

Әйтелде: «Бу шундый догадыр, әгәр аның белән әсир кеше дога кылса, ул дога сәбәпле Аллаһы Тәгалә әсирлегеннән чишәр иде».

Әбү Өмәмә Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять итте, ул әйтте: «Кем дә кем таң атканда:

اللهم لك الحمد لا إله إلا أنت ربي ةأنا عبدك آمنت بك مخلصا لك ديني
أصبحت على عهدك ووعدك ما استطعت وأتوب إليك من سيئ عملي
واستغفرك لذنوبي أنه لا يغفر الذنوب إلا أنت

Аллаһүммә ләкәл-хәмду, лә иләәһә иллә әнтә, рабби вә әнә габдук, әмәнтү бикә мухлисан ләкә дини, әсбахтү галә гаһдикә вә вәгъдикә мә-стәтагъту

вә әтубу иләйкә мин сәййи гамәли вә әстәгъфирукә лизүнүби, иннәһү лә йәгъфируз-зунубә иллә әнтә», – дип әйтсә һәм шул ук көндә вафат булса, аңа җәннәт вәҗиб булыр. Әгәр кичәгә кергәндә шул сүзләрне әйтеп, шул кичәдә вафат булса, аңа җәннәт вәҗиб булыр. «Әсбахтү галәә гаһдикә» дигән сүз урынына «әмсәйтү» дип әйтер».

Әбән бине Госманнан риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем таңга кереп, өч мәртәбә:

بسم الله الذي لا يضر مع اسمه شيء في الأرض ولا في السماء وهو السميع العليم

«Бисмилләһил-ләзи ләә йәдурру мәга-смиһи шәй-ун фил-әрдый вә ләә фис-сәмәә-и вә һүвәс-сәмигул-галиим», – дип әйтсә, аңа кичкә кадәр бәла ирешмәс. Әгәр шул сүзләрне кич кергәндә әйтсә, таңга кергәнче аңа бәла ирешмәс».

Әйтелде: «Әбәнне паралич суккач, аңа әйттеләр: «Безгә сөйли торган хәдисне оныттыңмы?» Әбән әйтте: «Белегез, Аллаһы белән ант итәм, мин ялганламадым. Аллаһы Тәгалә мине бәлаләндерергә теләгәч, миңа бу доганы оныттырды».

عن نافع بن عمر ﷺ قال : شهدت رسول الله ﷺ وقد اتاه رجل فقال : يا رسول الله قلت ذات يدي ن قال : "فأين انت من صلاة الملائكة ، وتسبيح الخلائق وما به يرزقون ؟ " قال : ما هو يا رسول الله ؟ ، قال : "سبحان الله وبحمده سبحان الله العظيم استغفر الله مائة مرة ما بين طلوع الفحر إلى أن تصلي صلاة الغداة ، تاتيك الدنيا صاغرة راغمة".

Ибен Гомәрдән риваять ителде. Ул әйтте: «Рәсүлуллаһка бер кеше килгәнен күрдем. Ул әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, кулым тарайды, ягъни фәкыйрь-

ләндем». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Фәрештәләр салаватыннан, бөтен халык тәсбихеннән, ул халык ризыклана торганыннан син кайда булдың?» Кеше әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, ул ни?» Рәсүлуллаһ әйтте: «Таң атканнан алып таң намазын укыганыңа кадәр йөз мәртәбә «сүбханаллаһи вә бихәмдиһи, сүбханаллаһил-газыйм әстәгъфируллаһ» дип әйтү. Шулай дога кылганда, сукыр бәхет сиңа килер».

Гайшә разыяллаһү ганһәдән риваять ителде. Ул әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм йокларга теләсә, ике учын җыя торган иде, ул ике учына өреп, «Ихлас», «Фәләкъ», «Нәс» сүрәләрен укып, ике учы белән йөзен, башын һәм бөтен тәнен сыпыра иде».

Гәкрәмәдән риваять ителде, ул әйтте: «Бер мосафир йоклаган кеше яныннан үтте. Ул кеше янында ике шайтанны күрде. Берсе иптәшенә әйтте: «Бар, аның күңелен боз». Иптәше барып, кире кайтты һәм әйтте: «Ул шундый аять укып йоклаган ки, аңа барырга безгә һич юл калмаган». Шуннан соң йоклаган кеше янына икенчесе китте. Ул да кире кайтты. «Дөрес әйткәнсең», – диде. Соңыннан киттеләр. Мосафир ул кешене уятып, бу вакыйга турында хәбәр бирде.

Әбү Мүҗлиздән риваять ителде, ул әйтте: «Кем дә кем залим түрәдән курыкса һәм: «Аллаһы Раббым булуына, Ислам дине булуына, Мөхәммәд галәйһиссәләм пәйгамбәр булуына, Коръәннең имам һәм хәким булуына разый булдым», – дип әйтсә. Аллаһы Тәгалә ул кешене ул түрәдән коткарыр».

عن يحيى بن سعيد قال : بلغني ان خالد بن الوليد قال : يا رسول الله إني أروع في منامي ، فقال له رسول الله ﷺ : "قل أعوذ بكلمات الله بالتامات من غضبه وعقابه وشر عباده ، ومن همزت الشياطين ، وأعوذ بك رب أن يحضرون".

Яхъя бине Сәгыйдтән риваять ителде, ул әйтте: «Миңа: «Халид бине Вәлид әткәне иреште: «Әй Рәсүлуллаһ, мин йокымда куркам», – диде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм аңа әйтте:

أعوذ بكلمات الله بالتامات من غضبه وعقابه وشر عباده ، ومن همزت

الشياطين ، وأعوذ بك رب أن يحضرون

Әгузү би кәлимәәтилләһит-тәммәти мин газабиһи вә гакабиһи вә шәрри гыйбәдиһи вә мин һәмәзәәтиш-шәйәәтын вә әгузү бикә рабби ән йәхдаруун» дип әйт».

Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән риваять ителде. Рәсүлуллаһ Мөгаз разыяллаһү ганһүнең кулын тотып: «Әй Мөгаз, мин сиңа васыять әйтәм. Һәр намаздан соң:

اللهم أعني على تلاوة ذكرك وشكرك وحسن عبادتك

«Аллаһүммә әгынни галә тиләвәти зикрук вә шукрук вә хусну гыйбәдәтикә», дигән сүзләрне ташлама».

Хозәйфә бине Йәмәнидән риваять ителде, ул әйтте: «Рәсүлуллаһ йокыдан уянган саен ошбу сүзләрне әйтә иде:

الحمد لله الذي أحياني بعد ما أماتني وإليه النشور

عن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "إذا حلم أحدكم حلما يخافه فليبزق

عن شماله ثلاث مرات ، وليستعذ بالله من شره ثلاثا ، فإنه لا يضره".

«Әлхәмдү лилләһил-ләзи әхйәни бәгъдә мә әмәтәни вә иләйһин-нүшүүр».

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әгәр берегез куркыныч төш

күрсә, сул якка өч мәртәбә төкерсен, өч мәртәбә Аллаһыга таянып начарлыгыннан сыенсын. Шулай булса, аңа зарары тимәс».

وعن أنس بن مالك ﷺ قال : جاء إلى رسول الله ﷺ وقال : يا نبي الله أي دعاء أفضل ؟ فقال : "أن تسأل ربك العفو والعافية في الدنيا والآخرة" ، ثم أتاه في اليوم الصاني فقال : يا نبي الله أي دعاء أفضل ؟ فقال : "أن تسأل ربك العفو والعافية في الدنيا والآخرة" ، ثم اتاه في اليوم الثالث فقال : مثل ذلك ، فقال النبي : "إذا اعطيت العفو والعافية في الدنيا والىخرة فقد أفلحت".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде. Ул әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм янына бер кеше килде һәм әйтте: «Әй Аллаһының илчесе, доганың кайсысы артыграк?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Раббыңнан дөнья һәм ахирәттә тыныч һәм сәламәт булуны соравың догаларның артыграгыдыр». Икенче көнне янә килде һәм әйтте: «Әй Аллаһының илчесе, доганың кайсысы артык?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Раббыңнан дөнья һәм ахирәттә тыныч һәм сәламәт булуны соравың догаларының артыграгыдыр». Моннан соң өченче көнне килде дә, сорады: «Әй Аллаһының илчесе, доганың кайсысы артык?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Раббыңнан дөнья һәм ахирәттә тыныч һәм сәламәт булуны соравың догаларының артыграгыдыр, тәхкыйк котылырсың».

Ибен Мәсгудтән риваять ителде. Сәфәрне теләсә, атка атланып:

سبحان الذي سخر لنا هذا وما كنا له مقرنين . وإنا إلى ربنا لمنقلبون اللهم أنت الصاحب في الشفر والخليفة في الأهل اللهم أطولنا الأرض وهون علينا

السفر اللهم إنا نعوذ بك من وعثاء السفر والحور بعد الكور وكآبة المنقلب وسوء المنظر في الأهل والمال والولد

дип әйтә иде.

Ибен Мәсгудтән риваять ителде, ул әйтте: «Әһелеңә керсәң, ул җәмәгатеңә ике рәкәгать намаз укырга боер. Соңыннан аның башыннан тот һәм әйт:

اللهم بارك لي في أهلي ، وبارك لأهلي في وارزقها مني ، وارزقني منها ، واجمع بيننا ما جمعت بخير ، وفرق بيننا ما فرقت بخير

«Аллаһүммә бәрик ли фи әһли вә бәрик лиәһли фий вә-рзукъһә минни вә-рзукъни миңһә вә-җмәгъ бәйнәнә мә җәмәгътә бихайри, вә фиррик бәйнәнә мә фәрррактә бихайр».

Җәгъфәр бине Мөхәммәдтән риваять ителде, ул әйтте: «Дүрт төрле нәрсә белән бәлаләнгән кешедән гаҗәпләндем, ничек ул кеше дүрт төрле нәрсәдән гафил була ала. Кайгы белән бәләләнгән кеше, ничек ул: ﴿ لَا إِلَهَ إِلَّا أَنْتَ سُبْحَانَكَ إِنِّي كُنتُ مِنَ الظَّالِمِينَ ﴾ «лә иләәһә иллә әнтә, сүбханәкә инни күнтү минәз-заалимиин» дигән сүзләрне әйтми, шуңа гаҗәпләндем. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ فَاسْتَجَبْنَا لَهُ وَنَجَّيْنَاهُ مِنَ الْغَمِّ وَكَذَلِكَ نُنجِي الْمُؤْمِنِينَ ﴾

«Йоныс галәйһиссәләмне кайгыдан коткарган кебек мөэминнәрне дә коткарырбыз». (Әнбия: 88)

Явыз нәрсәдән курыккан кешегә гаҗәпләнәм. Ничек ул кеше «хәсбийәллаһү вә нигъмәл-вәкил», дип әйтми. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿فانقلوا بنعمة من الله وفضل لم يمسسهم سوء واتبعوا رضوان الله والله ذو فضل عظيم﴾

«Мөселманнар вәгъдә ителгән урынга бардылар. Аллаһы Тәгаләдән нигъмәт йөзеннән сугыш булмыйча, уңышлы сәүдә итеп, күп мал белән сәламәт кайттылар, һәм Аллаһы разый булачак эшләрне кылдылар. Аллаһы Тәгалә яхшылыкка каршы күп яхшылык итүче, олы фазыйләт ияседер». (Әли Гыймран: 174)

Адәмнәрнең мәкереннән курка торган кешедән гаҗәпләндем. Ничек ул:

﴿ أُفَوِّضُ أَمْرِي إِلَى اللَّهِ إِنَّ اللَّهَ بَصِيرٌ بِالْعِبَادِ ﴾

«Эшемне Аллаһыга тапшырам. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә бәндәләрен күрүчедер», дип әйтми. (Гафир: 44)

Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ فَوَقَاهُ اللَّهُ سَيِّئَاتِ مَا مَكَرُوا وَحَاقَ بِآلِ فِرْعَوْنَ سُوءُ الْعَذَابِ ﴾

«Фиргавен кавеме әлеге мөэминне үтерергә теләделәр, ләкин Аллаһы Тәгалә ул мөэминне кәферләрнең мәкереннән саклады, Фиргавен кавеменә каты газаб иреште». (Гафир: 45)

Җәннәткә кызыккан кешегә гаҗәпләндем. Ничек ул:

﴿ مَا شَاءَ اللَّهُ لَا قُوَّةَ إِلَّا بِاللَّهِ ﴾

«Аллаһы Тәгалә теләгән эш була һәм һичбер эшне кылырга куәт юк, мәгәр Аллаһы ярдәм бирсә генә булыр» дигән сүзне әйтми. (Кәһеф: 39) Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ فَعَسَى رَبِّي أَنْ يُؤْتِيَنِي خَيْرًا مِنْ جَنَّتِكَ ﴾

«Шаять, минем Раббым синең җәннәтеңнән хәерлерәкне китерер». (Кәһеф: 40)

وقال قتادة : ذكر لنا أن رجلا قال على عهد رسول الله ﷺ اللهم ما كنت تعاقبني في الآخرة فعجله لي في الدنيا ، فمرض الرجل فأضنى حتى صار كأنه هامة ، فأخبر رسول الله ﷺ فاتاه ، فرفع رأسه وليس به حراك ، فقيل : يا رسول الله ، إنه كان يدعو بكذا وكذا ، فقال رسول الله ﷺ : "يا ابن آدم ، إنك لا تستطيع أن تقوم لعقوبة الله ، ولكن قل : اللهم ربنا آتنا في الدنيا حسنة وفي الآخرة حسنة وقنا عذاب النار" فدعا بها الرجل فبريء.

Котәдә әйтте: «Безгә риваять ителде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм заманында бер кеше: «Әй Аллаһым, ахирәттә мине газап итәчәк нәрсәңне дөньяда ук бир», – дип дога кылды. Ул кеше хасталанды, ябыкты, хәтта җир корты кебек калды. Аның хасталыгы турында Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмгә хәбәр бирделәр. Ул аның янына килде. Ул кеше башын күтәреп: «Әй Рәсүлуллаһ», – диде. Һәм: «Әй Рәсүлуллаһ, ул шулай дип дога кыла иде», – диделәр. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әй адәм баласы, Аллаһының газабын күтәрергә синең көчең җитмәс, шулай булгач син:

«اللهم ربنا آتنا في الدنيا حسنة وفي الآخرة حسنة وقنا عذاب النار»

«Аллаһүммә раббәнә әтинә фид-дүнйә хәсәнәтәү вә фил-әхирати хәсәнәтәү вә кыйнә газәбән-нәр»,– дип әйт. Бәс шул кеше ул доганы кылды һәм сихәтләнде».

Риваять ителде, Готбә вафат булгач, аны бер кеше төшендә күрде. Аңардан: «Раббың сине ни эшләтте?» – дип сорады. Ул әйтте: «Кылган догаларым сәбәпле Раббым мине ярлыкады. Ул догалар диварга язылды». Кеше йокыдан уянгач,

диварга карады. Анда Готбәнең язуы белән язылган иде:

اللهم يا هادي المضللين ، ويا راحم المذنبين ، ويا مقيل عثرات العاثرين ، ارحم عبدك من ذها الخطر العظيم والمسلمين كلهم أجمعين ، واجعلنا من الاخيار المرزوقين ، مع الذين انعمت عليهم من النبيين والصديقين والشهداء والصالحين ، وحسن أؤلئك رفيقا برحمتك يا أرحم الراحمين

Әйтелде: «Кем дә кем һәр намаздан соң бу биш төрле сүз белән дога кылса, ул кеше изгеләрдән язылыр.

اللهم أصلح أمة محمد اللهم ارحم أمة محمد اللهم فرج عن أمة محمد

اللهم سلم أمة محمد اللهم اغفر لأمة محمد ولجميع من آمن بك

«Аллаһүммә аслих үммәтә мүхаммәд, аллаһүммә-рхәм үммәтә мүхаммәд, аллаһүммә фәрриҗ ган үммәти мүхаммәд, аллаһүммә сәллим үммәтә мүхаммәд, аллаһүммә-гъфир лиүммәти мүхаммәд вә лиҗәмигы мән әмәнә бикә».

Әнәс бине Мәликтән риваять телде. Хәҗҗәҗ бине Йосыф аңа ачуланып әйтте: «Әгәр Габделмәлик бине Мәрвәннең хаты булмаса, мин сиңа шулай-шулай кылыр идем». Әнәс әйтте: «Алай итәргә көчең җитмәс». Хаҗҗәҗ әйтте: «Мине ул эштән нәрсә тыяр?» Әнәс әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм миңа өйрәткән догалар сине миңа берәр эш кылудан тыярлар. Ул догалар белән кич һәм иртә саен дога кылам». Хаҗҗәҗ әйтте: «Миңа өйрәт». Бәс Әнәс әбә кылды. Хаҗҗәҗ Әнәскә ялынды, ләкин йөзен борды. Әббән әйтте: «Әнәс разыяллаһү ганһү хасталангач, шул догалардан сорадым». Әнәс әйтте: «Өч мәртәбә

بسم الله على نفسي وديني بسم الله على أهلي ومالي وولدي بسم الله على كل ما أعطاني ربي الله الله ربي لا أشرك به شيئا الله الله ربي لا اشرك به شيئا الله أكبر الله أكبر الله أكبر وأعز وأجل مما أخاف وأحذر اللهم إني أعوذ بك من شر نفس ومن شر كل شيطان مريد ومن شر كل جبار عنيد فإن تولوا فقل حسبي الله لا إله إلا هو عليه توكلت وهو رب العرش العظيم عز جارك وجل ثناؤك ولا إله غيرك

«Бисмилләһи галә нәфси вә дини бисмилләһи галә әһли вә мәли вә вәләди, бисмилләһи галә күлли мә әгътани раббийәллаһ, аллаһ, аллаһ, рабби лә үшрикү биһи шәй-ән, аллаһ, аллаһ, аллаһ, рабби лә үшрикү биһи шәй-ән, аллаһү әкбәр, аллаһү әкбәр, аллаһү әкбәр вә әгаззу вә әҗәллү миммәә әхафү вә әхзәру, аллаһүммә инни әгузү бикә мин шәрри нәфси вә миң шәрри күлли шәйтанин мүридин вә миң шәрри күлли җәббәрин ганидин, хәсбийәллаһү ләә иләәһә иллә һүвә галәйһи тәвәккәлтү вә һүвә раббулгаршил-газыйм газзә җәәрукә вә җәллә сәнәә-үкә вә ләә иләәһә гайрук» дип әйт».

## Мәрхәмәтле, йомшак күңелле булу турында

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Гайшә разыяллаһу ганһәдән риваять итте. Ул әйтте: «Яһүдләрдән бер төркем халык Пәйгамбәр галәйһиссәләм янына кереп: «Әссәмү галәйкә (сиңа үлем булсын)», – диделәр. Пәйгамбәр галәйһиссәләм: «Вә галәйкүм (сезгә дә)», – дип җавап бирде. Гайшә разыяллаһу ганһә әйтте: «Сезгә дә үлем һәм ләгънәт булсын». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Гайшә, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә һәрбер囲 эштә йомшак

күңелле булуны сөядер». Гайшә разыяллаһү ганһә әйтте: «Алар әйткәнне ишетмәдеңмени?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Ишеттем, мин аларга «Сезгә» генә дидем».

عن عائشة ﷺ أن النبي ﷺ قال : "يا عائشة من أعطى حظه من الرفق فقد أعطى خير الدنيا والآخرة ، ومن حرم حظه من الرفق فقد من خير الدنيا والآخرة".

Гайшә разыяллаһу ганһәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Гайшә, берәүгә йомшак күңелле булудан өлеш бирелсә, аңа дөнья һәм ахирәт изгелеге бирелгән булыр. Берәүгә күңел йомшаклыгыннан өлеш мәхрүм ителгән булса, аңа дөнья һәм ахирәт изгелегеннән дә өлеш мәхрүм ителгән булыр».

عن سعيد بن المسيب ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "رأس العقل بعد الإيمان بالله مداراة الناس ، والتودد إلى الناس ، وما هلك رجل عن مشورة ، وما سعد رجل باستغنائه برأيه ، وإذا اراد الله أن يهلك عبدا كان أول ما يفسد منه رأيه ، وإن أهل المعروف في الدنيا هم أهل المعروف في الآخرة ، وإن أهل المنكر في الدنيا هم أهل المنكر في الآخرة".

Сәгыйд бине Мүсәййибтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһыга иман китергәннән соң аңлылыкның башы адәмнәр белән күркәм мөгамәлә кылу һәм адәмнәргә дус булу. Ир киңәш итүдән һәлак булмас, ләкин киңәшсез, үз уе белән генә эшләп бәхетле булмас. Әгәр Аллаһы Тәгалә бер колны һәлак итәргә теләсә, иң элек бозылган нәрсәсе – уе булыр. Чөнки дөньядагы яхшылык әһеле, ахирәттә яхшылык әһеледер, дөньядагы явызлык әһеле, ахирәттә дә явызлык әһеледер».

عن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "إن الله تعالى رفيق يحب الرفيق ، يعطي على الرفق مالا يعطي على العنف".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә йомшак күңелле, шәфкатьледер. Йомшак күңелле булуны сөя. Йомшак күңелле булганнарга тупас һәм чытык йөзлеләргә бирмәгәнне бирер».

وعن عائشة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "إذا اراد الله تعالى بأهل بيت خيرا أدخل عليهم الرفق ، وإن الرفق لو كان خلقا لما رأى الناس خلقا أحسن منه ، وإن الخرق لو كان خلقا لما رأى الناس خلقا أقبح منه".

Гайшә разыяллаһу ганһәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә бер өй халкына изгелекне теләсә, аларга йомшак күңелле булуны кертер. Чөнки йомшак күңеллелек холык булып урнашса, кешеләр аннан да күркәмрәк холыкны күрә алмаслар».

وعن عائشة ﷺ قالت : كنت على بعير فيه صعوبة فجعلت أضربه ، فقال النبي ﷺ : "يا عائشة ، عليك بالرفق ، فإنه لم يكن في شيء إلا زانه ، ولا انتزع من شيء إلا شانه".

Гайшә разыяллаһу ганһәдән риваять ителде. Ул әйтте: «Мин ялкау булган дөягә атланган идем. Мин аңа суктым. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Гайшә, йомшак күңелле бул. Чөнки бер әйбердә йомшаклык булса, ул әйбер зиннәтле булыр. Йомшаклык бер нәрсәдән соралмады исә, ул нәрсә гаепле булыр».

Гали бине Әбү Тәлибтән риваять ителде. Ул әйтте: «Наср» сүрәсе иңгәч, Пәйгамбәр галәйһис-

сәләм авырды. Күп тормады, пәнҗешәмбе көнне кешеләр янына чыкты. Тәхкыйк, ул башына ураган нәрсәсе белән башын минбәрнең ике ягына баглады да, ике күзе яшь агызган, йөзе саргайган хәлдә минбәргә утырды. Моннан соң Билалны чакырды. Аңа Мәдинәнең эчендә: «Рәсүлуллаһның вәсыятенә җыелыгыз», – дип чакырырга боерды. Чөнки ул сезнең өчен булган вәсыятьнең соңгысыдыр. Билал чакыргач, Мәдинә халкының олуглары, кечеләре җыелдылар. Алар, өйләренең ишекләрен ачык, базар әйберләрен җыештырмыйча, шул хәлдә калдырып, ашыгып килделәр. Яшь кызлар да Рәсүлуллаһның вәсыятен ишетер өчен пәрдәләреннән чыктылар, хәтта мәчет җыелган халык белән тулды. Пәйгамбәр галәйһиссәләм үзегезнең артыгызда булган кешеләргә киңәегез, киңәегез, дип әйтеп тора иде. Аннан соң Пәйгамбәр галәйһиссәләм: «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун», – дип елаган хәлдә торды, Аллаһы Тәгаләгә хәмед вә сәнә әйтте, үзенә һәм башка пәйгамбәрләргә салават укыды, моннан соң әйтте: «Мин Мөхәммәд бине Габдулла бине Габделмуталлиб бине Һәшим, гарәп, Мәккәле. Мин шундый пәйгамбәр ки, миннән соң пәйгамбәрләр булмаячак. Әй кешеләр, белегез! Дөреслектә, нәфесем үлем хәбәрен китерде. Дәхи дөньядан аерылыр чагым иреште. Мин Раббыма юлыгырга омтылучымын. Өммәтемнән аерылу никадәр кайгы! Миннән соң алар ни әйтерләр?! Әй Аллаһым! Рәхмәт кыл, рәхмәт кыл. Әй кешеләр, вәсыятемне тыңлагыз һәм аны саклагыз. Сезнең монда булганнарыгыз булмаганнарга ирештерегез. Чөнки бу сезнең өчен соңгы вәсыятемдер. Әй кешеләр, тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә сезгә иңдергән хак китабында, сезнең өчен хәләл кылган нәрсәләрне һәм сезгә хәрам булган нәр-

сәләрне, янә сезгә аңа килергә ярый торганнарны һәм аннан сакланырга кирәк булган нәрсәләрне бәян кылды. Бәс хәләлдән файдаланыгыз һәм хәрамнан тыелыгыз. Шөбһәле булганнарына иман китерегез, шөбһәсез мөхкәм булганнары белән гамәл кылыгыз, мөхкәмнәргә, аның охшашларын кыяс кылыгыз». Моннан соң башын күккә күтәрде һәм әйтте: «Әй Аллаһым, Син шаһид бул, мин ирештердем. Әй кешеләр, үзегезне азгын һәм аздыра торган нәфес теләкләреннән саклагыз, чөнки ул Аллаһыдан һәм җәннәттән ерак булучыдыр, ләкин җәһәннәмгә якындыр. Сезгә җәмәгать һәм ныклык лязем булсын, чөнки ул җәмәгать белән ныклык Аллаһыга һәм җәннәткә якын, уттан эрактыр». Моннан соң янә: «Әй Аллаһым, ирештердемме?» – диде. «Әй кешеләр, сез динегездә, әманәтегездә Аллаһыдан сакланыгыз. Янә колларыгыз милекләнгән нәрсәләрдә, ягъни колларыгыз хакында Аллаһыдан сакланыгыз. Аларга, ягъни колларыгызга һәм барча кул астыгызда булган ялчыларыгызга үзегез ашый торган нәрсәләрегездән ашатыгыз. Аларга үзегез кия торган нәрсәләрдән киендерегез. Аларны көчләре җитми торган нәрсәләр белән көчләтмәгез. Чөнки алар да сезнең кебек итле, канлы мәхлуклар. Аң булыгыз, кем дә кем аларга золым итсә, Кыямәт көнне мин аның дәгъвачысы, Аллаһы Тәгалә аларның хәкиме булыр. Янә хатыннар хакында Аллаһыдан сакланыгыз. Мәһәрләрен үтәгез, аларга золым кылмагыз. Әгәр аларга золым кылсагыз, Кыямәт көнендә ул золымыгыз кылган изгелекләрегездән мәхрүм итәр. Аң булыгыз, ирештердемме? Әй кешеләр! Үзегезне, бала-чагаларыгызны уттан саклагыз, аларга гыйлем өйрәтегез һәм аларны әдәпкә кертегез. Чөнки алар сезнең каршыгызда тоткыннар һәм әманәттер. Аң булыгыз,

ирештердемме? Әй кешеләр! Эшләрегезнең башында тора торган олуг кешеләргә буйсыныгыз, аларга гөнаһ кылмагыз. Гәрчә ул борыны, колагы киселгән хәбәш колы булса да. Чөнки кем дә кем аларга итагать кылса, миңа итагать кылган булыр. Миңа буйсынган кеше Аллаһыга буйсынган булыр. Кем дә кем аларга карышса, тәхкыйк, миңа карышкан булыр. Миңа каршылык кылган кеше, Аллаһы Тәгаләгә карышкан булыр. Аң булыгыз, алар хозурына гөнаһтан сакланыгыз. Аларның гаһедләрен бозмагыз. Ирештердемме? Әй кешеләр! Сезгә минем әһелбәйтемне, Коръән йөкләгәннәрне һәм галимнәрегезне сөю лязем булсын. Аларга ачу тотмагыз, хөсед кылмагыз һәм һөҗүм итмәгез. Аң булыгыз, кем дә кем аларны сөйсә, тәхкыйк, мине сөйгән булыр. Бер кеше мине сөйсә, дөреслектә, ул Аллаһы Тәгаләне сөйгән булыр. Кем дә кем аларны ачуландырса, тәхкыйк, мине ачуландырган булыр. Бер кеше мине ачуландырса, дөреслектә, Аллаһы Тәгаләне ачуландырган булыр. Аң булыгыз! Ирештердемме? Әй кешеләр! Таһарәтне җиренә җиткереп, рөкүгъләрен һәм сәҗдәләрен тәмамлау белән биш вакыт намаз уку сезгә лязем булсын. Әй кешеләр! Малларыгызның зәкәтләрен үтәгез. Аң булыгыз, зәкәтен үтәмәгән кешенең намазы намаз булмас. Белегез, берәүнең намазы намаз булмаса, аның өчен дин дә, ураза да, хаҗ да, җиһад савабы да булмас. Әй Аллаһым, ирештердемме? Әй кешеләр! Юлга чыгарга көче җиткән кешегә Аллаһы Тәгалә хаҗны фарыз кылды. Кем дә кем көче җитә торып, хаҗ кылмаса, ул кеше кайсы гына хәлдә булса да: кирәк яһүди, кирәк насара, кирәк мәҗүси булып үлсен. Мәгәр хаҗны кылмаса, кылмас. Әгәр ул бара алмаслык авыру белән авырса, яки золым кылучы

солтаннан тыелса гына хаждан калу мөмкиндер. Аң булыгыз, көче җитә торып хаҗ кылмаган кешегә шәфәгатемнән өлеш юктыр. Ул минем хаудыма килмәс. Аң булыгыз, ирештердемме? Әй кешеләр! Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә сезне Кыямәт көнне пакъ булган бер урында, олуг урында җыяр. Ул бик каты көндер. Ул көндә мал да, балалар да файда бирмәс. Мәгәр Аллаһыга сәламәт булган калеб белән генә килгәне файда табар, ягъни гөнаһсыз саф калеб белән генә котылыр. Аң булыгыз, ирештердемме? Әй кешеләр! Телләрегезне гөнаһ сөйләүдән саклагыз, күзләрегезне елатыгыз, тәннәрегезне мәшәкатьләндерегез, дошманнарыгыз, ягъни кәферләр белән сугышыгыз, мәчетләрегезне төзәтегез, иманнарыгызны саф итегез, кардәшләрегезгә нәсыйхәт кылыгыз, кардәшләрегезгә кылган нәсыйхәтне элек үзегез эшләгез, гаурәтләрегезне хәрамнан саклагыз, малларыгыздан садака бирегез, хөсед кылмагыз. Әгәр хөсед кылышсагыз, изгелекләрегез югалыр. Бер-берегезне артында яманлап сөйләмәгез, бәс һәлак булырсыз. Аң булыгыз, ирештердемме? Әй кешеләр! Колларыгызны азат кылырга тырышыгыз. Изгелекне фәкыйрьлек һәм мохтаҗлык көнегез өчен эшләгез. Әй кешеләр! Золым кылмагыз. Чөнки золым кылучыдан дәгъвачы Аллаһы Тәгалә Үзедер. Янә Кыямәт көнендә кылган гамәләгездән хисап бирүегез Аллаһы Тәгаләгәдер. Ул Аллаһы янына кайтачаксыз. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә сезнең явызлык кылуыгызны яратмыйдыр. Әй кешеләр! Кем дә кем изгелек эшләсә, үз файдасы өчендер. Кем дә кем явызлык кылса, шулай ук үзе өчендер. Синең Раббың (әй Мөхәммәд) һичбер колга золым кылучы түгелдер. Сез шундый көн өчен тәкъвалык кылыгыз. Ул көндә сез Аллаһыга кайтачаксыз. Моннан соң һәр кешегә

дөньяда кәсеп кылган нәрсәсе кирәк изге, кирәк явыз гамәл, һәркайсы үтәлер. Хәлбуки, алар золым кылынмаслар. Әй кешеләр! Мин Раббым янына китүчемен. Тәхкыйк, нәфсем миңа үлем хәбәрен китерде. Мин сезнең динегезне һәм өммәтегезне Аллаһыга тапшырам. Сезгә Аллаһының рәхмәте булсын. Әй сәхабәләрем, сезгә һәм барча өммәтемә Аллаһының рәхмәте һәм бәрәкәте булсын». Моннан соң минбәрдән төште дә өенә керде. Шуннан соң Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм өеннән чыга алмады».

## Сөннәт белән гамәл кылу

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Мәликтән риваять итте. Ул әйтте: «Дөреслектә, миңа Пәйгамбәр галәйһиссәләмнең сүзе иреште, ул әйтте: «Мин сезгә ике авыр нәрсәне калдырдым. Әгәр бу икегә ябышсагыз, адашмассыз: Аллаһының китабы һәм минем сөннәтем».

عن الحسن ، عن رسول الله ﷺ أنه قال : "عمل قليل في سنة خير من عمل كثير في بدعة ، وكل بدعة ضلالة ، وكل ضلالة في النار".

Хәсәннән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Сөннәт хозурында кылынган аз гына гамәл дә, бидгать хозурында кылынган күп гамәлдән изгерәк. Һәр бидгать адашудыр, һәр адашу уттадыр. Ягъни һәрбер диндә яңа бидгать белән гамәл кылучы зәлаләттә, һәр зәлаләттә булган кеше уттадыр».

Габдулла бине Мәсгудтән риваять ителде. Ул әйтте: «Сөннәттә уртача гамәл, бидгатьтә тырышып эшләгән гамәлдән изгерәктер».

Хәсәннән риваять ителде. Ул әйтте: «Сүз изге булмас, мәгәр гамәл белән генә. Сүз дә, гамәл дә изге булмаслар, мәгәр ният белән генә. Сүз дә, гамәл

дә, ният тә изге булмаслар, мәгәр сөннәт белән генәдер».

وروى معقل بن يسار ﷺ عن رسول الله ﷺ أنه قال : "رجلان لا تنالهما شفاعتي" وفي روية : "صنفان من أمتي لا تنالهما شفاعة : إمام ظلوم ، وغال في الين مارق منه".

Мәгкаль бине Ясәрдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Ике ир бардыр, аларга минем шәфәгатем ирешмәс (икенче бер риваятьтә өммәтемнән ике төрле сыйныфка минем шәфәгатем ирешмәс): җәбер кылучы имам һәм диндә бик ифрат кылып, диннән чыгучыдыр. Ягъни диндә арттырып җибәрүче кеше шундый кешедер, ул диндә дә шулкадәр зур итеп күрсәтер, хәтта әһел сөннәт вә җәмәгать юлыннан чыгар».

Әбү Кәгъбтән риваять ителде. Ул әйтте: «Сез пәйгамбәрләр юлына, сөннәткә лязем булыгыз. Чөнки пәйгамбәрләр юлы һәм сөннәт хозурында булмаган кол, Аллаһы Тәгаләне исенә төшерсә дә, аның ике күзе Аллаһыдан курыкканлыктан яшь агызса да, аны мәңге ут тотар. Ягъни никадәр изге гамәлләр кылып, Аллаһыдан бик курыкса да, сөннәт хозурында булмаса, барыбер ул утка керер. Янә пәйгамбәрләр юлы һәм сөннәт хозурында булмаган кол, Аллаһы Тәгаләне исенә төшереп, ике күзе яшьләнеп, Аллаһыдан курыкканлыктан тиреләре калтырар булса да, ул шундый агачка охшар ки, ул агачның яфраклары корыр да, аңа җил ирешеп яфраклары коелыр. Пәйгамбәрләр юлы һәм сөннәт хозурында уртача гамәл сөннәткә каршы булган гамәлне тырышып кылудан изгерәктер. Сез гамәл кылган чагыгызда иктисад һәм иҗтиһад хозурында

булса да, пәйгамбәрләр юлы һәм сөннәте хозурында булуын карагыз».

وعن رسول الله ﷺ أنه قال : "افترقت بنو إسرائيل على إحدى وسبعين فرقة ، وإن هذه الأمة ستفترق على اثنتين وسبعين فرقة إحدى وسبعون في النار ، وواحدة في الجنة". قالوا : يا رسول الله نا هذه الواحدة؟ قال : "اهل السنة والجماعة".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Бәни Исраил җитмеш бер төркемгә аерылды. Бу өммәт тә киләчәктә җитмеш ике төркемгә аерылыр. Җитмеш бере утта, җитмеш икедән бер фиркасы җәннәттә булыр». Сәхабәләр әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, ул бер фирка кемнәр алар?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әһлү сөннә вәл-җәмәгат».

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Өммәтемдә фәсәд таралганда, минем сөннәтемә ябышкан кешегә йөз шәһид савабы булыр».

Габдулла бине Мәсгудтән риваять ителде. Ул әйтте: «Әгәр сезне фетнә чолгап алса, ни эшләрсез? Ул фетнәдә олуглар картаер, кечкенәләр үсәр. Кешеләр аны сөннәт итеп алырлар. Әгәр шул сөннәт үзгәртелсә дә, ул сөннәт белән гамәл кылынса, бу мөнкәр, диелер, ягъни аннан эш булмас». Араларыннан берсе әйтте: «Әй Габдулла, бу кайчан булыр?» Габдулла әйтте: «Ышанычлы кешеләрегез азайса, түрәләрегез күбәйсә, факыйһләрегез азайса, кариләрегез күбәйсә. Ахирәт гамәле белән дөнья таләп ителсә. Дин гыйлеменнән башканы гына өйрәнсәләр. Бәс шул вакытта сезнең өстегездә түрәләр булыр. Әгәр ул түрәләргә буйсынсагыз, сезне供 аздырырлар. Әгәр ул түрәләргә каршы булсагыз, сезне үтерерләр». Ул әйтүче әйтте: «Инде

безгә ни кушасың, әй Габдулла?» Габдулла әйтте: «Син өеңнең паласларыңнан бер палас бул, ягъни өеңнән кузгалма, юк исә ут артыграктыр». Риваять итүче әйтте: «Ир култык астына кулын куйды да: «Әй Ибен Умму Габд, син мине үтердең», – диде.

عن عبد الله بن عمرو بم العاص ﷺ قال : خطبنا رسول الله ﷺ فقال : "أيها الناس ، اكرموا أصحابي ، وأحسنوا إليهم ، وأحبوهم ، فإن خير الناس أصحابي الذين بعثت فيهم ، فآمنوا بالله وصدقوني ، وآمنوا بما جئت به من عند الله ، واتبعوه ، وعملوا به ، ثم خير الناس من بعدهم القرن الذين يلونهم ، آمنوا بي ، واتبعوا أمر الله ، ولم يروني ، ثم القرن الذين يلونهم آمنوا بي ، ثم يجئ من بعدهم قرن يضيعون الصلاوات ، ويتبعون الشهوات ، ويدعون ما أمرهم به ويأتون ما نهيتهم عنه ، يقتبسون الدين باهوائهم ، ويراءون الناس باعمالهم ، يحلفون ولا يستحلفون ، ويشهدون ولا يستشهدون ، يؤتمنون فيخونون ، ولا يؤدون الأمانة ، وستحدثون فيكذبون ، ويقولون مالا يفعلون ، يرفع منهم العلم والحلم ، ويظهر فيهم الجهل والفحش ، ويرفع منهم الحياء والأمانة ، وسفشو فيهم الكذب والخيانة ، وعقوق الوالدين وقطيعة الأرحام ، وطول الأمل والبخل ، والحرص على الدنيا ، والشح والحسد ، والبغي وسوء الحلق ، وسوء الجوار ، يمرقون من الدين كما يمرق السهم من الرمية ، ولا تقوم الساعة إلا على شرار الناس فإن سركم أن تسكنوا بحبوحة الجنة ونعيمها ، فالزموا السنة والجماعة ، وإياكم ومحدثات الامور ، فإن كل محدثة بدعة ، وكل بدعة صلالة ، وإن الله لا سجمع أمة محمد على ضلالة أبدا ، فمن خلع

الطاعة ، وفارق الجماعة ، وضيع أمر الله تعالى ، وهالف حكم الله ، لقى تعالى ، وهو عليه غضبان ، وأدخلها النار".

Габдулла бине Гамру бине Гастан риваять ителде. Ул әйтте: «Рәсүлуллаһ безгә хотбә сөйләде. Бәс хөтбәсендә әйтте: «Әй кешеләр! Сәхабәләремне хөрмәтләгез. Аларга яхшылык кылыгыз һәм аларны сөегез. Чөнки кешеләрнең изгерәге сәхабәләремдер. Мин элек аларга җибәрелдем дә, алар Аллаһыга иман китерделәр, мине расладылар. Алар Аллаһы Тәгалә тарафыннан китергән нәрсәләремә иман китерделәр, иярделәр һәм аның белән гамәл кылдылар. Сәхабәләремнән кала изге кешеләр, аларга якын заман эчендә килгән тәбигыйннәрдер. Алар миңа иман китерделәр, Аллаһы Тәгалә боерганына иярделәр, ләкин мине күрә алмадылар. Табигыйннәрдән кала изге адәмнәр – аларга якын заман эчендә иярүчеләр, ягъни табигый табигыйннәр. Алар миңа иман китерерләр. Болардан соң шундый заман килер, намазларны тар кылырлар, нәфес теләкләренә ияреләр. Мин боерган нәрсәләр хакында дәгъвалашырлар, мин тыйган нәрсәләрне кылырлар. Үзләренең нәфес теләкләренә карап, динне сайларлар. Кылган гамәлләре белән кешеләргә рия кылырлар. Ант итәрләр, ләкин хакны өстен чыгарырга башкаларны ант иттермәсләр. Шаһидлык бирерләр, ләкин шаһидлыкны теләмәсләр. Аларга ышанып әманәт куярлар, алар хыянәт кылып, әманәтне үтәмәсләр. Сөйләшсәләр, ялган әйтерләр, кылмаганнарны кылдык диярләр. Алардан гыйлем һәм йомшаклык күтәрелер. Аларда начарлык һәм наданлык барлыкка килер. Алардан аят һәм әманәт күтәрелер. Араларында ялган һәм хыянәт, янә ата-ананы рәнҗетү һәм бертуган кардәшләрдән киселү

күбәер. Дөньяда күп торуны уйлау һәм саранлык, дөньяга бирелү, көнчелек һәм азгынлык таралыр. Начар холык, начар күршелек күбәер. Ук аудан тиз чыккан кебек диннән чыгарлар. Адәмнәрнең явызлыклары хозурына Кыямәт кубар. Әгәр сезне төрле нигъмәтләр хозурында җәннәттә торуыгыз шатландырса, сөннәт һәм җәмәгатькә лязем булыгыз. Үзегезне диндә яңа чыгарылган нәрсәләрдән саклагыз. Чөнки диндә чыгарылган һәр яңа нәрсә бидгатьтер. Һәр бидәгать зәләләттер. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә заләләт белән Мөхәммәд галәйһиссәләм өммәтен бергә җыймас, ягъни азгынлыкта булган кеше Мөһәммәд өммәтеннән саналмас. Кем дә кем Аллаһы Тәгаләгә итагать кылмаса, җәмәгатьтән аерылса, Аллаһы Тәгаләнең боерыгын тар кылса һәм Аллаһы Тәгаләнең хөкеменә карышса, ул Аллаһыга юлыгыр, хәлбуки Аллаһы Тәгалә аңа ачуланган булыр. Дәхи аны утка кертер».

عن العرباض بن سارية السلمي ﷺ قال : وعظنا رسول الله ﷺ نوعظة بليغة ، ذرفت منها العيون ن ووجلت منها القلوب ، فقال رجل من أصحابه : يا رسول الله ، إن هذه موعظة مودع ، فما تعهد إلينا ؟ قال : "أوصيكم بتقوى الله ، والسمع والطاعة ، فإنه من يعش منكم بعدي بر إختلافا كثير ، فإياكم ومحدثات الامور فإنها ضلالة ، فمن أدركته منكم فعليه بسنتي وسنة الخلفاء الراشدين المهديين ، عضوا عليها بالنواجذ".

Гыйрбад бине Сәриядән риваять ителде. Ул әйтте: «Безгә Пәйгамбәр галәйһиссәләм бик тәэсир итә торган бер вәгазь сөйләде. Ул сөйләгәндә күзләрдән яшь ага башлады һәм күңелләр курыкты. Сәхабәләреннән берәү әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, синең бу вәгазең озатучы кешенең вәгазенә охшый.

Безгә ни белән боерасың?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Мин сезгә Аллаһыга тәкъвалык белән, тыңлау һәм буйсыну белән вәсыять кылам. Чөнки сездән берәвегез миннән соң яшәсә, күп ихтиләфләр күрер. Үзегезне диндә яңа чыгарылган нәрсәләрдән саклагыз. Чөнки диндә яңа нәрсәләр – азгынлыктыр. Кем дә кем ул ихтиләфкә ирешсә, аңа минем сөннәтем лязем булсын. Һәм туры юлга күнгән һәм күндерүче хәлифәләр сөннәтен тотсын. Сез ул сөннәткә азау тешләрегез белән ябышыгыз, ягъни һичбер вакыт сөннәттән аерылмагыз».

وروى أبو سعيد الخدري ﷺ عن رسول الله ﷺ أنه قال : "من اكل طيبا ، وعمل بالسنة ، وامن الناس بوائقه دخل الجنة" ، قيل : يا رسول الله ، هذا في الناس كثير . قال : "وسيكون قس قرون بعدي ثم يقل".

Әбү Сәгыйд Худрийдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем хәләлне ашаса, сөннәт белән гамәл кылса, аның бәла һәм мәшәкатьләреннән кешеләр тыныч булса, ул кеше җәннәткә керер». Әйтелде: «Әй Рәсүлуллаһ, мондый кешеләр күп бит». Рәсүлуллаһ әйтте: «Миннән соң булган заманнарда андый кешеләр бик аз булыр».

Габдулла бине Мәсгудтән риваять ителде. Ул әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәләм бер сызык сызып: «Менә бу Аллаһы Тәгаләнең юлыдыр», – диде. Моннан соң уң һәм сул ягына тагы берничә сызык сызды һәм әйтте: «Бу да юллардыр, һәркайсында үзенә өндәүче шайтан бар».

Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән риваять ителде. Ул әйтте: «Һәр нәрсәнең афәте бар, бу диннең афәте нәфес теләкләредер.

Мөҗәһид әйтте: «Аллаһы Тәгаләгә омтылуга ике нигъмәтнең кайсысы олуграк икәнен белмим. Ислам диненә күндерсәме яки Аллаһы Тәгалә мине шул нәфес теләкләреннән сәламәт кылсамы?!»

## Ахирәт өчен кайгыру

Сәбит бине Хаҗҗәҗ Гомәр разыяллаһү ганһүдән риваять итте. Ул әйтте: «Үлчәнгәнче, нәфесләрегезне үлчәп карагыз. Хисап алынганчы нәфесләрегездән хисап алыгыз. Олуг максат өчен зиннәтләнегез. Ул максат – Кыямәт көнедер. Кыямәт көнендә килерсез, ул көндә сездән һич яшерен калмас».

Әбү Зәрр Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән хәдис көдсине риваять итә. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй Минем колларым! Мин золымны Үземә хәрам кылдым. Һәм аны сезнең арагызда да хәрам кылдым. Золым кылмагыз. Әй минем колларым! Сезнең барыгыз да азучыдыр, мәгәр Мин тугры юлга күндерсәм генә күнәрсез. Күнелүне теләгез, Мин сезне туры юлга күндерермен. Әй Минем колларым! Сезнең барыгыз да ачлардыр, мәгәр мин туйдырсам гына тукланырсыз. Бәс Миннән азык сорагыз, Мин сезне туйдырырмын. Әй Минем колларым! Барыгыз да ялангачлардыр, мәгәр Мин киендерсәм генә киенгән булырсыз. Кием сорагыз, Мин сезне киендерермен. Әй Минем колларым! Сез кич һәм көндез гөнаһ кылып торасыз, Мин барча гөнаһларыгызны ярлыкыйм. Миннән ярлыкауны сорагыз, Мин сезне ярлыкармын. Әй Минем колларым! Әгәр сезнең әүвәлгеләрегез һәм ахыргыларыгыз, кешеләрегез һәм җеннәрегез, барысы да иң тәкъва ир кадәр

булсалар да, бу Минем мөлкемә бер нәрсә арттырмый, ягъни Миңа сезнең изге гамәлегездән һич файда юктыр. Әй Минем колларым! Әгәр сезнең әүвәлгеләрегез һәм ахыргыларыгыз, кешеләрегез һәм җеннәрегез, барчасы сездән гөнаһ кылучырак ир кебек булсалар да, бу эш минем милкемнән бер нәрсәне киметмәс, ягъни сез барыгыз да гөнаһ кылсагыз да, Миңа аның зарары тимәс. Әй минем колларым! Әгәр сезнең әүвәлгеләрегез һәм ахыргыларыгыз, кешеләр һәм җеннәр бер пакь урында торсалар һәм һәркайсы үз кирәген сораса һәм Мин һәркайсына сораган нәрсәсен бирсәм, бу Минем каршымда булган нәрсәне һич киметмәс. Мәгәр бер диңгезгә энә батырылса, диңгез ничек кимесә, Минем дә сезгә бирүем шул диңгезгә энә батырып алу кебек кенә булыр. Әй Минем колларым! Мин сезнең кылган гамәлләрегезне бары үзегез өчен генә саныйм, Кыямәт көнендә аларны сезгә үтәрмен. Шулай булгач, әгәр берәү изгелек табса, Аллаһыга хәмед итсен, мин моны үзем кылдым дип уйламасын. Әгәр берәү изгелек тапмый икән, ул һичкемгә рәнҗемәсен, мәгәр үзенә генә рәнҗесен».

وروى أبو سعيد الخدري ﷺ ان النب ﷺ قال : "عودوا المرضى ، واتبعوا الجنائز ن تدكركم الآخرة".

Әбү Сәгыйд Худрий разыяллаһү ганһүдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Авыруларның хәлләрен белергә барыгыз, җеназаларга иярегез. Алар сезгә ахирәтне искә төшерерләр».

Кайбер хәкимнәрдән риваять ителде. Ул хакимнәрнең берсе җеназа артыннан мәеткә рәхмәт теләп баручы кешеләрне күреп әйтте: «Әгәр үзегезгә рәхмәт теләсәгез, яхшырак булыр иде. Әмма ул мәет

үлгән һәм өч куркудан котылган. Беренчесе, үлем фәрештәсен күргән. Икенчесе, үлем ачысын татыган. Өченчесе, актык сулауның куркынычын белгән».

Әйтелде: «Әбү Дәрдә разыяллаһү ганһү җәназа артындагы бер ирнең: «Бу кемнең җәназасы?» – дип сораганын ишетте. Әбү Дәрдә ул кешегә әйтте: «Бу син. Әгәр алай әйткәнне яратмасаң, бу мин буламын». Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ إِنَّكَ مَيِّتٌ وَإِنَّهُم مَّيِّتُونَ ﴾

«Син дә, алар да – мәетләр». (Зүмәр: 30)

Хәсән Басридән риваять ителде. Ул каберләр өстендә ашап тора торган бер ирне күрде һәм әйтте: «Бу кеше монафыйк. Үлем ике күзе арасында, ә аның ашыйсы киләдер».

Хәсән Басридән риваять ителде. Ул әйтте: «Шундый кавемгә бик гаҗәпләнәмен. Алар азык әзерләү белән боерылдылар, моннан теге йортка күчәргә нида кылындылар. Аларның әүвәлгесе соңгысын көтеп утыра. Хәлбуки, алар утырганнар да уйныйлар».

Хәсән Басридән риваять ителде. Әгәр бер мәетне күрсә, анасын күмеп кайткан кебек була иде.

Ибраһим Тәймидән риваять ителде. Ул әйтте: «Берәү иман китерүче булып та, җәннәт әһеленнән булмавыннан куркучы һәм кайгыртучы булмаса, ни файда? Чөнки җәннәт әһеле әйттеләр:

﴿ إِنَّا كُنَّا قَبْلُ فِي أَهْلِنَا مُشْفِقِينَ ﴾

«Без дөньяда әһелебез арасында Аллаһыдан куркып гөнаһлардан саклана идек». (Тур: 26)

Ибне Мәсгудтән риваять ителде. Ул әйтте: «Коръәнне яттан белүче кешегә түбәндә китерелгән нәрсәләр тиешле булыр: кешеләр йоклаган чакта ул кич уяу торуы белән; кешеләр ашаган чакта, ул

көндез ураза тоту белән, кешеләр шатланган чакта кайгыру белән; кешеләр көлгәндә, елау белән; кешеләр тәкәбберләнгәндә, ул түбәнчелекле булуы белән билгеле булыр. Янә Коръәнне яттан белүчегә кайгылы, йомшак күңелле булу, гафил, кычкыручы, тиз ачулы булмау тиешле була».

Шәкыйкъ әйтте: «Кол өчен кайгыру белән куркудан изгерәк юлдаш юк. Үткән гөнаһларына кайгырыр. Киләчәктә аңа ни нәрсә иңәчәген белмәү аны куркытыр».

Хәким әйтте: «Берәү өч нәрсәдән башкага көенсә һәм кайгырса, ул кайгы белән шатлыкны белмәгән кеше булыр. Беренчесе, иман белән үтәрменме, юкмы дип иманны кайгырту. Икенчесе, җиренә җиткерәмме, юкмы дип Аллаһының боерыгын кайгырту. Өченчесе, алардан котылырмынмы, юкмы дип дошманнарны кайгырту».

وروى أنس بن مالك ﷺ عن النبي ﷺ انه قال : "ما اغرورقت عين بمائها إلا حرم الله على النار إحراقها ، فإن فاضت على وجه صاحبها لم يرهق وجهه قتر ولا ذلة ، وما من عمل بر إلا وله ثواب إلا الدمعة ، فإنها تطفئ بحورا من نار ، ولو ان عبدا بكى من خشية الله تعالى في امة لرحم الله تلك الامة لبكاء ذلك العبد".

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Бер күз яшь тулып еласа, Аллаһы Тәгалә ул күзне яндыруны утка хәрам кылыр. Әгәр ул күзнең яше иясенең битенә акса, аның йөзенә зәгыйфьлек һәм хурлык якын булмас. Һәрбер изге гамәл өчен савап бар, мәгәр яшь кенә, ул булса, уттан булган чокырларны сүндерер. Әгәр бер өммәт эчендә берәр кол Аллаһыдан куркып еласа, Аллаһы

Тәгалә шушы колның елавы аркасында өммәткә рәхмәт кылыр».

Кәгъб Әхбәрдән риваять ителде. Ул әйтте: «Бит алмама яшь акканчы Аллаһыдан куркып елавым үзем кебек авырлыкта булган алтынны садака кылуымнаң да сөеклерәк. Берәү күз яшьләреннән бер тамчысы җиргә тамганга кадәр Аллаһыдан куркып елаучы булса, аны күк тамчысы кире кайтарганга кадәр ут тотмас. Хәлбуки, ул күк тамчысы кире кайтачак түгелдер. Күктән яңгыр яуса, ул кире күккә мәңге кайтмый. Шулай ук дөньяда Аллаһыдан куркып елаучыны да, ут мәңге тотмас».

روری عن عبد الله بن مسعود ﷺ ان النبي ﷺ قال : "ما من عبد يخرج من عينه من الدموع مثل الذباب أو راس الذباب من خشية الله تعالى فيصيب حر وجهه فتمسه النا أبدا".

Габдулла бине Мәсгудтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Берәүнең күзеннән Аллаһы Тәгаләдән куркып, черки кадәр яшьләр чыгып, йөзенә ирешсә, ул йөзне ут мәңге яндырмас».

Ибен Габбас әйтте: «Бер күз дә яшь агызмас, мәгәр Аллаһының фазыйләте белән генә. Фәрештә кальбен сыйпаганга кадәр ирнең күзе яшьләнмәс. Ягъни күзенең яшьләнүе фәрештәнең сыйпавы белән булыр».

وروى عن الحسن البصري ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "ما من قطرة أحب إلى الله تعالى من قطرتين : قطرة دمع في سواد الليل ، وقطرة دم في سبيل الله".

Хәсән Басридәр риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгаләгә ике тамчыдан артык һич тамчы юктыр. Беренчесе, караңгы

төндә аккан тамчы. Икенчесе, Аллаһы юлында аккан кан тамчысы».

Зиядтан риваять ителде, ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә кайбер китапларда әйтте: «Миннән куркып кол еламас. Елады исә, Мин аңа ачуымнан киметеп, әҗер бирермен. Янә кол миннән куркып еламас, мәгәр елады исә, җәннәттә шатлыкка әйләндерермен».

Гомәр бине Габделгазиздән риваять ителде. Ул бер кичәне намаз укый иде. Бәс:

﴿ إِذِ الْأَغْلَالُ فِي أَعْنَاقِهِمْ وَالسَّلَاسِلُ يُسْحَبُونَ . فِي الْحَمِيمِ ثُمَّ فِي النَّارِ يُسْجَرُونَ ﴾

«Куллары муеннарына богауланып, аяклары зинҗирләнеп кайнар суга салынсалар, соңра утта яндырылсалар – ул вакытта Аллаһыга каршы сүз әйтә алмаслар», дигән аятьне таң атканчы кат-кат укып, елый иде. (Гафир: 71, 72)

Тәмим Дәридән риваять ителде. Ул:

﴿ أَمْ حَسِبَ الَّذِينَ اجْتَرَحُوا السَّيِّئَاتِ أَنْ نَجْعَلَهُمْ كَالَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ ﴾

«Әллә бозык эшләрне һәм имансызлыкны кәсеп итүчеләр уйлыйлармы, дөреслектә, Без аларны иман китереп изге гамәлләр кылган мөэминнәр белән бертигез хөкем итәрбез, дип» аятен укып таңга кадәр елады. (Җәсийә: 21)

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде. Ул таңга кадәр кат-кат:

﴿ إِنْ تُعَذِّبْهُمْ فَإِنَّهُمْ عِبَادُكَ وَإِنْ تَغْفِرْ لَهُمْ فَإِنَّكَ أَنْتَ الْعَزِيزُ الْحَكِيمُ ﴾

«Әгәр аларны газаб кылсаң – кылырсың, Үз бәндәләреңдер, һәм әгәр аларны ярлыкасаң, әлбәттә, Син көчле һәм гадел хәкимсең» аятен укып елады. (Мәидә: 118)

Хәбәрләрдә килә, Давыд галәйһиссәләм гөнаһ кылганнан соң һич бер эчемлек эчмәде. Мәгәр эчте исә, эчемлекнең яртысы ике күзенең яшьләре белән катыштырылган була иде.

Бәһз бине Хәкимнән риваять ителде, ул әйтте: «Зира бине Әбү Әүфә безнең белән намаз укыды. Ул:

﴿ فَإِذَا نُقِرَ فِي النَّاقُورِ ﴾

«Әгәр Кыямәт өчен сур өрелсә», – дигән аятьне укыды. (Мөдәссир: 8) Бәс без аны үлгән хәлдә күтәреп алып киттек.

## Кешенең «таңга керүе» хакында

Мөҗәһидтән риваять ителде. Габдулла бине Гомәр разыяллаһү ганһү миңа әйтте: «Әй Мөҗәһид, һәркайчан таңга керсәң, үз-үзеңне кич белән алдама, ягьни бу таңда изге гамәл кылмасам да, кич белән кылырмын димә. Әгәр кичкә керсәң, нәфесеңне таң белән алдама. Үлгәнгә кадәр, терек вакытыңда кирәгеңне ал. Авырганнан элек, сау вакытыңда ал. Чөнки син иртәгә исемеңнең ничек булачагын да белмисең».

Хәкимнәрнең кайберләре әйттеләр: «Әгәр ир таңга керсә, аңа дүрт нәрсәне ният кылып керергә кирәк. Беренчесе, Аллаһы Тәгалә аңа фарыз кылган нәрсәне үтәү. Икенчесе, Аллаһы Тәгалә тыйган нәрсәләрдән тыелу. Өченчесе, башкалар белән мөгамәләдә булганда инсафлы булу. Дүртенчесе, үзе белән дошманнар арасын төзәтү. Әгәр шушы ниятләр белән таңга керсә, аның салих һәм котылучылар җөмләсеннән булуына өметләнәм».

Кайбер хәкимнәрдән: «Ир йокысыннан нинди ният белән торырга тиеш?» – дип сорадылар. Әйтте:

«Йоклаганы күренгәнгә кадәр торудан соралмас. Моннан соң торудан соралыр. Берәү ничек йоклаганын белмәсә, ничек торганын белмәс». Моннан соң әйтте: «Колга дүрт нәрсәне төзәтми торып, йокларга тиеш түгел. Беренчесе, җир йөзендә дошманы була торып, аның янына барып бәхиллек сораганчы йокламас. Чөнки үлем фәрештәсе килер дә, аны Раббысы каршына алып китәр. Хәлбуки, аның хәҗәте булмас. Икенчесе, өстендә Аллаһының фарызларыннан бер фарыз кала торып, йокларга ятмас. Өченчесе, үткәндәге гөнаһлардан тәүбә кылмый торып йокларга тиеш түгел. Чөнки ул күп вакытта йоклаган килеш үлә, хәлбуки ул гөнаһысында даим булыр. Дүртенчесе, дөрес васыять язганчы йокларга тиеш түгел. Чөнки ул күп вакытта шул килеш васыятьсез үлеп китәр».

Әйтелде: «Кешеләр өч сыйныф булып таңга керерләр: бер сыйныф мал теләп; икенчесе, гөнаһ теләп; һәм өченчесе, юл эзләп. Мал теләп таңга кергән кеше, малы күп булса да, ул Аллаһы Тәгалә ризыкландырганнан артыкны ашамас. Гөнаһ теләп таңга кергән кешегә хурлык һәм зәгыйфьлек тоташыр. Юл эзләп торган кешегә Аллаһы Тәгалә ризык һәм юл китерер».

Кайбер хәкимнәр әйттеләр: «Таңга кергән кешегә ике төрле эш лязем: тынычлык һәм курку. Тынычлык – ул Аллаһы Тәгалә биргән ризык белән тыныч булу. Курку исә – ул кешенең боерылган нәрсәсен тәмам иткәнче куркучы булуы. Әгәр шушы ике әмерне кылса, Аллаһы Тәгалә аны ике нәрсә белән хөрмәтләр: Аллаһы Тәгалә биргән нәрсәгә канәгать булу һәм Аллаһыга итагать итүнең ләззәтен тою».

Сәгыйд бине Мәсруктан риваять ителде. Ул әйтте: «Һәрвакыт Рабигъ бине Хайсәмнән: «Ничек

таңга кердегез?» – дип сорасалар. Әйтә торган иде: «Загыйфьләр, гөнаһ кылучылар булып таңга кердек. Ризыкларыбызны ашыйбыз, әҗәлләребезне көтәбез».

Мәлик бине Динардан риваять ителде. Аңа әйтелде: «Таңга ничек кердегез?» Ул әйтте: «Бер йорттан икенче йортка күчә торган кеше ничек таңга керә? Хәлбуки, ул җәннәткәме, әллә җәһәннәмгәме баруын белми. Без дә шулай белмичә таңга кердек».

Зекер ителде, Гайсә галәйһиссәләмгә: «Әй Аллаһының рухы, таңга ничек керәсең?» – диделәр. Гайсә галәйһиссәләм әйтте: «Өмет итә торган нәрсәгә ия булмаган һәм курка торган нәрсәне җибәрергә көчем җитмәгән хәлдә таңга кердем. Миннән дә фәкыйрьрәк һичбер факыйрь юк һәм изгелекләр барысы да башка кеше кулында булып, мин кылган гамәлемне закладка салучы булып таңга кердем».

Гамир бине Кайстан: «Таңга ничек кердең?» – дип сорадылар. Ул әйтте: «Нәфесемә гөнаһларым төялгән һәм Аллаһы Тәгалә нигъмәтләреннән төягән хәлдә таңга кердем. Белмим ки, кылган гыйбадәтемме яисә Аллаһының биргән нигъмәтләренә шөкер кылуыммы гөнаһларымнан котылу булыр».

Мөхәммәд бине Сириннән зекер ителде, ул бер кешегә: «Хәлең ничек?» – диде. Кеше әйтте: «Җәмәгате күп булып та, биш йөз дирһәм бурычы булган ирнең хәле ничек булыр, минем дә шулай ук». Ибен Сирин өенә керде дә, мең дирһәм алып чыкты. Аны ул иргә бирде һәм әйтте: «Биш йөз дирһәме белән бурычыңны түлә, биш йөзен әһелеңә тот». Шуннан соң Ибен Сирин берәүдән дә хәлең ничек, дип сорамый иде. Әгәр сораса хәленнән хәбәр бирер дә, аны карау моның өстенә лязем булуыннан куркыр иде.

Ибраһим Бине Әдһәмнән зекер ителде. Ул әйтте: «Кем дә кем таңга керсә, аңа дүрт төрле нәрсәгә шөкер кылу лязем булыр. Беренчесе, шөкер кылып: «Барча мактаулар Аллаһы Тәгаләгә булсын. Ул минем кальбемне һидәят нуры белән нурландырды, мине мөэминнәр җөмләсеннән кылды, азучылар җөмләсеннән кылмады», – дип әйтер. Икенчесе, «Барча мактаулар шундый Аллаһыгадыр, Ул мине Мөхәммәд галәйһиссәләм өмматеннән кылды», – дип шөкер кылыр. Өченчесе, «Барча мактаулар шундый Аллаһыгадыр, Ул минем ризыгымны башка кеше кулында кылмады», – дип әйтер. Дүртенчесе, «Барча мактаулар Аллаһы Тәгаләгәдер. Дөреслектә, Ул минем гаепләремне яшерде».

Шәкыйкъ бине Ибраһимнан китерелде. Ул әйтте: «Бер кеше йөз ел яшәп тә, шушы дүрт нәрсәне белмәсә, аңа уттан тиешлерәк нәрсә юктыр. Беренчесе, Аллаһы Тәгаләне тану. Икенчесе, Аллаһы Тәгаләнең гамәлен тану. Өченчесе, үз-үзен тану. Дүртенчесе, Аллаһының һәм үзенең дошманын танудыр. Аллаһы Тәгаләне тану – Аны яшерен эштә дә, күренгән эштә дә тану. Чөнки ул Аллаһыдан башка бирүче дә, тыючы да юктыр. Аллаһы Тәгаләнең гамәлен тану исә – Аллаһы Тәгалә кылган бер гамәлне дә кабул итми, мәгәр Аллаһы Тәгалә өчен чын күңелдән булганын гына кабул итә, дип тану. Үз-үзен тану – үзенең загыйфьлеген һәм Аллаһы Тәгалә тәкъдир иткән һичбер нәрсәне кайтара алмавын тануыдыр. Ягъни Аллаһы Тәгалә аңа бүлеп биргән нәрсәгә разый булуыдыр. Аллаһының һәм үзенең дошманын тану – дошманны явызлык белән тануы. Аны тану белән аңа җәза бирер, хәтта җиңәр».

Әйтелде: «Адәм улы таңга керде исә, Аллаһы Тәгалә аңа ун нәрсәне фарыз кылыр.

Беренче: Торган чагында Аллаһы Тәгаләне зекер кылуы. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَسَبِّحْ بِحَمْدِ رَبِّكَ حِينَ تَقُومُ ﴾

«Әй Мөхәммәд, торганда Аллаһыга хәмед һәм тәсбих әйт». (Тур: 48)

﴿ يَاأَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اذْكُرُوا اللَّهَ ذِكْرًا كَثِيرًا . وَسَبِّحُوهُ بُكْرَةً وَأَصِيلًا ﴾

«Әй иман китергән бәндәләр! Сез Аллаһыны күп зекер кылу белән зекер кылыгыз һәм көннең әүвәлендә һәм ахырында Аллаһыга тәсбих әйтегез». (Әхзәб: 41, 42)

Икенчесе: ят җирне каплау. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ يَابَنِي آدَمَ خُذُوا زِينَتَكُمْ عِنْدَ كُلِّ مَسْجِدٍ ﴾

«Әй адәм балалары! Һәр сәҗдә вакытында зиннәтегезне алыгыз, ягъни ят җирләрегезне каплагыз». (Әгъраф: 31) Зиннәтнең иң киме ят җирне яшергән кадәр булыр.

Өченчесе: намаз вакытларында тәһарәтне тәгәлләү. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ يَاأَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا قُمْتُمْ إِلَى الصَّلَاةِ فَاغْسِلُوا وُجُوهَكُمْ
وَأَيْدِيَكُمْ إِلَى الْمَرَافِقِ وَامْسَحُوا بِرُءُوسِكُمْ وَأَرْجُلَكُمْ إِلَى الْكَعْبَيْنِ ﴾

«Әй иман китергән бәндәләр! Башларыгызны мәсех кылыгыз һәм аякларыгызны тубыкларга кадәр юыгыз». (Мәидә:6)

Дүртенчесе: вакытлары ирешкәч, намазларны тәгәлләү. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ إِنَّ الصَّلَاةَ كَانَتْ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ كِتَابًا مَوْقُوتًا ﴾

«Дөреслектә, намаз вакыты мөэминнәр өчен билгеләнгән фарыз кылынды, ягъни өскә бурыч булган фарыз һәм вакыты билгеле кылынды». (Ниса: 103)

Бишенчесе: ризык эшендә Аллаһының вәгъдәсе белән тыныч булу. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ نَحْنُ قَسَمْنَا بَيْنَهُمْ مَعِيشَتَهُمْ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا ﴾

«Җир йөзендә булган һәрбер хайванның ризыгы Аллаһы Тәгалә өстендәдер, ягъни һәр хайванга ризык бирүче бер Аллаһыдыр». (Зухруф: 32)

Алтынчысы: Аллаһы Тәгаләнең биргән өлешенә канәгать булу. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ نَحْنُ قَسَمْنَا بَيْنَهُمْ مَعِيشَتَهُمْ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا ﴾

«Без дөнья тереклегендә аларның ризыкларын араларында бүлдек».

Җиденчесе: Аллаһыга тәвәккәл кылу. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَتَوَكَّلْ عَلَى الْحَيِّ الَّذِي لَا يَمُوتُ ﴾

«Һәрвакыт тере, һич үлми торган Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кыл». (Фуркан: 58)

﴿ وَعَلَى اللَّهِ فَتَوَكَّلُوا إِنْ كُنتُمْ مُؤْمِنِينَ ﴾

«Әгәр мөэмин булсагыз, Аллаһыга тәвәккәл кылыгыз». (Мәидә: 23)

Сигезенчесе: Аллаһының әмеренә һәм казасына сабыр итү. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ فَاصْبِرْ لِحُكْمِ رَبِّكَ ﴾

«Әй Мөхәммәд, Раббыңның хөкеменә сабыр кыл». (Каләм: 48)

﴿ يَاأَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اصْبِرُوا وَصَابِرُوا ﴾

«Әй иман китергән бәндәләр! Сабыр кылыгыз һәм мөләзәмәт итегез». (Әли Гыймран: 200)

Тугызынчысы: Аллаһының нигъмәтләренә шөкер итү. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَاشْكُرُوا نِعْمَةَ اللهِ إِنْ كُنْتُمْ إِيَّاهُ تَعْبُدُونَ ﴾

«Әгәр Аллаһыга гыйбадәт кылсагыз, Аның нигъмәтләренә шөкер кылыгыз». (Нәхел: 114)

Нигъмәтнең әүвәлегесе тәннең саулыгы. Нигъмәтнең олуграгы Ислам дине. Аллаһының нигъмәтләре күптер. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَإِنْ تَعُدُّوا نِعْمَةَ اللهِ لَا تُحْصُوهَا ﴾

«Әгәр Аллаһының нигъмәтләрен санасагыз, очына чыга алмассыз». (Нәхел: 18)

Унынчысы: Хәләлдән ашау. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ كُلُوا مِنْ طَيِّبَاتِ مَا رَزَقْنَاكُمْ ﴾

«Без ризыкландырган нәрсәләрнең хәләлләреннән ашагыз». (Бәкара: 57)

## Фикерләү фазыйләте

Гата бине Әбү Рабахтән риваять ителде. Ул әйтте: «Ибен Гомәр, Гобәйд бине Гомәйр белән бергә мин Гайшә разыяллаһү ганһәгә кердем. Без аңа сәлам бирдек. Ул: «Болар кем?» – дип сорады. Алар: «Без Габдулла белән Гобәйд һәм Гобәйд бине Гомәйр», – диделәр. Ул әйтте: «Әй Гобәйд, хуш килдең. Ни булды сиңа безгә бер дә килмисең?» Гобәйд әйтте: «Сирәк килсәң, дуслыкны арттырырсың!» Ибен Гомәр әйтте: «Бу үзебезнең сүзебезне куегыз. Син Рәсүлуллаһтан күргән нәрсәнең гаҗәбрәген сөйлә». Гайшә әйтте: «Ул Рә-

сүлуллаһ галәйһиссәләмнең бөтен эшләре дә гаҗәптер. Мәгәр тагын гаҗәбрәге бар. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм минем янга кичләргә килде. Минем түшәгемә керде, хәтта тиресен минем тиремә тоташтырды һәм әйтте: «Әй Гайшә! Миңа Раббыма гыйбадәт кылырга рөхсәт бирәсеңме?» Мин әйттем: «Аллаһы белән ант итәм, мин Аллаһыга якын булуыңны да, нәфсең теләгәнне дә сөям». Бәс савыт янына килде дә аннан тәһарәт алды. Моннан соң аяк хозурында торып елады, хәтта күз яшьләре култык астыннан биленә чаклы булган җиргә иреште. Аннан соң уң ягына таянды. Уң кулын уң яңагы астына куйды. Елады, хәтта күз яшьләренең җиргә ирешкәнен күрдем. Иртәнге намазга азан әйткәч, Билал килде. Рәсүлуллаһның елаганын күргәч әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, үткәндәге, киләчәктәге гөнаһларның барчасы да ярлыканган була торып, ник елыйсың?» Рәсүлуллаһ әйтте: «Әй Билал! Мин еламасам, шөкер кылучы кол булырмынмы? Ошбу кичәдә Аллаһы Тәгалә бу аятьне иңдерде:

﴿ إِنَّ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافِ اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ لَآيَاتٍ لِأُولِي الْأَلْبَابِ . الَّذِينَ يَذْكُرُونَ اللَّهَ قِيَامًا وَقُعُودًا وَعَلَى جُنُوبِهِمْ وَيَتَفَكَّرُونَ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ رَبَّنَا مَا خَلَقْتَ هَذَا بَاطِلًا سُبْحَانَكَ فَقِنَا عَذَابَ النَّارِ ﴾

«Җир вә күкләр байлыгы – Аллаһы Тәгаләнең байлыгыдыр, һәм Аллаһының һәрнәрсәгә көче җитәдер. Дөреслектә, җир һәм күкләрнең төзелешендә һәм төн белән көннең бер-берсен алмаштыруында акыл ияләренә Аллаһының барлыгына һәм берлегенә ышанырга, әлбәттә, көчле дәлилләр бардыр». (Әли Гыймран: 190, 191) Моннан соң әйтте: «Кем дә кем бу аятьне укып та уйланмаса, ул кешегә ни үкенеч!»

Кайбер хәбәрләрдә килде: «Кем дә кем йолдызларга карап, аларга гаҗәпләнсә, Аллаһының кодрәте хакында уйланса һәм укыса: ربنا هذا بلطلا سبحانك فقنا عذاب النار , «Раббәнә мә халәкътә һәзә бәтыйлән сүбханәкә вә кыйнә газәбәннәр», ул кешегә күктә булган һәр йолдыз санынча изгелек язылыр».

Гамир бине Кайстан риваять ителде. Ул әйтте: «Ахирәттә шатлыгы күп булган кешеләр – дөньяда кайгысы озынрагыдыр. Ахирәттә көлүе күп булган кешеләр – дөньяда елавы күбрәгедер. Кыямәт көнендә иманы белен котылучы кешеләр – дөньяда чагында уйлавы күбрәк булганнарыдыр».

عن أبي درداء ﷺ ان رسول الله ﷺ قال : "إن من الناس ناسا مفاتيح للخير مغاليق للشر ، ولهم بذلك أجر ، وإن من الناس ناسا مفاتيح للشر مغاليق للهير ، وعليهم بذلك إصر" يعني إثم كبير "طوبي لمن جعل مفتاحا للخير ن مغلاقا للشر ، وتفكير ساعة لي خير من قيام ليلة".

Әбү Дәрдәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Адәмнәр җөмләсеннән шундый кешеләр бар, аларның изгелек өчен булган ачкычлары явызлыкны бикләүчеләрдер. Бу гамәлләре бәрабәренә аларга савап бар. Адәмнәр җөмләсеннән шундый кешеләр бар, аларны явызлык өчен булган ачкычлары изгелекне бикләүчеләрдер. Аларга ошбуның бәрабәренә олуг гөнаһ бардыр. Изгелеккә ачкыч булып, явызлыкны бикләгән кешегә ни сөенеч! Минем өчен бер сәгать уйлану бер кич аяк хозурында торудан изгерәктер».

عن عمرو بن مرة أن النبي ﷺ مر بقوم يتفكرون فقال لهم : "تفكروا في الخلق ، ولا تفكروا في الخالق".

Гамрү бине Муррадан риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм уйланып тора торган бер кавемнән үтте. Аларга әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең мәхлуклары хакында уйланыгыз. Әмма Аллаһының Үзе хакында уйланмагыз».

عن أبي هريرة ﷺ عن رسول الله ﷺ انه قال : "إن الشيطان ياتي أحدكم ، فيقول : من خلق السموات ؟ فسقول : الله تعالى ، فيقول : من خلق الأرض ؟ فيقول : الله تعالى فيقول : من خلق الله ؟ فإذا احس احدكم من ذلك شيئا فليقل آمنت بالله وبرسوله".

Һәшим бине Гурвә атасыннан, ул Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән риваять итте. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Шайтан берегез янына килер дә: «Күкләрне кем яратты?» – дип сорар. «Аллаһы Тәгалә яратты», – дияр. «Җирне кем яратты?» – дип сорар. Янә: «Аллаһы Тәгалә яратты», – дип җавап бирер. «Аллаһыны кем яратты?» – дип сорар. Әгәр берегез моннан бер нәрсәне сизсә, әмәнтү билләһи вә рәсүлиһи дип әйтсен».

وروى عن رسول الله ﷺ أنه قال : "تفكر ساعة افضل من عبادة سنة".

Рәсүлуллаһтан риваять ителде. Ул әйтте: «Бер сәгать уйлану бер ел гыйбадәт кылудан изгерәктер».

Фәкыйһ әйтте: «Әгәр кеше фикерләү фазыйләтенә ирешергә теләсә, ул кеше биш төрле нәрсәдә фикерләсен. Беренчесе, аять һәм галәмәт хакында фикерләсен. Икенчесе, нигъмәтләр турында уйлансын. Өченчесе, Аллаһы Тәгаләнең савап бирүендә фикер кылсын. Дүртенчесе, газабы хакында уй-

лансын. Бишенчесе, аңа яхшылык кылуында һәм җәфа кылуы хакында фикерләсен».

Әмма аять һәм галәмәт турында уйлау – күкләрне һәм җирне яратуында Аллаһы Тәгаләнең кодрәтенә карау. Кич белән көндезнең алмашуына, үзенең яратылуын карап, Аллаһының кодрәте хакында фикер кылу. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿وَفِي الْأَرْضِ آيَاتٌ لِلْمُوقِنِينَ . وَفِي أَنفُسِكُمْ أَفَلَا تُبْصِرُونَ﴾ .

«Белергә теләүчеләргә җирдә галәмәтләр бардыр. Янә үзегезнең яратылышыгызда да галәмәтләр бардыр. Әллә шуларны күрмисезме?» (Зәрият: 20, 21)

Әгәр бәндә аят һәм галәмәт хакында уйланса, аның белән якыйнын һәм Аллаһыны тануын арттырыр. Әмма нигъмәтләр хакында уйлану: Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләренә караудыр.

Кайбер хәкимнәрдән «әлә» белән «нигъмә» сүзләре арасындагы аерма турында сорадылар. Әйтте: «Нигъмәтләрдән күренеп торганы «әлә», яшерен булганнары «нигъмә»дер. Моның охшашы: ике кул «әлә», ике кулның кувәте «нигъмә»; йөз «әлә», йөзнең күркәмлеге һәм чибәрлеге «нигъмә»; авыз «әлә», ашамлыкның тәмен тату «нигъмә»; ике аяк «әлә», аның белән йөрү «нигъмә». Бер кешегә ике аяк булып та, йөрергә куәте булмаса, менә ул кешегә «әлә» бирелде, әмма «нигъмә» бирелмәде. Тамыр, сөякләр «әлә» аларның саулыгы «нигъмә». Кайберләр әйтте: «Әлә» нигъмәткә ирешү, «нигъмә» бәлаләрнең китүе». Кайберләре моның киресен әйттеләр. Кайберләр: «Әлә» һәм «нигъмә» икесе дә бер. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿نْ تَعُدُّوا نِعْمَةَ اللَّهِ لَا تُحْصُوهَا﴾

«Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләрен санасагыз очына чыга алмассыз». (Ибраһим: 34) Аллаһы Тәгалә «әлә» белән «нигъмә»не аерым әйтмәде».

Әгәр кеше әлә белән нигъмәт турында уйланса, Аллаһыга мәхәббәте артыр. Әмма Аллаһының савабы бирелүе турында уйлану, Аллаһы Тәгаләнең вәлиләренә җәннәттә төрле хөрмәтләрдән санаган нәрсә хакында уйланудыр. Бу хакта уйлау савапка кызыгуны, аны теләүне һәм Раббысына итагать кылуда куәтне арттырадыр. Әмма Аллаһының газабы турында уйлану, Аллаһы Тәгаләнең дошманнарына тәмугта хурлык, газап һәм зәгыйфьлектән санаган нәрсәләре хакына уйланудыр. Шулар турында уйлау аңа куркуны арттырыр һәм гөнаһлардан тыелуга куәт бирер. Әмма Аллаһы Тәгаләнең аңа кылган яхшылыклары турында уйлану, Аллаһының яхшылык кылуы хакында уйланудыр. Ул яхшылыклар: аның гөнаһларын яшерде, аның бәрабәренә газап кылмады һәм тәүбә кылырга чакырды. Үзенең җәфасы хакында карау. Ничек ул Аллаһының боерыкларын ташлады һәм гөнаһларга керде. Моның хакында уйлану оялуны арттырыр. Әгәр шушы биш нәрсәләр хакында уйланса, ул кеше шундый кешеләр җөмләсеннән булыр, алар хакында Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Бер сәгать уйлану бер ел гыйбадәт кылудан да изгерәктер. Болардан башкаларда уйланмас. Чөнки болардан башкаларда уйлану – вәсвәсәдер».

Хәкимнәрнең кайберләре әйтте: «Өч нәрсә хакында уйланма. Ярлылык хакында уйланма, кайгыңны күбәйтер, комсызлыгыңны арттырыр. Золым кылган кешенең золымы хакында уйлама, күңелеңне борчыр, нәфрәтеңне арттырыр, ачуыңны даим кылыр. Дөньяда озак торуыңны уйлама, мал җыюны сөйдерер, гомерне әрәм итәр, изге гамәл кылуны соңга калдырыр».

Әйтелде: «Чын тәкъвалык – кешенең күңеле белән үзенә файда бирми торган нәрсәләр хакында уйланмаска гаһед бирүедер. Үзенә файда бирми торган нәрсәгә күңел киткән саен, үзенә файда бирә торган нәсәгә кайтарганга чаклы аңа чара эзләр. Бу сугышның катырагы, артыграк һәм иясе өчен шөгыльлерәктер. Кем дә кем намаздан башка чакта моны эшләмәсә, намаз эчендә дә моңа ия булмаска якын булыр».

Кайбер хәкимнәр әйтте: «Гыйбадәтнең тәмамы ниятнең дөреслегендә. Гамәлнең төзеклегенең тәмамы түбәнчелекле булудадыр. Бу икесенең тәмамы дөньядан бизүчелектәдер. Боларның барсының да тәмамы ахирәт эшендә кайгыру һәм көенү беләндер. Кайгыру һәм көенүнең тәмамы үлемне искә төшерүдә күңеленә ябышу һәм гөнаһлар хакында күп уйлану».

Әйтелде: «Тәннәрнең әхлагы ун төрле нәрсәдер: күкрәкләрнең саулыгы, мал юмартлыгы, телнең дөреслеге, нәфеснең түбәнчелекле булуы, катылыкта чыдамлык, аулакта елау, халыкка үгет, мөэминнәргә рәхмәт кылу, фанилык турында уйлау, әйберләрдән гыйбрәт алу».

Мәхкүл әйтте: «Кем дә кем түшәгенә килсә, бу көнендә эшләгән нәрсәсе хакында уйланырга тиешле. Әгәр ул көндә изгелек эшләгән булса, аның өчен Аллаһы Тәгаләгә хәмед әйтер. Әгәр гөнаһ эшләгән булса, Аллаһыдан ярлыкау сорар. Тиз көннән ул гөнаһысыннан кайтыр. Әгәр эшләмәсә, ул исәпләми сарыф кыла торган сатучы кебек булыр, хәтта банкрот булганын үзе дә сизмичә каладыр».

Кайбер хәкимнәр әйттеләр: «Хикмәт дүрт төрле нәрсәдән кузгаладыр. Әүвәлгесе, дөнья мәшәкатьләреннән бушаган тән. Икенчесе, дөнья ризыгыннан буш булган корсак. Өченчесе, дөнья малыннан буш булган кул. Һәм дүртенчесе, дөньяның ахыры

хакында уйлану, ягъни, ул эшнең ахыры ничек булуын уйлау. Чөнки ул ахыры ничек булачагын һәм аның кылган гамәлләре кабул кылынамы, юкмы икәнен белми. Аллаһы Тәгалә гамәлләрнең бары яхшыларын гына кабул кыладыр».

Фәкыйһ әйте: «Галимнәр булган бер төркем халыктан ишеттем. Алар хәдисне Халид бине Мигъданнән риваять иттеләр. Халид әйтте: «Мөгазгә әйттем: «Рәсүлуллаһтан ишетеп саклаган һәм сөйләгән көннән алып һәм көндә исеңә төшерә торганың бер хәдисне миңа сөйләче». Бәс хәзрәт елады, хәтта мин инде туктамас, дидем. Соңыннан әйтте: «Атам, анам сиңа фида булсын, Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм атта булып, мин артына атланган идем: «Әй Рәсүлуллаһ, сөйләче», – дидем. Күзен күккә күтәрде дә әйтте: «Әлхәмдү лилләһил-ләзии йәкъдый фии халкыйһи бимәә әхәббү». Моннан соң әйтте: «Әй Мөгаз». Мин әйттем: «Әй Аллаһының илчесе, боерыгыз, изгелек имамы, рәхмәт пәйгамбәре». Рәсүлуллаһ: «Мин сиңа бер хәдис сөйлим. Ул хәдисне бер пәйгамбәр дә өммәтенә сөйләмәде. Әгәр аны сакласаң, сиңа файда бирер. Әгәр ишетеп тә сакламасаң, Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә каршында хаҗәтең киселер», – диде. Моннан соң әйтте: «Аллаһы Тәгалә җирне күкләрне яратудан элек җиде фәрештә яратты. Һәрбер күк өчен фәрештә бар. Аннан һәр ишеккә шул фәрештәләрдән бер сакчы куйды. Сакчы фәрештәләр колның таңга кергәннән алып кичкә кергәнче кылган гамәлләрен язарлар. Соңынан күтәрелер, кояш нуры кебек нурлы булыр. Хәтта ул дөнья күгенә ирешсә, аны пакьләр һәм күбәйтер. Фәрештә әйтер: «Тукта, шушы гамәл белән иясенең йөзенә ор. Аллаһы Тәгалә сине ярлыкамады, дип әйт. Мин гайбәт

сахибе, ул кол мөселманнарны гайбәт кылды, мин аның гамәлен миннән башка фәрештәгә үтәргә куймым». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Сакчы фәрештә колның гамәле белән тагын ашар, аның нуры һәм яктырта торган яктылыгы булыр. Ул колның гамәле белән икенче кат күккә җитәр. Андагы фәрештә әйтер: «Тукта, шушы гамәле белән иясенең йөзенә сук. Аңа, Аллаһы сине ярлыкамады, дип әйт. Ул кол бу гамәле белән дөнья максатын теләде. Мин дөнья гамәленең иясемен, аның гамәлен миннән башка фәрештәгә үтәргә куймыймын». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Колның укыган күп намазы, садакасы белән сакчы фәрештә янә ашар, аның кылган гамәленә гаҗәпләнеп өченче кат күккә җитәр. Андагы фәрештә: «Тукта, шушы гамәле белән иясенең йөзенә өр. Аңа, Аллаһы Тәгалә сине ярлыкамады, дип әйт. Мин тәкәбберлек сахибе, ул кол гамәл кылды, ләкин мәҗлесс ләрендәге кешеләргә тәкәбберлек кылды. Аллаһы Тәгалә аның гамәлен миннән башка фәрештәгә үткәрмәскә боерды», – дип әйтер. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Сакчы фәрештәсе ураза һәм тәсбихтән гыйбарәт булган колның гамәле белән йолдыз ялтыраган кебек ялтырап тагын күтәрелер. Аны дүртенче кат күккә илтәр. Андагы фәрештә әйтер: «Тукта, шушы гамәле белән иясенең йөзенә өр. Аңа, Аллаһы Тәгалә сине ярлыкамады, дип әйт. Мин үз-үзенә исе китүченең фәрештәсемен, ул үз-үзенә сокланып, гамәл кылды. Раббым миңа аның гамәлен миннән башка фәрештәдән уздыртмаска боерды». Сакчы фәрештә гамәл белән колның йөзенә сугар һәм өч көн ләгънәт укыр». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Сакчы фәрештә башка фәрештәләр белән, иренә тапшырылган килен кебек, ирнең гамәлен алып тагын

күккә күтәрелер. Аның сугыш һәм ике фарыз арасында укыган намазлары белән бишенче кат күккә җитәр. Андагы фәрештә әйтер: «Тукта, шушы гамәле белән аның йөзенә ор һәм муенына йөклә. Өйрәнә торган кешегә һәм Аллаһы өчен гамәл кылучыга хөсед кылды, аларның арасына төште». Сакчы фәрештә ул кешенең гамәлен аның муенына йөкләр, ул яшәгән арада аңа ләгънәт укыр». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Сакчы фәрештәсе колның күп намазлары, кич каим булуы һәм камил тәһарәтләреннән булган гыйбадәтләр белән янә күккә күтәрелер. Аны алтынчы кат күккә илтер. Андагы фәрештә әйтер: «Тукта, шушы гамәле белән иясенә ор. Мин рәхмәт иясенең фәрештәсемен. Синең сахибең берәүгә гөнаһ яки зарар ирешсә, шатлана, аңа рәхимле булмый. Раббым миңа аның гамәлен башка фәрештәгә уздырмаска боерды». Сакчы фәрештә тугрылык, тырышлык, тәкъвалыктан гыйбарәт, яшен ялтыравы кебек ялтыраган колның гамәле белән янә күтәрелер. Аны җиденче кат күккә илтер. Андагы фәрештә әйтер: «Тукта, шушы гамәлең белән иясенең йөзенә сук һәм кальбен йозакла. Мин хиҗәб фәрештәсе. Һәр гамәлен яшерде, ләкин Аллаһы Тәгаләдән яшермәде. Ул аның белән дәрәҗәне, мәҗлесләрдә сөйләнүне, колларда атаклы булуны теләде. Раббым миңа аның гамәлен үземнән башкага уздырмаска боерды». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Сакчы фәрештә күркәм холыктан, тик тору һәм күп зекердән гыйбарәт булган гамәле белән шатланып, тагын күтәрелер. Күк фәрештәләре аны Гареш астына озата барырлар. Аның өчен шаһидлык бирерләр. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Сез минем колымның гамәленә сакчыларсыз. Мин үзендә булган нәрсәсенә юлдашмын. Ул бу

гамәле белән Минем ризалыгымны теләмәде, Миннән башканы теләде. Аңа Минем ләгънәтем булсын». Фәрештәләр барсы да: «Аңа Синең дә, безнең дә ләгънәтебез булсын», – диярләр. Күк әһеле: «Аның хозурына Аллаһы Тәгаләнең ләгънәте, җиде кат күкнең, җирләрнең һәм безнең ләгънәтебез булсын», – диярләр». Хәзрәти Мөгаз моны ишетеп, елады. «Әй Аллаһы Тәгаләнең илчесе, мин ни эшлим», – дидем. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әй Мөгаз, син Пәйгамбәргә ияр, сиңа якыйн лязем булсын. Әгәр синең гамәлеңдә кимчелек булса, телеңне кардәшләреңнән кис, гөнаһың үзеңә генә булсын, аны кардәшләреңә йөкләмә. Кардәшләреңне хурлап, үзеңне генә пакьләмә. Кардәшләреңне төшереп, үзеңне генә күтәрмә. Кылган гамәлеңне кешеләргә күрсәтү өчен кылма».

## Кыямәт көненең галәмәтләре

عن حضيفة بن اليمان ﷺ قال ك جاء رجل إلى النبي ﷺ فقال : يا رسول الله متى الساعة ؟ قال : ما مسؤول عنها بأعلم من السائل ، ولكن لها اشراط : تقارب الاسواق يعني كسادها ومطر ولا نبات ، وتفشوا العينة ، يعني أكل الربا ، وتظهر أولاد البيغة ، يعني أولاد الزنا ، ويعظم رب الال ، وبلوا أصوات الفسقة في المسجد ، ويظهر أهل المنكر على اهل الحق" ، قال : وكيف تامرني يا رسول الله ؟ قال ﷺ : "فر بدينك ، أو كن حلسا من أحلاس بيتك".

Хөзәйфә бине Ямәнидән риваять ителде. Бер ир Рәсүлуллаһка килеп: «Әй Рәсүлуллаһ! Кыямәт көне кайчан булачак?» – диде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Кыямәт турында соралган кеше сораучы кешедән белүчерәк түгел. Алай булса да, ул

Кыяматнең галәмәтләре бар. Базарлар очсызланыр, яңгыр булыр, үлән булмас, риба ашау фаш булыр, зинадан туган балалар күбәер, маллы кеше хөрмәтле булыр, мәчетләрдә бозыкларның тавышлары күтәрелер, хак әһеленә көрәшүчеләр күбәер». Ул ир әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, миңа ничек боерасың?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Динең белән кач, яки өеңнең паласларыннан бер палас бул, ягъни өеңнән кузгалма».

عن ابن أبي عيسى الاصفهاني رفعه قسل : يا رسول الله ، متى الساعة ؟ قال : " ما مسؤول عنها بأعلم من السائل ، ولكن أشراط الساعة عشرة : يقرب فيها الماحل ،" ويظهر فيها الفاجر ، ويعجز فيها المنصف ، تكون الصلاة منا ، والزكاة مغرما ، والأمانات مغنما ، واستطالة القراء وعند ذلك تكون إمارة الصبيان ، وسلطان النساء ومشورة الإماء".

Ибен Әбү Гайсә Әсфәханидән риваять ителде. Рәсүлуллаһка әйтелде: «Әй Рәсүлуллаһ, Кыямәт көне кайчан булыр?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Кыямәт турында соралган кеше сораучы кешедән белүчерәк түгел. Алай булса да, Кыямәт көненең галәмәтләре тугыздыр: хәйләкәр кеше якын ителер; гөнаһкәр кеше заһир булыр; инсаф кылучы кеше гаҗиз булыр; намаз загыйфь булыр; зәкәт өскә бурыч кына булып калыр, үтәлмәс; сакларга куелган нәрсә ганимәт ителер; гыйбадәт кылучылар урынсыз, озын калырлар; балалар түрә булырлар; хатыннар солтан, кәнизәкләргә киңәш ителер».

عن عمرو قال : جاس إلى مروان ثلاثة نفر بالمدينة فسمعوه يحدث عن الآيات ، أولها : خروج الدجال ، فقام النفر من عند مروان ، فجلسوا إلى عبد الله

بن عمر ، فحدثوه بما قال مروان ن فقال عبد الله : سمعت رسول الله ﷺ يقول : "إن أول الآيات خروجا طلوع الشمس من مغربها ، أو الدابة إحداهما قريبة على اصر الأخرى".

Гамрудән риваять ителде. Ул әйтте: «Мәрвәнгә Мәдинәдән өч төркем халык килде. Алар Мәрвәннең Кыямәт көне галәмәтләре турында сөйләгәнен тыңладылар. Ул: «Кыямәт көненең беренче галәмәте Дәҗҗалның чыгуы», – дип әйтте. Мәрвән яныннан бер төркем халык торып, Габдулла бине Гомәргә утырдылар. Аңа Мәрвән әйткәнен сөйләделәр. Габдулла разыяллаһү ганһү әйтте: Пәйгамбәр галәйһиссәләмнең әйткәнен ишеттем: «Кыямәт көненең беренче галәмәте кояшның мәгърибтән туачагы. Яки дәббәтүл-ард чыгар, боларның берсе икенчесенә якын булыр». Моннан соң сөйләргә керешеп, әйтте: «Һәркайчан кояш батса, Гареш астына килеп, сәҗдә кылыр. Кайтырга рөхсәт сорар. Аллаһы Тәгалә кояшның мәгъриб тарафыннан тууын теләгәнчегә кадәр аңа рөхсәт бирелер. Мәгъриб тарафыннан туу вакыты ирешкәч, Гареш астына килер сәҗдә кылыр, кайтырга рөхсәт сорар. Аңа рөхсәт бирелмәс. Тагын кайтыр да рөхсәт сорар, рөхсәт бирелмәс. Хәтта рөхсәт бирелеп тә, мәшрикъкә барып җитә алмавын белгәненә кадәр рөхсәт сорар. Әйтер: «Әй Раббым, адәмнәрдән мине ни-нәрсә ерак кылды?» Әгәр кич муенса кебек булса, рөхсәт сорарга килер. Аңа әйтелер: «Үз урыныңнан ту». Моннан соң Габдулла укыды:

﴿ يَوْمَ يَأْتِي بَعْضُ آيَاتِ رَبِّكَ لَا يَنفَعُ نَفْسًا إِيمَانُهَا لَمْ تَكُنْ آمَنَتْ مِن قَبْلُ أَوْ كَسَبَتْ فِي إِيمَانِهَا خَيْرًا قُلِ انتَظِرُوا إِنَّا مُنتَظِرُونَ ﴾

«Раббыңның кайбер галәмәтләре килер. Ул көннән әүвәл иман китермәгән булса, яки иманлы булып та, изгелек кылмаган булса, ул көндә кылган изгелеге һич нәфескә файда бирмәс. Әйт: көтегез, без көтүчеләрбез». (Әнгам: 158)

وعن عبيد بن عمير ان النبي ﷺ قال : "ليصبحن الدجال أقوام يقولون غنا نعلم أنه كاذب ، ولكنا نصحبه لنأكل من الطعام ، ونرعى من الشجر ، فإذا نزل غضب الله نزل فيهم كلهم".

Гобәйдтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Дәҗҗалга шундый кавемнәр юлдаш булырлар, алар әйтерләр: «Ул Дәҗҗалның ялганчы икәнен беләбез, бары тик ризыктан ашар һәм агачтан файдаланыр өчен генә аңа юлдаш булабыз». Шул вакытта аларның барчасына Аллаһы Тәгаләнең газабы иңәр».

عن سمرة بن جندب ان النبي ﷺ قال : "إن الدجال خارج وهو اعور عين الشمال ، وإنه يبرئ الأكمه والأبرص ، ويحيى الموتى ، فيقول للناس : أنا ربكم ، فمن قال : انت ربي فقد فتن ، ومن قال : ربي الله حتى يموت على ذلك فقد عصم من فتنته فيلبث في الأرض ما شاء الله أن يلبث ، ثم يجيء عيسى بن مريم عليه السلام من قبل المغرب مصدقا بمحمد ﷺ فيقتل الدجال ، ثم قال : إنما هي قسام الساعة".

Сәмра бине Җүндәбтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Дәҗҗал чыгачак. Аның күзе сукыр булыр. Ул анадан туума сукырларны, ала тәнлеләрне төзәтер, үлекләрне тергезер. Кешеләргә: «Мин сезнең Раббыгыз», – дип әйтер. Кем дә кем аңа «син минем Раббым» дисә, тәхкыйк, һәлак булыр. Кем дә кем «минем Раб-

бым Аллаһы» дип әйтсә һәм шул хәлдә үлсә, Дәҗҗалның фетнәсеннән котылыр. Ул җир йөзендә Аллаһы Тәгалә теләгән вакыткача торыр. Моннан соң кояш баешы ягыннан Гайсә бине Мәрьям килер, ул Мөхәммәд галәйһиссәләмне раслар һәм Дәҗҗалны үтерер». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Менә бу Кыяматнең каим булуы булыр».

Габдулла бине Гомәрдән риваять ителде. Ул әйтте: «Бер савытка үзләре белән торып кәфере һәм мөэмине җыелганга кадәр Кыямәт торгызылмас». Әйтелде: «Бу ничек була?» Әйтте: «Дәббәтүл-әрд чыгар да, һәр кешене мәчетенә кертер. Әмма мөэмин булса, ак нокта булыр. Ул мөэминнең йөзен каплап агартыр. Әмма кәфер булса, кара нокта булыр. Ул кәфернең йөзен каплап каралтыр. Хәтта базарларында сату кылырлар. «Моны ничек сатасың, әй мөэмин, моны ничек аласың, әй кәфер», – дип әйтерләр. Кайберәүләр кайберәүләренә кайтармас».

Ибен Габбастан риваять ителде. Ул әйтте: «Дәббәтүл-ард мамыклы һәм канатлы булыр, аның дүрт аягы булыр, ул Тәһәмә болыннарының кайберәүләреннән чыгар».

Ибен Гомәр Аллаһы Тәгаләнең:

﴿ وَإِذَا وَقَعَ الْقَوْلُ عَلَيْهِمْ أَخْرَجْنَا لَهُمْ دَابَّةً مِنَ الْأَرْضِ تُكَلِّمُهُمْ أَنَّ النَّاسَ كَانُوا بِآيَاتِنَا لَا يُوقِنُونَ ﴾

аятенең тәфсирендә әйтте: «Алар яхшылыкка өндәрләр һәм начар эшләрдән тыярлар».

وروى أبو هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "لا تقوم الساعة حتى تطلع الشمس من مغربها ، فإذا طلعت من مغربها آمن الناس كلهم أجمعون ، ويومئذ ﴿ لَا يَنفَعُ نَفْسًا إِيمَانُهَا لَمْ تَكُنْ آمَنَتْ مِنْ قَبْلُ أَوْ كَسَبَتْ فِي إِيمَانِهَا خَيْرًا ﴾"

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кояш мәгърибтарафыннан туганчы Кыямәт көне булмас. Әгәр кояш мәгъриб тарафыннан туса, кешеләрнең барчасы да иман китерерләр. Ләкин ул көндә, әгәр алдан иман китермәгән булсалар яки иманлы булып та, изгелек кәсеп иткән булмасалар, һичбер җанга иманнары файда бирмәс». (Әнгам: 158)

وعن أبي أوفى ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "ستأتي عليكم ليلة مثل ثلاث ليال من لياليكم هذه ، فإذا كانت تلك الليلة عرفها المتهجدون ، فيقوم الرجل ، فيقرأ ورده ن ثم ينام ، ثم يقوم فيقرأ ورده ن ثم ينام ، ثم يقوم فيقرأ ورده فبينما هم كذلك غذ ماج الناس بعضهم في بعض ، فيقولون : ما هذا ؟ فيفزعون إلى المساجد ، فإذا هم بالشمس قد طلعت من مغربها ، فتجيء حتى إذا توسطت السماء رجعت فطاعت من مشرقها ، فذلك قوله تعالى : ﴿ يَوْمَ يَأْتِي بَعْضُ آيَاتِ رَبِّكَ ﴾"

Әбү Әүфәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Сезгә хәзерге кичләрегезнең өч кичәсе кебек бер ҝич килер. Әгәр ошбу кич булса, аны мөҗтәһидләр белерләр. Ир торып да, гыйбадәт кылып, яңадан йоклар, янә торып, гыйбадәт кылыр, тагын йоклар, тагын торыр да, гыйбадәт кылыр. Ул гыйбадәтләр белән шөгыльләнгән арада кешеләр бер-берсенә килерләр дә, бу нинди эш, диярләр. Бәс алар мәчетләргә сыеныралар. Шул чакта кояш та мәгъриб тарафыннан туган булыр. Күкнең уртасына кадәр килер дә, кайтып мәшрикъ тарафыннан чыгар. Бу, Аллаһы Тәгаләнең: ﴿ يَوْمَ يَأْتِي بَعْضُ آيَاتِ رَبِّكَ ﴾ «Ул

көндә Раббыңның кайбер аятьләре күренер», дигән сүзенең мәгънәседер».

وعن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "الأنبياء إخوة لعلات أمهاتهم شتى ، ودينهم واحد ، وأنا أولاهم بعيسى بن مريم ، إنه لم يكن بيني وبينه نبي ، وإنه خليفتي في أمتي ، وإنه نازل ، فيقتل الخنزير ، ويكسر الصليب ، ويضع الجزية ، وتضع الحرب أوزارهم ، فيملأ الأرض قسطا وعدلا ، كما ملئت جورا وظلما ، حتى يرعى الاسد مع الإبل ، والنمر مع البقر ، والذئب مع الغنم ، وحتى يلعب الصبيان بالحيات".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Пәйгамбәрләр ата бертуган кардәшләр. Аналары төрле-төрле, диннәре бердер. Гайсә бине Мәрьям белән мин аларның әүвәлләредер. Аның белән минем арада пәйгамбәр булмады. Ул минем өммәтемдә халифемдер. Ул иңәр дә дуңгызларны үтерер, җизьяне куяр һәм сугышны кораллары белән куяр. Җәбер, золым белән тутырылган кебек, җиргә тугрылык һәм тигезлек тутырыр. Хәтта арыслан дөя белән, каплан сыер белән, бүре куй белән ашар, балалар еланнар белән уйнар».

Габдулла бине Гомәрдән риваять ителде. Ул әйтте: «Гайсә галәйһиссәләм иңәр дә, Дәҗҗал аны күреп, май эрегән кебек эрер. Ул Дәҗҗалны үтерер. Аннан яһүдләр аерылыр, алар да үтерелер, хәтта таш та: «Әй Аллаһының мөселман бәндәсе, менә монда яһүд яшеренгән. Кил, аны үтер», – дияр.

وعن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "إن يأجوج ومأجوج يحفرون الردم كل يوم ، حتى إذا كادوا أن يروا شعاع الشمس قال الذي عليهم :

ارجعوا ، فستفحرونه غدا ، فيعيده الله كما كان ، حتى إذا بلغت مدهم حفروا ، حتى إذا كادوا يرون شعاع الشمس ، قال الذي عليهم : ارجعوا ، فستحفرونه غدا إن شاء الله ، فيعودون إليه وهو كهيئته التي تركزها بالأمس ، فيحفرونه ، فيخرجون على الناس فينشفون المياه ن ويتحصن الناس في بيوهم منهم ، فيبعث الله عليهم نغما في أعناقهم ، فيهلكهم الله بها".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗ һәр көн киртәне казырлар. Кояшның шәүләсен күрергә якынлашкач, башлыклары: «Кайтыгыз, иртәгә казып бетерерсез», – диярләр. Аллаһы Тәгалә аны булган хәлгә кайтарыр, хәтта икенче көнне казыганда, кояшның шәүләсен күрергә якынлашса, башлыклары: «Кайтыгыз, иншәәллаһ, иртәгә казып бетерерсез», – дип әйтерләр. Икенче көнне киртә янына килгәч, аны кичен калдырган хәлендә табарлар. Адәмнәр өстенә чыгарлар да, суларын эчәрләр. Адәмнәр курыкканнарына шатланырлар. Аллаһы Тәгалә аларның муеннарына кортлар җибәрер. Алар шул корттан һәлак булырлар».

Әбү Сәгыйд разыяллаһү ганһүдән риваять ителде, ул әйтте: «Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗ соңында Аллаһының өе хаҗ кылыныр һәм агачлар утыртылыр».

Габдулла бине Сәламнән риваять ителде. Ул әйтте: «Үзе өчен мең яки артыграк бала калдырмыйча Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗдән берсе дә үлмәс».

وعن الحسن البصري ﷺ ،أنه قال : بلغني أن النبي ﷺ قال : "إن بين يدي الساعة فتنا كقطع الليل المظلم ، يموت فيها قلب الرجل كما يموت بدنه ، ويصبح الرجل فيها مؤمنا ، ويمسي كافرا ، ويمسي مؤمنا ويصبح كافرا يبيع فيها أقوام دبنهم بعرض من الدنيا قليل".

Хәсән Басридән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Кыямәт көне алдыннан караңгы кичнең кисәкләре шикелле фетнәләр кубар. Анда кешенең тәне үлгән кебек кальбе дә үләр. Ул вакытта ир таңга мөэмин булып, кичкә исә кәфер булып керер. Һәм кичкә мөэмин булып, таңга кәфер булып керер. Ул вакытта күп кешеләр, аз гына дөнья максаты өчен, диннәрен сатарлар».

عن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه قال : "بادروا بالأعمال قبل أن تظهر أشراط ست : طلوع الشمس من مغربها ، والدجال ، والدخان ، والدابة ، وخاصة أحدكم يعني الموت وأمر العامة يعني يوم القيامة".

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Алты нәрсә пәйда булганчы изге гамәл кылырга ашыгыгыз: кояшның батышы ягыннан тууы; Дәҗҗалның чыгуы; духан; дәббәтуардның чыгуы; үлем һәм Кыямәт көне».

وعن عبد الرحمن بن سابط أن النبي ﷺ قال : "إنه سيكون فيكم الخسف ، والنسخ ، والقذف" ن قالوا : يا رسول الله وهم يشهدون أن لا إله إلا الله قال : "نعم ، إذا ظهرت فيهم الأربع : القينات ، والمعازف ، والخمور ، والحرير".

Габдулла бине Сәбаттан риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Тиз арада сездә хөсеф, мәсех, казеф заһир булыр». Сәхабәләр әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, алар соң «ләә иләәһә илләәллаһ» дип шәһадәт бирерләрме?» Рәсүлуллаһ әйтте: «Әйе, әгәр аларда дүрт нәрсә заһир булса: кәнизәкләр, уен кораллары, исерткечләр һәм ефәк».

Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ قُلْ هُوَ الْقَادِرُ عَلَى أَنْ يَبْعَثَ عَلَيْكُمْ عَذَابًا مِنْ فَوْقِكُمْ أَوْ مِن

﴿تَحْتِ أَرْجُلِكُمْ أَوْ يَلْبِسَكُمْ شِيَعًا وَيُذِيقَ بَعْضَكُمْ بَأْسَ بَعْضٍ﴾

«Әйт: "Өстегездән һәм аяк астыгыздан сезгә газаб җибәрергә яки сезгә азгын халыкны аралаштырырга Аллаһы Тәгалә, әлбәттә, кадир", – дип» (Әнгам: 65)

Мәсрукътан риваять ителде, ул әйтте: «Мәчеттә бер ир сөйләшеп утырган арада әйтте: «Кыямәт көнне күктән төтен иңәр. Монафыйкларның колакларына һәм күзләренә тулыр, мөэминнәргә туман төшкән рәвештә булыр». Мәсрукъ әйтте: «Мин Габдулла бине Мәсгуд янына кереп, бу сүзләрне аңа сөйләдем, ул таянып тора иде. Торып утырды да әйтте: «Әй кешеләр! Кем дә кем гыйлеме булып, соралса, аннан җавап бирсен. Әгәр гыйлеме булмаса, ул: «Аллаһы – белүчерәк», – дип әйтсен. Аллаһы Тәгалә пәйгамбәренә әйтте:

﴿قُلْ مَا أَسْأَلُكُمْ عَلَيْهِ مِنْ أَجْرٍ وَمَا أَنَا مِنَ الْمُتَكَلِّفِينَ﴾

«Әй, Мөхәммәд галәйһиссәләм, кешеләргә әйт: "Ислам динен өйрәткәнем өчен сездән хак сорамыймын, һәм мин Коръәнне үземнән чыгарып сөйләүчеләрдән түгелмен». (Сад: 86)

Корәеш кәферләре Рәсүлуллаһка ышанмый башлагач Рәсүлуллаһ дога кылды:

اللهم اشدد وطأتك علي اللهم اعني عليهم

بسبع كسبع يوسف اللهم سنينا كسني يوسف

Аларны ачлык тотты. Ул ачлык вакытында мәшәкатьтән сөяк һәм үләксә ашадылар, хәтта ачлыктан үзләре белән күк арасында төтен рәвешен күрә башладылар. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿فَارْتَقِبْ يَوْمَ تَأْتِي السَّمَاءُ بِدُخَانٍ مُبِينٍ﴾

«Кыямәт көнен көтүче имансызлар өчен, ул көндә, күк каты төтен белән тулган булыр». (Духан: 10)

Ибен Гомәрдән риваять ителде. Ул әйтте: «Сәгыйд бине Әбү Вәккас Кодсиядә вакытта хәзрәти Гомәр аңа Надлә бине Могавияне Хәлвәнгә җибәрүе хакында язды. Сәгыйд Нәдләгә өч йөз атлы гаскәр биреп җибәрде. Алар чыктылар, Хәлвәнгә килделәр дә, аның тарафларын таладылар, ганимәт малга һәм әсирләргә ирештеләр. Ганимәт малларын һәм әсирләрен сөйрәп, кайтырга чыктылар, хәтта бер тау янына килеп җиттеләр. Нәдлә торып, намаз укырга азан укый башлады, «Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр», диде. Таудан бер җавап бирүче әйтте: «Әй Нәдлә, олуглау белән олугладың». Моннан соң Нәдлә: «Әшһәдү ән ләә иләәһә илләәллаһ», – диде. Таудан җавап бирүче әйтте: «Ихлас сүзе, әй Надлә». Нәдлә әйтте: «Әшһәдү әннә мүхәммәдән рәсүлуллаһ». Җавап бирүче әйтте: «Ул, безне Гайсә галәйһиссәләм шатландырган кешедер». Нәдлә әйтте: «Хәййә галәәс-саләһ». Ул: «Намазга барган һәм аны торгызуда тырышлык кылган кешегә тәүбә ит», – диде. Нәдлә әйтте: «Хәййә галәл фәләәх». Ул әйтте: «Мөхәммәд галәйһиссәләмнең дәгъватына җавап бирүчеләргә котылу насыйп ит». Нәдлә әйтте: «Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр ләә иләһә илләәллаһ». Ул әйтте: «Ихластан, ихлас әй Нәдылә, Аллаһы Тәгалә синең тәнеңне утка хәрам кылды». Нәдлә азанны әйтеп бетергәч әйтте: «Аллаһы рәхмәт кылсын, син кем, фәрештәме, яки җенме, яки Аллаһы колларыннан башка таифәме? Тавышыңны ишеттем, инде сурәтеңне дә күрсәт. Без Аллаһының, Рәсүлуллаһның һәм Гомәр бине Хаттабның гаскәребез». Шул чакта ул зур башлы, ак чәчле, ак сакаллы,

йоннан булган ике киемле бер карт күрде. «Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһ», – диде. Без дә: «Вә галәйкәссәләәмү вә рахмәтүллаһ. Син кем?» – дидек. Ул әйтте: «Мин, изге кол Гайсә галәйһиссәләмнең васыять әйтүчесе, Зәрнәб бине Йәргалә. Мине шушы тауда торгызды һәм үзе күктән иңгәнчегә кадәр миңа озын гомер белән дога кылды. Мөхәммәд галәйһиссәләмгә юлыга алмасам да, Гомәргә миннән сәлам укыгыз. Һәм аңа әйтегез: «Тугры бул һәм Аллаһыга якынай». Мин сезгә сөйли торган сыйфатлардан аңа хәбәр бирегез. Әгәр ул сыйфатлар Мөхәммәд галәйһиссәләм өммәтендә күренсә, качыгыз. Ирләр ирләрдән, хатыннар хатыннардан моңсыз булсалар, тиешсез эшкә тотынсалар. Олугы кечкенәсенә рәхмәт әйтмәсә. Кечкенәләре дә олыларны хөрмәтләмәсәләр. Яхшылык белән боеруны, начарлыктан тыюны ташласалар. Галимнәре гыйлемне акча җыяр өчен генә өйрәнсә. Яңгырсыз көннәрдә балалары ачулы булса. Саранннары бик катылансалар, юмартлары аз бирер булсалар. Өйләрен зиннәтләсәләр, күңел теләкләренә иярсәләр. Динне дөнья бәрабәренә сатсалар. Кеше канын җиңелгә санасалар, кардәшләрдән киселсәләр, хөкемне сатсалар. Манараларны озын кылсалар, мөсхәфләрне көмешләсәләр, мәчетләрне зиннәтләсәләр, ришвәт алсалар, риба ашасалар, байлар бик кадерле булса, хатыннар иярләргә атлансалар, шул вакытта качыгыз». Моннан соң күренмәс булып югалды».

Риваять ителде, моннан Сәгыйд тагын дүрт мең кеше белән чыкты. Шул урында кырык көн торды. Һәр намаз өчен азан укый иде. Ләкин җавап та, башка сүз дә ишетмәде.

## Әбү Зәрр Гафәри разыяллаһү ганһүнең хәдисләре

Хәрис Әгүвәридән риваять ителде. Әбү Зәрр разыяллаһү ганһү әйтте: «Мәчеткә керсәм, Рәсүлуллаһ ялгыз гына утыра. Бу Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм вәхи көтеп яки башка бер хаҗәте өчен утырадыр, дип уйладым. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әй Җүндәб, кил яныма». Мин аның янына килдем, Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм белән аулакта булуымны ганимәткә санап әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, син безгә тәһарәт белән боерасың, тәһарәт нәрсә ул?» Рәсүлуллаһ әйтте: «Әй Әбү Зәрр, тәһарәтсез намаз булмый. Янә тәһарәт әүвәлдә кылынган гөнаһлар өчен кәффарәт булыр». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, безгә намаз белән боерасың, намаз нәрсә ул?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Намаз фарыз кылынган нәрсәләрнең изгерәгедер. Теләгән кеше аз укысын, теләгәне күп укысын». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, син безгә зәкәт белән боерасың, зәкәт нәрсә ул?» Рәсүлуллаһ әйтте: «Әй Әбү Зәрр, әманәте булмаган кешенең иманы юк, зәкәте булмаган кешенең намазы юк. Аллаһы Тәгалә байларга фәкыйрләр мохтаҗ булмаслык кадәр белән малларыннан зәкәт бирергә фарыз кылды. Аллаһы Тәгалә байлардан зәкәт бирүләре хакында сораучыдыр, бирмәсәләр газап кылучылар. Әй Әбү Зәрр, зәкәт биргәнгә карап, мал кимемәс. Корыда яки диңгездә мал һәлак булмас, мәгәр зәкәт бирмәүдән генә һәлак булыр. Әй Әбү Зәрр, хисаплап куйган малыннан хуш күңел белән һичкем зәкәт бирмәс, мәгәр мөэмин булган кеше генә бирер». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, безгә ураза белән боерасың, ураза нәрсә ул?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Ураза

калкандыр, аның җәзасы Аллаһы каршында. Ураза тотучыга ике төрле шатлык бар: берсе, ифтар кылган вакыт, икенчесе, Раббысына юлыккан вакыт. Ураза тотучының авыз исе Аллаһы Тәгалә каршында яфәр исеннән дә хушрактыр. Кыямәт көнендә кешеләр алдына аш хәзерләнгән ашъяулык куелыр. Аннан иң элек ашаучылар – ураза тотучылар булыр». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, безгә сабыр белән боерасың, сабыр нәрсә ул?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Сабыр, җәмәгать арасында бер яфәре булган ир кебек булыр. Җәмәгатьнең барысы да ул ирдән яфәрнең исен табарга кызыгырлар». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, безгә садака белән боерасың, садака нәрсә ул?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Яхшы, яхшы, әй Әбү Зәрр. Яшерен бирелгән садака Аллаһының ачуын сүндерер. Ачык бирелгән садака иясеннән җиде йөз явызлыкны җибәрер. Садака гөнаһларны, утның һәм Аллаһының ачуын сүндерә. Садака гаҗәеп нәрсәдер», – дип өч мәртәбә кабатлады. Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, безгә кол азат итү белән боерасың. Кайсы колны азат итү яхшырак?» Рәсүлуллаһ әйтте: «Кыйммәтлерәге булганын азат итү». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, һиҗрәтнең кайсысы артыграк?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Явызлыктан күчүдер». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, адәмнәрнең кайсылары мөселманрак?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Мөселманнар аның кулыннан һәм теленнән тыныч булган кеше». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, адәмнәрнең кайсысы гаҗизрәк?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Догадан гаҗиз булган кеше». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, кешеләрнең кайсысы саранрак?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Сәлам бирергә саран булган кеше». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ,

сугышчыларның кайсысы артыграк?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Кем дә кем атын бугазлап, канын агызса, шул кеше сугышчыларның артыграгыдыр». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, Ибраһим галәйһиссәләм китабыннан һәм башка китапларның кайчан иңдерелүеннән хәбәр бирче». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Ибраһим сөхефләре Рамазан аеның беренче кичәсендә иңдерелде. Инҗил Рамазанның ун икенче көнендә иңдерелде. Забур исә унсигезенче Рамазанда иңдерелде. Тәүрат сигезенче Рамазанда иңдерелде. Коръән егерме дүртенче Рамазанда иңдерелде». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, пәйгамбәрләр һәм рәсүлләр күпме булды?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Пәйгамбәрләр йөз егерме дүрт мең, рәсүлләр өч йөз егерме өч булды. Кайберләре пәйгамбәр генә булып, рәсүл булмады. Кайберләре исә пәйгамбәр дә, рәсүл дә булды».

Фәкыйһ әйтте: «Шуңа охшаш хәдисне үзенең иснәде белән Әбү Зәррдән риваять кылып, миңа Габделвәһһаб тә сөйләде. Габделвәһһаб беренче хәдискә түбәндәгеләрне арттырды.

Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, кичнең кайсы вакыты артыграк?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Кичнең калган уртасы». Әбү Зәрр әйтте: «Намазның кайсысы артыграк?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Догасы озын булганы». Әбү Зәрр әйтте: «Садаканың кайсысы артыграк?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Ачлыктан, катылыктан мәшәкатьләнеп табылып та, фәкыйрьгә бирелгән садака». Мин әйттем: «Пәйгамбәрләрнең беренчесе кем булды?» Пәйгамбәр галәйиссәләм әйтте: «Адәм». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, Адәм рәсүл булдымы?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әйе,

Аллаһы Тәгалә Адәмне кодрәте белән яратты да, аңа рухыннан өрде. Пәйгамбәрләрдән дүртесе Адәм, Шис, Идрис, Нух сәрйәнидер. Әйтелде: «Гайсә галәйһиссәләмне дә сарьяни, диде». «Дүртесе: Һүд, Салих, Шөгәеб һәм Пәйгамбәрең Мөхәммәд галәйһиссәләмнәр гарәптәндер». Мин әйттем: «Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләренә күпме китап иңдерде?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Йөз дә дүрт. Шискә илле, Идрискә утыз, Ибраһимга ун сахифә, Тәүраттан элек Мусага ун сахифә, барысы йөз дә дүрт». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, Миңа васыять кылчы». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһыдан саклан. Чөнки ул барча эшеңнең башы». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, арттыр». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһының зикеренә һәм Корьән укуга лязем бул. Синең өчен күктә нур, җирдә шәриф һәм күркәм мактау булыр. Аллаһы юлында сугышка лязем бул. Чөнки ул өммәтемнең раһибләренә махсус булган сыйфаттыр. Хәердән башкага тик торуга лязем бул. Ул шайтанны үзеңнән качыру коралы һәм дин эшеңдә ярдәмчедер. Көлүдән саклан. Көлү калепне үтерә һәм йөзнең нурын җибәрә».

Фәкыйһ әйтте: «Миңа атам үзенең иснәде белән Әбү Зәррдән риваять итте, ул әйтте: «Мәчеткә керсәм, Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм ялгыз гына утыра иде. Бер тапкыр үз-үземә: «Рәсүлуллаһның ялгызлыгыннан файдаланып, аның янына барыйм», – дидем. Икенче тапкыр: «Барып, эшеннән мәшгуль итмим», – дидем. Булмады, барыйм дидем дә, бардым, сәлам бирдем. Янына барып бик озак утырдым. Миңа озак эндәшмәде, хәтта пәйгамбәр галәйһиссәләмне борчыдым, дип уйладым. Моннан соң эндәште: «Әй Әбү Зәрр, намаз укыдыңмы?» –

диде. Мин әйттем: «Юк». Ул әйтте: «Тор, укы. Һәрнәрсәнең бүләге бар, мәчетнең бүләге ике рәкәгать намаздыр». Тордым да намаз укыдым, аннан соң янына барып, озак утырдым. Моннан соң әйтте: «Әй Әбү Зәрр, таш белән сөрелгән адәм һәм җен шайтаннарыннан Аллаһы Тәгаләгә сыен». Мин әйттем: «Әй Рәсүлуллаһ, кешеләрдән дә шайтаннар буламы?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең:

﴿شَيَاطِينَ الْإِنسِ وَالْجِنِّ﴾

«Кешеләрдән һәм җеннәрдән булган шайтаннардан...». (Әнгам: 112) дигән аятьне ишеткәнең юкмы?» Соңыннан тик торды. Инде ул минем белән сөйләшми дип уйладым да, яңадан сүзгә керештем: «Әй Рәсүлуллаһ, син безгә намаз белән боерасың, намаз нәрсә ул?» Югарыда зекер ителгән сорауларны бирде. Әбү Зәрр әйтте: «Моннан соң кешеләр җыелды». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Адәмнәрнең саранрагы турында хәбәр биримме?» Әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, әйт». Рәсүлуллаһ әйтте: «Аның янында мин зекер ителгәндә, миңа салават әйтмәгән кешедер».

Габдулла бине Готбәдән риваять ителде. Габдулла бине Мәсгуд әйтте: «Рәсүлуллаһ Табук сугышына чыкканда, аңа монафыйклардан бер төркем юлдаш булдылар. Алардан берсе, яки икесе качтылар. Сәхабәләр: «Әй Рәсүлуллаһ, фәлән кеше качты», – дип әйттеләр. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Калдырыгыз, әгәр анарда хәер булса, Аллаһы Тәгалә аны тиз арада сезгә ияртер. Әгәр хәер булмый икән Аллаһы аннан сезне тынычландырган булыр». Әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, Әбү Зәрр качты». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте:

Калдырыгыз, әгәр аңарда хәер булса, Аллаһы Тәгалә аны сезгә ияртер». Әбү Зәрр дөясе арып артта калган иде, ул дөясен көтте. Дөясе арыгач, өстендәге нәрсәләрен үзенең аркасына күтәрде. Аннан соң Әбү Зәрр япа-ялгыз, бик каты эсседә, аркасына әйберләрен күтәреп, җәяүләп Рәсүлуллаһның эзенә ияреп кайтты. Сәхабәләр аны күргәч: «Әй Рәсүлуллаһ, берәү җәяү безгә таба килә», – диделәр. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Ул Әбү Зәрр булсын иде». Сәхабәләр яхшырак карагач: «Әй Рәсүлуллаһ, бу чыннан да Әбү Зәрр», – диделәр. Рәсүлуллаһның ике күзе яшьләнде һәм әйтте: «Аллаһы Тәгалә Әбү Зәррга рәхмәт кылсын: йөри ялгыз, үләр ялгыз, кубарылыр ялгыз».

Мөхәммәд бине Кәгъбтән риваять ителде. Ул әйтте: «Әбү Зәрр Госман разыяллаһү ганһү заманында Рабзә дигән урынга килгән иде. Шул урында аңа язмыш иреште. Аның янында хатыны белән колыннан башка һичкем булмады. Хатыны белән колына: «Мине юыгыз, кәфенләгез дә, юлның уртасына куегыз», – дип васыять итте. Сезгә юлда иң әүвәл очраган атлы кешегә әйтегез: «Бу Рәсүлуллаһның сәхабесе Әбү Зәрр, безгә аны күмәргә ярдәм итсәгезче». Әбү Зәрр үлгәч васыятен үтәп, юлның уртасына куйдылар. Гыйрактан бер җәмәгать белән Габдулла бине Мәсгуд очрады. Кол аларны күргәч торды да: «Бу Рәсүлуллаһның сәхабәсе Әбү Зәрр, безгә аны җирләргә ярдәм итсәгезче», – диде. Ибен Мәсгуд җирләргә кереште, үзе кычкырып елады. Моннан соң әйтте: «Рәсүлуллаһның «йөрерсең ялгыз, үләрсең ялгыз, кубарылырсың ялгыз», дип әйтүе дөрес булды». Аны күмделәр, Ибен Мәсгуд иптәшләренә Рәсүлуллаһның Табукка барган чагында сөйләгән сүзләрен сөйли-сөйли киттеләр».

Әбү Зәрдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Миннән соң сиңа бәла ирешер». Әбү Зәрр әйтте: «Аллаһы юлындамы?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы юлында». Әбү Зәрр әйтте: «Аллаһы юлында булса, мәрхәбә». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әй Әбү Зәрр, әгәр кара кол артында намаз укысаң да тыңла, аңа буйсын».

Рәсүлуллаһ вафат булгач, Әбү Бәкер разыяллаһү ганһү хәлифә булды. Ул Әбү Зәррне чакырды да, бүләк биреп елады. Әбү Бәкер әйтте: «Синең турында Рәсүлуллаһның әйткән сүзен ишеттем. «Мин, минем сәбәпле яки минем заманымда сиңа бәла ирешүеннән Аллаһыга сыгынам». Әбү Бәкер вафат булгач, Гомәр разыяллаһү ганһү хәлифә ителде. Ул Әбү Зәррне чакырды да мактады. Гомәр әйтте: «Мин Рәсүлуллаһның синең хакында әйткән сүзләрен ишеттем. Минем сәбәпле, яки минем заманымда сиңа бәла ирешүеннән Аллаһыга сыгынамын». Гомәр вафат булгач, Госман разыяллаһү ганһү хәлифә булды. Габдулла бине Габбас әйтте: «Мин Госман янында утырып тора идем. Әбү Зәрр килеп, керергә рөхсәт сорады». Ибен Габбас әйтте: «Әй мөэминнәрнең әмире, Әбү Зәрр керергә рөхсәт сорый». Госман әйтте: «Теләсәң, рөхсәт бир». Ибен Габбас әйтте: «Мин аңа керергә рөхсәт бирдем. Ул керде дә, утырды». Госман аңа әйтте: «Әбү Бәкер белән Гомәрдән үзеңне изгерәк уйлаучы синме?» Әбү Зәрр әйтте: «Алай дип әйткәнем юк иде». Госман әйтте: «Мин сиңа шаһид китерәм». Әбү Зәрр әйтте: «Аллаһы Тәгалә синең йөзеңне ак кылсын, мин синең шаһидеңне белмим, ләкин мин үземнең ничек әйткәнемне беләмен». Госман: «Ничек әйттең?» – дип сорады. Әбү Зәрр: «Рәсүлуллаһ: «Сезнең миңа

сөеклеләрегез һәм якыннарыгыз мин калдырган гаһедне миңа тоташканчы алыр», – дип әйтте дидем. Миннән башка барыгыз да дөньяга ирешкәнсез». Госман: «Мугавия янына бар», – дип, аны Шамга җибәрде. Әбү Зәрр Шамга килгәч, адәмнәрне өйрәтергә кереште. Аларның күзләрен елатты, күңелләрен кайгырта иде». Әбү Зәрр: «Сезнең берәрегезнең алтын яки көмешегез булса, аны Аллаһы юлына нәфәка кылмыйча яки бурыч иясенә санамыйча йокламасын», – дип әйтте. Могавия һәм кешеләр Әбү Зәррне тыңлап еладылар. Мугавия, Әбү Зәррнең сүзе кылган эшенә, эче тышына каршы булуын белергә теләп, Әбү Зәррга мең алтын җибәрде. Әбү Зәрр мең алтынны алды да, үзенә бернәрсә калдырмыйча өләште. Икенче көнне Мугавия илчене чакырды да: «Бар, Әбү Зәррга мин башка кешегә җибәргән мең алтынны ялгыш сиңа китергәнмен», – дип әйт», – диде. Мугавиянең илчесе Әбү Зәррга килде һәм әйтте: «Мине Мугавиянең газабыннан коткар. Мине мең алтынны башка кешегә бирергә, дип җибәргән икән, мин ялгышканмын да, сиңа биргәнмен», – диде. Әбү Зәрр илчегә әйтте: «Мугавиягә миннән сәлам укы. Аңа әйт: «Алтынның берсе дә калмады. Әгәр теләсәң, өч көн көт, җыеп алып бирермен». Мугавия Әбү Зәррнең сөйләгән сүзен эше раслаганын күргәч, Госманга: «Әгәр сиңа Шам кирәк булса, Әбү Зәррга кеше җибәр дә, үзен чакырт», – дип хат язды. Габдулла бине Габбас әйтте: «Госман Әбү Зәррга, минем яныма кил», – дип язды. Габдулла әйтте: «Әбү Зәрр Госман мәчеттә булган чагында кайтты. Госманга каршы чыгып сәлам бирде, Госман да сәламен кайтарды һәм әйтте: «Әй Әбү Зәрр, хәлең ничек?» Әбү Зәрр: «Яхшылыкта, сез ничек?» – диде. Госман мәчеттән чыкты, Әбү Зәрр

багана төбенә барып ике рәкәгать намаз укыды. Соңыннан утырды, аның янына кешеләр дә утырдылар. Әйттеләр: «Әй Әбү Зәрр, безгә Рәсүлуллаһның хәдисеннән сөйлә». Әбү Зәрр: «Ярар. Дустым миңа сөйләде: «Дөядә садака, игендә садака, акчада садака, куйда садака. Берәүнең өендә алтын, көмеш акчасы булып та, Аллаһы юлында нәфәка кылмаса яки бурыч иясенә бирергә дип хәзерләнмәгән хәлдә йокласа, ул акчалары саклаган хәзинә булыр, аның белән Кыямәт көнендә көйдерелер». Әйттеләр: «Әй Әбү Зәрр, Аллаһыдан саклан, нәрсә сөйләгәнеңне кара. Чөнки бу маллар кешеләрдә күп бит». Ул әйтте: «Коръән укыйсызмы?

﴿ وَالَّذِينَ يَكْنِزُونَ الذَّهَبَ وَالْفِضَّةَ وَلَا يُنفِقُونَهَا فِي سَبِيلِ اللَّهِ فَبَشِّرْهُمْ بِعَذَابٍ أَلِيمٍ ﴾

Шундый кешеләр ки, алтынны, көмешне хәзинә итеп саклыйлар, аларны Аллаһы юлында нәфәка кылмыйлар. Бәс аларга каты газап белән сөенеч бирелсен». (Тәүбә: 34) Әбү Зәрр ике яки өч кич торгач, Госман аңа илче җибәрде. Ташландык Рабзә дигән урынга китәргә кушты. Әбү Зәрр Рабзәгә барырга чыкты. Аларга, ягъни Рабзәдә торучыларга кара колның имам булуын тапты. Әбү Зәрргә имам бул диделәр, ул ризалашмады. Шул кара колның артында намаз укыды. «Аллаһы һәм Аның Рәсүле дөрес сөйләделәр», – диде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм миңа әйтте: «Кара колның артыннан намаз укысаң да, итагать кыл, тыңла». Әбү Зәрр шул урында үлгәнчегә кадәр торды».

Әбү Зәррнең хатыныннан риваять ителде. Ул әйтте: «Әбү Зәргә вафат вакыты килеп җиткәч, еладым. Әбү Зәрр: «Нәрсәгә елыйсың?» – диде. Мин әйттем: «Җирнең бер кырында үләсең, кәфенгә

төрергә бирәр кием дә юк». Әбү Зәрр әйтте: «Елама, шат бул. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнең әйткәнен ишеттем, ул бер җәмәгатькә әйтте һәм мин алар арасында идем: «Сезнең берегез җирдән булган бер кырда үләр, аны мөэминнәрдән бер җәмәгать карар». Ул җәмәгать эчендәге кешеләрдән барчасы да авылда яки җәмәгать эчендә һәлак булды, мәгәр мин генә кырда үләмен. Аллаһы белән белән ант итәм, мин ялган сөйләмим, ул ир мин, бәс юлны күрсәт!» Мин: «Хаҗилар киткән, юл эзләгән», – дидем. Өелгән ком өстендә аны карыйм, кирәк нәрсәсен сорыйм һәм дәвалый идем. Мин шулай тырышкан арада хайваннар өстендә бер җәмәгать килә. Мин аларга кием белән селкедем. Алар миңа таба ашыгып килделәр. Әйттеләр: «Әй Аллаһының кәнизәге, ни булды сиңа?» Мин әйттем: «Мөселманнардан бер ир үлә, аны кәфенләсәгезлә?» Әйттеләр: «Кем ул?» Әйттем: «Әбү Зәрр». Әйттеләр: «Рәсүлуллаһның сәхабәсе Әбү Зәррме?» Мин: «Әйе», – дидем. «Атабыз, анабыз фида булсын», – диделәр һәм ашыгып аның янына килделәр. Аларга мәрхәбә, диде. «Шатланыгыз, чөнки мин Рәсүлуллаһның әйткәнен ишеттем, бер җәмәгатькә әйтте һәм алар арасында мин бар идем. «Кырда бер ир үләр, аны мөэминнәрдән бер җәмәгать карар», – дип әйтте. Бу кавем эчендә авылда яки җәмәгать арасында һәлак булмаган һичкем юк, мәгәр мин генә. Бәс мин әлеге ир, сез мөэминнәрдән бер җәмәгать буласыз. Әгәр киемем яки хатынымның киеме кәфенемә җитәрлек булса, мин шулар белән генә кәфен кылыныйм. Аллаһы белән ант итеп әйтәм, сездән әмир яки илче, яки мәгъруф яки тикшерүче булган кеше мине кәфен кылмасын. Кавем арасыннан боларның берсе дә булмаган кеше чыкмады, мәгәр ансардан бер ир

булды. Ул ир әйтте: «Әй кардәшем, сине мин кәфен кылырмын. Чөнки мин син зекер кылган әйберләрнең берсенә дә ирешмәдем. Шушы киемем белән, яки анам тукыган ике киемем, яки ике җөббә белән кәфен кылырмын». Әбү Зәрр: «Мине син кәфен кылырсың», – диде. Анда булган җәмәгать арасыннан ансар Әбү Зәррне кәфен кылды. Болар барысы да динле кешеләр җөмләсеннән иде. Әбү Зәррдән ишеткән нәрсәләрне сөйли-сөйли шатланып кайттылар».

## Итагать итүдә тырышлык

عن معاذ بن جبل ﷺ أن رسول الله ﷺ قال : "ألا أدلكم على أبواب الخير؟" قالوا : نعم ، قال : "الصوم جنة ، والصدقة برهان ، وقيام العبد في جوف الليل يطفيء كل خطيئة".

Мөгаз бине Җәбәлдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Мин сезне изгелек эшләренә димләмимме?» Мин әйттем: «Әйе». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Ураза Аллаһының газабыннан сакланыр өчен калкан. Садака малны тиешле урынына тотканыңа дәлил. Колның төн уртасында гыйбадәт кылуы һәрбер гөнаһларны сүндерер».

عن أبي عبيدة ﷺ قال : سمعت رسول الله ﷺ يقول : "الصوم جنة ما لم يخرقها".

Әбү Гобәйдәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Ураза, әгәр аны гайбәт белән ертмаса, Аллаһының газабыннан калкан була».

Фәкыйһ үзенең иснәде белән Гайсә бине Әхмәдтән күчерә. Хәсән әйтте: «Дүрт нәрсә ахирәт азыклары җөмләсеннән: ураза – тән саулыгы; сада-

ка – кеше белән ут арасында пәрдә; намаз – колны Раббысына якынаю кылыр; күз яшьләре – гөнаһларны юу».

Фәкыйһ әйтте: «Әйтелде: «Итагатьнең асылы өч нәрсәдер: курку, өмет һәм ярату. Куркуның галәмәте хәрамнарны ташлау. Өметнең галәмәте итагатькә кызыгу. Мәхәббәтнең галәмәте омтылу һәм ышанычы арту. Гөнаһның асылы өч нәрсәдер: тәкәбберлек, комсызлык һәм көнчелек. Тәкәбберлек иң элек иблистә күренде. Аңа Адәм галәйһиссәләмгә хөрмәтләү сәҗдәсе кылырга боерылды, ул тәкәбберләнде сәҗдә кылмады, хәтта мәльгун булып әверелде. Комсызлык элек Адәм галәйһиссәләмдә беленде: Аллаһы Тәгалә тыйган агачка сузылды да, җәннәттә мәңге калмакчы булып, ул җәннәттән чыгарылды. Көнчелек исә элек Адәм улы Кабилдә заһир булды. Көнләшеп кардәшен үтерде дә, утка кертелде. Бәс һәркемгә гөнаһлардан саклану, тәгатьтә тырышу һәм тәгатьне Аллаһы Тәгалә өчен ихлас кылу важиб була».

فقد روى عن النبي ﷺ أنه قال : "من أخلص العبادة لله تعالى أربعين يوما ظهرت ينابيع الحكمة من قلبه على لسانه".

Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять ителде. Ул әйтте: «Кем дә кем кырык көн ихлас күңеленнән Аллаһы ризалыгы өчен гыйбадәт кылса, хикмәт чишмәләре кальбеннән теленә иңәр».

Әйтелде: «Өч төрле кеше үзләре өчен калепләрдә ачуны игәрләр, каргышны важиб итәрләр, бина кылганнарын җимерерләр. Беренчесе, адәмнәрнең гаепләре белән шөгыльләнүче кеше. Икенчесе, үз-үзенә сокланучы. Өченчесе, кылган гамәле белән рия кылучы кеше. Һәм өч төрле сыйныф калепләргә мәхәббәтне игәрләр, күк әһелләре

арасында дәрәҗәне һәм гафиятне мирас итеп алырлар. Беренчесе, күркәм холык иясе. Икенчесе, гамәлен Аллаһы Тәгалә өчен кылучы. Өченчесе, түбәнчелекле кеше».

Гомәр бине Хаттаб разыяллаһү ганһүдән риваять ителде. Ул әйтте: «Үзегездән хисап алынганга кадәр нәфесләрегез белән хисаплашыгыз. Чөнки ул хисабыгыз өчен уңайрак һәм җиңелрәк булыр. Үлчәлмеш булганыгызга кадәр нәфесләрегезне үлчәгез. Кыямәт көне өчен әзерләнегез.

﴿ يَوْمَئِذٍ تُعْرَضُونَ لَا تَخْفَى مِنكُمْ خَافِيَةٌ ﴾

«Ул көндә фаш ителерсез, сездән һичнәрсә яшерен калмас». (Хаккат: 18)

Яхъя бине Мөгаздән риваять ителде. Ул әйтте: «Кешеләр өч төрле сыйныфтыр. Бер төрле кеше, аның ахирәткә хәзерләнүе ашамлык нәрсәсеннән мәшгуль итәр. Бер төрле ирне ашамлык нәрсәсе ахирәт хәзерлегеннән мәшгуль итәр. Һәм бер төрле кеше, боларның һәр икесе белән шөгыльләнүчедер. Беренчесе, дәрәҗә ягыннан өстен булучылар һәм габидләр дәрәҗәсе. Икенчесе, һәлак булучылар дәрәҗәсе. Өченчесе исә, хатәр кешеләр дәрәҗәседер».

Хатим Заһидтән риваять ителде. Ул әйтте: «Дүрт төрле кеше үзенең дәрәҗәсен танымас, мәгәр дүрт төрле кеше генә таныр. Яшьләр үзләренең кадерен танымаслар, мәгәр аларның кадерен картлар гына таныр. Тыныч кешеләр үзләренең кадерләрен танымаслар, мәгәр бәла әһелләре генә таныр. Сихәт кадерен авырулар гына танырлар. Тереклек кадерен исә үлекләр генә белерләр».

قال الفقيه : هذا مستخرج من خبر رسول الله ﷺ : "اغتنم خمسا قبل خمس : شبابك قبل هرمك ، وصحتك قبل سقمك ، وغنام قبل فقرك ، وفراغك قبل شغلك ، وحياتك قبل موتك".

Фәкыйһ әйтте: Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнән хәбәр ителде: «Биштән элек биш нәрсәне ганимәт сана. Картлыгыңнан элек яшьлегеңне; авырганчыга кадәр сәламәтлегеңне; фәкыйрьлегеңә кадәр байлыгыңны; шөгылеңә кадәр бушлыгыңны һәм үлемеңә кадәр тереклегеңне ганимәт итеп сана».

Кешегә тереклегенең кадерен белү, аның хозурына килгән һәрбер сәгатен ганимәт дип белү тиешледер. Икенче сәгатьтә минем хәлем ничек булыр, дип, үлекләрнең үкенүләре хакында уйлау. Хәлбуки, алар ике рәкәгать намаз укырлык яки «лә иләһә илләәллаһ» дип әйтерлек вакыт тереклекне тәлиләр. Әгәр син шул аз гына вакытка ирешсәң, хәсрәт һәм үкенү вакыты килгәнче Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылырга тырыш.

Хәтимнән: «Гамәлеңне нәрсәгә бина кыласың?» – дип сорадылар. Хәтим әйтте: «Дүрт нәрсәгә бина кыламын. Әүвәлгесе, һичкемнең ризыгы миңа үтмәгәне кебек, минем өчен булган ризык та миннән башкага үтми, дип беләм. Шуңа ышанам. Икенчесе, минем өстемдә фарыз бар дип беләм. Ул фарызны миннән башка кеше үти алмас, шул сәбәпле мин ул фарыз белән мәшгульмен. Өченчесе, Раббым мине һәрвакытта күрә, дип беләм. Һәм Раббымнан оялам. Дүртенчесе, мине ашыктыра торган бер җәяүле бар дип беләм. Мин аны үзем ашыктырам».

Фәкыйһ әйтте: «Үлемгә ашыгу изге гамәлләргә хәзерләнү һәм Аллаһы Тәгалә тыйган нәрсәләрдән

тыелу. Ошбулар хозурына нык кылсын өчен һәм ахырын хәерле итсен өчен Аллаһы Тәгаләгә ялвару».

Хәкимнәрдән берсе әйтте: «Гыйбадәткә ният белән кергәнче, нигъмәтне Аллаһыдан дип кенә белгәнче, күңел куркусы белән гамәл кылганчы, гамәлен ихлас белән тапшырганчы, ир гыйбадәтнең тәмен тапмас. Әгәр гыйбадәткә ният белән керешсә, бу гамәлгә аны Аллаһы Тәгалә муафыйк кылганын белер. Әгәр нигъмәтне Аллаһыдан дип белсә, ул гыйбадәткә шөкер белән керешер дә, Аллаһыдан аңа артыклык булыр. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ لَئِنْ شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ وَلَئِنْ كَفَرْتُمْ إِنَّ عَذَابِي لَشَدِيدٌ ﴾

«Әгәр шөкер кылсагыз, Мин сезгә арттырырмын. Әгәр көфер кылсагыз Минем газабым бик катыдыр». (Ибраһим: 7) Әгәр гамәлне күңел курыкуы белән кылса, саваб бирү Аллаһы Тәгалә хозурына важиб булыр. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ إِنَّ اللَّهَ لَا يُضِيعُ أَجْرَ الْمُحْسِنِينَ ﴾

«Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә яхшылык кылучыларның гамәлләрен югалтмас». (Тәүбә: 120) Дөньяда савап – тәгатьнең ләззәтен тату. Ахирәттә исә җәннәттер. Әгәр ул гамәлне ихлас белән тапшырса, Аллаһы Тәгалә аннан кабул кылыр. Кабул булуның галәмәте – Аллаһы Тәгалә аны тәгатькә муафыйк кылыр.

Әйтелде: «Алдану галәмәте өч төрле нәрсәдәдер. Беренчесе, үзенең артыннан ияреп бармый торган нәрсәне җыю. Икенчесе, һәлак итә торган гөнаһларның күплеге. Өченчесе, коткара торган гамәлне ташлавы».

Аллаһы Тәгаләгә кайтучы, ягъни гамәле кабул булган кешеләрнең галәмәте – өч төрле сыйфаттыр. Беренчесе, кальбен уйлану өчен кылуы. Икенчесе,

телен зекер өчен кылуы. Өченчесе, гәүдәсен хезмәт өчен кылуыдыр.

Әйтелде: «Үз-үзен алдаучы кешенең өч төрле галәмәте бар: күңел теләкләренә ашыгу һәм таюдан тыныч булуы; дөньяда озак яшәүне уйлап, тәүбәне соңга калдыру һәм гамәлсез ахирәтне өмет итү».

Хәкимнәрнең берсе әйтте: «Кем дә кем өчне өч нәрсәдән башка дәгъва кылса, бел, шайтан аннан көләр. Беренчесе, дөньяны сөя торып, Аллаһы Тәгаләне зекер итәргә дәгъва кылган кеше. Икенчесе, озак борчылудан башка Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын дәгъва кылган кеше. Өченчесе, мәхлукларның мактауларын сөя торып, ихласны дәгъва кылган кеше».

Әбү Нәдрадан риваять кылынды. Ул әйтте: «Берәүдә дүрт төрле гамәл булып та, шулар белән башка хәерне арттырмаса, Аллаһы Тәгалә ул кешедән, ул гамәлләрне кабул кылмас. Әүвәлгесе, берәү сугышып кайтып та, башка изгелек кылмаса, бу Аллаһы Тәгаләнең – аның сугышын кабул кылмаганына галәмәт. Икенчесе, берәү Рамазан аенда ураза тотып та, башка изгелекне арттырмаса, бу Аллаһы Тәгаләнең аның уразасын кабул кылмаганына галәмәт. Өченчесе, берәү фарыз хаҗны кылып та, башка изгелекне кылмаса, бу Аллаһы Тәгаләнең аның хаҗын кабул кылмаганына галәмәт. Дүртенчесе, берәү авырганнан соң сәламәтләнеп, изгелекне арттырмаса, бу авыруы гөнаһларына кәффарәт булмаганына галәмәттер».

Әйтелде: «Акыллы кешегә кылган гамәлен ислах һәм иҗтиһадын тар итмәс өчен дүрт төрле нәрсә тиешле: аңа дәлил булсын өчен – гыйлем; гыйбадәткә бушану һәм халыктан өметсез булу өчен – тәвәккәл; гамәлен тәмам кылу өчен – чыдамлык һәм

савапка ирешүе өчен – ихлас, ягъни гыйбадәткә күңел баглау».

Хәсән Басри әйтте: «Ир җәннәтне теләмәс, теләде исә Аллаһы Тәгаләгә юлыкканчы тырышыр, ябыгыр, нечкәрер һәм истикамәтле булыр. Аллаһы Тәгаләнең сүзен күрмисеңме?

﴿ إِنَّ الَّذِينَ قَالُوا رَبُّنَا اللَّهُ ثُمَّ اسْتَقَامُوا ﴾

«Җәннәт әһеле шундый кешеләрдер ки, Раббыбыз Аллаһы диярләр, соңыннан истикамәт кылырлар». (Фуссыйләт: 30)

Хәкимнәрнең берсе әйтте: «Истикамәтле кеше тауга охшашлы булыр. Тауның исә дүрт галәмәте бардыр: тауны эсселек эретми; салкын тундырмый; җил селкетми; ташу агызмый.

Әйтелде: «Җиде төрле нәрсә изгелек хәзинәләре җөмләсеннәндер. Боларның барысы да Аллаһы Тәгаләнең китабы белән важиб: гыйбадәттә ихлас. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَمَا أُمِرُوا إِلَّا لِيَعْبُدُوا اللَّهَ مُخْلِصِينَ لَهُ الدِّينَ حُنَفَاءَ ﴾

«Без Аллаһыга ихлас белән гыйбадәт кылырга гына әмер ителдек. Тугры булган дин Аллаһы Тәгалә өчендер». (Бәйинә: 5) Икенчесе, ата-анага изгелек кылу. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ أَنِ اشْكُرْ لِي وَلِوَالِدَيْكَ إِلَيَّ الْمَصِيرُ ﴾

«Миңа һәм ата-анаңа шөкер кыл, ахырда Миңа кайтачаксыз». (Локман: 14) Өченчесе, туганнарыңа тоташу, алардан аерылмау. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي تَسَاءَلُونَ بِهِ وَالْأَرْحَامَ ﴾

«Аның исеме белән бер-берегездән кирәк нәрсәләрегезне сорый торган Аллаһыдан һәм кардәш-

ләр хакыннан сакланыгыз». (Ниса: 1) Дүртенчесе, әманәтне тапшыру. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ إِنَّ اللَّهَ يَأْمُرُكُمْ أَنْ تُؤَدُّوا الْأَمَانَاتِ إِلَى أَهْلِهَا ﴾

«Аллаһы Тәгалә сезгә әманәтләрне ияләренә тапшыруыгыз белән боера». (Ниса: 58) Бишенчесе, гөнаһ хакында һич кемгә буйсынмау. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَلَا يَتَّخِذَ بَعْضُنَا بَعْضًا أَرْبَابًا مِنْ دُونِ اللَّهِ ﴾

«Аллаһыдан башка бер-беребезне Раббы урынына ясама». (Әли Гыймран: 64) Алтынчысы, күңел теләге белән гамәл кылмау. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَنَهَى النَّفْسَ عَنِ الْهَوَى ﴾

«Үзен нәфесе теләгән гөнаһлы эшләрдән тыйды». (Нәзигат: 40) Җиденчесе, тәгатьтә тырышлык кылу, Аллаһыдан курку һәм савабын өмет итү. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ يَدْعُونَ رَبَّهُمْ خَوْفًا وَطَمَعًا وَمِمَّا رَزَقْنَاهُمْ يُنفِقُونَ ﴾

«Мөэминнәр шундый кешеләрдер, Аллаһы Тәгаләнең газабыннан куркып, савабын өмет итеп Раббыларына дога кылырлар һәм Без ризыкландырган нәрсәләрдән нәфәка кылырлар». (Сәҗдә: 16)

Һәркемгә Аллаһыдан курку һәм елау важиб була. Чөнки эш бик катыдыр.

Хәбәрдә риваять ителде. Гайсә галәйһиссәләм тавы булган бер авылдан үтте. Тауда елау һәм үксү тавышы ишетелде. Авыл халкыннан: «Бу нинди елау һәм үксү?» – дип сорады. Әйттеләр: «Әй Гайсә, без бу авылда тора башлаганыбыздан бирле ошбу тауда бу елауны ишетәбез». Гайсә галәйһиссәләм әйтте: «Әй Раббым! Бу тауга минем белән сөйләшергә

рөхсәт бирче». Аллаһы Тәгаләнең рөхсәте белән тау телгә килеп әйтте: «Әй Гайсә! Миннән ни телисең?» Гайсә галәйһиссәләм әйтте: «Елавыңнан һәм үксүеңнән хәбәр бирче?» Тау әйтте: «Әй Гайсә, мин шундый таудыр ки, кешеләр Аллаһыдан узып, аңа гыйбадәт кыла торган сынымнарны миннән ясадылар. Мин, Аллаһы Тәгалә мине җәһәннәм утына ташлар, дип куркам. Чөнки мин Аллаһыдан ишеттем. Ул әйтте:

﴿ فَاتَّقُوا النَّارَ الَّتِي وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ ﴾

«Шундый уттан сакланыгыз ки, аның утыны кешеләр һәм ташлардыр». (Бәкара: 24) Аллаһы Тәгалә Гайсә галәйһиссәләмгә вәхи җибәрде. «Ул тауга әйт: «Тынычлан, Аллаһы Тәгалә сине җәһәннәм газабыннан коткарды», – дип. Таш үзенең катылыгы белән Аллаһыдан курка. Бәс мескен, загыйфь адәм улларына уттан курыкмаска, котылырга, дип Аллаһыга сыенмаска ни калган?! Әй адәм улы, уттан саклан. Уттан саклану гөнаһлардан саклану белән булыр. Кол гөнаһ белән Аллаһының ачуын һәм газабын важиб итәр. Аллаһы Тәгаләнең газабына чыдарга синең өчен тәкать юктыр».

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде. Ул әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең:

﴿ وَكَذَلِكَ جَعَلْنَاكُمْ أُمَّةً وَسَطًا لِتَكُونُوا شُهَدَاءَ

عَلَى النَّاسِ وَيَكُونَ الرَّسُولُ عَلَيْكُمْ شَهِيدًا ﴾

«Без сезне адәмнәргә шаһидлар булуыгыз өчен һәм сезнең үзегезгә Рәсүл шаһид булсын өчен, гадел өммәт кылдык» (Бәкара: 143), – дигән аяте иңгәч, Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмнең ике күзе яшьләнде. Моннан соң әйтте:

"يا معشر الناس إن الله تعالى بعثني نبيا وارسلني رسولا ، واختاركم لنبيه ، وأشهدني عليكم ، وأشهدكم على الأمم السابقة والقرون الماصية".

«Әй адәмнәр җәмәгате! Аллаһы Тәгалә мине сезгә пәйгамбәр һәм рәсүл итеп җибәрде. Пәйгамбәре өчен сезне сайлады. Мине сезнең хозурыгызга шаһид кылды. Сезне үткән өммәтләргә һәм борынгыларга шаһидлар кылды». Ансарлардан Кайс бине Гурвә дип йөртелә торган бер ир торды һәм әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, үткән өммәтләргә ничек шаһид булырбыз, тәхкыйк, без алар җөмләсеннән булмадык һәм алар да безнең вакытыбызда булмадылар?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте:

"يا ابن عروة ، إذا كان يوم القيامة وبدلت الأرض غير الارض ، وطريت السماوات كطي السجل للكتاب ، وحشر الخلائق فمنهم سود الوجوه ، فيقفون أربعين عاما".

«Әй Ибен Гурвә, әгәр Кыямәт көне булса, җир асты өскә әйләндерелсә, китапның тышы төрелгән кебек күкләр төрелсә, мәхлуклар кубарылса, алар җөмләсеннән кара йөзлеләр һәм алар җөмләсеннән ак йөзлеләр булыр. Алар кырык ел торырлар». Әйтелде: «Әй Рәсүлуллаһ, алар нәрсә көтәрләр?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйткән тавышны көтәрләр:

﴿ يَوْمَئِذٍ يَتَّبِعُونَ الدَّاعِيَ لَا عِوَجَ لَهُ وَخَشَعَتِ الْأَصْوَاتُ لِلرَّحْمَانِ فَلَا تَسْمَعُ إِلَّا هَمْسًا ﴾

«Ул көндә кешеләр, Мәхшәр җиренә чакыручы Исрафил фәрештәгә ияреләр, ул чакыручыдан уңгасулга борылу булмас, Аллаһудан куркып тавышлар йомшарыр, һәм анда сөйләшкән тавышны ишет-

мәссең, мәгәр бик йомшак сөйләшерләр, колакны сөйләүчеләрнең авызына терәгән хәлдә генә ишетелер». (Таһа: 108) Моннан соң хайваннар китерелер. Берсе берсеннән үч алыр. Ул хайваннарга туфрак булыгыз, диелер. Бәс алар туфрак булырлар. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ وَيَقُولُ الْكَافِرُ يَالَيْتَنِي كُنتُ تُرَابًا ﴾

«Кәфер әйтер: «Мин дә туфрак булсам иде, дип». (Нәбә: 40) Моннан соң һәр пәйгамбәр өммәте белән китерелер. Болар арасында тугрылык белән хөкем кылыныр. Бер фирка җәннәттә, бер фирка сәгыйр җәһәннәмдә булыр. Моннан соң бер кычкыручы: «Кайда Нух галәйһиссәләм?» – дип кычкырыр. Ул китерелер. Аллаһы Тәгалә аңа әйтер: «Әй Нух, пәйгамбәрлегеңне ирештердеңме, әманәтне үтәдеңме?» Нух галәйһиссәләм әйтер: «Әй Раббым, пәйгамбәрлегеңне ирештердем, әманәтне үтәдем». Нух галәйһиссәләмнең кавеме китерелер. Әйтелер: «Әй Нух өммәте, менә бу Нух, аны ихлас кәлимәсенә сезне өндәр өчен җибәрдем. Ул сезгә пәйгамбәрлекне ирештердеме?» Нух галәйһиссәләм кавеме әйтер: «Әй Раббыбыз, безгә сөендерүчедән һәм куркытучыдан берәү дә килмәде». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй Нух! Менә бу синең өммәтең һәм алар сине инкарь кылалар. Үзең өчен шаһидлык бирүче кешең бармы?» Нух галәйһиссәләм әйтер: «Әйе, Мөхәммәд өммәте». Кычкыручы кычкырыр: «Әй адәмнәр өчен чыгарылган изге өммәт, әй Рамазан аенда ураза тотучылар!» Алар сафлардан торырлар. Аллаһы Тәгалә үзенең китабында әйткәнчә:

﴿ سِيمَاهُمْ فِي وُجُوهِهِم مِّنْ أَثَرِ السُّجُودِ ﴾

«Аларның йөзләрендә намаз укуларының галәмәте булыр». (Фәтх: 29) Алар әйттеләр: «Әй Аллаһының өндәүчесе, без синең каршыңда». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй Мөхәммәд өммәте, шаһидлык бирәсезме?» Алар әйтерләр: «Әй Раббыбыз! Нух галәйһиссәләм пәйгамбәрлеген ирештерде, әманәтне үтәде». Нух өммәте әйтер: «Нух әүвәлге пәйгамбәр, Мөхәммәд соңгы пәйгамбәрдер, бәс Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өммәте аның заманасына ирешми торып, ничек шаһидлык бирә алалар?» Мөхәммәд галәйһиссәләм өммәте әйтер: «Аллаһы Тәгаләнең Мөхәммәд галәйһиссәләмгә иңдерелгән китабында:

﴿ إِنَّا أَرْسَلْنَا نُوحًا إِلَى قَوْمِهِ ﴾

«Дөреслектә, без Нухны кавеменә җибәрдек» (Нух: 1), – дигән аяте бар. Без аны соңына кадәр укый идек». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй Мөхәммәд өммәте, дөрес сөйләдегез. Мин Үземә берәүне дә газап кылмаска ант итәм, мәгәр хаҗәт белән генә. Үз арагызда булган золымнарны кичерегез. Мин Үзем белән сезнең арагызда булган нәрсәне кичердем».

## Шайтанның дошманлыгы һәм аның аздыру юлларын белү

عن صفية بنت جحش أن رسول الله ﷺ قال : "الشيطان يجري من ابن آدم مجري الدم".

Сафия бинте Җәхшәдән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Шайтан адәм улында кан юлыннан йөри».

Ибен Габбас разыяллаһү ганһү Аллаһы Тәгаләнең «Нәс» сүрәсен тәфсир кылып әйтте:

﴿ قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ النَّاسِ ﴾

«Әй Мөхәммәд, әйт: «Кешеләрнең Раббысына, ягъни Хуҗасы сыенам».

﴿ مَلِكِ النَّاسِ ﴾

«Кешеләрнең патшасы булган Аллаһыга». Ягъни җеннәрдән һәм кешеләрдән булган барча мәхлукларның патшасы булучы Аллаһы Тәгаләгә сыгынам.

﴿ إِلَهِ النَّاسِ ﴾

«Кешеләрнең илаһысына». Ягъни кешеләрне бар итүчегә.

﴿ مِنْ شَرِّ الْوَسْوَاسِ الْخَنَّاسِ ﴾

«Чигенә-чигенә сәваблы эштән тыеп, гөнаһлы эшкә өндәп вәсвәсә кылучы ханнәснең зарарыннан», ягъни шайтан вәсвәсәләренең явызлыгыннан.

﴿ الَّذِي يُوَسْوِسُ فِي صُدُورِ النَّاسِ . مِنَ الْجِنَّةِ وَالنَّاسِ ﴾

«Ул шайтан адәмнәрнең һәм җеннәрнең күкрәкләренә вәсвәсә кылыр». Ибен Габбас әйтте: «Кешеләрнең күкрәкләренә кергән кебек җеннәрнең дә күкрәкләренә керер һәм вәсвәсә кылыр. Әгәр Аллаһы Тәгалә зекер ителсә, аларның күкрәкләреннән чыгар һәм качар».

وروى عن النبي ﷺ انه قال : "بعثت داعيا مبلغا وليس من الهداية شيء وخلق إبليس مزينا وليس إليه من الضلالة شيء".

Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Туры юлга өндәүче, ирештерүче булып җибәрелдем. Миндә һидаяттән һич нәрсә юктыр. Иблис аздыручы булып яратылды. Аңа заләләттән һич нәрсә юк». Ягъни, Иблис вәсвәсә кылыр һәм гөнаһларны матурлап күрсәтер, аның кулында шуннан күп нәрсә булмас.

Колга үзеннән вәсвәсәне җибәрергә һәм дошманы булган шайтанга карышырга тырышу тиешле була. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ الشَّيْطَانَ لَكُمْ عَدُوٌّ فَاتَّخِذُوهُ عَدُوًّا ﴾

«Шайтан сезгә дошман, сез дә аны дошман тотыгыз». (Фатыр: 6)

Акыллы кешегә дошманнан дусны аерып тану һәм дустына итагать итеп, дошманына иярмәскә тиеш була.

Надан кешенең галәмәте дүрт төрле нәрсә: урынсызга ачулану; батыл эшләрдә нәфесенә иярү; хаксыз урынга малын сарыф итү; дошманыннан аерып дустын тануның азлыгы. Ягъни Аллаһыга итагатен шайтан тәгатенә алмаштыруы гаҗәеп ямандыр. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ أَفَتَتَّخِذُونَهُ وَذُرِّيَّتَهُ أَوْلِيَاءَ مِنْ دُونِي وَهُمْ لَكُمْ عَدُوٌّ بِئْسَ لِلظَّالِمِينَ بَدَلًا ﴾

«Миннән узып шайтанны һәм аның нәселен дус кыласызмы? Хәлбуки, алар сезгә дошманнардыр усалларга алмашу ни ямандыр». (Кәһәф: 50)

Акыллы кешенең галәмәте дүрт төрле нәрсәдер: наданнарга йомшак күңелле булу; батыйльдан нәфесне тыю; малны тиешле урынына сарыф итү; дусны дошманыннан аерып белү.

Вәһәб бине Мүнәббәдән зекер ителде. Ул әйтте: «Иблис Яхъя галәйһиссәләмгә очрады. Яхъя галәйһиссәләм Иблискә әйтте: «Үз каршыңда булган адәм улларының табигатьләреннән хәбәр бирче». Иблис әйтте: «Алар җөмләсеннән бер сыйныф бар, алар синең охшашлы, аларга ни кылырга да булдыра алмыйм. Икенче төрле сыйныф, алар безнең кулыбызда. Балаларыгыз кулында булган туп кебек. Безгә аларның үзләре дә җитә. Өченче төрле сыйныф, алар сыйныфларның иң катырагыдыр.

Аларның берсенә каршы булабыз, хәтта хаҗәтебезне ирештерәбез. Ул куркып истигъфәр кыла да, аңа ирештергән нәрсәбезне бора. Без аннан өметсез дә булмыйбыз һәм хаҗәтебезне дә ирештерә алмыйбыз».

Хәкимнәрнең берсе әйтте: «Кешегә шайтан кайсы ишектән килә икән дип уйландым һәм карадым. Бәс ул ун төрле ишектән килә икән. Беренчесе, комсызлык һәм яман уй ягыннан килә. Мин аңа каршы канәгать һәм ышанычлык белән тордым. Үз-үземә әйттем: «Моны Аллаһының китабыннан нинди аять белән куәтли алырбыз, Аллаһы Тәгаләнең сүзен таптым:

﴿وَمَا مِنْ دَابَّةٍ فِي الْأَرْضِ إِلَّا عَلَى اللَّهِ رِزْقُهَا﴾

«Җир йөзендә булган хайваннарның ризыгы Аллаһы өстендәдер». (Һүд: 6) Ошбу белән шайтанны сындырдым. Икенчесе, карадым да, дөньяда озак торуны уйлау һәм оят тарафыннан килә икән. Үлемнең кисәктән килү куркынычы белән каршы тордым. Моны нинди аять белән куәтли алырбыз, дидем. Бәс Аллаһы Тәгаләнең сүзен таптым:

﴿وَمَا تَدْرِي نَفْسٌ بِأَيِّ أَرْضٍ تَمُوتُ﴾

«Нәфес кайсы җирдә үләчәген белмидер». (Локман: 34) Шуның белән шайтанны сындырдым. Өченчесе, рәхәтне һәм нигъмәтне теләү ягыннан килә икән. Нигъмәтне җибәрү һәм начар хисап белән каршы тордым. Нинди аять белән аны куәтли алырмын, дидем. Аллаһы Тәгаләнең сүзен таптым:

﴿ذَرْهُمْ يَأْكُلُوا وَيَتَمَتَّعُوا﴾

«Куй аларны, ашасыннар һәм файдалансыннар». (Хаҗәр: 3) Янә Аллаһы Тәгаләнең сүзе белән:

﴿ أَفَرَأَيْتَ إِنْ مَتَّعْنَاهُمْ سِنِينَ ﴾

«Аларны ничә еллар файдаландырсам, ни уйлыйсың?!» (Шугара: 205) Шуның белән шайтанны сындырдым. Дүртенчесе, карадым да, ул кешенең үз-үзенә исе китү ишегеннән килә икәнен таптым. Нигъмәт һәм ахырның куркынычы белән каршы тордым. Аны нинди аять белән куәтли алырмын, дидем. Аллаһы Тәгаләнең сүзен таптым:

﴿ فَمِنْهُمْ شَقِيٌّ وَسَعِيدٌ ﴾

«Кешеләр җөмләсеннән бәхетлеләр һәм бәхетсезләр бар». (Һүд: 105) Мин кайсы фиркадан булачагымны белмим. Шуның белән шайтанны сындырдым. Бишенчесе, аны кардәшләрне кимсетү һәм аз хөрмәт кылу ишегеннән килер күрдем. Аларның хакын тану һәм аларны хөрмәтләү белән каршы тордым. Аны нинди аять белән куәтли алырмын, дидем. Аллаһы Тәгаләнең сүзен таптым:

﴿ وَلِلَّهِ الْعِزَّةُ وَلِرَسُولِهِ وَلِلْمُؤْمِنِينَ ﴾

«Гыйззәт Аллаһы, Рәсүле һәм мөэминнәр өчен». (Мунафикун: 8) Ошбуның белән шайтанны сындырдым. Алтынчысы, карадым, ул хөсед ишегеннән килә икән. Тугрылык һәм Аллаһы Тәгалә халкына бүлеп бирүе белән аңа каршы тордым. Моны нинди аять белән куәтли алырмын. Аллаһы Тәгаләнең сүзен таптым:

﴿ نَحْنُ قَسَمْنَا بَيْنَهُمْ مَعِيشَتَهُمْ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا ﴾

«Без аларның тормышларын дөнья тереклегендә өлеш итеп бирдек». (Зухруф: 32) Ошбу белән аны сындырдым. Җиденчесе, карадым, ул рия һәм кешеләрнең мактавы ягыннан килә икән. Ихлас

белән каршы тордым. Аны нинди аять белән куәтли алырмын, дидем. Аллаһы Тәгаләнең сүзен таптым:

﴿ فَمَنْ كَانَ يَرْجُوا لِقَاءَ رَبِّهِ فَلْيَعْمَلْ عَمَلًا صَالِحًا وَلَا يُشْرِكْ بِعِبَادَةِ رَبِّهِ أَحَدًا ﴾

«Кем дә кем Раббысына юлыгуны теләсә, ул кеше изге гамәл кылсын, гыйбадәте белән Раббысына уртак кылмасын». (Кәһеф: 110) Ягъни ихлас белән гамәл кылсын. Сигезенчесе, карадым, ул саранлык ишегеннән килә икән. Халык кулында булган нәрсәнең бетүе һәм Аллаһы каршында булган нәрсәнең калуы белән каршы тордым. Моны нинди аять белән куәтли алырмын дидем. Аллаһы Тәгаләнең сүзен таптым:

﴿ مَا عِنْدَكُمْ يَنفَدُ وَمَا عِنْدَ اللَّهِ بَاقٍ ﴾

«Сезнең каршыгызда булган әйбер бетәр, Аллаһы каршында булган нәрсәләр калыр». (Нәхел: 96) Аны шуның белән сындырдым. Тугызынчысы, карадым, ул тәкәбберлек ишегеннән керә икән. Түбәнчелек белән каршы тордым. Моны нинди аят белән куәтли алырмын дидем. Аллаһы Тәгаләнең әйткән сүзен таптым:

﴿ إِنَّا خَلَقْنَاكُمْ مِنْ ذَكَرٍ وَأُنْثَى وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِنْدَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ﴾

«Без сезне ир һәм хатыннар итеп яраттык һәм бер-берегез белән танышуыгыз өчен төрле бүлек һәм кабиләләр кылдык, сезнең Аллаһы Тәгалә каршында хөрмәтлеләрегез – Аллаһыдан сакланучыларыгыздыр». (Хуҗҗрат: 13) Бәс шуның белән шайтанны сындырдым. Унынчысы, карадым, ул теләү ишегеннән керә икән. Бәс адәмнәрдән өметсез булу һәм Аллаһы каршында булган нәрсәгә ышану белән

каршы тордым. Моны нинди аять белән куәтли алырмын, дидем. Аллаһы Тәгаләнең сүзен таптым:

﴿ وَمَنْ يَتَّقِ اللَّهَ يَجْعَلْ لَهُ مَخْرَجًا . وَيَرْزُقْهُ مِنْ حَيْثُ لَا يَحْتَسِبُ ﴾

«Кем дә кем Аллаһыдан сакланса, Аллаһы аңа юл кылыр һәм аны үзе уйламаган урыннан ризыкландырыр». (Талак: 2, 3)

Хәбәрдә зекер ителде. Муса галәйһиссәләм Раббысына сер сөйләгән вакытта иблис мәльгун килде. Фәрештәләрдән бер фәрештә аңа әйтте: «Әй, син шушы хәлдә аннан нәрсә өмет итәсең?» Иблис мәльгун әйтте: «Җәннәттә чагында атасы Адәмнән өмет иткән нәрсәне өмет итәм».

Әйтелде: «Әгәр намаз вакыты керсә, иблис гаскәренә боерыр. Таралырлар һәм кешеләр янына килеп аларны намазларыннан мәшгуль итәрләр. Бәс шайтан намаз укырга теләгән кеше янына килер. Ул кешене намаз вакытыннан кичектерү өчен мәшгуль итәр. Әгәр аңа көче җитмәсә, ул намазның рөкугъләрен, сәҗдәләрен, кыйраәтләрен, тәсбихләрен һәм догаларын тәмам итмәскә кушар. Әгәр көче җитмәсә, аның күңелен дөнья шөгыльләре белән мәшгуль итәр. Әгәр болардан берсенә дә көче җитмәсә, иблис бу шайтанны богауларга һәм диңгезгә атарга кушар. Әгәр шушылардан берсен булдыра алса, иблис аны хөрмәтләр һәм олуглар».

Аллаһы Тәгалә иблистән хикәят кылып әйтте:

﴿ لَأَقْعُدَنَّ لَهُمْ صِرَاطَكَ الْمُسْتَقِيمَ . ثُمَّ لَآتِيَنَّهُمْ مِنْ بَيْنِ أَيْدِيهِمْ
وَمِنْ خَلْفِهِمْ وَعَنْ أَيْمَانِهِمْ وَعَنْ شَمَائِلِهِمْ وَلَا تَجِدُ أَكْثَرَهُمْ شَاكِرِينَ ﴾

«Аларны, ягъни бәндәләреңне туры юлыңнан, Ислам юлыннан тыярмын. Алдыннан һәм артыннан килермен, ягъни аларга дөньяны зиннәтләп күрсәтермен, хәтта ул дөньяга күңел урнаштырырлар. Һәм

аларга уңнан, ягъни дин һәм тәгать ягыннан һәм сулларыннан, ягъни гөнаһлар ягыннан килермен. Аларның күбрәген шөкер кылучылар тапмассың, ягъни аларны нигъмәтләрең хозурына шөкер кылучылар тапмассың». (Әгъраф: 16, 17)

Икенче аятьтә әйтте:

﴿ يَابَنِي آدَمَ لَا يَفْتِنَنَّكُمْ الشَّيْطَانُ كَمَا أَخْرَجَ أَبَوَيْكُمْ مِنْ الْجَنَّةِ ﴾

«Әй адәм балалары! Ата-анагызны җәннәттән чыгарган кебек шайтан сезне дә фетнәләмәсен». (Әгъраф: 27)

﴿ الشَّيْطَانُ يَعِدُكُمْ الْفَقْرَ وَيَأْمُرُكُمْ بِالْفَحْشَاءِ ﴾

«Шайтан сезгә фәкыйрьлекне вәгъдә кыла һәм бозык эшләр белән боера». (Бәкара: 268)

﴿ إِنَّ الشَّيْطَانَ لَكُمْ عَدُوٌّ فَاتَّخِذُوهُ عَدُوًّا ﴾

«Дөреслектә, шайтан сезгә дошман. Сез дә аны дошман тотыгыз». (Фатыр: 6)

Аллаһы Тәгалә бәян кылды, шайтан адәм балалары өчен дошман. Аларны үзе белән җәһәннәм утына тартыр өчен, аларның азуларын тели. Акыллы кешегә үзен аңардан коткарыр өчен аның белән тарткалашырга тырышу ваҗиб була. Чөнки ул шайтан мөэминнәр өчен ачык дошман. Шайтан кебек мөэмин өчен тагын дошманнар бардыр.

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Мөэмин кеше биш төрле катылык арасында: хөсед кыла торган мөэмин; ачуландыра торган монафыйк; сугыша торган дошман; аздыра торган шайтан; котырта торган нәфес». Ягъни, аны аздырырга һәм котыртырга сәбәп булган нәрсәләргә нәфес авышучыдыр.

Мөселман кешегә дошманнары хозурына куәтле кылсын өчен, Үзе сөя һәм разый була торган

нәрсәләргә муафыйк кылсын өчен Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорау тиешле була. Чөнки боларның һәркайсында Аллаһы Тәгалә җиңел кылган кешегә җиңелдер.

Габдрахман бине Зәедтән риваять ителде. Ул әйтте: «Кайбер мәҗлесләрдә Муса белән бергә утыра идек. Шул чакта иблис килде. Аның башында төрле төстәге бүрек бар иде. Аңа якын килгәч, бүреген салды да куйды. Моннан соң каршы килеп сәлам бирде. Муса әйтте: «Син кем?» «Мин иблис», – диде. Муса әйтте: «Сине монда нәрсә китерде?» Иблис әйтте: «Аллаһы Тәгаләдән урының өчен сиңа сәлам ирештерергә килдем». Муса әйтте: «Башыңдагы бүрек нәрсә ул?» Иблис әйтте: «Аның белән адәм балаларының калепләрен тартам». Муса әйтте: «Адәм балалары гөнаһ кылса, сине аңа җиңүче кыла торган нинди гөнаһ икәнен хәбәр бирче». Иблис әйтте: «Әгәр нәфесе аны гаҗәпләндерсә, гамәлен күпкә санаса һәм кылган гөнаһысын онытса, мин аны җиңәмен».

Вәһәб бине Мүнәббәдән риваять ителде, ул әйтте: «Аллаһы Тәгалә иблискә Мөхәммәд галәйһиссәләм янына килергә һәм һәрбер соравына җавап бирергә кушты. Мөхәммәд галәйһиссәләм янына бер карт сурәтендә килде. Кулында таягы да бар иде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Син кем?» Ул әйтте: «Мин иблис». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Ни өчен килдең?» Иблис әйтте: «Аллаһы миңа синең яныңа килергә һәм һәр соравыңа җавап бирергә кушты». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй мәльгун минем өммәтемнән дошманнарың күпме?» Иблис әйтте: «Унбиш: син; тугры имам; түбәнчелекле бай; дөрес сатучы; Аллаһыдан куркучы галим; үгетләүче мөэмин; йомшак

күңелле мөэмин; тәүбәсендә торучы тәүбә кылучы; хәрамнан саклanучы; һәрвакытта таһарәтле мөэмин; күп садака бирүче мөэмин; кешеләр белән күркәм холыклы булган мөэмин; кешеләргә файда китерә торган мөэмин; укырга даимчылык кыла торган Коръән хафиз; кешеләр йоклаган вакытта төнлә уяу торучы кеше». Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Минем өммәтемнән дусларың кем?» Иблис әйтте: «Алар унау: җәбер кылучы солтан; тәкәбберле бай; алдаучы сатучы; исерткеч эчүче; сүз йөртүче; зина кылучы; ятим малын ашаучы; намазны җиңелгә санаучы; зәкәт бирмәүче; дөньяда озак торуны уйлаучы. Менә бу кешеләр минем иптәшләрем һәм кардәшләремдер».

Бер хәбәрдә зекер ителде. Бәни Исраил эчендә сумгада гыйбадәт кылучы бер ир бар иде. Ул кешегә Бәрсыйсәл-габид дип әйтелә иде. Аның догасы кабул кылына иде. Кешеләр аңа авырган кешеләрен китерәләр иде. Ул дога кылып, авыручылар төзәлә иде. Иблис шайтаннарны чакырды да: «Кем аны фетнәли алыр. Чөнки ул сезне гаҗиз итте», – диде. Шайтаннар арасыннан бер гыйфрит әйтте: «Мин фетнәләрмен. Әгәр мин аны фетнәли алмасам, мин синең дустың булмыйм». Иблис риза булды. Шайтан китте, хәтта Бәни Исраил патшаларыннан бер патшаның урынына килде. Ул патшаның бик матур бер кызы бар иде. Ул кыз атасы, анасы һәм апалары белән утыра иде. Аны дивана кылды. Ата-анасы моңа бик кайгырдылар. Берничә көн үткәч, шайтан аналары янына кеше сурәтендә килеп керде һәм әйтте: «Кызыгызның терелүен теләсәгез, аны фәлән руханига алып барыгыз. Ул аны имләр һәм дога кылыр, кызыгыз сихәтләнер». Кызны аңа алып бардылар. Аңа дога кылды һәм кыз авыруыннан

төзәлде. Кызны өйләренә алып кайткач, теге авыруы яңадан заһир булды. Аларга шайтан килеп тагын әйтте: «Әгәр кызыгызның төзәлүен теләсәгез, рухани янында берничә көн тотыгыз». Кызны илтеп, аның янында калдырыр. Рухани кабул итмәде. Ләкин үтенүләреннән соң риза булды, кызны калдырдылар. Рухани көндез ураза тотып, кичне аяк хозурында үткәрә иде. Әгәр рухани кызны туйдырырга утырса, авыруын изһар кыла һәм кача иде, аннан йөзен бора иде. Бер көнне рухани аның йөзенә һәм тәненә карады. Охшашын күрмәгән йөз белән тән күрде. Бәс рухани түзә алмады, ул кыз белән якынлык кылды. Кыз аннан йөкле булды. Моннан соң рухани янына шайтан килде һәм әйтте: «Ул кызны йөкле кылдың, патша сине газапламый калдырмас. Мәгәр син ул кызны үтереп, сумганда күмсәң генә, котылырсың. Әгәр ул кызны синнән сорасалар, син аларга: «Үләр вакыты иреште дә, үлде», – дип әйт. Шуннан соң кайтып китәрләр». Икенче риваятьтә, «ул кыз төзәлеп өенә кайтты», – дип әйт. Шуннан соң кайтырлар. Кайтып кардәшләренең өйләреннән эзләрләр». Аннан соң шайтан аталары янына китте һәм әйтте: «Рухани кызга якынлык кылды, аны йөкле ясады. Сизелүеннән курыккач, аны бугазлап, гыйбадәтханәсендә күмде. Патша кешеләр белән руханига китте, гыйбадәтханәдә казып, кызны бугазланган хәлдә таптылар. Аннан соң руханины тотып астылар. Шайтан асылган раһиб янына килеп әйтте: «Син эшләгән нәрсәләрне барын да мин эшләттем. Әгәр син Аллаһыдан узып, миңа бер тапкыр сәҗдә кылсаң, мин сине коткарырмын. Аларга ул кызны башка кеше бугазлаган икән, дип хәбәр бирермен. Алар миңа ышанырлар». Рухани әйтте: «Мин бу хәлдә ничек сәҗдә кыла алырмын?» Шайтан әйтте: «Миңа башың

белән генә булса да, ишарә кылсаң, мин ризамын». Бәс рухани шайтанга бер тапкыр сәҗдә кылды. Шайтан аңа әйтте: «Мин синнән бизүчемен». Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ كَمَثَلِ الشَّيْطَانِ إِذْ قَالَ لِلْإِنسَانِ اكْفُرْ فَلَمَّا كَفَرَ قَالَ إِنِّي بَرِيءٌ مِنْكَ إِنِّي أَخَافُ اللَّهَ رَبَّ الْعَالَمِينَ . فَكَانَ عَاقِبَتَهُمَا أَنَّهُمَا فِي النَّارِ خَالِدَيْنِ فِيهَا وَذَلِكَ جَزَاءُ الظَّالِمِينَ ﴾

«Монафыйкларның яһүдләргә ярдәм итәбез диюләре, шайтан кебектер ки, ул шайтан кешегә кәфер бул диде, ягъни иманнан, һидәяттән ерак булырга вәсвәсә кылды, ул кеше шайтанга ияреп кәфер булгач, шайтан әйтте: "Әй имансыз кеше, мин синнән бизүчемен, чөнки мин барча галәмне тәрбия кылучы Аллаһыдан куркамын", – дип. Шайтанга ияргән кеше белән шайтанның ахыр хәлләре, тәхкыйк, алар икесе дә утта мәңге калучылардыр. Җәһәннәм утында мәңге калу, залимнәрнең җәзасыдыр». (Хашер: 16, 17)

Фәкыйһ әйтте: «Бел, синең өчен дүрт дошман бар. Син аларның һәркайсы белән җиһад кылырга мохтаҗсың. Беренчесе, дөньядыр. Ул дөнья алдакчы һәм хәйләкәр. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ فَلَا تَغُرَّنَّكُمْ الْحَيَاةُ الدُّنْيَا وَلَا يَغُرَّنَّكُمْ بِاللَّهِ الْغَرُورُ ﴾

«Сезне дөнья тереклеге алдаламасын. Алдаучы сезне Аллаһыдан алдаламасын». (Локман: 33) Икенчесе, нәфесең. Нәфес дошманнарның явызрагы. Өченчесе, шайтан. Дүртенчесе, кешеләр арасыннан шайтан. Кешеләр арасындагы булган шайтаннан сакланыгыз. Чөнки ул җеннән булган шайтаннан катырактыр. Чөнки җеннән булган шайтанның зарары вәсвәсә белән генәдер. Кешеләрдән булган шайтан

усал иптәштер. Аның зарары капма каршы булыр. Ул һәрвакыт синең яхшы дәрәҗәле булуыңны теләгән булыр, ә үзе алган дәрәҗәңнән дә төшерер».

وروى شداد بن أوس ﷺ عن رسول الله ﷺ أنه قال : "الكيس من دان نفسه وعمل لما بعد الموت والفاجر من اتبع نفسه هواها ، وتمنى على الله عز وجل المغفرة".

Шәддәд бине Әүстән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Акыллы кеше шундый кешедер, нәфесенә якын булыр, үлгәннән соң кирәге өчен гамәл кылыр. Ягъни, дөньяда нәфесе белән хисаплашыр, үлгәннән соң файдалануы өчен тәгать, гыйбадәт кылыр. Гаҗиз кеше шундый кешедер, нәфес теләкләренә иярер дә, Аллаһы Тәгаләдән ярлыкау өмет итәр».

Гайсә бине Мәрьямнан риваять ителде. Ул әйтте: «Ничек һәлак булса да, һәлак булган кеше гаҗәеп түгел. Ләкин ничек тә котылса да, котылган кеше гаҗәеп. Ягъни җәннәт мәкрүһ нәрсәләр белән чолгап алынган. Ут шәһвәт белән чолгап алынган. Янә һәр нәфестә вәсвәсә кыла торган шайтан һәм илһам кыла торган фәрештә бар. Шайтан һәрвакыт нәфескә дөньяны зиннәтләп күрсәтә һәм алдый. Фәрештә һәрвакыт аннан тыядыр. Нәфес боларның кайсы белән булса, шунысы җиңәдер».

## Риза

Мәймүн бине Мәһраннан риваять ителде. Ул әйтте: «Гомәр бине Габделгазиз миңа һәр айда ике тапкыр килергә кушты. Бер көнне бардым, үзенең курганы түбәсеннән миңа карды, ишеккә ирешкәнемә чаклы миңа керергә рөхсәт бирде. Хәзер мин ничек

шулай кердем. Керсәм, ул үзенең паласына утырган да, күлмәген ямый. Аңа сәлам бирдем. Миңа сәлам кайтарды. Мине утырттты. Моннан соң әмирләребез, шарт кылган нәрсәбез, безнең түрәләребез, зинданнарыбыз һәм башка эшләребез хакында сорады. Моннан соң үземә махсус булган эшләрдән сорашты. Чыгарга дип кузгалгач, әйттем: «Әй мөэминнәрнең әмире, синең өй әһелең арасында шушы күлмәгеңне ямаучы кеше юкмыни?» Ул әйтте: «Әй Мәймүн, дөньяның сиңа урын булуы җитәр. Бүген без монда, иртәгә икенче урында». Соңыннан чыктым аны калдырдым».

Аллаһы Тәгаләнең:

﴿ وَإِذَا بُشِّرَ أَحَدُهُمْ بِالْأُنثَى ظَلَّ وَجْهُهُ مُسْوَدًّا وَهُوَ كَظِيمٌ ﴾

«Әгәр ул мөшрикләрнең берсенә "кыз балаң туган", дип сөенеч бирелсә, хатынына ачуланып, дусларыннан оялып, йөзе каралып китәдер» (Нәхел: 58), – дигән аятенең тәфсирендә, Котәдә әйтте: «Бу гарәп мөшрикләренең эшләре. Аллаһы Тәгалә безгә аларның эшләгән эшләренең начарлыгы белән хәбәр бирде. Әмма мөэмин, Аллаһы Тәгалә аңа өлеш итеп биргән нәрсәгә разый булуга лаеграктыр. Аллаһы Тәгаләнең тәкъдир кылуы ирнең үзе өчен тәкъдир кылуыннан изгерәктер. Әй адәм улы, син яратмый торган, Аллаһы Тәгалә тәкъдир кылган нәрсә, үзең сөя торган нәрсә белән үзең тәкъдир кылуыңнан изгерәк. Бәс Аллаһыдан саклан һәм Аллаһының тәкъдиренә разый бул».

Фәкыйһ әйтте: «Бу сүз Аллаһы Тәгаләнең сүзенә муафыйк:

﴿ وَعَسَى أَنْ تُحِبُّوا شَيْئًا وَهُوَ شَرٌّ لَكُمْ وَاللَّهُ يَعْلَمُ وَأَنْتُمْ لَا تَعْلَمُونَ ﴾

«Өметсез мәкруһ күргән нәрсәнең сезнең өчен изге булуын һәм өметсез сөйгән нәрсәнең сезнең

өчен мәкруһ булуын Аллаһы Тәгалә белә, сез белмисез». (Бәкара: 216) Ягъни, үзегез өчен файданы һәм динегез, дөньягыз өчен булган файданы сез белмисез. Мин тәкъдир иткән нәрсәгә разый булыгыз. Чөнки сез нәрсәдә файда барын белмисез.

Хәкимнәрнең берсе әйтте: «Тора торган урыннар дүрт төрледер: дөньядагы гомеребез; кабердә торыр вакытыбыз; Хашер вакытында торуыбыз; яратылуыбыз, аның өчен булган мәңгелек кайта торган урыныбыз. Ягъни җәннәт яки җәһәннәм. Дөньядагы гомеребезнең охшашы, хаҗ вакытында кичен ашаучы кебектер. Күчәргә ашыгып, анда карарланмыйлар һәм хайваннарын, йөкләрен дә чишмидер. Кабердә торуыбызның охшашы, кайбер урыннарга иңү кебектер. Йөкләрен куялар, бер көн яки бер кич ял итәләр дә, күчәләр. Хашердә торуыбызның охшашы, һәр яктан һәр төрле халык өчен гаятүл-иҗтимагъ булган Мәккәгә иңүләре кебек. Хаҗ гамәлләрен үтиләр дә, уңга да сулга таралалар. Шулай ук Кыямәт көнендә дә, әгәр хисаплашудан бушансалар, бер төрле фирка җәннәткә, бер төрле фирка җәһәннәмгә аерылышалар».

Шәкыйкъ әйтте: «Биш нәрсә хакында җиде йөз галимнән сорадым. Аларның барысы да бер җавапны бирделәр. «Акыллы кеше кем?» – дидем. Әйттеләр: «Акыллы кеше дөньяны сөйми торган кеше». Мин әйттем: «Аңлы кеше кем?» Әйттеләр: «Аны дөнья алдамаган кеше». Мин әйттем: «Бай кеше кем?» Әйттеләр: «Аллаһы өлеш итеп биргән нәрсәгә разый булучы кеше». Мин әйттем: «Фәкыйһ кем?» Әйттеләр: «Артыкны өстәүдән тартына торган кеше». Мин әйттем: «Саран кем?» Әйттеләр: «Малыннан Аллаһы хакын үтәми торган кеше».

Әйтелде: «Колга Аллаһының ачуы өч нәрсә хакындадыр: Аллаһы Тәгалә боерганын киметүе; Аллаһы Тәгалә өлеш итеп биргән нәрсәгә разый булмавы; бернәрсәне теләп, тапмагач Аллаһы Тәгаләгә ачулануы».

Кайбер хәкимнәр Аллаһы Тәгаләнең:

﴿ وَالسَّارِقُ وَالسَّارِقَةُ فَاقْطَعُوا أَيْدِيَهُمَا ﴾

«Карак ир һәм хатынның кулларын кисегез» (Мәидә: 38), – дигән аятенең тәфсирендә әйттеләр: «Кем дә кем ун дирһәм урласа, кул киселер. Бу ун дирһәм өчен генә хөрмәт юк, хәтта мөэмин ирнең кулы аның өчен киселер иде. Ләкин аның кулы ике төрле мәгънә өчен киселә. Бу ике мәгънәнең берсе мөселманнарның хөрмәтен ертканлыгы өчен, икенчесе, Аллаһы Тәгалә бүлеп биргән нәрсәгә разый булмыйча, икенче кешенең малына омтылганы өчен. Аллаһы Тәгалә кәсеп кылган нәрсәсенә җәза итеп һәм Аллаһы Тәгалә бүлеп биргән нәрсәгә разый булуларына башкаларга гыйбрәт булсын өчен аның кулын кисү белән боерды».

Мөэмин булган кешегә Аллаһы Тәгалә бүлеп биргән нәрсәгә разый булу тиешле. Чөнки Аллаһы бүлеп биргән нәрсәгә разый булу пәйгамбәрләрнең һәм изгеләрнең әхлаклары җөмләсеннәндер.

Әбү Дәрдәдән риваять ителде, ул әйтте: «Ун ике төрле сыйфат пәйгамбәрләр әхлагы җөмләсеннән: пәйгамбәрләр Аллаһының вәгъдәсенә ышанучы булдылар; кешеләргә ялынмадылар; дошманлыклары шайтан белән булды; үз эшләрен үзләре карыйлар иде; халыкка йомшак күңелле иделәр; барча халыкның җәфасын күтәрәләр иде; җәннәтне анык беләләр иде, ягъни изгелек кылсалар, Аллаһы Тәгалә аларның һәм гамәлләренең сәвабын тар кылмас, дип

ышанырлар иде; тиешле урыннарда түбәнчелекле булдылар; дошманлык урынында нәсыйхәтне дәгъва кылмыйлар иде; аларның маллары фәкыйрьлек иде, ягъни алар артык малны тотмыйча, фәкыйрьләргә нәфәка кылалар иде; тәһарәткә даимчылык кылалар иде; дөньядан тапкан нәрсәләре белән шатланмыйлар иде һәм дөньядан югалткан нәрсәләренә үкенмиләр иде».

Кайбер галимнәр әйттеләр: «Заһидларның хөрмәте ун төрле әйбер. Беренчесе, шайтанга дошманлык кылу. Шайтанга дошманлыкны үзләренә важиб күрерләр:

﴿ إِنَّ الشَّيْطَانَ لَكُمْ عَدُوٌّ فَاتَّخِذُوهُ عَدُوًّا ﴾

«Шайтан сезгә дошман, сез дә аны дошман тотыгыз». (Фатыр: 6) Икенчесе, алар дәлилсез гамәл кылмаслар. Ягъни алар Кыямәт көнендә алар өчен нык дәлил булган вакытта гына гамәл кылырлар.

﴿ قُلْ هَاتُوا بُرْهَانَكُمْ إِنْ كُنتُمْ صَادِقِينَ ﴾

«Әйт, әгәр тугры булсагыз, дәлилегезне китерегез». (Бәкара: 111) Өченчесе, алар үләргә әзер икәнлекләрен белерләр.

﴿ كُلُّ نَفْسٍ ذَائِقَةُ الْمَوْتِ ﴾

«Һәр җан үлем ачысын татучыдыр». (Әли Гыймран: 185) Дүртенчесе, Аллаһы юлында сөярләр һәм Аллаһы юлында дошман тотарлар.

﴿ لَا تَجِدُ قَوْمًا يُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ يُوَادُّونَ مَنْ حَادَّ اللَّهَ وَرَسُولَهُ وَلَوْ كَانُوا آبَاءَهُمْ أَوْ أَبْنَاءَهُمْ أَوْ إِخْوَانَهُمْ أَوْ عَشِيرَتَهُمْ أُولَئِكَ كَتَبَ فِي قُلُوبِهِمُ الْإِيمَانَ ﴾

«Аллаһыга һәм ахирәт көненә иман китергән кешеләр җөмләсеннән Аллаһыга һәм Аның Рәсүленә хилафлык кылучыны дус тоткан, дип күрмәссең,

гәрчә алар аталары, улллары, кардәшләре, яки кабиләләре булсалар да. Менә шул кешеләрнең калепләренә иман язылды». (Мөҗәдәлә: 22) Ягъни, мөэмин булган кешенең Аллаһының боерыгына каршылык кыла торган кеше белән дуслыгы булмас, гәрчә ул атасы, улы, кардәше, яки кабиләсеннән булса да. Бишенчесе, алар яхшылык белән боерырлар, яманлыктан тыярлар.

﴿ وَأْمُرْ بِالْمَعْرُوفِ وَانْهَ عَنِ الْمُنكَرِ وَاصْبِرْ عَلَى مَا أَصَابَكَ إِنَّ ذَلِكَ مِنْ عَزْمِ الْأُمُورِ ﴾

«Яхшылык белән боер, яманлыктан тый, сиңа авырлыктан ирешкән нәрсәгә сабыр ит, менә бу эшләрнең чынлыгыннандыр». (Локман: 17) Алтынчысы, алар Аллаһының эшендә уйланырлар һәм гыйбрәт күзе белән карарлар.

﴿ وَيَتَفَكَّرُونَ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ ﴾

«Алар күкләрнең һәм җирнең яратылышында уйланырлар». (Әли Гыймран: 191)

﴿ فَاعْتَبِرُوا يَاأُولِي الْأَبْصَارِ ﴾

«Әй аң ияләре, гыйбрәт белән карагыз». (Хәшер: 2) Җиденчесе, фикерләү сәбәпле калепләрен Аллаһының ризалыгы булмаган нәрсәдән сакларлар. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ إِنَّ السَّمْعَ وَالْبَصَرَ وَالْفُؤَادَ كُلُّ أُولَئِكَ كَانَ عَنْهُ مَسْئُولًا ﴾

«Колак, күз һәм күңел боларның барсыннан да соралачак». (Исра: 36) Сигезенчесе, Аллаһының мәкереннән имин булмаслар. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿ فَلَا يَأْمَنُ مَكْرَ اللَّهِ إِلَّا الْقَوْمُ الْخَاسِرُونَ ﴾

«Аллаһының мәкереннән тыныч булмас, мәгәр мәхрүм булган кавем генә». (Әгъраф: 99) Тугызын-

чысы, Аллаһының рәхмәтеннән өмет өзмәсләр. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿لَا تَقْنَطُوا مِنْ رَحْمَةِ اللَّهِ إِنَّ اللَّهَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ جَمِيعًا إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ﴾

«Аллаһының рәхмәтеннән өмет өзмәгез, Аллаһы Тәгалә барча гөнаһларны ярлыкар. Ул Аллаһы бик ярлыкаучы, бик рәхмәтледер». (Зүмәр: 53) Унынчысы, дөнья нәрсәсенең килүенә шатланмаслар һәм дөнья нәрсәсенең китүенә кайгырмаслар. Аллаһы Тәгалә әйтте:

﴿لِكَيْلَا تَأْسَوْا عَلَى مَا فَاتَكُمْ وَلَا تَفْرَحُوا بِمَا آتَاكُمْ﴾

«Сездән үткән нәрсә өчен өметсез булмавыгыз өчен һәм сезгә килгән нәрсә белән шатланмавыгыз өчен». (Хәдид: 23) Ягъни, кол, аннан үткән нәрсәдәме, яки аңа килгән нәрсәдәме файда барын белмидер. Бәс һәр ике хәлдә бәрабәр булу тиешле. Мөэминнең охшашы нарат агачы кебектер. Нарат агачы эссе вакытта да, салкын вакытта да бер төрле булыр. Монафыйкның охшашы гөл кебек. Аз гына афәт ирешсә дә, үзгәрә. Шулай ук мөэмин дә, катылыкта да, киңлек вакытында да, хәле бер булыр. Ул Аллаһы Тәгалә өлеш биргән нәрсәгә разый булыр. Әмма монафыйк Аллаһы Тәгалә өлеш итеп биргән нәрсәгә разый булмас, нигъмәт вакытында золымлык кылыр, катылык вакытында аһ орыр. Бәс мөэмин булган кешегә пәйгамбәрләрнең һәм заһидләренең фигыльләренә ияру тиеш була. Кәферләрнең һәм монафыйкларның фигыльләренә ияреpгә тиешле түгелдер.

### Вәгазь бүлеге

Әбү Сәгыйд Худридән риваять ителде. Ул әйтте: «Безгә икенде намазыннан соң кояш батар-батмас

вакытка кадәр Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм вәгазь сөйләде. Рәсүлуллаһның ул вәгазен саклаган кеше саклады, оныткан кеше онытты. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм вәгазендә әйтте: «Сак булыгыз! Дөнья татлы яшеллек. Аллаһы Тәгалә сезне анда калдыручы. Һәм Аллаһы сезнең ни эшләгәнегезне карый. Аң булыгыз, Аллаһыдан һәм хатыннарыгызга җәбер кылудан сакланыгыз. Сак булыгыз, адәм уллары төрле дәрәҗәдә яратылдылар. Алар җөмләсеннән мөэмин булып туган, мөэмин булып яшәгән һәм мөэмин булып үлгәне бар. Алардан мөэмин булып туган, мөэмин булып яшәгән, кәфер булып үлгәне бар. Алардан кәфер булып туган, кәфер булып яшәгән, мөэмин булып үлгәне бар. Сак булыгыз, ачу – адәм улының кальбендә яндырылган ялкындыр. Ачу вакытында ике күзнең кызарганын һәм муен тамырларының күпергәнен күрмисезме?! Кем дә кем моннан бер нәрсәне тапса, ягъни ачуны сизсә, җиргә карасын. Аң булыгыз, ирләрнең изгерәге әкрен ачулы булган һәм ачуыннан тиз кайтулы булганыдыр. Әгәр тиз ачулы һәм тиз ачуыннан кайтучы булса, ул моның бәрабәренә булыр, ягъни гөнаһысы да, савабы да булмас. Адәмнәрнең явызрагы тиз ачулы булып та, ачуыннан әкрен кайтканыдыр. Әгәр әкрен ачулы һәм ачуыннан әкрен кайтулы булса, ул моның бәрабәренә булыр, ягъни изгелеге дә, явызлыгы да булмас. Аң булыгыз, сатучыларның изгерәге – соравы да, үтәве дә күркәм булганыдыр. Әгәр соравы күркәм булып, үтәве яман булса, ул моның бәрабәренәдер. Аң булыгыз, сатучыларның явызрагы соравы да, үтәве дә яман булганыдыр. Әгәр соравы яман булып үтәве күркәм булса, ул моның бәрабәренәдер. Аң булыгыз, һәр алдаучы өчен әләм булыр, Кыямәт көнендә ул аның белән танылыр. Сак

булыгыз, имамның халыкны алдавыннан олырак алдау юктыр. Сак булыгыз, сугышның артыграгы – җәбер кылучы имам алдында тугры булган сүзне әйтү. Аң булыгыз, берегезне дә адәмнәрдән курку хакны әйтүеннән тыймасын. Әгәр күрсә һәм белсә, куркып тормасын, хакны әйтсен. Сак булыгыз, дөньядан үткән кадәр калмады, мәгәр шушы кояштан батарга күпме калды исә, дөньядан да шулкадәр генә калды».

Әбү Һөрәйрәдән риваять ителде. Ул әйтте: «Без Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм белән Хөнәйн сугышы көнендә хәзер булдык. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм, мин мөселман, дип дәгъва кылучы бер иргә ишарәләп, менә бу тәмуг әһеленнән, диде. Бу ир дә сугышта хәзер булып, бик каты сугышты. Бәс Рәсүлуллаһның сәхабәләреннән бер ир Рәсүлуллаһка килде дә: «Әй Рәсүлуллаһ! Менә бу тәмуг әһеленнән дип сөйләгән ирне күрдеңме? Аллаһы белән ант итәм, ул Аллаһы юлында бик каты сугыша», – диде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Сак бул, ул тәмуг әһеленнәндер». Кайбер кешеләр шөбһәләнә иде. Шул арада ул ир җәрәхәт авыртуын сизде. Ук савытына кулын тыкты, аннан укны чыгарды. Кәлимә мөнкәрне әйтте дә, үз-үзен бугазлады. Мөселманнардан күп кеше моны күреп, Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм янына йөгерештеләр. «Аллаһы Тәгалә синең сүзеңне раска чыгарды. Теге кеше гөнаһ эшләп үз-үзен үтерде», – диделәр. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әй фәлән, тор! Җәннәткә һичкем кермәс, мәгәр мөэмин булган кеше генә керер». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Гамәлләр бары соңгылары беләндер. Намазның һәм уразаның күплегенә игътибар юк. Бары тик эшнең ахырына каралыр».

Габдулла бине Мәсгудтән риваять ителде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Сезнең берегезнең яратылышы анасының карынында кырык көн су (мәни) булып җыелыр. Соңыннан кырык көн аерчык кан булыр. Соңыннан кырык көн ит кисәге булып җыелыр. Моннан соң аңа дүрт кәлимә бирергә фәрештә җибәрелер. Ул фәрештәгә аның үләр вакытын, әмәлен, гамәлен һәм ризыгын яз дип, әйтелер. Янә ул бәхетсезме яки бәхетлеме, шуны да яз дип, әйтелер. Ир җәннәт әһеленең гамәлен кылыр, хәтта ул ир белән җәннәт арасында бер аршын микъдары гына калыр. Бәс аның хозурына язмыш өстен булыр да, тәмуг әһеленең гамәле белән соңланыр да, тәмугка керер. Сезнең берегез тәмуг әһеленең гамәлен кылыр, хәтта аның белән тәмуг арасында бер аршын гына калыр, бәс аңа язмыш өстен булыр, ул җәннәт әһеленең гамәле белән соңланыр да, җәннәткә керер». Бу хәдис әүвәлге «гамәлләр соңлары белән», дигән хәдискә муафыйк. Һәр мөселманга Аллаһыдан хатимәсенең изге булуын сорау вәҗиб була. Чөнки актык сулышта иманның чыгуыннан бик куркыладыр.

Яхъядан риваять ителде, ул:

اللهم إن أكثر سروري فيما أكرمتني الإيمان وأخاف أن

تنزعه مني فما دام هذا الخوف معي أرجو أن لا تنزعه مني

«Аллаһүммә иннә әксәра сүрурии фиимәә әкрамтәнии бил-имәәни үә әхафүән тәнзәгаһү миннии фәмәә дәәмә һәзәл-хауфү мәгый әрҗүүән ләә тәнзәгаһү миннии», – дип дога кыла иде.

Әбү Касимнән Самаркандта: «Гөнаһ кылу сәбәпле колдан иман сөреләме?» – дип сорадылар. Әйтте: «Әйе, өч төрле гөнаһ белән колдан иман

сөрелер: Аллаһы Тәгалә аны иман белән хөрмәтләгән өчен, Аллаһыга шөкер кылмау; иманның аннан китүеннән курыкмау һәм Ислам әһелләренә золым кылу».

Хәсән Басридән риваять ителде. Ул әйтте: «Ир утта җитмеш ел газап кылыныр. Моннан соң уттан оҗмахка чыгарылыр». Моннан соң: «Әй, мин шул ир булсамчы». Хәсән болай дип әйтте, чөнки ул эшнең ахыры ни булуыннан куркыр иде. Менә шулай изгеләр эшләрнең ахыры ни булачагыннан куркалар иде.

## Хикәяләр

Әнәстән риваять ителде. Ул әйтте: «Бер кеше Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм янына килде һәм әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, минем каралыгым һәм йөземнең ямьсезлеге җәннәткә керүемнән тыярмы?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Нәфесем Аның кодрәтендә булган Аллаһы Тәгалә белән ант итеп әйтәмен, әгәр Раббыгызны анык белсәң һәм Рәсүле китергән нәрсәгә иман китерсәң, алар җәннәттән тыймый». Теге ир әйтте: «Сине пәйгамбәрлек белән хөрмәтләгән Аллаһы белән ант итеп әйтәмен, лә иләһә илләллаһ вә әннә мүхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһү, дип шушы мөҗлескә утыруымнан сигез ай элек шәһадәт китердем. Дәхи мин синең алдыңда булган һәм булмаган кешеләрне өндәдем. Алар мине, каралыгым һәм йөземнең ямьсезлеге сәбәпле кире кактылар. Мин Бәни Сәлим кавеменнән нәселле бер кешемен, ләкин миңа кыз кардәшләремнең каралыгы өстен булды». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Бүген Гамрү бине Вәһһаб хәзер булдымы? Ул Бәни Сәкыйфтән Исламга яңа гына килгән бер ир

иде». Әйттеләр: «Юк». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм ул ирдән: «Аның өен беләсеңме?» – дип сорады. Әйтте: «Беләм». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Бар, җиңелчә генә ишеген как. Соңыннан сәлам бир. Кергәч, Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм синең кызыңны миңа өйләндер диде, дип әйт». Аның чибәр һәм акыллы бер кызы бар иде. Бу ишеккә килеп каккач һәм сәлам биргәч, гарәп сүзен ишетүләреннән шатландылар, ишекне ачтылар. Аның каралыгын һәм йөзенең ямьсезлеген күргәч, аннан тартындылар. Рәсүлуллаһ сезнең кызыгызны миңа өйләндерде, диде. Бәс аны начар кайтару белән кайтардылар. Ир чыкты да китте, хәтта Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм янына килде. Бәс кызы атасына әйтте: «Әй әткәм! Вәхи килеп фаш иткәнгә кадәр котылырга ашык. Әгәр Рәсүлуллаһ мине аңа никахландырган булса, Аллаһы һәм Рәсүле разый булган нәрсә бәрабәренә мин разый булдым». Карт чыгып Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмгә килде дә мәҗлеснең түбәненә утырды. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Синме Аллаһының рәсүлен кире кайтаручы?» Ул әйтте: «Эшләвен эшләдем, инде хәзер Аллаһыдан ярлыкауны сорыймын. Мин аны ялганлап әйтә, дип уйладым. Дөрес сөйләгәч, аңа кызымны никахландырам. Аллаһының һәм Рәсүленең ачуыннан Аллаһыга сыенам». Дүрт йөз дирһәм бәрабәренә кызны аңа никахландырды. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм иргә әйтте: «Сахибеңә, ягъни хатыныңа бар». Ир: «Сине хак итеп җибәргән Аллаһы белән ант итәмен, мин бер нәрсә дә таба алмадым, хәтта кардәшләремнән сорар идем», – диде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Хатыныңның мәһәрен мөэминнәрдән өч кешедән сора. Бар Госманга аннан ике йөз дирһәм ал». Госманга барды да, ул ике йөз дирһәмнән арттырып та бирде.

«Габдрахман ибен Гауфкә бар, аннан ике йөз дирһәм ал», – диде. Ул да арттырып бирде. «Галигә бар, аннан да ике йөз дирһәм ал», – диде. Ул да арттырып бирде. Шул арада ул хатынына сатып алган нәрсәсе белән базарда иде. Бер җәмәгатьнең тавышын ишетте, «Аллаһының атына атлан», – дип кычкырды. Ягъни Рәсүлуллаһның кычкыручысы җәмәгатькә, дип кычкырыр иде. Бер тапкыр күккә карады да: «Әй күкләрнең, җирнең һәм Мөхәммәднең илаһысы булган Аллаһы, әлбәттә, бүген бу дирһәмнәремне Аллаһы, Рәсүле һәм мөэминнәр сөйгән нәрсәгә тотамын», – диде. Ат, кылыч, сөңге һәм калкан сатып алды. Янә чалмасы белән бары күз кыйылары гына күренерлек итеп эчен һәм башларын урады, хәтта мөһаҗирләрнең янына килеп туктады. Бу нинди без танымаган кеше диделәр. Хәзрәти Гали аларга әйтте: «Куегыз, бәлки ул Бәхрәйннән яки Шам тарафыннан килгәндер. Диңгезнең галәмәтләреннән сорый килгәндер. Бүген сезгә үзен иялэштерүен сөяр». Ул сөңгесе белән кадарга, кылычы белән сугарга башлады, хәтта аның белән аты юнләде. Иңеп, кулларын сызганды, сугышка хәзерләнде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм аның кара беләкләрен күргәч таныды һәм әйтте: «Син Сәгъдме?» Әйтте: «Әйе». Һәрвакыт сөңгесе белән кадаса, яки кылычы белән сукса, Аллаһының дошманнарын үтерә иде. Шул чакта Сәгъд егылды, диделәр. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм чыгып, аңа таба юнәлде. Аның янына килеп, башын күтәрде дә, итәгенә куйды. Киеме белән йөзеннән туфракны сөртте. «Исең ни хуш ки, Аллаһыга һәм Рәсүленә сине сөйдерде», – диде. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм елады, соңыннан көлде дә йөзен алды. «Моннан соң хаудга килде», – диде. Әбү Ләбәбә әйтте: «Атам-анам сиңа фида булсын,

хауд нәрсә ул?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Ул хаудны Аллаһы Тәгалә миңа бирде. Аның киңлеге Сонга белән Басра арасы кадәрле. Тарафлары энҗе һәм якут белән капланган. Суы сөттән ак, балдан татлырактыр. Кем дә кем аның суыннан бер тапкыр эчсә, мәңге сусамас». Әбү Ләбәбә әйтте: «Сине күрдек, еладың, көлдең, аннан соң йөзеңне алдың». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Әмма елавымның сәбәбе – Сәгъдкә кызыгып еладым. Әмма көлүем – Аллаһыдан дәрәҗәгә менүенә, Аллаһының аны хөрмәтләвенә шатландым. Йөземне алуым – хур кызлардан булган аның хатыннарын күрдем, балтырларын ачып, балдакларын изһар кылып, аңа ашыгып киләләр. Бәс алардан оялып йөземне алдым». Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм аның коралын һәм атын һәм анда булган башка нәрсәләрне алырга кушты. Аны хатынына алып барыгыз. Аллаһы Тәгалә аңа сезнең кызыгыздан изгерәкне никахландырды, дип әйтегез», – диде.

Хикәя. Гали бине Әбү Талибтән риваять ителде, ул әйтте: «Пәйгамбәребез галәйһиссәләм мөселманнарны бер-берсенә кардәш итеп кушкач, Сәгыйд белән Сәгъләбәне дә кардәш кылды. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм Табук сугышын башлагач, Сәгыйд тә сугышка чыкты, кардәше Сәгъләбәне әһеле янында калдырды. Аның әһеленә аркасына күтәреп утын һәм су ташый иде. Боларда Аллаһыдан саваб өмет итә иде. Бер көнне Сәгъләбә килде дә, өйгә керде. Бәс аның янына иблис килде. Иблис Сәгъләбәгә пәрдә артына кара, диде. Сәгъләбә пәрдәне күтәреп, кардәшенең хатынын күрде. Ул бик матур хатын иде. Түзә алмады, ул хатын янына керде дә тотты. Хатын аңа әйтте: «Әй Сәгъләбә, Аллаһы юлында сугыша торган кардәшеңнең хөрмәтен саклый алмадың».

Сәгъләбә: «Ни үкенеч миңа», – дип кычкырды. Качып тау ягына йөгерде. Актык тавышы белән нида кылды:

إلهي أنت أنت وأنا أنا أنت العواد بالمغفرة وأنا العواد بالذنوب والخطايا

Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм сугышыннан кайткач, кардәш кушылган кешеләр бер-берсенә юлыкты. Сәгыйднең кардәш кушылган кешесе каршы алмады. Сәгыйд өенә кайтып хатынына әйтте: «Аллаһы юлында кардәш кушылган кардәшем ни эшләде?» Хатыны әйтте: «Ул үз-үзен гөнаһ диңгезләренә ташлады. Тауга качып китте». Сәгыйд кардәшен эзләп чыкты. Аны башына кулын куйган һәм йөзтүбән елаган хәлдә тапты һәм ул актык тавышы белән кычкырды:

واذل مقاماه مقام من عصى ربه

Бәс Сәгыйд: «Тор, әй кардәшем, сиңа ни булды?» – диде. Сәгъләбә әйтте: «Син кулымны муеныма багълаганчы, мин синең белән тормыйм. Хур булган кол иясенең ишегеннән ничек сөрелә, син дә мине шулай сөрерсең». Бәс шулай эшләде. Аның Хамсәнә исемле бер кызы бар иде. Ул кыз атасын җитәкләп, хәзрәти Гомәр ишегенә китерде. Аңа керде. Хәзрәт Гомәргә: «Мин Аллаһы юлында сугыша торган кардәшемнең хатынын тоткан идем. Минем өчен тәүбә булыр микән?» – диде. Хәзрәти Гомәр: «Каршымнан чык, әле мин сине чәчеңнән тотып каршымнан чыгарырга уйлаган идем. Минем каршымда сиңа тәүбә юк», – диде. Хәзрәти Гомәр каршыннан китеп, хәзрәти Әбү Бәкергә барды. Аңа кергәч әйтте: «Мин Аллаһы юлында сугыша торган кардәшемнең хатынын тоткан идем. Минем өчен тәүбә булырмы?» Әбү Бәкер әйтте: «Чык каршымнан, утың белән мине яндырма, каршымда сиңа һич тәүбә

юк». Әбү Бәкер каршыннан хәзрәти Гали ишегенә килде һәм әйтте: «Аллаһы юлында сугыша торган кардәшемнең хатынын тоткан идем. Минем өчен тәүбә булырмы?» Гали әйтте: «Чык, минем каршымда сиңа мәңге тәүбә юк». Хәзрәти Гали яныннан чыкты, хәлбуки, ул әйтте: «Әй кардәшем, әй кызым, болар мине өметсез кылдылар. Рәсүлуллаһ мине өметсез итмәс, дип өметләнәм». Кызы аны Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм ишегенә алып килде. Рәсүлуллаһ янына кергәч Рәсүлуллаһ аңа карады да әйтте: «Тәмугның зинҗир һәм богауларын исемә төшерденң». Әйтте: «Әй Пәйгамбәр, атам-анам сиңа фида булсын, мин Аллаһы юлында сугыша торган кардәшемнең хатынын тоткан идем. Минем өчен тәүбә булырмы?» Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Чык каршымнан, минем каршымда сиңа мәңге тәүбә юк». Чыкты. Кызы аңа әйтте: «Әй әтием! Мөхәммәд галәйһиссәләм һәм аның сәхабәләре синнән разый булганчы, мин сиңа кыз, син миңа ата булмассың». Бәс Сәгъләбә качып тауга китте. Актык тавышы белән нида кылды: «Әй Раббым! Гомәргә килдем, ул миңа сукмакчы булды. Әбү Бәкергә килдем, ул мине ачуланды. Галигә килдем, ул мине куды. Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә килдем, ул мине өметсез итте. Син ни эшләрсең, әй Мәүләм. Минем үтенечемә ярар дип әйтерсеңме, яки юк дип әйтерсеңме? Әгәр юк дип әйтсәң, ни кайгы, ни бәхетсезлек һәм ни үкенечтер миңа! Әгәр ярар дип әйтсәң, минем өчен ни сөенеч!» Күктән бер фәрештә каршы булып, Рәсүлуллаһ галәйһиссәләмгә әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйтә: «Халыкны синме яраттың, әллә Минме?» Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Юк, мин түгел, Син, әй Сәййидем». Фәрештә әйтте: «Аллаһы Тәгалә: «Минем колыма сөенеч бир, мин аны ярлыкадым»,

диядер». Бәс Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм: «Миңа Сәгъләбәне кем китерә?» – диде. Әбү Бәкер белән Гомәр тордылар: «Әй Рәсүлуллаһ, аны без китербез», – диделәр. Гали белән Салман тордылар һәм әйттеләр: «Әй Рәсүлуллаһ, аны без китерербез». Гали белән Салманга рөхсәт бирде. Алар чыгып, тауга таба юнәлделәр. Мәдинәнең бер көтүчесенә очрадылар. Хәзрәт Гали көтүчегә әйтте: «Рәсүлуллаһның сәхабәләреннән булган бер ирне күрмәдеңме?» Көтүче әйтте: «Әллә сез тәмугтан качучы кешене эзлисезме?» Болар әйттеләр: «Әйе, аның урынын безгә күрсәтче». Әйтте: «Әгәр аңа кич караңгыланса, ул шушы чокырга хәзер була, хәтта шушы агач астына килә. Моннан соң актык тавышы белән кычкыра:

واذل مقاماه مقام من عصى ربه

Болар кич караңгыланганчы тордылар. Шул чакта Сәгъләбә күренде, агач төбенә килеп, елап сәҗдә кылды, агачның астына бөгелде. Салман аның елавын ишеткәч янына барды һәм әйтте: «Тор, Сәгъләбә, Аллаһы Тәгалә сине ярлыкады». «Дустым Мөхәммәд галәйһиссәләмне ничек калдырдыгыз?» – диде. Салман әйтте: «Аллаһы һәм син сөйгәнче калды». Билал намазга камәт әйткәч, аны мәчеткә китерделәр. Ахыргы сафта торгыздылар. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм кыйраәт укып; اَلْهَاكُمُ التَّكَاثُرُ , дигәч, Сәгъ-ләбә бик каты сулады. Рәсүлуллаһ; حَتَّى زُرْتُمُ الْمَقَابِرَ аятен укыгач, ике тапкыр каты сулады да, дөньядан аерылды. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм бушангач, Сәгъләбә янына килде һәм: «Әй Салман, су сип», – диде. Салман әйтте: «Әй Рәсүлуллаһ, ул дөньядан аерылды». Кызы килеп: «Әй Рәсүлуллаһ, атам ни

эшләде?» – дип сорады. Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм: «Мәчеткә кер», – диде. Кызы мәчеткә керсә, атасы үлгән икәнен күрде. Кулын башына куйды. Моннан соң: «Ни кайгы, синнән соң кем миңа, әй әткәм?» – дип елады. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Хамсанә, мин сиңа ата, Фатыйма кардәш булуга разый булмыйсыңмы?» «Әйе, разыймын», – диде. Сәгъләбәне күтәргәч, Рәсүлуллаһ аның җәназасына иярде, хәтта кабер читенә ирешкәч бармак очларында гына йөрергә кереште. Күмеп кайткач, хәзрәти Гомәр: «Әй Рәсүлуллаһ, бармак очларыңда йөргәнеңне күрдем», – диде. Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Әй Гомәр, фәрештәләр бик күп булганлыктан аягымның табанын куярга көчем җитмәде».

## Үз-үзен саткан егетнең хикәясе

Габделвәхид бине Зәйдтән риваять ителде. Ул әйтте: «Көннәрдән бер көндә бер мәҗлестә идек. Сугышка чыгарга хәзерләнгән идек. Иптәшләремә дә иртәгесен сугышка хәзерләнүләре белән боердым. Мәҗлесебездә бер ир укыды:

﴿ إِنَّ اللَّهَ اشْتَرَى مِنَ الْمُؤْمِنِينَ أَنفُسَهُمْ وَأَمْوَالَهُم بِأَنَّ لَهُمُ الْجَنَّةَ ﴾

«Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә мөэминнәрдән нәфесләрен һәм малларын сатып алды. Алар өчен җәннәт». (Тәүбә: 111) Бәс унбиш яшь чамасындагы бер егет торды. Ул егетнең атасы үлгән дә, аңа күп мал мирас итеп калдырган иде. Ул егет: «Әй Габделвәхид, Аллаһы Тәгалә мөэминнәрдән нәфесләрен һәм малларын сатып алса, аларга җәннәтме?» Мин әйттем: «Әйе». Ул әйтте: «Әй Габделвәхид, мин сине шаһид кыламын, мин нәфесемне һәм малымны

җәннәт бәрабәренә саттым». Мин әйттем: «Кылыч йөзе моннан катырак, әле син сабый, син сабыр итмәсәң, бу сатудан да гаҗиз булырсың, дип куркам». Ул әйтте: «Әй Габделвәхид, мин җәннәт бәрабәренә Аллаһы белән сату итешәм, гаҗиз булсам булырмын. Мин сине шаһид кылам, мин Аллаһы Тәгалә белән сату итешәм». Мин әйттем: «Безнең нәфесләребез тарайды. Сабый бит эшли, ә без эшләмибез, дидек». Егет аты, коралы һәм нәфәкасыннан башка бар малын да садака кылды. Сугышка чыгар көн җиткәч, безгә килүче иң элек ул булды. Ул әйтте: «Әссәләмү галәйкүм Габделвәхид». Мин аңа сәламен кайтардым. Моннан соң киттек, ул безнең белән көндез ураза тота, кичен уяу тора. Безгә хезмәт итә, хайваннарыбызны көтә, йокласак саклый, хәтта Рум йортына җиттек. Бер көнне шулай торганда, бу егет кычкырырга кереште: واشوقاه إلى العيناء المريضة дип. Хәтта иптәшләрем: «Әллә бу егет вәсвәсәләнде, әллә акылы зәгыйфьләнде микән», – диделәр. Хәтта якын булды һәм кычкырырга кереште: يا عبد الواحد لا صبر لي واشوقاه إلى العيناء المريضة дип. Мин әйттем: «Әй дустым, әл-гайнәәл-мардыйә, дип әйткәнең нәрсә ул?» «Мин аз гына йоклаган идем, йокымда гүя ки бер килүче килде дә, миңа, сине гайнәәл-мәрдыйәгә алып китәм, диде. Бәс мине бер бакчага китерде. Ул бакчада суы бер дә үзгәрми торган елга бар. Елганың кырыенда җәриятәр. Ул җәриятәрнең өстендә әйтеп бетергесез бизәкләр һәм хөлләләр бар. Бу җәриятәр мине күргәч шатландылар һәм: «Гайнәл-мардыйәнең ире килгән икән», – диделәр. Мин сәлам бирдем, гайнәл-мардыйә сезнең

эчегездәме, дидем. Алар әйттеләр: «Юк, без аның ялчылары һәм кәнизәкләре, алдыңа бар». Бардым. Килсәм бер елга, анда тәме һич үзгәрми торган сөт, үзе бакча эчендә. Анда һәртөрле зиннәт һәм җәрияләр. Мин аларны күргәч, чибәрлекләренә һәм матурлыкларына гашыйк булдым. Болар мине күргәч шатландылар, бу гайнәл-мардыйәнең иредер, яныбызга килгән, диделәр. Мин сәлам бирдем, гайнәл-мардыйә сезнең эчегездәме, дип сорадым. Алар: «Сиңа дә сәлам, әй Аллаһының вәлие. Без аның ялчылары һәм кәнизәкләребез, алдыңа атла», – диделәр. Атладым. Болынның кырыенда хәмердән булган икенче бер елга күрдем. Анда да җәрияләргә юлыктым, алар шул кадәр матур ки, әүвәлгеләрен оныттырдылар. Аларга сәлам бирдем, гайнел-мардыйә сезнең эчегездәме, дип сорадым. Алар: «Юк, без аның кәнизәкләре, алдыңа үт», – диделәр. Үттем. Анда саф балдан булган өченче бер елга һәм бакча. Ул бакчада җәрияләр, аларның матурлыгы һәм нуры үткәннәрне оныттырды. Аларга сәлам бирдем, гайнел-мардыйә сезнең эчегездәме, дидем. Әй вәли Рахман. без кәнизәкләре генә, алдыңа үт, диделәр. Үттем. Эче энҗеләнгән чатырга төштем. Чатырның ишегендә җәрия. Ул җәрия өстендә бизәкләр һәм әйтеп бетергесез хөлләләр. Ул җәрия мине күргәч шатланды һәм чатырга: «Әй Гайнел-мардыйә, менә ирең килде», – диде. Чатырга якын булдым һәм аңа кердем. Ул урындыгы хозурына утырган. Урындыгы алтыннан, энҗе һәм якут белән бизәлгән. Мин аны күреп, гашыйк булдым. Ул: «Рәхим ит, вәлийү-рахман, сиңа безгә килү якын булды», – диде. Аны кочарга теләдем. Ул: «Тукта, чөнки сиңа әле миңе кочакларга вакыт ирешмәгән. Әле синдә хаят рухы бар. Аллаһы теләсә, бүген

безнең каршыбызда ифтар кылырсың», – диде. Әй Габделвәхид, көям, чыдар хәлем юк. Габделвәхид әйтте: «Мин дошман гаскәреннән егет үтергән тугызны санадым, унынчысы үзе булды. Аннан үттем, хәлбуки, ул канына буялган, көлде, хәтта дөньядан аерылды».

## Җәрихур-рахиб

عن يزيد بن جوشب قال : سمعت رسول الله ﷺ يقول : "لو كان جريح الراهب فقيها لعلم أن لإجابته أمه أفضل من عبادة ربه".

Йәзид бине Хәүшәбнең атасыннан риваять кылды. Ул әйтте: «Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм әйтте: «Җәрихур-раһиб фәкыйһ булса, анасын тыңлау, Раббысына гыйбадәт кылудан, әлбәттә, артыграк белер иде».

Риваять ителде, башка берәүдән ишеттем, ул Җәрихнең кыйссасын сөйләде. Җәрих Бәни Исраил эчендә бер рухани булган. Үзенең гыйбадәтханәсендә Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылган. Бер көнне намазда булганда, аның анасы килгән. Анасы әйтте: «Әй Җәрих». Намазы белән мәшгуль булганга, анасына җавап кайтармаган. Анасы әйтте: «Аллаһы сине зиначы хатыннар белән бәлагә калдырсын иде». Ул шәһәрдә бер хатын яшәгән, көннәрдән бер көнне ул хатын үзенең хаҗәте өчен чыккан иде. Бер көтүче аны тотып, Җәрихнең гыйбадәтханәсе янында көчләде. Ул хатын йөкле булды. Шәһәр халкы зина эшен бик олугка санарлар иде. Хатын бала тапкач, бер хатын зинадан бала тапты дип, патшага хәбәр бирделәр. Патша ул хатынны чакырды да: «Бу бала сиңа кайдан булды?» – дип сорады. Хатын әйтте: «Җәрихтән булды. Ул мине көчләде». Патша аңа

җәлладларын җибәрде. Җәрих намазда иде. Җәлладлар күпме эндәшсәләр дә, ул аларга җавап кайтармады. Хәтта гыйбадәтханәсен җимереп, муенына җеп салдылар һәм патшага китерделәр. Патша әйтте: «Син үзеңне габид кылдың да, кешеләрнең хатыннарына тиясең, үзеңә хәләл булмаган нәрсәләргә сузыласың». Җәрих әйтте: «Нәрсә эшләдем?» Патша әйтте: «Син шундый хатын белән зина кылгансың». Җәрих әйтте: «Эшләгәнем юк». Аңа ышанмадылар. Аның хозурына ант итте. Тагын ышанмадылар. Әйтте: «Ана яныма җибәрегез». Анасына җибәрделәр. Анасына әйтте: «Әй әнкәм! Син миңа начар дога кылган идең, Аллаһы синең догаңны кабул итте. Син догаң бәрәкәтендә миңа килгән явызлыкны җибәрү өчен Аллаһыга дога кылсана». Әнисе әйтте: «Әй Аллаһым! Әгәр Җәрихне минем догам бәрәкәтендә тоткын иткән булсаң, аннан күтәр». Җәрих патша янына кайтты һәм әйтте: «Кайда ул хатын, кайда ул бала?» Хатын белән баланы китерделәр. Хатыннан сорадылар, ул: «Әйе, минә шушы кеше минем белән зина кылды». Җәрих баланың башына кулын куйды да: «Сине яраткан Аллаһы хакы өчен хәбәр бирче, атаң кем?» – диде. Аллаһының рөхсәте белән бала телгә килеп: «Минем атам фәлән көтүче», – диде. Хатын моны ишеткәч, хакны икрар кылды, әйтте: «Син дөрес сөйләдең, мин ялганчы булдым. Миңа эшләгән кеше бары фәлән көтүчедер».

Икенче бер риваятьтә, хатын йөкле иде. «Җәрих сиңа кайда иреште?» – дип сорадылар. Хатын: «Агачның астында», – диде. Агач аның гыйбадәтханәсе астында иде. Җәрих: «Мине шул агачка чыгарсагызчы», – диде. Моннан соң агачка әйтте: «Әй агач, сине яраткан Аллаһы Тәгалә белән сорыйм, бу

хатын белән кем зина кылды?» Агачның барча ботаклары: «Көтүче», – диделәр. Соңыннан бармагы белән хатынның корсагына төртте. «Әй бала, атаң кем?» – дип сорады. Хатынның корсагыннан әйтелде: «Мин көтүче баласы». Патша Җәрихтән гозер теләде. Миңа гыйбадәтханәңне алтын белән төзәргә рөхсәт бир, диде. Җәрих: «Юк», – диде. Алай булса көмеш белән, диде. Җәрих: «Юк, әүвәл булган кебек балчыктан сал», – диде.

Ибраһим Мөһәҗир бине Мөҗәһидтән риваять ителде. Ул әйтте: «Һич бала кечкенә чагында сөйләшмәде, мәгәр дүртесе генә: Гайсә бине Мәрьям галәйһиссәләм, сахибул-ухдуд, сахибул-җәрих һәм сахибу Йосыф. Аллаһы Тәгалә Йосыф иясе турында аяте:

﴿ وَشَهِدَ شَاهِدٌ مِنْ أَهْلِهَا ﴾

«Зөләйханың әһеленнән бер шаһид шәһадәт бирде», (Юсуф: 26) – дип.

ЭЧТӘЛЕК


Садака хуҗасын нәрсәдән саклый? . . . . . . . . 3
Рамазан аеның фазыйләтләре . . . . . . . . 9
Ун көннең фазыйләте . . . . . . . . 24
Гашура көненең фазыйләте . . . . . . . . 32
Ирекле рәвештә һәм ак көннәрдә ураза тоту . . . . . . . . 36
Гаиләне тәэмин итү турында . . . . . . . . 44
Кул астында булучыларның хәтерләрен саклау . . . . . . . . 51
Ятимнәргә изгелек кылу . . . . . . . . 56
Зина турында . . . . . . . . 62
Риба . . . . . . . . 68
Гөнаһлар турында . . . . . . . . 74
Мәзлумнар (рәнҗетелүчеләр) турында . . . . . . . . 85
Мәрхәмәт һәм шәфкать . . . . . . . . 93
Аллаһы Тәгаләдән курку хакында . . . . . . . . 101
Аллаһы Тәгаләне искә алу . . . . . . . . 113
Дога бүлеге . . . . . . . . 124
Тәсбих әйтү турында . . . . . . . . 131
Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә салават әйтүнең әҗере . . . . . . . . 136
"Лә иләһә илләллаһ" кәлимәсен әйтү . . . . . . . . 142
Коръәннең фазыйләте турында . . . . . . . . 156
Гыйлем алу фазыйләте . . . . . . . . 164
Гыйлем белән гамәл кылу турында . . . . . . . . 175
Гыйлем ияләре белән утыруның фазыйләте . . . . . . . . 182
Шөкер кылу . . . . . . . . 190
Кәсеп итү фазыйләте . . . . . . . . 200
Ризык ашату һәм күркәм холык . . . . . . . . 214
Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл булу . . . . . . . . 221
Тәкъвалык турында . . . . . . . . 229
Оялу турында . . . . . . . . 238
Ният белән гамәл кылу . . . . . . . . 242
Үз-үзеңә соклану турында . . . . . . . . 250
Хаҗ фазыйләте турында . . . . . . . . 256
Аллаһы юлында сугышуның фазыйләте . . . . . . . . 264
Сугышта сакта тору . . . . . . . . 273
Атышу һәм атка атланып йөрүнең фазыйләте турында . . . . . . . . 276
Сугыш кылуның әдәбе . . . . . . . . 279
Мөхәммәд саллаллаһү галәйһи вә сәлләм өммәтенең фазыйләте турында . . . . . . . . 281

Ир кешенең хатынына карата булган хаклары . . . . . . . . . . 293
Хатынның иренә карата булган хаклары . . . . . . . . . . . . 296
Ике араны төзәтү һәм үпкәләшеп торудан тыю . . . . . . . . . . 300
Авыруның хәлен белергә бару турында . . . . . . . . . . . . . 307
Нәфел намазларының фазыйләте . . . . . . . . . . . . . . . . 314
Намазның камиллеге турында . . . . . . . . . . . . . . . . . 318
Дога кылу турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 325
Мәрхәмәтле, йомшак күңелле булу турында . . . . . . . . . . 337
Сөннәт белән гамәл кылу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 344
Ахирәт өчен кайгыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 351
Кешенең "таңга керүе" хакында . . . . . . . . . . . . . . . . 357
Фикерләү фазыйләте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 363
Кыямәт көненең галәмәтләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 373
Әбү Зәрр разыяллаһү ганһүнең хәдисләре . . . . . . . . . . . 385
Итагать итүдә тырышлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 395
Шайтанның дошманлыгы һәм аның аздыру юлларын белү . . . . . 406
Риза . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 418
Вәгазь бүлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 424
Хикәяләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 428
Үз-үзен саткан егетнең хикәясе . . . . . . . . . . . . . . . 435
Җәрихур-рахиб . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 438
Эчтәлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 441

**Фәкыйһ Әбү Ләйс Сәмәрканди**

**ТӘНБИҺҮЛ ГАФИЛИН**

Китапны басмага әзерләде ***Мөхәммәтьяр Нәҗметдин***
Корректор *Магсумова Н. М.*
Дизайнер *Плахотнюк Н. А.*
Компьютерда битләргә салучы *Шәйхетдинова Г. С.*

Басарга кул куелды 03.09.2004. Форматы $60 \times 90^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 28,0. Тиражы 3000 данә. Заказ К4/191.

ДУП "Полиграфия-нәшрият комбинаты".
420111, Казан шәһәре, Бауман ур., 19.